*Мәдинә Маликова*

# Кызыл гөл

*Романнар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-44
М 19

**Маликова Мәдинә**

Кызыл гөл: Романнар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 414 б.

Сөйгән ярын назга күмеп, бәхет бишегендә генә тибрәтү турында кем генә хыялланмый икән? Әмма бу матур теләкне тормышка ашыра беләбезме без?

Кызганыч, күпләр үзләренең парларына сөюнең татлы шәрабы урынына ачы агу бирәләр. Явызлык теләгәннән түгел, ә бәлки, вөҗдан сафлыгын саклый белмәгәнлектән. Мәхәббәт белән мәкер арасындагы көрәш сызыгы кешеләр йөрәге аша үтә. Бу китап менә шул хакта.

ISBN 5–298–04155–8

© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Маликова Мәдинә, 2005

## Кызыл гөл

R R R

Иртә җәйнең аяз, тыныч көне иде бу. Баюга борылган кояш эре күксел шакмаклардан укмаштырып торгызылган тугызар катлы йортларны, киң, озын юлларны нурга коендырган иде. Урамнарның берсе — башкалардан киңрәге, проспект дип аталганы — сөзәк үр битенә туры килгән. Аның бер ягы тәбәнәгрәк булып, икенче ягындагы озын биналар калкулык өстенә урнашкан, аларның нигезеннән машина юлына таба сөзәк чирәмлек төшә. Калкулыктагы тугыз катлы йортның астын биләп торган зур кибет тирәсендә халык өзелми: якшәмбе көнне кичкә таба күпләр сәбәп табып та, сәбәпсез дә ишегалларына, урамнарга чыгалар.

Әнә кибет ишегеннән алтмышлар тирәсендәге кечерәк буйлы бер карт чыгып килә. Нужа калачын шактый ашаган булса кирәк: тар җилкәләре салынган, коңгырт буйлы костюмы нык таушалган, башындагы аксыл бейсболкасы керләнгән. Ә менә күңеле хуш күренә. Кулындагы кара полиэтилен капчыгы да шактый бүлтәйгән, бер кырыйдан зур сыра шешәсе соры муенын сузган. Бабакай бүген генә пенсиясен алгандыр, мөгаен. Дөнья түгәрәк күренсен өчен, безнең картларга ни кирәк тагын! Һәркайсы әйтер: бәхетнең иң зурысы шушы инде!

Менә ул пыяла ишектән чыкты да кибет каршындагы бетон мәйданчыкка тезеп куелган кызыл пластик өстәл-урындыкларны күздән кичерде. Анда берән-сәрән яшь-җилкенчәк кенә утыра иде. Бабай, теге шешәне урталай бүлеп, тәмләп гәп сата-сата чөмерергә үзенә иш тапмады, күрәсең, күзен кыса төшеп, бетон баскычтан аска таба атлады.

Шул вакыт тротуардан «Адидас» тамгалы зәңгәр спорт костюмы, ак кроссовкалар кигән кара чәчле, нык бәдәнле егет аңа дәште:

— Фирдүс Садиров? — дип, картның чыраена текәлде ул.

— Әйе... Садиров... Фирдүс... Ә син...

Абзый сүзен әйтеп бетерә алмады, егет аңа ыргылды. Тирә-юньдәгеләр аны-моны абайлап өлгергәнче, бабай, тимер култыкса аркылы очып, дыңк итеп чирәмлеккә барып төште. Егет аның артыннан сикерде һәм җан ачуы белән картны типкәләргә кереште.

— Нишлисең? Бу ни хәл?.. Ни ачуың бар миндә?.. — дип, чиктән тыш сызлану һәм тетрәнү аша ыңгырашты бабакай.

— Заһидәне хәтерлисеңме?

— Нинди Заһидә? Каян?..

— Курсташыңны оныттыңмыни? Кадермәтованы! — дип, егылып яткан адәмнең башына каты итеп китереп типте тегесе. — Син илтеп тыктыңмы аны төрмәгә? Синме?

— Каян? Ничек? Тукта! — дип, кан саркыган иреннәре аша мыгырданды карт.

Егет ярсып аны типкәли, сулышына кабып, ярым пышылдау аша Заһидә турында, төрмә турында сорый, аның аяк астындагы карт ике кулы белән башын капларга тырышып бөгелеп килгән дә типкән саен яшел чирәмдә әүмәкләнә иде.

Тротуарда кеше җыелды, арада ирләр да шактый иде, әмма түгәрәкләнеп баскан халык арасыннан һичкем кыйнаучыны тыярга, өлкән яшьтәге кешене якларга омтылыш ясамады. Кәмит күрсәтәләрмени, берни дәшми басып торалар. Ниһаять, бала күтәргән хатынның әчтән ургыган нечкә тавышы һаваны ярып узды:

— Ирләр! Ни карап торасыз?! Үтерә бит хәзер!

Егет, башын борып, җыелган халыкка карады, аннары тагын бер тапкыр картның янтыгына типте дә, иелә төшеп:

— Исеңдә тот, кабахәт стукач! Мин сине җир йөзендә йөртмәячәкмен! Мортазадан булачак синең үлемең! Заһидәнең үчен кайтарам мин синнән! — дип ярсып пышылдады. Аннары, тирә-ягына күз дә салмыйча, эре-эре атлап, чирәмлек буйлап китеп барды. Һәм, йорт почмагыннан борылып, ишегалды ягына кереп югалды.

Шунда гына халык хәрәкәткә килде. Бала күтәргән хатынны янындагы карчык, мөгаен, әнисеДер, шелтәли иде:

— Мондый җирдә авыз ачалармыни? Үзеңә китереп бәрергә дә күп сорамаслар... Аның ишегә ирләр кысылсын әнә!

— Икесе бер шайкадандыр әле! Алар арасына керсәң, башың исән чыкмас, — дип җөпләде карчыкның сүзен янәшәдә торган юантык хатын. — Алар шулай бит хәзер: бергә оешып кеше талыйлар да, харам малны бүлешә алмыйча, бер-берсен үтерешә башлыйлар. Андыйлар белән зиратлар тулган!

— Бу картны кайсы шайка кирәксенер икән? — дип куйды бер ир, әкрен тавыш белән.

— Олысы-кечесе буталып бетте хәзер! Шайкаларны шул олы дигәннәр укмаштыра да инде! Син аның тәкъва кыяфәтенә карама. Күгәрчен булып юри кыланалар. Төпченебрәк карасаң, төрмә кошыдыр әле!

— Берәүне дә тора салып урам уртасында кыйнарга ярамый! — диде балалы хатын. — Әгәр берәр гаебе бар икән, милиция тикшереп ачыкласын да судка бирсен! Кем рөхсәт иткән монда самосуд ясарга?

Хатын, кыйнаучының китеп барганын күреп, тәмам батыраеп китте, җиңеннән тоткан анасыннан ычкынып, баскычка таба атлады.

— «Скорый» чакырырга кирәк! Милицияне дә! Кая монда телефон! — диде ул һәм, баласын күтәргән килеш, кибет эченә кереп китте.

Ә теге карт чирәмдә чалкан ята, башы җайсыз янтайган, мөгаен, һушсыз иде. Бер ир барып аның битен чәбәкләргә кереште, икенчесе кайсы кая таралып яткан ярты ипиен, бербөтен булкасын, яртылаш түгелгән бер пакет сөтен, «Беломорканал» тәмәкесен, асфальтка ук тәгәрәп төшкән сыра шешәсен кара капчыкка тутырырга кереште. Бейсболканы алып, каккалап, шунда ук тыкты. Бераздан абзый кыймшана башлады, иңнәреннән тарта торгач, торып ук утырды һәм, башын тотып, як-якка чайкалды.

— Кузгала аласызмы? — дип сорадылар аннан.

— Әз генә утырып торыйм да...

— «Скорый» чакырдылар анда. Хәзер килеп җитәр.

Бабай яңакларын капшаштырды, пинҗәк кесәсеннән бөгәрләнгән керле кулъяулыгын алып, кан саркыган ирен читен сөрткәләде.

— Нәрсәгә «скорый»... Врачка үзем дә бара алам. Кирәксә...

Һәм ул, янындагы ир кешенең беләгенә тотынып, аягына торып басты.

Халык таралган, тротуарда бер юантык хатын гына басып калган иде. Ни «ашыгыч ярдәм», ни милиция күренмәде. Абзый ир кешегә рәхмәт әйтте дә, авыш чирәмлектә ава-түнә атлап, әле генә егет кереп киткән якка юнәлде. Кибеттән чыгып килгән балалы хатын:

— Туктагыз! Милицияне күтеп алыгыз, ичмасам! — дип кычкырып калды. — Тотсыннар теге бандитны! Җавапка тартсыннар! Ул нинди хәл, көпә-көндез урам уртасында тик торган кешене үтергәнче кыйнау! Яшь кенә үзе! Шундый олы кешегә ташлана бит, ә!

Бабай кулын гына селтәде.

— Менә күрдегезме? — диде юантык хатын. — Әйттем ич мин сезгә. Аларның милиция белән бәйләнәсе килмәс!

Һәм, хаклыгы белән горурлану хисеннән үсеп киткәндәй, кыска чал чәчле башын чөеп, үз сүзенә үзе мөһер суккандай, каты-каты басып китеп барды.

R R R

Мортаза, ашыгып, ишегалды аша узды да күрше урам ягына борылды. Светофорда яшел ут кабынганын да көтеп тормыйча, күксел «Жигули» астына керә язып, спортчыларча җиңел йөгереп юлны чыкты һәм кузгала башлаган автобус эченә сикерде.

Автобус аны, эче тулы кешеләр белән бергә, егерме чакрым ераклыктагы Иске шәһәргә алып китте. Яңа шәһәргә, дөресрәге, Иске шәһәрнең сугыштан соң төзелгән зур гына бистәсенә, ул бүген Садиров дигән бәндәне эзләп махсус килгән иде. Тапты менә. Тик очрашу алдан уйлаганча булмады...

Мортаза автобусның арткы тәрәзәсе янына барып басты. Күп тә үтми урамнар артта калды, күз алдыннан зур экрандагы кебек күкрәп яшәргән табигать манзарасы шуыша башлады. Юл кырыйларына яңа яфрак ярган каеннар, юкәләр тезелеп баскан, урыны-урыны белән алар артында авыл йортларының түбәләре чагылып уза, тәрәзәләр елтырап китә. Ләкин Мортаза боларның берсен дә күрмәде, аның күз алдында әле һаман да бөрешкән карт тора иде. Нинди ямьсез, нинди көчсез ул бичара! Үз-үзен яклап кул да күтәрә алмады!

Ә бит Мортаза аны нык бәдәнле, куркыныч кыяфәтле итеп күз алдына китергән иде. Бүре төслерәк итеп. Андый җанварда исә ерткычларга хас камиллек, үзенчә матурлык булырга тиеш. Бүренең һәр хәрәкәте, гамәле бүречә! Ләкин бу адәм... Кем ул? Бүрегә хас гайрәтнең, кайнарлыкның, хәрәкәтләрендә төгәллекнең, күз карашында аяусызлыкның эзе дә юк бит анда...

Ләкин ничек соң ул үзеннән күпкә көчле, күпкә акыллы кешеләрнең тормышын, хәтта үзе белмәгән-танымаган Мортазаның да язмышын җимерә алган? Күзгә күренми торган нинди кодрәт, нинди көч бар ул бәдбәхеттә? Һич аңлап булмый иде моны.

Бу адәм белән очрашуны Мортаза бөтенләй башкача күз алдына китергән иде. Ничек итеп аның күзләренә текәлеп караячагын, нинди сүзләр әйтәчәген, аннары ничек итеп үч алачагын җентекләп планлаштырып куйган иде ул. Ләкин менә минуты килеп җиткәч, ярсуы ташып чыкты да планнарны оныттырды...

Хәер, барыбер күпмедер үч алынды, хәзер инде ул беркадәр канәгатьлек хисе кичерергә тиеш кебек иде. Ләкин аның урынына күңелне ачыну биләп алды. Кылынган явызлык артык зур, җәзасы исә чагыштыргысыз кечкенә булып тоелды. Уйлар буталды, бугазга тончыктыргыч төер утырды. Малай чакта, Казахстанда, саман йортта яшәгән әбисенә кунакка кайткач, кизәк исеннән шулай булгалый иде.

Уйларына мавыгып, автобусның соңгы тукталышка җиткәнен сизми дә калган икән. Инде хәзер троллейбуска күчеп, Иске шәһәрнең икенче ягына кайтырга кирәк. Ул шунда — сугыш елларында ук хәрби завод эшчеләре өчен салынган ике катлы баракларның берсендә яши иде.

Аның балачагы Казахстанның Семипалатински өлкәсендә үтте. Әтисе — кырым татары, әнисе Заһидә — казан татары. Заһидә иртә вафат булып, малай тугыз яшеннән үги ана кулында үсте. Урта мәктәпне тәмамлагач, армия хезмәтеннән соң бирегә килеп, институтка керде. Ә яшәвен әнисенең бертуган абыйсы янында баракта яшәде.

Мортаза биш ел укып, аннан соң ике ел заводта эшләгән арада, башта җиңгәсе үлеп китте, аннары абыйсы урын өстенә егылды. Ике уллары гаиләләре белән еракта яшәгәнлектән, хастаны карау-тәрбияләү Мортаза җилкәсенә төште. Нык чирләде абыйсы, бик интекте, җиде ай кузгала алмыйча ятып, ниһаять, дөнья куйды. Шулай итеп, аның торагы Мортазага калды.

Күпләр аңа көнләшеп карый, шәһәрдә үз торагың булу зур бәхет инде ул, диләр. Әмма Мортаза үзен бәхетле дип саный алмый. Кайчандыр, ун-унбиш елга чыдаса, шул җиткән дип, аннан-моннан корыштырган бу баракларның гомере күптән узган, әмма аларны җимереп, анда яшәүчеләрне яңа йортларга күчерү турында берәүнең дә уйлаганы юк. Киресенчә, мондагыларның баш очында түбә бар, бөтенләй үз куышы булмаганнарны кайгыртырга кирәк башта, диләр. Унике квадрат метр бер кешегә җитеп ашкан, дигән сылтау белән, Мортазаны заводтагы фатир чиратына да куймадылар. Шулай итеп, бу бүлмә, әлегә ярап торса да, киләчәктә әйбәтрәк яшәргә өметне кискән иде.

Абыйсын җирләгәннән соң, аңа җиңелрәк булырга тиеш иде кебек. Ләкин хаста карау мәшәкатьләреннән арынылса да, күңелне башка авырлык — ялгызлык сагышы изә башлады. Гүяки бүлмәнең почмакларына эчпошыргыч тынлык, өметсезлек кереп оялаган иде.

Моңа өйдәге һәрнәрсәнең соң дәрәҗәдә искереп, какшап, төссезләнеп беткән булуы да сәбәпче иде, билгеле. Ишектән кергәч тә сулдагы «Саратов» суыткычына төртелә язасың. Аннан арырак түрдә, ямьсез соры тумбочка өстендә аклы-каралы «Рубин» телевизоры күксел экранын тондырып утыра.

Уң кулда кием элгече, аннан ары янына килүгә ыңгыраша башлый торган какшау диван, аның астагы дүрт почмагыннан агач шакмаклар тырпаеп чыгып тора. Түр почмакта савыт-саба киштәләре. Тәрәзә буенда арзанлы клеенка белән капланган өстәл. Анда-санда куелган урындыкларның аркаларына кием-салым эленгән.

Бирегә килеп керүгә, күз ихтыярсыздан күңелгә ямь бирерлек берәр нокта, яктылык эзләп, бердәнбер нәрсәгә — тәрәзәгә текәлә. Һәм андагы юан, сырлы тимерчыбыктан корыштырып ясалган тупас рәшәткәгә барып төртелә. Бүлмә беренче катта, соңгы елларда хуҗаларның һәммәсе рәшәткә куйдырды — караклар чамасыз үрчегән, дигән сүз таралгач, куркалар... Мортаза фикеренчә, монда кереп ни урласыннар инде югыйсә. Әмма абыйсының башкалардан калышасы килмәде. Аны аңлап та була иде: хатыны белән икәүләп кырык елга якын заводта эшләп җыйган бөтен байлыгы шушында иде бит. Караклар да фәкыйрьнекен урлауны кулайрак күрә, чөнки байларны талау җиңел түгел, алар үз мөлкәтен саклый белә шул.

Хәзер менә бу рәшәткә Мортазага гел генә төрмә камерасын хәтерләтә торган булды. Бу юлы да ул, кайтып керү белән, акка буялган булса да, эчтән каралып күренгән шул котсыз тимерчыбыкка карады да тешләрен шыгырдатып куйды. Заманында аның әнкәсенең күз нурларын кискән рәшәткәләр дә шушындый булды микән?

Мортаза, зәңгәр курткасын салып, якындагы урындыкка томырды да шыксыз коридорга чыкты, аргы баштагы алты гаиләгә бердәнбер аш пешерү бүлмәсенең ачык ишеге турыннан узып, шулай ук уртак булган юыну бүлмәсенә керде. Тутык баскан калай юынгычка иелеп, краннан учына җылымса, ничектер лайлалы тоелган болганчык су агызды, кызган муенын, арт чүмечен сөрткәләде. Башын күтәреп, күгәрек таплары, чебен эзләре белән чуарланган көзгегә карады. Коңгырт күз төпләре кызарып чыккан, киң борынының канатлары киерелеп тора, чыгынкырак ияге, яңаклары тагын да нык каралган кебек — иртән кырынырга иренгән иде шул.

Ул, аш пешерү ягына кереп, газ плитәсендә су кайнатып алды, чәйнеген күтәреп, бүлмәсенә кереп китте. Ярый әле, коридорда күрше Флераның алты яшьлек малаеннан башка беркем очрамады. Мортазаның берәүне дә күрәсе килми иде.

Чәй дә, май яккан прәннек тә тәмсез тоелды. Ул, йөзен җыерып, чынаягын куйды да урыныннан кузгалды. Диванның тәрәзә ягына караган башы янында мәчет сурәте төшерелгән намазлык белән капланган тартма тора иде. Мортаза намазлыкны алды, аста кечкенә сандык күренде.

Бу сандык — ата-бабадан аңа калган бердәнбер хәзинә, аныклабрак әйткәндә, әнисенең мирасы иде. Аны егеткә, соңгы тапкыр ялга кайткач, әтисе күтәртеп җибәрде. «Кырымга китәргә дип торабыз әле без, улым, — диде ул. — Күчеп йөргәндә әйбер-кара тарала, чәчелә. Үзебезнең дә язмышның ничек буласын белгән юк. Монда — әниеңнең истәлекләре, синдә торуы яхшырак булыр».

Сандыкны Заһидәгә туган ягына кайткач бүләк иткән булганнар. Аларның авылында шундый затлы әйберләр ясый белүче осталар бар икән. Ул үзе, терсәк буе бер тартма кадәр генә булса да, бөтен хасиятен туры китереп, борынгыча итеп эшләнгән. Тышы кызылга буяп, ялтыравык җиз тасмалар белән шакмак ясап уратылган. Ул тасмаларга бизәкләр уелган. Кечкенә йозагында нәни генә җиз ачкычы да бар. Ачып җибәрсәң, эченә тоташ кызыл атлас ябыштырылганын күрәсең. Асылташлар саклый торган затлы тартма диярсең.

Тик Мортазаның әнисенең якут-мәрҗәннәре булмаган шул. Монда фоторәсемнәр, хатлар, төрле төстәге каләм белән язылган берничә дәфтәр генә ята.

Бирегә алып килгәч тә, Мортаза аларны бер кичтә өстән генә караштыргалап, кире салып куйган иде. Шуннан соң шактый вакыт кузгатмады. Үткәннәр белән ныгытып кызыксыныр чагы җитмәгән, андый ихтыяҗ тумаган иде әле, күрәсең. Яшь кешенең үз гамьнәре үзенә җитәрлек.

Ләкин менә өйдә берьялгызы калгач һәм заводта да эш нык сүлпәнләнгәч, вакытны кая куярга белми аптыраган чаклар була башлады. Элегрәк шөгыль күп иде. Заводның клубы гөрләп тора, стадионында төрле ярышлар үткәрелә иде. «Канат» дигән футбол командасы шәһәрдә генә түгел, хәтта Русия турнирларында да катнашып килде, һәм Мортаза анда яхшы уенчылардан саналды.

Хәзер исә клуб буш һәм караңгы, стадион чирәмендә кошлар гына чүпләнеп йөри. Яшь кешегә кая барырга?

Җырдагыча әйткәндә, «утырып уйлар уйладым» диярдәй чаклар ешайды. Һәм уйларның очы узган гомерләргә барып тоташа торган булды. Өстәвенә радио-телевидениедән илдә җитмеш ел буе хакимлек иткән коммунистик режимның гаделсезлекләре, үз халкына карата кылган җинаятьләре турында ачыктан-ачык сөйлиләр, гәзитләрдә дә бу хакта язып торалар. Һәм аларны укыган-тыңлаган саен, Мортазаның да йөрәк түрендәге җәрәхәте ныграк сыкрана торган булды. Аның да әнисе шул гаделсезлекләрне үз башыннан кичергән, мөгаен, шуның аркасында бик иртә дөнья куйган иде бит.

...Хәлбуки әнисенең башта төрмәдә утырып, аннары сөргенгә җибәрелгәнлеге үсмер чакта Мортазаны бик гарьләндерә торган иде. Анаң хөкемгә тартылган, атаң туган иленнән сөрелгән булса, нәсел-ыруың белән мактанып, әйтик, урыс яисә үзбәк балалары кебек кәпрәеп, түш киереп йөри алмыйсың... Коммунистлар партиясе хакимлек иткән чорда гаепсезгә хөкем ителгәннәр миллионлаган булган икән, дип сөйлиләр дә сөйләвен, ләкин бит барыбер шик кала: шәхсән бу кешегә чыннан да нахак бәла ягылганмы, әллә чынлап та берәр кырын эше булганмы? Төрмә юлларын узган кешеләр турында сүз кузгалганда, мондый шикне белдерүчеләр табылып тора иде: «Гаепсездән гаепләнгән, диләр диюен дә, әмма тикшереп карасаң, мөгаен, арты бик үк чиста түгелдер әле! Анда утырганнар бөтенесе берсе өстеннән берсе язган, берсен-берсе батырган!»

Мондый сүзләр Мортазаның бәгыренә бик каты бәрә иде. Газиз әнкәсенең нинди дә булса гаебен түгел, һич юк! — йомшаклыгын белүдән курыкты ул. Ә бәлки, ул да, төрмә газапларына, авыр җәзаларга түзә алмыйча, берәр төрле ярамаган кәгазьгә кул куйгандыр? Һәм шул кәгазь кайда да булса сакланадыр?

Менә шушылай шикләнүе аркасында, әнисенең башыннан ниләр узганын белү чарасына ныгытып керешә алмады Мортаза. Иң газиз кешесенең якты истәлегенә кер табы төшүдән курыкты ул.

Шулай да кайберәүләрнең, кайчандыр гаепләнеп, җәзага тартылган әти-әниләренең, туганнарының «Дело»ларын таптырып, укып чыгулары турында ишетелгәләп тора. Кыюрак егетләр якыннарының исемен аклауны таләп итәләр һәм шуңа ирешәләр дә иде. Ахыр чиктә, Мортаза да моның чарасына керешергә карар кылды.

Моңа вакыт та җитәрлек иде, чөнки менә тагын заводтагы бар халыкны ике атнага түләүсез ялга чыгарып җибәрделәр. Сугыш вакытында ук төзелгән бу завод су асты көймәләре өчен бик катлаулы приборлар эшләп чыгара иде. Хәзерге хөкүмәт су асты көймәләрен кирәксенми, эшләнгән кадәресе өчен дә акча бирми... Кыйммәтле приборлар, калай тартмаларга тутырылган килеш, ишегалларында тау булып өелеп ята. Алга таба да болай барса, меңләгән халыкның кулы — шөгыльсез, табыны иписез калачагын көт тә тор.

Хәлләр болай булганда, күңел ачып йөрисе килми шул. Җитмәсә тагын Мортазаның дус кызы Илүсә дә районга командировкага китеп барды, иртәгә генә кайтачак... Ә аның белән очрашасы, бүгенге хәлләр турында сөйләшәсе бик килә иде егетнең!

...Әйе, нәкъ менә Илүсә китеп барганнан соң, ямансу кичләрнең берсендә Мортаза әнисенең сандыгын актарып карыйсы итте. Чын мәгънәсендә сер сандыгы булып чыкты ул. Бүгенге хәлләрнең башы нәкъ менә шуннан — аның сырлап бизәлгән йозагына нәни җиз ачкычны тыгудан башланды да инде.

Иң элек Мортаза анда булган бар нәрсәне диванга чыгарып салды. Фотоларны җентекләп карап чыкты, дәфтәрләрне зур дикъкать белән укый башлады. Беренчесен ачуга, шигырьгә юлыкты:

Карадагның түбәсенә болыт элә ефәген,
Карадагның итәгенә дулкын бәрә күкрәген.
Газраил алса җанымны җиде ятның җирендә,
Илаһым, кайтар җанымны туган-үскән илемә.
Карадаг болытларының ефәгенә төреним,
Кара диңгез дулкынының бишегендә тибрәлим.

Таныш җыр. Семипалатинскида яшәүче кырым татарларының илен сагынып чыгарган җыры дип белә иде аны Мортаза.

Әмма менә бу юлы дәфтәр битенең астына башка төрле, шәмәхә кара белән язылган сүзләр күзгә ташланды: *«Бу шигыремне мин институтның беренче курсында укыган чакта язган идем. Шушы юллардан күсәк ясап, башыма китереп орырлар дип кем уйлаган?»*

Ничек? Бу шигырь әнисенеке булган, димәк? Ә Мортаза моны әлегәчә белми йөргән?!

Ә «күсәк ясау» дигәне нәрсәне аңлата?

Хәер, монысына артык баш ватып торасы да юк. Мортаза әнисенең кырым татарларын яклап йөргәне өчен җавапка тартылганын әтисенең сөйләве буенча белә иде.

Сандыктан чыккан дәфтәрләрдә исә ул хәлләр хакында берни дә күзгә чалынмады. Сөргенгә җибәрелгән кыз белән иленнән сөрелгән кырым татарыннан торган гаилә, әлбәттә инде, милиция күзәтүе астында булган. Анда инде күңел дәфтәреңә дә теләгәнеңне яза алмыйсың...

Ләкин сүзләрдә генәмени хикмәт?! Битләре саргаеп беткән дәфтәрләрне актарганда, Мортаза әнкәсенең нәзек, назлы, серле тавышын ишеткәндәй булды.

Менә тагын шигъри юллар:

> Тарадым чәчләремне, каралттым кашларымны,
> «Сөям» дигән кеше генә ашады башларымны...

Һәм шул ук битнең астына «Ф. С.ка» дип куелган.

Кемгә киная бу, нәрсәне аңлата? Шул... төрмәгә утыртулары турында сүз бармый микән? Кем ул «Ф. С.»?

Мортаза ашыгып дәфтәрләрне актарып чыкты: «Ф. С.» дигән тагын табылмасмы... Хатларны караштырды. Алар арасыннан конвертсыз кәгазь килеп чыкты. Анда җыр юллары: «Бәгырькәем, рәхәт яшә, миннән аерылгач та...» Монысында да «бәгырькәем» дигән сүз өстендә өстәмә бар: «Вилен бәгърем...»

Яза башлап та тәмамланмаган һәм җибәрелми калган хат булса кирәк иде бу. Кем ул Вилен?..

Соңгы дәфтәрдә моң-сагыш, әрнү турында җырлар, шигырьләр. Тигезле-тигезсез эре хәрефләр белән язылганнар. Гомеренең ахырында, үлем чире белән ятканда язгандыр аларны Мортазаның әнкәсе. Менә арадан «Минем бәхетсезлегем Садиров Фирдүстән башланды...» дигән сүзләр күзгә ташланды.

Һәм шул ук битнең кырые буйлап тигезле-тигезсез язылганы: *«Ф. С.! Кайчан да булса син моның җәзасын алырсың микән? Үчем кайтырмы?»*

Садиров Фирдүс! «Ф. С.»! Иң элек менә шуның эзенә төшәргә кирәк, дип уйлады Мортаза. Һәм берничә көн элек моның чарасына ныклап керeште дә.

R R R

Аны эзләп табу кыен булып чыкмады. Институтның кадрлар бүлегендә кайсы елны кемнәр укыганы, кемнең кая эшкә җибәрелгәне турында бөтен документлар саклана. Мортаза, әнием сездә укыган булган, ул инде мәрхүмә, аның сабакташларын бик күрәсем килә, дигәч, хәленә керделәр, Кадермәтова укыган группаның исемлеген күчереп алырга рөхсәт иттеләр. Анда Садиров Фирдүс тә бар иде... Тик Кадермәтова үзе генә юк, чөнки ул соңгы курска җитә алмаган...

Кадрлар бүлегендә эшләүчеләрдән сораша торгач, ике-өч кешенең хәзерге телефоны да мәгълүм булды. Мортаза шундук аларга шылтыратырга керeште.

Арадан берсе, Фәридә исемлесе, шылтыратучының кемлеген белүгә, өенә чакырды. Ерак барасы да түгел, шәһәр уртасында гына яши икән.

...Ишек ачылуга, Мортаза, сәламенә кушып, хуҗабикәгә кызыл тюльпаннар сузды. Фәридәнең сулган йөзе алсуланып чыкты. Кайчандыр, мөгаен, сары булып, хәзер тоташ агарган, күпертеп куелган сирәк чәчле, ак чырайлы, сылу гәүдәле һәм балаларча нәзек тавышлы бу апа үзе дә назлы чәчкәне хәтерләтте.

— Монысы өчен чын күңелдән рәхмәт, — диде ул. Аннары, башын артка ташлап, янында биегәеп торган егетнең йөзенә бераз сокланып карап торды да: — Гел әниең төсле икәнсең, — дип өстәде. — Әнисенә охшаган ир бала бәхетле була, диләр. Әйткәннәре бардыр инде. Кер әйдә, сал кроссовкаларыңны. Чәй эчәрбез кара-каршы утырып. Әтиебез дә, балалар да эштә. Ә минем бүген мәктәптә дәресем юк. Залга уз. Кунак килгәч әрле-бирле йөрерлек булмасын дип, чәйне залга әзерләдем.

Мортаза як-ягына каранды: бүлмәдә зур шкаф, «Фунай» телевизоры, йомшак диван, кәнәфиләр бик уңайлы итеп урнаштырылган. Шкафның бер ягына бәллүр савыт-саба, затлы чынаяклар, фарфор сыннар тезелгән. Диван-урындык япмалары да, пәрдәләр дә — һәммәсе алтынсу-сарыдан, тәрәзә төбендә кына гөлләре чәчәк атып утыра.

Уртадагы түгәрәк өстәлгә бик затлы табын әзерләнгән. Нәзек туралган сыр, колбаса телемнәре өстендә яшел бөдрә петрушка яфраклары ята, кыйммәтле конфет тартмасы ачып куелган. Һәм, әлбәттә инде, кызыл тюльпаннар, җыйнак, әмма бик затлы бәллүр вазага утыртылып, өстәл уртасына урнашты. Күптәннән мондый тормышны күрмәгән Мортазаның күзләре чагылгандай булды.

Әйе, табын бәйрәмчә иде. Ә менә сөйләшү сагышлы һәм җанны тырный торган булып чыкты.

Фәридә Заһидәнең вафаты хакында ишеткән икән. Ул Мортазаның хәл-әхвәлен, кайсы институтта укыганын, кайда эшләгәнен, ничек яшәгәнен сораштырып алды. Шоколад кәнфитне тешләштереп, куе кайнар чәйне әз-әзләп йоткан арада, Мортаза аның сорауларына кыска-кыска гына җавап бирде дә сүзне әнисенә күчерергә ашыкты.

— Ике генә курс бергә укып калган булсак та, онытмадык без аны, — диде Фәридә. — Ә минем йөрәгем түреннән ул беркайчан да китмәде. Тулай торакта янәшә караватларда йоклый идек бит!

Ашавыбыз да бергә булды! Авылдан килгән бар нәрсәне уртак итеп, бер савытта пешерә идек. Еш кына лекцияләрдән шулхәтле ачыгып кайтабыз, бәрәңге пешкәнне көтәргә сабырлык җитми, суганны турыйбыз да, үсемлек мае белән аш серкәсе сибеп, нык кына тозлап, кара ипи белән сыпырабыз гына... Шуннан да тәмлесе юк иде кебек.

Ул ямансу гына елмаеп куйды.

— Хәзерге яшьләргә сөйләсәң дә аңлашылмый инде ул чактагы хәлләр. Ипие дә җитәрлек түгел иде бит аның... Ә шулай да күңелне төшерми идек. Син шылтыраткач, тагын бер кат карточкаларны карап утырдым әле. Нинди бәхетле булганбыз икән бит без!

Ул җиңел хәрәкәт белән торып басты да күрше бүлмәдән катыргы тышлы зур альбом алып чыгып Мортаза каршына китереп куйды. Альбомның тышына зур итеп кып-кызыл роза чәчкәсе ясалган иде. Эчендә кызгылт катыргы битләргә кара почмаклар белән фоторәсемнәр беркетелгән. Фәридә, урындыгын шуыштырып, Мортазага каршы, өстәл почмагының икенче ягына утырды.

— Ашарга җитми, ә шулай да карточкага төшәргә акча таба идек. Карале, синең әниең көзге янына басып төшкән! Безнең бүлмәдә бу! Менә монда ул караватына утырып тора... Монысы беренче курста чак, монысы икенчедә... Менә без ял паркында... Бусы колхозга бәрәңге алырга баргач төшкәне... Ул елларда студентларны сентябрьдә бер айга авылга эшкә җибәрәләр иде... Сезгә анысы эләкмәгәндер инде, шулаймы? Фотограф үзебезнеке иде безнең. Курсташыбыз Фирдүснең «Зенит»ы бар иде...

— Фирдүс?..

— Әйе, Фирдүс. Садиров. Менә дигән фотограф! Безне гел төшереп торды. Сездә дә саклангандыр бит ул фотолар?

— Мондагыларның барсы да түгел... — диде Мортаза. Чыннан да, кызыл сандыктан чыккан фотолар арасында Заһидәнең көзге каршында, караватында, кызлар белән агачлар арасында төшкәннәре бар, әмма ни сәбәптәндер бөтен группа белән булганнары юк иде.

— Монысы да безнең беренче курста укыган чак, бу мин, ә менә әниең, — дип, ак, сөякчел бармагы белән төртеп күрсәтте Фәридә. — Күр әле, әниеңнең муенында нинди матур ак шарф. Ачык төсләрне ярата иде ул. Чем-ак, кып-кызыл, фирүзәдәй зәңгәр килешә иде аңа. Ә мин күксел, соргылт, сирень төслене яратам. Капма-каршы холыклы идек без... Әниең ут борчасы кебек иде синең. Бер минут тик тормый. Җырны да, биюне дә ул башлый, бөтенебезне бөтереп ала торган иде. Гадел иде, ачык, ярдәмчел иде. Группаның комсомол секретаре...

Фәридә арык куллары белән альбом битен сыпыргалады.

— Ул вакытларны сез бик ачык кына күз алдына китереп тә бетерә алмыйсыздыр. Алтмышынчы елларның ахырын дип әйтүем. Шәхес культы күптән фаш ителгән иде ителүен, ләкин чын ирек бирелмәде. Һич юк! Әгәр сүзең коммунистлар партиясенә каршы дип табылса, бетте баш!

— Кулга алып утыртып куялар идеме? Безнең Семипалатинскидагы кебек?

— Юк, кулга алулар турында ишетелми иде ишетелүен. Хакимият халыкны кулда тотуның яңа ысулларын тапты. Салкын сугыш дигән афәт килеп чыкты, теләсә кайсы минутта башыбызга атом бомбасы килеп төшүе бар дип котны ала башладылар.

Фәридә янә уфтангандай авыр сулады. Аннары ничектер урыныннан кузгалып куеп:

— Арада киң сулыш алып яшәүчеләр дә бар иде, — диде. — Сирәк, ләкин бар иде андыйлар!

Апаның йөзендә соклану, горурлану катыш елмаю яктысы кабынды.

— Синең әниең Заһидә шундыйлардан иде. Аның бабасы шәхес культы елларында репрессияләнгән булган икән. Бөтен милкен алып чыгып киткәннәр, үзен лагерьга, «Беломорканал» төзергә озатканнар. Заһидә бу хакта ачыктан-ачык сөйли иде. Күп еллар узгач кына белдек: репрессияләнгән кешеләрнең балалары безнең группада берничәү булган, ләкин алар моны теш арасыннан чыгармыйлар, яшерәләр иде. КГБ күзенә чалынсаң, киләчәккә барыр юлларыңны бикләп куячаклары һәммәбезгә көн кебек ачык иде чөнки.

Беразга тынлык урнашты. Мортаза, башын игән килеш, үзалдына сөйләнгәндәй:

— Биредә дә шулай булган икән, — дип куйды.

— Ә Заһидә курка белмәде, — дип дәвам итте Фәридә. — Нык уйлана иде ул һәм уйларын башкалар белән уртаклаша иде. Ачылып китеп сөйләшеп утырган чакларда, ачынып: «Бездә авыл халкы гомер-гомергә крепостнойлар хәлендә булды, аларга паспорт та бирелмәде. Шул булдымы гаделлек? Безнең әти-әниләребезне үз иленең гражданы дип тә танымадылар!» — ди торган иде. Мин үзем дә, аннан ишеткәч кенә, әти-әниемне чынлап торып кызгана башладым.

— Алай кыю уйлаучы, сөйләүче арагызда ул берүзе генә идемени соң? — диде Мортаза гаҗәпләнеп.

— Пышын-пышын үзара барыбыз да илдәге тәртип белән ризасызлыкны сиздерә идек инде. Беребезнең дә башына чүбек тутырылмаган, йөрәге дә таш түгел. Сәяси анекдотлар да күп йөри иде. Әмма кесәдән

йодрык янау бер хәл, ә менә йодрыгыңны күтәреп алга ыргылу — бөтенләй икенче... Безнең монда бөтенләй һава алышынмый иде бит. СССР бер тимер койма артында булса, без монда тагын бер тимер капкач астында идек... Дөрес, бер егетебез кыюланып киткән иде китүен. Тәүфикъ исемле. Ул мәктәп елларыннан ук турпоходларга йөргән, төрле яклардан килгән яшьләр белән аралашкан. Ә аларда фикер кайный. Әйтик, Балтыйк буе республикаларында, Украинада яшәүчеләрнең күзләре ачыграк булды, алар анда «Голос Америки» радиосын да тыңлыйлар иде. Җәйге каникулдан Тәүфикъ тагын да ныграк батыраеп килде. СССРның Чехословакияне, Венгрияне, асылда, оккупацияләп торуы турында сөйли, Евгений Евтушенконың шигырьләрен укый... Ләкин Мәскәүләргә яраган безгә ярыймы соң инде! Әгәр шунда Заһидә алып калмаса, башы киткән иде Тәүфигыбызның...

— Ничек алып калды соң аны минем әни?

— Әйтәм ич, комсомол секретаре иде ул. Гөнаһ шомлыгына каршы, Тәүфикъ комсомол билетын югалткан икән. Андый чакта ду кубып җыелыш җыялар, билетсыз калган бичараны бөтен кеше каршына бастырып талкыйлар, соңыннан каты кисәтү чәпиләр иде. Бу юлы да җыелдык шулай. Комсомолның район комитетыннан вәкил булып, уклау йоткандай турыга каткан бер егет килгән, чырае бик караңгы. Баксаң, ул Тәүфикъны комсомолдан куарга ук дип килгән икән. Комсомолдан гына булса ни әйтер идең дә, андыйны институтта да тотмаячаклар иде бит! Эш менә кая таба китте! Райкомга каршы сүз әйтеп булмый, тукмакның үз башыңа төшүе бар, арадан кайберәүләр, авызларында ботка болгатып: «Алай ярамый шул инде... Мондый сүзләр коммунизм төзү эшенә аяк чала...» — дигән кебек сөйләнделәр. Тоталитар режим бу мәсьәләдә бик шәп система булдырган иде бит: үзенә комачау итәрдәй кешене иң элек сабакташларыннан, хезмәттәшләреннән таптата иде ул! Заһидә башын иеп тыңлап утырды-утырды да, кинәт сикереп торып: «Ә мин каршы! — дип ярып салды. — Студентка уйларга ярамыймы әллә? Уйлаганын әйтергә ярамыймы? Әгәр аның фикере дөрес түгел икән, бәхәсләшегез! Үзегезнең хаклы икәнегезне исбат итегез! Югары уку йортына без укырга гына түгел, уйларга өйрәнергә, акыл тупларга килгән!» Әле дә күз алларымда тора. Кара бөдрәләре маңгаена сибелгән, ике бите алланып чыккан, күзләреннән очкын чәчри. Әйе, трибун иде синең әниең... Зур кеше булачак иде!..

Мортаза, йотлыгып, Фәридәнең күзләренә текәлде. Ул әнисен, чибәр, кыю, кайнар йөрәкле әнисен, үзе күргәндәй булды. Менә нинди булган икән ул! Һәммәсе куркып калганда да, дөрес сүзне ярып әйтә торган!

Бу вакыйгалар турында Мортазага моңарчы беркемнең дә сөйләгәне юк иде. Хәер, кем сөйләсен? Әнисе үлгәндә ул бала гына иде, ә әтисе боларны үзе дә белмәгәндер, бәлки.

— Шуннан... ни булды соң? — дип ашыктырды ул Фәридәне.

— Чыннан да, агач башын җил бора, адәм башын сүз бора, дигәннәр... Әгәр дә ул сүз Заһидә кайнарлыгы белән әйтелсә бигрәк тә. Иелгән башлар күтәрелде, йөзләргә нур иңде.

— Сез дә чыгыш ясадыгызмы?

Фәридә тыйнак кына көлемсерәде:

— Юк, минем тавыш бик зәгыйфь бит. Синең әниеңнән күпкә калыша идем. Ә кулымны, әлбәттә, Заһидәне яклап күтәрдем. Райком вәкиле ни тырышса да, Тәүфикъны комсомолдан чыгарттыра алмады. Кисәтү бирү белән чикләнделәр. Шулай итеп, алып калдык без Тәүфикъны.

Фәридә альбомның арткы битләрен ачкалады.

— Бу фотолар — соңгы курсларда төшкәне. Менә Тәүфикъ, иң өске рәттә, укытучылар белән янәшә. Кызыл диплом алган иде чөнки.

Мортаза Фәридәнең ак, сөякчел бармагы төртелгән түгәрәк фоторәсемгә текәлеп карады. Киңчә йөз, тыңлаусыз чәч, үзсүзлелекне, нык ихтыярны, хәтта катылыкны белдергән киң ияк һәм күзләренең җитди, кырыс карашы... Чын ир-егет... Карасана, андыйлар да кызларның яклавына мохтаҗ була икән!..

— Менә монда да бар ул, — дип, альбомның тагын бер битен ачты да олы сымак кыяфәтле, таза гәүдәле абый-апаларның күмәк фотосына күрсәтте Фәридә. — Бусы безнең ун елдан соң очрашкач төшкән карточкабыз. — Группабыз бик дус безнең, элемтәләрне өзмибез, ун ел саен очрашып торабыз. Тәүфикъның да килми калганы юк. Әле менә соңгысында Сочидан кайтып төште. Бер кочак розалар, зур бер тартма көньяк җимешләре белән. Бөтенебезне шаккатырды.

— Кайда соң ул хәзер?

— Мәскәүдә аспирантура тәмамлады, диссертация яклады, ниндидер институтның филиалларына йөреп укыта икән. Канатны киң җәя торган кеше, безнең мондагы тарлык, кысынкылыкка чыдый торган түгел... Ә менә монысы безнең Фирдүс... — Уртадагы сурәтне күрсәткәндә, Фәридәнең кинәт тавышы үзгәреп киткәндәй булды.

Мортаза, комсызланып, сыек чәче кыеклап артка таралган, озынча чырайлы ир кешенең сурәтенә текәлде. Төзек кенә йөзен эчкә баткан тар ияге бозып тора... Аннан да бигрәк күз карашы. Каядыр читкә текәлгән бу караш нәрсәнедер яшерә кебек. Кыскасы, ошамады, сөйкемсез тоелды ул Мортазага.

— Әнинең язмаларында бу исем бар, — диде ул, теш арасыннан кысып.

— Шулаймы? Мөмкин булса... аның миннән сере юк иде...Ниләр язган ул анда?

— Бер генә җөмлә... «Минем бәхетсезлегем Садиров Фирдүстән башланды...» дигән.

— Тәүфикъ та шулай ди шул... Мине дә, Заһидәне дә ул гына саткан, тәгаен белдем, дип сөйләде миңа. Фирдүсне стукач иде, диләр. Ул елларда сексот, дип тә йөртәләр иде. КГБның агенты була инде.

— Студентлар арасыннан ни эзләгән соң ул КГБ?

— Әллә белмисезме, бөтен илләрдә хакимият белән ризасызлык иң элек студентлар арасында тарала. Хөкүмәткә каршы иң алдан шулар кузгала. КГБ алар арасында үзенең кешеләрен булдырмый калмаган инде...

— Сезнең арада күп идеме соң алар?

— Кем белгән? Тәүфикъ белән булган хәлләрдән соң шик туды, әлбәттә. Берсе берәүдән шикләнә, икенчесе бөтенләй бүтәннән... Алай да хәзер инде мин сиңа белгәнемне әйтә алам. Дустым Заһидә хакына...

— Садиров турындамы? — дип сорады Мортаза һәм, тавышы артыграк кискен яңгыраганын үзе дә тоеп, кыенсынып куйды. Тик Фәридә аның соравын табигый кабул итте.

— Әйе, — диде. — Фирдүс турында. Соңгы очрашуга килгәч, Тәүфикъ миңа, безне Фирдүс чаккан булган, тәгаен белдем, диде. Заһидәнең утырып чыккан кеше токымыннан икәнен дә, кырым татарларын яклап сөйләгәнен дә шул җиткергән, диде.

— Минем әнием... Кырым татарларын яклап нишли ала иде соң?

— Син беләсең микән, сугыш елларында иленнән куылган башка халыкларга илленче еллардан соң үз ватанына кайтырга рөхсәт ителгән иде бит инде. Бердәнбер кырым татарларына гына Кырымга күчеп кайту тыелды.

— Нишләп белмәскә! Мин үзем кырым татары! — диде Мортаза, эчке бер горурлык белән. — Асанин мин!

Фәриданең башы иелде. Ул иренен тешләде.

— Син миңа рәнҗемә, — диде аннары. — Мин Заһидәне татарга чыккан дип ишеткән идем. Кайсы татарга, дип сорарга башка килмәгән. Үзебезнең милләт кешесе белән кавышкан икән, дип кенә уйлап куйдым.

—Ялгышканмын, димисездер бит?

Фәридә юк дигәнне белдереп башын селекте.

— Күрәчәгеннән әллә алдан ук сизде микән? — дип сорап куйды аннары уйланып. — Ул бит теге чакта ук кырым татарлары турында шундый матур шигырь язган иде... Әле дә исемдә. «Карадаг болытларының ефәгенә төрелим...» Кырым татарларын яклап, Мәскәүгә хат оештырмакчы иде ул. Хатны озаклап, җентекләп әзерләде. Группаның гомуми җыелышында тикшерик тә, һәммәбез кул куеп, Мәскәүгә җибәрик, дип, бөтенебезне үгетләде. Беркөнне лекцияләрдән соң җыелыш буласын игълан итте. Хыялый иде шул безнең Заһидәбез!

Фәридә хәзер дә исе киткәндәй башын чайкап куйды.

— Нинди карар кабул иттегез соң?

— Булмады ул җыелыш. Соңгы лекция тәмамлануга, һәммәсе кузгалып чыгып киттеләр. Берсенең авылдашы килгән, икенчесенең туганы көтеп тора, монысының башы авырта, тегесенең хәле бетеп тора икән... Заһидә белән икәү утырып калдык шулай. Соңрак Фирдүс сугылып чыкты бугай. Хәтердә шулайрак калган.

— Ә Тәүфикъ? Ул кайда иде?

— Тәүфикъка андый җирләрдә катнашырга ярамый иде. Үзең дә чамалыйсыңдыр. Теге чакта көчкә котылган иде бит. Бу юлы ул миңа алдан ук әйтеп куйды: «Заһидәгә әйт, үпкәләмәсен, мин ул хатка кул куя алмыйм», — диде...

— Ә сез куркып тормагансыз, җыелышка калгансыз бит әле.

— Дөресен генә әйткәндә, мин дә курыктым. Кат-кат үгетләдем Заһидәне. Андый хатны җибәрсәк тә, шәһәрдән дә чыгармаячаклар, мондагы органнар эләктереп алачак, дидем. Кул куйган кешеләрне Тәүфикъ ише генә итмәсләр, белеп тор, дидем.

— Ә ул?

— Бөтен намуслы кешеләр куркып тора торган булса, бу дөньяны тоташ золым басып алачак, диде. Әниең, Габдулла Тукай кебек, бар җиһанны чиста, саф итәргә теләде. Ләкин шагыйрь дә язган бит: «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым», —дигән. Хәерлегә булмас синең бу дуамаллануың, дидем. Дуамалрак иде шул ул!

— Хат киттеме соң? Икегезнең исемнән...

Фәридә, гаҗәпләнеп, Мортазаның йөзенә күз сирпеп алды.

— Син мине гаепләрсең, бәлки, ләкин мин ул хатка кул куймадым. Мин фәкать әниеңне ялгыз калдырырга теләмәдем. Бары шул гына.

— Анысы өчен дә рәхмәт инде!.. Димәк, җыелыш булмый калган, әмма әнинең аны оештырырга тырышуы турындагы хәбәр органнарга барып ирешкән... Кем җиткергәнен дә белгәнсез...

Мортаза альбомның соңгы битендәге карточкага текәлде. Юан гәүдәле апалар, пеләш башлы абзыйлар елмаешып карап торалар. Егерме елдан соң очрашканнарына сөенешкәннәр. Киңәйгән чырайларын җыерчыклар чуарлаган булса да, Мортаза икесен бер күз сирпүдә таныды: Тәүфикъ алгы рәткә, Фәридә белән янәшә урындыкка утырган, Фирдүс урта рәттә, алар артында басып тора иде.

— Заһидә кинәт юкка чыкты бит ул, — дип, бик авырлык белән башын иеп сөйләп китте Фәридә: — Лекциядән соң, ниндидер очрашуга барасым бар, дип, шәһәр үзәгенә киткән иде, шуннан кайтмады. Берәр туганнарында йә танышларында куна калгандыр дип, үзебезне юаттык. Гәрчә аңарчы аның беркайчан да читтә кунганы булмаса да. Ә инде икенче көнне лекциягә дә килмәгәч, деканатка кердек. Декан Васил Кәбирович, авылына шылтыратып белешербез, анда да булмаса, милициядән эзләтербез, диде. Аннары сессия башланды... Аның кулга алынганлыгы шактый вакыттан соң гына, колактан колакка гына килеп иреште. Һәм төрле имеш-мимеш, чыш-пыш китте. Фирдүсне телгә алдылар... Мин ышанмадым. Чөнки ярата иде бит ул Заһидәне! Үлеп гашыйк иде! Беренче курстан ук!

— Гашыйк иде?!

Мортазаның күз алдыннан әнисе дәфтәрендәге җыр юллары сызылып узгандай булды: «Сөям дигән кеше генә ашады башларымны...»

— Ә... әни? — дип сорады ул, шомлангандай агарынып.

— Әниең аны якын да китермәде. Бездә егет кайгысы юк иде әле. Алда ничә ел уку тора иде бит... Фирдүс исә аның артыннан ачыктан-ачык йөрде. Теңкәсенә тиеп бетте.

Фәридә күпертеп куйган чал чәчле башын иеп уйга калды.

— Шикләндем, уйландым, ләкин һич кенә аңлый алмадым, — диде, ниһаять. — Кеше күңеле — кара төн, дигәннәре шулдыр инде... Соңыннан үзе дә үкенде булса кирәк, бик озак уйга батып йөрде. Мин, бер җаен туры китереп, Заһидә турында сүз катып караган идем. Берни белмәгәнгә салышты. «Хәзерге вакытта судсыз-нисез берәүне дә утыртмыйлар, — гына диде. — Берәр төрле аңлашылмаучылык килеп чыккандыр. Ачыкларлар...» Ә көз көне, каникулдан килгәч, Заһидә Казахстанга киткән, шундагы институтка укырга күчкән дигән хәбәр алдык. Барыбыз да җиңел сулап куйдык. Мин, аның адресын сорап, авылына язган идем дә, җавап килмәде. Шулай итеп, бик теләсәм дә, Заһидәнең язмышын белә алмадым.

— Сез Садировның хәзер кайда икәнен беләсезме соң? Элемтәдә тора торгансыздыр бит?

Соңгы җөмләне ничектер астыртын мәгънә, эчке ачыну белән әйткәнен Мортаза үзе дә сизми калды. Фәридә сирәк аксыл керфекләрен сирпеп алды. Күңеле, чыннан да, бик сизгер иде апакайның.

— Юк, мин аның белән аралашмыйм, — диде ул сабыр гына, дустына явызлык кылган адәмне якын итүнең яхшы түгеллеген кем аңламый инде дигәндәй. — Ләкин курсташларны очратканда аның хакында да сүз чыга. Бер очрашканда Тәүфикъ миңа аның озак еллар колониядә тәрбияче булып эшләгәнен әйтте.

— Төрмәдә, димәк?!

— Халыкча әйтсәң, шулай инде. Бездән бер курс түбән укыган берәү, эчкечелеккә бирелеп, урлашуда катнашкан өчен хөкемгә тартылган да шул колониягә эләккән булган. Ирекә чыккач, Фирдүскә бик күп рәхмәтләр укыган, диделәр, чөнки аның ярдәме белән берничә ел алданрак чыккан икән. Кешегә тора салып зыян кыла торганнардан түгел ул Фирдүс. Егылганны таптап үтмәс...

Соңгыларын Фәридә ничектер акланырга теләгәндәйрәк сөйләде. Мортаза, чәй өчен рәхмәт әйтеп, урыныннан кузгалды.

— Аны колониядән табып була, димәк? Кайсы колония инде ул?

— Юк, ул колониядә түгел хәзер. Пенсиядә. Андый урыннарда эшләүчеләрнең стажы башкачарак бара бит, пенсиягә дә алданрак чыгаралар. Моннан бер ел элек хатыны үлгән дип ишеткән идек. Балалары да читтә бугай... Миндә аның телефоны бар. Соңгы очрашуда һәммәсенекен дә язып алган идем. Хәзер.

Ул, китап шкафының бер тартмасын ачып, кечкенә дәфтәрчек алды.

— Садиров... Менә ул. Телефоны, адресы... Хәзер язып бирәм.

Фәридә, иелеп, кәгазь кисәгенә яза башлады. Аның тар җилкәләренә, чаларган кечкенә башына текәлеп карап торган Мортазаның күңелендә каршылыклы хисләр айкалды. Әнисенең яшьлек хатирәләрен саклаган, уртак тәлинкәдән суган салаты ашаган апа күңелгә бик якын иде. Шул ук вакытта бу нечкә хискә ирексездән ризасызлык, рәнҗеш тә килеп кушылды. Егет, тамагына килеп төелгән авыр сулышын сиздермәскә тырышып, борылып, курчак өедәй җыештырылган бүлмәне күздән кичерде. Хуҗа хатынның, шактый төс салган булса да, бик килешле, пөхтә сатин халатына карады. Нинди чисталык, пакьлек!

Беркайда бернинди тап күрмәссең, тузан бөртеге дә юк хәтта. Ләкин ник соң әле күңел ямь тапмый, нилектән монда яшерен бер кер, өстән каплап куелган арусызлык бар кебек тоела?

Инде хушлашып, ачык ишекнең бусагасын атларга әзерләнгәч, Мортаза кинәт борылды да, күзләрен кысып, Фәридәнең йөзенә карады.

— Ә шулай да... Сорамый да булмый... Сез ничек шулай итә аласыз?

Апаның йөзенә аптырау галәмәтләре бәреп чыкты. Дөрес, ул егетнең эчләре тырпайганын сизгән иде инде. Тик үзенә моның сәбәбен яшь аермасы белән аңлатып, мөмкин кадәр йомшак сөйләшергә тырышкан иде. Яшьләргә өлкәннәрне аңлау да, алар белән уртак тел табу да җиңел түгел. Әмма бу соңгы сораудан Фәридә бөтенләй гаҗиз калды.

— Нәрсәне... нишләткән әле без?..

— Ул... бәндәнең шымчы икәнен, курсташларыгыз өстеннән язганын белә торып, ничек сез аның белән бергә укый алдыгыз? Ничек бер табынга утырып бәйрәм итә аласыз?.. Аның белән елмаешып карточкаларга төшәсез?

Фәридәнең башы иелде. Шактый уйланып торганнан соң:

— Тормыш катлаулы бит ул, энем, — диде. — Аны олыгайгач кына аңлый башлыйсың...

— Ул чакта сез миннән дә яшьрәк булгансыз!

Бу юлы инде ризасызлыкка әрнү, рәнҗү ачысы да килеп кушылды.

— Ләкин нәрсәдә гаепли ала идек соң без аны? — дип, эчке бер сызлану белән аның күзләренә текәлеп карады Фәридә. — Ул бит имеш-мимеш кенә, пышын-пышын сөйләнгән сүзләр генә иде. Кешенең чыраена бәреп, син шымчы дип әйтеп буламыни? Әйтәм бит, сез ул вакытларны бөтенләй күз алдына китерә алмыйсыз.

— Курыктыгыз, димәк...

— Әйе, курка идек! Шәхес культы елларында туган балалар шул без. Ана карынында ук курыккан...

— Ә менә бу соңгы карточка?! Егерме елдан соң төшкәне?!

— Егерме елдан соң, өч-дүрт сәгатькә очрашкач, шуның ише бәхәс куптарып буламы? Аннан ни файда?

Мортаза борылып бусага аша атлады.

— Тукта, — дип, аның артыннан чыкты Фәридә. — Рәнҗеп китмә миңа. Шылтырат, яме! Телефонны беләсең.

...Урам буйлап атлаган саен, Мортазаның ачуы көчәя барды. Димәк, аның әнисе белән бергә укыган, янәшә караватта йоклап, бер табактан ашаган кешеләр, ул кулга алынгач, коткару өчен кыл да кыймылдатмаганнар. Аны кара әләк белән төрмәгә тыккан кешегә берәр сүз әйтү түгел, кырын да карамаганнар. Киресенчә, һаман дус күреп, үз итеп яшәгәннәр. Утыз ел буе!

Ничек ул алай? Ничек бу мөмкин?

Бөтен явызлык нәкъ менә шундый астыртын эш йөртүче хаиннәрдән башлана бит! Ул шулай бернинди җәзасыз калырмы? Гаделлекме бу?

Бу сораулар Мортазаның бәгырен утлы тимер кебек көйдерә иде. Ул шундук кулындагы кәгазь кисәгенә язылган адрес буенча Яңа шәһәргә китте.

...Тугыз катлы йортның җиденче катына күтәрелеп, коңгырт төскә буялган ишекнең төймәсенә басты. Эчтә тавыш-тын ишетелмәде. Баскычтан менеп килүче карчык тыны кысылып туктады да:

— Сез Фирдүс Максутовичкамы? — диде. — Әле генә кибеткә кереп китте. Миңа каршы булды.

Мортаза, аска төшеп, кибет ягына юнәлде.

Теге залимгә үзенең кемлеген әйтеп, чыраена туры карамакчы иде. Әнисе хакында теге елны ниләр язганын сорамакчы иде.

Ләкин картның канәгать кыяфәтен күргәч, кинәт мие томаланып китте. Ул, нишләгәнен үзе дә аңышмыйча, баскычка сикерде.

...Һәм менә хәзер, үзенең бу дуамаллыгын аңлаудан гаҗиз булып, кызыл сандык янында утыра. Фоторәсемнән аңа көзге каршына баскан кыз көлеп карап тора. Бәхете ташып, куанычтан балкып! Кем тартып алган аның бу очынуын, талпынуларын? Кем кискән бәхетен? Гомерен кем кыскарткан?

Хәзер инде, бераз суынгач, моңа бер Садиров кына гаепле түгел икәнлекне аңлый башлады Мортаза. Шымчы бит ул кемнәрнеңдер кулында корал гына. Ул ни сөйләмәс тә нәрсә язмас. Төп хикмәт аның сүзен тыңлап, язганнарын укыган кешеләрдә. Мортазаның әнисен кулга алучыларда, аның өстенә нахак гаеп өеп, суд каршына бастыручыларда. Төрмәдә чакта аның исәнлеген какшатучыларда. Әйтә торган иде бит Мортазаның әтисе: төрмә генә кыскартты әниеңнең гомерен, дип.

Менә шул залимнәрне табарга тиеш иде Мортаза. Нишләткәннәр аның әнисен, шуны белергә. Һәм үчен алырга!

R R R

Кибет янындагы чирәмлектә аңына килеп аягына басканнан соң, Фирдүс биек тупыллар, каеннар белән күләгәләнгән ишегалды ягына китте. Каршыдагы тугыз катлы йортның подъездына кереп, җиденче катка күтәрелгәч, калтыранган куллары белән тимер ишекнең йозагына зур ачкычын кертә алмый азапланды.

Ниһаять, фатирына кереп, кулындагы кара букчадагы ипине аш бүлмәсенең таплы өстәленә, сөтне кыршылган «Саратов» суыткычына бушатканда, нишләгәнен аңламады. Сыра шешәсен ачты, аннан пышт иткән тавыш чыкты. Башка вакытта йөрәкне җилкендереп, кәефне күтәреп җибәрә торган бу аваз бүген колакка барып та ирешмәде кебек. Ул, болганчык сары сыекчаны өстәлдәге кызыл этәч сурәте ясалган калын пыяла кружкага койды да голкынып эчә башлады. Әмма башка чактагы кебек тәнгә рәхәтлек хисе таралмады.

Фирдүс артсыз каты урындыкка ишелеп утырды да, терсәкләрен өстәлгә терәп, башын ике учына салды. Кулына дым сыланды. Аның иреннән кан саркый, шешенгән бите-борыны кызышып сызлый, башы шаулый, эче авырта иде.

Әмма барыннан да бигрәк бәгыренә кадалган утлы ук сыкрандыра иде аны. Ул укны кара чәчле, ут күзле егет китереп кадады аңа. Кем ул? Хәер, нигә сорап торырга. Моңарчы беркайчан очрашканнары булмаса да, Фирдүс аны таныды. Заһидәнең улы иде бу. Кайчан да булса килергә тиеш иде ул һәм менә, ниһаять, килде. Синең өчен үч алырга килде, Заһидә!

Хәзер инде син шушы ярсуыннан шашкан егет рәвешенә кердеңмени, Заһидә? Мондый булу килешми сиңа! Бөтенләй башка төрле идең бит син! Күперенке иреннәреңнән елмаю китми, кара бөдрәләрең астында янып торган коңгырт күзләреңдә дәртле очкын сүнми иде. Көлү тавышыңнан, тулы бер кыллы оркестр уйнагандай, тулай торакның коридорлары чыңлап тора иде. Тирә-юнеңә күзгә күренмәс нур тибрәнешләре, тарту көче тарата идең син...

Китапларда язалар бит: «роковая женщина» диләр. Үзенә карата тыелгысыз, акылдан шаштырырлык сөю хисе кузгата торган гүзәл зат. Һәм үзенә гашыйк булганнарны һәлакәткә илтә торган сихер иясе... Кармен! Клеопатра! Андыйлар белән бер сукмакта кара-каршы очрашудан Ходай сакласын!

Ә менә Фирдүсне Заһидә белән очраштырды язмыш... Маңгайга-маңгай бәрелештерде...

Ул теп-тере кебек күз алдына килеп басты. Тик шаулап-көлеп түгел, язгы бер кичтәгечә ачулы, ярсу булып. Хәтер чоңгылында кинәт җанланды да, болай да сызланып торган бәгырьне күзләреннән ургылган ялкын теле белән өтеп алгандай итте. Нәфрәт уты иде бу. Җирәнү катыш күралмау хисе. Башка бүтәннәр бу ачык чырайлы кызның якты, нурлы күзләреннән яшен кебек үтергеч ут бөркелүен күз алдына да китермиләрдер. Фирдүскә генә бәрде ул яшен. Уты аның гына йөрәген көйдерде...

Һәм ярасы бөтен гомергә җитте. Шуның аркасында, фәкать шуның аркасында гына ул мантый алмады.

Фирдүс сары тырнаклы каты бармаклары белән зәңгәр язулы «Беломор» кабын ертты, папирос алып җәрәхәтле иреннәре арасына тыкты, аннары кабызып, олы бүлмәгә керде. Иске диван, какшау өстәл, кечкенә генә кыршылган китап шкафы һәм аның киштәсендәге «Рубин» телевизоры белән җиһазланган бер бүлмәле бу фатир — аның бу дөньядагы соңгы куышы иде. Хатыны вафат булганнан соң, өч бүлмәле фатирны будәргә туры килде, чөнки килен каената белән яшәргә теләмәде. Кырык ел буе армый-талмый хезмәт итүенең әҗере менә шушы булды. Ә бит ул — үзенең ватанына башкалардан икеләтә артык хезмәт күрсәткән кеше!

Һәм менә шулар өчен бирелгән бәя. Очны-очка көчкә ялгарлык пенсия дә эченнән җан җылысы качкан шушы куыш...

Хәлбуки яшьлегендә ул һич кенә дә бүтәннәрдән ким булып калырга теләмәде, киресенчә, бер башка өстен булырга ашкынды! Һәм үзен моңа хаклы дип тә саный иде. Әмма теләгәнчә күтәрелеп булмады. Укуда уртачадан узалмады, кая инде ул гел «бишле»гә укыган Заһидәгә җитү. Шулхәтле алдынгы, энергияле иде ул кыз, сабакташлар, имтиханга керер алдыннан: «Кадерматова байрагы астында алга, җиңүләргә!» — дип шаярта торганнар иде. Инде егетләр белән бил алышып шаярышуларга, спорт белән шөгыльләнүгә килгәндә, Фирдүс ачыктан-ачык көрәшкә чыгарга беркайчан да атлыгып тормады. Чөнки җиңелсә, гарьлегеннән шулхәтле үзен-үзе талый, өзгәләнә, хәтта күзгә күренеп суырылып китә, ябыга иде.

Җиңелү, калышу берәүгә дә куаныч китерми, билгеле. Шуңа күрә һәркем кай ягы белән булса да алдырырга, ягъни кимсенеп яшәүдән саклый торган калкан булдырырга тырыша. Шунда гына ул үзен чын ир-егет итеп тоя ала. Ул калкан — берәүләрдә беләк көче, икенчеләрдә акыл үткенлеге, йә булмаса, җор тел, кешеләрнең күңелен җәлеп итә торган сөйкемле сөяк, ниһаять. Кызганыч ки, язмыш Фирдүскә боларның берсен дә бирмәгән иде.

Шулай да аның өчен андый эчке бер калкан — үзен башкалардан өстен итеп тоярга, хәтта рәнҗеткәннәрдән үч алырга бик үтемле бер чара табылды. Дөрес, аны ачыктан-ачык күкрәк турыңа чыгарып куярга ярамый иде. Бу калкан, Габдулла Тукай шигырендәге таз малайның күлмәк астыннан киелгән подносы кебек эчкә яшерелеп, кимсетү укларын үткәрмәү өчен хезмәт итә иде. Иптәшләре үчекләп кабыргасына төрткәндә, яисә маңгаена чирткәндә, яки шаян сүз белән чеметтереп алганда, ул сабырлык саклый, елмаеп кына җавап бирә. Ләкин аның бу елмаюы эчендә үчен кайтару ышанычы һәм шул ышанычтан туган яшерен тантана ята иде. «Көлегез, көл! Елар чакларыгыз алда әле! Иманыгызны өшкерәм әле мин сезнең!» — ди иде ул эченнән генә.

Һәм бу рәвешле тантана итү, башкалардан өстенлекне тою өчен аңа баш күтәрми китапханәдә утырырга да, тирләп-пешеп гантель уйнатырга да, стадионда туп куарга да, бәгъзеләр кебек, тимер караватның матрасын алып ташлап, җәймә җәеп кенә йокларга да кирәкми иде.

Аның кодрәте каләме очында иде.

Әйе, күзгә-башка чалынмыйча гына билгеләнгән урынга барырга да, теләгәнеңне язып, өстәл артында, каршыңда утырган утызлар тирәсендәге казах кыяфәтле Токтогулов фамилияле абыйга биреп кайтырга...

Нәкъ менә шушы адәм Фирдүскә беркем белән дә бәхәскә кермәскә, узышмаска, көрәшмәскә, киресенчә, һәммәсе белән дус булырга киңәш итеп тора да иде инде. Бу яшерен эш өчен нилектән Фирдүсне сайлап алганнардыр, анысын Токтогуловтан сорап булмый иде, билгеле. Әмма егет үз-үзенә моның сәбәбен, минем ышанычлы, нык рухлы икәнемне күреп алганнардыр, мөгаен, шуңа хезмәттәш итеп сайлаганнардыр, дип аңлата иде.

...Хезмәттәшлек исә Фирдүс өчен көтелмәгәнчә башланды. Беренче курста укыганда, декабрьнең бер кичендә, Фирдүсне тулай торактан чакырып чыгардылар. Тышкы ишек төбендә аны бер ят егет көтеп тора иде. «Сине иртәгә сәгать дүрткә «Совет» кунакханәсенә чакырдылар, — диде ул. — Егерме икенче бүлмәгә. Килми калма! Һәм бу хакта берәүгә дә әйтмә!» Ул ничектер серле итеп, кашларын күтәреп, авызын бүлтәйтеп куйды да, урам яктан ишеккә таба борылган ике егетне күреп, ашыгып китеп барды.

Фирдүс аның артыннан аптырап карап калды. Кунакханәдә кем көтсен инде? Авылдан килгән берәрсе булуы ихтимал. Алай дисәң, авылдаш белән очрашуның кайчан сер булганы бар? Әллә... берәр кызмы? Әйтик, Заһидә булса?.. Бу тиле уй иде, билгеле. Нишләп инде Заһидә аны кунакханәгә чакырсын! Аның коңгырт күзләренең карашы Фирдүс өстеннән шуып кына уза лабаса. Сәламенә дә ничектер аңышмыйчарак кына, әдәп саклап кына җавап бирә.

Хәер, кызларның күңеле эһ дигәнче үзгәрә дә төрләнә бит ул. Бүген болай, иртәгә тегеләй. Бәлки, берәр төрле бәйрәмдер, әйтик, кемнеңдер туган көне... Андый җиргә парлашып бару яхшырак... Бер кичкә генә булса да, Заһидәнең егете булып торсаң, ә?..

Ләкин икенче каттагы пәрдәләре ябылган ярым караңгы бүлмәдә Фирдүсне Заһидә түгел, казах кыяфәтле, таза гәүдәле, кара костюмлы кеше каршы алды. Сәер иде бу, серле иде. Алай гына да түгел, шомлы иде. Ни кирәк бу адәмгә?

— Утыр әйдә, Фирдүс энекәш. Мин Сәет исемле, фамилиям Токтогулов. Сәет абый дисәң дә була, — диде ул, исәнләшкәннән соң. Аның калын тавышы йомшак, ягымлы ишетелде, күзләре көлемсерәп карады. — Синең белән бер мәсьәләдә киңәшеп аласы бар иде.

— Нәрсә турында?

— Синең киләчәгең турында, — диде Сәет, уйлангандай итеп. — Синең үзеңнең генә түгел, барыбызның да, хәтта илнең язмышы турында бераз фикерләшеп алсак каршы булмассың бит? Әллә вакытың юкмы? Берәр кая ашыгасыңмы?

Әмма Фирдүс ашыгам дип кире чыгып китәргә ярамаганын сизенгән иде инде. Студентлар арасында кайберәүләрнең махсус органнар белән бәйләнгән булуы, коммунистлар партиясенә, совет властена каршы ялгыш кына ычкынган һәр кыек сүзне анда җиткереп торуы турында чыш-пыш пышылдашалар иде. Фирдүсне дә, тегеннән сак бул, моның янында авызыңны чамалап ач, дип кисәтүчеләр булгалады.

Үзе дә шыр аңгыра түгел, казах абый ачыктан-ачык әйтмәсә дә, нинди кармакка килеп капканын тиз аңлады ул. Һәм, студентларның үз иптәшләре өстеннән әләк ташыган «стукач»ларга мөнәсәбәтен яхшы белгәнгә күрә, беренче минутта, ничек тә булса шома гына ычкынырга кирәк моннан дип, эченнән генә бик катгый карарга килеп тә куйды.

Абыйның нияте исә һич тә кешеләрне начар юлга тартуда түгел иде кебек. Ул Фирдүснең ничек укуы, ниндирәк фәннәрне яратуы, ата-анасы белән кызыксынды.

— Өлкән буынга бик авырга туры килде шул, сугышны да күрде алар, аннары илнең җимерелгән хуҗалыгын торгызу да алар җилкәсенә төште, — дип көрсенеп куйды абый кеше. — Әтиең сугышта булгандыр бит?

Фирдүснең әтисе Максутның сугыш кырында аягын калдырып кайтканын Токтогулов, мөгаен, белә иде. Алай да әтисенең хәленә керү егетнең күңелен нечкәртеп, әңгәмәдәшенә карашын җылытып җибәрде. Әкренләп кенә сүз әле дә сугышларның тынып тормавына, империалистларның торган саен совет иленә каршы ныграк теш кайравына килеп тоташты. Дошман хәтәр, мәкерле. Ул безнең илне төрле яктан уратып алган. Хәрби базалары көнбатышта да, көньякта да чикләребезгә терәлеп тора. Аларның ниятен алдан белеп тору, аннан да бигрәк халыкның рухи бердәмлеген саклау һәм ныгыту бик мөһим. Атом сугышын булдырмый калу, инде булган очракта дошман явын тиз арада тар-мар итү өчен, илнең һәр намуслы гражданины кулыннан килгәнне эшләргә бурычлы. Безнең разведка, контрразведка шуңа хезмәт итә дә инде. Уңышлы эшләүче бер разведчикның башкарган эшләре кайбер очракларда бөтен бер армиягә торырлык була...

Фирдүс, башка күп малайлар кебек үк, разведчиклар турында күп китаплар укыды, аларның фидакарьлегенә, батырлыгына, зирәклегенә, ныклыгына сокланып туймады. Кемнең генә шундый буласы килмәс икән?

Токтогулов егетнең ниләр уйлаганын-кичергәнен үтәли күреп тора, сүз сөрешен әңгәмәдәшенең йөрәк тибешенә көйләп алып бара иде.

Хәзерге вакытта, дөньяда салкын сугыш барганда, империалистларның аны теләсә кайсы минутта кайнар сугышка әйләндерү ихтималы булганда, разведканың әһәмияте отыры арта бара. Бу өлкәдә эш алып бару өчен безгә нык ихтыярлы, фидакарь, күзәтүчән, игътибарлы, нык рухлы яшьләр кирәк.

...Кунакханәнең караңгы бүлмәсендә булган бу сөйләшү менә хәзер, утыз елдан артык гомер узганнан соң, Фирдүс картның хәтерендә бөтен нечкәлекләре, төсмерләре, күңелдә кузгалган каршылыклы хис-тойгылары белән яңарды. Дөп-дөрес иде Токтогуловның сөйләгәннәре! Фирдүс аларга хәзер дә кул куярга әзер! Шул чорның күпчелек яшьләре шулай уйлый иде! Алай гына түгел, коммунизм төзү өчен, совет властен яклау өчен бөтен көчен, кирәк булса гомерен бирергә әзер иде алар. Шулай түгел иде дип кем әйтә алыр?!

Токтогулов егет күңелендә кузгалган шушы дулкынга атланып алды да алга таба китте. Сугышны булдырмау ул бит әле чикнең теге ягындагы дошманның мәкерле планнарын алдан ук белеп тору дигән сүз генә түгел. Алар безнең илне эчтән таркатуга да ифрат күп көч куялар. Халыкның ышанычын, үзәген, иманын сындыру өчен миллиардлаган акча түгәләр. Америка разведкасы идарәсенең элеккеге башлыгы Аллен Даллесның ниләр язганын беләсеңме?

Юк, Даллесның мәкерле планнары белән Фирдүс аңарчы таныш түгел иде. Баксаң, ул адәм актыгы СССРны эчтән таркатуның ифрат әшәке ысулларын тәкъдим иткән икән. Совет кешеләренең әхлагын җимерергә кирәк, дигән ул. Моның өчен аларга шундый кинофильмнар җибәрергә, шундый китаплар язарга, яшьләрне шундый җырлар белән мавыктырырга кирәк ки, яңа буын үз рәхәте артыннан гына чабарга өйрәнсен, ата-анасын да, ватанын да кайгыртудан бизсен, акчаны-алтынны Алла урынына куйсын. Шуңа ирешсәк, СССРны җиңү өчен безгә атом бомбасы да кирәк булмаячак, ул үзе таркалып бетәчәк, дигән ул хаин. Халыкара империализм безгә каршы көрәшнең нинди юлын сайлаганын аңладыгызмы инде?! Кешенең җанына һөҗүм бара!

Әгәр дә без хәзерге яшьләрнең ни уйлаганын, нәрсәгә омтылып яшәгәнен даими белеп тормасак, оттырачакбыз. Халыкның сулышын ук белеп торырга кирәк безгә. Бу, әлбәттә, кемгәдер кыенлык китерү, зыян салу өчен түгел. Һич юк. Ежов, Берия заманнары, Сталин чоры күптән үтте. Ләкин бер генә дәүләт тә үзенең эчке саулыгын кайгыртмыйча, халыкның уй-фикерләрен белмичә яши алмый.

Боларга каршы ни әйтәсең? Кыскасы, озакка сузылган бу әңгәмәнең ахырына таба Фирдүснең күз карашы яктырды, сыны ныгып, җилкәсе киңәеп киткәндәй булды.

Әлбәттә, күңелнең иң тирән җирендә нәрсәдер тынгысызлап, борчып тора, монда нииндидер бер якка тайпылу, кер табы бар иде шикелле. Ләкин башкалардан өстенлек алу, бик мөһим бер яшерен сергә ия булу тойгысы бу шикне чигендерде...

Аннары тагын шунысы: бу сиңа утыз җиденче ел түгел, хәзер берәүне дә, контрлыкта гаепләп, терәп атмыйлар. Ә разведка-контрразведка һәр илдә бар. Андый органнар белән элемтәдә торуның киләчәк өчен файдалы булуы да ихтимал! Токтогулов моны ачыктан-ачык вәгъдә итмәсә дә, киная ясады бит! Димәк, калганы Фирдүснең үзеннән, аның сизгерлегеннән, төгәллегеннән, сер саклый белүеннән торачак!

Бу очрашудан ул ничектер очынып, канатланып чыкты. Шуннан соң алар Токтогулов белән төрле кунакханәләрдә очрашкалый торган булдылар. Икенчеме-өченчеме тапкырында шунысы да ачыкланды: бу шөгыльнең бераз әҗере дә булачак икән әле! Монысы инде дүрт балалы сугыш инвалидының студент улына бер дә артык түгел иде!

Кем аңа таш ата ала? Үз ватанының серен дошманга саткан хыянәтче түгел лә ул! Киресенчә, ил иминлеген кайгырткан патриот!

R R R

Хода шаһит, ул бер генә мәртәбә дә, беркем турында да нахак сүз язмады. Токтогуловның каршына утырып, кәгазьгә тезгәннәре чын дөреслек иде. Һәммәсе кеше алдында кычкырып әйтелгән сүзләр, көлешә-көлешә тыңлаган анекдотлар. Әйтик, менә берсе, Тәүфикъның сөйләгәне, аеруча хәтергә сеңеп калган. Өч яшь егет туйга әзерләнәләр икән, ди. Берсе француз, икенчесе американ, өченчесе урыс егете, ди, боларның. Французның кәләше унсигездә, американныкы кырыкта, урыс егетенең булачак хәләл җефете җитмештән узган икән. «Ни өчен сез нәкъ менә шушы кешене гомерлек яр итеп сайлап алдыгыз? — дип сораганнар, ди, болардан. «Сөйгәнем яшь, чибәр, дәртле, аның өчен җаным фида», — дигән француз. «Булачак хатынымның элекке ире вафат булган, миллионнары аңа калган. Гомерем буе балда-майда йөзеп яшәячәкмен!» — дип җавап биргән американ. «Ә сез?!» — дип гаҗәпләнеп караганнар урыска. «Ә минем кәләшем Владимир Ильич Ленинны үз күзләре белән күргән! Моннан да зур горурлык бармыни?» — дип мактанган урыс.

Фирдүснең дә йөрәген мүк басмаган, боларны язганда ул үзе дә, сез, коммунистлар, чыннан да шундый бит, мин шуны йөзегезгә бәреп әйтә алам дигән сыманрак эчке бер кинәнү кичерә иде. Бу мәсьәләдә Токтогулов аның тезгенен озынга җибәргән иде шул: без сиңа теләсә нәрсә сөйләргә рөхсәт итәбез, партияне, совет властен күпме сүксәң дә гаепләмәбез, тик башкаларның гына теле чишелсен дә эчендәге тышка чыксын дип, очрашкан саен искәртеп торды ул. Коммунистлар партиясенең башында бер аягы белән кабер ягасына баскан, сөрсегән картлар утыруы турында анекдот сөйләүчеләр, авыл халкының соңгы елларга кадәр крепостной хәлендә булуыннан зарланучылар, Чехословакиядә, Венгриядә булган бәрелешләр турында чын дөресен әйтүчеләр хакында язды Фирдүс. Берничә тапкыр Тәүфикъны да телгә алды. Ансыз булмады, чөнки сәясәт турында сүз кузгалды исә, аеруча кызып китүче һәм иң кискен фикер йөртүче шул иде бит.

Ләкин Фирдүс беркемгә дә яла якмады, бары тик күргән-ишеткәннәрен генә язды! Дөрес, бер очракта, фәкать бер тапкыр гына өстәп җибәрелде җибәрелүен...

Моның өчен бик җитди сәбәп бар иде шул. Кайнар хис, йөрәкнең тыелгысыз талпынуы аңарчы үзе дә уйламаган, алдан әзерләнмәгән сүзләрне каләм очыннан койды да куйды.

...Башкалардан яшерен сере, алардан аермалы бер олы максаты — киләчәктә разведчик, ягъни туган илнең берүзе бер армиягә торырлык яклаучысы булу мөмкинлеге Фирдүсне нык үсендереп җибәргән иде. Һәм бу аның Заһидәгә булган мөнәсәбәтендә дә кыюлык өстәми калмады, билгеле.

R R R

...Хәзер исенә төшергәндә, ул чакта артыграк кызып кителгән кебек тоела тоелуын. Ләкин яшьлекнең януларын картлыкның кыршаеп каткан аршыннары белән үлчәп булмыйдыр шул.

Әйе, ярата иде ул Заһидәне! Кем әйтә Таһирдан артык яратучы булмаган дип?! Кем сөйли Мәҗнүн мәхәббәтеннән көчлесе юк дип?! Фирдүс эчендә янган утларның кызулыгын үлчәп караганыгыз булдымы сезнең?

Аның Таһирдан йә Мәҗнүннән аермасы хисләренең зәгыйфьлегендә түгел, ә бәлки, мәгъшукасының Зөһрә йә Ләйлә кебек булмавында иде. Тигезсез мәхәббәт иде бу, ә андый гыйшыкның ачысы бәгырьне бигрәк тә нык талый икән...

Сабыр итмәде түгел Фирдүс, түзде. Сер бирмәскә тырышты. Ләкин гыйшык дигән нәрсә кешенең акылын ала, бөтен ихтыярын сындыра шул ул. Аннары тагын көнләшү дигәне дә бар бит әле. Группада Фирдүс бердәнбер егет түгел, арада кызларны гел үзләренә генә каратып торганнары да бар. Тел бистәсе Тәүфикъны гына ал әнә. Теге чакта, комсомол җыелышында, аны яклап ничек чәчрәп чыкты Заһидә? Гаделлекне яклыйм дип кенә микән? Ә бәлки, күңелендә башка хисләр дә кайныйдыр?

Кыскасы, әле тапмаган да килеш югалтудан курка иде Фирдүс. Лекцияләрдә башы ихтыярсыздан гел Заһидә тарафына борыла, институттан тулай торакка кайтканда, аяклары үзләреннән-үзләре гел аның артыннан атлый иде. Беркөнне кызларның, Заһидәнең янтыгына төртеп: «Бер елмаеп карасана инде шуңа, аннан гына укаң коелмас!» — дип, чырык-чырык көлешкәне колакка килеп иреште. Ах, әгәр дә ул чытлыклар аның эчендә ургыган ялкынны белсәләр икән! Телләре аңкауларына ябышып кибәр иде!

Ахыр чиктә Фирдүс үзенең чигенер җире калмаганын аңлады. Ул барыбер кызны үзенә каратырга тиеш иде.

Чираттагы очрашуда Токтогулов биргән акчаны үзенә тотмады, егетләрне сыйларга бер ярты белән бер пачка «Беломор»лык кына бүлеп алып куйды да калган бөтенесенә «Красная Москва» дигән кыйммәтле хушбуй алды. Май бәйрәме алдыннан иде бу, бүләк бирергә үзенчә бер сылтау да бар иде кебек. Андый

чакта студентлар җыелышып табын да оештырып ала. Заһидә бүлмәсендәгеләр дә бәйрәм өстәле ясадылар, дүрт кызның икесе янына егетләр дә кереп чыкты. Фирдүсне генә чакыручы булмады...

Ә икенче көнне институт залында кичә узды. Гадәттәгечә инде: башта концерт, аннары танцы, ягъни биюләр.

Вальс көе уйный башлауга, Фирдүс зал аша, диварга елышыбрак, бик үк күзгә ташланмаска тырышып, Заһидәгә таба китте. Егетләрнең күбесе вальс бии белми, шунлыктан кызларның да шактые читтә басып кала. Ә Фирдүс ул биюне махсус өйрәнеп куйган иде. Заһидә белән биер өчен. Алай да, урыныңнан кузгалганчы, тагын бераз уйланырга кирәк булгандыр. Заһидә аның белән бик сирәк бии, анда да кызганганга күрә генә ризалашканы сизелеп тора иде. Ләкин әлеге дә баягы шул аякларның акылга буйсынмавы бит... Аннары кичәгә килер алдыннан егетләр белән теге яртыны «сындырып» куйганнар, ул да күңелгә күбәләк канаты куйган иде.

Заһидә исә бу юлы гадәттәгедән дә кырыс кыланды:

— Ял итәм әле! — генә диде дә башын читкә борды. Кара бөдрәләре сирпелеп, алсу, нәфис колак бөтеркесе күренеп китте, алкасының кашы җемелдәп күзне чагылдырды. Нәкъ шундый минутларда, нечкә муенын сузыбрак, йомры ияген чөя төшеп, бөтен торышыннан горурлык бөркеп торганда, Фирдүскә аеруча газиз тоела иде ул...

Кулыннан тотып, зырылдатып тартып китереп, кочаклап аласы иде дә бит... Мең күз алдында тарткалашып булмый... Башны иеп, борылып китүдән башка чара калмады.

Ул залдан ук чыгып китте. Ишегалдында, язгы төннең тынгысыз караңгылыгы кочагында, якты тәрәзәләрдән саркыган дәртле көйләрне тыңлап, ялгызы шактый озак басып торды. Бер-бер артлы өч-дүрт папирос тартты. «Беломор»ны. Аның белүенчә, илнең чын ирләре, аеруча сугыш вакытында утлар-сулар кичкәннәре, нәкъ менә шушы папиросны ярата иде.

Ниһаять, кичә тәмамланды, халык таралыша башлады. Чыр-чу килеп, көлешеп, яшьлек алгысавыннан, бию дәртеннән йөрәкләре җилкенгән кызлар чыкты. Кайбер бәхетле егетләр, җанга якын ярларын култыклап алып, читкә, язгы кичнең хуш исле әңгеренә алып кереп киттеләр. Фирдүскә исә бер төркем кызлар артыннан, бераз ара калдырып, ияреп кайтырга гына калды...

Тулай торакка кайтып җиткәч, ул, батыраеп, караңгылыктан чыкты һәм Заһидәнең каршына барып басты:

— Бер генә минутка мөмкинме?..

— Нәрсә тагын?

Фирдүс кесәсендәге кырлы-сырлы хушбуй шешәсен капшады.

— Бер генә сүз...

— Керә торыгыз, мин хәзер, — диде Заһидә кызларга.

Фирдүс аны терсәгеннән тотып, ишек өстендәге лампа яктысыннан читкәрәк, янәшәдәге тупыл төбенәрәк алып китте. Яшел агачның кәүсәсендә, җан иясенең тамырларындагы кан агышы кебек, дым тибенгәне сизелә, бөреләреннән әчкелтем-татлы сагыз исе аңкый иде.

Фирдүс кабаланып кесәсеннән шакмаклы шешәне чыгарды.

— Минем сиңа бәйрәм бүләгем бар иде, — диде, дулкынланудан сынып киткән пышылдау белән. — Соңардым инде бераз. Ләкин яз дәвам итә бит әле!

Ул бүләген кызның салынып торган учына сонды да, төшеп китмәсен өчен, сул кулы белән аның бармакларын кысты һәм уң кулы белән иңеннән кочып алды. Калтыранган түшен кызның вак бизәкле ситсы күлмәк белән генә өртелгән күкрәгенә терәде, кызышкан авызы белән аның иреннәренә үрелде. Заһидә ычкынырга тырышып тыпырчынды. Фирдүс исә аның саен ныграк елышты, гәүдәсенең бөтен авырлыгы белән аны тупылның кытыршы кәүсәсенә китереп кысты.

— Җибәр!.. Ишетәсеңме, җибәр!.. — дип пышылдады Заһидә, сулышына кабып.

Ә Фирдүс ишетерлек хәлдә түгел, миен кайнар томан урап алган, ул фәкать кызның йөрәк тибешен, кайнар тәне тетрәнгәнен генә тоя, бөтен вөҗүден ләззәткә сусау биләп алган иде.

— Бәйләнмә миңа! Минем синең белән йөрисем килми! — диде Заһидә, шактый ук кычкырып. Фирдүснең авызыннан бөркелгән аракы катыш тәмәке сасысы кызның сулышын кисте, иңнәрен урап алган куллары, өскә ауган гәүдәсе бөтен тәнен келәшчә белән кыскандай итте. Заһидә, коштай иректе җан иясе, бу рәвешле ихтыярын кискәнне, тәненә хуҗа булганны берничек тә кичерә алмый иде. Хәзер еллар ераклыгыннан телескоп пыялалары кебек хиссез, салкын караш белән караганда, Фирдүс үзе дә аңлый моны. Ул бар дөньясын оныткан хәлдә, өзелеп сөйгән ярының тетрәнеп торган кайнар тәнен кочагында тойганда, Заһидә үзен яман төш күргәндәй, өстенә албастылар ябырылып бастырылгандай хис иткәндер. Хисләр уртак булмаса, шулай бит ул. Ләкин ул чакта егет моны аңламады, кыз әйткән сүзләрнең ачы

мәгънәсе аның зиһененә барып ирешмәде. Аннары кызларның юри генә каршы килгән булып кылана торган гадәтен белә иде бит инде. Заһидәне торган саен ныграк кысты ул.

— Җибәр, диләр сиңа, җирәнгеч!

Һәм Заһидә башын агач кәүсәсе кырыннан читкәрәк шудырып артка каерды да Фирдүскә төкерде. Төкерек күзгә туры килде.

Фирдүс, тураеп, куллары белән битен каплады. Аяк астындагы ташка пыяла төшеп ватылганы ишетелде, тирә-юньгә татлы, ләкин артык көчле булганлыктан күңелгә тия торган хуш ис таралды. Бу ис, биткә-муенга, киемгә һәм тупыл бөреләренә май булып сыланып, җиләс һаваның сафлыгын бозган кебек итте.

— Якын киләсе булма бүтән! — диде Заһидә, аклы күлмәгенең түшен төзәткәләп. — Рәтләп әйткәнне аңлый белмәдең инде. Җирәнәм мин синнән!

— Ни дидең син? Нәрсә дидең?

— Кыланмышларың ямьсез синең! — диде, йомшартырга тырышыбрак Заһидә. — Ипле генә йөрсәң, болай ук күңелем кайтмас та иде, бәлки.

Заһидәнең ярсып түгел, чыгырыннан чыгып та түгел, ә эчке бер ышаныч белән, нык итеп, тыныч тавыш белән әйтелгән бу сүзләре Фирдүснең башына бозлы су койгандай итте дисәң, бик үк дөрес булмастыр. Йортка ут капса, янгыннарны сулар сүндерә. Ләкин йөрәккә капкан утлар алай гына сүнми икән шул. Аларга коелган сулар ялкынны күмергә әверелдереп, бәгырьне эчтән көйдерә торган итә икән.

Заһидә бер селтәнү белән аны аяк астына ташлап, өстенә баскандай, тирескә батыргандай итте. Мондый каты басымнан, пружина кебек атылып, егетнең горурлыгы калкып чыкты. Бу гүзәлнең аягы астында туфрак булырга әзер кебек иде ул. Ләкин тапталырга, пычранырга, җирәнгеч булып күренергә?.. Юк инде, анысы булмас!

Кыз ак күбәләк кебек киң канатлы кыска җиңнәрен җилпеп, яктырып торган ишек аша кереп киткәндә, Фирдүс башны әйләндерерлек ис тараткан пыяла ватыкларына баскан килеш торып калды. Шул минутта ул сөю хисенә ниндидер башка бер хис, көчле теләк килеп кушылганын аңлады.

Мин-минлек хисе, үч алу теләге иде бу.

Әйе, бу тәкәббер чибәрнең текә муенын бөгәсе, чөелгән башын идерәсе килде аның. Шушы кечтә бөреләре тулышкан сусыл тупыл төбендә әйткән сүзләре, кыланмышлары өчен үкендерәсе, гафу үтендерәсе килде. Әмма эчендә нинди генә хисләр янса да, ахыр чиктә Заһидәгә начарлык теләмәде ул. Аның язмышын имгәтү, һәлакәткә илтү башына да килмәде! Алла сакласын!

Фәкать бу ак күбәләкне, канатыннан эләктереп, аскарак тартырга гына кирәк иде. Ул да түбәнсетелсен, Фирдүс каршында, аннан да яхшырагы — бөтен кеше алдында башын иеп, гаепле булып басып торсын. Гәүдәсе бөгелсен, кыяфәте бөрешсен, очкынлы күзләренә яшь томаны өртелсен... Акланырга тырышсын ул, ярдәмгә мохтаҗ булсын. Ярдәм итәрдәй кеше эзләсен! Менә шунда Фирдүс бөтенесенең күз алдында торып басып аны яклар, коткарып калыр! Менә кайчан белер ул Фирдүснең кадерен!

Әйе-әйе, Тәүфикъ кебек итәргә кирәк аны! Ул да әнә ничек, дөньяга сыймагандай колачын җәеп, һәммәсе турында үзенә аерым фикер әйтеп йөри торган иде. Колхозга бәрәңге казырга баргач, без монда килеп җирдә казынырга тиеш түгел, югары уку йортына белем алыр өчен кердек, колхоз басуында бил бөгәргә ялланмадык, дип сөйләнеп йөрде. Яшелчә базасына черек бәрәңге белән кәбестә актарырга барудан баш тарта иде. Әмма менә теге комсомол җыелышыннан соң майлагандай булды егет. Колхоз басуында да беренче, яшелчә базасында да. Принципларын би-ик тиз оныттырдылар!

Ә нишләп әле Заһидәнең дә кикриген шул рәвешле шиңдермәскә?.. Башын иеп, кочакка үзе кереп сыенырлык итмәскә?..

Бу юлы Фирдүс, кагыйдәне бозып, язуны алдан хәстәрләп куйды. Булмаганны язмады, нахак гаеп такмады. Азрак кызып китеп, буяулар куертып җибәрелгән иде анысы. Бәхетсез гыйшык утында янган кеше аңлар Фирдүсне. Кадерматованың комсомол дисциплинасын бозучыларны ачыктан-ачык яклавы өстенә, кырым татарларын үз илләренә кайтаруны таләп итеп, югарыга күмәк хат язарга өндәп йөрүе турында язды ул. Фикердәшләрен берләштереп, төркем оештырырга тырыша, дип тә өстәде. Әйе, «төркем оештыру» дигән бу көфер сүз авторучкадан үченең кара тамчысы булып үзеннән-үзе тамды, язучысы сизми дә калды дияргә була.

...Язуны Токтогуловка тапшырганнан соң, бер ун көн ул-бу булмады. Заһидә гадәттәгечә шат күңел белән йөри бирә, Фирдүс тә бераз тынычланган, кызуы басылган иде. Әләгенең хафасыз гына үтеп китүенә бик разый иде ул. Җитмәсә, семестр тәмамланып килә, имтиханнар башланыр чак җиткән. Комсомол җыелышлары җыеп, кемнәрнедер тикшерү вакыты түгел. Шуларны уйлап, ул тәмам тынычланган иде инде.

Ләкин бер иртәне Заһидә лекциягә килмәде. Бүлмәдәш кызлары да аның кайда икәнен белми булып чыкты. Алдагы көнне лекциядән соң кем беләндер очрашырга тиеш булган, шунда киткән җиреннән кунарга кайтмаган. Бәлки, теге кеше авылдан берәр хәвефле хәбәр алып килгәндер дә Заһидә ашыгып кайтып китәргә мәҗбүр булгандыр?

Шулай дип уйларга калды.

Тагын өч көн үтеп, Заһидә зачет тапшырырга да килмәгәч, группадашларның күңеленә пошаман төште. Деканаттан телефон аша авылына шылтыратып белештеләр. Заһидә анда да кайтмаган икән...

Фирдүснең җаны убылгандай булды. Шундук Токтогулов белән очрашырга ашкынды ул. Теге язуны кире алырга. Һич тә булмаса, икенчене язарга. Кадерматовага ачуы кабарган булуын, шуның аркасында арттырып җибәргәнен аңлатырга. Гафу сорарга. Тәүбә итәргә. Кадерматованы гаепләмәүләрен үтенеп ялынырга, ялварырга...

Тик каян табарга соң ул казах абыйны? Алар тагын бер айдан соң, каникул алдыннан гына очрашырга тиешләр иде. Ләкин хәлләр ай буе көтәрлекмени?

Ул туп-туры КГБ бинасына барып керде. Ишекнең эчке ягында, өске катка алып менә торган киң имән баскыч төбендә басып торган төз сынлы сержанттан Токтогуловны сорады. Тегесе, кечкенә өстәлдән кара телефонны күтәреп, кемгәдер шылтыратып алды да чак кына көтәргә кушты. Бераздан өстән, ашыкмый гына атлап — юк, Токтогулов түгел — күк костюм кигән ак чырайлы, утызлар тирәсендәге бер кеше төште. Фирдүснең студент билетын дикъкать белән ачып карады, аннары кемне эзләп килгәнен кабатлап сорады һәм, ягымлы тавыш белән: «Ә ник әле сез аны бирердән эзлисез? — диде. Аның тавышында чын күңелдән гаҗәпләнү чагылды. — Элек кайда очрашсагыз, шунда барырга кирәктер, бәлки». — «Ләкин без тагын бер айдан гына очрашырга сөйләшкән идек...» — «Бик кирәксенгәч, бүген үк барыгыз. Бәлки, юлыгыз уңар. Очрашырсыз. Сау булыгыз».

Чыннан да, Токтогулов кунакханәнең таныш бүлмәсендә утыра булып чыкты.

— Йә, ни әйтерсең? — диде ул, егетнең сәламен дә алып тормыйча.

Фирдүс Заһидәнең югалуы хакында быдырдый башлагач, Токтогуловның киң карасу чыраенда башта аптырау, гаҗәпләнү, аның артыннан ачу чагылды, кысылган күзләреннән пистолет көпшәсе карагандай булды.

— Синең ни эшең бар анда?

— Кинәт юкка чыкты бит... Кая икәнен белмибез...

— Югалганнарны эзләргә милицияме әллә син?

Пәрдәләре корылган ярым караңгы бүлмәдә шомлы тынлык урнашты. Шунда кинәт Фирдүс үзен бөтенләй ят җирдә, чит кеше белән, — юк, нинди кеше булсын! — ниндидер ерткыч хайван белән очрашкандай тойды. Хәер, ерткыч тырнагына түгел, коточкыч зур бер машинаның тәгәрмәчләре арасына кереп кысылган кебек булды ул.

— Исеңдә тот: син кушканны гына эшләргә тиеш. Фәкать үзеңнән таләп ителгәнне генә! Беркайчан да, бернинди сәбәп белән дә мине эзләп йөрмәскә! Аңладыңмы?! — диде Токтогулов, кырыс тавыш белән.

— Мин... соңгы очрашканда биргән теге язу... Бәлки, ялгыш аңларга урын калдырганмындыр... Төгәллек җитмәгәндер...

— Анысын да син кайгыртырга тиеш түгел. Кирәкле урында төгәлләрләр... Ә син иң элек үзең турында уйла! Әгәр дә берәр разведчик бу рәвешле тотнаксыз һәм саксыз кыланса, бөтен агентура тулысынча дошман кулына төшкән булыр иде!

... Бу очрашудан Фирдүс бөтен эче актарылып ташлангандай чыкты. Ул тулай торакка кайтып кергәндә, Заһидәнең язмышын беләләр иде инде: милиция тарафыннан тоткарланган икән, декан старостага шулай дип әйткән.

Аны, әлбәттә, тиз арада чыгарырга тиешләр иде. Һәркемгә мәгълүм бит инде: соңгы елларда органнар законга таянып кына эшли. Ә Кадерматованың законны бозганы юк. Курсташлары, бер-бер аңлашылмаучылык кына килеп чыккандыр, озак тотмаслар, диештеләр дә шуның белән юандылар. Аннары имтиханнар вакыты җиткән иде, һәркемнең үз хәле хәл дигәндәй... Тагын бер айдан каникулга таралыштылар...

Ә сентябрь аенда, укулар яңадан башлангач, Кадерматованың группа исемлегеннән сызылганы мәгълүм булды. Деканаттан документларын үзе соратып алган, диделәр.

Шулай итеп, аны күрү бүтән насыйп булмады. Институтны тәмамлауның ун еллыгына җыелгач, Заһидәнең вафат икәнлеге беленде. Кемдер каяндыр ишеткән, ләкин нидән үлгәнен әйтмәделәр.

Фирдүс, кулга алынуының серен ул үзе белән кабергә алып киткәндер, дип өметләнгән иде... Юк икән, хәтәр сер мирас булып аның улына күчкән икән. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, дигәннәре менә шул буладыр инде.

Тик менә шунысы аяныч: ул чакта Заһидәнеңниләр кичергәне группадашларына билгесез булып калды. Ә Фирдүснең язмышы шактый имгәнде. Студент егетләрнең аңа карауга чырайлары кыйшаеп, күзләре сәер елтырый торган булып китте. Кемдер аның КГБ ишегеннән кергәненме, чыкканынмы күреп калган, «стукач ул, сак булыгыз» дигән сүз җибәргән иде. Ә андый тамга сиңа гомерлеккә тагыла. Койрык булса, кисеп кенә ыргытыр идең дә, монда алай ансат котыла алмыйсың. «Мин КГБ шымчысы дигән сүз — ялган!» — дип кычкырып йөреп булмый. Хәер, берәү дә ул хакта күзеңә туры карап сорамый да бит.

Айлар, еллар үз эшен эшләде, Фирдүс күңелендәге давыллар тынды. Вөждан газабы кичерергә дә артык зур сәбәп юк иде, чөнки Токтогулов белән очрашулар нык сирәгәйде, аннары бөтенләй тукталды. Заман үзгәрде, бөтен илне, халыкны йодрыгында йомарлап тоткан партиянең көче бетте, аның чукмары булган органнарның да хәле мөшкелләнде. Токтогулов кебекләргә эш калмады.

Шулай итеп, Фирдүснең разведчик булырга дигән матур хыялы тормышка ашмады, ул гомерен колониядә тәрбияче булып уздырырга тиеш булды.

Үткән эшкә салават дияргә генә калган иде дә бит...

Каян килеп чыкты соң әле бу егет? Үтерәм, ди бит, җир йөзендә йөртмим, ди. Үтерер дә... Милицияне кисәтеп куярга микән әллә?..

Ләкин нәрсәдер анда барудан тыя иде. Фирдүс канлы йөзен учына салып утыруында булды.

R R R

Җилле, тиз үзгәрүчән көн иде бу. Әле яңгыр сибәләп үтә, әле тагын аязып китә. Иртәдән тимер юл вокзалы тирәсендә болганган Мортазаның да күңеле шушы көн кебек тынгысызланды, һаман алгысаудан туктамады.

Илүсә поездан төшеп трамвайга таба бара иде, каршысына килгән Мортазаны күргәч туктап калды.

— Син ничек монда? Берәр кая китәргә җыендыңмы әллә?

Аның тавышында гаҗәпләнүдән бигрәк куаныч яңгырады, ак йөзендә елмаю балкып, бит очларында сөйкемле уймаклар хасил булды.

— Исәнме-саумы, диген башта... — диде Мортаза. — Китмим беркая да. Сине каршы алам. Кая, бир әле сумкаңны. Җип-җиңел бит бу! Авылдан күчтәнәч биреп җибәрмәделәрмени? Бигрәк саранннар икән!

Ләкин Илүсәнең уенда башка иде:

— Минем нәкъ шушы поезд белән кайтасымны каян белдең соң син?

— Үзең әйткән идең бит, унөчендә кайтам, дип. Бүген өченче поездны каршы алуым. Көнозын сакта тордым дияргә була.

— Башка эшең юкмы әллә?

Эшсезлек-шөгыльсезлекне Илүсәнең җене сөйми, әмма бу юлы юри генә үчекләп сөйләшкәне тавышыннан, елмаюыннан сизелеп тора иде.

— Минем гамьнәр-мәшәкатьләр чамасыз күпкә китте әле, Илүсәкәй-гөлкәй, — диде Мортаза. — Бер башка гына сыярлык та түгел.

— Ә-ә, аңлашылды, башыңны бушатырга килгәнсең икән! — диде үртәп Илүсә.

— Башны гына түгел, күңелне дә! Анысы да тулып ташты! Син ярдәм итмәсәң, хәлем мөшкел!

Илүсә аның сүзләрендәге ишарәне үзенчә аңлады, йөзе алланып чыкканын сиздермәс өчен, башын читкә, якынлашып килгән трамвайга таба борды. Мортаза аның дулкынланып иңенә төшкән көлсу чәчләренә, көрәнсу чалбарлы костюм кигән матур сынына, кыска җиңеннән чыгып күренеп торган, кояшта каралган нечкә беләкләренә сокланып карады.

Алар, халык белән уралып, трамвайга керделәр дә арткы мәйданчыкның почмагына елыштылар.

— Юлың уңдымы соң? — дип сорады Мортаза.

— Барсы да булды. Алты авылга бардым, бөтенесенең җитәкчеләре белән очраштым, сөйләштем.

— Һәммәсе дә проектыңны кабул иттеләрме?

— Ә кая барсыннар? — диде көлеп Илүсә. — Аларның башка чарасы юк.

Соңгы вакытта Илүсә кебек экология белгечләренә авыл җирендәге җитәкчеләрнең дә бик җитди йомышы төшә башлады. Чөнки һәр хуҗалыкның эшчәнлеген экологик яктан нигезләү турында закон чыкты. Ә андый документларны экологлар гына төзи ала. Алар, урынга барып, авылның картасын сызып, котельныйдан чыккан төтеннең, гараж-мастерскойларда аккан бензин-майларның, фермадан чыккан тиреснең күләмен билгеләп, табигатькә ни дәрәҗәдә зыян салынуын ачыклый һәм чистарту юлларын күрсәтә. Әгәр шундый документ булмаса, хуҗалык җитәкчесенә штраф артыннан штраф салалар. Шул рәвешле, авыл кешеләренең тагын бер мәшәкате артты.

Илүсәнең әтисе Илдар Бәдретдинов — журналист, танышлары күп, бу мәсьәләдә дә киңәш сорап аңа килүчеләр булып тора.

Трамвайда халык күп иде, аларны төрле яктан китереп кыстылар. Ләкин бу һич тә бимаза булып тоелмады, киресенчә, тирәли басып торучылар, үзенә бер киртә сыман, алар өчен аулак урын булдырган кебек иде. Сүзләренә колак салучы да, борылып күз салучы да юк — маңгайны маңгайга терәп диярлек баскан килеш, ярым пышылдашып сөйләшеп бару бик тә рәхәт иде. Илүсә көлеп-шаярып үзен кайсы авылда ничегрәк кабул иткәннәрен, җитәкчеләрнең ниндирәк икәнен сөйләде. Күңеле күтәренке иде аның. Һәм акча эшләгәннән генә дә түгел. Ул, хәзерге авылларда да табигатькә бик зур зыян салалар, дип исәпли һәм, әгәр дә күмәк көч куеп тырышсаң, җир-суларның пычранганын чистартып, әлегә кадәр чиста калганын шул килеш саклап булачагына чын күңелдән ышана иде.

Мортаза аның сүзләрен колак читеннән генә шудырып уздыра, күңеленә исә кызның моңлы да, дәртле дә тавышы гына үтә иде. Бу тылсымлы авазны ул нык сусаганнан соң салкын, татлы чишмә суын эчкәндәй йотлыгып тыңлады. Сагынылган, бик сагынылган икән. Ун көн буе күрешмичә ничек түзелгәндер... Һәм, гомумән, Илүсәне күрмичә, аның дөньяда барлыгын да белмичә, егерме җидегә кадәр ничек яшәлгән диген...

Ә бит беренче очрашканда ул бу кызны бөтенләй ошатмаган иде. Хәер, кызлар кайгысы идемени ул чакта!

Заводның тәмам туктап калып, эшчеләрне күпләп кыскарту барган чор иде бу. Цех начальнигының тырышлыгы белән, Мортазаны эштән чыгарып җибәрмәделәр, хезмәт куркынычсызлыгы буенча инженер итеп күчерделәр. Аңа шушы вазифа йөкләнгәч кенә, гөнаһ шомлыгына каршы, бер ай эчендә ике зур фаҗига булды.

...Төнге сменага калган биш слесарьны иртән ачык склад идәнендә тәгәрәшеп яткан хәлендә таптылар. Икесе җан тәслим кылган, өчесе һушсыз иде. Яннарында аунаган калай савытларны һәм тоздан бушаган кәгазь капларны күрүгә, фаҗиганең сәбәбе аңлашылды: «БФ-88» дигән җилемне эчкәннәр болар. Элек тә ишетелгәли, сизелгәли иде: сәрхушләр кул астында бернинди хәмер дә, хәтта техник спирт та булмаган очракларда җилемгә тотыналар, дип. Аңа башта су, аннары тоз салып озак кына болгаталар да сөзәләр... Ләкин моңарчы үлгән кеше юк иде әле.

Ә менә бу юлы эш зурга китте. Шау-шу, ыгы-зыгы купты. Бичараларны «ашыгыч ярдәм» машинасына салып озатуга, төрле оешмалардан вәкилләр килеп җитте... Тотындылар гаеплене эзләргә. Иң беренче итеп, Мортазаның якасына килеп ябыштылар, билгеле. «Хезмәт куркынычсызлыгы буенча инженер ни караган?» Шундук завод лабораториясенә берничә банка җилем белән берничә кап тоз кертеп бирделәр, әлеге тинтәк слесарьлар кыланганны кабатлап эшләргә боердылар. Ак халатлы яшь кызлар тегесен-монысын кушалар, болгаталар, селкиләр. Ә үзләренең күзләре тасырайган, борыннары җыерылган... Шундый да зәһәр сыекча хасил булган ки, аны эчкән бәндәләрнең бөтен гәүдәләре ничек кара кисәүгә әйләнмәгәндер!

Анализ нәтиҗәләре бар гаеп эчкечеләрнең үзләрендә икәнлекне раслый иде. Җилемне эчәргә ярамаганын сабый да белә.

Завод директорының иркен кабинетында тезелеп утырган комиссия членнарының берничәсе уйчан тавыш белән, бик гадиләштереп кенә сөйләгәннәр иде дә, бу көнгәчә күзгә күренмәгән ак халатлы яшь кыз торып басты.

— Гаепне вафат кеше өстенә салу бик ансат ул! Чөнки мәрхүм үзен яклап сүз әйтә алмый! — дип ярып салды. — Оялырга кирәк! Заводта булган үлем өчен җитәкчеләр җавап бирергә тиеш!

Аның нечкә, кискен, хисле тавышы олпат ирләрне сискәндереп куйды һәм Мортазаның баш очында тарала башлаган болытларны куертып җибәрде.

Шәһәрнең экологик контроль бүлегеннән килгән вәкил булып чыкты бу.

— Куркынычсызлык буенча инженер цехта кунып-төнеп ятарга тиешме әллә? — дип сорады Мортаза. — Сакаллы сабыйларга нәнкә юк монда!

— Әгәр эшчеләрегезгә сүзегез үтми икән, нәнкә урынына йөрергә кала, — диде кистереп теге вәкил.

Моңарчы төп гаепне мәрхүмнәрнең үзләренә аударып утырган җитәкчеләр, теге чәчбинең коткысына бирелеп, авызларындагы ботканы бүтән якка болгата башладылар. Мортаза өстендәге болыт куерды, күк күкрәде. Әле дә ярый, яшене каты сукмады — инженер Асанинга шелтә генә чәпеделәр һәм өч айга премиядән мәхрүм иттеләр.

Завод-фабрика җитәкчеләренең һәркайсы әйтер: ул эколог, санитар врач ише белгечләр белән каберең якын булмасын, дияр. Читтән сорашып белеште Мортаза: аны өч айга премиясез калдырган тел бистәсе Илүсә исемле икән. Фамилиясе — Бәдретдинова. Медицина институтының санитария факультетын тәмамлаганнан соң эшли башлавына бер генә ел. «Андыйлардан да көйсезе юк инде, — дип уйлады ул

чакта Мортаза. — Дөньяның рәтен белмиләр, гел китап сүзен генә сөйләп йөриләр. Тиз генә игә китерермен димә! Алар акылга утырганчы күзең күгәрер».

«Игә китерү» дигәндә, экологлар, санитария врачлары хакында йөргән төрле сүзләрне күз алдында тота иде ул. Җайларын таба белсәң, майласаң-көйләсәң, бер ертык-тишекне дә күрмиләр, дип сөйлиләр бит. Һәм күпчелек моны гаепкә дә санамый, чөнки мәсьәләне үзара килешеп хәл кылу ике якка да файдалы: эш кешесенең дә эше өзелми, тикшерүченең дә кесәсе такыр тормый...

Бу Бәдретдинова дигәннәре исә гел дөреслек артыннан гына чаба торган булып чыкты. Ә бит ул шәһәрнең экология иминлеге бүлегендә эшли, димәк, һаман килеп тикшереп торачак, башка тукмак булачак иде.

Дус-ишнең кайберләре, Мортазаның буйдак икәнлеген истә тотып, күз кысып:

— Шуны да көйләү җаен таба алмыйсыңмыни соң?! Күз кунмаслык егет түгел бит үзең! — дип киная ясыйлар, кайсылары, шактый ямьсез итеп, турыдан киңәш бирәләр иде. Алар карашынча, кызның күңелен йомшартырга форсаты да бар, чөнки Бәдретдинованы завод буйлап озатып йөрү куркынычсызлык өчен җаваплы Асанинга йөкләнә иде.

Озын бетон биналар турыннан узып, мазут сеңгән асфальт юллар буйлап янәшә йөргәндә, бу икәү арасында бәхәс туктап тормады. Илүсә завод торбасыннан бөркелгән ялкынлы төтенгә, җирдәге мазут күлдәвекләренә төртеп күрсәтеп нәфрәтләнә, Мортаза исә аның игътибарын юл кырыйларындагы тирәкләргә, дирекция һәм лаборатория биналары каршындагы гөл түтәлләренә юнәлтергә тырыша иде.

Тора-бара Мортаза бу сүз көрәштерүләргә күнегеп киткәндәй булды. Ошата башлады хәтта. Яшәешнең бер кирәкле ягына әйләнде кебек алар. Табынга куелган гәрчич йә керән төслерәк: үзе ачы булса да, ризыкны тәмләндерә.

Ни хикмәт, аларның тәмам дуслашып китүенә тагын бер фаҗига сәбәп булды. Төнге сменада эшләүчеләрнең берсе, вагоннан буш мичкәләр бушатканда, кинәт аңын югалтып, хастаханәгә эләккән. Андагы кизү табиб төн уртасында цех начальнигының өенә шылтыратып йокысыннан торгызган да: «Мичкә белән ни ташыйсыз сез анда? — дип сораган. — Бер эшчегезне безгә китерделәр. Агуланган, хәле бик авыр, тик нәрсә белән агуланганын белми торып дәвалап булмый!» — «Бу — дәүләт сере, аны әйтергә ярамый», — дип җавап биргән тегесе. Табиб кызып киткән, аны аты-юлы белән сүгеп ташлаган ташлавын да, ләкин шуннан ни файда?

Иртәнгә теге бичара җан тәслим кылган иде инде. Мәрхүмнең үлеме турындагы кәгазьгә табиблар «неясная этиология», ягъни үлемгә китергән чирнең сәбәбе ачыкланмаган, дип язып куйганнар.

Гадәттәгечә, гаепләне эзләү башланды. Дөрес, зур комиссия төзеп тормадылар, вакыйгага кагылышы булган берничә кеше генә җыелып сөйләштеләр. Мортаза бу юлы да үзенең баш өстендә күк күкрәр дип шым калган иде. Әмма, ни хикмәттер, монысында Бәдретдинова аның ягына басты.

— Эшчеләр белән инструкцияләр үткәрелгән, кагыйдәләр язылып, стенага эленгән, респираторлар, перчаткалар өләшенгән — кыскасы, инженер башкарырга тиешленең һәммәсе эшләнгән, — диде ул.

Мортазаның эченә җылы йөгерде: дөресен генә әйткәндә, гәрчә бу хакта үзалдына уйларга курыкса да, нәкъ менә Илүсәгә ярар өчен эшен җиренә җиткереп башкара иде ул.

— Ник сез ул матдәнең нәрсә икәнен табибка әйтмәдегез? — дип, цех начальнигына ябырылды Илүсә. — Сезнең бер сүзне яшерүегез аркасында кеше һәлак булган. Сез — үтерүче, беләсегез килсә! Моның өчен судка бирергә кирәк!

— Дәүләт серен саклаган кешене утыртып куйганнары юк әле, — дип мыгырданды өлкән яшьтәге җитәкче.

Бүлмәдәге ирләрнең ник берсе моңа каршы әйтсен!.. «Үзе карасын иде... Саклансын иде...» — диештереп, гаепне мәрхүмнең үзенә сылап калдырдылар.

Утырыш тәмамланып ишегалдына чыккач, Илүсә болдыр култыксасына таянды да иелеп туктап калды. Җилкәләре калтырый, сулкылдап елый иде ул! Мортаза, шаккатып, аның тар иңенә орынды.

— Бер сүз аркасында... Бер сүз... Әгәр табиблар агуның нинди икәнен белсәләр, мөгаен, коткарган булырлар иде... Син беләсеңме, аның ике баласы ятим калган бит... — дип сөйләнде Илүсә. Аннары башын күтәрде дә: — Дәүләт сере дигән ул сүз... бу очракта... бер кешенең гомере киселүгә, ике баланың ятим калуына торамы? — дип сорады. — Әйт, торамы?!

«Йа Алла, күзе күрмәгән кешеләр өчен кем шушылай өзгәләнә инде?» — дип уйлады Мортаза. Һәм кесәсеннән кулъяулыгын капшады. Бу беркатлы кызыкайның битен-күзен сөртеп аласы килә иде аның. Әнә бит, алсуланган нәфис борын яфраклары ничек тетрәнеп тора. Ләкин, беренчедән, егетнең кулъяулыгы керләнгән, йомарланган иде, икенчедән, күңеле нечкәргәнен сиздерәсе килмәде.

— Табиб кеше һәр үлгән артыннан елап калмый, — диде ул. — Күз яшьләрең чишмә булса да җитмәс.

— Табиб дигәч тә... Аларның эчендә җаны юкмы әллә?

Мортазаның табиблар белән якыннан аралашканы юк, әмма монысының җаны бик тә сизгер, күңеле бик нечкә икәнен аңлады. Һәм үзе дә көтмәгәндә:

— Әйдә, мин сине озатып куям, — диде.

Кыз, башын игән килеш, чыгар юлга борылды, Мортаза аңа иярде. Шул көннән соң алар шактый еш очраша торган булдылар.

Әмма әлегә кадәр мөнәсәбәтләр дусларча гына иде. Менә хәзер, агачлар яфрак ярып, шомырт чәчәген коеп, сирень тәлгәшләре ачылгач һәм шул вакыт эчендә ун көнгә аерылып торгач, бу дөньяда икесе өчен генә калыккан бер кояш барлыгы беленде.

Трамвай аларны зур урамның уртасында калдырып китте. Хәзер җир асты юлына төшәргә дә, теге якка чыгып, унбиш минутлап җәяү барырга кирәк. Троллейбуска утырсаң да булыр иде, тик берсенең дә юлны кыскартасы килмәде.

Мортаза сумканы болгап бара, ә Илүсә биек үкчәле туфлиләре белән тиз-тиз атлый.

— Әйдә, бакчага керик тә әнә теге эскәмиягә утырып торыйк әле бераз, — диде Мортаза.

— Кайтып җитәбез бит инде!

— Син ул кайтып җитәсең... Ә мин менә... адаштым әле... Кердем карурманнарга, адаштым бураннарда... Нәкъ минем хакта инде бу җыр.

— Нәрсә булды?

Мортаза авыр сулап куйды.

— Болай аяк өсте генә сөйли торган сүз түгел.

— Әйдә алайса, утырып сөйләшик.

Алар урам чатындагы сирәк агачлы, аркылы-торкылы сукмаклар белән телгәләнгән бакчага керделәр. Кичкә авышкан кояш бөдрә миләшләрнең, кыргый алмагачларның куе ябалдашларын моңсу нурга төргән, бакча уртасындагы түгәрәк түтәлдә соң чәчәк ата торган тюльпаннар, аяз күк гөмбәзенә туйганчы багып калырга тырышкандай, кызыл керфек-таҗларын киң итеп ачканнар — эчтән алтынсу бәбәкләре балкып күренеп тора.

Түтәл тирәли берничә эскәмия куелган. Алар шуның читтәрәгенә, эре яфраклы камыр агачының ышыгына барып утырдылар.

— Син югында мин гел өйдә булдым, — дип башлады Мортаза. — Заводны унбиш көнгә яптылар, вакыт күп иде.

— Инде... Бу шәһәрдә барыр җир тапмаска! — диде Илүсә. — Бәби түгелсең җитәкләп йөрткәнне көтеп утырырга!..

Мортаза, башын салып, бераз тынып торды.

— Мин үткәннәргә сәяхәт ясадым, Илүсә, — диде аннары, эчке бер мәгънә белән.

— Үткәннәргә? — Кызның тавышында сагаю чагылды. — Кемнәр янына?..

— Әниемнең яшьлегенә барып кайтмакчы булган идем. Минем сиңа әнием хакында сөйләгәнем юк иде бит әле.

— Сөйләштердең бит азрак. Чибәр, уңган иде, дидең, укытучы булып эшләгәнен әйттең... Ләкин син тугыз яшеңдә чакта...

Илүсә тукталып калды.

— Әйе, ул үлгәндә, миңа тугыз гына яшь иде, — диде Мортаза. — Ни генә белгәнмен соң мин ул чакта? Урамда малайлар мине ристан малае дип тотып кыйнагач, өйгә кайтып җылый идем. Шунда әти, син берәүгә дә ышанма, әниеңнең гаебе юк, аңа нахак бәла такканнар, дип юата иде. Ләкин сүзен расларлык дәлиле юк иде шул аның... Әниемнең йөз аклыгын раслыйсым килә минем. Ныклы дәлилләр китереп, кире кагып булмаслык итеп исбатлыйсым килә. Һәм алай гына да түгел...

— Нәрсә тагын? — дип сорады Илүсә, аның тавышында ниндидер катылык сизеп.

— Аңа нахак бәла ягып, төрмә газапларына дучар иткән кабахәтләрнең җавапка тартылуын телим. Явызлык җәзасыз калырга тиеш түгел. Үч алынырга тиеш!

— Ничек итеп?!

Мортаза, алтын керфекле кызыл гөлләргә текәлеп, бераз дәшми торды да әкрен генә сөйли башлады. Кызыл сандык, андагы хатлар, истәлекләр турында. Аннары Фәридә белән очрашуы, аннан алып чыккан ризасызлык тойгысы хакында. Һәм әнисен чаккан стукачны эзләп табуын сөйләде ул. Шунда җиткәч, тагын тынып калды.

— Әллә бардың дамы? — диде сагаеп Илүсә.

— Бардым. Һәм үчемне дә алдым...

— Милициягә тотып бирдеңме әллә?

— Нинди милиция? Нишли ала ул мондый очракта? Үзем...

Илүсә, башын күтәреп, киң ачылган күк күзләре белән Мортазаның йөзенә текәлде.

— Ә ничек үч алдың син аннан?

— Ирләр ничек үч ала? Сугып ектым да типкәләдем.

— Типкәләдең?.. Карт кешедер ич ул? Әгәр берәр җире имгәнгән булса?.. Ул чакта... Үзеңне утыртып куячаклар бит, син шуны беләсеңме?

— Имгәнсен! Кадалып китсен! Шул кирәк аңа!

— Бу самосуд! Моның өчен уголовный статья бар!

— Ничәнчесе?

— Закон буенча йөрергә кирәк!

— Закон?! Нәрсә ул закон? Бу илдә андый җаһилләрне җавапка тарта торган гадәт юк һәм булмас та. Гәрчә андыйларның җирдә яшәргә хакы булмаса да! Гаделлек ягыннан караганда...

— Син соң үзеңнең гаделлегеңә чынлап ышанасыңмы?

— Ә син ничек уйлыйсың? Асылда, ул минем бөтен язмышымны имгәткән хәшәрәт. Әниемнең гомере кыска булуы да, мөгаен, шуңа бәйле. Нәрсәдер булган әни белән ул төрмәдә... Ничектер эчтән имгәткәннәр аны... Әти шулайрак сөйли торган иде. Әниеңнең исәнлеген төрмә какшаткан, дия иде.

Илүсәнең йөзе үзгәреп, җитдиләнеп китте.

— Әллә кыйнадылармы икән? — дип сорады ул шөбһә белән. — Шәхес культы чорында төрмәдәге мәхбүсләрне коточкыч җәзаларга дучар итә торган булганнар бит. Ничә китаптан укыдым. Әнә «Колыма хикәяләре» дигән әсәрендә Ибраһим Салахов ниләр язган. Хатын-кызларны ничек газаплаулары хакында Евгения Гинзбургның китабында җан өшеткеч күренешләр бар. Укыгансыңдыр бит?

— Шәхес культының андый котырган еллары узган иде дә бит... Белмим инде... — диде Мортаза сызланып.

— Белмисең, ә хөкем итәсең! Җәзасын да бирә башлагансың! — диде Илүсә, кискен итеп. — Кем әле ул стукач? КГБда аның сүзе белән генә йөргәннәр дисеңме әллә? Һәммәсен дә ничек типкәләп бетерерсең икән?

— Йөрәк түзми бит, кызып кителде...

— Иң элек әниеңнең ниләр кичергәнен беләсе иде, — диде Илүсә уйланып. — Их, әти-әниләрнең дәвамы булып яшибез, аларның нинди утларда янганын белмибез шул без, аңламыйбыз! Әниеңә, мөгаен, сәяси гаеп такканнардыр. Ә беләсеңме, ул елларда репрессияләнгән кешеләрне аклауга ирешеп була бит хәзер. Бик күпләр якыннарының «Дело»ларын яңадан күтәртә.

— Мин дә бу хакта уйлыйм да бит, «Дело»ны аны сораган бер кешегә бирмиләрдер шул. Юлын табарга кирәк.

— Әти белән киңәшеп карыйм әле, — диде Илүсә. — Репрессияләнгән кешеләр турындагы мәкаләләр гәзиткә аның кулы аша уза. Шундый бүлектә эшли ул. Әле күптән түгел генә бер КГБ кешесенең зур язмасын бастырып чыгарышты...

— Әллә үзем сөйләшеп карыйммы?

Илүсә урыныннан торып басты, керфекләре киң ачылган кызыл гөлләргә карап:

— Ашыктырма, — диде. — Һәр эшнең үз җае бар, ботканың да мае бар...

Әти-әнисе янына егет алып кайту — Илүсәнең үзе өчен генә түгел, бөтен гаиләсе өчен бик тә мөһим һәм дулкынландыргыч вакыйга булачак иде. Шуңа күрә ул моңа бик җаваплы карый, үзенә гомерлек пар итеп сайлаган кешене генә бусага аша атлатып кертергә мөмкин дип саный иде. Һәм моңа ике яшь йөрәк бер-берсен аңлашкач, иң зур сүзләр әйтелгәч, вәгъдәләр бирешкәч кенә җөрьәт итәчәк иде ул.

Мортаза аның уйларын сүзсез аңлады. Ул урыныннан кузгалды, кызның сумкасын алды. Алар бакчадан чыгар юлга борылганнар иде, урам якта берничә кешенең бер тарафка борылып туктап калганын күрделәр.

— Салават күпере! Бу ни гаҗәп?!

Мортаза белән Илүсә дә башларын күтәрделәр. Әйе, кантарлы, тынгысыз соргылт, күгелҗем болытлар өстеннән, киң булып дугайланып, бөтен төсләрен ап-ачык балкытып, салават күпере сузылган иде. Һәм шушы җете күпер нәкъ уртасыннан сынган кебек тоела, чөнки киң генә аксыл тасма аны икегә бүлгән иде.

— Өзелгән ич бу! — диде Илүсә, ничектер шомланып. — Болай да була микәнни?

— Минем дә мондыйны күргән юк иде... — диде Мортаза.

Һәм Илүсәнең нечкә беләген учына алды. Аның орынуына кызның нечкә тамырлары сизелер-сизелмәс тетрәнү белән җавап бирде. Йөрәккә дәртле кайнарлык та, шул ук вакытта җан тынычлыгы да агылгандай булды.

R R R

Берничә көннән Илүсә Мортазага яхшы хәбәр китерде. Аның әтисе, үзенең дуслары, белешләре белән бергәләшеп тырыша торгач, Кадермәтованың «Дело»сы белән танышырга рөхсәт алган. Үзенә генә түгел, гаепләнгән кешенең иң якын кешесенә, ягъни бу очракта улына да. Журналист буларак Илдар Бәдретдинов тә мондый эшләр белән бик кызыксына икән, шуңа күрә икәүләшеп барырга тели икән дә, ләкин Мортаза риза булмады. Чөнки әнисенә кагылышлы фаҗигале серләрне иң элек ул үзе генә белергә теләде. Гәзиткә басып чыгару яхшы булырмы аларны, юкмы, анысын соңрак күз күрер, дип уйлады ул.

Мортаза Илүсә биргән телефон буенча шылтыратты, калын, йомшак, ягымлы тавышлы кеше аны сәгать өчкә шәһәр үзәгендәге һәркемгә мәгълүм булган, аскы каты соры гранит белән тышланган мәһабәт бинага чакырды.

Сырлап ясалган бакыр тоткалы имән ишек каршына барып баскач, Мортаза, шашып типкән йөрәген тынычландырырга тырышып, бераз туктап торды... Кайчандыр, нәкъ шушындый кояшлы, ямьле җәйге көнне, Заһидә дә ошбу ишек янына килеп баскан иде һәм, күңелен ирексездән биләп алган шомлану хисеннән хәлсезләнеп, икеләнеп, берничә мизгелгә хәрәкәтсез калган иде. Аннары куркуын басарга тырышып, бөтен батырлыгын җыеп, авыр ишекнең җиз тоткасына тотынган иде...

Һәм менә ничә еллар узганнан соң, аның улы шушы бусага янына килеп басты. Эчтә нәрсә көтә аны? Моңарчы билгеле булмаган нинди серләр ачылыр?

Ул, әнисе төсле үк итеп, тирән сулыш алды да җиз тоткага тотынды. Ишекне ачканда: «Ай-яй, авыр итеп тә ясаганнар инде», — дип уйлап куйды.

Эчке якта төз сынлы постовой тора иде, ул Мортазаның паспортын сорап алды һәм, янәшәсендәге тумбочкадан кара телефон трубкасын күтәреп, кемгәдер шылтыратты. Күп тә үтми каршыдагы киң баскычта күксел костюм кигән ачык чырайлы яшь егет күренде.

— Сез Асанинмы? — диде. — Исәнмесез! Рәхим итегез, узыгыз әйдә.

Икенче катка менеп, биек, киң коридор буйлап бераз баргач, егет, ишекләрнең берсен ачып, Мортазаны эчкә чакырды да:

— Аз гына көтеп торыгыз. Мин хәзер, — дип чыгып китте.

Бүлмәдәге җиһаз: шкафлар, урындыклар да, зур өстәл өстендәге авыр каләм савыты, яшел абажурлы мәрмәр өстәл лампасы да — һәммәсе гадәттән тыш зур булып күренде. Мортаза үзен кечерәеп калгандай тойды, җаны суынып киткәндәй булды. Бәлки, бу — бөтен җиһазның да, такта белән тышланган диварларның да ниндидер карасу-коңгырт төскә буялган булуыннан шулай тоелгандыр.

Егет тиз әйләнеп керде.

— Сез кыенсынып тормагыз, өстәл янына утырыгыз, — диде.

Һәм папканы өстәлгә куйды да ишекне тавышсыз гына ябып чыгып китте.

Мортазаның йөрәге шашып тибә иде. Йа Раббым, менә шундый папкалар аркасында җимерелә микәнни язмышлар, вакытсыз өзелә микәнни гомерләр? Әллә ни калын да түгел үзе...

Тышына номер сугылган, исем-фамилия язылган. Астарак «70 нче статья — «совет властена каршы агитация һәм пропаганда» дигән сүзләр. Аннан аскарак «191 нче статья, беренче бүлек» дип куелган. Монысы ни тагын?! «Милициягә яки халык дружиначысына каршылык күрсәтү». Ни дигән сүз бу? Кемгә каршылык күрсәтте икән яшь кыз бала?..

Мортаза тетрәнгән бармаклары белән кайчандыр ак булып та, күп куллар тотканга күрә соры төскә кергән, ботинка бавына охшаган бәйләвечне чиште.

Катыргы эченә ак җеп белән эреле-ваклы кәгазь битләре тегелгән, алардагы язулар төрле куллардан, төрле төстәге кара белән язылган иде.

Һәм менә бу эшне башлау өчен беренче этәргеч: зәңгәрсу пөхтә кәгазьгә бик төзек, тигез хәрефләр тезелеп киткән. Укырга җайлы итеп, кәгазьнең бер ягына гына, ике биткә сузып язылган. «Бездә тупланган мәгълүматларны тикшергәннән соң, түбәндәгеләр ачыкланды», — дип башланган ул һәм биш пункттан тора. «Кадермәтова коммунистлар партиясенең һәм совет хөкүмәтенең сәясәтен хурлый, хакимиятне аерым кешеләргә һәм милләтләргә карата гаделсезлектә гаепли. Группаның комсомол җитәкчесе булуыннан явыз ният белән файдалана, хөкүмәткә каршы коткы таратучыларны хуплый, яклый. Аларга үзе дә кушыла. Мәсәлән, аның кырым татарларын яклап язган шигыре бар. Бу халыкны Кырымга кайтаруны таләп итеп, имзалар җыярга йөри, оешма тупларга тырыша... Ул үзе шәхес культы чорында хөкем ителгән кеше нәселеннән. Шәхси әңгәмә вакытында ул иминлекне саклау органнарының эш ысулларын яманлады, безгә ярдәм итүчеләрнең кайберләрен белгәнлеген әйтте һәм аларны бөтен халыкка фаш итү белән янады...»

Язуның ахыры Мортазаны сискәндереп җибәрде: «Алда әйтелгәннәрдән чыгып, без түбәндәге нәтиҗәгә килдек: кадрларыбызны саклау һәм органнарның абруен югары тоту зарурлыгын истә тотып,

Кадерматованы бүген үк тоткарларга һәм мәсьәлә ныклап ачыкланганга кадәр сак астында тотарга кирәк дип саныйбыз».

Һәм иң аска «лейтенант Токтогулов» дип кул куелган. Кәгазьгә ниндидер начальниклар «согласен» дип имза салган, рәсми карар чыгарылган.

Лейтенант Токтогулов — менә кем керткән Мортазаның әнисен төрмәгә!

Ә Садиров дигән бәдбәхет кая?.. Мортаза комсызланып, ашыгып кәгазь битләрен актаргалады. Исем-фамилияләр шактый иде. Тикшерүче Сидоров А.Н., Гельмс Э.Б., Канчуров В.Ш. Надзиратель Кузьмина. Анысы «Кадермәтова миңа һөҗүм итте, битемне тырнады, күземне чыгара язды» дип зарланган, сүзләрен табибтан алган белешмә белән ныгыткан. Әһә, 191 нче статья менә каян килеп кергән икән!

Гельмс дигәне табиб булгандыр, ахры, «медицина белешмәсе» язган. Кадермәтова авырып торган икән. Йөрәк белән булса кирәк. Сәбәбе ачыкланмаган — «этиология не выяснена» дип нокта куйган табиб.

Канчуров В.Ш-ның кыска-кыска язулары Кадермәтова белән очраштыруны, аңа әйбер-кара тапшырырга рөхсәт итүне үтенүләрдән гыйбарәт иде. Мортазаның йөрәге, нәрсәдер сизенеп, авырттырып сулкылдап куйды. Әнисенең кәгазьләрендәге Вилен түгелме бу?

Йа Алла, кемнәр генә кысылмаган бер студент кызның язмышына! Нәрсә кирәк булган аларга? Ни ачулары булган анда?

Шушы зобаниларның кайсыннан башланган фаҗига бу? Кем шымчылык иткән?

Папкада андый сорауга җавап юк иде. Токтогуловның язуындагы «бездә тупланган мәгълүматлар» дигән ишарә генә бар. Әйе, КГБ үзенең серләрен саклый белә...

Тукта, тукта, ярсыма, дип, үзен тынычландырырга тырышты Мортаза. Монда әкренләп эш итәргә кирәк. Бер мәртәбә ачу-ярсуыма ирек бирдем бит инде. Шуннан ни мәгънә булды? Ыбыр-чыбыр, вак-төяк белән булышканмын, фәкать шул гына. Ә чын явызлык кылганнар — менә алар! «Бәлки, бер Канчуров дигәне генә минем әниемнең хәлен җиңеләйтергә тырышкандыр. Фәкать ул гына... Аны да эзләп табарга кирәк булыр... Шушы «Дело»дагы тәртип белән барыйм әле мин, — дигән карарга килде Мортаза. — Токтогуловтан башлыйм. Нинди сәер фамилия!»

R R R

Әмма Мортазага Токтогуловны күреп сөйләшү насыйп булмаячак иде. Чөнки казах кыяфәтле ул адәм СССР таркалуга үз ватанына китеп барган иде инде.

Хәер, күрешкән булсалар да, лейтенант аңа чын дөресен сөйләмәс иде. Чөнки Кадермәтова мәсьәләсендә Токтогулов зур гына хата җибәрде. Ул эшли торган системада агентлар белән эшләүнең тегермән ташыдай саллы һәм каты тәртибе бар бит. Сәет исә аннан читкә тайпылды һәм шуның нәтиҗәсендә теге ташның бер чите тырнак очы кадәр генә кителгәндәй булды. Тәртип булган җирдә тәртипсезлек булмый калмый шул ул... Нәтиҗәдә Токтогуловка шактый гына күңелсез минутлар кичерергә туры килде, теге чытлык кыз исә төрмә камерасына ук барып керде.

Тайпылыш бер дә юктан башланды дияргә була. Фирдүснең язуын укыгач һәм аның чыраена дикъкать белән карагач, лейтенант мәсьәләнең асылын бик тиз аңлап алды. Егеткәйнең чибәр кызыкайга күзе кызган, ә тегесе баш бирми, кырәсең. Бу маңка исә мәгъшукасын органнар ярдәмендә өркетмәкче, аннары, хәленә кергәнгә сабышып, яхшатлы булмакчы. Әйе, күсәкнең зурысына ябышкан иде егет! Күтәрә алмаслыгына! Тар гына башына шулхәтле мәкер ничек сыя диген!

Тик баш анда гына түгел, Токтогуловның үзендә дә бар. Һәм ул да ирләр затыннан. Стукачның зиһенен шул дәрәҗәдә чуалткан кыз аны да кызыксындырып җибәрде. Һәм аның башында үзенә бер план туды: башбирмәс чәчбине кармакка эләктерү бер дә начар булмас иде.

Бу урында укучым начар уйлый күрмәсен тагын, Токтогулов һич кенә дә күз күрмәгән кызга кул сузу турында уйламады. Бу мәсьәләдә би-ик талымлы иде ул, теләсә кемгә ябыша торган түгел... Нияте бөтенләй башкада иде аның. Үзалдына шаян елмаеп, тиктормас кыздан агент ясасаң, бер дә начар булмас иде, дип уйлап куйды ул. Нәкъ менә шундыйлардан — кеше күзенә кылчык булып керә торган кызыл авызлардан, тел бистәләреннән нәтиҗәле эшләүче шымчылар чыга да инде. Партиягә, советка каршы сөйләнеп йөрүләреннән дә зыян юк, аларга ияреп бүтәннәрнең теле ачыла, эчтән генә уйлап йөргән көфер фикерләре, җитәкчеләргә булган нәфрәте ургылып тышка чыга. Ә йомыкыйга-тешләккә кем ачылсын да кем серен чишсен?! Аннары кыз булуы да яхшы, егетләрнең уй-хыялларын алардан да оста итеп кем белә ала?!

Яшь студентны, бигрәк тә кыз баланы ризалатачагына, ихтыярын сындырачагына Токтогуловның шиге юк иде. Шундыйны да көйләмәскә, җайламаска тагын!

Менә шунда хаталанды да инде КГБ лейтенанты. Ашыкты, үз-үзенә артык ышанды. Очрашуга чакырганчы, бераз вакыт кызны читтән күзәтәсе, аның хакында, гыйшыктан мие түнгән Фирдүстән генә түгел, башкалардан да сораштырасы иде. Аннан да бигрәк, өстәгеләр белән киңәшеп, фатихаларын алырга кирәк иде. Ә Сәет, аны-моны үлчәп-уйлап тормыйча, үгезнең мөгезенә ябышты — әзерлексез-нисез кызны күзгә-күз сөйләшергә чакырды.

Заһидәне елмаеп, шул ук вакытта зыялыларга хас тыйнаклык, әдәп белән каршы алды ул. Кызның, бусаганы атларга ашыкмыйча, корылган пәрдәләргә текәлеп карап торуын күргәч:

— Сез аңа игътибар итмәгез, эссе бит, кояш күзгә бәрә, — диде. — Керегез, кер. Әллә куркасызмы? Мин кеше ашамыйм!

Күрештеләр. Лейтенант үзен Токтогулов дип таныштырды, Сәет абый дип дәшәрсең, диде.

Фирдүс язганнардан чыгып, Токтогулов бу кызның кайсы кылына чиртергә кирәклеген чамалаган иде инде, шунлыктан нәкъ кирәкле сүзне тапты: Заһидәнең куркак булып күренәсе килми иде. Җебегәннәрне гомергә җене сөймәде! Ул батыраеп эчкә узды һәм ишек янындагы кәнәфигә тураеп утырды.

Токтогулов каршыдагы кәнәфигә урнашты да күнегелгән пластинкасын әйләндерергә кереште: башта әңгәмәдәшенең хәл-әхвәлен сорашты, аннары җай гына дөнья хәлләренә күчте. Империализмның торган саен явызлануы, кайнар сугышның кыза баруы турында сөйләде ул. Аллен Даллесның мәкерләрен ачты. Мондый шартларда илебезнең намуслы яшьләренә бу куркынычка фидакарьләрчә каршы тору кирәклеген, бу фронтта дошманны җиңү өчен бөтен мөмкинлекләрне файдалануның мөһимлеген аңлатырга тырышты.

Ләкин, ни хикмәттер, сөйләгән саен тавышы тоныклана, дәрте сүрелә барганын тойды ул. Әйтерсең лә тыңлаучысы белән ике арада күзгә күренмәс калкан пәйда булган да, сүзләр шуңа бәрелеп, читкә сибелә иде. Ниһаять, Токтогулов туктап калырга мәҗбүр булды. Заһидә, алгарак иелә төшеп, шактый ук кычкырып:

— Аллен Даллесның сәясәтенә каршы торырга, дисез инде, алайса, — диде. — Донос язучы стукачларның саны арткан саен, халыкның әхлагы яхшырыр дип уйлыйсызмы әллә?

Теге күзгә күренмәс калкан артыннан сөңге тондыргандай иттеләрмени! Токтогулов югалып калды. Шунда гына ул кем белән бәйләнгәнен аңлый башлады. Ансат кына игә китереп булмаячак иде кызны. Теге селәгәй Садиров кемгә гашыйк булганын үзе дә белми икән!

Чыпчык кебек кенә булып күренсә дә, батыр рухлы булып чыкты бу Кадермәтова. Ул инде шәхес культының начарлыклары турында белә, аннан да бигрәк гадел, ихлас, кыю булырга кирәк дигән рухта тәрбияләнгән, күп китаплар укып, дөреслекне яклап утка кергән геройларны үзенә үрнәк итеп алган иде. Хәлбуки акылны әдәбияттан гына җыеп, тормышны китап аршыны белән генә үлчәү һәр очракта да файдага түгел. Күп укыган кешенең мие бер якка авышыбрак киткән була шул, нихәл итәсең. Укыган кеше — чукынган кеше, дигәннәре шуны аңлатадыр да инде...

Кыскасы, кара-каршы утырган бу ике әңгәмәдәшнең җеннәре бер-берсенә каршы булып чыкты, һәм, минутлар узган саен, ул җеннәр котыра гына бара иде. Заһидәгә бу адәм мисле ерткыч булып күренде. Кызның йөзеннән кырыслык китмәде, күзләрендә нәфрәт сүнмәде. Бу сәгатьтә ул үзен явызлыкка каршы соңгы тамчы канына хәтле көрәшергә әзер дип тоя иде.

Пәрдәләре корылган ярым караңгы бүлмәнең һавасы кызганнан-кыза барды. Лейтенант үзенең нияте барып чыкмасын, ниһаять, төшенде, үзара аңлаша алмауларына уфтангандай көрсенеп куйды, елмаеп башын чайкады:

— Кызганыч, сез бик күп нәрсәне аңламыйсыз икән әле, — диде. — Без сезне бернәрсәгә дә мәҗбүр итмибез бит. Бу үзенә бер тәкъдим генә. Кабул итмисез икән, бигайбә... Ләкин...

Ул тукталып тын алды.

— Ләкин, — дип дәвам итте аннары, — бернәрсәне күңелегезгә уеп куярга тиешсез: бу очрашу хакында беркемгә дә сүз ычкындырмагыз. Монда сөйләшкәннәр шушы урында онытылсын. Югыйсә...

Заһидә урыныннан сикереп торды:

— Югыйсә нәрсә? Сез миңа янамакчымы әллә? Куркытмакчымы? Үтте инде андый заманалар! Безнең әтиләрнең котын алып торганыгыз да җиткән! Инде бераз иркен сулыш алдык дигән идек. Ә сез әле һаман шундый икән!

— Нинди икән?— дип, урыныннан әкрен генә күтәрелеп, тыныч тавыш белән сорап куйды Токтогулов. Ул йөзенә елмаю галәмәте чыгарган, ә тавышында исә эчке бер зәһәрлек чалымнары бар иде. Заһидә моны сизде, әмма үзенә җебеп төшәргә ирек бирмәде.

— Кешеләрне бер-берсе өстенә өстереп, яла яктырасыз икән! Мин әле андый сүзләргә ышанмый йөри идем! Шымчыларны менә ничек вербовать итәсез икән сез! Белеп торыгыз: мин моны бөтенесенә әйтәчәкмен! Җыелышта торып сөйләячәкмен!

— Нинди җыелышт-т-та?

Токтогулов тотлыгып куйды хәтта.

— Комсомол җыелышында! Группаның комсомол секретаре мин, беләсегез килсә!

Лейтенант үз колакларына үзе ышанмады. Бу инде сиңа телен тыя белми торган такылдык, сертотмас үрдәк кенә түгел... Граната иде бу! Гүяки Токтогулов саксызлык белән кулындагы гранатаның чекасын тартып чыгарган! Кулда тотып торып та булмый, читкә ыргытырга да ярамый. Шартлау бөтен тирә-юньне яңгыратачак һәм КГБ лейтенантының баскан урынын упкын итәчәк! Чөнки мир алдында фаш булган агент кемгә кирәк?!

Нишләргә? Менә шунда Токтогуловның башы нәкъ Фирдүс уйлаган юнәлештә эшли башлады да инде. Ягъни үзеңне яклау өчен органнарны кулланырга. Башка чара юк иде. Йә КГБ коткара аны, йә башы бетә.

— Комсомол җыелышында сөйлим, дисез инде, алайса... — диде ул сузып. Һәм үзен кулга алырга тырышты. Нindидер бер башсыз кыз каршында җебеп ага торган мәми авыз булса, органнарда эшләмәс тә иде шул ул.

— Бик кызыклы тәкъдим ич бу, — дип дәвам итте ул. Ә үзе эченнән хәйлә корырга кереште. — Ул җыелышның көн тәртибен, үткәрү формасын алдан уйларга кирәк булыр инде. Шулай бит? Мәсьәлә бик җитди. Сүз илнең куркынычсызлыгын тәэмин итүгә кагыла... Әйдәгез, утырып сөйләшик әле.

Аның кинәт тынычланып, хәтта ачылып киткәнен күргәч, Заһидә гаҗәпләнүеннән югалып китте. Кызуы сүрелә башлады, ничек итеп кире утырганын үзе дә сизми калды.

— Сез инде анда бездән дә кеше чакырырсыз. Шулай бит? — дип сорады Токтогулов, үтенгән сыманрак итеп.

— Сезнең кешеләр... андый җыелышларга барамыни? — дип сорады Заһидә, күзләрен шар ачып.

— Чакыручы булса, кире какмыйбыз, — диде Сәет елмаеп.

— Чакырабыз! Килегез! — диде Заһидә кабынып. Аныңча, бу бик тә кызык булачак иде. Комсомол җыелышына КГБ кешесе килсен әле! Мондыйны аның әлегәчә ишеткәне юк иде.

— Тик алдан сөйләшеп куймыйча булмый, — диде Токтогулов. Беркатлы кызыкайның хәйлә кармагына килеп капканын күргәч, аның күңеле җылынып китте. — Җәмәгатьчелек белән элемтә тота торган бүлек бар бездә. Менә шул бүлекнең җитәкчесе...

Сәет бер мизгелгә тынып торды һәм теленә беренче килгән исемне атады:

— Подполковник Гаскәров Айрат Шәймәрдәнович андый җыелышларга вәкилне бик теләп җибәрә. Кайчакта үзе дә бара...

— Подполковникмы? Үземе?

— Әйе. Үзе. Менә хәзер барып сөйләшсәгез, чакырсагыз...

Заһидәнең күз алдыннан группадашлары чагылып узды. Әгәр дә җыелышка КГБ подполковнигы килсә, күзләре тоз булыр иде үзе дә! Һәм... теге җирәнгеч Фирдүс бәйләнүдән туктар иде...

— Ул подполковник белән ничек сөйләшеп була соң? — дип сорады ул, тәмам башы әйләнеп.

— Менә хәзер икәү бергә барабыз да сөйләшәбез.

— Ничек алай кинәт кенә? Ә бәлки, ул урынында түгелдер?

Сәет кул сәгатенә карап алды.

— Нәкъ менә шушы вакытта җәмәгатьчелек вәкилләрен кабул итә ул.

— КГБда ... җәмәгатьчелекне кабул итәләрмени?

Сәет, елмаеп, кызның беркатлылыгына гаҗәпләнгәндәй башын чайкады.

— Органнар халык ярдәменә таянып эшли, — диде. — Әгәр шулай итмәсәк, эшебез нәтиҗәле булмас иде. Шуңа күрә күптән түгел яңа бүлек ачтык. Халык белән элемтәнең яңа формаларын эзлибез.

Заһидә башын иеп уйга калды. Ул икеләнә иде.

— Ә бәлки, җыелышны көзгә калдырыргадыр, — диде ул. — Хәзер сессия җитә. Аннары каникуллар башлана.

— Мондый эшне озакка сузарга ярамый, — диде Токтогулов нык итеп.

Заһидә көрсенеп урыныннан кузгалды.

— Әйдәгез, киттек алайса...

«Ахмак!— дип куйды эченнән генә Токтогулов. — Синең белән урамда җитәкләшеп йөрер дип белдеңме әллә мине?»

— Сез барып чират ала торыгыз, — диде ул, астыртын көлемсерәп. — Минем монда тиз генә бер җиргә сугылып чыгасы бар.

Һәм шәһәр үзәгендәге, бер ягы тоташ бакчадан торган урамдагы, гранит белән тышланган өч катлы мәһабәт бинаның адресын атады.

— Керә торыгыз. Дежурныйга Токтогулов чакырды, диярсез. Мин хәзер килеп җитәм!

Соңгысын әйткәндә, лейтенантның күзләре янә хәтәр елтырап куйды. Заһидә моны күрде, әмма никадәр дәһшәтле икәнен аңламады. Дөресрәге, эчендә кузгалган шомны һаман басарга тырышты. Куркырлык нәрсә эшләгән соң әле ул?!

...Мортаза өчен чишелмәгән сер булып калачак бу очрашу һәм сөйләшү менә шушылай узды.

R R R

Заһидә чыгып китүгә, Токтогулов бүлмәдәге телефонны алды:

— Мин әле бу, — диде ул, аргы баштагы кешенең исемен атамый гына. — Анда Кадерматова дигән берәү килер, мине сорар. Шуны каршы ал да, үзеңә алып кереп, бераз әңгәмә корып утыр әле, зинһар. Берәр сәгать чамасы... Ничек нәрсә турында? Егет кеше кызлар белән ни хакында сөйләшә? Бигрәк тә чибәр кызлар белән... Сине өйрәтеп торасы юк инде... Соңыннан аңлатырмын...

Ә шулай да теге чытлыкның үз аягы белән елан авызына барып керүенә бик үк ышанып җитеп булмый иде. Бөтенләй үк томана түгелдер лә, нинди бусаганы атлыйсын беләдер...

Токтогулов кунакханәдән чыкты да, кызу-кызу атлап, урам буйлап китте. Ерактан ук күреп алды: Заһидә бакчада иде.

Шау-шулы, тынгысыз шәһәрнең уртасында күңелгә тынычлык, җанга ял бирә торган ямьле бер урын иде бу. Аргы башта, биек агачлар белән уратып алынган киң генә мәйданда, балалар өчен таган-атынгычлар, шугычлар куелган, агачтан уелган аю, төлке, алып батыр сыннары басып тора. Анда сабыйлар чыр-чу килә, якындагы балалар бакчасыннан уйнарга чыкканнардыр, күрәсең. Бирге баштагы озын өстәл янында берничә бабай домино суга. Ә уртада, фонтан тирәсендәге уңайлы эскәмияләрдә, әбиләр гәпләшеп утыра.

Бакчаның иң матур бизәге менә шушы — борынгыдан калган фонтан иде. Ул бронзадан зур гына чәчәк савыты рәвешендә эшләнгән, аңа шундый ук бронзадан коелган мәхәббәт алласы — канатлы малай амур килеп кунган. Җәясенең җебен тартып, угын сузган да шукланып карап тора ул. Бакча аша үтеп-сүтеп йөргән яшь-җилкенчәкнең йөрәгенә сөю угын кадамый калмас... Вазадан биек булып өскә бөркелгән су рәшә хасил иткән, анда салават күпере уйный. Көмеш тамчылар бронза малайны коендыра, фонтан тирәсендәге түтәлгә, язның иркә гөлләре — ак, сары нарциссларга сибелә.

Заһидә, кара сумка тоткан сул кулын арткарак каерып, уң кулын тамчылар арасына, мәхәббәт алласына таба сузган. Күлмәгенең киң җиңе аны ак күбәләккә охшатып җибәргән, ул үзе дә шушы бакчаның бер матур бизәге булып, яшәеш тантанасын тулыландырып тора иде шикелле. Ни уйлый ул, күңелендә нинди хисләр кайный? Әллә аргы як урамга илтә торган сукмакка борылыр алдыннан икеләнеп, сагаеп калганмы? Әллә соң кичен бирелә берәрсе белән очрашырга вәгъдәләшкән дә шуны уйлап күңеле кузгалганмы? Алай булуы да бик ихтимал.

Озак та үтмәс, сабыйлар да, әби-бабайлар да өйләренә таралыр. Язның алгысытулы киче, бакчаны серле кара өрфиягә урап, һәр агач янында ышык куыш булдырыр. Аларга парлылар кереп посар...

Ләкин син, ак күлмәкле кызыкай, юкка талпынасың, очынасың... Бүген кич син ул парлар арасында булмассың шул инде...

Бер мизгелгә Сәетнең күңелен кызгану, үкенү хисе тырнап узгандай булды. «Сумкасы шактый авыр күренә, китап-дәфтәр тутыргандыр инде, — дип уйлап куйды ул. — Һәммәсе бар бу кызда, дөньяның җаен аңлау гына юк...»

Токтогулов кыска керфекләрен аска төшерде. Кызганам дип җебеп төшәргә ярамый иде аңа, үзен кайгыртырга кирәк иде.

Менә Заһидә борылды да, бакчадан чыгып, урам аркылы каршыдагы таза йортка таба юнәлде. Бер мизгелгә туктап калды. Әгәр ул ишекне ачмаса? Бусага аркылы атламыйча, кире борылып китсә? Язмышы бөтенләй башкача булыр иде, бәлки?

Ләкин юк, ничек кенә булмасын, бу кичне Заһидә тулай торагына кайтып керәчәк түгел иде. Токтогулов мең төрле башка хәйлә табачак, барыбер аның юлын кисәчәк иде. Ул инде кыз кире борылган очракта нишләргә икәнен уйлап, төрле планнар корган иде. Трамвайга утырса, кесәмнән янчыгымны урлады дип бәйләнергә була. Яисә урамда берәр милиционер күренсә, шуның турыннан узганда, колагына пышылдарга: «Бозык хатын бу, миңа начар чир йоктырды, милициягә алып барыйк әле», — дияргә.

Ләкин алайга китсә, эш катлауланачак, кирәкмәгән шаһитлар пәйда булачак, Токтогулов өчен исә мәсьәләне тыныч хәл итү күпкә хәерлерәк иде. Нәкъ ул теләгәнчә килеп чыкты да. Заһидә, зифа сынын нәфислек һәм көч катыш хәрәкәт белән киереп, авыр имән ишекне тартты. Һәм эчкә атлады.

Сәет, канәгать елмаеп, фонтан янына килде, күзен кысып, кулын мәхәббәт алласына таба сузды. Салкын тамчылар гүяки аның борчуларын юып төшергәндәй булды. Иң авыры эшләнгән, хәзер теге бинага

керәсе дә, мәсьәләнең асылын аңлатып, рапорт кына язасы калган иде. Шуның белән аның вазифасы төгәлләнәчәк, ак күбәләккә охшаган кызның язмышы башка кулларга күчәчәк иде.

R R R

...Ә башка куллар дигәне ул үзе әкрен генә әйләнә торган бер сырлы тәгәрмәч кебек иде. Аңа бер эләксәң, ычкыну бик авыр: ничек кенә тыпырчынсаң да, бер сырдан икенчесенә шудырып кына торалар.

Ишекнең эчке ягында хәрби киемле кырыс егет басып тора иде. Ул Заһидәнең студент билетын сорап алды да, ачып карагач, янындагы тумбочкадан кара телефон трубкасын күтәреп:

— Кадермәтова килде, — диде.

Аннары, трубканы урынына куеп, Заһидәгә таба борылды:

— Бер минут торып торыгыз, — диде.

Озак көтәргә туры килмәде, читләре яшел, уртасы кызыл тар палас түшәлгән киң имән баскычта күксел костюм кигән ыспай егет күренде.

— Килеп җиттегезме? — диде ул, ачык елмаеп. — Исәнмесез! Әйдәгез. Күтәбез.

Заһидә, егетнең ягымлы йөзен күргәч, тынычланып баскычтан менеп китте.

Өске катның коридоры биек, диварларның аскы өлеше имән такталар белән тышланган иде. Идәнгә баскычтагы төсле тар келәм сузылган. Җанны изә торган авырлык бар иде монда. Ләкин Заһидә шомлану хисенә бирешмәскә тырышты. Егет, арырак китеп, зур имән ишекне ачты да:

— Рәхим итегез, — диде.

Бүлмәдә һәрнәрсә: аяклары сырлап эшләнгән карасу шкафлар, урындыклар, зур имән өстәл өстендә бик күп ручкалар сыйган каләм савыты һәм яшел абажурлы мәрмәр лампа — артык саллы, авыр булып күренде. Нindidер кырыслык, шомлылык бар кебек иде биредә. Биек тәрәзәдән сузылган кояш нурлары гына күңелне изә торган бу мохиткә бераз җан өрә иде кебек. Егет үзенең исемен әйтеп тормады, өстәл артына узып, Заһидәгә каршысыннан урындык күрсәтте.

— Бераз гына көтәргә туры килер, — диде. — Ашыкмыйсыздыр бит?

— Сабыр итәргә була, — диде Заһидә, бик үк чишелеп китмичә.

Егет елмаеп башын чайкап куйды.

— Сабыр итә белү бик яхшы сыйфат инде ул, — диде. — Һәр эштә кирәк. Сез, мөгаен, студенткадыр?

Заһидәнең кайда укыганын белгәч, егет, сүзне сүзгә ялгап, нинди фәннәр укытылуын, бу сессиядә ничә имтихан бирәчәкләрен сораштырып алды. Ул әңгәмәне бик шома итеп, чын күңелдән кызыксынгандай алып бара. Әмма барыбер вакытны гына сузганы сизелеп тора иде. Бер-ике тапкыр ул, башын читкә борып, иснәштереп тә алгандай итте.

Ниһаять, урыныннан кузгалды.

— Сез монда аз гына утырып торыгыз, мин хәзер, — дип чыгып китте. Аның артыннан ишек тавышсыз гына ябылды. Бүлмәдә тынлык урнашты. Баеп барган кояшның нурлары сүрелә төште, почмакларга күләгә кереп оялагандай булды.

Менә, ниһаять, ишек ачылып, аннан гимнастерка, кара юбка, күнитек кигән, кыска чәчләрен берет белән бастырган, тупас чырайлы бер хатын күренде.

— Кадермәтовамы? — дип сорады ул.

Заһидә, сагаеп, әкрен генә урыныннан күтәрелде.

— Әйе... Мин...

— На выход! — диде хатын, командирларча тавыш белән.

— Нәрсә?!

— Бүлмәдән чык, диләр сиңа. Бу портфель синекеме? Ал!

Коридорда Заһидә уңга, баскыч ягына таба борылган иде, арттан:

— Сулга! — дигән команданы ишетеп, тукталып калды. — Сулга атла! — диде хатын.

«Сулга! Аска! Уңга!» дигән командаларны үтәп, арттан каты-каты басып килгән аяк тавышлары көенә, бормалы коридорлар, баскычлар буйлап шактый атлады Заһидә. Барган саен коридорлар котсызрак, идән пычраграк күренде, ахырда баскыч кырыйларында рәшәткәләр пәйда булды.

— Чишен, — диде хатын, аны бер кысан бүлмәгә алып кергәч.

— Ничек?.. Нәрсәгә?..

— Чукрак түгелдерсең бит? Чишен!

— Сез нәрсә? Мине кулга алдыгызмы әллә? Токтогуловны чакырыгыз!

— Чакырырлар... Кирәк дип тапсалар.

— Ә ордер?! Ордерыгыз кая?!

— Ордеры да булыр, калганы да. Сал күлмәгеңне.

Хатын тупас итеп аның җиңеннән тартты. Заһидә чирканып китте, ашыгып итәген өскә күтәрә башлады.

— Бөтенләй чишен! Миңа аркаң белән борыл. Аякларыңны киң җәеп бас! Нәрсә мыштырдыйсың?! Алга иел!

Хатын аның шәрә аркасына төртте, аннары колак артларын капшады, чәчен туздырды. Бармаклары боздай суык һәм каты иде.

...Тентегәннән соң, Заһидәне төрмә камерасына кертеп яптылар. Дивар буйларындагы икешәр катлы ятакларга, түшәм астындагы рәшәткәле тәрәзәгә карагач, ул үзен бастырылгандай хис итте. Тынчу һава сулыш юлларына пычрак чүпрәк булып кереп тыгылды. Артыннан тимер ишек шартлап ябылганда, ул һушыннан язар хәлдә иде.

Иркен басуларда, елга буйларында, әрәмәлекләрдә балдай татлы һава сулап үскән, карашы белән киң офыкларны иңләргә күнеккән авыл баласының җаны, вөҗүде мондый кысанлыкка чыдый алмый иде. Йөрәге күкрәк читлеген тишәрдәй булып дөпелдәде. Әгәр хәзер үк чыгармасалар, үләчәген тоеп, йодрыклары белән тимер ишекне төяргә тотынды ул.

— Ачыгыз! Чыгарыгыз мине! Ялгышлык бу! Хата! Минем бер гаебем дә юк! Токтогуловны чакырыгыз!

— Шашма! — диде артта утыручы хатыннарның берсе. — Барыбыз да синең кебек. Гаепле кеше юк монда...

— Карале, сабый гына түгелме соң бу? — диде кайсыдыр. — Бала-чагаларны да тотып яба башладылар инде.

— Ничава, монда тиз өлгерер, — диде икенчесе.

Кемдер Заһидәнең иңеннән кочып алды.

— Бәргәләнмә, сеңелкәш. Кулларыңны авырттырырсың. Әйдә, утырыйк әле менә монда. Хәзер кич инде, сиңа кирәк кеше эштән киткәндер. Иртәгә килер, Аллаһы боерса. Бер кичкә кер мичкә, дигәннәр. Сабыр ит.

— Берсекөнгә зачет, минем әзерләнәсем бар, — диде Заһидә, күз яшьләренә төелеп.

Хатыннар көлеп җибәрделәр. Кайсыдыр сызгырып куйды.

— Карале, студентканы керткәннәр бит безнең янга? Портфеле дә бар әнә...

— Монда башка төрле фәннәрдән имтихан бирергә туры киләчәк сиңа, сеңелкәш! Шуларына әзерлән! — диде берсе сузып.

...Икенче көнне ишектәге кечкенә тишек яныннан китмәде Заһидә. Коридорда аяк тавышлары ишетелгән саен, колагы белән тимергә берегә иде. Ишек ачылгалады, кемнәрнедер чакырып та чыгардылар, әмма Кадермәтова фамилиясен әйтүче булмады.

Аннары ял көннәре җитте... Аннары дүшәмбе, сишәмбе дә узып китте. Заһидә инде бәргәләнми, надзиратель хатынга ялынып кына эндәшә иде.

Ләкин җавап бер булды:

— Кирәк булгач, чакырырлар!

Заһидә шашар дәрәҗәгә җиткән күзләре белән бүлмәдәшләренең әле берсенә, әле икенчесенә карый, һаман бер сүзне тәкрарлый:

— Минем бернинди гаебем юк... Студент мин... Зачетымны бирә алмый калдым... Ник тоталар мине монда?.. Коточкыч хата бит бу, ялгыш...

— Урыс халкы бик дөрес әйткән бит, «от сумы да от тюрьмы не зарекайся», — диде бер хатын көрсенеп. — «Теләнеп йөрмәм, төрмәгә кермәм, дип ант эчмә» дигән сүз. Саный китсәң, монда ярты халык гаепсезгә утыра.

— Алай гына да түгелдер әле, — дип, өметсез тавыш белән җөпләде икенчесе.

Алты кешегә исәпләнгән камерада утыручы бу унөч хатынның берничәсе Мәскәүдән кием-салым алып кайтып саткан, берсе Чувашстаннан үз шәһәренә чүпрә ташыган. Тотылганнар, спекуляция өчен җавапка тартылачаклар. Бәгъзеләре караклыкта гаепләнә. Арада кеше үтергәне дә бар икән — бер хатын, исерек ире белән кара-каршы сугышканда, үзен-үзе белештермичә, пычак кадаган.

Заһидә, ниһаять, ярсудан талчыгып, басынкыланып киткәндәй булды, уйлана башлады. Ул үзенең Тәүфикъны яклап чыкканын, кырым татарлары турында язган шигырен, җыелыш җыярга маташканын исенә төшерде. Чүпрә саткан өчен тотып япканны, андый кыланмышлар өчен утырталар да утырталар инде... Һәм аның бәгыренә, котып салкыны булып өерелеп, утыз җиденче елларның шаукымы бәреп кергәндәй булды.

Кем китереп тыкты аны бу таш капчыкка? Токтогуловка аның хакында кем әйткән? Һәм иң ачысы, мигә утлы без булып кадалганы: нишләтерләр аны монда?!

R R R

Ниләр булды икән Мортазаның әнисе белән? «Дело»дагы кәгазьләр бу сорауга ачык итеп җавап бирмәде. Сидоров фамилияле тикшерүченең сорау алу беркетмәләрендә дә һаман шул Гарипов хакында, Мәскәүгә хат юлларга маташу турында сүз бара иде.

Заһидә белән төрмәдә очрашкан кешеләрне табарга кирәк дигән нәтиҗәгә килде Мортаза. Бәлки, алар чын дөресен сөйләр.

Тик аларны каян эзләргә?

Эш тагын Илүсәгә барып терәлде.

— Иң элек табиб белән сөйләш син, — диде ул. — Алар кешелекле, ярдәмчел. Фамилиясе ничек дидең әле?

— Гельмс.

— Бигрәк әйбәт икән.

— Нәрсәсе әйбәт?

— Сирәк очрый торган фамилия. Эзләргә җиңел. Минем әти момент табып бирә аны.

Һәм, чыннан да, ике көннән Э.Б.Гельмсның адресы Мортазаның кулында иде инде. Баксаң, хатын-кыз икән ул, Эльза Бруновна.

Сәер фамилияле табибә Идел буе немесларыннан булып чыкты. Шәһәр үзәгендә, үр өстендәге бакча эченә урнашкан, кайчандыр бик затлы булган, хәзер инде нык искергән йортларның берсендә яши икән.

Фатирның ишеген киң чырае буразналар сызылгандай җыерчыкланган, иннек ягылган иреннәре өстенә каралып мыек чыккан, юантык гәүдәле яланбаш карчык ачты. Сәламне алгач, Мортазага җете, үткен коңгырт күзләре белән берничә тын текәлеп карап торды да:

— Менә хәзер аермачык исемә төште, — диде ул. — Сез әниегезгә охшагансыз. Сезнең отчествогыз Виленович, фамилиягез Канчуров, шулай бит?

Мортазаның йөзе тартышып куйды. Телефоннан сөйләшкәндә ул үзен Кадермәтованың улы дип таныштырган, фамилиясен әйтмәгән иде. Ләкин нишләп әле бу апа аны ниндидер Канчуровның улы дип белә? Һәм шулхәтле ышанып әйтә тагын!

— Юк, ялгыштыгыз, — диде Мортаза. — Османович мин. Асанин.

— Димәк, алар бергә булмаганнар... — Эльза Бруновна кыенсынып киткәндәй булды. — Гафу итегез. Бәлки, ялгыш ычкындырганмындыр. Кызганычка каршы, мин аларны шундук күздән югалттым, аннан соңгы язмышларын белә алмадым. Үзегез дә аңлыйсыздыр, безгә берни белән дә кызыксыну күрсәтергә ярамый иде... Әниегезнең хәле ничек соң?

— Әни... күптән вафат инде.

Эльза Бруновнаның йөзе тагын да картаеп киткәндәй булды. Ул, борылып, өске ут кабызылган булса да, шактый караңгы, борынгы шкафлар белән тыгызланган алгы бүлмәгә, аннары зал ягына таба атлады.

— Узыгыз, — диде. — Менә бирегә, диванга утырыгыз.

Үзе киң култыксалы, иркен, йомшак кәнәфигә утырды да, түгәрәк өстәлгә уң терсәген куеп, ияген кул аркасына терәде.

— Нинди аяныч! — диде ул көрсенеп. — Гафу итегез, ничә яшьтә вафат булды ул?

— Утыз биштә иде.

— Һәм диагноз?

Табибәнең йөзендә сагаю, хәтта курку чагылгандай булды.

— Бавыр циррозы.

— Әлбәттә, әлбәттә, — дип башын селкеде апа. — Сорап торасы да юк... Башкача булу мөмкин дә түгел. Сез... этиегез кулында үстегез, димәк?

— Әти һәм үги әни кулында...

— Шуннан курыккан идем дә инде мин...

— Нәрсәдән курыккан идегез?

Хатын, башын югары тоткан хәлдә, бераз вакыт почмакка карап утырды.

— Сезнең дөресен белергә тулы хокукыгыз бар, әлбәттә, — диде табибә. — Ләкин нигә мин? Ни өчен мин?

— Мин әниемнең «Дело»сы белән танышкан идем, — диде Мортаза, шактый ук аптырашта калып. — Сез аның авыруы хакында белешмә язган булгансыз. Мин медицина терминнарын аңламыйм, почеркыгызны да танып булмады. Бәлки, үзегез әйтерсез... Нәрсә белән авырды ул?

— Әйе, сезнең хокукыгыз бар. Ә менә минем... бурычым... — диде хатын буталып.

Мортазаның гаҗәпләнүе артканнан-арта барды.

— Сезнең бурычыгыз? Кем каршында?

— Дәүләт, дөресрәге, ватан каршында, дияргә кирәктер. Мин ант биргән кеше. Дәүләт серен чишәргә хакым юк...

Шуннан соң шактый вакытка тынлык урнашты. Мортаза табибәнең аңлатуын түземсезләнеп көтә, ә Эльза Бруновна исә нәрсәгәдер икеләнә, уйлана кебек иде.

— Минем әниемнең дәүләт серенә ни катышы булсын? — диде, ниһаять, Мортаза. — Белсә дә, тел һәм әдәбият серләрен генә белгәндер, филология факультетында укыган бит ул. «Дело»да дәүләт сере хакында сүз юк.

Эльза Бруновна, егетнең беркатлылыгына гаҗәпләнгәндәй, башын як-якка чайкады.

— «Дело»ларга һәрчакта да дөресе генә язылса икән...

— Нәрсә язылмаган соң анда?!

— Мин үзем дә барысын белмим. Күргәннәремнән чыгып, уйланам гына. Шикләнәм генә...

— Нәрсәдән? Әллә берәрсеннәнме?

Кинәт табибәнең сүз чишмәсе ерылып киткәндәй булды, ул ашыгып сөйли башлады:

— Яшьләр өлкән буынны күндәмлектә, сарык көтүе кебек кая кусалар, шунда барып, баш иеп яшәүдә гаепли. Золымга күмәкләшеп каршы тору булмаган, диләр. Алар мең тапкыр хаклы. Әйе, берәүләр залимнәргә хезмәт итте, икенчеләр алданып аларга иярде, өченчеләр, һәммәсен аңласалар да, куркудан өнсез калган иде. Инде кем дә булса аз гына баш калкытса... Андыйларны юк итүнең системасы бик яхшы көйләнгән иде шул. Дөрес, безнең чорда аның әйләнеше кимегән иде инде. Ләкин ул җимерелмәгән, исән иде һәм эшләвен дәвам итте.

Өлкән яшьтәге табибәнең бу рәвешле үрсәләнеп сөйләнүе Мортазаны аптырашта калдырды. Моның ниндидер бик тирән бер мәгънәсе барлыгы сизелә, әмма Эльза Бруновна анысын ачыктан-ачык әйтми иде.

— Әйе, мин куркытылганнар кавеменнән идем, — дип дәвам итте ул. — Ә менә Заһидә, синең булачак әниең, башын ими торган асыл затлардан иде. Башкалардан аерылып тора иде, корыган дала уртасында балкыган мәк чәчәге кебек. Минем хәтеремдә ул шундый булып саклана. Һәм аның мәхәббәте дә романтик кыйсса булып истә калды... Шуңа күрә мин сезнең фамилиягез Канчуровтыр дип уйлаган идем дә...

— Мин сезне аңламыйм, — диде Мортаза. — Нигә сез ачыктан-ачык кына сөйләмисез? Ул хәлләрдән соң утыз ел узды бит инде. Дәүләт серләре дә әллә кайчан ачылды!

Эльза Бруновна, нинди беркатлы син дигәндәй, ачы көлемсерәп карады.

— Сернең ниндие булмас! Ул чакта хәтта көчле өермә дә дәүләт сере булып саналды, аның турында гәзитләргә язарга ярамады. Андыйлар ачылды. Әмма бар шундый яшерен әйберләр, алары, бәлки, мәңге фаш ителмәс. Бу очрак та, ихтимал, шундыйдыр. Бик тә яшерен һәм хәвефле дәүләт серенә бәйледер... Тик мин аны сиңа әйтергә тиеш. Юкса җаным тынгы тапмастыр...

Ул тирән итеп сулыш алды да авырлык белән генә сүзен дәвам итте:

— Эш болай булды. Беркөнне безгә бер кызны китерделәр һәм сәламәтлеген тикшерергә куштылар. Тикшердек. Ул таза-сау, ябылып торудан бераз төсе генә качкан иде. Икенче көнне мине шәфкать туташы белән бергә баш табиб чакырып алды. Ампула бирде һәм алдагы көнне тикшергән кызны процедура бүлмәсенә алып кереп, инъекция ясарга кушты.

— Сау-сәламәт кешегәме? Нинди укол ул?

— Нинди препарат дисезме? Ампуланың пыяласы чип-чиста иде... Берни дә язылмаган иде, аңлыйсызмы? Аның нинди препарат икәнлеген мин белмәдем, белмим һәм, мөгаен, беркайчан да белә алмам инде.

— Ничек соң сез, врач була торып...

— Аңлагыз, мин үзем дә анда тоткын идем! — диде ачынып Эльза Бруновна. — Тоткын! Сез аның ни икәнен беләсезме?!

Һәм башын читкә борды.

— Юк, сез аны белмисез. Һәм белмәгез дә! Язмыш сезне андый җирләргә якын да китермәсен!

— Һәм сез...

— Әйе, шәфкать туташы уколны ясады. Ә миңа бер бит кәгазь бирделәр дә күзәтүләремне шуңа теркәп барырга куштылар.

— Ләкин «Дело»да андый кәгазь юк!

— Күрәсең, ул бөтенләй башка папкага теркәлергә тиеш булгандыр. Ниндигә дисезме? Ә мин каян белим? Ун минут үттеме-юкмы, кызның хәле кинәт начарайды. Пульсы тигезсезләнде, сулышы авырайды. Шунда...

— Шуннан нәрсә?

— Аңлагыз, мин аны коткардым ул чакта. Мөмкин булмаганны эшләдем дияргә була! Мин аның йөрәген ике сәгать буена туктатмый тота алдым. Ике сәгать буе! Гәрчә препаратның составын белмәсәм дә. Ә мондый чакта дәвалау бик кыен. Чөнки чирнең каян килеп чыкканлыгы билгесез. Ягъни авыру тарихына «неясная этиология» дип язып куела торган очрак бу!

Мортазаның исенә кылт итеп үзләренең заводында булган хәл килеп төште. Мичкәдән чыккан ис белән агуланган йөк ташучыны табиблар коткарып кала алмады. Чөнки агуның ниндилеген белмәгәннәр. Нәкъ мондагы кебек...

— Һәм ике сәгатьтән соң ул терелдеме?

— Ике сәгатьтән соң кирәкле даруны китереп җиткерделәр. Канчуров алып килде.

— Ул Канчуров дигәнегез табиб идемени?

— Вилен Канчуров, — дип җавап бирде табибә, серле итеп. — Ул коткарып калды Заһидәне. Әгәр ул дару алып килмәсә, без аны ни тырышсак та алып кала алмый идек.

— Кем иде соң ул?

— Кадермәтованың адвокаты, диделәр. Ләкин бу мине гаҗәпсендерде... Нинди адвокат?! Мәхбүсләрнең берсенең дә адвокаты юк иде ул чакта. Төрмә эчендә андый кешене мин беренче тапкыр күрдем. Җитмәсә, адвокатның да ниндие диген әле! Заһидә өчен җанын фида кылырга әзер иде! Хәер, Заһидә үзе дә...

Табибә Мортазага үткен караш ташлап алды. Аннары:

— Кичерегез... — диде.

— Ә ул... адвокат... даруын тапкан икән, теге уколның ниндилеген дә белгән, димәк?

— Анысын әйтә алмыйм. Миңа аның белән сөйләшергә туры килгәне булмады. Алар тикшерүче белән бик дуслашканнар иде.

— Хәзер кайда икән соң ул?

— Канчуровмы? Белмим. Заһидә киткәннән соң, ул да бүтән күренмәде... Ә менә тикшерүчене, Антон Никитичны әйтә алам. Күптән пенсиядә инде. Хәлләрне белешеп торабыз, бер-беребезне бәйрәмнәр белән котлыйбыз. Шылтыратыгыз сез аңа! Әйбәт кеше ул. Әниегезгә бик күп яхшылыклар эшләде.

Тикшерүче... яхшылык кылганмы?! Ә нишләп соң, алайса, Мортазаның әнисе сөргенгә эләккән? Ни гаебе өчен?!

Эльза Бруновна, башын иеп, кәгазьгә Антон Никитичның адресын, телефонын яза иде, шунлыктан Мортазаның чыраенда чагылган гаҗәпләнү галәмәтләрен күрмәде.

— Ул сезгә, әлбәттә, миннән күбрәкне сөйләр. Мине дә онытмагыз. Соравыгыз туса, шылтыратыгыз... Чынлап әйтәм... Бер дә кыенсынып тормагыз...

Соңгысын әйткәндә, табибәнең тавышында үтенү, ялыну аһәңнәре чагылды. Күзләре яшьләнеп киткәндәй булды хәтта.

— Сезне күрү минем өчен бик зур куаныч, — диде ул, озата чыкканда. — Менә бит нинди чибәр егет булып үскәнсез. Һәм сау-сәламәт... Ә минем күңелне шик корты кимереп тора иде.

Мортаза баскыч мәйданчыгында тукталып калды:

— Нинди шик?

— Бар иде инде... Хәзер менә үзегезне күргәч, җаным тынычланды.

Ул, күтәрелеп, очкынланып киткән күзләре белән Мортазаның йөзенә текәлеп карады. Бу минутта Эльза Бруновнаның карашында аналарча ярату, бетми-сүнми торган олы кайгырту, хәтта горурлану да бар иде кебек.

— Сез диспансеризация үткәнсездер бит? Хәер, студент чакта тикшереп торганнардыр, — диде ул, һич көтмәгәндә.

— Нинди диспансеризация? Нәрсәгә?

— Ну... Сез бит укымышлы, зыялы егет. Ә интеллигент кеше үзенең сәламәтлеген даими кайгыртып торырга тиеш. Әниегез булмагач, моны исегезгә төшереп торучы да юктыр, бәлки. Әледән-әле врачка күренеп, сәламәтлекне тикшертеп тору беркемгә дә зыян итми. Сезнең кебекләргә бигрәк тә...

— Кем кебекләргә?! Минем башкалардан ким җирем бармы әллә?

— Юк, әлбәттә, һич юк! Минем өчен сез барсыннан да мең артык! Тик барыбер... медик буларак үтенеп сорыйм сездән. Нәни генә борчуыгыз булса да, врачка барыгыз. Болай да әледән-әле тикшерелеп торыгыз. Әниегез урынына ялварам! Вәгъдә бирегез миңа!

Ул дымлы күзләре белән Мортазаның йөзенә төбәлгән, гүяки аның эчендәге иң яшерен, моңарчы үз-үзенә дә сиздерергә теләмәгән сызлавыгын күрә иде.
Мортаза аңа аркасы белән борылды.
— Әлбәттә, әлбәттә... — диде ул ашыгып. — Исемдә тотармын... Барырмын, каралырмын... Хушыгыз!

R R R

Урамга чыкканда, Мортазаның чигәсенә чүкеч белән бәрәләр кебек иде. Бу нинди табышмак? Нинди укол кадаганнар аның әнисенә? Һәм ни өчен әле бу апакай аның, Мортазаның, саулыгы белән шулхәтле кызыксына? Борчыла хәтта! Нилектән ул, бөтен эчне үтәли күргәндәй, кистереп карый? Әллә соң егетнең бик тә эчкә яшерелгән кимчелеген сизеп алдымы?! Тик каян, ничек?
Бар шул, бар Мортазаның яшерен борчуы!.. Алай гына да түгел, кешедән ким ягы бар аның. Тик моны тел тибрәтеп берәүгә дә әйтеп булмый. Иң якын дустыңа ачылсаң да, көләчәк кенә. Тыштан, бәлки, күрсәтмәс, ләкин эченнән, «и бичара, тәмам гарип икәнсең», дип мыскыллап уйлап куячак. Ә инде ул тагын берәрсенә ычкындырса... Гомер буе артыңнан чыш-пыш сөйләп йөриячәкләр...
Әйе, егерме җидегә җиткәнче гыйффәтле булып калу егетләрне генә түгел, кызларны да бизәми, аларны да «карт кыз», «сазаган» дип чуттан чыгара башлыйлар. Ә ир заты турында ни дияргә кала?..
Мортаза өч-дүрт тапкыр үзенең ирлеген расларга омтылып карады. Беренчесе армиядә хезмәт иткәндә булды. Себердәге ерак бер гарнизонга эләккән иде ул. Андый җирдә офицер хатыннарына эш юк, ирләре көн буе учениедә, солдат көтүләп йөри, ә болар өйдә, башларын кая куярга белмичә аптырап ята. Ә яшь йөрәк җилкенә, кан кайный... Марш-бросоклар булганда, офицерлар гарнизоннан бөтенләй ерагая. Дневальный булып калган солдатлар исә командирларының гаиләләренә авыр эштә ярдәм иткәли...
Утызлар тирәсендәге бер чая хатын Мортазаны чакырды шулай. Күп итеп кер юган да шуны эләсе бар икән. Юеш әйбер авыр бит ул, үзе генә күтәрерлек түгел. Менеп киттеләр икәүләшеп чормага. Алдан, ләгән күтәреп, Мортаза, арттан теге ханым...
— Элешергә дә ярдәм ит инде, — диде хатын. Чыннан да, үзенә генә читен, карават җәймәләре, юрган тышлары зур бит алар. Мортаза баудагы чүпрәкләрнең почмагы идәнгә тиеп пычранмасын дип тырыша, рәтләп-тигезләп маташа, теге хатын да, аның аркылы сузылып, кулы белән ышкып шомарткалый. Мортазаның башы әйләнеп китте, бөтен тәне ут капкандай кызыша башлады. Уйлап, чамалап торыр хәлдән узган иде, нәкъ егетләрчә кисәк борылды да хатынны умырып кочаклап алды ул. Баудагы чүпрәкләр чорма туфрагына шуышып төште, аның өстенә хатын ауды, аннары Мортаза. Шуннан соң...
Баш кызган, күңел күгенең капусы ачылган, тән кылтырана-бәргәләнә иде. Ләкин... ләкин хатын никадәр генә назланса да, егет ничаклы гына ашкынса да, теләгәнчә барып чыкмады...
Бәхеткә, хатын бөтенләй үк оятсыз-затсыз түгел икән, кәефе шактый кырылган булса да, егетне хурламады, мыскыллап көлмәде.
— Син беренче тапкырмы әллә? — дип сорады ул, бармакларын халат итәгенә сөрткәләп.
— Әйе-е... Беренче...
— Гыйффәтле егетләр килгәли шул монда, — диде хатын, юатырга тырышкандай. — Син артык борчылма... Бәлки, рәткә керерсең әле...
Тавышында исә канәгатьсезлек катыш өметсезлек ярылып ята иде.
— Син бар, төш моннан, — диде ул. — Калганын үзем карармын.
Мортазаны ул йортка бүтән чакырмадылар. Башка берәү анда еш була һәм бик канәгать булып кайта иде.
Армиядән кайткач, рәтләнмәмме дигән өмет белән, ике-өч тапкыр шактый тәҗрибәле хатыннарның кочагына кереп карады Мортаза. Иң соңгысында, утыздан узган хатын аңа кызганып карады да: «Сиңа, егеткәем, без генә ярдәм итә торган түгел, — диде. — Табибка күренми булмас. Бик шәп белгечләр бар бит хәзер. Телисеңме, таныштырам?»
Мортаза, оятыннан җир тишегенә керердәй булып, кызарынып чыгып китте.
Ул бу хакта уйламаска тырыша, чынлап гашыйк булсам, җан сөйгән ярым белән кавышсам, бар да үз җаена салыныр әле, дип, өметләнә иде. Теге хатыннар йөрәккә якын түгел иде бит, фәкать шуның аркасында гына дәрт кабынмады, дип, үз-үзен юата иде.
Карт табибәнең үткен карашы, эчке бер мәгънә белән әйткән сүзләре аның бәгырендәге авырткан ноктага бөтенләй икенче яктан китереп бәргәндәй итте.
Ишегалдына чыккач, Мортазаның күзенә иң беренче булып төртелгән нәрсә — колгаларга тарттырылган озын баулардагы керләр булды. Ап-ак җәймәләр кояш нурларыннан кинәнә, талгын җилдә җилпенгәләп куйгандай итә. Кемнәрнең татлы серләре сеңгән аларга? Аулак бүлмәләрдә, тылсымлы

төннең кара чыбылдыгы астында нинди парлар, бу җәймәләрне ак җилкән итеп, ләззәт диңгезләрен кичкән дә, канат итеп, җиде кат күкләргә очкан икән?..

Бауларның бәгъзеләренә буйдан-буйга ал, зәңгәр, чуар нәни ыштаннар тезеп эленгән. Бәхетле парларның байраклары кебек алар... Ә Мортазаның өеннән беркайчан, беркайчан да андыйларны чыгарып элә алмаслар микәнни?

Бөтен кешегә болай гына, тик торганда бирелә торган бәхет бит бу югыйсә. Аның өчен зур белем алу да, эш урынында югары күтәрелү дә, спорт рекорды кую да таләп ителми. Һәр чиләкнең үз капкачы табыла, диләр. Хатыннар белән надан да, ялкау да йоклый, баланы аны ахмак та ясый. Шуңа күрә аның өчен берәүнең дә түшенә орден такмыйлар. Киресенчә, хатын-кыз белән артык мавыккан, һәр җилпенгән итәк артыннан чабарга әзер торган, берәр чытлыкның шәрә боты ялтыраган саен селәгәе аккан кешеләрне бик үк хөрмәт тә итмиләр кебек.

Ләкин бу өстән караганда гына шулай. Ир-ат халкы ак җәймә өстендә күрсәткән көч-гайрәте белән мактанырга бик тә ярата! Ул инде өч егет бергә җыелып, тәмәке көйрәтеп җибәрсә, хатыннар хакында шаярышып, көлешеп алмый калынмый. Тормыш мәшәкатьләрен онытып, күңелне күтәреп җибәрү өчен шулай кирәк дип санала.

«Хәлләр ничек?» — «Шәп тора әле хәлләр! Хатынның күңеле бик хуш! Әле менә өченче көн урман кисеп, эт булып кайткан идем. Кыл өзәрлек хәл дә калмаган, кашыкны көчкә авызга китерәм. Мала-ай, хатын тузына башлады бит берзаман! Әле мәчене тибеп очыра, әле баланы төртеп җибәрә. Баштарак моның хикмәтен аңламый тордым. Бераздан барып җитте миңа. Әһә, мин әйтәм, имәндә икән чикләвек! Хатынны сарайга дәшеп чыгардым да, печәнлеккә алып менеп, бөтен көчне җыеп... Булдырдым бит, көйләдем тегене... Кире өйгә кергән идек, кояш чыккандай булды. Мәчегә дә сөт бирелде, малайның да башыннан сыйпалды...» — «Ну, хатын янда булганда яхшы ул. Әле менә мин икенче шәһәргә имтиханнар бирергә барган идем. Заочно укыйм бит, үзегез беләсез. Имтиханнарны шома гына тапшырып булмады, тагын бер айга калырга туры килде. Китаптан күз алмый берәр атна утыргач, ми түнә, башка берни керми башлый. Чөнки астан тынгы юк... Чарасын күрми булмый, кибеткә кереп, бер яртыны кесәгә тыгам да китәм таныш адресларның берәрсенә...» — «Адресларың шулай күпмени?» — «Һаман берсенә йөрү хәвефле бит ул... Дөрес аңламаулары мөмкин. Артык сылanулары... Хатын әйбәт бит минем, тормышны бозасы килми...» — «Хатыны булганга рәхәт ул. Ә менә буйдак чакта, теге студент елларда ничек читен иде! Кайчакта урамнан барганда, берәр чибәрне күреп, фигура бозыла да куя. Атлап барыр әмәл калмый. Анда инде берәр багана янында туктап, игъланнар укыганга сабышасың. Шактый торасың шулай, бер аягыңны алгарак сузып, тәмәке суырып...»

Мортаза да, башкаларга ияреп, шаркылдап көлә, кайчакта берәр анекдот кыстырып җибәрә. Ләкин, асылда, мондый сөйләшүләр аның җанын гына ачыттыра.

Хәзер бу ачыну тагын да көчәйгән иде. Карт табибәнең борчылуы тикмәгә генә түгел, билгеле. Теге уколның зыяны Заһидәнең үзенә генә түгел, баласына да тимәдеме икән дип шикләнә ул, мөгаен.

Нишләткәннәр аның әнисен?.. Кем әйтер моны? Агуга каршы дару алып килгән Виленмы? Кем ул? Аны каян табарга?

R R R

Эльза Бруновна дөрес шикләнде: Вилен Канчуров бернинди дә адвокат түгел иде. Химия белгече иде ул. Һәм фәнни-тикшеренү институтында, аның да бик югары дәрәҗәле саналган беренче бүлегендә эшли иде.

Биредәге галимнәрнең хезмәте дә, алар үзләре дә, атом һәм водород бомбаларын ясаучылар, ракеталарның, су асты көймәләренең проектларын эшләүчеләр кебек үк, дәүләт сере булып саналды. Чөнки алар разведка өчен кирәкле яңа төр матдәләр ясау белән шөгыльләнәләр иде.

Бу бүлек институт бинасының икенче катында, калын тимер ишек артында урнашкан. Аңа фәкать кодлы йозакны ачып, эчке яктагы сакчыга махсус пропускыңны күрсәтеп кенә кереп була. Мондагылар башка бүлекләрдә эшләүчеләр белән бөтенләй диярлек аралашмый, кунак-кунак йөрешү дә, хәтта тукталып хәл белешү дә юк. Алар үзләрен бүтәннәрдән күпкә югары саныйлар, чөнки, киемнәренә, яшәү рәвешләренә, ялтырап торган кара ботинкалары белән институт коридорларына нык басып йөрүләренә караганда, хезмәт хакын да чагыштыргысыз күбрәк алалар иде. Аларның туры муеннарына, кысылган иреннәренә һәм каршыларындагы бер ноктага текәлгән салкын күзләренә бер караш ташлауга, кайда эшләгәннәрен чамалап була иде.

Дөрес, шәхес культы фаш ителгәннән соң, алтмышынчы еллар башындагы «язгы җилләр» бу коридорга да бәреп кереп, сискәндереп җибәрде һәм бирелә эшләүче кәттә егетләрнең җилкәләрен бөрештереп, муеннарын бөкте.

Ләкин менә еллар үтте, Вилен институтны алтын медаль белән тәмамлап бирегә эшкә килгәндә, сәясәтнең угы, сәгать теледәй, тагын элекке якка авышкан иде инде. Бигрәк тә разведка, контрразведка үсенеп киткән, чөнки елдан-ел көчәя барган салкын сугышның төп фронт сызыгы, асылда, шул өлкәдә уза иде.

Беркемгә дә сер түгел: фәнне алга этәргән төп көчләрнең берсе — ул сугыш. Дөньяны шаккатырган бик күп ачышлар нәкъ менә сугыш коралларын камилләштергәндә, аларны торган саен куәтлерәк, җимергечрәк итү өчен тырышканда ясала.

Химия өлкәсендә дә бу шулай иде. Уйлап карасаң, исең китәрлек: галим дип аталган акыл ияләре адәм балаларын үтерү өчен нинди генә агулар уйлап чыгармаган! Алар уйлап таба тора, заводлар меңәр-меңәр тонна эшләп чыгара, поездлар ил буйлап тарата. Ахырда санап карасалар, Җир шарындагы бөтен җан иясен юк итәрлек агу ясалган икән.

Монысы — күпмедер дәрәҗәдә халыкка мәгълүм булганы. Аның әле билгесез калганнары да бар. Мәсәлән, разведкага кагылышлы өлкәдә. Бу серләрнең ачылмавы бер дә гаҗәп түгел, чөнки андый матдәләрне тегендә-монда йөртер өчен тимер юл вагоннарының хаҗәте юк. Разведкага кирәк нәрсә энә очына сыярга тиеш. Ул энәне, мәсәлән, зонтик таягының башына беркетеп куясың. Аннары урам буйлап барганда, тигез җирдә абынып, зонтигыңны ялгыш болгап җибәрәсең. Һәм ул очы белән бер узгынчыга төртелә. Теге сискәнеп куя. Син аннан кечелек белән гафу үтенәсең. Аңлашасыз, елмаешасыз. Теге адәм энә чәнчелгән янтыгын угалап куя да, бу хакта шундук онытып, үз юлы белән китеп бара. Ләкин ул ерак китәргә тиеш түгел. Егылырга тиеш ул. Һәм шул егылуыннан тормаска.

Аны күтәреп алып хастаханәгә илткәнче, табиблар тегене-моны караштырганчы, шактый вакыт үтәр. Ул арада әлеге адәм мәңгелеккә күзен дә йомып куяр.

Бу хәлләр чит илдә булачак бит инде. Ә анда кешенең кадере зур. Сау-сәламәт ир-егетнең кинәт үлүе күпләрне сәерсендерәчәк. Шау-шу кубачак, тикшерү башланачак. Менә шул вакыт андагы галимнәр анализлар алып төрле яктан тикшергәндә, теге агу табылырга тиеш түгел. Колба-пробиркаларда нинди генә матдәләрне катнаштырып азаплансалар да, нинди генә микроскопларга күзләрен тегәп баксалар да, нәтиҗәдә «неясная этиология», ягъни үлемгә китергән чирнең сәбәбе ачык түгел дигән сүз торып калырга тиеш.

Димәк, агуның бик көчле, тиз тәэсир итүчән һәм шул ук вакытта организмнан бик тиз чыгарыла торган булуы зарур.

Менә шушындый агулар ясау белән шөгыльләнә иде институтның яшерен бүлеге. Һәм бирелә миен, көчен сыккан талант ияләренең исемнәре сер булып саклану бик тә табигый иде. Монда ясалган бөек ачышларның авторы кем булу озак еллар, ә бәлки, галим үзе бу якты дөньядан киткәнче билгесез булып калачак иде...

Хәлбуки яшь галим Виленның нәкъ менә соңгысы белән һич тә ризалашасы килми иде. Гомере буе серлелекнең караңгы базында ятасы килми, якты дөньяга чыгасы килә иде аның. Шушы тыелгысыз теләк-ашкыну аны югарыдагылар сызып куйган төп юлыннан кырый сукмакка тайпылдырды. Һәм Заһидә белән очраштырды.

Ул болай башланды. Язның җәйгә күчкән көннәрендә, яшь күңелләрнең бик тә дәртле, чамасыз алгысыган чорында, Вилен үзенең остазы профессор Рассекаев белән сөйләшеп утыра иде.

— Бу яңа препаратның бик үзенчәлекле бер ягы ачылды бит әле, — диде профессор. — Син үзең аны, мөгаен, күз алдында тотмагансыңдыр да... Без монда табиблар белән дә сөйләшеп алдык. Гаҗәп хәл. Моңарчы күзәтелгәне юк иде.

Һәм ул, күзлеген тупыйк борын очына табарак шудырып, калын пыялалар өстеннән шәкертенә текәлде. Аның чал кергән киң кашлары астыннан тонык соры күзләрендә соклану чагылды. Өстәлнең икенче ягында утырган Виленның болай да төз сыны тагын да тураебрак китте, аксыл чыраенда канәгать елмаю балкыды. Тигез тыгыз, ап-ак тешләреннән нур сибелгәндәй булды, чибәр йөзе, зәңгәр күзләре үзенә бер ымсындыргыч, шул ук вакытта шомлы яктылыкка уралды. «Көчле, — дип уйлады профессор. — Ерак китәчәк. Әмма юлына аркылы төшүдән Ходай сакласын... Чәйнәп кенә ыргытыр...» Шул ук вакытта егетнең күзләрендә үзенең сурәтен күргәндәй булды ул. Ә анда таушалган костюмы астында иңнәре салынып төшкән, бөрешкән карт чагыла иде. Бер генә мизгелдә профессорның күңелен көнләшү хисе телеп узды. Тик бернишләп тә булмый шул. Яшьлекне дә, гайрәтне дә картаеп үлгәнче саклап булмый. Ә менә гомер буе туплаган белемеңне, тәҗрибәңне югалтмый саклау, хәтта үзеңнән соң да яшәрлек итеп

калдыру бик мөмкин эш. Кыргый җанварга охшаш бу егет олыгайган галимнең хезмәтләрен, ачышларын киләчәккә алып барачак иде. Чөнки профессорның иң өметле һәм сөекле укучысы иде ул.

— Ник соң әле син үзең ясаган препаратның нинди хикмәте барын сорамыйсың? — диде профессор.

— Ул элеккеләрдән күпкә тизрәк тәэсир итә һәм эз калдырмый, — диде Вилен, бик ышанычлы, нык тавыш белән.

— Алай гына түгел шул... Яңа бер сыйфаты килеп чыкты әле аның. Арка миенә тәэсире бик көчле икән. Андагы аерым бер үзәкләргә...

— Безгә шундый бурыч куйдылар да бит инде, тиз һәм көчле тәэсир итсен, диделәр. Аның өчен арка миенә тәэсир итү кирәк тә!

Ах, үзсүзле дә инде бу егет!

— Кайбер нерв үзәкләренең чамадан тыш артык активлашуы күзәтелә.

— Марафон чабышына чыкмыйлардыр бит? — диде көлеп Вилен.

— Ә син авызыңны җыя төш. Чабуын чапмыйлар. Егылып яталар. Әмма кайбер органнары чамадан тыш активлаша.

Егетнең юка иреннәре кысылды, елмаюына ризасызлык галәмәтләре кушылды. Ул үзенең яшьлеге, гайрәте биеклегеннән каршысындагы картка, куе сары керфекләрен кыса төшеп, сынап һәм кимсетеп карады.

«Эчле, — дип уйлады карт. — Безнең эштә җебегәннәр, изелеп төшкән боламыклар мантый алмый шул, нихәл итәсең. Каты бәгырьле, таза тешле кешеләр кирәк».

— Алга куйган бурычны үтәдек без үтәвен. — Профессор, күзлеген кире урынына күтәреп, карашын ялтыравык өстәл тактасына төбәде. — Препаратның тәэсире унбиш-егерме минуттан башлана һәм бик тиз көчәя. Монысы без теләгәнчә. Әмма побочный эффекты...

— Ә нәрсә? Нинди эффект?

Вилен, алга авышыбрак, остазының авызына текәлде. Кыланмышларыннан күренеп тора: белә иде ул эшнең хикмәтен, бик яхшы белә иде. Әмма моны профессор авызыннан ишетәсе килә иде.

— Синең препаратыңнан җенси дәрт кузгала икән, — диде карт, карашын читкә төбәп. — Һәм һич сүрелми, диләр. Полковник Канчуровны бу бик сәерсендерде. Анысы артыкка киткән, ди. Без сезгә ирлек җегәрен көчәйтүче дару ясарга кушмадык, ди.

Полковникның фамилиясен әйткәндә, профессорның тавышында үзенә бер аһәң, курку катыш хөрмәт чагылып узды. Вилен исә көлеп җибәрде.

— Әгәр дә кеше үз гомеренең соңгы минутларында татлы хисләр кичерә икән, безнең разведкага аннан ни зыян?

— Анысын сез полковник белән үзегез сөйләшерсез, — диде, чал кашын җыерып профессор. — Абыегыз бит ул сезнең.

— Әйе, туганнар без. Бер нәселдән... — диде Вилен, профессорның соравын җавапсыз калдырмас өчен генә, битараф тавыш белән. Аның уйлары башкада иде. — Побочный эффект һәр даруда бар, — дип дәвам итте ул. — Ә монда зыянлы да түгел икән бит. Җан бирер алдыннан җенси теләк диген, ә? Каршысында чалгы тотып торган әҗәлне күрми кеше, матур кыз белән кочышу-сөешү турында хыяллана!

— Анысы инде ничектер, патологоанатомнар мәрхүмнең күңелендә нинди хисләр кайнаганын безгә язып бирмиләр. Ә менә эрекциянең үлгәннән соң да сакланганын язалар, хәтта астына сызып куялар. Чалбар кигезерлек түгел, табутка салырга уңайсыз, диләр. Ярый бездә андый мәетләрне туганнарына бирү гадәте юк, суд карары тормышка ашырылды, гәүдәсе фәлән зиратка күмелде дигән белешмә генә җибәрәләр. Ә менә чит илдә, мәрхүмнең якыннарында берәр шик тусамы? Андагы бөтен табибларны, аларга өстәп үзләренең контрразведкасын аякка бастырулары ихтимал. Безгә шул кирәкмени, ди полковник Канчуров. Хәер, үзе аңлатыр әле.

Баядан бирле урынында кыбырсып утырган Вилен остазының бу озын нотыгын ахыргача сабырлык белән тыңлап бетерә алмады, сикереп торды да ишек яныннан урап килде. Һәм кинәт башында ниндидер уй чагылып узгандай туктап калды.

— Җенси теләк бетми, димәк... Ә хатын-кызларда ничек?

Профессор күзлеге өстеннән янә аңа текәлде. Аның карашында көнләшү катыш курку чагылды. Әйе, ерак китәчәк бу егет, бик ерак! Колачы киң, биеккә күтәрелергә омтылышы көчле. Очар да, күтәрелер дә! Заман икенчеләнеп бара шул хәзер. Илленче еллар башындагы кебек, оядан очып чыккан һәр лачынның канат очларын кыркып тору кимеде. Кыркучыларның кайчылары үтмәсләнеп килә шикелле. Өстәвенә бу егетнең яклаучысы да көчле. Минем шәкертем эшемне дәвам итүче дип мактана мактануын да профессор, нинди шәкерт булсын ул аңа? Гомер буе куркып, төрмәгә ябып куймагайлары, дип коты очып, эчтән

калтырап яшәгән картка?! Кемнеңдер «айт» дигәненә «тайт» дип торган, Ходай биргән бар талантын үзе теләгән эшкә түгел, башкалар кушканны үтәүгә багышлаган фән кешесенә?

Әнә, бу егет остазым дип әдәп тә сакламый, һаман үз туксаны туксан. Хатын-кыз кайгысы анда! Профессорның каршына килеп баскан да, өстәл аша иелә төшеп, без күзләрен аңа төбәгән.

— Федор Кузьмич! Хатын-кызлар турында патологоанатомнар ниләр яза?

— Синең препаратың аларда сыналмаган әле. Анысы белән контрразведка бик кызыксынмыйдыр да. Хатын-кызларга алар, мөгаен, башка чара кулланалардыр.

— Абзыйга әйтәм әле, — дип, тагын ишек яныннан әйләнде Вилен. — Фән өчен бик кызыклы бит бу! Шулай бит, Федор Кузьмич?

— Ә бәлки, — диде профессор, авыз эчендә чүбек әвәләгәндәй. — Эксперимент үткәреп карарга була. Хатын-кызлар төрмәсенә заявка бирсеннәр соң. Берәр яшь, сау-сәламәт кандидатура тапсыннар... Мин кул куярмын...

— Әйе шул, абзыйга сездән хат алып барырга кирәк, — диде Вилен. Ул башына килгән һәр эшкә шундук тотына торган иде. Ә нәрсәгә сузарга? Калган эшкә кар ява, диләр.

Һәм ул профессор өстәлендәге кара телефон аппаратына сузылды. Аппарат янында кәгазь ята, анда: «Барлык сөйләшүләр тыңлана», — дип язылган иде. КГБ кисәтүе иде бу, андагылар тыңлый.

Тыңласыннар соң! Вилен чит кешегә түгел, полковник Канчуровның кабул итү бүлмәсенә шылтырата лабаса.

R R R

Касыйм Канчуровның бүлмәсендә һәрнәрсә, әкияттәге алып батыр өчен эшләнгәндәй, зур итеп, нык итеп ясалган иде. Ишеккә каршы якта, бүлмә хуҗасының баш өстендә арык, кырыс чырайлы, кәҗә сакаллы, фуражка һәм френч кигән адәмнең — Дзержинскийның сурәте эленеп тора.

Саргылт тукымадан тегелгән гадәти җәйге костюм кигән олы бәдәнле, зур башлы полковник бу мохиттә ничектер кечерәеп калган кебегрәк күренде.

— Ни булды? Тияләрме әллә? — дип каршы алды ул Виленны. Һәм, урыныннан кузгалмый гына, үзе утырган өстәлгә тар башы белән терәп куелган озын өстәл кырыеннан урын күрсәтте.

Вилен бик иркенләп йомшак урындыкка утырды, кулындагы кара портфельдән бер бит кәгазь чыгарып, абыйсы алдына шудырды.

— Бу нәрсә тагын? — дип, куе сары кашларын җыерды полковник.

— Профессор Рассекаевның үтенеч хаты, — диде Вилен, серле елмаеп.

— Ник турыдан-туры үзе минем белән сөйләшми?

— Син укып кара башта.

Язу кыска иде, полковник аны бер күз салуда укып чыкты, әмма озак текәлеп карап торды. Дөресен әйткәндә, профессор Рассекаевның хаты ошамады аңа.

— Кычытмаганны кашып йөрисез шунда, — диде ул, ниһаять. Аннары, башын күтәреп, Виленның үзенеке кебек үк зәңгәр, әмма яктырак, үткенрәк күзләренә текәлде. — Син уйлап чыгардыңмы әллә моны? Нәрсәгә ул сиңа? Әнә ресторанга бар да күзең төшкән кызга аракы белән шампанны кушып чөмерт. Ике рюмкадан тәкатьсез калып, якаңнан эләктереп алыр да эчке бүлмәгә өстери башлар.

Вилен, мәгънәле елмаеп, яңа препаратның киләчәктә нинди әһәмияткә ия булачагын аңлата башлады. Җенси куәтне арттыра торган даруны табу өстендә дөньяның иң мәртәбәле галимнәре эшли. Әгәр без бөтенесеннән алда шундый препарат ясый алсакмы?..

Касыйм энесен ярты сүздән аңлады, әмма бик очынып китмәде.

— Безгә кирәге булмаганда, төкерәм мин синең фәнеңә! — диде ул. «Без» дигәндә ул разведканы күз алдында тота иде. — Киләчәктә синең үзеңә кирәк булса гына инде... Экспериментны да үзең үткәрмәкчеме әллә?

— Нәтиҗәсен үз күзем белән күрсәм яхшырак инде.

— Мәетләр белән эш иткәнең бармы соң әле синең? Адәм баласының җан биргәнен күргәнең дә юктыр әле, бәлки? Ул сиңа ресторандагы шәрә кызларның бот болгаганын күзәтеп утыру түгел!

— Син нәрсә, абзый! — Вилен абыйсына, үзләренең ягындагыча, «абзый» дип дәшә иде. — Шактый хәлләр үтте инде бу баштан! — Егет, шукланып, салам төсле чәчләрен сыпырып куйды. — Дүрт ел элек, теге ике пассажир поездына ут кабып янганнан соң, студентларны шунда беренче итеп җибәрделәр бит.

Әйе, андый хәл булып алган иде шул. Бер үзәнле урында җир астыннан уза торган торба ярылган да газ чыгып торган. Көн җилсез булган, газ шул үзәнлеккә җыелган. Кара-каршы ике поезд килгәндә, электр чыбыгыннан очкын чәчрәп, бөтен дала җәһәннәмгә әверелеп, ут эчендәге вагоннар берсе өстенә берсе

менеп беткән иде. Андагы әкәмәт! Нечкә күңелле студентлар, аерата кызлар, баштарак һуштан язып, мәетләр янында үзләре тәгәрәшеп яттылар. Беренче көннәрдә Виленның да күңеле болганып, агарынып каткан чаклары булды. Әмма ул бирешмәскә тырышты. Атна ахырында барысының да нервылары чыныкты. Елау-сыктау бетте, тамактан ризык үтә башлады.

«Әгәр дә син бу минутта каршыңда маңка малай утыра дип уйлыйсың икән, бик нык ялгышасың, абзыкаем», — дигәнне аңлата иде егетнең елмаюы.

— Ә, әйе, онытып җибәргәнмен! Ул тирәдә сез дә чуалган идегез бит әле, — диде өлкән Канчуров. — Анысы бик яхшы булган. Ир-егетне чыныктыру кирәк. Тәнен генә түгел, нервыларын да.

— Чыныккан мин, абзый, чыныккан.

Полковник көрсенеп башын чайкады:

— Ә шулай да мондый эшкә кулым тартмый минем, — диде. — Разведкада ул икенче, анда мәҗбүрият куша. Ә монда сезнең бу экспериментларыгыз безне палач хәленә куя шикелле...

Вилен аның беркатлылыгыннан көлеп җибәрде:

— Фән корбаннарсыз булмый шул, абзый! Күптән әйтелгән бит инде бу!

Полковникның чырае ачылмады, әмма ул сүзне озакка сузмыйча, адъютантын чакырып, «секретный» дигән гриф белән ике кәгазь язарга кушты. Берсе — яңа медик препаратны сынау өчен, яшерен рәвештә, хатын-кызлар төрмәсеннән бер кандидатураны сайлап алырга. Ул яшь, сәламәт һәм чиста булырга тиеш. Икенчесе — Канчуров Вилен Шаяхмәтовичка төрмәгә пропуск бирергә.

— Ә ампула белән инструкцияне без институттан җибәрербез, — диде Вилен.

Ул чыгып киткәч кенә, полковник, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, маңгаен уып куйды.

— Кайда булачак соң әле бу? — диде үзалдына. — Мәетне ирләр төрмәсенә ташып йөрмәсләр бит инде. Шунда ук тикшерсеннәр дә.

Һәм тагын адъютантын чакырып кертте.

— Тагын бер кәгазь кирәк булыр, — диде ул. — Хатын-кызлар төрмәсендәге баш табиб исеменә. Патологоанатомик тикшерүләрне ярты сәгатьтән ясарга һәм сәгать саен анализларны кабатлап торырга. Моның өчен баш табиб үзе җавап бирә, дип кисәт. «Совершенно секретно» дигән грифлы кәгазьгә басыгыз! Һәм бусын иртәгә җибәрергә.

«Андагы табибларга озак уйлап торырлык булмасын, — диде ул үз-үзенә. — Солдатлар кебек, команданы алуга — үтәсеннәр!»

R R R

Әйе, армия хезмәтен узмаса да, әҗәлнең кыланмышларын күрергә туры килгәләде Виленга. Дөрес, мондый күренешләрдән тәм таба торган җәлладлар кавеменнән түгел ул үзе. Аңа шул күсе, дуңгыз, эт кебек хайваннарда үткәргән тәҗрибәләрне күзәтү дә бик җиткән. Ә адәм балаларының ничек-ничек җан тәслим кылуына килгәндә исә, ул моңарчы үзе ясаган препаратны сынау турында табиблар язып биргән белешмәләрне уку белән канәгатьләнә иде.

Ләкин бу очракта каны кызган, тәкате төкәнгән хатын-кызның кыланмышларын үз күзләре белән күрәсе килде. Чыннан да, аның даруы нинди тәэсир ясый икән? Фәкать шул гына. Тәҗрибә өчен сайлап алынган хатынның, ягъни «кандидатура»ның нindирәк икәнлеге аны бөтенләй кызыксындырмады. Олымы ул, кечеме, чибәрме-ямьсезме — аның өчен барыбер иде. Төрмәгә килеп эләккән икән, рәтле нәрсә түгелдер. Һәрхәлдә, аны үзең белән чагыштырып булмый. Ике аяклы, ике куллы булса да, бөтенләй башка төрле җан иясе, әйтик, маймыл кебегрәк инде ул. Тәҗрибә өчен лабораторияләрдә асрала торган күселәр, этләр кебек.

Ул иртәне Вилен шактый вакытын үзенең эш бүлмәсендә яңа килгән журналларны карап утырды. Галимнәр, югары дәрәҗәдәге фән әһелләре өчен чыгарыла торган басмалар иде болар. Әмма аларда да Вилен Канчуровның соңгы ачышлары хакында язарга ярамый иде. Яңа фәнни казанышлар турында укыганда, галимнәрнең сурәтләренә караганда, аның бәгырен көнчелек хисе талады. Кешеләрнең хезмәте күренә, исемнәре бөтен дөньяга таныла. Вилен булдырганның чирeгe хәтле дә эш майтара алмаган башка бүтәннәр йолдыз булып калыкканда, аңа җир астында тырмашкан сукыр тычкан булып яшәргәме?! Моны уйлаганда, егетнең сулышы кысыла башлый иде.

Тагын бераз тикшерүләр үткәреп, препаратны чак кына үзгәртергә кирәк. Аның үтергеч сыйфатын бетереп, җенес әгъзаларына тәэсирен генә калдырырга. Ахыр чиктә, иң шәп дарулар иң көчле елан агуларыннан ясала бит. Бу очракта да нигә шулай итмәскә?

Әйе, ул үз эшендә төрле еланнарның агуларын да файдалана һәм бик сирәк очрый торган агулы үсемлекләрне дә. Аларның бәгъзеләрен хәтта Көньяк Америкадан ук китерәләр. Виленның бередә, тимер

ишек артында, бикләнеп утыруының төп сәбәбе дә шунда: эш өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган, хөкүмәт разведка өчен бернәрсәне дә жәлләми. Мондый шартларда бөтен зирәклеген җиксә, белемен арттырып торса, көчен кызганмаса, морадына ирешми калмас ул. Мәгълүм булганча, бүгенге чорда иң зур ачышлар төрле фәннәрнең бер-берсенә тоташкан ноктасында ясала. Шуңа күрә ул фармацевтиканы да, токсикологияне дә нык өйрәнде.

Хәзер аның бару юлы ачыкланып килә шикелле. Озакламый моннан кыяклау ягын карарга кирәк. Билгесез галим булып каласы килми иде аның. Менә шушындый кәгазьләрдә, ачык буяулар белән басыла торган журналларда исемен балкытасы, шөһрәтле һәм бай буласы килә иде.

Ә бу препарат байлыкны күп китерәчәк. Җенси көчсезлекне җиңә торган даруга күп меңнәр мохтаҗ. Һәм бигрәк тә түрәләр, чит илләрнең байлары кирәксенә аны. Аларның дөньясы түгәрәк, хатыннар белән әвәрә килүдән бүтән гаме калмаган. Атаклы миллиардерларның күпмесе, әнә картайгач, бөрешеп-сөрсеп беткәч, дөньяның иң чибәр кызларына өйләнә. Башларыннан сыйпатыр өчен генә түгелдер бит инде! Әгәр аларга теге чибәркәйләр кочагында ләззәт кичерерлек дару бирсәң, ә? Шуның өстенә тагын даруның хатыннарга яраклысын да ясап чыгара башласаң? Чибәркәйләрнең дәрте кузгалып, тәкатьсезлектән тонган күзләренә карт ирләре яшь күренеп, шашып-шашып иркәләнсәләр? Һай, нинди шәп булачак иде бу! Җирдә шундый оҗмах тудырган галим өстенә алтын яңгыр явачак иде... Вилен ул даруларга исем дә табып куйды инде: «Вика-инь» һәм «Вика-ян» дип аталачак алар. Беренче өлеше аның үз исем-фамилиясеннән, икенчесе — кытай философиясеннән: аларда «инь» — хатын-кыз табигатен, «ян» ир-ат табигатен аңлата. Шәп исем булачак бу!

Фән өлкәсендә галимнәр арасында узыш-ярыш бара һәм ул бер минутка да туктап тормый. Һәр юнәлештә төрле илләрнең күп галимнәре эзләнә. Яңа ачышны кем алданрак патентлап куйса, шул уңа. Виленга башкалардан алда өлгерергә кирәк. Дөрес, хәзергә бу илдә мондый казаныш белән мактанып, түш киереп йөреп булмас булуын, чөнки бездә җенси куәт турында авызны зур ачып сөйләү юк. Гәрчә бик күпләр нәкъ менә шул яктан зәгыйфьләнеп, зур рухи газап чигеп яшәсәләр дә. Андыйлар арасында төрлесе бар: яшерен заводларда агуланган эшчеләр дисеңме, атом-төш коралын ясауда һәм сынауда катнашкан егетләр дисеңме — санап бетергесез. Әлегә аларны исәпкә алучы да, хәлләренә керүче дә, дәва бирүче дә юк. Әмма мәңге болай булмас, дөнья үзгәрми тормас. Халыкка иркен сулыш алырга мөмкинлек бирелсә, бу мәсьәлә шундук калкып чыгачак, Вилен уйлап тапкан даруга ихтыяҗ чамасыз булачак. Моңа алдан ук әзер торырга кирәк, юлыңа беркем дә аркылы төшәрлек булмасын.

Вилен шуларны уйлап елмаеп куйды да, ак күлмәгенең затлы каптырмалы, крахмалланган керсез җиң очын кайтарып, авыр алтын сәгатенә күз салды. Бәй, унике тулып узган икән бит инде! Ә сынауны бердә башларга дип сөйләшенгән иде. Ач йөреп тә булмас, тиз генә ашап алырга кирәк!

Ул журналларны өстәл тартмасына салып бикләде дә урыныннан кузгалды. Аннары телефонын алып төрмәгә шылтыратты:

— Башлый торсыннар анда! Мин озакламый килеп җитәм!

Коридорда аңа көрәнсу костюм кигән җыйнак гәүдәле илле яшьләрдәге ир кеше каршы булды. Аяк тавышлары гына ишетелсен, ул кем узганын күрми калмас, бүлмәсеннән атылып чыгар!

— Исәнмесез, Вилен Шаяхмәтович! Ашханәгә барумы?

— Саумысез, Гобәй Не... Насипович, — диде Вилен, авызын чалшайтып. — Әйе, шунда бару.

Ул «Насипович» урынына «Неусыпович» дип әйтүдән чак тыелып калды. Чөнки бүлектәгеләр бу адәмне үзара нәкъ менә Неусыпович дип атыйлар, ягъни күзен һич йоммый, һәммәсен күрә торган уяу кеше дип беләләр иде.

— Гадәттә соңрак ашый торган идегез, — диде ул Виленга, арттан тагылып.

— Аннары барасы җир бар.

Вилен тиз генә узып китә алмады, коридорның аргы башында басып торган сакчы егетнең, борынгы заман түрәләре каршында кылангандай кечелекле кыяфәт белән, ишек бикләрен ачканын көтеп торырга туры килде. Неусыпович та Вилен артына килеп баскан иде.

— Берәр фәнни киңәшмәгәме әллә? — диде ул, ясалма елмаеп.

— Эксперимент үткәрәбез.

— Шулаймыни?! Бик яхшы, бик яхшы. Уңышлар телибез сезгә. Бездән хәер-фатиха. Кайда инде ул?

— Төрмәдә, — диде Вилен, саруы кайнаганын сиздермәскә тырышып.

— Ә-ә, шулаймыни... Нәтиҗәсе кайчан билгеле булыр икән?

— Анысын бездән дә алданрак сез белерсез инде, — дип, Вилен ачык ишектән чыгып шыларга ашыкты.

Бу бинада аның эчен иң нык пошырган адәм шушы иде инде. Башкалар кебек үк «фәнни хезмәткәр» дип аталса да, аның фәнгә бернинди дә катнашы юклыгы, бирегә махсус органнар тарафыннан күзәтчелек

итәргә куелганы барысына да мәгълүм иде. Ишек янындагы каравылчы берни түгел, аның яныннан узасың да китәсең. Ә менә Неусыповичтан котылу чарасы юк. Ул сине коридорда да сагалый, бүлмәңә кереп, кәгазьләреңә дә борынын тыга һәм ничек сулыш алганыңа кадәр тиешле урынга хәбәр итеп тора. Бер ягы гына яхшы: шыр надан үзе, химиядә дә, фармакологиядә, ягъни дарулар турындагы фәндә дә берни аңламый. Шуңа күрә бүлектәгеләр Неусыповичның кадерен бик беләләр, аңа каршы әйтмиләр. Алла сакласын, аны алып, урынына берәр белемлерәкне китереп куйсалар нишләрсең? Ул чакта инде Виленга яшереп кенә үзе теләгән препаратны ясау өчен бернинди мөмкинлек калмаячак. Шуңа күрә Неусыповичка каршы әйтергә һич ярамый иде.

Ашханә юлында күрше бүлектә эшләүче Анфиса очрады. Аның белән берничә авыз сүз алышмый узып китеп булмады. Кыскасы, барасы җиренә аз гына соңарды Вилен.

R R R

...Ә төрмәдә барысы да әзер иде. Дөрес, алдагы көнне шактый ыгы-зыгы кубып, аптырап калулар булды булуын. Полковник Канчуров кул куйган боерыкны алгач, баш табиб Сергей Матвеевич Грачев та, Эльза Бруновна да шактый сәерсенделәр. Кәгазьне кат-кат укып, юллар арасындагы яшерен мәгънәне аңларга тырыштылар. Гүяки бу — разведчиктан килгән шифрлы язма иде. «Яңа медик препаратны сынау өчен» дигән сүзләр аңлаешлы иде югыйсә. Әмма нинди икәнлеге дә, кешегә нindирәк йогынты ясаячагы да, дикъкатьне нәрсәгә юнәлтергә кирәклеге дә язылмаган иде. Ләкин разведкадан, ни кирәк сезгә, дип сорап буламыни? Әйтелгәнне үтәргә генә кала.

Моңа кадәр органнарның бирегә мондый эше төшкәне юк иде югын. Дөрес, өстән караганда, гайре табигый нәрсә күренми иде. Яңа даруларны сынау була торган хәл — галим-табиблар аны үзләрендә дә сыный. Шәкерт-студентларның да күпләре моңа бик теләп бара, чөнки аның өчен имтиханда билгене бер баллга арттырып куялар.

Бер генә кыенлыгы бар — төрмәдә яшь, сәламәт хатын-кызны табу җиңел түгел. Аннары «чиста» дигәнне ничек аңларга тагын? Юындырып куярга диюләре генә микән? Ай-һай ла! Сайланган «кандидатура»ны, рәсми кәгазьгә язып тормасалар да, эксперимент алдыннан мунча кертеп, чиста кием кигезәләр бит инде. Мөгаен, бу сүз артында юынган булу гына түгел, тирәнрәк мәгънә ятадыр. «Гыйффәтле» дигәнне аңлатмый микән? Андыйлар исә бу тирәгә бик сирәк эләгә, эләксә дә, чиста калып озак утыра алмый.

Шулай итеп, төрмә табибларына шактый баш ватарга туры килде. Тикшерүчеләрдән сораштыра торгач, алар Кадермәтовага килеп юлыктылар. Куелган таләпләргә нәкъ менә ул тулысынча җавап бирә иде.

Төнгә каршы, отбой булыр алдыннан, мәхбүс кызны камерадан чакырып алдылар. Сәламәтлеген сораштылар, кан басымын үлчәделәр, үпкәсен тыңладылар. Хатын-кыз табибы өенә кайтып киткән иде инде, Эльза Бруновна Заһидәне ширма артына алып кереп үзе карады.

Табибәнең күпне күрсә дә бирчәймәгән күңеле сыкрап куйды. Төрмә-зоналарда мондый хатын-кызны ни көткәне билгеле бит инде. Бигрәк тә яшь, чибәр булса... Күңелгә янә шик корты үрмәләде. Нәрсәгә кирәк икән мондый «кандидатура» сайлату? Яңа даруны сынау дигәннәре үзенә бер сылтау гына түгел микән? Әллә берәр азгын начальникның яңа гына пешеп җиткән татлы җиләк белән сыйланасы килгәнме? Яки үзеннән зуррак түрәне сыйлыйсы? Аларны кем белеп бетерсен... Элекке елларда КГБ хуҗасы Бериянең ниләр кыланганын хәзер бөтен халыкка фаш иттеләр итүен. Ул ерткыч күзе төшкән яшь кызларны урамнан алып кереп мәсхәрәли торган булган. Хәтта кулга алынып, төрмәдә ятканда да: «Шәраб бирегез! Кыз китерегез!» — дип кычкырып ятканын сөйлиләр. Атыласын белә торып! Үләр алдыннан аңа хәмер белән кыз кирәк булган!

Ул чордагы күпләр һәр яктан аннан үрнәк ала иде... Берияне атканнан соң, койрыкларын кысканнар иде кысуын да, хәзер тагын иркенәеп киттеләр. Элекке гадәтләрен куа башласалар гаҗәпмени?

Ә андыйлар гигиенаны бик кайгырта. Борынгы заманнарның алпавытлары кебек, беренче төн аларныкы булырга тиеш! Яңа дару сыныйбыз, диюләре кызны тикшертү өчен бер сылтау гына түгел микән? Ә бәлки, «препарат» дигәннәре авыртуны баса торган дару — гап-гади новокаин гынадыр?

Табиблар алдында бик күп сораулар туды, әмма җавап юк иде. Йөрәкләре сыкранса да, телләре бикле калды: кушканны үтәмичә мөмкин түгел иде.

Икенче көнне төш турында, Кадермәтованы процедура бүлмәсенә алып кереп киткәч кенә, Сергей Матвеевичның кулына тагын бер кәгазь китереп тоттырдылар. Аны алып укыгач, табибның чырае күгәреп чыкты...

R R R

...Вилен ак «Волга»сын бакча янындагы мәйданчыкта туктатты. Аңа кирәкле бина — бакчаның каршы ягында, әмма аның ишеге төбенә машина куярга рөхсәт ителми.

Ул машинадан төште дә ашыгып бакчага керде. Агачлар арасындагы юлдан, бер-берсенең итәкләренә тотынып, чыркылдашып сабыйлар бара иде — якындагы балалар бакчасыннан булса кирәк. Каен төбендәге өстәл янында картлар домино суга, эскәмияләрдә әбиләр гәпләшеп утыра.

Ни ашыкса да, Вилен фонтан янында туктамый китә алмады. Шыбырдап коелган тамчылар арасыннан мәхәббәт алласына таба бармакларын сузды, ак, сары нарциссларга сокланып карады. Башка бер сәер уй килде: нинди гаҗәп бу дөнья! Шушындый оҗмах бакчасы каршында нинди шомлы, серле биналар басып тора! Хәтергә «Җәһәннәмгә илтә торган юлларга изге ниятләр түшәлгән» дигән гыйбарә килде. Оҗмах белән тәмуг янәшә... Ике урам аша гына...

...Караңгы чырайлы сержантка ияреп, авыр, шыгырдавык, тутыккан тимер ишекләр аша узганда, Вилен үзен, чыннан да, бөтенләй башка, газаплы урынга килеп эләккәндәй тойды. Менә алар хастаханәләргә генә хас, күңелне изә торган ис килгән коридорга килеп керделәр. Сержант бер сүз әйтми генә тезелеп киткән ишекләрнең берсен ачты. Вилен эчкә атлады.

Каршыда, ак җәймәле өстәл янындагы урындыкта, яртылаш акка буялган тәрәзә пыялалары аша төшкән кояш яктысында, ак күлмәкле кыз утыра иде. Ул карашын тәрәзәгә төбәгән, уң кулының учы белән сул беләген кысып тоткан. Бүлмәдә тагын ак халатлы ике хатын-кыз бар иде. Берсе, яшьрәге, шәфкать туташы иде булса кирәк, поднос тоткан, анда шприц, мамык кисәге ята. Икенчесе өстәл янында нидер язып утыра иде. Уколны ясаганнар иде инде...

Ишек ачылганны күреп, өстәл янындагы хатын тураеп басты. Талчыккан чырайлы, бераз калкыбрак торган зур коңгырт күзле бу апа, мөгаен, табибә иде.

— Исәнмесез. Мин лабораториядән, — диде Вилен, аның сүзсез соравына җавап биреп.

— Мин табибә... Эльза Бруновна... Ун минут элек кенә инъекцияне ясадык, — диде ул ярым пышылдап.

Ак күлмәкле кыз әкрен генә башын борды да салмак хәрәкәт белән торып басты. Виленга ул бик яшь булып күренде. Менә аның чуалган куе кара чәче артка сирпелде, тулышып торган иреннәре ачылып, энҗе тешләре күренде. Менә ул, керфекләрен тибрәндерергә дә онытып, Виленның йөзенә текәлде. Аның коңгырт күзләрендә башта гаҗәпләнү, сорау галәмәтләре чагылды. Аннары очкын булып сөенеч кабынды. Ул көчәйде, очынуга, талпынуга әверелеп, кызның түгәрәк бит очларын алландырды, ирен читләрендә елмаю балкытты.

Шунда бүлмә яктырып киткәндәй, дөнья кинәт үзгәргәндәй булды. Әйтерсең лә бу кыз бала Виленның килгәнен көткән. Бик күптәннән, сагынып-зарыгып, бәгырьләре телгәләнеп көткән ул аны... Ахыр чиктә, тәмам гаҗизләнеп, өмет йолдызы сүнәр чиккә җиткән булган. Менә хәзер күңел күгендә ул йолдыз кинәт өр-яңадан калыккандай, алай гына түгел, күк капусы ачылгандай булды.

Ул бөтен барлыгы, җаны-тәне белән Виленга омтылды. Бу омтылышта гөл чәчкәсендә булган сафлык-садәлек, караңгы төндә еракта балкыган учак чаткыларындагы тарту көче бар иде. Күзләрдән саф җанның, керсез күңелнең яктысы бөркелсә, яшь, сәламәт, дәртле тәннән күзгә күренмәс, тыеп булмас дулкыннар ургылды һәм Виленны баштанаяк серле, әкияти томан белән төреп алгандай итте. Егетнең рухы, җаны, бөтен вөҗүде бу нурларга, бу дулкынга, акылдан сорап тормыйча, фикерләү белән исәпләшмичә, нәкъ шундый ук алгысу, очыну, куаныч белән җавап бирде.

Кыз, бөтен гәүдәсе белән алга тартылып, кулларын Виленга таба сузды. Ул менә-менә егылыр кебек тоелды, әмма каушамады, шикләнмәде, ул егетнең үзен күтәреп аласына ышанган иде. Кайсы адәм заты башка берәүгә шушылай якты, җылы нур бөркеп карый? Кемгә таба ул шундый ышаныч, куаныч белән омтыла? Бәлки, ике бертуган Сак белән Сок бик озак күрешә алмый газаплангач, түзә алмаслык сагынудан зар-интизар булып, аһ-зарлардан күп күз яшьләре түккәннән соң күрешә алган булсалар, нәкъ менә шулай исәнләшерләр иде. Ана кеше озак еллар читтә йөреп кайткан газиз баласын шушылай каршы ала. Явызлар тарафыннан рәнҗетелгән кыз бала сөекле абыйсын күреп шулай куана. Һәммәсе бар иде бу караштa, бу ымда һәм, тагын шуңа өстәп, Мәҗнүнен күргән Ләйләдәге кайнарлык та кушылган иде аларга.

Салават күпере кебек төсләргә бай бу тойгылар Виленның да йөрәгенә килеп тоташты һәм анда шундый ук туганлыкны да, гыйшыкны да эченә алган хисләр кузгатты. Бернинди фәннең дә андый нурларның, дулкыннарның серенә төшкәне, бернинди галимнең дә аларның көч-куәтен иң төгәл мыскаллар белән үлчәгәне, иң көчле микроскоплардан күрә алганы юк әле. Аларны туктатырлык, тәэсиренә каршы торырлык киртәләр дә юк бу дөньяда.

Вилен бирегә ник килгәнен онытты. Ул, нишләгәнен аңламыйча, кулларын җәеп алга атлады, кызны күтәреп алды. Һәм шунда ук аның гәүдәсе хәлсезләнгәнен тойды, дымлы күзләренә кара пәрдә шуышканын күрде.

Кызны сак хәрәкәт белән дивар буендагы тар ятакка яткыргач, Вилен табибәгә борылды:
— Укол! Укол ясагыз хәзер үк!
— Нинди укол?
— Сез нәрсә? Табибмы, сарыкмы? Препарат белән бергә аңа каршы даруы да бирелә!
— Ә... Нигә?.. Мондый очракларда...
— Хәзер үк без җибәргән ампуланы китерегез!
Агарынган табибә ишектән чыгып йөгерде.
Ә кызның карашы тоныклана бара, тик күз бәбәгенең төбендә бер нокта гына сүнәргә теләми, ул һаман егеткә төбәлгән иде. Вилен аның башын күкрәгенә кысты, йомшарган тәненә үз йөрәгенең көчен бирергә теләде. Күпмедер вакыттан соң ишек ачылганы, табибәнең гаепле тавышы ишетелде:
— Безгә бер генә ампула китерелгән. Башка берни юк, ди баш врач.
— Анысы сезгә алдан җибәрелгән иде бит!
— Мин белмим... Баш врач... — дип, нидер быдырдады куркудан теле тотлыккан табибә.
Эш шунда ки, андый агулар ясаганда, аның тәэсирен киметә йә бөтенләй бетерә торган даруын да ясыйлар. Элегрәк ул дару бераз запас белән җибәрелгән иде. Шуңа күрә бу юлы Вилен бер ампула гына куйды да. Аның башын ялкын чорнап алгандай ярсу басты.
— Мин хәзер әйләнеп киләм, ә сез аны исән тотыгыз! — диде, әмер биргәндәй итеп. — Теләсә нинди чарасын күрегез, әмма мин килгәндә исән булсын! Башыгыз белән җавап бирәсез! Кая монда баш врач? Әйдә, күрсәт! — диде ул шәфкать туташына.
Баш табиб Сергей Матвеевич, урта яшьләрдәге кеше, ак башлык кигән, халаты өстеннән зәңгәрсу клеенка алъяпкыч буып куйган, резин перчаткаларын кулына учлап, бүлмәсе буйлап әрле-бирле йөренә иде. Атылып килеп кергән Виленга таба кисәк борылды да туктап калды. Аның күк күзләреннән ургылган нәфрәт пуляга тиң, эчендә җаны булганны аяктан егарлык иде. Әмма Вилен моны сизмәде, кабаланып:
— Сезме баш врач? — диде.
— Сез кем соң? Кем кертте монда сезне?
— Мин... лабораториядән... Канчуров минем фамилиям.
— Мин монда баш врач... Сезнең эшегезнең нәтиҗәсен көтеп торам менә, — диде ул, ачуын тыярга тырышып. — Әзер торырга боердылар.
— Алай булгач, нишләп сез һаман монда?
— Ә кайда булыйм? Моргка ук кереп торыйммыни? Шунда илтсеннәр, мин хәзер барып җитәрмен!
— Кая илтсеннәр?
— Моргка, кая булсын! Бездән тормас, шундук тотынырбыз. Сезгә бит минутында кирәк. Менә монда сорауларны язып җибәргәннәр.
Табиб өстәлдән кәгазь бите алып, Виленның битенә китереп терәгәндәй итте. Үлгәннән соң ярты сәгать үтүгә тикшерүләр башларга, аннан соң ярты сәгать саен анализлар алып торырга...
— Безнең буйсынмый хәлебез юк, — диде табиб. — Әйдәгез, киттек!
— Кая?
— Ярганны карап торасыгыз киләдер бит? Шуңа дип килгәнсездер?
Виленның томан сарган миендә кинәт якты лампочка кабынгандай булды. Бу кеше теге кызны ярырга әзерләнгән ләбаса... Әйе, разведка хезмәте өчен препаратның йогынтысын шулай тикшерергә кирәк тә.
— Икенче ампула кайда? — дип, табиб өстенә килә башлады ул.
Сергей Матвеевич урыныннан кузгалмады, үзеннән шактый калку егетнең йөзенә туры карар өчен, башын гына артка чөйде.
— Нинди дару? Кайсы ампула? Ә сез аны безгә китердегезме соң?
— Элек җибәрелгән иде бит! Шуны бирегез!..
— Кая җибәрелгән иде? Безгәме? Беләсегез килсә, бу — бездә беренче очрак! Беренче! Аңладыгызмы? Һәм соңгысы да булыр! Минем белән болай шаярырга ярамый! Сезнең монда нинди сынау ясаганыгыз әле генә беленде! Ун минут элек китерделәр миңа моны!
Табиб кәгазь битен Виленның борын төбендә селкеде:
— Больше не допущу! Здесь вам не крысятник! — дип кычкырды ул. — Сезгә нәрсә, үлемгә хөкем ителгәннәр генә җитмиме әллә?! Судсыз-нисез үтерергә кем хокук бирде?! Төрмә дигәч тә, кешеләр утыра монда да. Хатын-кызлар!
Виленның өстенә кайнар су коелгандай булды. Әйе, ул теге даруны күбрәк итеп җибәргән иде. Ләкин ирләр төрмәсенә! Ә бу — хатын-кызлар төрмәсе!..
Каршысында профессор Рассекаев кебегрәк берәү яисә полковник Канчуров басып торса, бу абый болай кычкырына алмас иде, билгеле. Яшь кешедән ул бик үк курыкмый, шуңа күрә ачу-ярсу хисләрен

бәйдән ычкындырган иде. Өстәвенә ул бу егетнең нәрсәдәндер нык каушаганын, нишләргә белми бәргәләнгәнен сизеп алды һәм шунлыктан тагын да очыныбрак китте.

— Доктор, зинһар, чарасын күрегез! — диде ялварып Вилен. — Саклагыз аны, саклап калыгыз! Мин хәзер әйләнеп киләм! Хәзер даруын китереп җиткерәм!

— Аңламассың сезне, — диде табиб, алъяпкычын сала-сала. — Әле генә тиз арада җан бирсен, әле генә тере калсын...

Һәм, үзалдына сукрана-сукрана, ишектән чыгып, йөгерә-атлый коридор буйлап китте.

— Моннан ары безгә болай гына керә алмаслар... Төбенә төшми калмам... — дип сөйләнде ул, ашыгудан тыны кысылып.

Вилен исә йөгереп барып ак «Волга»сына утырды да шәһәргә чапты...

Ул кире әйләнеп килгәндә, кызны тәгәрмәчле арбага (носилкага) күтәреп яткырганнар, янына кан сала торган аппарат куйганнар иде. Ишек ачылган тавышка Сергей Матвеевич белән Эльза Бруновна дәррәү борылып карадылар. Аларның йөзенә күз салуга, Виленнең иңеннән тау төшкәндәй булды — ул Заһидәнең исән икәнлеген аңлап алды.

— Менә, — диде, учындагы пробирканы сузып. — Укол ясагыз тизрәк!

Шундук үзе дә сизмичә, шактый тупас хәрәкәт белән табибәне читкәрәк этәреп, Заһидәнең өстенә иелде һәм аның сизелер-сизелмәс сулышы йөрәгенә шатлык, куаныч булып тулганын тойды.

Шактый вакыттан соң ул, кан салу аппаратының салкын тимер таягын тотып, Заһидә яткан носилка белән коридор буйлап бара иде.

Кызны палатага кертеп, ипсез тар караватка күтәреп салдылар. Заһидә керфекләрен күтәрде. Виленны күрүгә, күзләрендә янә очкыннар кабынды, иреннәрендә елмаю яктысы чагылды.

— Мин синең киләсеңне белдем, — дип пышылдады ул. — Мин сине шундый көттем... Шундый көттем...

Вилен тетрәнгән куллары белән аның чуалган чәчен сыйпады.

— Тыныч бул, мин монда. Барысы да узды инде... Борчылма...

Тәбәнәк карават янындагы җайсыз утыргычта, бөгелә төшеп, кызның йөзеннән күзен алмый шактый озак утырды ул. Аның озынча ахак тырнаклы алсу, нәфис бармакларын сыйпады. Күзләрендәге нурлы томан аша бераз сәерсенү, сорау галәмәтләре күреп:

— Мин Вилен, — диде. — Ә син?..

— Заһидә мин. Вилен дисеңме?.. Беренче ишетәм...

— Миндә генә бит ул исем, шуңадыр. Беләсеңме ул каян алынган? Владимир Ильич Лениннан. Синең яныңда бик зур кеше утыра, белеп тор.

Заһидә хәлсезлектән авырайган керфекләрен төшермәскә тырышып елмайды:

— Син юридик факультеттанмы?

— Нишләп алай уйлыйсың?

— Безнең декан Васил Кәбирович бик яхшы кеше бит. Әтиебез кебек. Мин уйладым, ул мине ташламас, дидем. Юридик факультеттагылар белән киңәшер дә адвокат җибәрер, дидем. Сине монда ул җибәргәндер бит?

Алар янына Сергей Матвеевич килеп басты.

— Авыруга ял итәргә кирәк, — диде. — Күп сөйләштермәгез.

Табиб читкә киткәч, Вилен Заһидәнең колагына иелеп, назлы гына итеп пышылдады:

— Мин сиңа барысын да, барысын да сөйләрмен. Иртәгә.

— Ә син килерсеңме?

— Мин сине моннан алып чыгарга килдем, Заһидә!

Китәр алдыннан Вилен баш табибтан:

— Ул-бу куркыныч юктыр бит инде? — дип сорады.

— Ампулада нинди матдә булганын әйтсәгез, мин сезгә авыруның хәле ничек буласын әйтермен, — диде Сергей Матвеевич тыенкы гына. Аның элекке ярсуы басылган, бу егетнең ачуын китерергә ярамаганлыгын, йон уңаена сыйпарга кирәклеген ул төшенгән иде инде. Югарыдан килгән кәгазьләргә «полковник Канчуров» дип имза салынган, аның улы микән әллә бу? Һәрхәлдә, туры муенына, киң канатлы, чөенке борынына караганда, арты нык төсле бу егет. «Андыйлар белән саграк булырга кирәк, — дип уйлады табиб. — Кайсы шагыйрь әйткән әле «йөртә безне язмышлар» дип? Язмышлар түгел, Канчуровлар йөртә безне!»

— Бу кыз... танышыгыз, ахрысы?! — дип, егетнең йөзенә төбәлде ул. Җавап булмагач, үкенгәндәй, әкрен тавыш белән дәвам итте: — Кызганыч, безгә әйтүче булмады...

Йөргән кызыдыр, мөгаен, дип нәтиҗә чыгарды Сергей Матвеевич. Ләкин ничек ул бирегә килеп эләккән?..

Бер-бер аңлашылмаучылык килеп чыкса, гаепне аның өстенә өймәгәйләре дип шикләнә иде табиб. Өстәгеләргә бернинди ышаныч юк, үзара буталышып яталар шунда. Уйлап карасаң, кем генә таптамаган бу илдә төрмә юлларын! Дәүләт җитәкчесе Калининның, тышкы эшләр министры Молотовның хатыннары, Сталинның үзенең кардәшләре... Ул органнарга ышансаң! Бер кулы нәрсә эшләгәнне икенче кулы белми. Эт баш, сыер аяк!

Соравына җавап булмагач:

— Авыруның сәбәбен белмичә дәвалау җиңел түгел, — дип куйды Сергей Матвеевич, төшенке тавыш белән.

— Этиологиясе ачыкланмаган очракларда да авыруны дәвасыз калдырмыйсыздыр бит? — диде, аның йомшаклыгын күреп батырайган Вилен.

— Әлбәттә, әлбәттә... Болай караганда, хәле начараерга тиеш түгел шикелле. Төнгелеккә кизү оештырырбыз...

R R R

Мортаза сырхауханәгә иртәнге җидедә үк килде. Көн аяз, җәйге җиләс иртә ямьле булса да, егетнең күңел күген көзнең карлы-яңгырлы болытлары каплаган кебек иде. Бинаның эченә кереп, регистратура тәрәзәсенә таба сузылган су буе чиратны күргәч, тәмам кәефе кырылды.

Йа Алла, коммунистлар хакимлеге бетерелгәннән соң, тормыш тамырдан үзгәрде, диючеләр бар тагын. Сырхауханәгә килеп карасыннар алар! Андагы һәр бүлмәнең ишек төбенә тезелеп утырган кешеләрнең сытык чырайларын күрсеннәр. Синең чират та минем чират, дип төрткәләшкәннәрен, талашканнарын ишетсеннәр. Җитмәсә тагын, Мортазага кирәкле, ишегенә «Уролог» дип язылган табиб янына ашкынучыларның күпчелеге пенсионер картлар булып чыкты. Аларны Ватан сугышы, аннан соңгы елларда җир тырмашып яшәү, олыгайган көндә собес чиратлары — бер сүз белән әйткәндә, нужа бозып бетергән.

Өлкәннәрне яратмау гөнаһ, әмма ни генә дисәң дә, бирегә җыелган картларга карагач, күңелдә җылы хис кабынмый шул. Җитмәсә, килгәне бере сугыш ветераны яисә тагын берәр төрле льготник булып чыкты һәм табибка чиратсыз керергә хокукын белдерде.

Аларның үзара зарланышып, ничек-ничек чирләве турында сөйләгәннәрен тыңлап озак утырырга туры килде Мортазага. Күбесе бирегә еллар буе йөри, кайсылары берничәшәр тапкыр операция кичергән икән. «Простата, бөердәге ташлар, рак... Ә Степан Петрович үлеп киткән бит!» дигән сүзләр, әкрен тавыш белән әйтелсәләр дә, колакны ярып керә иде. «Монда эшне бүтәнчәрәк оештырып булмый микәнни соң? — дип уйлады Мортаза аптырап. — Миндәге кәгазь кисәгенә тугыз сәгать унике минутка дип язылган бит югыйсә. Башкаларның да вакыты күрсәтелгән. Шул тәртипне саклап булмый микәнни?»

Ахыр чиктә ул: «Халык артык үсенеп китмәсен өчен, коллык психологиясен саклау өчен махсус шушылай корылгандыр бу, — дигән нәтиҗә чыгарды. — Түрәләр үзләре мондый җиргә килеп йөрми бит. Алар өчен үзенә аерым дәвалау урыннары бар. Андагы тәртип бөтенләй башка, диләр».

Дөрес, ул эшли торган заводның да үз хастаханәсе бар барын. Чират та күп булмый анда, табиблар да ягымлы. Әмма Мортазаның танышлар арасында мондый зар белән чуаласы килми иде... Гәрчә Гиппократ антында, авыруларның серен саклармын, дигән сүзләр булып, врачлар аңа тугрылык сакларга вәгъдә бирсә дә, алар алдында капчыкны төбеннән тотып селкер алдыннан бик нык уйларга кирәк. Нинди сер булсын ди ул, синең карточкаңа язылып, ачык киштәгә куелгач! Аны, кем теләсә, шул алып укый ала лабаса. Һәм, гомумән, табибларның күбесе сер тота белми.

Шуларны уйлаганнан соң, Мортаза район сырхауханәсенә килде дә инде. Озак утырды ул. Түзәргә тырышты. Ахырда сабыр канаты сынды, сикереп торды да чыгып китте.

Нишләргә инде хәзер?..

Әллә соң ишеткән, укыганнардан чыгып, үз белдегең белән ныклабрак дәваланып караргамы? Соңгы елларда «сүз иреге» бу өлкәдә дә ачылды бит. Хәтта нәкъ шушы турыда гына махсус гәзит-журналлар чыга. Ниләр генә юк анда! Бөтенесен шулхәтле чишендереп, аты-юлы белән язалар ки, медицина дәреслекләрең бер якта торсын.

Юл уңаеннан Мортаза шундыйларның берсен — «Спид-инфо» дигәнен бер кочак алып кайтты да рәттән мәкаләләр укый башлады. Күпчелеге күңелгә тия торган, хәтта җирәнү хисе уята торган булып чыкты. Чөнки табигать бүләк иткән шушы хәзинәнең матурлыгы, күңелне сафландыра, кешегә канат куя торган кодрәте юкка чыгып, хайвани канәгатьлек хисе алуга гына кайтып калган иде. Гәрчә... хайваннар

да, үзләренә пар сайлаганда, ничек кенә бизәнми, көязләнми дә, кошлар ничек кенә сайрамый. Ә мондагы язмаларда сандугач җырлары да, тавис койрыклары да юк... Болар язганча итеп, бәлки, киләчәктә тимердән ясалган, җансыз роботлар кушыла торган булыр. Әгәр дә аларны үзләреннән-үзләре, кеше катнашыннан башка гына үрчи торган итсәләр?..

Шул чүп-чар арасыннан энҗе бөртеге табарга тырышып шактый азаплангач, бер мәкаләдән эшкә яраклы киңәш табылган кебек булды. «Америкага акча эшләп кайтырга барган идем, — дип язган бер урыс кешесе. — Шунда бер хатын белән танышып, якынаеп киттек. Бер-беребезне ошаттык, өйләнешергә булдык. Анда, загста язылыр алдыннан, «никах килешүе» төзиләр икән. Мин инде аны рәтләп укып та тормадым, кулымны куйдым. Яшәп киттек шулай. Ир кеше буларак, гаиләне тәэмин итүне үземнең бурычым санап, элеккедән дә тырышыбрак эшли башладым. Таксида шофер мин. Иртә таңнан төнгә чаклы чабам, эт булып арып кайтам, койрык тагасы гына кала. Ә ул мине караватка өстери... Мин әйтәм, арыдым, бер хәлем дә юк. Берзаман бу миңа, син, ди, никах килешүен бозасың, мин сине судка бирәм. Нинди судка? Нәрсә өчен? Ул минем борын төбенә теге килешү кәгазен китереп терәмәсенме! Ә анда, әгәр дә мәгәр ир яки хатын үзенең җәмәгатенең җенси теләген үтәүдән баш тартса, бу килешү юкка чыгарыла, һәм аерылганда гаепле як бөтен милектән мәхрүм ителә дигән пункт бар икән!

Бик каты уйга калдым мин шуннан соң. Һәм ныклы бер карарга килдем... Эшне ташладым, өйдә ята башладым. Хатын үз эшенә китә, ә мин өйдә көч җыеп ятам. Гайрәтне арттыру өчен ата-бабадан калган чараларны кулланам. Каймак чөмерәм, петрушка яфрагы чәйним. Хатын, ишектән килеп керүгә, минем кайнар кочакка эләгә. Баштарак бик ошады бу моңа. Әмма бераздан маемлаганы сизелә башлады. Тукта инде, юынып алыйм, ди. Ә мин әйтәм, син тирләгән килеш тәмле... Бер иртәне эшенә киткәндә мин дә моңа иярдем. Машинаны паркның аулак почмагына илтеп туктаттым да чатлап ябыштым моңа. Ул бәргәләнә, ычкынмакчы була, эшенә соңга калудан курка. Ызгышып-талашып, көчкә ычкынды. Ә кич кайтуына мин моның борын төбенә магнитофон кассетасын китереп терәдем: «Никах килешүен ничек-ничек бозганнарың бөтенесе монда язылган!» Күзен акайтып карады да чыгып китте бу. Иртәгесен адвокаты шылтырата: «Эшне зурга җибәрмәгез инде, — дип ялына. — Хатынығызның, суд юлларында йөреп, мир алдында рисвай буласы килми. Күпме акча бирсә, сез тавышсыз-тынсыз гына аерылырга риза булырсыз икән?» Кыскасы, хәзер мин буйдак, кесәдә йөз сиксән мең доллар акча. Өйләнсәм дә, киләсесендә үзебезнең урыс кызына гына өйләнәм. Америка хатыннары фәлән җиремә дә кирәк түгел!»

Мортаза, көрсенеп, гәзитне читкә алып куйды. Каймакның файдасы турында ишеткәне бар иде инде, ә менә петрушка...

Шуннан соң ул бер атна чамасы каймак белән петрушканы күпләп ашап торды. Аллага шөкер, аның ише яфракларның мул һәм арзан чагы иде. Әмма... Яхшыга үзгәреш сизелмәде.

Күрәсең, табибка бармый чара юк иде...

Бу юлы чиратта утырасын алдан белеп, кулына берничә гәзит тотып барды ул һәм тирә-ягында сөйләшкәннәрне колагына элмәскә тырышты.

Һәрнәрсәнең ахыры була, диләр, иртән килеп утырган Мортазага, ниһаять, сәгать бер тулганда табиб янына керү насыйп булды. Пенсия яшьләрендәге абый аны өстәл янына чакырды.

— Фамилиягез? — диде абый, аның сәламенә ым белән генә җавап биреп.

— Асанин, Асанин... — дип кабатлады һәм өстәлдәге кәгазь өеменнән берсен тартып алды. Анда Мортазаның исем-фамилиясе, туган елы, адресы язылган иде.

— Тыңлыйм сезне, — диде табиб, талчыккан тавыш белән. — Нәрсә борчый, сөйләгез.

Мортаза янәшә өстәл артында бик тырышып нидер язып утыручы, ак башлыгы астыннан алтын бөдрәләре күренеп торган яшь кызга борчылып карап алды. Ул махсус ир табибны сайлаган иде, ләкин монда шәфкать туташы да буласын исәпкә алмаган икән.

Әмма кире чыгып китеп тә булмый, ул, кызга ишеттермәскә тырышып, тавышын әкренәйтеп, берничә сүз белән үзенең зарын әйтеп бирде. Җөмләсенең ахырында тавышы төшенкеләнгәнен тойды, кәгазьгә нидер тырмаштырып утырган табиб ягыннан битарафлыкның салкын җиле өрә кебек, ян өстәл янындагы кызыкай исә, бөтен эшен онытып, зәңгәр күзләрен зур ачып, шаккатып аңа текәлгән иде.

Мортаза үзен аның күзләре белән күргәндәй булды: башкаларның зарлары — бөердәге ташлар, шешләр, авыр шикләр белән чагыштырганда аның зары көлке булып тоелу гаҗәпмени?

Әмма табибның йөзе җитди калды. Ул, башын күтәреп, Мортазаның йөзенә текәлде. Егетнең чиста итеп кырылган булуга карамастан нык каралып торган ияген, борын астын, калку муен төерен, зәңгәр футболкасының ачык изүеннән күренеп торган кара төкләрен, киң җилкәләрен, кыска җиңеннән күпереп чыккан тыгыз мускулларын күздән кичерде, тавышының бәрхеттәй йомшак куе аһәңен тотып алды. Аның каршында чын ир-егет утырганын күреп, башын чайкап куйды.

Аннары тагын иелеп яза башлады, бер-бер артлы сораулар бирде:

— Бала чакта нәрсәләр белән авырдыгыз? Буйдакмы, әллә өйләндегезме инде? Әти-әниегезнең ничә баласы бар? Бергә яшиләрме? Нәсел-ыруыгызда шушындыйрак кимчелектән зарланган кеше юкмы?

Аннары иң сискәндергәне:

— Җенси тормыш белән кайчаннан бирле яши башладыгыз? Венерик авырулар кичергәнегез булмадымы?

Ниһаять, ширма артына узарга кушты. Шәфкать туташына:

— Вассерман реакциясенә направление языгыз, — диде.

Анысының СПИДка анализ икәнен Мортаза белә иде инде.

...Табиб янында булу — кунакка бару түгел, рәхәт дип әйтә алмыйсың. Мондыйларында исә бигрәк тә читен. Ширма артында шактый авыр тоелган хәлләрдән соң тагын өстәл янына утыргач, табиб:

— Минемчә, сездә ул-бу куркыныч нәрсә булырга тиеш түгел, — диде. — Бер атнадан анализлар әзер булыр. Аннары, бәлки, сезгә психологлар белән эш итәргә туры килер.

Мортазаның сискәнеп киткәнен күреп, тынычландырырга ашыкты:

— Мин психиатр димим, психолог, дим. Бездә күпләр аларның аермасын аңламый. Әнә Көнбатышта һәркемнең үз психологы бар. Хәзер бездә дә андый белгечләр ишәйде. Андыйлар гына ярдәм итә алмаса, сексологларга мөрәҗәгать итәргә була. Хәзер эшләр җиңел, — дип, беренче тапкыр көлемсерәп куйды ул. — Акчаң гына булсын! Алар үз дәрәҗәләрен яхшы беләләр. Даруларның да төрлесен тәкъдим итәләр...

Аның бу көлемсерәвендә үзенә бер җиңеләю сизелә иде. Күрәсең, ул Мортазаның зарын әллә ни җитдигә санамады. Ә бәлки, сәламәт кеше ансыз да яши ала дип уйлагандыр. Мортаза, үрелеп, язуга карады. Табиб «Функциональные нарушения... Этиология не выяснена» дип язды да зур итеп сорау галәмәте ясап куйды.

— Неясная этиология...

Бу сүзләр Мортазаның теленнән ихтыярсыздан ычкынды. Эльза Бруновна сүзләре иде бу. Каян хәтергә килде дә тел очыннан өзелеп төште соң әле?

Табиб, башын күтәреп, аңа гаҗәпләнеп карады:

— Ә сез аннан курыкмагыз, — диде. — Тикшерүләрдән соң сәбәбе ачыкланыр да әле, бәлки.

Әмма тавышында шикләнү чагылгандай тоелды. Табиб бер дару да бирмәде, ничек дәваланып булганын әйтмәде, анализлар тапшырырга дип, берничә кәгазь кисәге тоттырды да шуның белән эшен төгәлләде.

Урамга чыкканда, Мортазаның күңеле ифрат төшенке иде. Ул ким кеше, гарип кеше. Кимлеге бер күрүдә күзгә ташланып тормаса да, хәле аксак-туксак, кулсызлардан да аянычрак. Чөнки аның кимлеге кешеләрдә кызгану хисе түгел, бөтенләй башка тойгылар уята. Егет кешегә чын ир булмау — гарьлек. Көлке!

Ләкин нилектән? Сәбәбе нәрсәдә? Эльза Бруновнаның зур түгәрәк коңгырт күзләрендәге борчылу янә хәтердә яңарды.

Мортаза йөгереп барып троллейбуска утырды. Көн үзәге булуга карамастан, халык күп җыелган иде. Бу сәгатьләрдә троллейбуслар сирәк йөри шул. Арада яшь кызлар да бар, лекциядән чыккан студентлар булса кирәк. Итәкләре кыска, кофта астыннан кендекләре күренеп тора. Кыбырсыклар, дәртлеләр, тәннәре кояш эссесеннән генә түгел, эчләрендәге яшьлек учагының кызуыннан да эсселәнгән. Мортаза шулар арасына кереп уралды. Гадәттәгечә, арткы мәйданчыкта тыгызлык хасил булды, кызларның берсе, җайлап басарга тырышып, Мортазага нык ышкылып боргаланды. Егет сагайды... Аның тәне бу ымсындыргыч көчкә җавап бирергә тиеш иде. Табигать-ана кушканча... Әмма Мортазаның күңеле кузгалса да, тәне җавапсыз калды.

«Кая барам соң әле мин?» Троллейбус аны шәһәр үзәгенә таба, Илүсә эшләгән бина тарафына алып бара иде. Анда сәгать бердән икегә кадәр төшке ял вакыты. Бик сагынган чакларында, Мортаза, шушы вакытта барып, аны күреп кайта иде. Үзе дә аңышмастан, бүген дә шул гадәтен кумакчы икән.

Ләкин аның моңа хокукы юк! Илүсәнең вакытын алып, анда ниндидер өметләр уятып йөрергә берниндн хакы юк аның!

Ник утырды соң әле ул бу троллейбуска? Автобуска утырырга кирәк бит аңа! Яңа шәһәргә барырга. Тикшерүче Сидоровны эзләп табарга. Һәм аннан чын дөресен әйттерергә: нишләткәннәр аның әнисен?! Аңа кадаган агуның ниндилеген белергә, табибларның «неясная этиология» дигән нәтиҗәсен үзгәртергә кирәк.

Мортаза, халыкны төрткәләп, чыгу ягына таба узды.

R R R

Ишек ачылуга, Мортаза хуҗаның үзеннән алда күзлеген күрде. Калын пыялалар кара спорт костюмы кигән чандыр гәүдәле картның күзләрен зурайтып күрсәтә, аның җыерчыклы арык чыраена үзенә бер эчкерсез, ихлас кыяфәт бирә иде. Бабай, ишеккә аркылы басып, Мортазага текәлде. Аның бөтен торышыннан, тагын нинди яман хәбәр китерде икән инде бу кеше дигәндәй, сагаю сизелде. Нихәл итәсең, картайган саен безнең өйләрдә сөенеч-куанычлар сирәк кунакка әверелә, ә менә кайгы-хәсрәт дигәннәре эзен суытып тормый шул.

— Исәнмесез! — диде Мортаза. — Сидоров Антон Никитичны күреп сөйләшә аламмы мин?

— Исәнме! Мин ул Антон Никитич. Ә син кем?

Мортаза җавап биреп өлгермәде, фатир эченнән нечкә, хәлсез тавыш ишетелде:

— Антоша! Кем бар анда? Ник кермисез?

— Безгә түгел, күршеләрне сорыйлар, — диде карт эчке якка карап, шактый ук кычкыра төшеп. Аннары Мортазага таба борылды да: — Карчык авырып ята минем, — диде. — Әйт йомышыңны.

— Минем йомыш аяк өсте генә сөйләшә торган түгел иде шул...

— Өйгә чакырыр идем дә... карчык борчылыр... авыру кешене беләсез...

— Әйдәгез, алайса, урамга чыгып сөйләшик.

— Хәзер, әйтим дә...

Баскыч мәйданчыгында көтеп торган арада, Мортаза каршылыклы хисләр кичерде. Тикшерүчене ул төксе, каты чырайлы итеп күз алдына китергән иде. Гәрчә Эльза Бруновна мактап телгә алган булса да. Бу карт исә дөньяның бер бичара мәхлугы төсле иде. Андыйларны урысларда «божий одуванчик» диләр.

Ул ярым ачык калган тимер ишекне күздән кичерде. Арзанрагын сайлаганнар, ямьсезен, бизәксезен. Күгәргән калын калайга йозакны куйганда да нечкәләп тормаганнар, ничек туры килсә, шулай ябыштырганнар — җөйләре ямьсез, бүлтәеп тора. «Ник буяп куймаска инде шуны?.. Төрмә ишекләре дә шундый була торгандыр», — дип уйлады Мортаза.

Подъездның тузанга каткан тәрәзәләре бу охшашлыкны тагын да көчәйтә иде. Карт үзе дә мәхбүсне хәтерләткән кебек тоелды. Аның да арада иң кыерсытылганын. Теге, анекдоттагы кебек, иртәгә сине тотып асабыз, дисәләр, бауны үзем белән алып килимме, дип сорый торганын.

Шушы да тикшерүче була алды микәнни? Башкаларның язмышын хәл кылып утырды микәнни? Кемнән ничек сорау алырга, нинди гаеп тагарга, кайсы статьялар буенча җавапка тартырга һәм нинди җәза бирүне таләп итәргә... Озак елларга төрмәгә утыртыргамы, сөргенгә озатыргамы, әллә бөтенләй юк итәргәме?..

Ничек алай мөмкин? Мәхбүсләр арасында моннан күпкә көчлерәк, чая, үткен, тазарак егетләр булгандыр лабаса! Табигатьнең дә, җәмгыятьнең дә закончалыгы буенча өскә көчлеләр, уңганнар күтәрелергә тиеш, ә бу бәндә ничек башкаларның баш өстенә менеп баса алган?

Кире әйләнеп чыкканда, бабайның чырае тагын да караңгыланып киткәндәй күренде. Мөгаен, аның кулы аша узган кешеләрнең язмышын сорашып килүчеләр моңарчы да булгандыр. Рәхмәт әйтмәгәннәрдер, күрәсең...

Ул тимер ишекне иңбашы белән этеп, шыгырдатып бикләде дә:

— Әйдәгез, — диде һәм, тамырлары каралып, бүртеп чыккан кулларын баскыч култыксасыннан шудырып, аска таба атлады. Адым саен аның тезләре сыгылып-сыгылып китә иде.

Урамда җылы, якты, тик бу икәүнең күңеленә кереп оялаган шомлы караңгылык дөнья ямен күләгәләгән иде. Тикшерүче карт каен агачы төбендәге яңгырдан күгәргән тар агач эскәмиягә барып утырды да кулы белән янына шапылдатып суккалады:

— Кил алайса, әйтәсе сүзеңне утырып сөйлә.

Мортаза, аның янына утырып, алгарак иелде, фикерен тупларга тырышты.

— Алтмыш тугызынчы елда сез Кадермәтованың эшен тикшергәнсез. Бәлки, хәтерлисездер. Заһидә Кадермәтова. Студент кыз...

— Син аның кеме соң?

— Улы.

— Сиңа минем хакта кем әйтте? — дип сорады карт. — Канчуровмы? Полковник үзе әйтмәс. Димәк, Вилен?

— Сезнең адресны миңа Эльза Бруновна бирде.

— Улмыни-и... Кара әле... Нишләп монда килеп йөрисең син? Тиешле органнарга барырга кирәк. Гаепләнүчеләрнең туганнарына «Дело»ларны укыталар бит хәзер.

— Булдым. Алдым. Укыдым. Анда аңлашылмаган нәрсәләр күп.

Карт, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранып алды.

— Нәрсәсе аңлашылмый икән? Минем беркайчан да законны да, инструкцияләрне дә бозганым булмады.

Мортаза бу адәмгә күңел ачкычы табарга кирәклеген аңлады. Югыйсә берничек тә ачыктан-ачык сөйләшү булмаячак иде.

— Хәтерлисез микән, минем әнием... Кадермәтова тикшерү барган вакытта кинәт кенә авырып киткән... — дип башлады ул, тавышына аерата йомшаклык бирергә тырышып.

— Анысын Эльза Бруновна миннән яхшырак белә бит инде, — диде карт, сынын турайтып. — Ул әйтмәдемени соң?

— Хикмәт шунда, әнигә ниндидер укол кадаганнар. Шул уколдан соң әни чак үлми калган. Сез анда булгансыздыр бит? Хәтерлисезме?

— Хәтерлим, — диде карт, кырт кисеп. — Бик яхшы хәтерлим. Кадермәтова үзе истә. Ә хастаханәдәниләр булганын миңа нечкәләп әйтеп тормадылар шул.

— Сез, тикшерүче буларак, аңа нинди укол ясаганнары белән кызыксынмый калмагансыздыр бит? Әгәр ул кинәт чирләп киткән икән, моңа игътибар итеп, сәбәбен ачыкларга тиеш булгансыздыр?

— Аны миңа кем докладывать итеп торсын? Өстән табибларга фәрман җибәрелгән, алар шуны үтәгән.

— «Дело»да нишләптер бу хәлләр турында берни дә язылмаган...

— Ә нәрсәсен язасың аның? Табиблар миңа бер документ та бирмәде. Соңыннан, берничә көн узгач, үзем белешмә соратып алдым. Сәламәт дип язып бирделәр. Анысы урынындадыр бит?

— Анысы бар. Ләкин сездән рөхсәт алмыйча ниндидер экспериментлар үткәрә ала идемени алар?

— Таптылар бер гаеплене! — диде карт, каршыдагы йортның тәрәзәләренә карап. — «Козел отпущения» ясадылар миннән тәмам. Укол кадаган өчен дә мин гаепле, утыртып куйган өчен дә, сөргенгә озаткан өчен дә.

Карт пыяла аша зур булып күренгән моңлы, рәнҗешле күзләре белән Мортазага текәлде, күгәренгән юка иреннәре читендә ак күбек бәреп чыкты.

— Бөтен гаепне бер кеше өстенә өю җиңел ул. Минем урында үзең булсаң нишләр идең икән! Анда бик әтәчләнеп булмый иде! Кикрикләрне тиз шиңдерәләр иде безнең заманда!

Мортазаның ачы елмайганын күреп, ул янә кызып китте:

— Әгәр дә син мине куркак дип уйлыйсың икән, бик нык ялгышасың. Фронтны узган кеше мин, ут эченә кергән солдат!

Аның тавышында горурлык яңгырады.

— Ватан сугышында катнаштыгызмыни? — дип сорады Мортаза, гаҗәпләнеп һәм ничектер йомшарып киткән тавыш белән. Аның уенча, КГБ үзенең кадрларын ут эченә илтеп тыгарга тиеш түгел иде кебек.

— Японнарга каршы сугышларда катнашырга туры килде безгә, — диде сагышланып Сидоров. — Хинган тауларын кичтек, Гоби чүлләрен гиздек, японнарның ут яңгыры астында атакага ташландык. Яраланган да булды. Башка тиде. Күзгә зыяны калды менә. Ул чакта мин синнән яшь идем әле. Унсигезем тулуга алып киттеләр... Беркемнең дә мине куркак дигәне булмады!

Ул, уңгарак авышып, чалбар кесәсеннән «Беломор» пачкасы тартып чыгарды. Калтыранган бармаклары белән папирос тартып алды, аның ак очын учына бәргәләде дә, юка иреннәре арасына кыстырып, озак кына кесәләрен актарды. Мортаза, зажигалкасын чыгарып, черт итеп нәни ялкын теле чыгарды да аның папиросына ут элдерде. Бабай тирән итеп суырды, башын күтәреп, каен ябалдашына таба куе төтен өрде.

— Мә, кабыз берне син дә, — дип, пачканы сузды.

— Мин ташлап йөри идем шул әле.

— Йөргән кызың тәмәке исен яратмыймыни?

«Каян белгән?» дигән уй чагылып узды Мортазаның башында.

— Кеше кушканга түгел. Үзем ихтыярны сынап карарга булдым, — диде аннары.

Бу тайпылыш ике арадагы киеренкелекне киметеп җибәргәндәй итте. Карт та йомшарган кебек булды.

— Мин сезне аңлыйм, — диде, бераз уйланып торгач. — Яшь чакта үзем дә сезнең кебек идем. Һәммәсе бик ачык, күз алдында ярылып ята иде. Әнә фронт сызыгы, аның артында дошман, бу ягында үзебезнекеләр. Ә менә тыныч тормышта барысы бергә буталган булып чыкты.

Ул тавышланып суырды, папирос очы янган йөрәгенең ялкыныннан кызып кызарган кебек тоелды.

— Сугыштан соң алты ел хезмәт итәргә туры килде. Кайткач, юридик факультетка укырга кердем... — дип дәвам итте ул әллә үкенеп, әллә яшьлеген сагынып. — Монда каян кем атачагын белеп булмый, шуңа күрә җан кысыла, рух сына иде.

Бу сүзләр Сидоровның авызыннан куе төтенгә уралып чыкты. Җил Мортазага таба исә иде, төтеннең ачы сасысы тынга бәрде.

— Нишләп алай? — диде Мортаза. — Сталин заманнары узган, шәхес культы фаш ителгән иде бит инде. Гадел хөкем итәргә кем комачаулады сезгә?

— Әйе, шәхес культы фаш ителгән, Сталинны, Берияне хурлап күп сүзләр сөйләнгән. Ләкин системасы калган! Система шул ук иде, аңлыйсыңмы?! Аңа берничек тә каршы торып булмый! Аннан гаделлек таләп итү карцерның бетон стенасын маңгаең белән ватарга маташу кебек ул!

— Һәм сез, системага хезмәт итеп, минем әни кебек бер гаепсез кешеләрне җәзага тарту белән шөгыльләндегезме? Нindидер бер шымчының сүзенә карап...

— Шымчыдамыни эш?

Карт, төпчеген тапталган көлсу туфракка ташлап, аягы белән баскалап куйды. Шунда гына Мортаза аның өй чүәге кигән килеш чыкканын күреп алды.

— Әниеңә охшагансың син, — диде карт, аңа карамый гына. — Төсең дә шул, холкың да. Ул да шулай, күкрәген калкан итеп, дөреслеккә юл ярып бармакчы иде. Системага каршы тормакчы! Беркатлы сабый!

Мортаза утырган урыныннан сикереп торды.

— Һәм сез, бөтенесен белә торып, аңлый торып, аны...

— Ә син андый очракта нишләр идең? Әллә, андыйларны ирекккә чыгарып җибәрер идем, димәкчеме?

Мортаза дәшмәде. Зиһененең бер почмагында ул бу картның көчсезлеген, системаның, ә бәлки, кемнеңдер кулында корал гына булганлыгын аңлый, шуңа күрә артык кызып ачулана да алмый иде.

— Әгәр беләсең килсә, аның миңа эләгүе бәхетенә булды әле, — диде Сидоров. — Кызгандым мин аны. Мин кылган хәтле яхшылыкларны аңа һичкем кылмагандыр әле. Аның хакына дип, үз өстемә үзем бүре китергән чакларым булды. Соңрак, мине эштән кыскартканда, Кадерматованы да искә алдылар. Картайган көнебездә әнә хаста карчык белән икебез көчкә җан асрар көнгә калдык. Хәер, алары синең өчен мөһим түгел, билгеле.

— Биш елга сөргенгә җибәрерлек ни гаебе бар иде соң аның?

— Тартай теленнән табар, дигәннәр. Гел дөреслекне генә такылдап йөрергә ярыймы әллә? Каян килгән ул? Гомер иткән хатыныңа да әйтергә ярамаган нәрсәләр була. Өйләнгән булсаң, үзең дә чамалый башлагансыңдыр инде. Ни исемле дидең әле?

— Мортаза мин.

Карт башын түбән иде.

— Әйе... Әйттем мин аңа, әйттем... Ә ул миңа ышанмады. Эзлим, диде, табам, диде. Аннан башка яши алмыйм, диде. Яшь иде шул әле. Синең чама булгандыр...

— Сез кем турында сөйлисез?

— Юк, болай гына, — дип, хатирәләреннән арынырга тырышкандай башын чайкап куйды ул. — Анысы миңа кагылмый иде. Анысы бүтәннәрнең йөрәк эше иде.

— Ә мин белергә телим. Һәм моңа хакым бар дип саныйм!

— Әниеңнең йөрәк серенме? Үзеннән сора!

— Ләкин... минем әнием күптәннән вафат бит!

— Гафу ит. Кайгыңны уртаклашам, — дип мыгырданды карт. — Ә теге укол турында... Син Канчуровны табарга тырыш. Вилен Канчуровны.

— Адвокатнымы?

— Адвокат? Канчуровмы адвокат?

— Ә кем иде соң ул?

— Химик. Ә бәлки, фармацевтика галимедер. Һәрхәлдә, фәнни-тикшеренү институтыннан иде ул. Шуннан сорашып карагыз.

— Ә сез... аның адресын йә телефонын бирә алмыйсызмы?

Сидоров Мортазага гаҗәпсенеп карады.

— Эх, молодой человек! — диде. — Бала булып кылану килешми сиңа! Күптән мыек чыккан! Канчуров кебек кешеләр алар дәүләт сере булып санала! Аның безгә фамилиясен әйтү дә, телефонын бирү дә үзе бер җинаятькә тиң иде. Мин аларны шул чакта ук онытырга тырыштым. Дәүләт серләренең андыйлары хәзергәчә ачылмагандыр әле. Юктыр...

Аннары кинәт сискәнеп китте:

— Вакыт күпме икән? Сәгатемне алмый чыккан идем.

— Өч тулып унбиш минут, — диде, сул беләген күтәреп Мортаза.

— Карчыкка укол ясар вакыт узып киткән бит, — диде карт. Һәм саубуллашты да ашыгып ишеккә таба китте.

Мортазаның сорыйсы сүзләре тагын бар иде. Әмма бу карттан сөйләгәненнән артыгын алып булмаячагын аңлады ул.

R R R

Тикшерүче Мортазадан, атаң кем, фамилияң Канчуров түгелме, дип сорамады. Чөнки ул Эльза Бруновнадан күбрәкне белә иде. Ләкин һәммәсен дә әйтеп бетереп буламыни? Һәм кирәк микән? Кадермәтова белән Канчуровның гыйшкы — йөрәк эше, тикшерүчегә кагылмый иде. Тагын шунысы да бар: һәркем үзенең яшьлек мәхәббәте хакында балаларының белүен теләр идеме? Бигрәк тә балалар бөтенләй башка кешедән туган булса...

Ә шулай да тышкы яктан караганда бер-берсенә бөтенләй охшамаган булсалар да һәм төрле заманнарда яшәсәләр дә, Вилен белән Мортаза арасында ниндидер уртаклык бар иде. Яшьлеккә хас ашкыну, дөреслекне белергә омтылыш. Һәм аны төбенә кадәр ачып була дигән беркатлы ышаныч... Үз вакытында тикшерүче белән Вилен арасында да шактый кискен сөйләшү булган иде.

— Минем сезгә «Дело»ны күрсәтергә хакым юк, — диде ул чакта Сидоров. — Өстәгеләргә мөрәҗәгать итегез. Менә аннан кушсалар, рәхим итегез...

Алар тикшерүче бүлмәсендә өстәл артында кара-каршы утыралар иде.

— Әгәр беләсегез килсә, мин дәүләт серләренең моннан күпкә зурракларын белә торган кеше. Сезнең мондагы ише генә түгел!

Шулай диде дә Вилен, иелеп, өстәлдә яткан папканы үзенә таба тартты, папка кырыйларына ябыштырылган ботинка баулары җилпенеп куйды. Тикшерүче сискәнеп кулын сузган иде, егет каты бармаклары белән аның беләген кысты.

— Мин монда ниләр язылганын белергә тиеш. Ә бәлки, сез безнең эшчәнлегебезгә кагылышлы мәгълүматларны теркәп барасыздыр?

— Тик икебез арасында калырлык булса гына... Беркемгә әйтмәсәгез генә, — дип быдырдады тикшерүче.

— Әйтмәм, әйтмәм... Кадермәтова... — дип укыды Вилен. — Студентка. Икенче курста. Гаебе нәрсәдә соң аның?

Егет, күп китап укыган кешеләргә хас булганча, кәгазь битләрен салмак кына ачып япкан арада, үзенә кирәкне эләктерә барды.

— Та-ак... Бабасының гаепсезгә утыртылганын сөйләп йөри, имеш... Бабаңны кызгану җинаятьме әллә? Тагын нәрсә? Кырым татарларын яклап шигырь язган?! Шагыйрә дәмени әле ул? Кырым татарларын үз ватаннарына кайтаруны максат итеп куйган төркем оештыручы! Көчле-е... Тагын... Бер җыелышта группадашын яклап чыккан... Тәүфикъ исемле икән. Йөргән егетеме әллә?

Вилен, башын күтәреп, бездәй күзләре белән тикшерүченең күзлегенә төбәлде.

— Егетемени?

— Кем?

Вилен бармагы белән папкага төртте.

— Менә бу Тәүфикъ дигәне... Килеп йөриме әллә?

— Анысы безнең эшкә кагылмый. Кыз гыйффәтле. Безгә шунысын гына белергә кушылды.

— Тәне гыйффәтле. Ә күңел ягы ничегрәк булды икән, — дип, тынычланыбрак, үзалдына сөйләнеп, тагын папкага иелде Вилен. — Бәлки, алар арасында күз зинасы булгандыр?

Тикшерүченең керфеге дә селкенмәде, чырае җитди калды.

— Анысы безгә кагылмый. Уголовный кодекста «күз зинасы» дигән статья юк, — диде ул салкын гына.

— Ә башкасы сезгә кагыламы? Бабасын кызганган, группадашын яклаган, кырым татарлары турында шигырь язган. Аларны хөкүмәт үзе аклаган бит инде! Әллә сез белми калдыгызмы?

Виленның мыскыллы соравыннан Сидоровның чырае тагын да караңгыланып китте, күзлек пыялалары ныграк ялтырый башлады.

— Менә сез нәрсәләр белән мәшгуль икән монда! Шушы... — Вилен папканың беренче бите астындагы имзага күз салып алды. — Токтогулов дигән адәм боларны үзе уйлап чыгаргандыр әле. Әллә берәр шымчы чакканмы?

— Агентлар белән эш итү минем вазифама керми, — диде Сидоров, бу юлы инде кәттә егетнең наданлыгына басым ясагандай итеп. — Алар белән аерым служба эшли.

— Кем инде ул аерым служба? Менә мондагы Токтогуловмы? Каян килгән андый фамилия? Ә-ә, сез бит кайнар интернационалистлар! Барча милләтләрне бер казанга салып болгатып, уртак совет халкы пешереп чыгарырга тырышасыз. Ә бәлки, хикмәт башкададыр? Токтогулов кебекләрнең биредә кызганыр кешесе юктыр? Нәсел-ыруы Урта Азиядәдер бит? Шушыларның сүзенә карап, сез бер гаепсез кешене үлемгә хөкем иттегезме?

— Кемне... хөкем иткән? Тикшерү бара, аңлыйсызмы? Монда суд түгел, мин дә судья түгел, тикшерүче!

— Алайса, ничек соң бу Кадермәтова безнең белән... — Вилен бераз сүз эзләп торды да — ...очрашты? — дип тәмамлады.

Тикшерүченең күзләре пыяланы тишеп чыгардай булып акайды. Ул торып басты да:

— Беләсезме нәрсә, — диде. — Без шулай килешик: мондагы сүзләрне сез әйтмәдегез, мин ишетмәдем. Әгәр дә инде Кадермәтова сезгә бик тә кызганыч икән, ул чакта, барыгыз, өстәгеләр белән сөйләшегез. Полковник Канчуровтан сорасагыз, һәммәсен аңлатып бирер.

КГБ тәгәрмәче янында шактый талкынып шомартылган булса да, абзыйның тешләре бөтенләй үк коелып бетмәгән икән әле, астыртын гына эләктереп алды!

— Өстән безгә нинди кәгазь килгәнен беләсезме сез? — дип дәвам итте ул. — Кемне сорадылар бездән? Яшь, сәламәт, гыйффәтле кыз бала кирәк, диделәр. Анысын да мин сайлап алмадым. Мин фәкать шундый кандидатура барлыгын гына әйттем. Бу очракта сез мине берничек тә гаепли алмыйсыз!

Вилен тикшерүче белән араларны бозуның үз файдасына түгеллеген аңлап алды. Алай да эчтәге ачуны, дөресрәге, ачынуны тиз генә басып булмый иде.

— Астан язганны хуплап, өстән кушканны үтәп утырыр өчен генә утыртылганмы әллә сез монда? — дип мыгырдады ул. Әмма тавышы йомшарганнан-йомшарды: — Дөреслекне ачыкларга тиеш сез.

Һәм «Дело»ны ябып, бауларын бәйләде дә портфеленә салырга омтылды. Сидоров, урыныннан сикереп торып, аның беләгенә ябышты:

— Сез нәрсә?

— Мин моны үзем белән алам!

— Ничек аласыз? Кем рөхсәте белән? Мин инде болай да нарушениегә бардым! Аны сезгә күрсәтергә берничек тә тиеш түгел идем! Тайна следствия!

— Мин аны полковникка күрсәтәм!

— Кирәк булса, полковник үзе соратып алыр. Язма рәвештә.

Тикшерүченең карга тәпиләренә охшаган бармаклары «Дело»ны Виленның ак, чиста, хушбуй исе аңкып торган кулларыннан тартып алды. Егет, сугышырга ярамаганын аңлап, чигенергә тиеш тапты.

— Авырга алмагыз, зинһар, Антон Никитич, — диде. — Миңа болар аңлашылмый. Ифрат сәер тоела. Монда язылганнар кешене төрмәгә тыгу өчен нигез була алмый бит. Юридик яктан караганда, буш күкәй кабыгына да тормый алар! Фәкать шул гына.

Тикшерүче, кесәсеннән зур карасу кульяулыгын чыгарып, күзлек пыялаларын сөрткәләде. Бәхәснең болай тәмамлануына ул канәгать, әмма дулкынлануы басылмаган иде әле.

— Сезнең эшнең дә, безнең эшнең дә үзенчәлекләре күп инде, — диде ул. — Читтән караганда, миңа да сезнең гамәлләр үтә сәер тоела. Аңлашылмый. Гәрчә без бер системага хезмәт итсәк тә...

Вилен сүзне кире элекке агымына кайтарырга ашыкты:

— Сез ничек уйлыйсыз: Кадермәтованы чыгару озакка сузылмастыр, шәт?

Антон Никитич аңа кистереп карап куйды.

— Андый эшләр төкерек салдым, сикереп чык, дип кенә башкарылмый шул, энекәш...

Аннары, егетнең йөзенә бәреп чыккан ризасызлык галәмәтләрен күреп, тынычландырырга ашыкты:

— Барысы да сездән тора, — диде. — Әгәр абыегыз... полковник Канчуров безнең начальниклар белән уртак тел тапса, шундук бөтен документлар әзерләп бирелер... Минем тарафтан берниндн тоткарлык булмаячак... Шәп булыр иде ул! Минем өстән дә авыр йөк төшәр иде, — дип өстәп куйды аннары.

Ул да кызгана иде Заһидәне, һәм бу уртак хис әле генә булып узган әйткәләшүнең ачысын бетерде. Алар, дустанә диярлек, кул бирешеп саубуллаштылар.

R R R

Виленның кичерешләре тавышына ук чыккан иде булса кирәк, телефон аша бер авыз сүз әйтүгә, абзасы:

— Ни булды тагын? — дип борчылып сорады.

Егет шактый буталды, полковник башта аны аңламый торды.

— Тикшерүчене алыштырырга кушасыңмы әллә? — диде аннары гаҗәпләнеп. — Синең ни эшең бар анда? Кайсысы булса да барыбер түгелмени?

— Монда бер гаепсез кешене тәҗрибәгә җибәргәннәр...

— Соңыннан әйтерсең! — диде полковник. Аның тавышы кинәт салкынаеп китте. — Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел бу.

— Алайса, мин хәзер киләм!

— Ә ник? Син нәрсә, анаң итәгенә ябышып йөри торган маңка малаймы әллә? Үзеңә кирәкне үзең хәл итәргә өйрән! Күптән вакыт!

Һәм полковник, гасабиланып, трубканы ташлады.

Вилен эшеннән иртәрәк китте, «Волга»сын гадәтләнгән урында калдырып, бакчага керде. Фонтан янындагы буш эскәмиягә барып утырды. Абзасы эшли торган бинаның ишеге моннан яхшы күренә иде.

Фонтанның кеше борчуларында гаме юк, ул һаман дәртләнеп югарыга бөркелүендә иде. Вак тамчылар рәшә хасил иткән, анда шаян салават күпере хасил булган. Аның уртасыннан мәхәббәт алласы Амур үзенең алтынсу угын сузган.

Ах, наян малай, тидерден шул инде син угыңны егетнең йөрәгенә! Яраның ачысын да, татлысын да салдың! Нишләргә инде хәзер аңа, җан сөйгәнен таш капчыктан ничек йолып алырга?

Вилен карашын аскарак, көмеш тамчыларга коенып утырган ак һәм алтынсу нарциссларга төбәде дә: «Бу гөлләр сулганчы, мин аны коткарырга тиеш, — дип, үз-үзенә вәгъдә бирде. — Иң беренче итеп шушы фонтан янына алып килермен мин аны. Шушы эскәмиядә янәшә утырып торырбыз...»

Әллә ни кыен эш булырга тиеш түгел иде бу. Абзасы аның гозерен бу юлы да аяк астына салмас. Әнә ул имән ишектән чыгып килә. Түбәнәеп барган кояш яктысында әкияти баһадир кебек тоела ул: киң җилкәләре иркен күксел пинжәгенә сыеп бетмәгән кебек, төймәләре ычкындырылган, керсез ак күлмәге аша калкандай күкрәге калкып тора. Кыска итеп алынган сары чәчле зур башы нык, таза муенга утыртылган. Ул чаттан килеп чыккан кара «Волга»ның якынайганын көтеп, тукталып калды. Вилен йөгерә-атлый бакча сукмагы аша аңа таба китте.

— Исәнме, абзый, тагын бер кат. Мин сине көтә идем.

Полковник күн портфелен машинасының арткы утыргычына ыргытты да энесен читкәрәк әйдәде. Сөйләшкәнне шоферы ишетеп торуын теләмәде, мөгаен.

— Тыңлыйм, — диде ул, каядыр читкә карап. Башка чакта энесен күрүгә ярату катыш көлемсерәү белән яктыртыла торган киң, шома чырае бүген кырыс иде аның. Һәм, Виленны тыңлаган саен, йөзендәге канәгатьсезлек галәмәтләре артканнан-арта гына барды. Ниһаять, егет тынып калгач, ул чалбар кесәсеннән ап-ак, зур кулъяулыгын алып, гасабиланып маңгаен сөрткәләде.

— Ни җитми сиңа? — дип сорады аннары. — Тегесен болай ит, монысын тегеләй, дип, төрмә контингентын ары-бире куып йөртергә мине кем дип белдең син? Анда дуңгыз абзары түгел, ә мин көтүче түгел! Һәр эштә тәртип булырга тиеш!

— Гаебе дәлилләнмәгән, расланмаган кешене үтерергә китерү — тәртипме?

— Нәкъ шундыйны бирегез, дип, кем заявка җибәрде соң әле безгә? Профессорың белән син үзең түгелмени?

Полковник машинасына таба талпынды.

— Сәламәт булсын! Чиста булсын! Еллар буе төрмәдә яткан хатыннар арасыннан андыйны табып кара син! Уйларга кирәк иде башта!

Ул машинасы янына барып җиткәндә, шоферы ишеген ачып куйган иде инде. Полковник иелгән җиреннән кире турайды да:

— Моннан ары ул тирәдә эзең булмасын! — диде. — Бүген үк шылтыратып куям. Кертмәсеннәр!

Машинаның ишеге шартлап ябылды, тәгәрмәчләре хәрәкәткә килде. Вилен ишек тоткасына ябышты.

— Абзый, гафу ит, — диде, ачык тәрәзәгә иелеп. — Кызып кителде... Мин барысын да аңладым. Сиңа бер генә үтенеч: беркая да шылтыратма. Беркемгә бер сүз дә әйтмә. Моны мин үзем ерып чыгарга тиеш.

— Әллә кайчан шулай кирәк иде! — диде ачылып полковник. — Егет бул! Югыйсә бит син мине дә шактый уңайсыз хәлгә куясың! Бер-беребез өстеннән йөрү килешми безгә. Канчуровларның сүзе бер булырга тиеш. Нәсел-ыруның йөз аклыгын сакларга өйрән.

Һәм, машинадан үрелеп, Виленның җилкәсенә шап-шап каккалап куйды.

Юлда басып калган Виленга кара «Волга» белән бергә нindидер бер аяусыз, дәһшәтле көч ерагаеп барган кебек тоелды. Әйе, шушы минутта Заһидә белән күрешү мөмкинлегеннән чак кына бөтенләй мәхрүм калмады бит... Әле дә ярый аңлап алды, әле дә ярый абзасының уен борып куйды...

R R R

Икенче көнне ул тагын институттан иртә чыгып китте. Соңгы вакытта гомумән күңеле эшкә ятмый иде аның.

Машинасы белән шәһәр уртасына килде дә рәттән кибетләр тезелеп киткән урамга юнәлде.

Моңа кадәр аның бер тапкыр да «Хатын-кыз киемнәре» дигән кибетнең бусагасын атлап кергәне юк иде. Хәзер менә элгечләрдәге күлмәкләрне актаргалап карый башлагач, аларның күрексезлегенә, төсләренең ямьсез алалыгына хәйран калды. Боларны соң кемнәр кия икән? Нинди егетләр аларны җан сөйгән ярларына бүләк итеп бирә икән? Һәркайсы үзенә аерым кыяфәтле адәм балаларын тагын да матуррак, күреклерәк итү өчен түгел, ә тәннәрен каплар өчен генә эшләп чыгарылган иде болар. Ә бәлки, һәммәсен дә көтүдәге сарыклар кебек бериш итеп күрсәтү өчен, махсус шулай тегәләрдер. «Заһидә кебекләргә мондыйны кигерү — җинаять!» — дип уйлады кәефе кырылган Вилен.

Аның алсу төсле күлмәк аласы килә иде... Килешле тегелгәнен. Мәскәүдә туган-тумача бар, алар товарның менә дигәнен, чит илдән кайтартылганын табып бирә ала инде. Әмма телләре дә үткен шул: кемгә, ник, дип теңкәгә тиячәкләр, кая, үзен алып кил, кигезеп карамыйча булмый, дип бәйләнәчәкләр. Бернишләр хәл юк, Заһидә янына буш кул белән барып булмый. Төксе чырайлы сатучы хатын белән киңәшкәннән соң, элгечтәге күлмәкләрдән берсен, аклырагын, иплерәген сайлады Вилен. Шуңа өстәп «Красная Москва» исемле ислемай да алырга булды — арада шунысы иң затлысы да, кыйбатлысы да иде. Аннары азык-төлек кибетенә сугылып, печенье, прәннек алды да, машинасына утырып, бакча артындагы таныш бинага юнәлде. Ишектән кергәч, сакта торучы сержантка:

— Тикшерүче Сидоровка шылтырат, лабораториядән килделәр, дип әйт, — диде.

Сержант ул кушканны үтәде, телефонын куйгач:

— Бераз көтегез, ул хәзер үзе төшә, — диде.

Хәлбуки Виленның алдан кисәтми-нитми килүе Антон Никитичны шактый четерекле хәлгә куйды. Эш сәгатьләре бетеп килә, киңәшер кеше дә юк. Ә ул икеләнә иде. Тикшерү астындагы мәхбүсләрне ирекtәгеләр белән очраштыру бик сирәк һәм тикшерү өчен зарур булганда гына эшләнә, һәм аның катгый үз тәртибе бар. Ә бу җилкенчәк егетнең килеп сарып йөрүен ничек аңлатырга? Кайсы яктан карасаң да, кирәге юк иде аның монда. Алай да, озын коридор буйлап узып, баскычтан төшкән арада уйлангач, таякны кинәт бөгәргә үк ярамас дигән фикергә килде Сидоров. Канчуровларның арасына керү — тегермән ташлары арасына кысылу белән бер, дип сөйлиләр. Шуңа күрә ул Виленга ачык йөз белән сәлам бирде, үзе белән алып кереп китте.

— Сезнең эшләр төгәлләнмәдемени соң әле? — дип сорады ул.

— Фәнни-тикшеренү эшләренең күпме көч, вакыт таләп иткәнен үзегез чамалыйсыздыр, — дип җавап бирде Вилен. — Тикшеренү дигәне бар бит аның!

Антон Никитич бу дәлилгә каршы сүз тапмады, өстәлендәге телефон трубкасын күтәреп, 863 нче мәхбүсне китерергә кушты.

Бусаганы атлап керүгә, Заһидәнең йөзе алланып чыкты. Дөрес, ул Виленга таба кулларын сузып, ашкынып атламады, тыелды, бусага янында басып калды. Әмма күзләреннән, ирен читләреннән, бөтен йөзеннән, нәкъ беренче тапкыр очрашкандагы кебек, куаныч, бәхет, җылы наз бөркелде. Һәм нәкъ шул минуттагыча Виленны да татлы томан урап алгандай булды. Ул кызга каршы атлады:

— Исәнме, Заһидә...

— Исәнме, Вилен. Килмәссең дип курыккан идем...

— Әйттем ич мин сиңа!

Тикшерүче аларның әле берсенә, әле икенчесенә сәерсенеп карады да:

— Безнең табибларның берәрсен чакырыйммы әллә? — дип сорады. — Киңәшергә кирәкмиме, диюем.

— Безнең тикшеренүләрдә алар ярдәм итә алмый, — диде Вилен.

— Миннән берәр ярдәм кирәк түгелдер бит? Берәүне күреп киләсе бар иде...

Сидоров үзенә турыдан-туры кагылышы булмаган хәлләрдән читтәрәк булырга тырыша иде. Белмәгәннең беләге авыртмый.

— Борчылмагыз, барып килегез, — диде Вилен. — Мин монда бераз вакыт булам әле.

Тикшерүче ишекне сак кына ябып чыгып та китте. Шулай итеп, Вилен белән Заһидә беренче мәртәбә икәүдән-икәү калдылар.

Зур сумкадагы әйберләрне өстәлгә бушаткач, Заһидәнең сөенүенә чик-чама булмады.

— Борыл тәрәзәгә! Карамый тор! — дип шаярып, әмма катгый итеп әмер бирде ул.

Күлмәк киңрәк булып чыкты.

— Менә болай иткәч, ярый ул, — дип, Заһидә иске күлмәгенең билбавы белән билен буып куйды.

Аны иң нык куандырганы ислемай булды.

— Ай, бигрәк затлысын алгансың!

Һәм тышына алтын белән Мәскәү Кремле ясалган шакмаклы шешәнең пыяла бөкесен ачып, бармакларын чылатты да колак артларына, муенына сөрткәләде.

— Синең үзеңнән килгән хуш ис бар хушбуйлардан татлы, — дип пышылдады Вилен, аны сак кына кочагына алып.

Сагынышып, зарыгышып күрешкән гашыйкларниләр сөйләшә? Моны Ләйлә белән Мәҗнүннән, Таһир белән Зөһрәдән дә матуррак итеп әйтеп булмастыр. Нинди шигъри, хисси, затлы һәм мәгънәле сүзләр белән иркәли алар бер-берсен! Моны китаптан укыганда, безнең дә йөрәкләр җилкенә, күзләргә яшь тула. «Ах, нигә соң мин җанга якын ярыма шушындый матур сүзләр әйтә алмадым икән!» — дип уфтанабыз без көрсенеп.

Тик аның шунысы бар: гашыйкларның ничек аңлашканын үз колагы белән ишеткән кеше юк. Бу хакта безгә бөек шагыйрьләр бәян итә. Алар исә адәм балаларының, тел очыннан өзелгән сүзләреннән бигрәк, күңел тибрәнешләрен тотып ала, шуларны кәгазьгә төшерә. Шигырь итеп, җыр итеп. Мин исә бу кыйссамны җыр итеп түгел, чәчмә юллар белән язам. Шуңа күрә Заһидә белән Виленның ничек аңлашканнарын кабатларга алынмыйм. Гашыйклар мине болай да аңлар, салкын җаннарны җылытырлык сүзләр таба алуыма исә шикләнәм...

Мин фәкать кайбер сүзләрнең мәгънәсен генә аңлатып китә алам.

— Син минем өчен Җәбраил фәрештә булдың... — диде Заһидә. — Әни сөйли торган иде... Мин ышанып җитми идем, әкият дип кабул итә идем... Бар икән ул Җәбраил... Син икәнсең ул...

Һәм, хисләре тулып ташудан аңын җуяр дәрәҗәгә җитеп, Виленның кулларын учына алды да иреннәренә китерде.

— Нишлисең син? Егетләрнең кулын үбәләрмени? — дип, аны кочагына алды егет.

Кызның муеныннан, ислемай исенә кушылып, үзенә бер сафлык, садәлек, фәкать сабыйларда гына була торган һәм шул сабыйны сөйгән кешеләрнең генә борыны тоя торган хуш ис аңкый иде. Вилен бу татлы исне ләззәтле шәраб урынына эчте. Ләкин дөньяның иң кыйммәтле, иң затлы шәрабы да бу татлы ис белән чагыша алмас иде. Чөнки күпмедер эчкәннән соң, алар ачы тоела башлый, гайрәтне чигерә. Ә менә сөйгән кешеңнең күзгә күренмәс нурлы дулкыннарга уралган хуш исе беркайчан да үзгәрми, күңелгә тими, аңа уралып мәңге-мәңге яшәп була.

Тик бераздан, башын күтәреп карагач, Вилен бу бүлмәнең котсызлыгын, ямьсезлеген, диварларга сеңгән һәм шулардан Заһидәнең аклы күлмәгенә, чәч бөдрәләренең очларына сылана башлаган башка бер исне, уйларны кыса, күңелне җәберли торган мохитне тойды.

— Син мине үзең белән алып чыкмыйсыңмы? — дип, бала-чага беркатлылыгы белән аның йөзенә текәлде Заһидә.

Вилен аның карашына түзә алмыйча башын иде.

— Алып чыгам, әлбәттә... Ләкин бүген үк булмый. Монда бит, үзең беләсең, төрле инстанцияләрне үтәргә кирәк... Тик син түз. Бирешмә...

— Минем ике зачетым бирелми калды бит инде... Бер атнадан имтиханнар башлана!.. Син миңа дәреслекләр алып кил әле, яме?

«И сабый! И беркатлы җан! Нинди зачет, нинди имтихан?.. Үлемнән чак калганыңа сөен! — дип уйлады Вилен, аны күкрәгенә кысып. — Хәер, ярый әле син белмисең... Ул агуның нинди икәнен дә, минем кемлегемне дә».

— Син аны уйлама, — диде ул. — Имтиханнарны сиңа соңыннан аерым тапшырырга рөхсәт итәрләр. Ныклап әзерләнгәч. Кайчан телисең, шул вакытта.

Икең бер булып кочаклашып утырганда, ике йөрәк бергә типкәндә, борчулар тарала, һәммәсе дә җиңел генә хәл кылыныр кебек иде.

Вилен полковник абзасының караңгы чыраен, каты сүзләрен генә түгел, үзенең кайда икәнлеген дә онытты, Заһидәнең тетрәнгән иреннәренә берегеп, дөньядагы иң татлы, иң исерткеч шәрабны эчте дә эчте, һич кенә дә аерыла алмады...

R R R

...Ә тикшерүче Сидоров коридорда әрле-бирле борсаланып йөри иде. Берәрсенең бүлмәсенә кереп утырып булмый, нишләп болай бушка вакыт уздырып йөргәнеңне аңлатырга туры киләчәк. Хәлне исә һичкемгә белдерергә ярамый иде. Коридордан кеше сирәк уза, аяк тавышлары ишетелүгә, Сидоров, тиз-тиз атлап, аңа каршы китә һәм, исәнме-саумы, хәлләр ничек, дип, бик ашыккан кыяфәт белән китеп бара. Аннары тагын бер почмакка посып уйга кала иде. Яшь Канчуровның нинди «эксперимент» белән шөгыльләнгәне аңлашыла башлаган иде инде аңа...

Тикшерүченең үз кабинетыннан бу рәвешле «очрашулар урыны» ясаганын өстәгеләр белсәме?! Ярый ла полковник Канчуров якласа. Энесенең төрмә кошы белән «вәч-вәч» икәнен полковник белә микән соң әле? Нииндидер яшерен препарат белән агуланган кыз белән тагын. Ай-һай ла!

Сидоров, йөзенче мәртәбә генә түгелдер, сәгатенә күз салды. Бер сәгать узган иде инде. Ни зарыгып күрешкән булсалар да, бу вакыт эчендә теләгән сүзеңне сөйләп бетерергә була... Шулай да алар, мөгаен, бүлмәдән үзләре чыкмастыр...

Ул, ботинкалары белән каты-каты басып, коридор буйлап узды һәм, тамагын нык кырып, ишекне ачты. Егет белән кыз бер-берсеннән читләштеләр. Заһидә кызыл чәчкәле ак күлмәк кигән, бүлмәгә бу урынга бөтенләй ят булган, бию кичәләрендә иң затлы кызлардан гына аңкый торган хуш ис таралган иде.

— Сезгә бирелгән вакыт узды, — диде Антон Никитич, ягымлы, әмма шул ук вакытта катгый итеп. — Хушлашырга туры килер.

Ул күтәрелеп карады һәм шундук эшнең бик тирәнгә киткәнен аңлады. Аның алдында чыннан да гашыйклар басып тора иде. Күз карашларыннан түгелгән уртак нур, бит очларында уйнаган алсу яктылык, тәннәренең бер-берсенә тартылып та, чит кеше алдында оялудан гына читләшеп торуы, тагын әйтеп бетереп булмый торган, әмма, хуш искә уралып, бүлмәдәге бөтен мохитне үзгәрткән сихри дулкыннар моны раслый иде. Тикшерүченең гомер уртасына җитеп, күпне күреп муртайган җаны кинәт йомшап китте, яраланган тән тамырларыннан күптән инде тоелмаган җылы дулкын узды.

Надзиратель хатын килеп Заһидәне алып чыгып киткәннән соң, тикшерүче моннан соң болай очраштыра алмаячагын әйтергә дип авызын ачкан иде, Виленга күтәрелеп карагач, алдан әзерләнгән сүзләре тамак төбенә төелеп калды. Егетнең моңарчы тимердәй салкын булып тоелган зәңгәр күзләрендә сөю бәхетенең нуры балкый һәм аерылу газабының ялкыннары яна иде. Әйе, бу егет гашыйк иде һәм аның өчен мәхәббәтеннән мөһимрәк һәм сөйгәне белән кавышу теләгеннән дә көчлерәк берни юк иде.

Зиһенен йөрәк хисләре томалаган адәм акыл тавышын ишетәмени?!

Сидоров үзендә бу егетнең юлына аркылы басарлык көч юклыгын аңлады. Дөресен генә әйткәндә, теләге дә юк иде аның. Әгәр кулыннан килә торган булса, ул бу мәгъшукларны бүген үк никахлаштырып, кавыштырып куяр иде дә, типтереп туйларында биер иде! Һәм бик бәхетле булыр иде!

Әмма дә ләкин... Ул Заһидәне, ничек кенә теләсә дә, ирекккә чыгарып җибәрә алмый иде шул.

Гашыйклар белән бу рәвешле бәйле булу үзе тагын хәтәр хәл иде. Сөю ялкынында икәү дөрләп янганда, алардан ургылган ялкын телләре бүтәннәрне дә ялмап ала кайчак!

Сидоров шундый ялкынның эссесен тойгандай булды.

Нишләргә?

Положение буенча Сидоров, үз начальнигыннан узып, Канчуровка мөрәҗәгать итәргә тиеш түгел. Шик-шөбһәләре турында тикшерү идарәсе җитәкчесенә язып бирергә тиеш иде ул. Ләкин бит мәсьәлә бик тә четерекле иде. Канчуровларның начар данын таратуга сәбәпче булып, полковникның бара торган юлына палас җәясе урынга, таш ыргытучы булып күренүең ихтимал.

Аркылысын-буен җиде кат кына түгел, җитмеш кат үлчәгәннән соң, ахыр чиктә барыбер да дөрес кисәчәгенә иманы бик үк камил булмаса да, Антон Никитич полковник белән элемтәгә керергә булды.

...Икенче көнне иртән ул, Канчуровның кабул итү бүлмәсенә шылтыратып, адъютанттан полковник белән тоташтыруын үтенде. «Нинди мәсьәләдә?» — дип сорады адъютант, командир тавышы белән. «Шәхси мәсьәлә, — диде Антон Никитич. Аннары тавышын әкренәйтеп, серле итеп: — Полковникның племяннигы Вилен Канчуровка кагылышлы», — дип өстәде.

Ул Виленның полковникка бертуган түгел, туганнан туган энекәш икәнен белешкән иде инде. Кайберәүләр мондый кардәшлекне чыбык очы, тал башы дип санасалар да, татарларның мишәр дип аталган кавемендә бу һич тә алай түгел икән. Алар, яһүдләр кебек, бер-берсен җан тырмашып күтәрешәләр, дип сөйләде белгән кешеләр. Касыймның да, милләте татар була торып, шундый югары күтәрелүе үзенең уңганлыгыннан гына түгел, ә бәлки, кавеменең күмәкләшеп артыннан этүеннән дә иде булса кирәк.

Полковник тикшерүчене шундук үзенә чакырды. Чыннан да, аның өчен туганнар мәнфәгатен кайгырту күп нәрсәдән мөһимрәк иде булса кирәк.

R R R

Касыйм Канчуров эшнең бу кадәр үк тирәнгә киткәнен белми иде әле. Тикшерүче Сидоровны тыңлаганда, баштарак аның зәңгәр күзле кырыс чыраенда ышанмау, сабырсызлык галәмәтләре ярылып ята иде. Ләкин Антон Никитичның калын күзлек пыялалары аша сабыйларча ихласлык белән мөлдерәгән күзләренә текәлебрәк карагач һәм энекәше белән соңгы сөйләшүне исенә төшергәч уйлана калды ул. Тикшерүчене бер сүз әйтми тыңлады да:

— Сүзегез беттеме? — дип сорады. — Тогда можете идти. Китәргә рөхсәт.

— Миңа нишләргә соң инде хәзер? — дип аптырап урыныннан купты Антон Никитич.

— Үзегезгә тапшырылган бурычны үтәүне дәвам итегез, — диде полковник. Аның күзләреннән боз салкыны бәргәндәй булды.

Сидоров тәмам шым булып чыгып китте.

Хәлбуки Касыйм үзе дә шактый ук аптыраште калган иде. Аның өчен башка сыймаслык хәл иде бу. Акылын җуяр дәрәҗәдә гашыйк булыр яше узган бит инде Виленның! Аннары чибәр кызлар күргән саен мәлҗерәп төшә торганнардан түгел, нык буынлы, салкын акыллы ир-егет ул лабаса! Полковник тәгаен генә белми, кызыксынганы да юк, әмма күзе бар, күреп тора: егет инде кү-үптән ир булды! Хәзер инде кирәк чакта берәр гүзәлне кочу аның өчен ресторанда балык уылдыгы сорап алу белән бер булырга тиеш. Аллага шөкер, моңа бөтен мөмкинлекләре бар. Акчасы да, чибәрлеге дә җитәрлек.

Ә ул гашыйк булган, имеш! Кемгә диген! Төрмә сасысына гарык булган мәхбүскә! Аның да коточкыч агу белән агуланганына!

«Иблис затыннан яратылгандыр бу хатын-кыз дигәннәре, билләһи, — дип уйлады ул. — Хәтта төрмәгә ябып та котылып булмый шулардан. Менә дигән асыл егетләрнең башларын шулар ашый бит, каһәр суккыры! Өрлектәй ирләрне егып сала торган агуга да бирешми үзләре. Атом бомбасы шартлагач, бөтен җан иясе һәлак булганда да, күселәр исән кала икән. Хатын-кыз кавеме дә шул күселәр белән бер балчыктан әвәләнде микән әллә?»

Ни генә булмасын, полковник Канчуровның турыдан-туры ябылу урыннарына күрсәтмә биреп утырасы килми иде. Моңа вәкаләте дә юк иде аның. Институт галимнәрен төрмәгә кертүне сорап, профессор Рассекаев мөрәҗәгать иткән иде бит. Бу юлы да аның аркылы эш йөртү җайлырак булыр дигән фикергә килде ул.

Ул адъютантына телефон аша профессор белән тоташтырырга боерды. Рассекаев белән гадәттән тыш йомшак, ягымлы сөйләште, исәнлек-саулыгын сорашты, аннары:

— Сезнең белән киңәшәсе бар иде, Федор Кузьмич, — диде. — Вакыт табып, килеп чыга алмассызмы икән?

Рассекаев, кырык эшен кырык якка ташлап дигәндәй, шундук йөгереп килеп җитте, әлбәттә.

Күзлек астыннан җыерчыклы чыраеның яртысы гына күренеп торган, бер якка бөкрәеп килгән бу картның дөньядагы иң куркыныч агулар ясау белән мәшгуль булуын әйтсәң, адәм ышанмас иде. «Әйе, адәм баласының эчендә ни барын белеп булмый, — дип уйлады Касыйм. — Андагы сер сандыгы бер генә түгел һәм ачкычлары да бик ерак яшерелгән».

Профессор сүзне Виленны мактаудан, аның ерак китәчәгенә, зур галим булып үсеп җитәчәгенә һичшиксез ышануыннан башлады. «Кырык ел эшләү дәверендә минем андый өч кенә шәкертем булды», — диде ул.

Шулай итеп, полковникка җай эзләргә дә туры килмәде, сүз үзеннән-үзе соңгы экспериментка барып тоташты.

— Безне нәкъ шул мәсьәлә кызыксындыра иде, Федор Кузьмич, — диде полковник. — Бу юнәлештә тикшеренүләрне тагын күпме дәвам итәргә уйлыйсыз?

Профессор, сорауга кыска гына җавап бирәсе урында, тулы бер лекция укырга кереште. Фән бик катлаулы өлкә бит ул, кайда нинди ачыш ясаласын белеп булмый. Әйтик, әнә Архимед, юынырга дип лаканга кергәч, суның ташып түгелүенә игътибар иткән. Ньютон, башына алма килеп төшкәч, җирнең тарту көчен белгән... Монда да кайда нинди ачыш ятканын...

Полковник аны бүлми чыдый алмады:

— Бүгенге көндә хатын-кызлар төрмәсендә андый күзәтүләр алып бару сезнең быелгы эш планыгызга кертелгән идеме соң? — дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды ул. — Һәм бу эш нәкъ менә аспирант Канчуровка йөкләтелгәнме?

Профессор, сирәк чәч белән өртелгән сөякчел башын иеп, сул җилкәсен сикертеп җавап бирде:

— Юк, — диде. — Ләкин...

— Сез миңа турысын гына әйтегез, Федор Кузьмич!

— Әйтәм бит, яшьләргә дә юл бирми булмый... Аларның теләген һаман-һаман аяк астына салып таптый торган булсак...

— Димәк, минем аңлавымча, бу эш план буенча түгел, ә аерым бер фәнни хезмәткәрнең теләге буенча гына башкарыла. Шулай килеп чыга бит, Федор Кузьмич?

Касыйм, әлбәттә, бу матавыкны үз энекәше башлаганын бик яхшы хәтерли, әмма моны профессор авызыннан әйттерәсе килә иде.

Рассекаевның исә уй-фикере бөтенләй башка юнәлештә агыла иде. Аның тоник күзләре хәтта күзлек аркылы да елтырап куйды. О-о, үз дәрәҗәсен бик белә иде, каршында фәннең «ф» хәрефен дә аңламаган

солдафон утырганын аңлый иде ул. Профессорның эчендә хәрбиләрне, гәрчә алар разведка эшләре белән шөгыльләнсәләр дә, надан санап, яшерен кимсетү ята иде. Химиядә ни аңлый соң алар?

Шуңа күрә, мәктәп баласына аңлаткандай, сабырлык белән янә сөйләргә кереште:

— Без эшли торган өлкә — ул бит фәннең алдынгы сызыгында. Гәрчә бүгенге көн өчен бик мөһим, ифрат кирәкле проблемаларны чишү белән шөгыльләнсәк тә, аның киләчәктә нинди нәтиҗәләргә китерүен белеп бетереп булмый...

— Минем аңлавымча, әгәр дә кеше, сез ясаган агудан сәгатендә егылып җан бирмәсә дә, киләчәктә барыбер аның тәэсиреннән котыла алмаячак, барыбер сәламәтлеккә тиенмәячәк, шулаймы? — дип, хәрбиләрчә ачык итеп сорады полковник.

Профессор борынын җыерып куйды, бу сорау аңа артык тупас тоелды булса кирәк.

— Шәрәләндереп әйткәндә, шулайрак шул, — диде ул.

— Ә нәрсәгә аны киендереп торырга! Монда мәсьәлә, киресенчә, ап-ачык булырга тиеш.

— Андый проблемалар озаклап, дистә еллар буе күп кешеләрне тикшерүне, күзәтүне таләп итә. Әнә бит, атом бомбасын беренче тапкыр сынаганда, шартлау булу белән шул урынга солдатларны куып керткәннәр. Аларның, көчле нурланышка дучар булып, бераздан һәлак буласын белмәгәннәр ул чакта. Газапланып һәлак буласын... Һәм аннары моның аяныч йогынтысы аларның балаларына күчәсен дә белмәгәннәр.

Канчуров сискәнеп китте:

— Нәрсә? Балаларына, дисезме? Нәсел тамырын корытамы? Сез ясаган препаратмы?

Профессор җыерчыклы кулларын җәйгәндәй итте.

— Кем белә нәрсә буласын... Күзәтүләрнең нәтиҗәсе әйтер...

— Нәрсәне күзәтергә?

«Безнең нәселдә сынау үткәрсеннәрме әллә?»

Юк, соңгысын әйтмәде Касыйм, тел очында туктатып калды. Әмма бу уй мине ярып узды.

Ул, урыныннан кузгалып, тәрәзә янына барып басты. Зиһене чуалып киткәнен әңгәмәдәшенә сиздерәсе килми иде.

— Шул препаратмы әле ул побочный эффект бирә торган? — дип сорады ул борылмый гына.

— Әйе, нәкъ шул.

— Алайса, ул хатынның нилектән шулай кылануы аңлашыла. Шулай бит?

Полковник кинәт борылды да, каты-каты басып, профессорга таба атлады. Федор Кузьмич хәтта куркып китте, сугудан сакланырга теләгәндәй, муенын җыерып, башын эчкә тартты.

— Ул препаратның сезнең хезмәткәрләргә дә эләккән булуы мөмкин бит! — диде күзләре агарган полковник, аңа таба иелеп.

— Ничек?! Андый хәлнең булуы һич мөмкин түгел! Саклану чаралары бездә бик каты куелган. Аннары Вилен Шаяхметович тәҗрибәле кеше! Фәннәр кандидаты!

— Ә нишләп соң...

Полковник сүзен әйтеп бетермәде, кулын гына селкеде дә урынына барып утырды. Ул үзен кулга алган иде инде.

— Мин сездән шуны үтенеп сорар идем, — диде ул. — Фәннәр кандидаты Канчуровның тикшерү идарәсенә барып йөрүе бүгенге көндә сезнең бүлектә алып барыла торган тикшеренүләр өчен бик үк мөһим булмаса...

— Һич юк, һич юк, — дип, аның уңаена авышырга ашыкты профессор.

— Ул вакытта сез Канчуровка даими пропуск бирүне сорап язган хатыгызны юкка чыгарсагыз яхшы булыр иде.

— Ничек? Ул хат анда бит инде!

— Ә сез тагын бер хат языгыз. Рәхмәт әйтеп. Һәм андый пропускның кирәге бетте инде, дип. Хәзер үк. Тагын шуны үтенәм: бу сөйләшү безнең икебезнең арада гына калсын иде. Сез сер саклый белә торган кеше, мине аңларсыз дип ышанам.

— Әлбәттә, әлбәттә... Тик сез бер дә юкка борчыласыз. Безнең препарат бик тиз таркала, кешедән кешегә йокмый.

— Сез лабораториядә хуҗа, без — хокук саклау органнарында, — дип, аның яшерен уйларын аңлап утырган полковник бик җайлап кына үз урынына утыртты аны. — Хәзерге вакытта сезнең хезмәткәрегезнең анда болганып йөрүе күзгә ташлана торган бер күренеш булып тора һәм сәламәт булмаган кызыксыну уята. Ә бу безгә һич кирәкми. Шулай булгач, сез инде безнең үтенечне кире какмагыз.

«Шпиономания белән саташкансыз инде, сезне бәхәсләшеп җиңәрмен димә», — дип уйлады профессор. Ә полковниктан:

— Монда языйммыни? — дип сорады.

— Нишләп монда? Аны рәсми кәгазьгә басып, исәпкә алырга һәм штамп сугарга кирәктер бит? Хәзер үк сезне машина белән институтка илтеп куярлар. Көтеп торырлар. Һәм шундук хатыгызны кичекмәстән адресатка илтеп тапшырырлар да.

Профессор дәшмәде. Әмма бу солдафон аның мин-минлегенә бик каты тигән иде. Ул моңа каршы тора алмый, электән куркып килгән гадәт үзенекен итә. Аның саен рәнҗеш арта гына бара иде. Полковниклар күп ул бу илдә! Ә менә профессор Рассекаев уйлап чыгарганны дөньяда беркемнең булдыра алганы юк әле!

Нәфрәте күзләрендә чагылудан куркып, ул керфекләрен аска төшерде. Хушлашып полковникның кулын кысканда да, карашын идәндәге кызыл паластан күтәрмәде.

R R R

Иртәгәсен Вилен, ике кулына ике зур төргәк күтәреп, турыдан-туры бакча каршындагы ишеккә килде.

— Мин тикшерүчегә, Антон Никитич Сидоровка, — диде әчке яктагы таш сындай үрә каткан нечкә билле сержантка. — Ул мине көтә.

Тикшерүченең йомшаклыгын сизеп алган иде инде ул, бу юлы да сындырырга өметләнә иде. Аңа атап күчтәнәчләр дә алып килде: «Столичный» аракы, кара уылдык, затлы балык. Һәммәсен рестораннан алырга туры килде. Әмма җәл түгел иде. Ә икенче кулда — Заһидәне сыйларга дигәннәре. Анысында — «Советское» шампанское, тәмле конфет, торт.

— Бер минут! — диде сержант һәм телефон трубкасын күтәрде.

Озак тыңламады, башын күтәреп:

— Өлкән тикшерүче Сидоров урынында түгел, — диде.

Вилен борылып чыкты да, сулышына кабып, йөгерә-атлый өске урамга, бинаның икенче ягына чыга торган ишеккә таба китте. «Баш табиб Грачев урынында булса гына ярар иде!» — дип теләде ул күңеленнән.

Сергей Матвеевич урынында иде. Телефоннан Виленның тавышын ишеткәч һәм аның капка төбендә икәнен белгәч, ул аптырап китте:

— Ничек? — диде. — Сез белмисезмени? Сезнең пропускыны кире алдылар бит!

— Кем?

— Институттан килгән хат буенча дип ишеттем.

Вилен кире йөгерде, бакча аша чыгып, «Волга»сына утырды да институтка таба куды. Андагы сәркатип кыз, чыннан да, кичә шундый хат киткәнен раслады. Нишләп? Ни өчен? Монысын сорар кеше дә юк иде, чөнки профессор Рассекаев икенче шәһәргә китеп барган, анда аны ашыгыч рәвештә ниндидер комиссиягә чакырганнар икән...

Вилен тәмам гаҗиз иде. Ул үзен тау куышында адашып калгандай хис итте. Килгән юлын югалткан, чыгар юлы күренми. Аңлашылмый иде бу, башка сыя торган түгел... Остазының беркайчан да аны авыр хәлгә куйганы булмады. Нигә алай иткән ул? Аннан да бигрәк хәзер нишләргә? Заһидә көтә бит аны, зарыгып көтә!..

Аңа фәкать Касыйм абзасы гына ярдәм итә ала иде. Дөрес, узган юлы ачык чырай күрсәтмәде күрсәтүен. Әмма тынычрак урында иркенләбрәк сөйләшсәләр, энесенең күзләренә туры карася, аның хәлен аңлар, ярдәм итми калмас.

Вилен абзасының кабинетына ике кулына ике букчаны кочаклаган килеш барып керде. Ишек төбендәге адъютант сәерсенеп карап калса да, полковникның туганын туктатырга батырчылык итмәде. Бүлмәгә кергәч, Вилен букчаларын ишек янындагы урындыкларның берсенә куйды да түргә таба атлады. Исәнләштеләр. Полковник утырырга кушты. Авыр тынлык урнашты. Ул шактый озак дәвам итте, әмма Касыйм берни сорамады, сүзне башларга ашыкмады.

Ниһаять, Вилен, бөтен батырлыгын җыеп, абзасының күзләренә мөлдерәп карап, гозерен аңлатырга кереште. Касыймның карашы томанланып тора, ни уйлый: хуплыймы ул энесен, әллә гаеплиме, һич аңларлык түгел иде. Вилен үзен кар көрте ерып баргандай тойды, сүзләре буталды. Кадерматова дигән мәхбүсне даими күзәтүнең фәнни зарурлыгын, бу эшне ул үзе башкарырга тиешлеген аңлатырга маташты ул. Бу препаратның киләчәге зур булуын, дөньякүләм яңгыраш табачак зур ачышка китерәчәген сөйләде. Һәм мондый препаратны булдыру өчен дөньяның иң талантлы галимнәре җитәкчелегендәге зур коллективлар эшләгәнен...

— Ишеттем инде, ишеттем, минем миемә кершән сипмәсәң дә була, — дип бүлдерде аны Касыйм. Ул энесен үтәли күрә иде кебек. — Профессор Рассекаев белән киңәштек без бу мәсьәләдә. Синең уңышларың безне чиктән тыш куандыра, әлбәттә. Без сине, икәүләшеп, арт ягыңнан этеп күтәрер идек! — Касыйм ике учын баш өстенә таба югары күтәреп куйды. — Күзәтергә кирәк, әлбәттә. Эшләргә, тырышырга, — дип, Виленга сөеп карады ул. —Бөтенесен бер селтәнүдә хәл итәргә омтылуың да аңлашыла. Яшь чакта мин үзем дә шундый идем. Безнең нәсел каны кайный шул синдә!

Ул, урыныннан торып, Виленның урындыгы артына килеп басты. Аның йөзен күрер өчен егеткә башын җайсыз каерып карарга туры килде, бу аны кечерәйтеп, баласытып куйды. Вилен кузгалмакчы булды, абзасы ике кулы белән нык итеп аның иңнәренә басты.

— Алмагачны утыртуга, икенче көн иртәнгә ул үсеп куйсын, өйләгә чәчкә атсын, кичкә алмасы пешсен дә авызга төшсен. Күңел шуны тели, әйе бит?

Ул хихылдап көлеп куйды. Бу көлүдә баласыту белән бергә ярату аһәңнәре чагылды.

— Әмма агач без кушканча, без теләгәнчә түгел, үзенчә үсә. Фәнни ачышлар да шулай. Монда профессор миңа аңлатты. Синең препаратыңның чын кыйммәтен ачыклау өчен күп еллар кирәк булачак икән әле.

Вилен торып басмакчы иде, Касыйм тагын көч белән аның иңбашларына басты.

— Бик күп сынаулар үткәрергә, дистә еллар буе күзәтүләр алып барырга туры киләчәк икән. Барсына да берүзең өлгерерсеңме соң? Ябылу урыннарында да табиблар бар. Карарлар, күзәтерләр, анализларын ясарлар да һәммәсен бәйнә-бәйнә сезгә язып бирерләр.

Виленның моңа каршы әйтер сүзе юк иде. Чарасызлыктан зиһене чуалып, ул башын иде.

Касыйм, өстәлнең икенче ягына чыгып, каршыга утырды.

— Ял итәргә кирәк сиңа, — диде ул. — Фәнни ачышлар җиңел генә бирелми. Күп уйлау йөрәк маен ашап кына калмый, минең сүлен киптерә. — Ул, бу сүзен бик тапкырга санап, елмаеп куйды. — Син анда, лаборатория белән төрмә арасында чуалып, якты дөньяда ниләр барын оныткансыңдыр инде. Егет кешегә җилләнергә кирәк! Ансыз яшәп булмый! Абзаң буларак, мин сиңа андый киңәш бирергә тиеш тә түгелмендер, бәлки. Әмма синең белән без чын ирләрчә сөйләшә алабыз. Шулай бит? Бар әле син, дускай, ресторанга... Сине көтә-көтә кайбер чибәркәйләр зар-интизар булганнардыр инде анда, ә? Сасы камераларда яткан занюханный төрмә кошлары түгел шул инде алар! Бар, сөендер. Затлы ризык белән сыйла һәм сыйлан!

Вилен, телен аркылы тешләгән хәлдә, башын иеп утыруында булды. Ул чарасыз иде. Турысын әйтеп булмый, араларны гына бозачаксың... Иң аянычы шунда: полковник аның хәлен аңламаячак, ә менә Вилен абзасының күңеле изгелектә генә икәнлеген бик яхшы аңлый иде! Үзе дә аның белән бер нәсел орлыгыннан яралган, шул кавемнең сөтен имеп, сүзен ишетеп, алардагы тәкәбберлеккә тиң горурлык тойгысын сеңдереп үскән егет — мәгърур Канчуров иде ләбаса ул!

Аның каушаганын тоеп, Касыйм һаман бер ноктага бәрде.

— Мин сиңа әйткән идем бит инде, анда да эксперимент ясарга булганын, — дип, күзләрен түшәмгә күтәреп, ничектер мәгънәле елмайды ул. — Французский шампанскийга мул гына итеп «Столичный» аракыны аудар да, шуны зур гына бокалга салып, берәр шәп кызыйга тоттыр. Синең ачышларың хөрмәтенә күтәреп җибәрсен икене-өчне... Тәэсире синең препараттан кимрәк булырмы? Ә бәлки, көчлерәктер дә?! Препаратыңның «побочный эффект»ын әйтәм. Чын-чын, сынап, чагыштырып кара әле син! Без яшь чакта моны куллангалый идек!

Касыйм ялманып алды, күзләре майланып китте, иреннәренә мәгънәле елмаю җәелде.

— Их, энекәш... Синең урыныңда мин булсаммы! Яшь чакта яшәп кал! Муенга гаилә камыты кигәч, әллә кая сикерә алмыйсың! Тукай әйтмешли, картаеп каткач буыннар, рәтле эш майтарып булмый...

Ихластан, яратып, игелек теләп, йомшак итеп әйтелгән сүзләр, шуңа өстәп җылы, ягымлы караш, ике арадагы туганлык якынлыгы кемнең генә җанына сары май булып ятмас икән?

Вилен икеләнеп ишек тарафына, урындыктагы букчаларга борылып карады.

— Нәрсә анда? — диде полковник. Ул инде эшнең хикмәтен аңлаган иде. — Передачамы? Анысы өчен борчылма. Хәзер үк илтеп тапшырырлар. Әгәр телисең икән, записка яз син аңа.

— Нәрсә дип?

Полковник көлеп җибәрде.

— Әйтер сүзең юкмыни соң бер дә?

— Мин аңа үзем барырга вәгъдә иткән идем. Бәлки, бүген...

— Алай булмый, — диде полковник дустанә итеп, әмма шул ук вакытта катгый ныклык белән. — Ничек итеп мин профессорның сүзен аяк астына салыйм ди? Ул пропускыны юкка чыгарган, мин аны яңартыйм, имеш. Бала-чага уены түгел бу сиңа. Яз шунда берәр нәрсә. Командировкага китәм, диген...

— Минем аңа ялган сөйләгәнем юк!

Бусы һич көтмәгәндә телдән ычкынды. Касыйм аңа текәлеп карады:

— Син аңа кем икәнеңне, кайда эшләгәнеңне,ниләр ясаганыңны да сөйләдеңме? Дәүләт серен чиштеңме әллә?!

Аның тавышында курку катыш янау чагылып узгандай булды.

— Юк... Ул мине адвокат дип белә.

— Адвокат дип? Син аңа үзең шулай дидеңме?

Касыйм җиңеләеп көлеп җибәрде. Виленның йөрәгенә кинәт сызлавык килеп чыккандай булды. Шунда гына ул Заһидә белән ике арага зур ялган кереп оялаганын аңлады.

Ул абзасы каршындагы өстәлдән кәгазь-каләм алды да бер минутка тукталып калды. Язу, кулдан-кулга күчеп, әллә ничә күз аша үтәчәк иде.

*«Иптәш Кадермәтова!* — дип башлады ул. — *Кичерегез, мин бүген килә алмыйм. Ашыгыч эш килеп чыкты. Канчуров».*

— Нинди иптәш булсын ул сиңа? — диде Касыйм, язуны кулына алгач. — Гражданка дияргә иде. Аннары... адвокат гафу үтенә димени?

Вилен язуны алырга кулын сузган иде, Касыйм бирмәде.

— Ну ярар инде. Дәүләт серенә бәйле нәрсә түгел, — диде һәм, кара телефон аппаратының төймәсенә төртеп, адъютантын чакырды.

Чыгып киткәндә, Вилен букчаның тикшерүчегә тәгаенләнгәнен үзе белән алды.

R R R

Полковникның адъютанты Кадермәтовага дигән төргәк-передачаны ишек төбендәге сакчыга калдырып, тикшерүче Сидоровка бирергә кушты да кырт борылып чыгып китте. Антон Никитич букчаны бераздан гына төшеп алды.

Бүлмәсенә кереп, Виленның язуын укыгач, ул моның хикмәтен үзенчә аңлады. «Яшисең-яшисең, эшлисең-эшлисең, адәм баласын үтәли күрергә өйрәнгән кебек буласың, барыбер андагы каралыкны, эшәкелекне күреп бетерә алмыйсың, — дип уйлады ул. — Инде монысын ихлас дип уйлаган идем. Хисләре чын кебек тоелган иде. Бичара кызны кызганыр, ничек тә моннан йолып алыр дип өметләнгән идем. Тагын ялгыштым. Монысы да азгын булып чыкты...» Төргәктәге тәм-том, җимешләрне актарганда, ул шулай уйлады. Муены көмеш тасма белән чорналган зур, авыр, яшькелт шешәне кулына алгач, икеләнеп торды. Моның ишене камерага бирү катгый тыелганын Канчуровлар яхшы белә, билгеле. Әмма санашып-нитеп тормыйлар, теләгәннәрен кыланалар. Хушлашу бүләге җибәргән менә. Яратканы өчен түли. Фахишәгә түләгән кебек. «Э-эх!— дип ачынып уйлады тикшерүче. — Дөреслек юк шул ул бу дөньяда!»

Бернишли алмыйсың, үз өстеңә йөкләнгәнне төгәл үтәргә генә кала. Мәхбүсләргә передачалар тапшыру сәгате үткән, Кадермәтова исә шушы минуттан башка-бүтәннәр белән бер рәткә куелган иде. Ә тәртип шулай куша: бу төргәк Кадермәтовага иртәгә, барлык башка передачаларны тапшырган вакытта бирелер. Хәмердән башкасы, әлбәттә...

...Иртәгәсе көннең исә киләсе бар иде әле. Заһидә өчен ул килмәде дә килмәде. Чөнки бүгенгесе үтмәде. Коридорда аяк тавышы ишетелгән саен, аның йөрәге аша кайнар дулкын йөгереп узгандай була, йөзе алланып, ireннәренә елмаю җәелә иде. «Хәзер ишек ачыла! Хәзер мине чакыралар!» Ләкин адымнар якыная да туктап тормыйча узып китә һәм ерагая башлый. Ниһаять, берсе тукталды. Ишекне ачтылар! Һәм... «Мартынова!» дип кычкырдылар. Бүтәнне, башка берәүне чакырып чыгардылар... Йөрәккә боз җиле бәргәндәй булды... Менә кайда икән ул «уттан алып суга салу» дигән сүзләрнең мәгънәсе... Моңа ничек чыдарга?!

Үз кайгысы гына булса түзәр иде Заһидә! Беренче көннәрдә кичергәннәре хәзер аңа бик кечкенә булып тоелды. Чөнки бүген Вилен өчен ут капкан иде аның бәгыренә, шунысына түзәр хәл юк иде.

Ник килми ул? Таш яуса да, бөтен дөньяга ут капса да килми калмый бит ул Заһидәсе янына. Әгәр килә алмаган икән, димәк... Димәк, нидер булган! И Ходаем, әллә соң йөрәге тотып, хастаханәгә алып киттеләр микән дә, анда һушсыз ята микән? Урамнан ашыгып барганда, машина бәргәнме әллә? Ул анда, кан эчендә, ә Заһидә монда, тимер ишек артында?..

Ул сабыр итәргә тырышты. Төшкә кадәр көтте. Аннан соң да бөтен көчен йодрыгына йомарлагандай итте, чыдады. Кичкә таба ишекне шакылдата башлады, тикшерүче янына илтүләрен сорады. «Бүген эш көне тәмамланды, иртәгә әйтербез», — диделәр.

Әйтүе генә ансат! Иртәгәне ничек күтәреп алырга? Йокысыз төннәр үз өеңдә, йомшак ятагыңда да авыр үтә, вакыт агышы бик салмакланган, саеккан кебек тоела. Ә инде төрмәдәге мәхбүс өчен аның ни газаплы икәнен сөйләп торасы да юк. Вакыт гүяки зинданның аяусыз диварларына, йозакларына, бикләренә эләгеп кала. Камерадагыларның уфтанып әйләнгәләгәнен, кайсыныңдыр сагышны арттырып гырлаганын тыңлап, сабыр итәргә тырышып, ничә сәгать яткандыр Заһидә. Йөрәгенең дөп-дөп типкәнен ничә мең тапкыр санагандыр... Кара төндә карурманда адашкандай булды аның өчен бу төн.

...Ул, бичара, белми иде шул әле — мондый төннәр адәм баласының башына төшә торган хәсрәтләрнең иң зурысы түгел! Монысына гына чыдарга була. Алдыңда ышанычың, өметең булганда бигрәк тә...

Коридорда аяк тавышлары дөпелдәп, надзиратель хатынның «Подъем!» дигән каты тавышы ишетелгәнче, бер төн түгел, бер ел үткәндер... Әгәр исән булса, Вилен йөгереп килеп җитәргә, сәгать тугыздан да... — ю-ук! — сигездән дә калмый, Заһидәне чакыртып алырга тиеш иде. Ләкин менә чәй дигән җылымса болганчык сыекчаны тимер кружкаларга салып чыктылар, ипи сыныклары өләштеләр.

— Аша! — дип үгетләде аны хатыннар. — Кичә дә көн буе авызыңа бер валчык кермәде. Ярамый алай! Ачлыктан бәгырь көеп кибә дә корыган утын кебек дөрләп кабынырга гына тора. Чылатып торырга кирәк аны, өсте-өстенә төрмә баландасын сибеп торырга кирәк!

Тамактан ризык үтмәгәнен белмиләр иде шул!

Ишек ачылган саен, Заһидә тыны бетеп алга ыргылды. Вилен ник килмәде? Ни булган аңа? Заһидәгә шуны гына белергә кирәк, фәкать шул соравына гына җавап бирсеннәр. Бер генә сүз белән. Бер генә сүз! Тикшерүчегә илтсеннәр, аның белән очраштырсыннар! Бер генә минутка! Ул әйтер! Ул мәрхәмәтле!

Нигә бу надзиратель хатын шулхәтле кансыз? Заһидәнең гозерен... юк, үтенечен... юк, алай гына түгел — таләбен Антон Никитичка ник җиткерми ул? Ни хакыгыз бар?!

Ул үзен-үзе белештермичә кычкырына, бәргәләнә башлады:

— Тикшерүчегә илтегез мине! Сидоровка!

— Тикшерүченең командирымы әллә син? Кирәк кешене үзе чакыра ул!

— Мин ачлык игълан итәм! Сусыз ачлык!

Камерадагылар елмаешып куйдылар.

— Ансат дип беләсеңме әллә син аны? — дип, башын чайкап куйды өлкәнрәге. — Бик исләре китәр инде...

Надзиратель хатын аңа кара көеп карады:

— Син нәрсә, китап укып саташтыңмы әллә? Элекке революционерлар кебек буласың киләме? Патша төрмәсе түгел бу сиңа! Ашарыңа биргәннәренә рәхмәт әйт!

Заһидә ишектән шуып кына чыгып китәргә омтылды. Надзиратель хатын сискәнеп каршы басты, соң чиккә җитеп гасабиланган Заһидә аңа кизәнде, йөзен тырнап алганын үзе дә сизми калды. Нечкә сынлы, тәрбияле кыздан моны һич көтмәгән хатын хәтта бер мәлгә югалап калды. Әмма шундук аңына килде дә:

— Ах, ты, сука! — дип, Заһидәне камера эченә болгап атты...

Хатыннар кызны юаткандай булдылар, тартып торгызып, урынына яткырдылар. Ләкин шул ук вакытта аларның күңелендә элекке көннәрдә купкан көнчелек хисе кызганудан өстенрәк булып калды. Соңгы вакытта бу кызыкай артыграк үсенеп киткән иде шул. Тикшерүче яныннан ничек очынып кайтып керүен генә күр, бию кичәсендә булганмыни! Яңа күлмәк кигән, баштанаяк хушбуйга коенган! Каян килгән тамаша бу мондый урында?

Дөрес, ул, адвокат белән күрештем, дигән була булуын да, ләкин биредә нинди «адвокат»ларның күңелне шушылай күтәргәне билгеле бит инде... Һәрхәлдә, төрмә баландасын шактый гына чөмергән хатыннарга мәгълүм иде бу... Һәм бу «тәҗрибәле» затлар Заһидәгә элегрәк көнләшеп караган булсалар, хәзер исә аның кыланмышларын кинәнеп күзәтәләр иде. Күпләрнең башыннан үткән: бирегә эләккән яшь, чибәр кызларны башта шулай күтәреп чөеп җибәргәндәй итәләр дә, аннары, нәфесләре канәгатьләнгәч, арт белән борылалар. Һәм син, менә шушылай итеп, камераның бетон идәненә дыңгылдап килеп төшәсең...

— Ничава, күнегерсең әле, — диде бер хатын, һәммәсенең уртак фикерен белдереп.

Һәркемнең үз хәле хәл, һәр кешенең үз башы үзенә газиз! Ә монда мисле ачы фаҗигане тере сурәте кебек туктаусыз ишекле-түрле әйләнгәләп, сораганга рәтләп җавап бирмичә, беркемне күрмичә-ишетмичә болганган кеше һич тә кирәк түгел иде.

Шактый гына вакыттан соң надзиратель хатын кире әйләнеп керде дә:

— Кадерматова, на выход! — диде.

Камерадагылар шым булдылар.

— Карале, үзенекен итте бит бу чыпчык, — диде берсе. — Тәки тикшерүчегә бара.

— Бармый торсын әле, — диде надзиратель хатын. — Карцерга бара ул, беләсегез килсә!

...Җәзаның иң аяусызы менә кайда икән ул! Коры тимер ятак кына куелган, кап-караңгы, дымлы һәм салкын таш куышта. Тәне газапланганын тоймады да шикелле Заһидә. Җан газабы — Вилен хәсрәте талый иде аның бәгырен! Әгәр Заһидәне монда китереп тыкканнар икән, димәк, Виленның сүзен санга сукмыйлар, аның белән гомумән исәпләшмиләр дигән сүз. Ә нинди очракта шулай булуы ихтимал? Ашыгыч рәвештә берәр кая китсә дә, хәтта чирләп ятса да, соңрак аның ни әйтерен уйламый булдыра алмаслар иде... Димәк, бередәгеләр аны бөтенләй юк дип саный. Ничек алай булуы ихтимал? Әллә соң аны да кулга алдылар микән? Ләкин ни өчен? Ә бәлки, аны нәкъ менә Заһидәне яклаганы өчен кулга алганнардыр?!

Бу уйга чыдау мөмкин түгел иде. Мөгаен, Вилен бу минутларда аның өчен — Заһидә аркасында газап чигәдер. Ә ул монда кысылып ята, аны яклап бер сүз дә әйтә алмый!

Бергә булган минутларны мең тапкыр күз алдыннан үткәрде ул. Виленның артык дәрәҗәдә онытылып назлый башлаганын сизгәндә, аның кулларын йомшак кына читкә этәргән чакларын уйлап, мең мәртәбә үкенде. Ахырга кадәр җитәргә, гел аныкы булып бетәргә кирәк иде, дип өзгәләнде.

Таза-сәламәт егет җан сөйгәне белән бергә уртак бәхет бишегендә тирбәлергә теләсә, бу гөнаһмыни? Әгәр чын дөресен әйтсәң, Заһидәнең дә тәне, һәр күзәнәге аңа сеңеп, аныкы булып эреп бетәргә омтылмадымыни? Саф кыз оялчанлыгы гына тотып калган иде аны. Шул гына егетнең калтыранган кулларын үзенең тыгызланып кызышкан күкрәкләреннән алып, исерткеч хуш исле сулышыннан битен читләштерергә мәҗбүр иткән иде. Заһидәнең бармаклары аның муенының, колак яфрагының нәфис йомшаклыгын хәтерли, борыны аның чәченнән килгән татлы исне саклый. Аның кулларыннан килгән кайнар дулкын әле дә килеп бәрелгәндәй була, һәм кызның бөтен вөҗүде тетрәнә.

Әйе, моңарчы ул оялды, кыенсынды. Ләкин тагын очрашулар насыйп булса, оялу хисен онытыр иде Заһидә. Сөю булган җирдә оят юк, дигәннәр. Ә Заһидә аны сөя, беркайчан, беркемне болай яратканы юк һәм булмаячак та! «Әгәр тагын күрешсәк, бөтен барлыгым белән аңа буйсыныр идем, алай гына да түгел, аныкы булырга теләгемне үзем сиздерер идем... Аңа сеңеп бетеп, баш түбәсеннән үкчәсенә кадәр иркәләп назлар идем...» — дип, дога урынына кабатлый ул. Әйе, бер-берсен мәңге ташламаска, ир-хатын булырга ант эчеп кавышачаклар алар.

Ах, ник соң ул Заһидә иректә чакта, шәһәр урамнарында йөргәндә очрамады икән? Нигә бу язмыш иң бәхетле мизгелләрне бәхетсезлек белән бутады? Һәм шуның белән аларның фаҗигасен мең тапкырга тирәнәйтте?..

Кайда ул? Кайсы төрмәнең нинди салкын диварлары артында газаплана? Мөгаен, Заһидәне уйлыйдыр, аның өчен үзәге өзеләдер!

Заһидә, үзен-үзе белештермичә, ишеккә ташлана:

— Ачыгыз! Тикшерүчегә илтегез мине! Ул гаепле түгел! Тамчы да гаебе юк аның!

Әмма ишекләр калын, кыз баланың йодрыгы, тезе, маңгае көчсез. Ишетүче юк.

Ул бәргәләнә, сугыла да, борыныннан, ярылган маңгаеннан аккан канга сулышы буылып, идәнгә егыла.

Кич җиткәч, азык эзләп ярыклардан чыккан күселәр, кан исен сизеп, аның битенә үрмәли башладылар. Ул, сикереп торып, аркасын боздай салкын, юеш диварга терәп басты. Төнне шулай чыкты. Хәер, вакытны чамалый алмады, тәүлекнең ничәнче сәгате икәнен белмәде ул. Биредә төнне көннән үзләренә генә бирелгән табигый сәләт белән күселәр генә аера иде.

R R R

Заводта янә кыскартулар башланды. Цехлардагы, ишегалларындагы чүп-чарга, канализация коелары тирәсенә җәелгән мазут күлдәвекләренә игътибар итәргә җитәкчеләрнең вакыты да, көче дә калмаган иде. Бер Мортазаның гына күзен ерта кебек иде алар. Ул Илүсә белән киң мәйданнарны тар итеп йөргән чакларын сагына, әрепләшкән минутлары да татлы булып искә төшеп, үзәкне өзә иде. Җиргә иелгәндә, кызның юка костюм-чалбары аша тәненең тыгызлыгы беленеп, таза-саулыгы, яшьлек көче бөркелгән чаклары күз алдына килә. Аннары көлсу чәчләрен сирпеп башын күтәрүе, очлы борынын җыеруы, дугаланып килгән нечкә кашы астыннан өздереп каравы... Саф, нечкә аһәңле тавыш... Нинди бәхетле минутлар булган ул, Мортаза кадерен генә белмәгән!..

Илүсәне эзләп барудан тыелып торыр өчен, аңа бөтен ихтыяр көчен җигәргә кирәк булды. Ярый әле, баракта телефон юк. Ярый әле, Илүсәнең эше заводта гына түгел...

Йокысыз төннәр, «уф» дисәң, авызыңнан ялкын бөркелердәй көннәр бик әкрен үтә иде. Онытырга кирәк, мәңге искә төшмәслек итеп хәтердән чыгарып ташларга... Әмма бу уй шулкадәр ачы, бәгырьнең сыкравына чыдарлык түгел иде.

Көндезләрен генә булса да онытылып торырга эш-шөгыле дә юк иде, ичмаса. Заводка барсаң, башта һаман бер уй: кайчан кадрлар бүлегенә чакырып алырлар да, «кыскарту сәбәпле вазифаларыннан азат

итәргә» дигән приказны кайчан чыгарып эләрләр икән дисең. Ә бәлки, «үз теләгем белән эштән азат итүне сорап» гариза язарга тәкъдим итәрләр. Һәм шуннан соң... Шуннан соң нишләрсең дә башны кайларга куярсың?

Хәер, бер карасаң, хәзергедән әллә ни аермасы булмас та кебек үзе. Бүгенгесен дә рәхәт тормыш дип булмый бит: эшкә дип килсәң — мәгънәсезгә болганып йөрү, өйгә кайтсаң — ялгызлык. Такыр кесә белән күңел ачып йөри алмыйсың. Өч ай инде хезмәт хакы биргәннәре юк. Завод ашханәсендә, дөрес, төшкене ашаталар, хакын аерым бер журналга теркәп кенә баралар. Кайчан да булса акча биргәндә тотып калырга. Завод кибетеннән, шулай ук яздырып, ипи, яшелчә, консервы ише ризык алып була. Аларны җитәкчеләр бартерга, ягъни станоккамы, башка кирәк-яраккамы алыштырып ала. Кайбер хуҗалыкларга көрәк-сәнәк тә ясап биргәлиләр. Бик борынгы заманнарда, әле акча уйлап чыгарылмаган чакларда, кыргый кабиләләр бер-берсе белән шулай сәүдә иткән, диләр...

Хәер, иң камил приборлар ясый торган заводта көрәк, таба ише нәрсәләр әмәлләү, әле андый эшнең дә сирәк-мирәк булуы үзе үк кыргыйлыкка таба чигенүнең бер ачык мисалы түгелмени?

Әмма, хәлләр ничек кенә мөшкел булмасын, эшчеләр заводтан чыгып китәргә ашкынып тормый. Биредә син бөтенләй үк кайгыртусыз түгел, җитәкчеләр ачтан үләргә ирек бирми... Аннары бу авырлыклар үтәр, цехлар яңадан гөрләп эшләп китәр дигән өмет сүнми иде...

...Беркөнне иртән Мортаза, гадәттәгечә төшенке күңел белән эшкә килеп, калай жетонын проходной диварындагы кадакка эләргә үрелгән иде:

— Мортаза! Исәнме, Мортаза! — дигән тавышны ишетеп, сискәнеп китте.

Ул, борылып карарга куркып, хәрәкәтсез калды. Сулышына буылып килеп кергән хатыннарның берсе:

— Нәрсә булды анда, кулыгыз ябышып каттымы әллә? — дигәч кенә, читләшергә туры килде: смена башланыр минут җиткән, проходнойдан халык тоташ үтеп тора иде.

Ул борылмый булдыра алмады.

— Саумы, Илүсә...

Һәм, күзе чагылгандай, керфекләрен кысты: Илүсә гадәттәгедән дә чибәр күренде. Кыска җиңле, сыланып торган чалбарлы көрәнсу костюмы шул ук, ләкин үзе яңача да кебек. Чөнки көлсу чәчен сул якка тараган да зур гына елтыр кашлы каптырма белән эләктереп куйган. Бу аның йөзенә үсмерләргә хас шуклык биреп тора иде. Егетнең йөрәге сулкылдап куйды: Илүсәнең бу каптырмасы аның өчен тагылган иде.

— Бигрәк җитди каршы аласың, — диде кыз шукланып. — Көтмәгән идеңме әллә?

— Экологларны кайсы гына заводта көтеп алалар икән? — дип, шулай ук шаяртып җавап бирде Мортаза. — Гаеп эзләп йөрисез бит сез!

— Булмаганны түгел, булганны гына!

Алар, шулай чәнечкеле сүзләр әйтешеп, турникет канатлары арасыннан әйләнеп эчкә уздылар.

Илүсә үзен бик ихлас тотарга тырыша, гүяки Мортазаның озак килми торуына һич тә үпкәләмәгән, бер дә хәтере калмаган кебек иде. Завод эшләмәсә дә, табигатьне кайгыртучы оешмалар йоклап ятмый, менә тагын чираттагы тикшерү вакыты җиткән икән, ул шуңа килгән, имеш. Кәгазь-каләме дә, туфракны, цехлардан аккан суларны анализга алырга савыт-сабасы да үзе белән. Ул уң иңенә эленгән киң каешлы зур гына көрән сумкасын селеккәләп куйды — аннан пыяла чыңлаган тавыш ишетелде.

Киттеләр шулай, нәкъ элекке чактагы кебек икәүләп, киң ишегалды буйлап!

Канализация коесын каплаган түгәрәк чуен капкач янында туктагач, Илүсә ак йөзенә кырыслык галәмәтләре чыгарырга тырышты.

— Монда каян мазут җәелгән? — диде. — Нинди шакшы ага сезнең цехлардан?

— Кая шакшы?! Бу суда балык үрчетеп була! Карп маймычларын җибәрсәңме!..

— Карарбыз хәзер анда нинди маймыч йөзгәнен. Капкачын кем ача соң әле моның?

Гадәттә, ярдәмгә слесарьларның берәрсен чакыра торганнар иде дә, Мортазаның чит кешене китерәсе килмәде. Ул якындагы цехтан лом алып чыкты да авыр капкачны каерып ачты.

Илүсә сумкасыннан бауга асылган уенчык чиләк алды, аның авызын аска каратып баз эченә ташлады, астан шапылдаган тавыш ишетелде. Чиләкне тартып алгач, Илүсә нәфис борынын җыерды: судан керосин исе килә, өстендә яшелле-шәмәхәле булып май катламы йөзә, үзе язу карасы салгандай болганчык иде.

— Күрәсеңме? — диде ул, чиләкне Мортазаның битенә таба сузып. — Ә сез шуны шәһәр канализациясенә коясыз. Ә ул аннан елгага китә. Аннан кире водопроводка килеп керә.

— Керсә соң! Начар түгел ич!

— Шушымы начар түгел? Ә бәлки, моны эчәргә дә ярый, диярсең әле?

— Кая, эчеп күрсәтәм!

Мортаза чиләккә ябышты. Бу шаяру гына түгел, ул чынлап торып чиләктәге агулы сыекчаны эчәчәк иде. Бөтен дөньясына үч итеп! Өзелсен иде Илүсәнең үзәге!

Аның эчке бер алгысаудан алланган йөзендә, тетрәнеп торган борын канатларында, кысылган иреннәрендә, коңгырт күзләренең аңлашылмас ялтыравында хәтәр тәвәккәллек күреп, Илүсә куркып китте. Ул ике куллап чиләкне үзенә таба тартты:

— Син нәрсә? Шушында егылып җан бирмәкчеме әллә?

— Туган заводымның абруе дигәндә, җан да жәл түгел!

Илүсә чиләкне әйләндерде, майлы сыекча, чәчрәп, аның чалбар балакларын кап-кара таплар белән чуарлады.

— Тарткалашмаска иде, — диде Мортаза. — Хәзер нишлисең инде?

— Менә син нишләр идең, әгәр аны эчсәң? Күрәсеңме, ул нинди?

— Үзебезнең завод суы, үземнең авыз! Һәм мин аңа үзем хуҗа.

Мортаза, ике кулын спорт чалбарының кесәсенә тыгып, ияген чөеп басты, каршы цех бинасының бетон диварына текәлеп, теш арасыннан:

— Миңа нәнкә кирәкми, — диде.

Илүсәнең йөзенә чиксез гаҗәпләнү катыш хафалану бәреп чыкты. Бу ни дигән сүз? Монда ник килгәнеңне беләм, әмма юкка йөрисең, синең миңа кирәгең юк дигәнне аңлата түгелме?

Кыз моны шулай аңлады, һәм бу аның горурлыгына бик каты бәрде. Әйе, аның бирегә килүе эше буенча гына түгел. Дөресрәге, бөтенләй эш буенча түгел. Заводның табигатькә кылган хилафлыгын карап-күзәтеп торыр өчен башка оешмалар да бар: җирендәге чүп-чарга районның санэпидстанциясе бәйләнә, түккән суларына — «Водоканал»... Аннары инде тикшергән очракта да, тагын бер-ике кешене ияртеп, комиссия төзеп килергә тиеш иде ул.

Илүсәне алар түгел, башка гамьнәр алып килгән иде бирегә. Мортазаны күрәсе килгән иде аның. Соңгы вакытта күздән югалуының сәбәбен беләсе килгән иде. Бер сүз белән әйткәндә, сагынган иде ул аны! Һәм күңел түрендә егет тә аны сагынгандыр, тик берәр төрле борчу йә мәшәкать килеп чыкканга күрә генә килә алмый торгандыр дип уйлаган иде.

Баксаң, хикмәт бер дә тормыш матавыкларында түгел, ә егетнең үзендә икән. Элегрәк аның күңел бакчасы Илүсә өчен ачык иде. Ә хәзер ул гөлбакчаның капкалары ябылган, йозаклары бикләнгән. Ник? Нилектән? Нинди серле ачкычлар табарга ул йозакларга?

Турыдан-туры сорап та булмый, чөнки күңел йозакларының серле ачкычларын сүзләр белән генә эзләп табып булмый. Алар уртак хисләр аша гына табыла...

Бүген исә уртак кичерешләрнең юлына таш ишелеп төшкәндәй булган иде. Илүсә үзен шул үтеп булмаслык, күз җитмәслек таш өеменә килеп бәрелгәндәй хис итте.

Ләкин аның бирешәсе килми иде әле. Кимсенгән булып күренәсе килми иде. Ул чиләкнең нечкә бавын учына йомарлап тотты да яңадан коега таба борылды.

— Кем кемгә нәнкә әле монда? Син мине озатып йөрисең түгелме? — диде, мөмкин кадәр битараф тавыш белән. — Хәзер анализга суны яңадан алам да, коены ябып куярсың. Шуның белән эш бетә безнең.

— Ә нәрсәгә анализ? Комиссия белән килеп алырсыз!

Шулай диде дә Мортаза, чуен капкачны ярсу белән каты шакылдатып шудырып, кое авызын ябып та куйды. Илүсәнең иреннәре кысылып, ике битендәге уемнары тирәнәеп чыкты. Ул хәйран калып егеткә текәлде. Мортаза янә кулларын кесәсенә батырган, карашын бетон диварга төбәгән иде.

Илүсә бөтен сабырлыгын җыйды. Кызмаска, әрепләшү дәрәҗәсенә төшмәскә! Һәм үпкәләгәнеңне, рәнҗегәнеңне дә сиздермәскә. Ул тирән итеп сулыш алды да:

— Ярый алайса, комиссия җибәрербез, — диде.

— Җибәрегез, җибәр!

Әйе, комиссия ул сиңа бер Илүсә генә түгел! Аңа гадәттә бик чая апалар кергән була, һәм алар таләпне дә каты куя, штрафны да саллы чәпи. Комиссия минем өчен синнән яхшырак дигәнне аңлата иде түгелме Мортазаның сүзләре?! Ничектер җавап бирәсе иде моңа, әмма тамакка ачы төен утырган, тел көрмәкләнгән, авызны ачсаң, тавыш калтыранып чыгачак иде.

Илүсә, күзләренең дымланганын сиздермәс өчен, егеткә арка белән борылып, чиләген сумкасына тыкты, пыяла савытлар тонык кына чыңлап куйды.

— Сау булыгыз, — диде ул, борылып карамый гына.

— Хушыгыз...

Илүсә сумкасының киң каешын уң иңенә салды да, биек үкчәләре белән тек-тек басып, проходнойга таба китте. Ул Мортазаның карашын тоя, сынын туры тотарга, адымнарын тигез атларга тырыша иде. Һәм әйләнеп карамаска, түзәргә тырыша иде...

Мортаза, гомерлеккә хәтеренә сеңдереп калырга теләгәндәй, керфек тә какмыйча карап калды. «Үпкәләде, — дип уйлады ул. — Рәнҗеп китә... Ләкин башкача мөмкин дә түгел бит...»

Илүсәнең чәч каптырмасындагы елтыравык ташлар кояш нурында җемелдәп ала, юл читендәге өрәңгеләрнең күләгәсенә эләккәндә тоныкланып китә иде. Менә ул соңгы тапкыр елтырап алды да күздән югалды — Илүсә проходнойга кереп китте. Борылып карамады. Әгәр шунда тукталып борылып караса, Мортаза түзә алмас иде. Йөгереп барыр иде дә, каршына тезләнеп, кулларын үбеп гафу сорар иде...

Шулай итәр иде дә бит... Ә аннан соң? Аннан соң ни булыр иде? Газапларны сузу гына булыр иде бу... Барыбер ахыры аерылышу белән тәмамланырга тиеш бит. Шулай булгач, шушы минутта барысы берьюлы хәл ителү хәерлерәк түгелмени?

Шулай диде акыл. Ә йөрәк моның белән риза түгел, йөрәк сызланып бәргәләнә иде.

R R R

Аек акыл белән кайнар хисләрнең каршылыгы, бәхәсе бер Мортазаның гына күңелендә кайнаганмыни да, аның гына бәгырен көйдергәнмени? Аяусыз бәрелешләр кешеләр белән кешеләр арасында яки илләр белән илләр арасында гына була дип уйлаучылар бик нык ялгыша. Бик күп очракларда ут сызыгы безнең йөрәкләрне ярып уза.

Гашыйк булган, сөя белгән, кайнар канлы кешеләр моны кичерми калмыйдыр.

Мортазага кадәр күп еллар элек Виленны да газаплады бу көрәш.

Абзасы әйткәннәр аны бик нык уйга салган иде. Заһидәнең нурлы күзләрен, йомшак кулларын, назлы бөдрәләрен, аннан килгән татлы исне ерагайткан, томанга урагандай иткән иде алар.

Полковник яныннан чыккач, Вилен, ресторанга сугылып, ике кешелек өстәлгә заказ биреп чыкты. Аннары институтка китте. Эш сәгате тәмамланып килә иде, эчкә кермәде, ишектән чыккан халыкны читтәнрәк кенә күздән үткәреп торды.

Әнә күрше бүлектә эшләүче лаборантка Анфиса чыгып килә. Ачык сарыга буяган чәчләрен бүрек итеп күпертеп куйган, куе зәңгәр төстәге кыска итәгеннән кояшта янып өлгергән төз аяклары бөтен муллыгы белән күренә. Андыйлар турында «аягы колагыннан үсә» диләр. Терсәк турыннан киң балитәк тагылган кыска җиңле кофтасы да, озын баулы сумкасы да, без үкчәле туфлиләре дә күк йөзе төсле ачык зәңгәрсу — үз кадерен белеп, төз гәүдәсенең бөтен сылулыгын күрсәтеп киенә белә бу заман кызы. Виленны күрүгә, йөзенә елмаю җәелде, ашыкмыйча гына аңа таба атлады.

— Сәлам, Анфиса!

— Исәнме, Вилен! Мине көтәсеңме?

— Сине көтәм, әлбәттә! Кичкә нинди планнарың бар?

— Әллә берәр кая чакырасыңмы?

Анфисаның бик оста буялган-кершәнләнгән һәм шунлыктан чибәр тоелган бөркет борынлы озынча чыраеннан куаныч яктысы бөркелде.

— Әгәр минем чакыруны кабул итсәң, — диде тыйнак кыланып Вилен.

— Тәртибеңә карарбыз! — дип, уенны күтәреп алды Анфиса.

— Бүгеннән тәртипне отлично ясарга ант итәм. Честное пионерское! Җир йотсын!

— Синдәй егетне җирдән йоттырып тораммы соң! — дип култыклап алды аны Анфиса.

Алар шулай, элекке чактагы кебек чөкердәшеп, институт бинасының аргы башына, машиналар тезелгән мәйданчыкка таба юнәлделәр. Вилен үзенең ак «Волга»сын шунда куйган иде.

...Ресторан чит илләрдәгечә шәп итеп салынган кунакханәнең аскы катында булып, биредә яшьләрнең иң кәттәләре җыела иде. Ишектән кереп килүче Вилен белән Анфисаны күрүгә, ыспай кара костюм кигән метрдотель аларга каршы атлады:

— Хуш киләсез! Күптән күренгәнегез юк иде. Өстәлегез көтә! — дип, кулы белән кече залга ишарәләде ул.

Алар өстәл янына урнашуга, официантка килеп басты. Вилен, менюга карап та тормыйча, француз шампанские, «Столичный» аракы, салат, кыздырган ит һәм шоколад китерергә кушты.

Кече зал үзе шактый аулак булып, анда утыручылар артык күзгә ташланмый, аларга исә зур залдагы тәбәнәк сәхнә, андагы оркестр яхшы күренә иде. Әлегә сәхнәдә рояль, барабаннар, контрабас һәм микрофон гына тора иде. Ләкин озакламый анда фәкать шушы залда гына була торган тамаша башланачак иде. «Цветомузыка», ягъни «төсле музыка» дип атала иде ул һәм шәһәрдә бердәнбер иде.

Тамаша беренче тапкыр күрсәтелгән кичне ресторанга шәһәрнең элитасы, ягъни бик дәрәҗәле кешеләр генә керә алды. Алар арасында, билгеле, Вилен да бар иде, һәм ул үзе белән Анфисаны алып килгән иде. Гаҗәеп тәэсир калдырды ул кичә. Сәхнәгә дүрт музыкант — квартет: пианист, контрабас, ударник һәм

кларнетист урнаштылар. Микрофон каршына нәзек гәүдәле, озын чәчле егет чыгып басты. Түшәмдәге, диварлардагы утлар сүнде, өстәлләрдәге шәмнәр генә янып, бөтен зал үзенә бер серле, күләгәле яктылыкка күмелде. Оркестр уйнап җибәрде һәм... гәпләшүләр ярты сүздә өзелде, бар карашлар сәхнә ягына төбәлде. Анда, оркестр артындагы бөтен диварны иңләп-буйлап, гүяки салават күпере калыкты һәм ул, музыка тирбәлешенә буйсынып, җилпенә башлады. Ал, кызыл, зәңгәр, яшел, күк, шәмәхә төсләрдәге нурлы тасмалар дулкын булып боргалана, бер-берсен узыша, бәрелешә, чәчрәп сибелә һәм тагын тоташып куыша иде. Әйтерсең лә алар нәкъ менә музыка авазларыннан пәйда булалар һәм шуларның тибрәнешләрен кабатлыйлар иде.

Бу нурлы моң дөньясына җырчы егетнең бәрхет кебек йомшак тавышы килеп үрелде:

Яннарыңа киләм, кызыл гөлләр,
Язгы гөлләр тотып кулыма.
Сөюемә кушып, кызыл гөлләр,
Гөлләр сибәм барыр юлыңа...

Нурлар да, моңнар да, җырның сүзләре дә шушы мизгелләрнең, шушы кичәнең кадерен белергә, рәхәтен тоеп калырга өнди, алай гына түгел, йомшак тибрәлдереп үгетли иде.

Вилен белән Анфиса, сәхнә алдындагы мәйданчыкка чыгып, башка парлар белән бергә, сихри нурлар балкышында серле җыр көенә шактый биеделәр. Егетнең гамь-ваемнары онытылган, тирә-юнендә оҗмахтагыдай гүзәллекләр булдырылган, табынына иң затлы нигъмәтләр куелган, куенына хур кызыдай чибәркәй кереп сыенган иде — адәм баласына үзен бәхетле тояр өчен ни кирәк тагын?!

Һәм ул кичтә Вилен бу тылсымлы йогынтыга тулысынча бирелде. Кичәдән соң аның Яңа шәһәрдәге ялгызы гына яши торган фатирына икәү бергә кайттылар...

Шулай итеп, бу кич алар өчен икеләтә истәлекле булды. Беренчедән, нурлы музыканың шәһәрдә беренче тапкыр балкып яңгыравына шаһит булу, ә икенчесе, шул тамашаның тәэсиренә бирелеп, аны-моны уйлап тормыйча дигәндәй, иркәләнү-сөешү булды. Югыйсә әлегә хәтле мөнәсәбәтләр болай ук тирәнгә китәр дип уйланылмаган иде. Сәнгатьнең көченә, адәм балаларын ни рәвешле әвәрә итә алуына шаккатарсың, диярсең гена кала. Һәм кайчандыр, гасыр башында «төсле музыка» дигән хикмәтне уйлап чыгарган композитор Скрябинга, аның хыялларын тормышка ашырып, шушы ресторанда могҗиза ясап куйган галим егетләргә рәхмәт укырга... Ә бәлки... рәнҗергәдер... Хәер, моңа мөнәсәбәтен Вилен үзе өчен ачыкламаган һәм ул хакта уйлап башын катырмый да иде.

Шуннан соң алар бу ресторанга сирәк-мирәк килгәли торган булдылар. Бизәкле моңнарның дулкыны егетнең фәнни уйлanулардан талган башын сафландырып, гамьнәрен таратып җибәрә, чибәр кыз белән назланышу тәнгә көч өсти иде.

Бу юлы да онытылырга, үзен гөнаһлы җирдән аерылгандай хис итәргә теләде ул. Менә таныш квартет чыгып, музыка кораллары янына җайлап урнашты, ыспай егет микрофонны үзенә таба тартты, түшәмдәге, дивар буйларындагы утлар әкренләп сүрелде, сүнде, өстәлләрдәге шәмнәр генә янып калды... Көчле музыка башланды, оркестр артындагы диварда якты нур тасмалары, шарлары, шакмаклары биешергә, куышырга-узышырга тотынды.

Тик... нишләптер йөрәк җилкенмәде, бәгырьнең нечкә бер җире сыкранудан туктамады. «Төсле музыка» да, әкияти серлелеген югалтып, үзенә бер фокус булып тоелды. Вилен бу тамашаның ничек ясалганын таныш егетләрдән сорашып белгән иде инде, әллә шуңа микән? Серләр ачылгач, фокусларның кызыгы бетә шул инде ул. «Заһидәгә күрсәтсәң, шаккатыр иде, ә! — дигән уй килде аңа. — Бу ресторанга кергәне булды микән? Юктыр, мөгаен... Рестораннарга йөри торганга охшамаган... Сорарга да җай чыкмады... Иң беренче итеп шушында алып килергә кирәк... Ирекккә чыгуын бирегә бәйрәм итәргә...»

Кызның күзләре гаҗәпләнүдән, сокланудан ничек сабыйларча түгәрәкләнеп ачыласы аермачык булып күз алдына килеп басты. Вилен аның үтә беркатлы, әйтерсең лә бөтен җанын төбенәчә ача торган карашын күргәндәй булды. Авыл җирендә кайбер инешләр шундый була: саф су астындагы ком сырлары, вак балыклар, су төбендә уйнаган кояш тәңкәләре ялтырап күренеп тора...

Кинәт ул битенә салкын су бәргәндәй айнып китте: булмаячак аңа ул күзләргә карау, алар төбендә уйнаган якты нурлар алышынуын, уйнавын, биюен күрү. Заһидәне онытырга кирәк!

Ул, керфекләрен күтәреп, каршысындагы Анфисага карады. Кыз, сагаеп, күк күзләрен аңа төбәгән иде. Сораулы иде аның карашы, ялварулы иде. Бер мизгелгә Виленның күңелен кызгану хисе сызып узды. Анфиса белән аларның юллары вакытлыча гына кушылып алгандыр, мөгаен. Сагынмый ул бу кызны, юксынмый, кирәксенми хәтта. Җай туры килгәндә, иптәшкә ярап тора, фәкать шул гына. Тиң түгел алар, тиң түгел. Тиң булмау гашыйклар арасында калкып торган биек тау бит ул. Аның аркылы очып үтәр өчен

мәхәббәт канатларының, ай-һай, киң һәм көчле булуы кирәк! Анфиса исә Виленның күңеленә андый канатлар үстерә алмады...

Кыз үзе дә моны аңлый булса кирәк. Алар үзара мөнәсәбәтләр турында тирәнгә кереп сөйләшмиләр, очрашулар биргән татлы сәгатьләрне киләчәк турындагы уйлар ачысы белән агуламыйлар иде.

Анфиса, урындыгы аркасына элеп куйган зәңгәр сумкасыннан катыргы тартма чыгарып, озын, нәзек сигарет тартып алды. Нәни зажигалкасыннан челт итеп ялкын теле чыгарып, ут элдерде.

Официантка өстәлгә салатлар, шешәләр китереп куйды, чәнечке-пычакларны шудыргалады, аннары аракы шешәсен ак салфеткага урап тотты да кечкенә рюмкага салырга үрелде.

— Мин үзем! — дип туктатты аны Вилен. Һәм зур бокалга башта яртылаш аракы, аннары күбекләнеп торган шешәдән шампанский койды.

Анфиса аңа коты очып карады.

— Нишлисең син, Вилен?

— Эксперимент! — диде Вилен. — Химико-биологический! Химиклармы без, юкмы? Ә химик тәвәккәл булырга тиеш! Һәм батыр! Әйдәле, аю тотарлык кына!

— Аюы кайда соң анық?

— Ә каршыңдагысы? Мине тоту аю тотудан җиңелме әллә?

Анфиса бокалыннан бер генә йотым кабып куймакчы иде дә, Вилен үрелеп, аны беләгеннән тотып алды.

— Яле, яле, беренчесен төбенә кадәр! Әллә сагынмадыңмы мине?

Анфиса аңа каршы тора алмады...

— Ә хәзер, әйдә, биибез!

Вилен кызга ашарга ирек бирмичә, кулыннан тотып торгызды да, зур залга, оркестр каршындагы бию мәйданчыгына, башка парлар арасына әйдәде. Кызның таныш һәм бик тә күндәм тәне буйсына гына түгел, нинди хәрәкәт ясалачагын алдан ук сизеп-тоеп тора, шуңа әзерләнә һәм егет белән бер тән кебек атлый, бөтерелә иде. «Ә бәлки, абзый чыннан да хаклыдыр, — дип уйлады Вилен. — Хатыннарның кыяфәте төрле булса да, асыл җисеме бердер... Урыс әйтмешли, клин клином вышибают. Чөйне чөй белән бәреп чыгаралар. Бер кызны икенчесе белән алыштыру шулхәтле авыр эшмени?» Кайсыдыр китапта укыганы бар аның: бер адәм, гомер иткән хатынын талак кылып, яшь кызга өйләнмәкче булган. Алдан бер галим кеше белән киңәшергә ният кылган бу. Теге абзый аны көймәдә йөреп килергә чакырган. Елганың уртасына җиткәч, әйткән моңа: «Көймәнең уң ягыннан сузылып, кулыңны суга батыр. Ә хәзер сул якка сузылып, шулай ук кулыңны чылат. Аермасын сиздеңме?» — дигән. «Юк, — дип җавап биргән егет. — Шундый ук су». — «Хатын-кызның җисеме дә шундый ук, бертөсле, — дип аңлатып биргән тәҗрибәле акыл иясе. — Көймәнең сул ягындагы суны уң яктан акканы белән алыштырудан ни мәгънә табарсың икән?» Татарда да бит, берне аерып, башкага өйләнгән ир турында: «Шыр тиле икән, бер хатынны икенчегә алыштырган!» — дип сөйлиләр. Ә бәлки, Виленга да хисләрен тыярга кирәктер? Зәһидәне онытырга һәм Анфиса белән элекке мөнәсәбәтләрне дәвам итәргә... Ахыр чиктә, Зәһидә каршында бурычлы түгел бит ул... Мөнәсәбәтләрнең тирәнгә киткәне юк...

Ә нурлар биешә, моңнар чыңлый, яшь егетнең бәрхет тавышы аларга үрелеп җырлый:

> Бик сагындым сине, бәгърем, өзелеп сагындым,
> Сине уйлап мең кат яндым, мең кат кабындым.
> Сорыйм сине тулган айдан, сорыйм Чулпаннан:
> Сөйгәнем, дим, кайда? Нигә хәбәр юк аннан?

Шушы тылсым арасында алар икәү бер булып бөтерелә...

Менә җыр тынды һәм салават күпере сүнде, парлар үз өстәлләренә тарала башладылар. Вилен да Анфисаны җитәкләп кече залга таба алып китте.

Өстәл янына утыруга, тагын бокалларны тутырды, тагын кызны көчләп диярлек эчерде.

Анфиса тиз биреште. Күпмедер вакыт башын иеп утырганнан соң, тураеп, елмаеп, Виленга өздереп карады. Аның караңгыланып киткән күз төпләрендә учак кабынгандай булды. Ул учак ымсындыра, чакыра иде. Утка очкан күбәләкләрне үзенә тарта торган көч бар иде аларда. Вилен керфек тә какмый шул утка текәлде. Һәм ялкын астында, күз төбендәге күмерләрдә бер тыелгысыз теләкне — тәннең тәкатьсезлеген, тотнаксыз нәфеснең чагылышын күрде.

Шунда, Виленның күз алдын томалап, Зәһидәнең күз карашындагы балкыш чагылып узгандай булды. Нинди генә төсләр юк иде анда! Ихласлык, сафлык, ышаныч, өмет. «Төсле музыкадагы» кебек үк, салават күперенең бөтен төсләре ялтыра Зәһидәнең нурлы күзләрендә...

Анфисаның күзләрен исә гүяки кызыл томан сарган иде. Кинәт оркестр тагын уйнап җибәрде. Вилен сәхнәгә таба борылып карады — анда, оркестр артында да тоташ кызыл төс кенә болгана кебек күренде.

Ул учы белән маңгаен уып куйды. Кесәсеннән кыйммәтле портмонесын алды да, өч кызыл йөзлекне тартып чыгарып, өстәлгә ташлады.

— Нишлисең син, Вилен?

— Башта бер фикер туды әле. Хәзер үк кәгазьгә теркәп куярга кирәк... Сау булып тор бүгенгә.

— Бүгенгә? Ә иртәгә?

— Иртәгәнең киләсе бар бит әле...

Һәм ул биючеләр арасыннан бәргәләнеп, ашыгып ишеккә таба китте.

R R R

Бер нәрсә уйлый башласаң, гел шуны искә төшерә торган хәлләргә юлыгасың. Кичен Мортаза үзенең аклы-каралы «Рубин» телевизорын кабызган иде, тагын шәхес культы заманы турында тапшыру күрсәтә башладылар. КГБ системасының үзендә эшләгән бер адәм, бик тәмләп, тәфсилләп, СССР разведкасының эш ысуллары турында сөйләргә кереште. Ул чакта Советлар Союзыннан чит илләргә качып китүчеләр дә, тегеләр ягына күчкән разведчиклар да булган икән. Разведка шундыйларның кайберләрен юк итү өчен бик көчле, тиз тәэсир итүчән агулар кулланган икән. Әлбәттә инде, бу эш сиздермичә, мыштым гына эшләнергә тиеш булган. Әйтик, урамдагы берәүгә каршы килгән узгынчының зонтик очы төртелә. Очраклы хәл кебек бу. Ләкин, шуннан соң озак та үтми, бу адәм егыла да җан тәслим кыла. Теге узгынчының зонтик очы агулы булган икән...

Телевизордан сөйләүче әкренләп андый агуларның кемнәр тарафыннан, ничек ясалганына күчте. Мортаза, шаккатып, керфекләрен тибрәндерергә куркып, экранга текәлде.

— Бу өлкәдә эшләүче шундый бер профессор бар иде, — дип сөйләп китте экрандагы кеше. — Карап торуга бер бөрешкән карт кебек кенә үзе. Әмма үз өлкәсендә бик зур галим иде. Иң куркыныч еланнарның агуларыннан да зәһәррәк матдәләрне шул ясады. Сынауларны да үзе үткәрә иде. Минем үземнең шундый очракка туры килгәнем булды. Төрмә камерасыннан бер мәхбүсне китерделәр. Профессор, бик ягымлы, үз итеп, аның хәл-әхвәлен сорашырга кереште. «Якынрак килегез әле, сөеклем, — диде. — Тыңлап карыйк. Пульсыгызны да үлчик. Әйбәт, әйбәт». Аннары: «Алай да сезгә бераз дәваланмыйча булмас, — дип, нәтиҗә чыгарып куйды. — Кайбер шикләр бар. Зурга киткәнче, чарасын күрергә кирәк. Хәзер без сезгә бер укол ясап алырбыз. Аннан соң карарбыз», — дип, үзалдына сөйләнеп, укол энәсен мәхбүснең аркасына кадап та алды. Унбиш-егерме минут үттеме-юкмы, әле генә ярыйсы таза күренгән ир кеше күз алдында бөрешә башлады. Чырае күгәреп чыкты, сулышы кысылды һәм гөрс итеп идәнгә егылды...»

Мортаза сикереп торды да телевизорның төймәсенә басты. Тонган экранны утлы кылыч белән ягандай, аркылы сызык пәйда булды — ул сүнәр алдыннан шулай кылана иде. Әмма хәзер бу күренеш шомлы бер мәгънәгә ия булып күренде.

Егет ашыгып аягына кроссовкаларын киде дә урамга чыкты.

Почмактагы киоскының киштәләрендә аракының төрлесе тезелеп тора иде, акчасы иң арзанлы вермутка гына җитте. Кире кереп, болганчык кызыл сыекчаны чәй кружкасына тутырып салды, җирәнүен басып, авызына койды. Бераздан башны, шул сыекчаның үзе кебек, болганчык томан баскандай булды, әмма минең бер ноктасы аек калды.

Моңа кадәр ул теге чакта әнисенә кадаган уколның агу булуына бик үк ышанып бетмәгән иде. Ләкин булган икән бит андый хәлләр, чыннан да булган икән!

Төн ничектер бәргәләнеп, саташып узды. Иртәгәсен заводка килүгә, лабораториягә юнәлде ул. Химиклар химикларны белми калмас. Аңа Вилен Канчуровны табарга кирәк иде.

Лабораториядә институтларны төрле елларда тәмамлаган белгечләр эшли. Күпчелеге хатын-кызлар, арада шактый өлкәннәр дә бар. «Курсташларыгыз арасында Канчуров юк идеме?» — дип сораштыра торгач, бер очы чыга башлагандай күренде. Андый егетне белгән-ишеткән табылмады, ә менә моннан егерме еллар элек фәнни-тикшеренү институтында эшләгән берәүне искә төшерделәр. Икенче көнне Мортазага телефонын да китереп бирделәр. Яңа шәһәрдә яши икән, Анфиса Дмитриевна исемле.

Телефоннан: «Алло! Тыңлыйм!» — дип, карлыккан тавыш җавап бирде. Мортаза башта әллә ир кешеме дип тә уйлаган иде. «Әйе, мин ул Анфиса Дмитриевна», — дигәч, эшнең нидә икәнлеге аңлашылды. Мәскәүдәге танылган артисткаларның да шактые шушындый, тәмәкене күп пошкырту нәтиҗәсендә «утырган» тавыш белән сөйләшә.

Ул Мортазаның кем икәнен, нинди максат белән очрашырга теләгәнен аңламый аптырап бетте. «Мин ул институттан күптән киттем инде... Андагылар белән элемтәм югалды... Канчуровның үзенә мөрәҗәгать

итәргә кирәк сезгә...» — дип, кат-кат кабатлады, шул ук вакытта ни сәбәптәндер телефон трубкасын куярга да ашыкмады. Мортаза аны ризалатып булачагын аңлады. «Беләсезме, бу бик мөһим мәсьәлә, — диде ул. — Канчуровка һәм минем әнигә кагылышы булган...» — «Әниегезгә?.. — Апаның тавышы тәмам пышылдауга күчте. — Сезгә ничә яшь соң?» — «Егерме җиде тулды». — «Алайса... сез бүген сәгать җидедә килә аласызмы? Безнең фатирның коды 735».

Нәкъ билгеләнгән вакытта Мортаза Яңа шәһәрнең үзәгендә, зур парк янында урнашкан алты катлы йортның домофонлы тимер ишеге төбендә басып тора иде инде. Әйтелгән саннарны басуга, домофоннан таныш калын тавыш: «Керегез!» — диде.

Фатирның имәннән сырлап ясалган ишеге башкалардан аерылып тора иде. Май чүлмәгенең тышыннан билгеле, диләр, өйнең эче дә затлы җиһазланган булып чыкты. Иркен, алгы бүлмәнең диварларында ук үрмәле гөлләрнең сабаклары салынган, ә эчке якта өстәл уртасындагы зур гына бәллүр вазага озын сабаклы гладиолуслар утыртылган иде.

Ләкин барыннан да бигрәк хуҗабикә үзе сокландырды. Ул зур-зур тавис кошлар чигелгән, озын зәңгәр атлас халат кигән, салам төсле чәчләрен биек итеп баш түбәсенә өеп куйган. Күз тирәләре, керфекләре нык буялган, иреннәре кызартылган, битенә мул итеп кершән ягылган. Фәкать салынып торган йомшак ияге генә олы кеше икәнлеген күрсәтеп тора иде.

Ул чигүле чүәге белән Мортазага таба йомшак башмаклар шудырды.

— Салыгыз кроссовкаларыгызны.

Аннары бүлмәгә чакырды. Иркен бүлмә курчак өе кебек җыештырылган, бар нәрсә әле генә кибеттән кайтартылган кебек өр-яңа, керсез. Һәммәсе бар, тик җылылык, ямь җитми, почмаклардан күңелне изә торган сагыш саркый кебек иде.

— Рәхим итегез. Сезгә кайда уңайлырак: дивандамы, кәнәфидәме? — дип сорады Анфиса.

— Миңа урындык уңайлырак.

— Кофе эчәсезме?

— Юк, рәхмәт.

Анфиса түгәрәк өстәлнең түр ягына, тәрәзәгә арка белән утырды да, «Ментоловые» дип язылган пачкадан бер сигарет алып авызына капты, аны нәни ялтыравык зажигалка белән кабызды һәм пачканы Мортазага таба шудырды.

— Тартасызмы?

— Рәхмәт.

Мортаза хуш исле сигаретны алды, ашыкмый гына кабызды. Ни генә димә, бергәләп тәмәке төтәтеп җибәрсәң, аралар җылынып киткәндәй була. Анфиса чәчәкле ваза артына посыбрак утырган да кунакны бик җентекләп күзәтә иде шикелле. Менә ул тирән итеп көрсенде, нык итеп тәмәкесен суырды һәм төтенен түшәмгә өрде.

— Димәк, сез Канчуров түгел, — диде аннары. Аның тавышында ниндидер җиңеләю, хәтта сөенеч чагылып узгандай булды.

— Асанин мин, — диде Мортаза. — Сезгә бер соравым бар иде. Әниемнең язмышына кагылышлы. Аны студент чагында кулга алган булганнар...

— Гафу итегез, нәрсә өчен?

— Сәяси эштә гаепләп... Төрмәдә аңа ниндидер укол кадаганнар... Һәм ул авырган. Нәкъ шул чакта әни янына Вилен Канчуров дигән кеше килеп йөргән...

— Бу хәлләр алтмыш тугызынчы елның җәй башында булганмы?

Анфиса моны сораган кебек түгел, раслаган шикелле әйтте. Ул урыныннан торды да, тәрәзә янына барып, ишегалдына карагандай итте. Йөзендә чагылган кичерешләрне кунак егеткә күрсәтәсе килми иде аның.

— Әйе, алтмыш тугызынчы елны, — диде Мортаза.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Почмакта биегәеп утырган алтын телле зур сәгатьнең текелдәве генә ишетелеп торды.

Бераздан Анфиса үзен кулга алды, күрәсең, борылып:

— Шулайдыр дип уйлаган идем... — диде.

Ул кире урынына утырды. Һәм янә ваза артына посыбрак:

— Сез соң миннән ни телисез? — дип сорады.

— Миңа шул уколның нинди икәнлеген белергә кирәк.

— Гафу итегез, әниегезнең исәнлеге ничек?

— Ул юк инде. Күптәннән...

— Менә ничек... Теге чакта исән калган, ә соңыннан...

— Төрмә табибәсе әйтүенчә, аны Вилен Канчуров коткарып калган. Даруын ул табып китергән.

— Ах, менә ничек... Аңлашыла...

Анфиса, тагын да ныграк дулкынланып, тәрәзә яныннан урап килде.

— Даруын Канчуров алып килгән, димәк, агуның да ниндилеген белгән, — диде Мортаза. — Ә ул сезнең институтта эшли торган булган...

— Әйе, институт бер дип санала иде шул...

Анфиса, нәрсәгәдер тәвәккәлләгән шикелле, вазаны читкәрәк шудырып, Мортазага текәлеп карады.

— Әлбәттә, сезнең бу хакта белергә тулы хакыгыз бар, — диде. — Әйе, без Вилен Канчуров белән бер институтта эшләдек. Шактый якын... дуслар да идек... шикелле... Ләкин институт тыштан караганда гына тербөтен иде. Асылда анда бер-берсенә мөнәсәбәте булмаган ике фәнни оешма яшәп килде. Хөкүмәт өчен иң мөһиме булып профессор Федор Кузьмич Рассекаев җитәкчелегендәге беренче бүлек саналды. Ул бүлеккә теләсә кемне алмыйлар иде, шуны белеп торыгыз! Галимнәрнең дә каймагы җыелган иде анда!

— Алар... нинди тикшеренүләр алып барды соң?

— Ә сез моны андагылардан гайре кем дә булса белгәндер дип уйлыйсызмы әллә? Эх, энекәш! Дәүләт серенең ни икәнен аңламый түгелсездер!

— Ә шулай да...

— «Шулай да» дигәненә килсәк һәм моның сезгә турыдан-туры кагылышы булганын исәпкә алсак, мин фәкать шуны гына әйтә алам: беренче бүлек, КГБ белән нык бәйләнешле булып, аларның заказын үти иде. Беренче чиратта — разведка заказын... Ә разведкага нәрсә кирәк?

Мортазаның күз алдыннан алдагы кичне телевизордан күргән тапшыру чагылып үткәндәй булды. Теге агу сынаган галим Рассекаев түгел идеме икән?

— Бик көчле агулардыр, бәлки... — дип җавап бирде ул Анфисаның соравына.

— Без дә менә шундый фаразлар белән тукланып яшәдек. Шунлыктан әниегезнең ул чакта исән калуы үзе бер могҗиза. Һәм бу могҗизаны талантлы галим Канчуров ясаган, дияргә генә кала. Гений иде шул ул! Үз өлкәсендә юл ярып баручылардан иде.

Мортаза исә үзенекен уйлап утыра иде.

— Нинди ерткычлык, — диде ул үзалдына. — Моның өчен аларны... хөкем итәргә кирәк иде.

Анфиса, янә урыныннан торып, бүлмә буйлап әрле-бирле йөренә башлады.

— Нәрсә өчен хөкем итәргә? Яңа ачыш ясаган өченме? Алар ясаган препарат — ул фәкать химик яисә фармакологик бер матдә генә. Хикмәт аның кем кулына эләгүендә һәм ничек, нинди максатларда кулланылуында. Фәнни ачышлар — шул ук үткен балта кебек. Була аны яхшыга файдаланып, була яманга. Дөньяда иң дәһшәтле водород бомбасын кем уйлап чыгарган? Академик Сахаров. Аның бомбасын Яңа Җир дигән атауда сынап карар алдыннан галимнәр шактый шиккә төшкәннәр. Чөнки Җир шары урталай ярылмагае дигән куркыныч туган. Аны сынаганда беләсезме күпме кеше нурланыш алган? Ләкин Сахаровны берәү дә ерткыч дип күз алдына китерми. Киресенчә. Кеше хокукларын яклаучы буларак Нобель премиясе алган даһи ул. Ә соң Нобель үзе? Аның да иң зур ачышы — динамит бит. Бик катлаулы мәсьәлә бу.

Анфиса боларны Мортазадан бигрәк үз-үзен ышандыру өчен сөйли иде шикелле. Бу хакта ул, мөгаен, күп уйланган иде. Вилен Канчуровны аклыйсы килә иде аның һәм моның өчен тулы бер фәлсәфә булдырган иде. Әмма болай фикерләү аның үзенә үк какшау тоела, ышанычын ныгыту өчен аңа теләктәшләр кирәк иде.

Мортаза, хуш исле булса да, тәмсез тоелган сигаретны сирәк кенә суыргалап, дәшми утыруында булды. «Гаделсезлекләрне, җинаятьчеләрне аклар өчен нинди генә фәлсәфәләр кормый кайберәүләр! — дип уйлады ул ачынып. — Ә безгә, әнием белән миңа, нинди урын бирелә инде бу фәлсәфәдә? Тәҗрибә ясар өчен, экспериментлар үткәрү өчен генә кирәкле җан ияләре белән рәттәнме?»

— Сезнеңчә, иң талантлы галимнәр фәнни юлларын иблискә хезмәт итүдән башлый булып чыга түгелме? — дип сорады Мортаза. — Фәнни ачыш ясыйм дип, минем әниемне агуларга ни хакы булган аның? Ничек сез шуны аклый аласыз? Гафу итегез, ә сез үзегез?

— Мин үзем? Сез мин эшләгән өлкә белән кызыксынасызмы? Миңа Ходай зур талант бирмәгән, кызганычка каршы. Мин ул чакта гади лаборант идем. Аннары аспирантурада укыдым, кандидатлык диссертациясе якладым. Без прикладной эшләр белән шөгыльләндек. Мисалга, янгын сүндерүчеләр өчен ут капмый торган киемнәр ясадык. Безнең костюмнар бик югары температураларга ифрат чыдам. Эссене үткәрмиләр. Дөньяда иң яхшылардан, диләр...

— Котлыйм, — диде Мортаза һәм төпчеген бәллүр көл савытына нык итеп басып сүндерде. — Мин сездән тагын бер нәрсә хакында сорар идем...

— Әгәр җавап бирә алсам...

— Беренче бүлектә ясалган матдәләр, алар кеше тәнендә күпме вакыт саклана икән? Һәм ни дәрәҗәдә?

— О-о, анысын беркем дә әйтә алмый! Бу өлкәдә эш башланмаган дияргә була... Шул беренче бүлектәге бер лаборант кыз ялгыш кул аркасына иприт тамызган булган. Иприт бит ул әллә кайчаннан мәгълүм матдә. Һәм ул чакта ук бик гади кебек тоела иде. Лабораториядә һәммәсе кул астында бит инде, шундук дезинфекция ясаганнар, барлык тиешле чараларны күргәннәр. Җәрәхәт барлыкка килгән булса да, дәвалый торгач төзәлгән. Әмма...

Анфиса Мортазага текәлеп тынып калды. Егетнең эчен шомлану хисе баскандай булды.

— Шуннан? Нәрсә?

— Бер елдан ул кыз тапты. Кызының кулында, нәкъ шул урында, кап-кара миңе бар иде. Гомере буе күзәтү астында тора... Андый-мондый хәл килеп чыкмагае дип куркалар...

Мортаза урыныннан торып басты.

— Вилен Канчуровның үзен берәр ничек табып булмас микән? — дип сорады ул.

— Германиядә яши бит ул! Шул чакта ук чит илләргә чыгу турында хыяллана иде. Чикләр ачылу белән китте дә барды. Гаиләсе белән бергә китте. Бирегә кайтса да сирәк кайтадыр. Һәрхәлдә, соңгы елларда ишетелгәне юк. Бик кыйммәтле препарат уйлап чыгарган бит ул. Бәлки, ишеткәнсездер дә. Ике төрле вариантта чыгарыла. Ирләр һәм хатын-кызлар өчен. «Вика-ян» һәм «Вика-инь» дип атала. Кирәксенгән танышларыгыз булса, тәкъдим итә аласыз. Бик яхшы, диләр. Бөтен дөньяда тарала. Бездә аның белән махсус фирма шөгыльләнә. Хәзерге вакытта, үзегез беләсез, дарулар белән сәүдә итү иң табышлы эш бит ул. Бигрәк тә безнең илдә. Күпме агу эшләп чыгарылды, күпме атом бомбалары сыналды. Берсе дә эзсез үтми, һәммәсе күпләргә тәэсир итә... Ходай сезне андый җирләрдән ерак йөртә күрсен берүк... — Анфиса тирән итеп көрсенеп куйды. — Талантлы, көчле кеше беркайчан да, беркайда да югалып калмый шул, — диде. — Бездәге «Вика» фирмасының да эшләре гөрләп бара, диләр. Әгәр теләсәгез, Канчуровлар турында шуннан белешеп була. Фирманың җитәкчесе Канчуров бит.

Мортаза дерт итеп сискәнеп куйды. Анфиса моны сизмәде, тәмәке төтенен өскә өреп, карашын шуңа төбәгән иде.

— Марат Канчуров, — дип дәвам итте аннары. — Вилен Канчуровның улы. Аның офисы, беләсезме кайда?

Һәм Анфиса Иске шәһәрнең үзәктәге аулак бер тыкрыгын атады.

— Телефоннарын белмисезме?— дип сорады Мортаза.

— Юк шул... Минем аларга эшем төшкәне юк. Аны белешү кыен түгел бит. Мәгълүм фирма.

Мортаза, рәхмәт әйтеп, урыныннан кузгалды.

Ишек төбендә Анфиса, ничектер эчке бер тетрәнүдән сынып киткән тавыш белән:

— Ә беләсезме, сезнең әниегез бик бәхетле булган, — диде. — Иртә китүе кызганыч, әлбәттә. Әмма Ходай биргән гомере эчендә бәхетнең зурысын татыган кеше ул...

— Сез минем әнине белә идегезме әллә? — дип, хәйран калып сорады Мортаза.

— Күзгә-күз очрашкан булмады, әмма... без — хатын-кызлар бит! — дип, җөмләсен икеле-микеле тәмамлап куйды Анфиса.

— Сез аның башыннан ниләр узганын күз алдына да китермисез!

Анфиса башын иеп серле көлемсерәде. Аннары, гадәтенчә үзалдына уйлангандай:

— Адәм баласы, бигрәк тә хатын-кыз, дөньяга нәрсә өчен килә дип уйлыйсыз? — диде. — Бу җирдә иң төп вазифасы нинди аның? — Ул башын күтәрде дә сөрмә тартылган керфекләре арасыннан күк күзләре белән Мортазага текәлеп карады. — Сөяр-сөелер өчен һәм... баласын назлап иркәләр өчен килә ул җиһанга. Ә сезнең әниегез боларның барысын да татыды, тиешле вазифасын үтәде. Сөйде-сөелде. Сөйгәне — егет солтаны иде. Андый тагын кем бар икән?! Бала тапкан синең әниең, чибәр, көчле ул үстергән. Хатын-кыз өчен бәхетнең зурысы менә шул инде...

Анфиса шунда сүзен өзде дә:

— Сау булыгыз, уңышлар телим, — дип, фатирындагы сагышлы ялгызлык кочагына кереп бикләнде.

Ә Мортаза тагын табышмак алдында калды. Анфиса әйткәннәрнең чын мәгънәсенә төшенү җиңел түгел иде, әмма бер нәрсә бик яхшы аңлашылды: бу чибәр апа аның әнисеннән көнләшкән һәм бу хис әлегә хәтле сүрелмәгән иде...

R R R

Заманында Заһидә, бөтенләй уйламыйча-белмичә, Анфисаның бәхетен җимерде — Вилен исемле егет солтанының йөрәк түреннән аны чигендереп, мәхәббәт тәхетенә үзе менеп утырды. Дөрес, моның өчен ул

бик кыйбат түләде. Әмма чын гашыйклар хак белән санашамыни? Анфиса да бәясеннән тормаган булыр иде, әмма аңа түләү мөмкинлеге бирелмәде.

Хатын-кызның йөрәге сизгер, теге чакта Виленның ни сәбәпле рестораннан кинәт чыгып киткәнен аңлады ул. «Башына килгән фикерен язып кую» сылтау гына иде, онытмаска дигәнеңне өстәлдәге салфеткага да сызгалап куярга була. Хикмәт бөтенләй бүтәндә — егетнең башка берәүне юксынуында, сагынуында иде.

Анфиса Виленны шактый ук җилбәзәккә саный иде, шуңа күрә, күңеле нык рәнҗесә дә, үткәреп җибәрергә тырышты. Сабыр итте, көтте. Егеткәй кире әйләнеп кайтыр дип өмет итте.

Әмма өметләр акланмады. Дөрес, алар институт ишеге төбендә кайчакта кара-каршы килгәлиләр иде, әмма Вилен туктамый гына сәлам биреп узып китә торган булды. Кайсы гына кызның йөрәге моңа түзәр икән?

Ләкин чыдамый кая барасың? Анфиса таныш-белешләр аркылы егетнең күңеленә кем кереп урнашканын белергә тырышты. Бераздан, колактан-колакка йөри торгач, аңа күңелсез хәбәр килеп ирешә. Вилен түзә алмаган, эч серләрен кайсыдыр бер дустына чишкән — төрмәгә эксперимент үткәрергә баргач, ялгышлык белән кулга алынган Заһидә исемле студентка белән очрашуы, аңа үлеп гашыйк булуы турында сөйләгән икән. Бу хакта ишеткәч, Анфисаның күңелен көнләшү тойгысы биләп алды. Ах, шул мәхбүс кыз урынында булсаң икән дигән уй башыннан китмәде.

Ләкин әгәр чыннан да ул, Заһидә язмышына дучар булып, караңгы, салкын таш тартмага ябылса, үз хәлен онытып, сөйгәне өчен генә сызланыр идеме икән?..

Бәхет булыр идеме бу аның өчен, әллә ачы фаҗигаме?..

...Ә менә Заһидә үзе турында уйламады, фәкать Вилен өчен генә янды-көйде. Ник килми ул? Ни булган?.. Ачыгыз ишекне! Бер генә сорауга җавап бирегез! Сөйгәнем хакында бер авыз сүз генә әйтегез!.. Кайда ул? Ни хәлдә?

...Аның бертуктаусыз тикшерүче белән очрашуны таләп итүен, чамасыз бәргәләнеп, камерадашларының да күңелен ургытып торуын төрмә җитәкчеләре Сидоровка һәрдаим ирештереп тордылар, билгеле. Әмма Антон Никитич аны чакырырга кушмады, чөнки үзе аптырашта иде. Сабый күңелле, шунлыктан дөньяның рәтен белмәгән бу беркатлы бала белән бик җитди сөйләшергә, алай гына түгел, карашларын үзгәртергә кирәк иде. Ләкин чамасыз гасабиланган, чыгырдан чыккан кеше белән җитди мәсьәләләр турында фикер алышып буламыни?!

Кадермәтованың надзирательгә һөҗүм итүе һәм шуның өчен биш тәүлеккә карцерга утыртылуы турында белгәч, Сидоров тынычланып киткәндәй булды. Анда беренче эләккән кеше үзгәрми калмый. Бу чәчби дә бераз дөньяның рәтенә төшенер, телен тыярга кирәклеген, ниһаять, аңлар. Аннан шул гына таләп ителә дә бит инде: яшьләр арасында кирәкмәгән сүз таратып йөрерлек булмасын. Чөнки андый сүзләр бик куркыныч нәрсә бит ул — эссе җәйдә урман торфына капкан ут кебек. Янган торфны сүндереп тә буладыр, ә менә утлы сүзнең көйгән эзе беркайчан бетми, юкка чыкмый. Иминлек саклау системасын мондый уттан саклау өчен бөтен чаралар яхшы!

Чәүчәләк кызга биш тәүлек карцерда утыру җитәр, ул аннан кындәмләнеп, ихтыяры сынып чыгар. Шуннан соң аның белән ашыкмыйча, иплэп кенә сөйләшергә мөмкин булыр. Бар белгән-ишеткәнеңне бөтен дөньяга сибеп йөрергә ярамаганын яхшылап аңлатырга. Алай гына түгел, гомер онытмаслык итеп, кызган тимер белән бәгыренә уеп куйгандай итәргә! Шуннан соң, монда булганымны, бирелгә сөйләшкәннәрне сер итеп саклаячакмын, дип, имзасын аласың да, дүрт ягың кыйбла, кызыкай! Аның ише максималистлар дөреслек артыннан куалар, әмма биргән вәгъдәләрен беркайчан да бозмыйлар. Институтына, «Студентыгыз сессия вакытында бездә булды, әмма аның гаебе юк, имтиханнарын көз көне тапшырырга рөхсәт итүегезне үтенәбез» дип, язу да юлларга кирәк булыр. Укысын! Кеше булсын!

Шушындый катгый бер карарга килгәннән соң, Сидоров Кадермәтованың «Дело»сын өстәл тартмасының эченәрәк шудырган иде, бармаклары шытырдавык пакетка төртелде. Кадермәтовага дигән күчтәнәч һаман шунда ята икән әле. Хәер, шулай булмый соң: тәртип бозган мәхбүскә күчтәнәч ташыйлар димени? Җитмәсә, шампанский да кушып! Ходай язмаганны!

«Кече Канчуров әйләнеп килә күрмәсен тагын, — дип уйлап куйды тикшерүче. — Бөтенесен бозып ыргытачак!»

R R R

Антон Никитичның күңеле дөрес сизде: Вилен һич тә тынмаган, ул нишләргә белми бәргәләнә иде.

Сабыр төбе сары алтын, дип кем әйткән анда? Бу мәкальне уйлап чыгарган кеше таш күңелле булгандыр, сөя белмәгәндер! Мәхәббәт утында дөрләп янган йөрәк күпме түзә ала?

Түзмәде түгел Вилен, түзде. Биш көн буе томан эчендәгедәй йөрде. Көннәрен миңгерәгән хәлдә лабораториядә айкалды, кичләрен ялгыз фатирында телевизор карап утырды. Һәм, беркайчан булмаганча, ялгызы гына эчте. Тартты.

Вакыт узган саен йөрәкнең янулары әкренләп кимергә, сызлануы басылырга тиеш иде. Ә ул торган саен ныграк әрнеде. Күңел Заһидә янына ашкынудан туктамады.

Бу — аны күрәсе килү, кочакка алып назлау-назлану, аның җырга тиң сөйләгәнен ишетү теләге генә түгел, бу — аның өчен борчылып яну иде. Хәлләре ничек икән? Зарыгып көтә микән? Үпкәләде микән, әрнеп елый микән?

Кызган башка торган саен куркынычрак уйлар килә иде. Ә бәлки, препаратның тәэсире соңрак килеп чыккандыр да, Заһидә чирләп киткәндер? Табиблар аны ничек дәваларга белмидер? Препаратка каршы дару да юк бит аларда! Ә сорарга куркалардыр. Дәүләт серенә бәйле әйбер бит ул... Ә бәлки, ул үлгәндер дә инде?! Абзасы бу хакта белгәнгә күрә, Виленны анда барудан тыймадымы икән?

Нишләргә? Полковникка барып булмый, бердәнбер өмет профессорда иде...

Вилен таң атканын көч-хәл белән көтеп алды. Профессор, эшкә килгәндә ишек төбендә шәкертен күргәч, гаҗәпләнеп куйды: егеткәйнең соңга кала торган гадәте бар, Рассекаев үзе исә һәрвакыт ярты сәгать алдан килә торган иде. Аннан да бигрәк, профессорны күрүгә, Виленның төсе үзгәреп китүе күзгә бәрелде...

— Хәерле иртә, Федор Кузьмич!

— Исәнмесез, Вилен Шаяхметович, саумысез! Иртәләгәнсез бүген! Төшегездә берәр ачыш ясап, «Эврика!» дип уяндыгызмы әллә?

— Профессор, минем сезгә бик ашыгыч үтенечем бар иде.

— Тыңлыйм, коллега.

— Хәтерләсәгез, соңгы эксперимент вакытында берьюлы ике препарат сыналды. Бүген нәкъ ун көн. Мин сездән ул авыруга күз салуыгызны теләр идем.

— Әйе, шактый кызыклы очрак...— диде профессор уйланып. — Андагы табибларның күзәтүе генә сезне канәгатьләндермиме?

Вилен гасабиланып көлеп куйды.

— Федор Кузьмич! Сез безне шулай өйрәттегез бит: үз күзеңә һәм үз кулыңа гына ышанырга кирәк! Аннары, минем өчен сезнең караш, сезнең фикер бик мөһим! Бу бит... уникаль очрак!

Егет моны шулхәтле хисләнеп, ялвару һәм таләпчәнлек белән әйтте ки, профессорның йөрәге тибрәлми кала алмады.

Шәкертенең мәхбүс кыз белән үзара мөнәсәбәтләреннән бихәбәр булганлыктан, Рассекаев Виленның бу хәтле өзгәләнүен фәнгә бирелгәнлек, чын иҗат кешесенә илһам килгәндә генә була торган рухлану билгесе дип кабул итте. Моны хупларга гына кирәк иде, әлбәттә.

Дөрес, аның хәтерендә полковник Канчуров белән булган соңгы очрашу чагылып узды узуын. Ләкин КГБның фән әһелләренең башына басып йөрүенә дә бер чама булырга тиештер ләбаса!

Кыскасы, профессор полковникны чеметеп алырга каршы түгел иде. Һәм ул тәвәккәлләде:

— Сез кайчан бармакчы соң анда?

Куанычтан Виленның йөзе алланып чыкты.

— Хәзер үк мөмкинме, профессор?

Федор Кузьмич сәгатенә карап алды.

— Хәзер дисезме? Тугызга кадәр булса гына. Аннары барасы җирем бар...

— Өлгерәбез, профессор, өлгерәбез. Сезнең бер күз салуыгыз җитә...

— Ярый, хәзер шылтыратып әйтик тә, кузгалырбыз.

Профессорга даими пропуск бирелгән, ул үзе белән бер-ике коллегасын да алып бара ала, тик кайчан, кая барасын һәм үзе белән ничә кеше буласын алдан хәбәр итәргә тиеш иде. Ул бүлмәсенә телефоннан шылтыратырга юнәлде.

...Тикшерү идарәсеннән профессор киләсен әйтеп шылтыраткач, Сидоровның мие түнеп китте. Кадермәтова карцерда утыра лабаса! Кешегә күрсәтерлеге калган микән?!

Ә бәлки, аны карцерга ябу хата булгандыр? Секретный бүлекнең тикшеренүләренә зыян салуда гаепләмәгәйләре тагын...

Ул ашыгып телефон трубкасына ябышты. Тиз арада мәхбүсне карцердан чыгарсыннар, адәм рәтенә кертсеннәр. «Мунча керт! — дип кычкырды ул, сулышына кабып, надзиратель хатынга. — Матри, исле сабын белән юындыр! Аның анда хушбуе бар иде, сипсен! Ярты сәгатьтән кызарып пешкән алма кебек, минем каршымда басып торсын! Комиссия килде монда! Су эчертергә онытма! Капкалап та алсын бераз!»

Озак та үтмәде, аскы ишектәге постовой профессор Рассекаев белән аның ярдәмчесе Канчуров килгәнлеген хәбәр итте. Канчуров? Шул гына җитмәгән иде!

Чакырылмаган кунакларны каршы алганда, Сидоров нишләргә белмәде. Урындыкларны әле тегендә, әле монда күчереп маташты, өстәлен сыпыргалады.

— Киләсегезне әле генә хәбәр иттеләр. Кадерматова мунчага кергән икән. Хәзер китереп җиткерерләр... Әз генә сабыр итик инде...

Вакыт уздыру өчен нидер сөйләшергә кирәк иде. Ләкин уртак сүз табылмады, гәп ялганмады. «Мондый җирдә эшләүчеләр шушындый буладыр инде, — дип уйлады Вилен, тикшерүченең сирәгәйгән көлсу чәчен, озын-озын буразналар сузылып төшкән карасу какча яңакларын, тәмәкедән күгәреп беткән сирәк тешләрен, таушалган, килешсез, арзанлы пинжәген күздән кичереп. — Урамда булса, моны теләсә кем тибеп китә ала югыйсә. Ләкин аның кулына килеп капсаңмы! Алыптай баһадирлар да бөгелеп төшәдер...»

Сидоров исә каршындагы егетнең уй сөрешен чамалый иде. «Маңка! — дип уйлады ул үз чиратында. — Минем кебек гадәти крестьян гаиләсендә үссәң һәм абыең да КГБ полковнигы булмаса, кай тирәләрдә йөрер идең икән?»

Рәшәткәле тәрәзәнең тузанлы пыялалары аша үтеп кергән кояш нурлары да бүлмәгә кот кертә алмый, бу икәүнең күзеннән-йөзеннән саркыган салкынлык күңелне күшектерә кебек иде.

— Исәнмесез!

Һәммәсе сискәнеп ишеккә таба борылдылар. Заһидәгә бер күз салуга, Вилен күңеле дөрес сизгәнлеген аңлады. Кызның кыяфәте сәер иде: төссезләнгән хастаханә халаты кигән, башына яулык урынына кашларын каплап диярлек зур ак марля кисәге ураган.

Дөрес, куанычтан очкынланган күзләренең карашы, йөзенең балкышы бөтен игътибарны шундук үзенә тартты. Әмма егетнең борчылуы таралмады. Ул сикереп торды да кызның башыннан марляны тартып алды. Заһидәнең юеш кара чәчләре астыннан маңгае күпереп тора, күз төпләре, борын тирәләре шешенеп-күгәреп чыккан иде.

— Кем кыйнады? — диде, шашар дәрәҗәдә гаҗәпләнеп Вилен.

— Кыйнаган? Камерада үзара сугышканнардыр! Товаркалары, тынгы бирми, дип зарланган иде, — дип торып басты Сидоров.

— Юк-юк, беркем тимәде! — диде елмаеп Заһидә. — Таеп егылдым. Юынгыч кырыена бәрелдем...

— Дөресен әйтәсеңме? Чынлап үзеңме? Ә бәлки, сине әйтмә дип куркытканнардыр?

— Ну-с, коллега, — дип, якынрак килде профессор. — Күреп торам: гомумән алганда, туташның кәефе начар түгел. Ә бу тирәдәгеләренә килгәндә, — ул читтән генә кулы белән Заһидәнең битенә ишарәләде, — аларын сез биредәге табиблар белән бергәләп тикшерерсез. Миңа исә саубуллашырга рөхсәт итегез. Ашыгам.

Аны озаткач, тикшерүченең өстеннән тау төшкәндәй булды. Виленның үзен генә көйләү читен булмаячак иде.

— Менә монда сезнең күчтәнәчләрегез дә шул килеш тора бит әле, — дип, өстәл тартмасыннан таныш төргәкне тартып чыгарды Сидоров.

— Сез... аны моңарчы тапшырмадыгызмыни?

— Ә сез передачага хәмер куярга ярамаганын белми идегезмени? Аны ничек камерага бирәсең? Ә монда, кеше күрмәгәндә рөхсәт менә! Бер сәгать вакыт сезгә!

Һәм тикшерүче, егетнең күңеле йомшаганны сизеп, җиңел сулап чыгып китте.

Аның артыннан ишек ябылганны да көтеп тормыйча, Вилен Заһидәне кочагына алды. Кыз бөтен тәне белән аңа сеңде.

— Син исән, исән! — дип пышылдады ул, һушыннан язар дәрәҗәгә җитеп. — Сине кулга алмаганнар...

— Кем әйтте сиңа алай дип? Ни өчен кулга алсыннар мине?

— Минем өчен гаепләгәннәрдер дип котым очты. Ә син иректә икәнсең!

— Синең өчен минем ничек курыкканымны белсәң иде! Ниләр генә уйлап бетермәдем! Әллә чыннан да камерада кыерсыталармы үзеңне? Син дөресен әйт! Башкасына күчертермен...

— Юк, чыннан да, мин үзем...

— Ләкин бу кадәр...

— Мин синең белән очраштыруларын таләп иттем... Ишекне шакылдатканда башымны бәргәнемне сизмәгәнмен...

— Кичер мине, кичер... Пропускымны алдылар, кертмәделәр...

Вилен Заһидәне өстәл янына илтеп утыртты да букчаны бушата башлады.

— Безгә дә бер бәйрәм булырга тиештер бит! Хәзер шампан ачабыз...

Заһидә, сискәнеп, аның кулына ябышты:

— Кирәкми... Ачма...

Аның хәтерендә кинәт язгы кич, авызыннан тәмәке һәм хәмер сасысы бөркелгән берәүнең сулышны кисеп, тәнне җәберләп ябышканы чагылып узды. Ләкин бу минутта, ул хакта сөйгәненә сөйләп, бәхет күген болытлыйсы килмәде.

— Йөзем суы гына бит ул! Бәйрәм икән бәйрәм булсын! — диде гаҗәпләнеп Вилен.

— Исен яратмыйм! — диде Заһидә.

— Булсаң да булырсың икән...

Виленның күңеленә наз тулды. Ул саклык белән, йомшак итеп Заһидәне кочагына алды.

Алар туктаусыз сөйләштеләр. Сүзләр буталчык, ләкин моның әһәмияте юк, чөнки күңелләр бер дулкында тирбәлә иде.

— Мин сагындым сине... Өзелеп сагындым... — диде Виленның битен сулышы белән өтеп Заһидә. — Мин үз-үземә ант иттем: синеке генә булырга... Тик син миңа әйт кенә, бу минуттан син минем хатыным, диген. Хәләл ярың булыйм...

— Әйе, син минеке, мин синеке... — диде зиһенен кайнар томан сарган Вилен. — Бүген безнең туебыз...

Һәм кызның шешенке битеннән башлап муенын, сабыйларча чиста тәнен, күкрәкләрен, уймактай кендеген үбәргә тотынды. Баштарак Заһидә оялды, кыенсынды, үзе дә аңламастан берәр ишарә, ым белән Виленның гайрәтен чигермәгәем дип тартынды. Әмма тәнне салкынайта, акылны айныта торган бу тойгыдан егетнең ихлас кайнарлыгы арындырды. Заһидә җан сөйгәненең ихтыярына буйсынды, бөтен вөҗүденә татлы, шул ук вакытта утлы агым бәреп кергәндәй булды.

— Без мәңгегә бергә...— дип, җан сөйгәненең колагына пышылдады ул.

— Син минем хатыным! — диде Вилен. — Белеп тор: шушы минуттан син — Канчурова!

R R R

Киткәндә Вилен ачылмаган шампан шешәсен тикшерүчегә күчтәнәч итеп бирде. Һәм салпы ягына салам кыстырырга кирәк тапты:

— Сез бик яхшы тикшерүче, Антон Никитич, — диде. — Мин тиешле урында бу хакта әйтми калмам. Тик моннан ары бәрелү-сугылулар була күрмәсен иде... Аңлагыз: Заһидә минем өчен бик кадерле кеше. — Һәм сүзе үтемлерәк булсын өчен дип өстәп куйды: — Хатыным ул минем.

Тикшерүче сискәнеп китте. Әмма мәсьәләнең асылын шундук аңлап алды. Калын пыялалы күзлеген почмакка таба борган килеш, хуплаган сыман итеп, ияген каккалады. Бераз вакыт сүз таба алмый торганнан соң:

— Без хәзер аны Канчурова дип беликмени инде? — дип сорады.

— Шулай дип белегез. Шушы арада без моны рәсмиләштерәчәкбез.

— Димәк, ул биредә озак тормастыр бит инде?

— Сезнең яктан да ярдәм булса, тиз чыгар ул моннан.

— Безгә кагылганы барсы да тәртиптә булыр... — дип мыгырданды Сидоров.

Ләкин асылда, тикшерүче аңлавынча, биредә бернинди тәртип юклыгы ярылып ята иде. Нинди хатын булсын ул? Фамилиясе башка, үзе кыз кеше... Һәрхәлдә, бирегә кергәндә гыйффәтле иде. Чырайларыннан күренеп тора: булган монда хәлләр. Ләкин акылы булган кеше бу хакта кычкырып йөри димени? Гыйшыктан мие түнгән түгелме бу егетнең?

Мәгъшуклар белән юлың кисешмәсен, дип уйлап куйды Сидоров. Үзләре генә әвәрә булсалар бер хәл иде, башкаларның эшен бутап ташлый алар кайчакта.

«Бүлмәмнән очрашу урыны ясап би-ик хаталандым, ахрысы», — дип пошынды Сидоров. Үзенең кочагына чак сыя торган хәләл җефете юан Верага бер генә тапкыр да хыянәт итмәгән намуслы ир буларак, эш урынында әкеш-мәкеш килүчеләргә нәфрәт белән карый иде ул. Канчуровлардан коты очып курыкканга күрә генә икәүдән-икәү очраштырган иде ул аларны. Хәзер ни булыр инде?

Хәлбуки полковникның ни әйтерен дә, энесенең тагын ниләр кыланырын да белеп булмый иде. Һәрхәлдә, өлкән Канчуров кечесенең гамәлләренә мөһер сугып утырмаячак. Монысы көн кебек ачык. Әгәр энекәше килеп, мин мәхбүс кызны хатынлыкка алам, без аның белән тикшерүче бүлмәсендә зөфаф киче ясадык инде, дип әйтсәме? Әйтер дә, тәмам шашкан бит! Ул чакта таякның авыр башы Сидоровка төшәсен көт тә тор.

Әйе, эшләр хәтәр иде. Мондый чакта полковникка үзең бару хәерлерәк булыр дигән карарга килде ул.

Канчуров аны шул көнне үк кабул итте. Дөрес, кочак җәеп каршы алмады үзе. Чырае кырыс, күз карашы караңгы иде. Утырырга тәкъдим итүне дә кирәк санамады.

— Мин сезгә бурычымны үтәү йөзеннән килдем, — диде Сидоров, сәлам биргәннән соң. — Канчуровлар гаиләсенә кагылышлы мәсьәләләрне сезгә ирештереп тору тиеш дип саныйм.

— Тиеш дип санийсың икән, әйт! — диде полковник коры гына.

— Сүз Кадерматова турында бара. Кичә миңа, аның фамилиясе үзгәргән, хәзер ул Канчурова, дип әйттеләр.

— Нәрсә? Нинди Кадерматова? — Касыймның чыраена чиксез гаҗәпләнү бәреп чыкты. — Нинди Канчурова?

— Сез белмисезмени? Бу гаҗәп... Сезнең энегез Вилен кичә безгә, Кадерматова минем хатыным, дип игълан итте. Һәм аның тиздән ireккә чыгарылачагын әйтте.

Антон Никитич бу сүзләрнең кайда, ничек әйтелгәнен аңлатып тормады. Бәхеткә, Касыйм да аны-моны сораштырмады, чөнки әле генә ишеткән яңалыктан уйлары буталып киткән иде. Ул урыныннан торып, гадәтенчә тәрәзә янына барып басты, тикшерүчегә аның кыска итеп кыркылган нык арт чүмече, таза муены гына күренеп калды.

— Хәзер сез нишләмәкче инде? — дип сорады ул, башын бормый гына.

— Эшне судка җиткермәү өчен мөмкинлекләр табарга була, — диде тикшерүче. — Тик бераз вакыт кирәк булачак. Кызның үзенә дә кайбер нәрсәләрне аңлатасы бар.

Тынлык урнашты. Сидоровның эченә шом төште. Ниһаять, полковник борылды да өстәле янына килеп басты. Аның ак чыраенда тәвәккәллек чагылды.

— Менә болай, — диде ул, катгый тавыш белән. — Ул хатынны мөмкин кадәр ераккарак озатырга кирәк. Һәм тиз арада.

— Ләкин моны суд...

— Суд аны бернинди дә сәяси статья белән түгел, уголовный статья белән хөкем итәр, шулай бит?

— Ләкин ничек?

— Аны сиңа мин өйрәтергә тиешмени? Тап гаебен! Тап статьясын! Бу шәһәрдә эзе булмасын! Һәм гомере буе әйләнеп кайтмаслык ит!

— Ләкин аны күп елга утыртырга...

— Ә нигә утыртырга? Сөргенгә озатсыннар! Казахстанга! Семипалатински тирәләренә!

Сидоровның җилкәсеннән тау төшкәндәй булды. Четерекле хәлдән болай ансат котылуына чиксез шат иде ул. Статьядан эш тормас анысы. «Кешесен генә эләктерергә кирәк, статьясы табылыр» дигәннәре хак бит. Аннары бу Кадерматова белән баш катырып торасы да юк. Надзирательләрдән, режимны бозды, тәртип саклауга куелган кешеләргә каршылык күрсәтте, дип, хулиганлыкта гаепләп, яздырып кына алырга кирәк. Гаепләнүченең мондый гамәлләре һичшиксез гаебен тирәнәйтүче дәлил булып тора.

...Шул көнне үк Кадерматованың «Дело»сы бик пөхтә итеп, җиренә җиткереп, судка бирерлек итеп әзерләп куелган иде инде. Тәҗрибәле, үткен һәм уңган тикшерүче иде шул Сидоров. «Калганын судьялар карар, — дип куанып уйлады ул. — Дөреслекне яратучы бу дөньяда бер син генә түгел, сеңелкәш. Мин дә гел дөрес юлдан гына барып, гел яхшыны гына яклар идем. Ләкин алай яшәп булмый шул. Кайда ул син яклаган Тәүфикъ? Кырым татарлары кайда? Алар сине яклыймы? Дуамалланмаска иде. Системага тел-теш тидерәләр димени? Менә мин дә сине яклый алмыйм. Гәрчә һичкемгә зыяның тимәсен белсәм дә. Бу очынуларың яшьлек шаукымы гына булып, олыгайгач киртәгә керәчәгеңне бик яхшы аңласам да, йолып кала алмыйм мин сине...»

R R R

Икенче көнне төштән соң Вилен тикшерүче бүлмәсенә бер кочак кызыл тюльпаннар, зур бер сумка күчтәнәч күтәреп килеп керде. Тикшерүче белән бергәләп туй табыны ясап алырга иде аның нияте. Өстәле артында тыныч кына кәгазь актаргалап утырган Антон Никитич, урыныннан кубып, аңа каршы атлады.

— Исәнмесез! — диде Вилен, сулышына кабып.

— Саумысез! — дип, калын күзлеге аша зурайган күзләрен тутырып карады Сидоров. — Сез мине гафу итегез инде, зинһар. Хәбәр итәргә өлгермәдем.

— Нәрсәне? Ни булды?

— Юк, бернинди дә гадәттән тыш хәл булмады. Курыкмагыз. Һәммәсе тәртиптә.

— Тәртиптә булгач... Мин Заһидәне күрә аламдыр бит?

— Анысы хәзер миннән тормый шул. Мин аның «Дело»сын тәмамлап куйдым. Эш минем кулдан китте, судка барып терәлде дигән сүз. Без аны башка төрмәгә күчердек.

— Ничек? Бер төн эчендәме?

— Монда, бер кузгалсалар, бик җитез кыланалар.

— Суд аны аклар бит?
— Анысын мин сезгә әйтә алмыйм. Суд минем сүз белән йөрми, үзегез аңларга тиеш.
— Аның бер гаебе дә юк лабаса!
— Анысын суд ачыклар.
— Сез соң нинди нәтиҗә ясап бирдегез? Ул нинди статья белән гаепләнә?
— Ну, аны да бөтенләй үк керсез дип әйтеп булмый. Һәрхәлдә, биредә үзен тәртипле тотмады. Товаркалары да, надзирательләр дә бик зарландылар.
— Шуның ише юк-барга игътибар итәләрме?
— Ә сез төрмәдә бунт күтәрүне нәрсә икәнен беләсезме?
— Бунт? Заһидә бунт күтәргәнме?
— Күтәрде шул менә. Тик башкалар аңа кушылмады гына. Алай да андыйны йомып калып булмый. Бүген берсенә юл куйсаң, икенче көнне, һәммәсе дәррәү кузгалып, бөтен төрмәне ду китерәчәкләр. Тәртип булырга тиеш!
Виленның гаҗәпләнүе чиктән ашты:
— Хатыннардан да шулай дер калтырап куркып торасызмы әллә?
— Беләсегез килсә, иң куркынычы шул хатыннар инде аның. Сыер дуласа, аттан яман, дигән борынгылар.
— Нишләтмәкче соң сез аны? — дип сорады Вилен, соң чиктә гаҗизләнеп. Ул үзен маңгае белән таш диварга килеп бәрелгәндәй хис итә иде.
Сидоров егетне кызганып куйды.
— Сабыр итегез, — диде. — Башны ташка орудан файда юк. Аңа артык куркыныч янамый. Күп дигәндә биш-алты ел бирерләр.
— Биш ел... төрмәме?!
— Юк, төрмә үк булмас. Аны, мөгаен, сөргенгә озатырлар. — Аннары, җиңеләеп китеп, өстәп куйды: — Сөргендәге кеше югалмый. Аны табып була.
— Ничек?
— Анысын инде үзегез уйлагыз. Тапмый калмассыз. Әгәр хисләрегез чын булса... — дип өстәп куйды тикшерүче.
Вилен, чәчкәләрен, сумкасын өстәлгә куеп, урындыкка утырды да, башын учларына салып, чигәләрен кысты. Тәрәзәнең ачык форточкасы аша урам яктан узган машиналарның шавы нык булып ишетелә башлады.
...Менә ул машиналарның берсе — ала-колага буялган калай фургонлы «уазик» чаттан борылды да күрше урамдагы биек капка каршында тукталды. Капканың тимер канатлары авырлык белән шыгырдап ачылды. Машина эчкә керде. Такыр ишегалдында сак астында кара сумка тоткан ак күлмәкле хатын-кыз басып тора иде.
Әгәр дә Вилен, тикшерүче бүлмәсеннән чыгып, капка ягына барган булса, бәлки, Заһидәне күреп калыр иде. Машинаның тимер тартмасына менеп утырыр алдыннан Заһидә, нидер көтеп, каерылып урам якка карады. Ләкин анда сакчылардан башка кеше күренмәде...
— Син мине эзләрсең, табарсың, — дип, дога урынына пышылдады аның шешенке иреннәре. — Мин сине көтәрмен. Без бер-беребезне өзелеп сөйгән ярлар, мәңгелек парлар, ир белән хатын бит... Мәңге аерылгысыз... Син мине эзләрсең!.. Табарсың!..
Артындагы сакчы, тупас итеп, аны тимер тартмага төртеп кертте дә, арттан үзе сикереп менеп, калын ишекне каты шапылдатып япты. Заһидә дөм караңгылыкка чумды...

R R R

Никадәр ачуы килгән булса да, Касыйм Канчуров үзен кулга ала белә иде. Яши торгач, хәйләсез дөнья файдасыз икәнен нык аңлаган, шуңа күрә туры сөйләргә ничек кенә яратса да, эчендәген тышка чыгармаска өйрәнгән иде ул.
Энекәшенең рөхсәт сорамый-нитми бүлмәгә бәреп кергәнен күргәч, һәм аның имән күмере салган самавырдай кызып сөйләгәнен тыңлаганда, полковник тыштан тыныч калды.
Ниһаять, Вилен әйтәсен әйтеп бетергәндәй булды, хәлсезләнеп урындыкка килеп утырды.
— Та-ак, — диде сузып Касыйм. — Әгәр дә мин сине дөрес аңласам, син ул кызны яратасың, шулаймы?
Вилен раслап башын иде.
— Кайда танышкан идегез соң сез?

— Шунда... Мин... эш белән баргач...
— Та-ак... Бер күрүдә кабынган мәхәббәт, димәк, сезнең арада. Яшь чакта андый хәлләр булгалый шул.
Вилен каш астыннан гына күз сирпеп алды, абзасының ачуланмаганын күреп, бераз тынычланып китте.
— Алайса, син, энекәш, сөенергә генә тиеш, — диде бераз тынып торганнан соң Касыйм. — Следственный төрмәләрдә еллар буе утыручылар бар. Ә бу очракта тикшерү тәмамланган, эш судка җибәрелгән. Хәзер инде аз гына көтәсе калган.
— Ләкин сезнең ул суд дигәнегез фарс кына бит. Әгәр берничә елга утыртып ук куйсалар?
— Анысын инде судьялар карар, — диде нык итеп полковник. — Суд эшенә кысылып йөрергә кушмыйсыңдыр бит син миңа? — Ул янә беразга тынып калды. — Әгәр инде син җан сөйгән ярларны төрмәгә кереп эзләп тапкансың икән, ул чакта сабыр канатларың нык булсын. Еллар буе көтәргә туры килгәндә дә сынмасын, — дип дәвам итте аннары. — Ах, как это благородно! Ах, как это красиво! Берәр язучыга сөйләргә кирәк моны! Әлегә кадәр алар, селәгәйләрен агызып, төрмәдәге ирләрен көтеп яшь түгүче хатыннар турында гына язалар иде. Сөйгән ярны төрмәдән эзләп тапкан егет турында язсыннар алар!
Ни тыелырга тырышса да, полковникның үте сытылды.
— Сөйгәнем генә түгел, хатыным ул минем! — дип ярып салды Вилен, үзе дә көтмәгәндә.
— Шулаймыни? Хатыныңмыни? Кайчан өйләнеп өлгердең соң әле син? Безгә әйтеп тормыйча? Атаң-анаң ризалыгын да алмыйча, ә?
— Әйтермен! Менә чыксын гына... Шундук Нижгарга алып кайтам мин аны...
— Син һәммәсен дә бик яхшы уйладыңмы? Теге дару... аның өчен эзсез үттеме икән?
— Анысын да уйладым. Әгәр берәр төрле йогынтысы калган икән, аны мин генә белә алам һәм дәвалау чарасын да табачакмын! Бүтән бернинди табиб булдыра алмый моны! Ул яктан караганда да без бергә булырга тиеш. Ләкин эш анда гына түгел, мин яратам аны!
— Син нәрсә... Гыйшык дигәч тә... Тилердеңме әллә? Һәркем үз тиңен сайлый... Берәү дә маймылга гашыйк булмый!
Полковник, гадәте буенча, тәрәзә каршына барып басты.
— Димәк, син Таһир ролен уйнамакчы инде... Таһир белән Зөһрәне агызганнар суларга... Мәҗнүн булмакчы... Ләйләнең чибәрлеген күрү өчен Мәҗнүн күзләре кирәк... Димәк, синдә шул Мәҗнүн күзләре инде... Котлыйм... Алай сөйгән кеше сирәк ул...
— Ә нишләп Мәҗнүн? Мин Вилен булып та ярата беләм! Кайберәүләр кебек таш йөрәкле түгел!
Бу сүзләр полковникның күңелен тырнап узды. Ах, эчендә җаны булган ир-егетнең йөрәк түрендә, бәгыренең иң нечкә бер җирендә, гомере буена исенә төшкән саен үзәген өзә торган яшьлек мәхәббәтенең чаткысы көйрәмимени?
Беренче сөйгән яры белән гомерлек пар булган һәм кара гүргә кергәнче гөрләшеп яшәгән кем генә бар икән бу дөньяда? Булса да, андыйлар ата ялганчыдыр...
Шул минутта полковник үзенең дөрес юлдан барганлыгына тәмам ышанган иде инде. Вакыт кирәк, вакытны сузарга кирәк, дип уйлады ул.
— Ну что ж, — диде ул, башын күтәреп һәм зәңгәр күзләре белән энесенең нәкъ үзенеке төсле якты күзләренә туры карап, — ярат! Чын мәхәббәткә киртә юк, диләр. Димәк, сезгә шулай язгандыр. Утлар-сулар кичәргә. Бездән хәер-фатиха!
Вилен үз колакларына үзе ышана алмады. Чыннан да, абзасы аның яклы булыр микәнни? Егетнең чыраендагы гаҗизлек галәмәтләре әкренләп куанычка алышынды, алсу иреннәре киң җәелеп, күзләренә язгы күк тирәнлеге иңде.
— Чынлапмы, абзый?
— Ә минем кайчан шаярганым бар? Яки алдаганым бармы? Бигрәк тә туганнарны.
Вилен андыйны хәтерләми, хәтерләсә дә, бу минутта исенә төшерәчәк түгел иде. Аның абзасына бик тә, бик тә ышанасы килә иде.
— Юк, әлбәттә, юк, — диде ул.
— Безнең нәсел гомергә алдау-йолдауны белмәде, — диде горурлык белән өлкән Канчуров.
— Заһидә дә шундый! Нәкъ безнең нәсел төсле! — диде елмаеп Вилен. — Туры сүзле, ихлас күңелле. Бирегә дә шул дөресен әйткәне өчен генә килеп эләккән. Эчендәге тышында!
— Эчендәгенең барсын да тышыңа чыгару бик үк яхшы түгел инде ул. Хайвани гадәт дияргә була, — дип, тыныч кына нәтиҗә чыгарып куйды полковник. — Аңгыра башлар йә бөтенләй тәрбиясез бәндәләр генә беркатлы була. Тәрбияле кеше капчык төбен чыгарып селкемәс. Үзен әдәп, әхлак, инсаф кысасында тота белер.
Ләкин энесенең чыраенда сызлану галәмәтләре чагылганны күреп, сүзен төзәтергә кирәк тапты.

— Ну, ничего, яшь бит әле ул, өйрәнер, — дип елмаеп куйды. — Канчуровлар кысасына кергәч, менә дигән булыр.

— Адвокаты кем булыр икән?

— Анысы өчен бер дә борчылма. Яхшырагын бирерләр, — дип тынычландырды аны Касыйм. — Анысын гына миңа ышанып тапшырырсың, бәлки? Әллә синең без белмәгән оста адвокатларың бармы?

Вилен абзасының күңелен китәргә теләми иде.

— Бөтен өмет синдә инде, абзый, — диде ул.

Вилен кабинеттан чыгып киткәндә, Касыйм аңа кызыгып һәм сокланып карап калды. Егетнең йөрәге җилкенгәне, күңеле очынганы адымнарыннан ук күренеп тора иде. Әйе, гашыйкларның кыяфәте бөтенләй икенче шул аның. «Ни кызганыч, безнең яшьлек хисләре бөтенләй тиң булмаган кешеләргә бүләк ителә», — дип көрсенеп нәтиҗә чыгарып куйды ул. Төрмәдә яткан Кадермәтованың яхшы кыз булуына ул ышанмый, моны аңа һичкем исбатлый алачак түгел иде. Күзгә төртеп торган гаеп-кыегы дә юктыр, бәлки, ләкин барыбер Канчуровлар арасында андыйлар булырга тиеш түгел! Ул хатын Касыймның энесен үзенә гашыйк иткән өчен генә дә мең тапкыр гаепле һәм шуның җәзасын алачак иде.

R R R

Бер атнадан соң тикшерүче Сидоров, Виленны үзенә чакырып, «сер итеп кенә» Заһидәнең биш елга сөргенгә җибәрелгәнен әйтте.

— Адресын... Адресын бирегез! — диде Вилен.

— Этап белән озатылалар бит алар. Адресы урынына барып җиткәч билгеле була инде...

— Кая озатылалар? Магадангамы, Воркутагамы?

— Сөргенгә гадәттә башка якларга җибәрәләр. Әйтик менә, Семипалатински өлкәсенә...

— Тәгаен шундамы?

Тикшерүче күзлек пыялалары аша Виленга текәлеп бераз дәшми торды.

— Ник дәшмисез? Ул минем хатыным, аңлыйсызмы? Хатынымның хәлен белә аламмы мин, юкмы? — диде Вилен сабырсызланып.

— Мин аңлыйм да бит... — дип җавап бирде Сидоров сузып кына. — Тик менә башкалар аңлар микән? Загс язуыгыз юк бит әле сезнең. Паспортыгызга пичәт сугылмаган.

— Бару белән пичәт суктырачакбыз. Сөргендәгеләргә өйләнешү тыелмый, шулай бит? Кая барырга икәнен генә әйтегез, — дип торып басты Вилен. Аның кайнарлыгы Сидоровның да күңелен йомшартты.

— Тота-каба чыгып чаба алмассыз шул әле, — диде ул ахырда. — Төрмә юлларында йөрер өчен бик күп сабырлыклар кирәк. Әгәр сез үзегезне чыннан да... өйләнгән дип саныйсыз икән, тормышыгызның бик нык үзгәрәчәген дә исегездән чыгармагыз.

— Өйләнгәч, тормыш үзгәрер инде.

— Эшегезне кинәт кенә ташлап, һәммәсенә кул селтәп чыгып китмәссездер бит?

— Сез миңа этапның кая, кайчан барып җитәсен генә әйтегез. Аны гына белеп буладыр бит?

Тикшерүче тирән итеп көрсенде дә:

— Семипалатинскида минем бер яхшы танышым бар иде, безнең системадан, — диде. — Мин сезгә аның телефонын бирәм. Әгәр күчеп-нитеп китмәгән булса яисә телефоны үзгәрмәсә, ярдәм итәр, бәлки. Тик бу безнең арада сер булып калсын иде.

Тикшерүче шуннан артыгын бик теләсә дә эшли алмый иде — Вилен моны аңлады.

R R R

Тагын да берничә көннән соң, поездның соңгы калтырча вагонында көньякка таба барганда, Вилен Заһидәне табачагына һич тә шикләнмәде. Сидоровның танышы белән элемтәгә кереп тә булмас, бәлки. Ләкин адәм баласы — салам кибәненә төшкән энә түгел, бигрәк тә сак астында булганда. Вилен Заһидәне тапмый кире китмәячәк, моның өчен ул алдында торган таш диварларны маңгае белән тишәргә әзер иде.

Көн эссе, көньякка таба арырак киткән саен, вагон эче бөркүләнә барды. Купеда ул ясле-бакча яшендәге ике балалы казах гаиләсе белән туры килде. Юлдашлар белән сүз ялганмады — Виленның кешедә гаме юк иде. Көне буе коридор тәрәзәсеннән басу-урманнарга, шәһәр-авылларга карап торды ул, төнен исә өске киштәдә йокысыз тирбәлеп ятты. Һаман уйланды да уйланды, уйларының очына чыга алмады. Тик бер нәрсә аермачык иде: яшерен бүлеккә кире әйләнеп кайтмаячак ул. Моңарчы ничек анда эшләгән — хәзер моңа үзе дә аптырый. Бөтен талантыңны, көчеңне агу ясауга багышлау — җинаятькә тиң шөгыль икән бит! Элек ул бу хакта уйлап башын катырмый иде. Ләкин менә соңгы вакытта кинәт зиһене

ачылып киткәндәй, вөжданы уянгандай булды. Һәм җаны туктаусыз әрни башлады. Заһидәнең күзенә карап, үзенең асылда кемлеген,ниләр белән шөгыльләнгәнен ничек әйтергә? Һәм... аңа ясалган уколның нәрсә икәнен нинди сүзләр белән аңлатырга? Әйтми-сөйләми калып та булмаячак, чөнки ике арада бозлы кыядай калкып торган бу шомлы серне гомер буена шул килеш тоту мөмкин түгел!

Сөйгәненә күңел капкаларын ахырынача ачар Вилен, һәммәсен сөйләр, аның сәламәтлегенә салган зыяны өчен дә, агу белән үтертелгән кешеләр өчен гафу үтенер. Алай гына түгел, Заһидәнең аягына егылып, ярлыкавын сорар. Һәм калган гомерендә фәкать кешеләргә файдалы эш белән генә шөгыльләнергә ант итәр...

Бу — Заһидә белән ике араның керсезлеге өчен кирәк. Аларның мәхәббәте саф, чиста булсын өчен Вилен һәммәсенә дә риза: институтын ташларга да, күпмедер вакытка фәнни эзләнүләрен туктатып торырга да. Мәхәббәте хакына, җан сөйгән яры белән бергә булу өчен ул бөтен авырлыкларны җиңәр, кирәк булса, җир казыр, теләсә нинди кара эшкә җигелер. Һәм хатыны өстенә ягылган нахак гаепне алып ташлау, аны иреккә чыгарып, бергәләп кире кайту өчен бөтен көчен куяр.

Аннары яңадан фән дөньясына керергә, хыялында йөрткән даруны эшләргә дә мөмкинлекләр табылмый калмас.

...Тырык-тырык тыркылдап барган поезд тәгәрмәчләренең тавышына уралып, шундый уйлар буталды Виленның башында. Аның өстенә күңелнең бер кырыена кереп оялаган курку хисе дә тынгы бирмәде. Беркемгә әйтми-нитми чыгып киткән өчен баштан сыйпамаслар, билгеле. Чөнки яшерен урыннарда эшләүчеләргә шәһәрдән рөхсәтсез чыгып китү катгый тыела. Бу минутларда Неусыпович, нашатырь кыстыргандай әрле-бирле чабып, институтта ду куптаргандыр. Һәм тагын башка урыннарда да... Тиз генә куып тота алмаслар алуын. Чөнки Виленның кая киткәнен беркем белми. Тапкач, нишләтерләр икән? Дәүләт серен чишкәне юк, әллә ни кыла алмаслар әле. Хөкемгә тартсалар да, сөргенгә җибәрүдән катырак җәза бирмәсләр. Димәк, андый очракта да Заһидә янына эләгү мөмкинлеге табылыр дигән сүз. Ни генә булмасын, абзасы бөтенләй үк ташламас. Канчуровлар бер-берсен ярдәмсез калдырмый...

...Төн уртасы узган иде, аның уйларын коридордагы шау-шу бүлдерде. Поезд станциягә килеп туктаган, вагонга яңа юлчылар керә булса кирәк. «Бигрәк каты дөпелдиләр, солдатлар кебек» дигән уй узды баштан. Ул арада проводник хатынның: «Менә бередә», — дип, куркынган тавыш белән әйткәне ишетелде, ишекне дөмбәсли башладылар. Купедагы балалар елап җибәрде, өске киштәдән әтиләре сикереп төште дә бикне ачты. Ишектә өч милиционер күренде.

— Канчуров! — диде алда басып торган лейтенант, кырыс тавыш белән. — Кайсыгыз Канчуров?

— Мин.

— Төшегез. На выход!

— Минем билетым бар...

— Анысын карарбыз. Бирегез әйберләрегезне!

— Ә ни өчен әле сез?..

— Күп сөйләшеп тормагыз! Поездны тоткарлыйсыз. Собирайся живо!

Виленны поездган төшерделәр дә вокзалдагы милиция бүлегенә кертеп утырттылар.

— Сезне кире Казанга озатырга боерык килде, — диде андагы кыршылган өстәл артында утыручы капитан.

— Ни өчен?

— Анда аңлатырлар.

Кояш чыгар алдыннан Виленны кире төньякка таба алып та киттеләр. Купега аның белән бергә гади генә киенгән ике таза егет кереп утырды.

...Ул дөрес уйлаган иде: Неусыпович аның юкка чыкканын шундук сизеп алды. Чөнки бу бүлектә эшләүчеләр күздән югалып торырга тиеш түгел. Вилен иртән эшенә килмәгәч, өенә шылтыратты, җавап булмагач, югарыдагыларга хәбәр итте.

Төш турында полковник Канчуровка шылтыратып, энесенең юкка чыгуы турында әйттеләр. Касыймның күңеленә шом керде. Энекәшеннән мондый ук этлекне көтмәгән иде ул. Ә бәлки, юаныч эзләп берәр сөяркәсенә баргандыр да, эчеп, айный алмыйча, шуның фатирында ятадыр? Ах, шулай гына булса икән лә! Юк икән шул, Вилен икенче көнне дә эшендә күренмәде. Моны белүгә, полковник Сидоровны үзенә чакырды. Сөйләшү озакка сузылмады, ул башлыча Канчуровның ярсып кычкырынуыннан гыйбарәт булды. Ни өчен Сидоров кирәкмәгән нәрсәгә кысыла? Ни өчен ул хөкем ителгәннәрнең кайда буласы турында теләсә кемгә мәгълүмат бирә? Кем рөхсәт иткән? Моның өчен ни буласын онытканмыни?

Ләкин, ничек кенә ярсып кычкырынса да, полковник хәзер генә Сидоровны җәзага тарттыра алмый, чөнки бу вакыйга тирәсендә ыгы-зыгы куптару, сүз үрчетү һич кенә дә аның файдасына түгел иде. Шуңа күрә ул, тикшерүчене куып чыгарып, телефонга ябышты. Башка шәһәрләрдә үз өлкәсендә эшләүчеләр

белән танышлыгы җитәрлек, шулар ярдәмендә тиз һәм шау-шусыз гына энекәшен кире кайтару чарасына кереште. Һәм, чыннан да, мәсьәләне бик тиз хәл итте...

...Казанга поезд кичке якта килеп төште.

— Кайсы төрмәгә илтәсез инде сез мине? — дип сорады Вилен үзенә ияреп вагоннан төшкән егетләрдән.

— Фатирыгызга.

— Ничек алай?

— Безнең смена шунда көтә. Сезне аларга тапшырабыз да китәбез, — диде моңарчы «керәбез, чыгабыз, көтәбез» дигәннән бүтән рәтле сүз дә әйтмәгән егетләрнең берсе.

Моңарчы беркайчан да милиция кулына эләкмәгән, бернинди кыерсыту-кимсетүне күрмәгән Виленга күзәтү-сак астында булу бик авыр тәэсир итте. Поездда бер тәүлек кайткан арада ул, төрмә камераларын, андагы мәхбүсләрне күз алдына китереп, тәмам коелып төшкән иде. Шуңа күрә, «фатирыңа илтәбез» дигәнне ишетүгә, эче куаныч белән тулды. Күкрәк тутырып, үз өеңнең һавасын сулау гына да ни тора! Моңа кадәр кадере генә беленмәгән икән! Бәлки, каядыр алып чыгып киткәнче, өсне алыштырырга, юынып алырга да мөмкинлек бирерләр әле... Өйдәге телефоннан абзасына шылтыратып та булыр, мөгаен...

Фатир ишеге төбендә гадәти күлмәк-чалбар кигән ике ят ир көтеп тора иде. Озата килүчеләр белән алар арасында кыска гына сөйләшү булып алды, ниндидер кәгазьләр бирештеләр. Вилен исә ишеген ачып керергә ашыкты.

Телефон трубкасына тынлык кереп оялаган иде. Өзгәннәр... Рөхсәт сорамыйча килеп кергән ирләрнең берсе:

— Сезгә телефоннан шылтырату тыела, — диде. — Бүгеннән сез күзәтү астына алынасыз. Беркая да чыкмагыз, беркем белән дә элемтәгә кермәгез. Эшегезгә барганда-кайтканда, безнең кеше сезнең тирәдә булыр.

Бу сүзләрдән соң Виленның өстеннән тау төшкәндәй булды. Күзәтү, диме? Күзәтү генәме? Димәк, ул өендә яшәячәк. Нинди бәхет!

Аның сыны турайды, ияге күтәрелде. Ул гадәттәге кыюлыгы кире кайтканны тойды һәм буйга үзеннән шактый кыска адәмгә керфекләрен кысып карады:

— Нинди күзәтү? Сез мине өемдә тоткын итәсезме әллә? Под домашний арест утыртасызмы?

— Теләсә ничек дип әйтегез. Тик шуны белеп торыгыз: әгәр берәр кая тайпылырга маташсагыз, шундук кулга алыначаксыз. Каршылык күрсәтсәгез... безгә корал кулланырга рөхсәт бирелде.

— По какому праву?! Ни хакыгыз бар? Ордер кая? Суд карары кая?

— Кисәтеп куйган өчен рәхмәт әйтергә кирәк. Белеп торуыгыз начар булмас, шулай бит?

Абзасына Вилен икенче көнне эштән шылтыратты. Ләкин полковник Канчуровны Мәскәүдә, диделәр. Ике көннән кайтасы икән. Ул кайтмыйча торып, бернишләп булмый иде.

Институтта исә һәммәсе үз тәртибе белән дәвам итә, аның белән эшләүче өч-дүрт ир-ат, секретарь кыз һәм профессор Рассекаев Виленның ике көн югалып торганын сизмәгәннәр дә кебек. Анда рәхәт, күзәтү астына алынганыңны тоймыйсың, чөнки элек тә бикле ишек артында идең, хәзер дә.

Кыскасы, абзасы кайтуга, ул нык уйланган һәм шактый суынган иде инде.

R R R

...Вилен кабинетка барып кергәндә, Касыйм ике кулын буш өстәленең карасу-елтыр тактасына куеп утыра иде. Энесен күргәч, ул башын күтәрде, һәм Вилен йомшак келәмгә сөртенеп куйды: абзасын мондый бөрешкән хәлдә күргәне юк иде әле аның. Касыймның иңбашлары төшкән, ак яңаклары салынган, киң маңгаенда ал сызыклар хасил булган. Кызарынган күзләренең мөлдерәгән карашында сызлану һәм җәберсенү ярылып ята.

— Исәнме, абзый.

— Үзең күрәсең, исән әле бүгенгә.

— Нишләп... бүгенгә?..

— Чөнки иртәгәсен белеп булмый. Анысы миннән тормый.

— Ә кемнән тора?

— Синнән, кадерле энекәш, фәкать синнән генә.

— Мин тоткынлыкта хәзерге вакытта, абзый. Под домашним арестом.

— Ә синең төрмәгә үк кереп утырасың киләме? — дип, каты гына сорап куйды Касыйм.

— Нишләгән әле мин ул хәтле?

— Үзең белмисеңмени? Бу эшеңә урнашыр алдыннан нинди документларга кул куйганыңны оныттыңмы әллә?

— Мин дәүләт серен сакларга гына сүз биргән кеше. Вәгъдәмне бозганым юк!

Бу сүзләрдән Касыймга гайрәт иңеп киткәндәй булды.

— Дәүләт серен сакларга гынамыни? — диде ул, яхшы ук кычкырып. — Син үзеңнең режимный учреждениедә эшләгәнеңне оныттыңмыни? Рөхсәт алмый-нитми әллә кая чыгып китәргә кем хокук бирде сиңа?

— Чит илгә түгел ләбаса! Үз илем юлларыннан гына йөрдем!

— Син бу шәһәрдән беркая да чыгып китәргә тиеш түгел! Һәм моны бик яхшы беләсең!

— Аның өчен генә ул кадәр ыгы-зыгы куптарырга дигәнмени?

Алар бер-берсенең күзләренә карашып тордылар.

— Әгәр дә син, бу ыгы-зыгыны мин куптарган дип уйлыйсың икән, бик нык ялгышасың, — диде, ниһаять, Касыйм. — Мин сезнең гыйльми эшләрегезне күзәтүче генә. Куркынычсызлыкны тәэмин итү белән башкалар шөгыльләнә. Һәм алар миңа буйсынмый. Әгәр берәр ялгыш адым ясасам, алар минем үземне үк...

Касыйм сүз таба алмады, тыны буылып, Виленга аркасы белән борылды, бераз вакыт каршысындагы кәҗә сакаллы адәмнең сурәтенә карап торды. Аннары башын иеп:

— Ярый, син үзеңнең киләчәгеңне уйламыйсыңдыр...

— Бик уйлыйм! Мин киләчәгем өчен көрәшәчәкмен! Мин барыбер...

— Нәрсә, тагын чыгып качмакчымы әллә? Тик кая кадәр генә бара алырсың икән? Белеп тор: икенче юлы сине фатирыңа кайтарып куймаячаклар! Туп-туры тиешле җиргә илтеп тыгарлар!

— Куркытасыңмы, абзый?

— Куркытмыйм. Куркам...

— Минем өчен курыкма, абзый... Мин үземне үзем кайгырта беләм...

— Һәм, үзеңне кайгыртканда, башкаларны таптап уза да беләсеңме? Син төшеп баткан сазлыкның безне дә суырып алачагын уйладыңмы соң? Бар, кит! Гыйшкың шулхәтле көчле икән, күзең тонган икән, чап җәһәннәм тишегенә! Ләкин шуны белеп тор: синең аркада монда әллә ничә кеше егылып калачак. Рәтле урында утырган Канчуровларның бөтенесен бәреп төшерәчәкләр. Ит комбинаты директорлыгыннан Зыятдин абзаңны, халык контроле җитәкчелегеннән Юныс абзаңны. Шушы арада мине генерал званиесенә тәкъдим итәчәкләр иде... Ул токтарланачак, билгеле. Чөнки синең кыланмышларыңны Мәскәүдә дә беләләр инде... Мине отставкага озатырга кыҗрап йөрүчеләрне нык сөендердең! Ә Зыятдин абзаңның өч кызы, Юныс абзаңның ике улы... Аларның да юлы киселер... Әйт, ни начарлыгыбыз тиде сиңа безнең? Ни өчен син бөтен Канчуровларның нәсел тамырына капчыклап тоз тондырдың?

Вилен бу кадәр үк дип башына да китермәгән иде. Ул хәлсезләнеп урындыкка барып утырды да, терсәкләрен өстәлгә куеп, маңгаен учларына салды.

— Гафу ит мине, абзый...

Бүлмәдә тынлык урнашты. Касыйм кесәсеннән зур ак кулъяулык алып, каты итеп борынын сеңгерде, сулыш алуыннан ук аның җиңеләеп киткәне сизелде.

— Булганы булган инде, башны ташка бәрүдән файда юк, — диде ул. — Киләчәктә алдыңны-артыңны карабрак йөрергә туры килер. Эшеңдә дә тел тидерерлек булмасын. Кара аны! Профессорың һәр җирдә сине алыштыргысыз кадр дип мактап торса, кагыла алмаслар!

Виленның иреннәре нечкәреп, агарып киткәндәй булды:

— Менә анысын булдырып булмый, — диде ул авырлык белән.

— Нәрсәне булдыра алмыйсың тагын?

— Агу ясау белән мин бүтән шөгыльләнмәячәкмен.

— Бусы ни дигән сүз инде?

— Аны кемнәрдәдер сыныйлар. Алар да кеше бит! Ата-аналары, хатыннары, балалары бардыр!..

— Ах, менә син нәрсә турында... Тәмам җебеп аккансың икән, селәгәй, — дип, үзалдына әйтеп куйды полковник һәм бераз вакыт тынып утырды. — Ә кем белә анда сезнең ни белән шөгыльләнгәнегезне? — диде. — Неусыпович кына сизә күрмәсен.

— Ул әйтсәң дә аңламый.

— Бигрәк яхшы. Мыштым гына үз эшеңне эшләп утыр шунда.

— Рәхмәт, абзый, — диде Вилен чын күңелдән. — Күзәтүне кайчан алдырасыз соң инде?

— Анысына тыкшынырга кушма инде син миңа, энекәш. Үпкәләмә дә. Күрмә дә син аларны! Кызлар белән свиданиега барганга сүз әйтмәсләр бит!

— Ә хат алышканга? Анысына сүз әйтәләрме?

— Хат? Нинди хат?.. Ә-ә, син аны әйтәсеңме...

Касыйм, Заһидәне исенә төшереп, чыраен сытып куйды.

— Анысы өчен борчылма, — диде ул, карашын читкә борып.

R R R

Анфиса Дмитриевна дөрес әйткән, «Вика» фирмасының игъланнары гәзитләрдә басылып тора, анда телефоны да, адресы да күрсәтелгән икән. Мортазага боларны белү кыен булмады.

Нидирәк кеше икән ул Марат Канчуров? Әтисенең яшьлек мәхәббәте хакында белә микән? Белсә, моңа ничегрәк карый икән?

Күзгә-күз очрашкач, бу турыда сүз кузгату килешеп бетәрме? Ай-һай ла... Мортазаның күңелендә Вилен Канчуровка карата шырпы очы хәтле дә җылылык юк һәм булуы мөмкин дә түгел. Бәс, шулай икән, Марат Канчуров аның әнисе белән кызыксыныр дип буламыни?

Димәк, очрашкач сүзне нидән башлау турында бик нык уйларга кирәк. «Вика-ян», «Вика-инь» дигән препаратларны сылтау итәргә туры килер, бәлки. Кытайларда «ян» дигәне — ирләр табигатен, «инь» дигәне хатын-кызны аңлата. Димәк, даруларның беренчесе ир-ат өчен, икенчесе хатыннар өчен булып чыга.

Ә бәлки, сүзне шуннан башлап, бу даруларны тапкан бөек галим Вилен Канчуровның үзе белән элемтәгә керү мөмкинлеген белешергәдер?

«Дөреслеккә дә туры килә, «Вика-ян» дигәненә үзем үк мохтаҗ лабаса», — дип, ачы көлемсерәп уйлап куйды Мортаза.

...Канчуровның офисында телефонны яңгыравык, рәсми тавышлы бер хатын-кыз, күрәсең, секретарь алды. Марат Виленовичны сораганны ишеткәч:

— Сез каян? — диде. — Кем икәнлегегезне әйтеп сөйләшегез, зинһар.

— Мортаза исемле мин.

— Мортазин?

Кызыкайның әлегә кадәр мондый исемне ишеткәне булмаган, ахры.

— Исемем Мортаза минем. Фамилиям Асанин.

— Марат Виленовичка ни йомышыгыз бар?

— Мин аның үзе белән сөйләшергә телим! — диде Мортаза, мөмкин кадәр ышанычлырак, таләпчәнрәк тавыш белән.

— Ә бәлки, сезгә аның урынбасары ярдәм итәр? Хәзер, Альберт Викторович белән тоташтырам.

Күпмедер вакыт телефонда ниндидер көй уйнап торды, аннары түрәләрчә кырыс, калын тавыш ишетелде:

— Тыңлыйм! Кем әле бу?

— Асанин.

— Нинди Асанин?!

— Мин Марат Виленовичның үзе белән сөйләшергә телим. Сүзем бик җитди. Аның әтисенә кагылышлы. Шәхси мәсьәлә.

— Ә бәлки, башта сез минем янга килерсез? Алдан уйлашырбыз...

Бернишләр хәл юк, Мортаза сәгать бишенче яртыда үзенә һич кирәге булмаган Альберт Викторович янына барырга риза булды.

«Вика»ның офисы шәһәр үзәгендәге тыныч, ямьле тыкрыкларның берсендә, кечкенә бакча артында, ике катлы, кечерәк кенә, әмма бик затлы итеп төзелгән борынгы йортта икән. Бина челтәрле тимер рәшәткә белән уратып алынган, шундый ук челтәрле капкага бик пөхтә хәрефләр белән «Капка каршына машина куймагыз. Керү пропусклар буенча» дигән кызыл язу эленгән. Эчке якта ике-өч машина күренә.

Ыгы-зыгылы, тынгысыз һәм борчулы кала урамнарыннан чисталыгы, аулаклыгы белән аерылып тора иде бу почмак. Өске катлам кайда гына булса да, үз тирәсендә аерым бер затлы мохит булдыра белә, ул беркайчан да гади халык белән катнашмый, болганмый.

Менә ишегалдыннан, озын саплы себерке белән өч көчекне куалап, зәңгәр халат кигән кыска буйлы адәм — урам себерүче килеп чыкты.

— Пшол вон! Пшол! Туйдырдыгыз инде тәмам!

Этләр, борылып, өргәләштереп, бакчага кереп киттеләр. Урам себерүче кире ишегалдына юнәлде. Мортаза бакчадан чыгып өлгермәде, теге адәм капканың башта бер, аннары икенче канатын киңрәк ачып куйды, эчке яктан күксел-зәңгәрсу «Ниссан» чыкканы күренде. Күрәсең, бик кәттә кеше утырган иде аңа. Шәһәр урамнарында көннән-көн ишәя барган иномаркалар арасында «Ниссан»нар еш очрамый. Алар бик бай, талымлы, затлы кешеләр өчен генә.

Машинаның караңгы төстәге пыялалары аша эчтәгеләр күренми иде. Ул урам якка борылып өлгермәде, эчке яктан джинсы костюм кигән, соргылт мыеклы адәмнең кул болгап йөгереп килгәне күренде.

— Марат Виленович! Бер генә минут!

— Нәрсә тагын?! — Машинаның арткы ишеге ачылып, аксыл эшләпәле берәү башын сузды. Алар сөйләшеп алдылар, Мортазага сүзләре ишетелмәде. Аның карашы машинадагы адәмгә юнәлгән иде.

Менә нинди икән ул Марат Канчуров! Кырыйлары дулкынландырып бөгелеп куйган ковбой эшләпәсен генә күр син аның! Күзләре күләгәдә, эре, ак тыгыз тешләре, шакмакланып килгән ияге генә күренә. Керсез ак күлмәгенең өске сәдәфе ычкындырылган, киң җилкәләре саргылт пинжәгенең иңнәрен киергән.

— Марат Виленович! — дип, Мортаза машинага таба атлады.

Әмма тегесе эшләпә астыннан күз генә сирпеде дә машина ишеген шалт итеп ябып куйды. Эчтән:

— Бу нинди сукбай? Разберитесь! — дигәне генә ишетелеп калды.

Машина кузгалды да урам ягына борылып күздән югалды. Мортаза сасы төтенгә уралып торып калды.

— Әй, син! — дип, аңа таба атлады әле генә Канчуров белән сөйләшкән кеше. — Нәрсә дип биредә болганасың, ә? А ну, ычкын моннан!

— Мин Марат Виленовичка. Йомыш белән, — диде Мортаза, башын мөмкин кадәр югары тотарга тырышып.

Теге адәм аның спорт костюмын, кроссовкаларын, бөтен кыяфәтен күздән кичерде дә, кимсетүле тавыш белән:

— Марат Виленович урамда хәер өләшми, — диде. — Өтәләнеп йөрмәсәң дә була.

— Кем хәер сораша әле монда? Кем?

Мортазаның әтәчләнгәнен күреп, мыеклы капкага таба чигенде.

— Ну! Ну! Кара аны, тагын бу тирәдә күрсәм...

— Урамга да хуҗа булдыгызмы инде әллә сез монда?!

Мыеклының җиңелеп каласы килми, шул ук вакытта сугышырга да исәбе юк иде, ул мыгырданып капкадан кереп китте, Мортазага ишетелерлек итеп, урам себерүчегә:

— Син бу типны хәтерләп кал әле, — диде. — Кара аны, бу тирәдә болганмасын!

Себерүче тузан әсәре дә кунмаган асфальтны себергәндәй итенергә тотынды.

— Безнең территория бу, — дип, башын күтәрми генә Мортазаның аяк очын себеркесе белән тырнаштырды ул. — Монда чисталык өчен мин җавап бирәм. Син бар, үз юлыңда бул. Безнең монда прием юк. Оешмалар белән генә эш итәләр. Товарны да оптом гына озаталар. Дару кирәк булса, аптекага бар.

...Кем сөйли анда, адәм балалары бу җиргә тигез булып килә, дип? Виленның улы белән Заһидәнең улы тигез булып туганнармы?

Бер үк илнең гражданнары булсалар да, бер үк чорда, бер үк шәһәрдә яшәсәләр дә, аларның язмышы җир белән күк арасы кебек.

Һиндстанда яшәүче халык төрле-төрле касталарга бүленгән, диләр. Иң түбән каста әһелләре «орынырга ярамый торганнар» дип атала, алар чүплек башларыннан ары китә алмый икән. Безнең халык бу хакта укыгач хәйран кала. Ләкин нигә? Уйлап карасаң, Марат Канчуров өчен Мортаза Асанин шундый орынырга ярамый торган бәндә түгелмени?

Һиндстанда адәм баласы үзенең кемлеген белеп үсә, киләчәген чамалый. Һәм язмышка рәнҗеми. Бездә исә яшьтән һәммә кеше бертигез дигән сафсаталарны сеңдереп үстерәләр. Андыйларга үзенең түбәнлеген аңлау — зур фаҗига.

Гарьләнү, ярсу Мортазаның күзен дә, зиһенен дә томалаган иде. Ул ничек трамвайга барып утырганын, аннары троллейбуска күчкәнен сизмәде. Аңына килгәндә, Илүсә яши торган урамның башындагы базар турында басып тора иде.

Базар ябылган инде, әмма тротуарның ике ягы буйлап сузылган чәчкә сатучылар үз урынында. Ниндиләре генә юк! Уңда әби-апалар тезелеп баскан — кулларында кызыл тюльпаннар, ак, шәмәхә сиреньнәр, зәңгәр күзле миләүшәләр. Болары үзебезнең як гөлләре. Сулда брезент түбә астында, чәчкәләрнең ерак илләрдән китерелгәннәре — озын сабаклы, эре, җете розалар, бөдрә хризантемалар, исемнәре билгесез чит ил гүзәлләре.

Элеккерәк елларны бергә укыган иптәшеңне котлар өчен чәчкә табып булмый иде. Ярый әле әбекәйләр, язын ландыш, җәен ромашка җыеп, урам чатына чыгып басалар иде. Хәзер әнә чәчкәләрнең без моңарчы күрмәгән төрләләрен очкычлар белән әллә кайсы ерак илләрдән ташыйлар. Гөлгә уралган киләчәкнең хәбәрчеләре кебек алар...

Күңелдә каяндыр хәтергә кереп калган җыр яңарды:

> Яннарыңа киләм, кызыл гөлләр,
> Язгы гөлләр тотып кулыма...

Мортаза спорт чалбарының арткы кесәсен капшады. Затлы розалар алырлык акчасы юк югын, әмма тюльпаннар арзан лабаса... Бәяләре зур булмаса да, күз явын алырлык үзләре, йөрәккә капкан ялкын телләре кебек янып торалар...

Ак тәлгәшле сирень алыргамы әллә? Әнә нинди нәфис, хуш исле алар... Мөгаен, арада биш таҗлылары да бардыр... Илүсә кичен, хуш искә уралып, биш таҗлысын эзләп утырсын әле...

Мортаза өч тюльпан, бер сирень ботагы алды.

Чәчкә рәтләреннән узгач, ике ягына бишәр катлы «хрущевка» йортлар тезелеп баскан тыныч урам башлана. Аларның котсызлыгын яшерергә теләгәндәй, юлның ике ягына биек тупыллар, каеннар тезелеп баскан. Нигә язмыш Илүсәгә илтә торган бу урамны шундый ямьле итте икән? Мортазаның үкенечләре әрнүлерәк булсын дипме икән әллә?

Нигә бара ул бу урамнан? Якын да килмәм, дип, үз-үзенә ант эчкән иде бит инде! Ләкин менә шушы минутта тапталган җанын, кешелеген терелтергә кирәк аңа. Ә моның дәвасы — фәкать шушы урамда, шушы юлларда... Һәм Илүсәнең йөзендә, күзләрендә...

Ә ник әле Мортазага үзен шушы дәвадан мәхрүм итәргә? Шәһәр урамы бу лабаса, кем теләсә, шул йөри. Туры килсә, һәр узгынчы Илүсәгә дә, күз тутырып, туйганчы карап кала ала.

Илүсә яши торган таш йорт урамда бердәнбер — тугыз катлы, бер генә подъездлы. Төзүчеләр аны «нокта» дип тә атыйлар. Ишек төбеннән каршы йортның диварына кадәр иркен генә аралык калдырылган, анда киңәеп өрәңге, карагайлар, берничә миләш үсеп утыра. Шул рәвешле, ике урам арасында үзенә күрә ярыйсы гына ышык, тыныч урын хасил булган.

Илүсәнең йорты да, ул йөргән юллар да башкаларга охшамаган, үзенә бер төрле шул...

Агачлар арасында гади генә такта эскәмия бар. Мортаза шунда барып утырды. Ерак та түгел ике яшь хатын сөйләшеп тора, икесе дә куллары белән бала арбасының тоткасына ябышкан. Берсенең арбасы зәңгәр, күрәсең, ир баладыр. Икенчесе аллы-гөлле чуар. «Малай микән, кыз микән?» Элегрәк ир балаларны, зәңгәр тасма белән биләп, зәңгәр арбага салалар, ә кыз балалар өчен тасманың да, арбаның да кызылын сайлый торганнар иде. Хәзер менә мода үзгәреп килә. Нинди бәби үстергәннәрен ятлар белмәсә дә ярый, ди торганнардыр. Ә Мортаза үзенекен белгертеп йөртер иде. Кызылы булса — мактанып, зәңгәре булса — горурланып...

Кинәт аның ярым кысылган күз кабаклары астында аермачык булып Илүсә пәйда булды. Ул әнә чәчкәле арбаны салмак кына тәгәрәтеп тупыллар арасыннан бара. Сиртмәле биек тәгәрмәчләр, саф көмештән ясалгандай, кояш нурларында елык-елык килә — мактанчык малайларның велосипеды кебек. Чөнки арбада ир бала тирбәлә. «Чуарны алып дөрес эшләмәдек бит әле без, — дип, Илүсәнең иңбашына орына Мортаза. — Әйдә, яңаны, зәңгәрне алыйк. Монысын куеп торырбыз. Кыз алып кайтканчыга кадәр...»

Тукта, нишлим мин, болай уйларга ярамый... тынычланырга кирәк, дип, карашын аяк астына төбәде ул. Ә анда, дистәләгән аяк таптаган, такырланып беткән көлсу туфракта, тереклек ияләре яшәү өчен тырмаша. Бәбкә үләне нечкә сабакларын, нәни яфракларын калкыткан. Әнә бака яфрагы чәчкә сабагы чыгарган хәтта. Җимешләнә алыр микән? Орлыгын шушы тапталган туфракка сибеп, киләсе җәйдә тагын тишелеп чыгар микән? Чыгар, әлбәттә. Адәм баласы аны ничек кенә таптаса да, күпме генә интектерсә дә, тереклек юкка чыкмый.

Шушы эскәмиядә янәшә утырганда, Илүсә, бу үләннәргә карап уйланып:

— Җир буйлап кеше бара, кеше артыннан чүл бара дигән сүз бар, — дигән иде. — Ләкин бу сүзләр кешенең үз аягы белән йөрүе хакында түгел. Заводлар, машиналар турында әйтелгән бу. Аларны тереклеккә зыян салмый торган итәргә кирәк.

Илүсә менә шундыйрак итеп Мортазаны «агартырга» ярата. Күптән мәгълүм хакыйкатьләрне аның авызыннан ишетү Мортазага да чиксез рәхәт. Сөйләсен генә. Аның сүзләре мөһим түгел, тавышы тыңлап туйгысыз.

Үләннәрне экологлар, табигатьне саклаучылар кайгырта. Ә менә Мортаза кебекләр турында кем уйлар? Аны да таптап уздылар түгелме?..

Кинәт кемдер дәшкәндәй булды, Мортаза сискәнеп башын күтәрде. Арырак, урамның икенче ягында, Илүсә басып тора иде. Әле генә троллейбустан төшкән булса кирәк, бер төркем халык арасында светофорның яшел уты кабынганын көтеп тора. Бу якка карарга вакыты юк, башын сулга борып, янынннан узган машиналарны күзәтә.

Менә кузгалды да ашыгып урам аша уза башлады. Ул якынайган саен, Мортазаның йөрәге ныграк типте. Ни әйтер ул аңа? Мине кимсеттеләр, дип зарланырмы? Үзен кызгандырырга тырышырмы? Аның тар җилкәсенә башын салып, күз яше түгәрме?!

Мортаза кинәт борылды да, агачларга ышыкланырга тырышып, ашыгып каршы як урамга таба китте.

...Баракка кайтып керүгә, күрше Флерага юлыкты. Һәм кулындагы кызыл тюльпаннар белән ак сиреньне аңа сонды.

— Махсус сезгә дип алып кайттым, — диде.

Хатынның сулган йөзе үзгәреп китте, күзләре зур булып ачылды.

— Миңа?! Нинди очрак белән?

— Иң якын кешемә бирермен дип алган идем. Сездән якыны юк икән, — диде Мортаза.

Һәм бүлмәсенә кереп китте. Флера исә дулкынланудан хәле бетеп басып калды.

R R R

...Иң үзәкне өзгәне шул — Вилен Заһидәгә адресын әйтергә өлгермәгән иде. Иң беренче эш итеп шуны әйтәсе калган да бит, болай кинәт аерылышырбыз дип кем уйлаган. Бар өмет әлеге дә баягы һаман шул бер тикшерүче Сидоровта иде. Вилен, сабырлыгы җиткәндә, көн аралаш, инде түзәр хәле калмаган чакларда һәр кичне таныш бакчага барып, бронзадан коелган шаян малай каршысындагы эскәмиягә утыра да урамның теге ягындагы ишектән Сидоровның чыкканын көтә. Ләкин картның чырае һаман караңгы, күзлеге үк өметсез ялтырый иде. Җәй уртасы узды, көннәр көзгә авышты, фонтан тирәсендә кашкарыйлар чәчкә атты. Виленның күңеле исә корыган түтәл кебек иде. Ул ябыгып-суырылып китте хәтта.

Ниһаять, көткән хат килде. Заһидә чибәр, кайнар канлы булуы өстенә зирәк тә иде шул, чарасын тапкан, хатны тикшерүчегә юллаган, Виленга дигәнен исә шуның эченә салган. Бер бит кәгазьне кулына алгач, егетнең авызы колагына җитте.

Хат кыска, хәлем зарланырлык түгел, бер кырым татары гаиләсенә фатирга керттеләр, мәктәпкә җыештыручы булып эшкә урнашырга йөрим дигән гап-гади сүзләрдән тора иде. Вилен юллар арасыннан назлы сагыну сүзләрен эзләде. Таба алмагач, бу хатның чит күзләр аркылы узасын белгәнгә күрә, күңелендәген кәгазьгә түгәргә кыенсынгандыр, дип, үзен юатты. Җавабында исә, бутала-бутала, сагынулардан саргаюы, аны гына уйлавы, озакламый янына барачагы турында язды.

Бәхетеннән башы әйләнгән егетнең күңеленә монда берәр төрле мәкер юк микән дигән шик килмәде. Хәлбуки Сидоров Заһидәнең хатын Виленга бирүдән элек полковник Канчуровка күрсәткән иде.

Касыйм хатны, разведканың бик кыйммәтле документы кебек, фоторәсемгә төшереп алды. Шактый гына уйланганнан соң, гашыйкларның арасын өзү ансат булмас, ахрысы, дигән нәтиҗәгә килде ул. Энекәшнең ни кыланырын белеп булмый, дуамал, башбирмәс Канчуровлар нәселеннән бит ул! Шуңа күрә мәгъшукларны тоташтырган хисләр җебен әкренләп нечкәртү, зәгыйфьләндерү ягын карарга кирәк иде. Разведка кешесе моның чараларын яхшы белә, мөмкинлекләре дә җитәрлек иде, билгеле.

Ул үзенә почерклар остасын чакырып китерде. Бик тә яшерен һәм четерекле вазифаларны башкара торган пеләш башлы, чал мыеклы, юан корсаклы бу адәм хатын-кыз җенесенә ифрат хирыс иде.

Полковник, аның майлы, ялагай чыраен күрмәс өчен, карашын өстәлгә төбәп, кыска гына үзенең гозерен аңлатты:

— Моннан бер кыз бала сөргенгә җибәрелгән иде, — диде ул. — Менә шуны ничек итеп анда яхшы гына урнаштырып булыр икән?

— Кушыгыз гына! — диде белгеч.

— Фәрман биреп йөри торган эш түгел шул бу, — диде сабыр гына Канчуров. — Шәхси танышларымның кызы иде. Алай-болай рәнҗетсәләр, бик үкенечле булачак. Чит җирдә берүзе, туган-тумачасы да, яклаучысы да юк... Мондый очракта сез нинди киңәш бирер идегез?

— Кая озаттылар соң аны?

— Казахстанга, Семипалатински өлкәсенә...

— Кыз кеше дисезме?

— Яшь кыз шул. Беренче курста гына укый иде әле.

Язу остасы озак уйлап тормады:

— Кияүгә бирергә кирәк аны! — дип, күзләрен майландырып елмаеп куйды. — Алай-болай берәрсе бозып ташлаганчы, дим. Ул якларда тәртип каты, берәрсенең кулы тисә, беркем аңа өйләнмәячәк. Шуңа күрә, эшне озакка сузмыйча, бер яхшы гына егет табарга да...

— Мәҗбүри кавыштырып булмас шул аларны, — диде моңа каршы Канчуров. — Патша заманнарында Сахалинга каторгага килеп төшкән хатын-кыз затын шундук хатынлыкка алып китә торган булганнар да бит... Чехов әнә шулай дип язган...

— Шәп кагыйдә булган ул! Хатын-кызны ялгыз яшәтәләрмени!

— Хәзер андый тәртип юк шул.

— Кем кулына эләксә, шул файдаланачак инде аны.

Касыймның чырае тартышып куйды.

— Шул шул менә. Ә мин, үзең дә аңлыйсыңдыр, андагыларга командир түгел. Тора салып кысылып йөреп булмый...

— Нәрсәгә сезгә кысылырга? Җибәрегез мине!

— Андагы коллегаларга илтеп тапшырасы документлар да бар иде барын... — диде Касыйм, әле генә башына килгәндәй. Хәлбуки ул боларның һәммәсен алдан ук уйлап куйган иде инде. — Шул йомыш белән барсаң гына инде...

— Бер уңайдан ялгыз кызыкайның да язмышын хәл итеп кайтыр идем, — диде пеләш адәм.

— Тик шунысы... ул кыз мондагы бер егет белән хат алышып тора...

— Анысы кыен эш түгел, араларын тиз суытырбыз!

Полковник, өстәл тартмасын ачып, Вилен белән Заһидәнең язу үрнәкләрен, хатларының фоторәсемгә күчермәләрен алды да почерклар остасына сузды.

— Кыз ягын үзең карарсың, ә егет мәсьәләсендә саграк эш ит, — диде. — Бик кызу канлы, берәр нәрсә сизсә, әлләниләр кыланып ташлавы ихтимал. Ашыкма! Иренмә дә. Еллар буе, мине яраталар, көтәләр, дип ышанып йөрсен шунда. Тегесенең койрыгы бозга катканчы, берни белмәсен!

— Аны гына эшлибез!

Бу адәм кешеләрнең почеркын гына түгел, психологиясен дә яхшы белә иде, Семипалатинскида үзенә кирәк бәндәләрне тиз тапты. Заһидәгә әледән-әле бәйләнеп, якынлык кылырга тәкъдим ясап торырга, аны, чарасыз итеп, кияүгә чыгарга мәҗбүр итәргә кирәк иде. Моны эшләргә бик теләп алынучылар табылды. Кыз карап торырга чибәр генә, поселокта егетләр җитәрлек. Сайласын күңеленә хуш килгәнен!

Вилен белән Заһидәнең барча хатлары пеләш башлы аша уза, дөресрәге, аның өстәлендә кала, ә тегеләргә исә ул язганнар китә башлады. Командировкадан әйләнеп кайткач, ул, озакка сузмыйча, Вилен кулы белән язып, мондый хат юллады: *«Кадерле Заһидә! Кичер мине! Мин сине шулкадәр яраттым, синең йөрәгеңә яра ясап, дөресен әйтергә җөрьәт итмәдем. Минем ярәшкән кызым бар иде. Ах, әгәр дә без йөрәк кушканча гына яши алсак икән! Ләкин бу дөньяда намус дигән сакчы да бар бит әле. Намусым минем элегрәк биргән антыма хыянәт итәргә юл куймый. Син мине аңларсың, гафу итәрсең дип өметләнәм. Озакламый безнең туебыз булачак. Синең дә үзеңә тиң яр очратуыңны телим. Бәхетле бул! Каргама мине, Заһидә! Әгәр син каргасаң, миңа начарлык теләсәң, мин мәңге бәхетле булалмам! Син минем бәхетсез булуымны теләмәссең бит, Заһидә?!»*

Бу хәлләр хакында берни белмәгән Вилен хат язуын дәвам итте. Тик аның хатлары, көньякка таба юл алмыйча, Иске шәһәрдәге бинаның бер бүлмәсендә кала, аңа җаваплар да шунда языла иде. Асылда Вилен айлар буе Заһидә белән түгел, пеләш башлы, капкорсаклы адәм белән хат алышты...

R R R

...Төн карасы Мортазага уй-кичерешләрнең тагын да ачыракларын алып килде. Урам якның яктысы идәнгә тәрәзәнең рәшәткәләре арасыннан имгәнеп төшә, өй турыннан әледән-әле, әкияттәге аждаһа кебек улап, диварларны селкетеп, машиналар узып китә. Дөнья шомлы, ә бүлмә эче кысынкы, тар, сагышлы иде.

Бизәкле капка төбендә булган хәлләр күз алдыннан чагылып узды да күңелдә янә язмышка рәнҗү, ярсу хисе уятты, үч алу теләге кузгатты. Ак эшләпә кигән, тук чырайлы адәмне, елтыравык машинасыннан тартып чыгарып, бәргәләргә, типкәләп җирдә аунатырга иде! Әгәр инде атасыннан үч алып булмый икән, малае җавап бирсен! Ни өчен әле бар бәхет Канчуров нәселенә генә булырга тиеш? Шәп машиналарда йөрү, хан сарае кебек иркен йортларда яшәү, затлы ресторханнарда ашау, Канар утрауларына барып ял итүләр аларга. Чибәр кызга өйләнеп, бәбиләр алып кайтып, аларны сөеп үстерү дә аларга! Ни өчен? Акыллы йә сәләтле булганы өчен дә, тырышлыгы өчен дә түгел, һәммәсе тумыштан бирелгән аңа! Атасының кылган явызлыгы өчен бирелгән!

Мортазага, аның әнисенә карата явызлык кылып алганнар алар бу бәхетне! Аңлатырга кирәк аларга моны! Үкендерергә, тәүбәгә китерергә кирәк! Югыйсә бу җирдә бернинди гаделлек булмаячак!

Төн шулай, хаста кебек кайнарланып, әрнеп узды.

...Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, бер килсә гел килеп кенә тора бит ул. Икенче көнне иртән аны цех начальнигы чакырып алды.

— Мин сине сакларга бик тырыштым, — диде, — ләкин хәзер бернинди мөмкинлек калмады. Сиңа бездән китәргә туры килә. Алай да күңелеңне бик төшермә, хәзер җәй, бер тамагыңны туйдырырлык шөгыль табарсың ничек тә. Гаиләле кешеләргә читен. Ә буйдак егет ачтан үлмәс.

Элекке айлар өчен завод Мортазага ундүрт мең акча тиеш икән дә, анысын хәзер генә бирә алмыйлар икән. Мөмкинлек булуга расчет ясалыр, дип вәгъдә бирде бухгалтер.

Мортазаның кесәсендә исә нибары ике йөз сум калган иде. Бик сузып тотсаң, бер атналык.

...Кичке уңайда ул тагын теге затлы бина янына килде. Тәбәнәк рәшәткәгә таянып шактый көтте. Кичәге маэмайлар да шул тирәдә чуала, сирәк-мирәк узгынчыларга өргәләп ала иде.

Менә олы урам ягыннан, салмак кына шуышып, таныш «Ниссан»ның борылганы күренде. Зәңгәр халатлы урам себерүче, каян күреп алгандыр, йөгереп килеп капканы киңрәк ачып җибәрде. Машина эчкә кереп туктады. Шофер ашыгып чыкты да уң як арткы ишекне ачты — аннан тар ак чалбар, кендектән югары ак майка кигән, иңенә ак сумка аскан, озын торыклы, буялган аксыл-сары чәчле кыз чыкты. Арткы сул як ишекне исә урам себерүче ачты, аннан ак эшләпәле кеше күренде.

— Канчуров!

Кинәт яңгыраган таләпчән тавыштан Марат туктап калды. Мортаза аңа таба атылды. Бәреп егачак иде ул аны, салып таптаячак иде. Әмма ничектер ике арага сары чәчбикә килеп кергән булып чыкты. Мортаза кызны читкә этеп җибәрде, әмма Маратның йөзенә сугасы урынга эшләпәсен генә бәреп төшерә алды — Канчуров иелеп өлгергән иде. Чын мәгънәсендә шушы заман егете иде ул, ә андыйлар өстәл артында акча санап кына утырмый, менә дигән тренажерлары, тәҗрибәле тренерлары булган спорт залларына да йөриләр. Джиу-джитсу яки самбо алымнарын белмәгән егет адәм рәтле дип саналмый да. Марат, астан селтәнеп, Мортазаның иягенә китереп сылады һәм, беләген каерып, аны болгап атты. Ул арада шофер егылып яткан Мортазаның бөеренә типте. Бина ишегеннән тагын икәү йөгереп чыкты...

Бетерәчәкләр иде аны, изеп ташлаячаклар иде. Ләкин Канчуровка үз офисы янында кеше үтертеп, ыгы-зыгы куптаруның һич кирәге юк иде. Ул тузанда аунап яткан эшләпәсен алып каккалады да машинасының ачык ишегеннән утыргычка ыргытты. Мортаза тирәсендә мәш килгән егетләргә:

— Җитте, җитте, — диде. Аннары янәшәдә тыныч кына басып торган сары чәчле кызны култыклап алды.

— Что за избиение младенцев! — диде кыз, иркә тавыш белән. — Җыелышып бер сабыйны тукмыйлар димени! Дамалар күз алдында болай кылану ярамый! Тый син боларны!

— Булыр сиңа сабый, — дип, тынына буылып кычкырды берсе. — Кемдер котыртып җибәргән аны!

Марат шаркылдап көлеп җибәрде.

— Кем җибәрсен мондый көчекне? Кем аңа акча әрәм итсен! Әнә Бэлланың ухажерыдыр әле! Шулаймы, Бэллочка? Дөрес әйтәмме? Ну, милая, ник бу хәтле ачуын китердең син аның, ә? Үзеңне яраткан кешене кызгана белергә кирәк, җаныкай!

— Ну, Маратик, — дип назланып, аның иңенә сарылды кыз. — Бөтен ахмаклыкны да көйсезлекне миннән күрәсең. Ташла әле шул яман гадәтеңне!.. Минем аны гомеремдә күргәнем юк.

— Ә ул сиңа читтән күз салып йөргәндер... Инде, ниһаять, менә шушылай синең дикъкатеңне җәлеп итмәкчедер!..

— Ну, Маратик!.. Һәр дурак өчен мин җавап бирә алмыйм бит инде!..

— Әйтәм ич, берәрсе яллап җибәргән!.. — диде сулышына кабып мыеклы адәм.

— Кесәсен карагыз алайса! — диде Марат. — Булган кәгазьләрен алыгыз. Аягына баскач, үзе үрмәләп килер. Тик монда ятмасын! Ераккарак чыгарып ташлагыз! Шулай бит, Бэллочка?

Һәм алар, култыклашып, ишеккә таба киттеләр.

Мортазаның спорт чалбары кесәсеннән паспортын, заводка пропускысын, бар булган акчаларын алдылар да, өч ир, өч яктан тотып, бакча юлы аша урамга таба сөйрәделәр.

— Тор, көчек, ишелеп ятма монда! — дип тибеп куйды берсе, китәр алдыннан.

Мортаза шактый вакыт һушын җыя алмый ятты. Сирәк-мирәк узгынчылар аның тарафына күз генә салып узып китә бирделәр: шәһәр урамнарында исерекләр шактый ауный, халык моңа күнегеп беткән инде. Ниһаять, ул көч-хәл белән торып утырды, тузанлы учы белән битен сөртте. Кулына кан сыланды. Чалбар кесәсеннән кульяулык алмакчы булды, ләкин кесәләре эчке ягы белән тышка асылынып тора иде.

Аның бөтен тәне сызлый, бигрәк тә эче авырта иде. Канчуров кебекләрнең иярченнәре адәм баласын ничек имгәтергә икәнен яхшы белә!

Ләкин, барсыннан да бигрәк, җанның сыкравына түзәрлек түгел иде.

Ул, авырлык белән торып, буш кесәләрен кире үз урынына кертте, чалбарын каккалады, бармаклары белән тузгыган чәчен тырнаштырды. Футболкасының итәген каерып, битен сөрткәләде. Һәм, янтая төшеп, аксый-туксый трамвай тукталышына таба китеп барды.

Аңа башта трамвайга, аннары троллейбуска утырырга кирәк иде. Трамвайда кондуктор бәйләнде, троллейбустан төшкәндә, водитель ишекне ябып куйды, исереккә санап, аты-юлы белән сүкте. Аңа кушылып утыргычлардагы картлар, карчыклар мыгырдаштылар. Алар инде мондый очракны ычкындырмый, чөнки, гомер буе авыр тормышта яшәп, холыклары бозылып беткән. Ул каршы әйтмәде. Ниһаять, водитель ишекне ачты һәм, Мортаза төшкәндә, җаен туры китереп, артына тибеп калды.

Баракка кереп, бүлмәсенең ишеге төбенә килеп баскач кына ачкычларының да юклыгы Мортазаның аңына килеп җитте. Анысы да Канчуровта калган... Хәзер ул аның, хуҗасының аяк астына шыңшый-шыңшый шуышып килгән эт кебек, паспортын, ачкычын, пропускысын сорап килгәнен көтеп утырадыр, шул минутларда ничек кинәнәсен күз алдына китереп, астыртын елмаядыр. «Юк инде, андый ләззәтне бирмәячәкмен мин сиңа, — дип кырт кисте Мортаза. — Анысы ук булмас. Әгәр мин шунда барсам, әнием ни әйтер иде?»

Ул күрше бүлмәнең тырналып, көрән буяулары кубып беткән такта ишеген какты. Флера исә аш бүлмәсе ягыннан килеп чыкты да шаккатып аңа төбәлде:

— Ни булды?

— Заводта... Баскычтан егылдым, — диде Мортаза.

— Врачка күрендеңме соң?

— Карадылар. Үзебезнең поликлиникада.

— Бодяга сөртергә кирәк аңа. Бирмәделәрме? Алайса, һич булмаса, бака яфрагы ябыштырып куйыйк. Хәзер алып керәм.

— Мин анда ачкычны төшереп калдырганмын, ахрысы, — диде Мортаза.

— Соң, ачкычың бездә бар бит!

Мортаза, абыйсының вафатыннан соң, бер ачкычны Флераларда тота иде.

— Хәзер, бака яфрагы алып керәм! — дип йөгереп чыгып та китте Флера.

Мортаза кереп «Саратов» суыткычын ачты, аның өске тимереннән бер уч кар сыдырып алып яңагына, иреннәренә кысты, иягенә салкын су акты. Суыткычта ярты шешә сөттән гайре берни юк һәм якын киләчәктә нәрсәдер булырына өмет тә калмаган иде.

Флера, яшел яфраклар белән бергә конверт та тотып керде.

— Онытып торам икән, сиңа хат бар бит, — диде ул. Аннары, бераз ишек төбендә таптанып торгач, авыр сулап куйды. — Сиңа әйтергә дә оят инде, аптыраганнан гына... бер сүзем бар иде, Мортаза, — диде.

— Нәрсә аптырап торырга, чит кеше түгел лә, — диде Мортаза шешенгән иренен кулы белән кыскан яфрак аркылы.

— Аптыраган үрдәк арты белән чума, диләр... Башка чарам калмаганга күрә генә... — дип, һаман таптанды Флера. Кырыкка да җитмәгән бу хатынның сулган йөзендә нык икеләнү чагылды. — Сорап булырдай бөтен кешедән сорап чыктым инде. Альфредыбызның сандалиларыннан аяк бармаклары тырпаеп чыккан, өйдә утыра. Заводтан ачка үлмәслек продукция бирәләр дә бит, ипи белән маргарин ашап кына торып булмый. Алай җан саклый алсаң да, ялангач йөреп булмый. Бала үсә бит, киемнәре кечерәя!

Мортаза, бар булган акчамны заводтагы бер танышыма әҗәткә биргән идем шул, дип, гафу үтенде.

Хат Кырымнан, әтисеннән иде. Һәм шактый ук күңелне төшерә торган булып чыкты. Осман Асанин үткән атнада төнлә ниндидер билгесез кешеләрнең һөҗүм итеп, аларның һәм тагын берничә гаиләнең палаткаларын яндырулары турында язган иде. Бернәрсәсез коры далада утырып калганнар. *«Сине искә төшергән саен, сөенеп туя алмыйм,* — дип укыды Мортаза. — *Ни акылларың җитеп киттең син анда. Монда безнең туган җиребезнең туфрагы утлы булып чыкты. Ничек көн итәсебезне күз алдына да китерә алмыйбыз. Бигрәк тә балалар кызганыч. Улым! Мин синнән бик үтенеп сорарга мәҗбүрмен! Зинһар өчен, сеңелең Зареманы кайтып алып китсәнә! Быел унынчыга керәсе, ләкин кайда, ничек укыр, әлегә хәтле билгеле түгел. Җиткән кызга бу тормышта яшәү бигрәк авыр бит. Идрискә дә унбиш тулды, анысы үзебезнең янда ничек тә әрәм булмас. Егет булып килә. Ә менә Зарема кызганыч. Аның өчен бик борчылабыз. Сезнең анда тыныч, үз куышың бар. Зур заводта эшлисең. Беразга булса да сыендырып торсаң, аннары тагын күз күрер иде. Монда да берзаман тамырланып китәрбез бит инде...»*

Ни гаҗәп, боларны укыганнан соң, Мортазаның күңеле кузгалмады, тыныч калды. Ул гүяки үз-үзенә читтән торып карады. Бу хат аңа язылмаган иде. Башка берәүгә — Кырымга хәтле кайтып, әтисенең күз яшьләрен сөртергә, сеңлесен, янына алып, үз хисабына яшәтергә сәләтле, нык буынлы, хәлле егеткә язылган иде. Мескенлеккә төшкән, япа-ялгыз калган, тамырларыннан аерылган Мортаза кулына ялгыш килеп кергән хат иде ул.

Ул кәгазь битен кире конвертына салып, телевизор өстенә куйды. Бүлмәдә янә сагышлы күләгәләр ишәя, киңәя бара иде кебек. Бердәнбер якты нокта — дивар буендагы кечкенә кызыл сандык булып тоелды. Ләкин аның эчендәге истәлекләр дә Мортазадан ерагая иде шикелле.

Ул, өстәл янына утырып, кәгазь алды. *«Бу сандык Илүсә Бәдретдиновага тапшырылырга тиеш»,* — дип язды. Бераз уйланып торды да Илүсәнең телефонын өстәп куйды.

Аннары, почмактагы ак чиләкне алып, пешерү бүлмәсенә чыкты, краннан тутырып су агызды. Бүлмәгә кертеп, чиләкне диван янына куйды. Диван читеннән тәбәнәгрәк икәнен күреп, астына таба кыстырды. Утырып, кулына лезвие алды. Тик шундук, нидер исенә төшкәндәй, кире куйды. Каләм алды. Дәфтәр

битендәге язу астына: *«Илүсә! Син мине гаепләмә,* — дип өстәде. — *Мин сиңа һәммә серләрне чишеп бетерә алмадым. Мөмкин дә түгел, ә бәлки, кирәк тә булмагандыр. Тик шуны бел: мин сине яраттым, фәкать шул гына»*.

Ул сул беләген күтәрде дә нык итеп лезвие белән сызып җибәрде, диванга чалкан ятып, яралы кулын чиләктәге суга тыкты.

Бераздан ул ничектер тынычланып киткәндәй булды, әкренләп керфекләре авырая башлады. «Менә бу дөньяның тагын бер үги баласы китеп бара, — дип уйлады ул, үзенә читтән карагандай. — Туган иленең газиз баласы китә, дияргә дә булыр иде, бәлки. Ләкин баласымы соң мин бу илнең?» Мортаза үги әнисенең авыр тормыштан иртә җыерчыкланган кырыс чыраен күз алдына китерде. Ул апакай үз балалары Зарема белән Идриснең башларыннан ешрак сыйпый иде, билгеле. Туры килгәндә, кәнфитне дә аларга күбрәк биргәндер. Ләкин Мортазаны да ач-ялангач йөртмәде, укудан тыймады. Авырганда тәрбияләде. Әтисе белән бергәләп чын күңелдән кеше итәргә тырышты.

Ә соң менә бу ватан дигәне нинди мөнәсәбәттә булды Мортазага? Атасын, иленнән, ата-баба җиреннән сөреп, кол хәленә куйды. Анасын зинданга ябып, агу салды. Мортазаны туганчы ук нәселсез итте. Ватан шундый була микәнни?

Мортаза үч алырга теләгән иде, ләкин анысы да барып чыкмады. Ничек дигән әле шагыйрь Габдулла Тукай:

> Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
> Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым;
> Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:
> Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым...

Алмадым... Ә Илүсә дөньяны пакьләргә тырыша...

Мортазаның уйлары чуалды, башын томан сарды...

R R R

*«Кадерле Вилен! Бу хатны язу бик авыр, әмма язмый да булмый. Мин кияүгә чыгам. Ярәшкән кешемә синең хакта сөйләдем, ул һәммәсен аңлады, кичерде. Тик бер шарт белән: минем тормышымда син һичбер вакыт күренергә тиеш түгел. Хуш! Бәхетле бул!*

*Басу капкасын чыккач та, сулга каерылгач та,*
*Их, дускаем, рәхәт яшә, миннән аерылгач та...*
*Заһидә».*

...Бу юлы Виленны туктатып калырдай көч юк иде инде. Ул поездга утырмады, самолет белән Мәскәү аша китте.

Бер очкычтан икенчесенә күчеп, төнлә дә очарга туры килде. Көн яктырганын ул аэропортта көтеп алды, иртүк автобуска утырды.

Озакка сузылган очыштан, йокысыз төннән соң Виленның башын томан сарган, уйлары бутала иде. Биредәге мохит аңа бөтенләй ят тоелды. Мәскәүдә әле кар да эреп бетмәгән, ә биредә агачлар яфрак ярган, халык җиңелчә плащ, костюм киеп йөри. Тирә-юньдә айкалган кешеләрнең күбесе шәрекъ кыяфәтле булуы күзгә ташлана. Һәрнәрсә синең биредә чит-ят икәнлегеңне искәртеп тора кебек.

Заһидә монда ничек яши ала икән?.. Алып китәргә кирәк аны, бүген үк алып китәргә...

Ул эченнән генә шушы сүзләрне тәкрарлый, ләкин күңел түрендә моңа ышанычы кимегәннән-кими бара иде.

Исеме хат конвертларындагы адрес буенча гына таныш кечкенә поселокка ул төш вакытындарак барып җитте. Бу сәгатьтә Заһидә өендә түгелдер, дип уйлады. Һәм туры мәктәпкә китте.

Ике катлы бинаның коридорында тынлык, дәресләр бара иде. Аргы баштан яулык бәйләгән өлкән яшьтәге хатын килеп чыкты.

— Заһидә? Кадерматова дисезме? — дип кабатлап сорады ул гаҗәпләнгәндәй. — Башлангычта укыта бит ул. Аларның дәресе бетте инде.

— Кай тирәдә яшәгәнен әйтегез әле, зинһар.

Хатын аңа текәлеп карады да:

— Сез аның кеме соң? — дип, сорауга сорау белән җавап бирде.

— Мин?.. Дуслар без. Якташлар.

— Дус?..

Хатынның карасу чырае тагын да караңгыланып киткәндәй булды.

— Алдан мин барып әйтим аңа, хуп? — диде аннары. — Син монда торып тор. Кем килде дияргә соң?

Вилен, портфеленнән кәгазь-каләм алып, калтыранган кулы белән ашыгып сыргалады: *«Мин килдем, Заһидә! Вилен».*

Бу язуны алуга йөгереп килеп җитәргә тиеш иде ул. Ләкин, шактый вакыт узганнан соң, урамнан ашыгып теге апаның килгәне күренде.

— Бер сәгатьтән очрашырбыз, дип әйтте, — диде ул, күзгә туры карамый гына. — Әнә тегендә, автовокзал кафесы янында көтәргә кушты.

...Юл уңаенда бер хатын чәчәк сатып тора иде, Вилен аннан тюльпаннар алды да, ачык һавадагы өстәлләрнең иң кырыйдагысы янына утырып, официант малайдан чәй китерүен сорады. Өстәлләр тирәсендә кеше бетеп тормый, автобустан төшкәннәрнең кайберләре тиз генә тамак чылатып ала, кайсылары ныклап ашарга утыра иде. Ни өчен мондый ыгы-зыгылы, тузанлы урынны сайлады икән Заһидә? Аларга аулак җир кирәк бит!

...Ни зарыгып көткән булса да, Вилен аныерактан танымады. Халык арасында озын итәкле алсу костюм кигән, башына шундый ук алсу ефәк яулыкны бик килешле итеп бәйләгән, бала күтәргән яшь хатынны күргәч, үзалдына: «Менә бит, ямьсез киенгән бу кара халык арасында зыялылары да бар икән», — дип уйлап куйды.

Һәм карашын шундук икенче якка юнәлтте, узгынчылар арасыннан ак күлмәкле, эре кара бөдрәле таныш сынны эзләде.

— Исәнме, Вилен!

Вилен тынсыз калды. Аның каршында, сабый бала күтәреп, алсу костюм кигән Заһидә басып тора иде. Вилен торып басты да ике кулын сузды:

— Исәнме, Заһидә... Син... бөтенләй үзгәргәнсең... Танымаслык булгансың...

Заһидә, баланы сул кулына күчереп, бармак очлары белән генә егетнең учына орынып алды.

— Ә син һаман элеккечә икәнсең, Вилен.

Вилен тюльпаннарны аңа сузды. Заһидә, рәхмәт әйтеп, чәчәкләрне өстәлдәге биек стаканга, кәгазь салфеткалар янына кыстырып куйды. Аннары кара-каршы утырыштылар да сүзсез калдылар. Виленны телсез иткәне бала иде. Дүрт-биш айлык чамасыдыр. Зәңгәр куртка кигезгәннәр — малай булса кирәк. Башлыгы астыннан кап-кара чәчләре тырпаеп чыгып тора. Кемнең сабые бу?..

— Менә улым да үсеп килә инде, — диде Заһидә, аның әйтелмәгән соравына җавап итеп. — Гомер уза... берникгә дә карамый...

— Улым дисеңме? Заһидә... Син миңа, кияүгә чыгам, дип, әле генә яздың бит!

— Ни сөйлисең син, Вилен? Минем сиңа елдан артык язганым юк инде. Синең өйләнәм дигән хәбәреңне алганнан соң...

— Минме өйләнәм? Каян алдың син аны, Заһидә?

Заһидә, баланы тезенә утыртып, сумкасыннан конверт чыгарды. Вилен кулы белән язылган хат иде ул. Ләкин сүзләре... Аларны укыган саен, егетнең башында чәч төпләре кымырҗый башлады.

— Мин язмадым моны...

— Синең кулың түгелмени?..

— Минем кул... Ләкин... охшатып язганнар моны, Заһидә! Бу хата! Коточкыч мәкер! Моны...

Ул махсус органнар турында әйтергә теләде, ләкин телен аркылы тешләде.

— Син шушыңа ышандыңмы? — дип кенә әйтә алды ул.

— Син миңа баштук чын дөресен әйтмәгәнсең бит...

— Мин сине яраттым, Заһидә. Яраттым, яратам... Син мине яратмыйсыңмыни инде?

Заһидә, башын иеп, шыңшый башлаган баланың битенә битен терәде.

— Чү-чү, Мортаза... Кыбырсыма... Егет кеше бит син...

— Мортаза?

— Әйе, Мортаза. Әтисе шулай кушты.

— Әтисе... кем соң аның?

— Минем белән бер язмышлы кеше. Кырымнан. Укытучы. Бергә эшлибез.

— Заһидә, син аны миннән өстен күрдеңме?

— Судта мин сине көткән идем, — диде Заһидә, башын читкә борып. Ул гүяки каршысында утырган кешегә түгел, үз-үзенә сөйли иде. — Минем адвокатым Вилен Канчуров, ул килсен, дигәч, авызларын чалшайтып көлделәр генә. Шунда мин аңладым: син адвокат түгел икәнсең. Кем син?

Заһидә, күзләрен тутырып, аңа текәлеп карады. Аның карашыннан таныш нур, салават күпере кебек күп төсләрне, мең төрле хисләрне: мәрхәмәтле кайгыртуны, туганнарча якын итүне, аналарча куанычны, Ләйлә кебек сөюне... һәм шуның өстенә үпкәләүне дә, гафу итәргә, кичерергә әзер торуны да — һәммәсен,

һәммәсен сыйдырган яктылык бөркелде. Болай итеп фәкать ул гына, Заһидә генә карый ала иде, һәм Вилен аның өчен ярты гомерен бирергә әзер иде. Тик калган яртысы — җирдә яшәгән хәтлесе аның белән бергә генә узсын!

— Әйе, мин адвокат түгел. Ләкин сине якларга теләдем... Якларга тырыштым, Заһидә!

— Кем син?

— Минме? Һөнәремне беләсең киләме? Мин...

Виленның сүзе киселеп калды. Берничә җөмлә белән әйтә торган түгел, озаклап аңлатырга кирәк иде. Әмма дәүләт серен болай сүз арасында гына чишү, антыңны ансат кына бозу мөмкин түгел.

— Заһидә, мин сине алырга килдем. Әйдә, китәбез, — диде Вилен, аңа таба авыша төшеп. — Хәзер машинага утырыйк та китик. Баланы үз балам кебек карармын, Заһидә!

Малай кыбырсый, әнисенең күкрәк турын тырнаштыра, мөгаен, тамагы ачкан иде.

— Бу баланың хакы минекеннән өстенрәк, — диде Заһидә, малайның кара башын сыйпап. — Мин аны үз әтисеннән аермаячакмын.

Вилен, өстәл аркылы сузылып, аның беләгеннән тотты. Заһидә, аның бармакларын этеп, уң якка күз сирпеп алды.

— Кем ул анда? — дип сорады Вилен.

Аргырак өстәл янында өч егет утыра, берсе дә бу тарафка карамаган, үз сүзләре белән мавыккан иде. Ләкин аларның киеренке җилкәләреннән ничектер сагаеп утырганнары, дикъкатьләре бу тарафка юнәлгәне сизелде.

— Син бу баланың әтисен ияртеп килдеңме әллә?

— Әйе, ул монда, — диде Заһидә. — Бала анасының намусына тузан бөртеге дә кунарга тиеш түгел. Шуңа күрә...

Вилен, хәлсезләнеп, кире артка авышты. Ул чарасызлыгын аңлаган иде инде.

— Күзәтүчеләрең артыңнан йөри, ә син барыбер бала күтәргәнсең, — диде ул, рәнҗешен яшерә алмыйча.

Заһидә ялт итеп аңа күз генә салып алды. Вилен аның хәлен сүзсез аңлады. Бу минутта бала — анасының намус калканы иде. Әгәр кулында сабые булмаса, Заһидә сөйгәненең сузылган кулын кире этәрә алмас иде. Хисләрен тыярга көче җитмәс иде аның...

— Миңа китәргә вакыт, — диде Заһидә, баланы кулында тирбәткәләп.

— Бер генә сүз... Заһидә, соңгы үтенечем: әгәр бер-бер хәл килеп чыкса... Сиңа ярдәм кирәк булса һәм ул ярдәмне беркем дә күрсәтә алмаса... Син миңа, зинһар, хәбәр ит!

Заһидә аңа гаҗәпләнеп карады. Дәшмәде. Янә баласын иркәләде.

— Бу бик җитди, Заһидә. Шундый хәлнең булуы ихтимал, фәкать мин генә сиңа ярдәм итә алачакмын...

Бу сүзләрнең төп мәгънәсен аңлату өчен, Вилен үзенең шөгылен дә, Заһидәгә нинди укол ясаганнарын да әйтергә тиеш иде. Ләкин шул ук вакытта бу — Заһидәнең бәгыренә китереп ору белән бер булачак иде. Вилен моны эшли алмады. Ул эченнән, ул-бу була калса, мине исенә төшерми калмас, хәбәр итәр, дип юанды.

Алар кул бирешми генә хушлаштылар. Заһидә, Мортазаны күтәреп, шәм кебек төз, биек тупыллар тезелеп баскан аллея буйлап китеп барды. Кафедагы ирләр дә кузгалып, шул тарафка атлады, һәм тиздән алар артыннан алсу күлмәкле сын күренмәс булды. Соңгы очрашуның истәлеге булып сусыз стаканда кызыл гөлләр генә утырып калды.

...Мәкернең мәхәббәтне җиңүе беренче генә идемени?

R R R

Ул көнне Илүсә заводка тагын килде. Проходнойдагы турникетның әйләнмәле канатлары арасыннан узганда, аның күңеле каршылыклы хисләрдән бәргәләнде. «Ник килдем инде, йә? Монда мине көтеп торган кеше юк лабаса... Күргәч, кәефе генә кырылыр. Мине берәр төрле кимсетү, рәнҗетү ягын гына карар. Әгәр дә ачыктан-ачык сөйләшә алсак, бөтенләй башкача булыр иде дә бит... Ләкин ачылырга теләми шул ул... Ә бәлки, чыннан да, миннән гайрәте чиккәндер...» Мортаза турында шулай уйлады ул. Күңел бәргәләнә, әмма аяклар үзләреннән-үзләре шушы тарафка тарта иде. Һәм менә ул, элек килгәнендә төгәлли алмаган эшен тәмамлауны сылтау итеп, кечкенә чиләк, банкалар салган сумкасын күтәреп, проходнойдан үтеп китте.

Цехка кергәндә, тезләре калтыранганын тоеп, эчтән генә үзен тиргәп алды: «Ни булды сиңа? Нәрсә җебеп төштең? Ул караңгы чырай күрсәтә дип, дөньяң җимерелмәс ләбаса?» Ләкин йөрәк тынычлана алмый, һичкайчан булмаганча тынгысыз тибә, ниндидер бәхетсезлек булгандай шомлана иде.

Күңеле дөрес сизгән икән: Мортаза урынында юк иде.

— Бездән китте ул, — диделәр.

Илүсәнең кулыннан сумкасы төшеп китте, аның эчендәге пыяла савытларның чылтырап ватылганы ишетелде.

— Ничек «эштән китте»? Ни өчен? — дип, аңлый алмыйча кат-кат сорады ул.

— Аның ни гаҗәбе бар, — диде цех начальнигы. — Бездә кыскартулар бара бит. Күрмисезмени, цех тик тора.

Илүсә кинәт борылды да заводның проходноена таба йөгерде.

Ничек троллейбуска утырганын, ничек баракка барып кергәнен сизмәде. Мортаза өендә юк иде. Кыз урамга чыкты да башын иеп уйга калды. Ул инде үзенең үпкә-сапкаларын оныткан, бәгырьне бер генә борчу телгәли иде: Мортаза кайда, нишләп йөри? Теге чакта да, «стукач» дип, бер картны тотып тукмаган булган, бу хәлендә тагын әллә ниләр кыланып ташламагае. Аның дуамаллыгы белән! Янында бер тотынып торыр кешесе дә юк бит, ичмасам! Хәленә керүчесе юк...

Ә Илүсә егетнең хәлен бик аңлый иде! Тик моңарчы бу хакта ачыктан-ачык сөйләшеп аңлашырга җай гына табылмады... «Их, юләр мин, юләр, — дип тиргәде ул үз-үзен. — Узган юлы ник шулай борылып китеп барырга иде инде? Ул бит мине яратмаганга түгел, үзен миңа лаек санамаганга шулай кыланды. Аңлый идем, белә идем, тик горурлыгымны җиңә алмадым. Әгәр дә каядыр бөтенләйгә китеп барган булса?.. Ярый ла бер-бер фаҗига килеп чыкмаса...»

Шомлы уйлар учагында янып, урам уртасында сәгатьләр буе басып торып та булмый иде. Илүсә, ниһаять, троллейбуска утырды да эшенә китеп барды.

Ләкин җанга тынгы иңмәде. Киресенчә, эчнең януына чыдап торырлык түгел иде. Өйгә кайткач, әтисе аның йөзенә текәлеп карады да:

— Ни булды? — дип сорады.

— Барысы да тәртиптә, әти.

— Теге егет белән ачуланыштыгызмы әллә?

— Ник алай дип сорыйсың?

— Төсең качкан.

— Мин аны күрмәдем бүген.

— Әнисе турында тагын ниләр белде икән, сора әле син аннан.

— Газетага язарга дисеңме әллә?

— Ә нигә язмаска? Бик кызыклы язмышлар бит. Һәм гыйбрәтле.

Илдар Бәдретдинов башын иеп уйланып торды да:

— Андый язмышлар турында кешеләргә сөйләргә кирәк, — дип куйды. — Безнең барыбыз өчен дә бик зур сабак бу.

— Их, әти! Аның хәзерге хәлен белсәң иде!..

— Нәрсә? Ни булган?

— Үзем дә белеп бетермим...

Илүсә ашыгып халатын салды. Чалбарлы костюмын киде дә ишекне ачты.

— Син кая? — дип, аш бүлмәсеннән йөгереп чыккан әнисенә:

— Мин хәзер... — диде дә баскычтан аска таба томырылды.

Ярты сәгатьтән ул баракка атылып барып керде, бүлмәнең ишеген каерып ачты һәм диван янына барып тезләнде:

— Ни булды? Нишләдең син, Мортаза?!

Җавап булмады, ләкин Илүсә хәлне аңлаган иде инде. Ул чиләкне читкә этәрде дә, егетнең изүен ачып, яңагын аның күкрәгенә терәде. Йөрәгенең саңгырау гына лепелдәвен сизгәч, күзләреннән яшь атылып чыкканын тойды.

— Син исән, бәгърем! Исән! Исән!

Илүсә, егетнең салынып төшкән хәлсез беләгеннән кызыл тасма сузылганын күреп, диван япмасының почмагын теше белән ертырга тырышып карады. Булмады. Өстәлдән лезвие алып, каты тукыманы телеп җибәрде, аннан озын тасма ертып алды да Мортазаның беләген кысып урады. Аннары коридорга чыгып, күршенең ишеген шакыды. Флерага:

— Зинһар, «ашыгыч ярдәм» чакырыгыз! Мортазаның хәле начар! — диде.

Үзе, кире бүлмәгә кереп, диван янына тезләнде.

— Җаныкаем, ни булды? Нишләп болай күгәрде синең битләрең? Кайда болай кыйнадылар сине? Кайларда йөрдең син? Ник минем яныма килмәдең? Синең өчен ничек өзгәләнгәнемне белсәң иде...

Илүсә шулай сөйләнә, үзе тыелгысыз елый иде. Күз яшьләре белән бергә аның соңгы көннәрдә булган сызлануы, шикләнү-икеләнүләре агыла иде кебек. Ниһаять, ул сөйләнүдән туктады, тик сулкылдавын тыя алмады. Шунда Мортаза керфекләрен күтәрде:

— Сиңа килергә кирәкми иде, — диде, хәлсез тавыш белән. — Без барыбер... бергә була алмаячакбыз...

— Мортаза!.. Син мине яратмыйсыңмыни соң?

— Мин сине шундый яратам, Илүсә... Синсез яши алмыйм. Шуңа күрә дә мин... бүген...

— Син минем аркада... шушы эшне кылдыңмы әллә?

— Мин сиңа кирәк түгел, Илүсә... Син барысын да белмисең генә... Әгәр белсәң, шундук ташлап китәчәксең... Шуңа күрә бүген килмәвең яхшырак булыр иде...

— Мортаза, бәгърем, алай димә... Мин беләм, җаным... Барысын да беләм...

Илүсәнең күзеннән тагын тыелгысыз яшь агылды. Шул ук вакытта иреннәрендә елмаю яктысы кабынды.

Мортаза яткан урыныннан калкынырга омтылыш ясады.

— Нәрсәне... беләсең?..

— Соң... нәрсәне дип... Табибә ләбаса мин! Әллә оныттыңмы?

— Белгәч... Ник соң син монда?

— Мин дә бит синсез яши алмыйм, Мортаза! Син кирәк миңа.

— Ник? Ник кирәк мин сиңа?

— Мин яратам сине, Мортаза!

— Минем кебекне яратып буламыни?

— Ул бит... икәү арасындагы мөнәсәбәтләрнең бер ягы гына, Мортаза. Яратышкан кешеләрнең күңелен бер-берсенә мең төрле ефәк җеп бәйли. Салават күпере кебек. Безнең арада үрелгән җепләрнең берсе тоныклангандыр да, бәлки... Ләкин башкалары нык, ачык, таза бит, шулай түгелмени? Әгәр без бергә булсак, нечкәргән җепне ныгыту чарасы табылмасмыни?.. Ләкин минем бу хакта уйлыйсым да килми бүген... Син исән... Без бергә... Нинди зур бәхет... Әти дә сине чакыра... Ул көтә сине...

— Битләр рәткә кергәч инде...

Илүсә Мортазаның күкрәгенә башын салды. Егет кулы белән аны үзенә кысты. Аның да күзләре яшьләнгән иде, ләкин ул моны сиздермәскә тырышты.

R R R

Мортазаны бер атна хастаханәдә яткырдылар. Битендәге таплар исә ун көннән артыкка сузылды.

Илүсә белән алар көн саен очрашып тордылар. Күңелне кыршаулап, тынны кысып торган бикләр ачылды, җанга көн яктысы үтеп кергәндәй булды. Инде бернәрсәне дә яшермәскә, барысын да ачыктан-ачык әйтергә була иде кебек. Мортаза теге көнне ниләр булганын, үзен кем кыйнаганын да сөйләп бирде. Дөрес, кызгандырырга тырышып та, ярсып та түгел, ә бәлки, көлке итеп тасвирлады ул бу хәлләрне.

— Әгәр аяк астында әнчекләр болганмасамы? Теге салам чәчле кыз арага кереп кысылмасамы?

— Беләм инде, беләм, бетерә идең син аны! — дип көлә Илүсә. — Әле дә Алла саклаган!

— Ул шөкер итсен, ул! Аны Алла саклады!

Аңлашкач, киңәшкәч, бергә-бергә уйлашкач, элек бик авыр һәм гарьлек булып тоелган нәрсәләр җиңел генә хәл ителде дә куйды. Марат Бәдретдинов, редакция исеменнән «Вика» фирмасына шылтыратып, Мортазаның бөтен документларын соратып алды. Теге сугыш чукмарларының закон белән бәйләнешәсе килми икән, йөгерә-йөгерә һәммәсен китереп бирделәр, ике йөз тәңкә акчаны да кире кайтардылар хәтта.

Менә, ниһаять, кызның әти-әнисе белән танышыр көн дә килеп җитте. Мортаза Илүсәне эшеннән каршы алырга китте.

Иртәрәк иде әле, сәгать биш кенә, юл уңаеннан бераз әйләнеч ясап, шәһәр бакчасына керделәр. Домино сугып утырган бабайлар, эскәмияләрдә сөйләшеп утырган әбиләр яныннан уздылар, уртадагы киң агач диванга барып утырдылар.

Каршыдагы фонтан бихисап тамчыларын өскә бөрки, бронза савыт өстендә өрфиядәй рәшә хасил булган. Анда бик нәфис салават күпере тирбәлә. Төсле нурлар арасыннан шук мәхәббәт алласы алтын угын сузган... Тамчылар шыбырдап киң табакка коела, аның тирәсендә соң чәчәк ата торган кызыл тюльпаннар балкый.

Йа Раббым! Табигатьнең кодрәте белән адәм баласының якты хисләре, көлемсәр холкы, уңганлыгы, кулының осталыгы бергә үрелгәч, нинди гүзәллек хасил булган!..

Мортазаның күңеленә дә салават күпере төсләренә манылган җиңелчә томан саркыды, күз керфекләренә фонтаннан бөркелгән дым эленде. Ул гүяки тамчылар арасыннан мәхәббәт алласына таба

кулын сузып торган ак күлмәкле кызны күргәндәй булды. Аның да күңелен бизәкле рәшәдәй моң, ямансулык сарган. Менә кыз сынын турайтып басты, учындагы тамчыларны гөлләр өстенә сипте дә борылып читкә атлады. Ике ягына агачлар тезелеп үскән киң юл буйлап урамга таба китте. Аяклары җиргә тими, канат кебек киң җиңнәрендә очынып кына бара сыман. Менә ул урамга чыкты һәм каршы яктагы саллы бинаның ишеге янына барып басты.

«Ачма ул ишекне! Кермә!» — дип кычкырасы иде аңа...

Мортаза сискәнеп керфекләрен күтәрде. Имән ишек янында кеше-кара күренми иде. Гомумән, аннан керүче-чыгучы сирәк. Ләкин Мортаза бик яхшы белә: бинаның эчендә туктаусыз хәрәкәт бара. Анда гүяки зур бер тәгәрмәч — җепләре белән бөтен илне уратып алган, кешеләрнең бергәләшеп яшәвен тәэмин итә торган бинийая зур машина-системаның бер тәгәрмәче туктаусыз әйләнеп тора.

Адәм балалары булдырган система, аларның кулы белән ясалган һәм хәрәкәткә китерелә торган машина. Тик нишләп соң ул кешеләр файдасына гына эшләми? Нилектән ул Мортазаның әнисе кебекләрне эләктереп ала да изеп ыргыта? Ул тәгәрмәчне хәрәкәткә китерүчеләрнең күпчелеге: тикшерүче Сидоров та, табибә Эльза Бруновна да, башкалар да асылда начар кешеләр түгел бит югыйсә. Нилектән бу?

Илүсә сак кына аның иңенә орынды:

— Син нишләп болай моңайдың әле?

Мортаза ияге белән бакча юлының аргы башына — аннан күренеп торган бинага ымлады.

— Система турында уйлыйм, — диде. — Нигә ул шундый аяусыз икән?

— Система кызгану дигән нәрсәне белми, ди минем әти, — дип җавап бирде Илүсә.

— Ләкин нишләп? Ул бит давыл түгел, яшен түгел... Табигать афәте түгел. Җәмгыятьне кешеләр үзләре кора, бергә оешып яшәүнең тәртипләрен алар урнаштыра. Ягъни системаның нинди булуы аларның үзләреннән тора.

— Кемнәр «алар»? «Без» дияргә кирәктер. Без дә кеше бит!

— Ләкин бу... без урнаштырган система түгел... Мин нишли алам?

— Һәрхәлдә, җебеп төшәргә ярамый! Явызлыкка бирешеп торалар димени! Син менә баш иеп кенә яшәргә риза түгел бит! Йодрыгыңны эшкә җигәргә генә торасың!

— Анысы бар шул... Әнигә охшаган мин. Әнине дуамал иде, диләр.

— Әгәр синең әниең кебекләр булмаса, бу дөньяны тоташ явызлык басып киткән булыр иде инде, — дип нәтиҗә чыгарып куйды Илүсә. — Шундыйлар каршы торганга күрә, явызлык күпмедер авызлыклана, система да барыбер яхшыга үзгәртелә. Тик бирешергә кирәкми. Вәгъдә бир миңа: җебеп төшмәскә, бирешмәскә!

— Вәгъдә, вәгъдә!

Мортаза елмаеп аның кулын кысты. Һәм җанында да, тәнендә дә моңарчы сизмәгән ныклык тойды.

Ә мәхәббәт алласы көлеп-шаярып алтын угын төби, фонтан рәшәсендә салават күпере балкый, түтәлләрдә кызыл гөлләр керфекләрен ачкан, кояш гөлбакчаны, тынгысыз урамнарны — Иске шәһәрне дә, Яңа шәһәрне дә җылы нурга күмгән иде.

*2004–2005*

# Фидая

## 1

Шомырт чәчәк аткан чак иде. Төн. Тирән ярлар арасыннан аккан елганың ике ягына сузылып утырган авыл, биек, куе тирәкләр, өянкеләр ышыгына сыенып, йокыга талган. Агач башларына терәлгән салынкы болытлардан, яңгыр дисәң яңгыр түгел, дым коела кебек, ара-тирә йөгереп узган җил генә яфраклардан эре тамчыларны сибеп китә. Еракта, авыл өстендәге олы юлдан тигез гүләү ишетелеп куя, кайдадыр трактор гөрелди. Тик бу тавышлар авыл йортларын урап алган тынлыкны көчәйтә генә, ә урам баганаларындагы лампочкалар караңгылыкны куерта гына сыман. Мондый төннәрдә авылларда аеруча моңсу була; һәр йорт, башкалардан ерагаеп, бар җиһанда берьялгызы калгандай тоела.

Шунысы юата: май төннәре тиз үтә. Озакламый таң атар, иртәнге җил болытларны таратыр, яңгыр туктар, тирә-юнь, яшеллеге-чәчәкләре белән балкып, нурга күмелер. Әнә бит, төн карасы аша аксыл томан йомарламнары булып шәйләнгән шомырт агачлары да шундый иртәнең киләсен хәзердән хәбәр итә кебек. Шуңа күрә, алдагы таңның хәерле, ямьле булып туачагына ышанганга, һәммә җан иясе тыныч йоклый, килер көнгә көч җыя.

Хәер, барсы да йокламый икән. Әнә олы урамда мәктәп ихатасына урнашкан бер йортның өч тәрәзәсеннән дә гөлт итеп яктылык сибелде, алар каршында, энҗе бөртекләре булып, тамчылар җемелдәште. Караңгылыкны бозган бу тәрәзә артында ниндидер борчу, тынгысызлык, хәтта хәвеф бардыр кебек тоелды. Йокының татлы сәгатендә вакытсыз, урынсыз кебек иде ул.

Бу хисне тагын да көчәйтеп, йортның тышкы ишеге каерылып ачылды, эчтән бөркелгән яктылыкта күлмәкчән генә яланбаш хатын шәүләсе күренде. Менә ул, озын кунычлы резин итекләрен лаштыр-лоштыр китереп, ашыгып урамга чыкты, биегәйтелгән урта юл буйлап югары очка таба йөгереп китте. Сирәк лампочкалар, пыскак яңгыр күзне алыштыргангамы, әллә артык кабалангангамы, ул абынды-сөртенде, бер-ике тапкыр, янтаеп китеп, пычракка кулы белән таянды. Әмма үзе моны сизмәде дә кебек, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, сулкылдый-сулкылдый йөгерә бирде. Биегәеп, каралып утырган идарә, клуб бина元 турыннан узды, ниһаять, күпергә илткән киң тыкрыкның каршы ягындагы ихатага җиткәч туктады, пычранган бармагы белән капка баганасындагы кыңгырау төймәсенә басты. Якындагы багана башыннан төшкән яктылыкта капка түбәсендәге «Медпункт» дигән язу аермачык укыла иде. Хатын сабырсызланды, төймәгә озак-озак басып торды, аннары дөбердәтергә кереште.

Ниһаять, дымнан бүрткән өй ишегенең сыкрангандай шыгырдап ачылганы ишетелде, йокыдан айнып җитмәгән, әмма ягымлы хатын-кыз тавышы:

— Ишетәм, ишетәм, хәзер ачам, — диде.

— Мөнирә, мин бу! Киенеп чык тизрәк!

— Хәзер, хәзер. Үзең дә яңгыр астында торма, кер, — дип сөйләнә-сөйләнә капканы ачты Мөнирә.

Биш минут үткәндерме-юкмы, алар кире әйләнеп тә чыктылар. Мөнирә плащ кигән, юлдашының да иңенә куртка салган иде. Ишек төбендә аларны унбиш яшьләрдәге кыз бала озатып калды.

— Кызым, син дә озаклама, тиз генә киен дә килеп җит, — диде аңа Мөнирә.

Юлдашы бераз тынычлана төшкән иде булса кирәк:

— Аны кузгатмасаң да ярар, йокласын, — диде.

Аның тавышында баягы сулкылдау сизелми иде инде.

— Килсен, — диде Мөнирә гади генә. — Бәлки, ярдәме тиеп куяр.

— Үзең генә ярдәм итә алмассың микәнни?

— Кирәге чыкмаса, әйләнер дә кайтыр. Яшь кешегә нәрсә ул! — диде Мөнирә, тыныч, хәтта битараф булырга тырышып.

Алар ашыгып түбән очка таба киттеләр. Мөнирәнең сул кулында кечкенә чемодан, уңы белән юлдашын култыклап алган, аны егылудан сакларга тырыша иде.

Мәктәп ишегалдына кергәч, хатын:

— Иркә уянмаган иде әле, — диде.

— Шыпырт кына керербез, аны борчымабыз, — дип пышылдап диярлек җавап бирде Мөнирә.

Алар өйгә кереп озак та тормадылар, хатын янә урамга атылып чыкты, янә югары очка таба йөгерде. Бу юлы медпунктка түгел, аны узып, күперне дә чыгып, аръякка, куе, шомлы агачлар каршына рәт булып тезелгән йортларның берсенә. Үрсәләнеп капканы какты. Бу шакылдау бөтен урамны аякка бастырырлык иде кебек; күршеләрнең этләре яман өрде, кайдадыр казлар каңгылдашты. Ә эчтәгеләр көттерделәр, бик озак чыкмый тордылар. Ниһаять, ишек шыгырдады, калын, ачулы хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Ни кыланасыз ул хәтле? Ут чыктымы әллә?

— Машина кирәк! Машина! Мәгъсүм чирләп китте! Хәле начар! — дип үрсәләнеп җавап бирде хатын.

Эчтәге хатын, сөйләнә-сөйләнә, ашыкмый гына капка бикләрен ачарга кереште. Аның тавышы нык йомшарган, ул гадәте шулай булганга гына мыгырдана иде инде:

— Мин монда машина кочаклап ятаммы әллә? Янымда булса, шушы минутта чаптырыр идем дә, юк бит!

— Син бит авылның хуҗасы. Председательгә бармый, кемгә барыйм...

— Председатель дигәч тә, кемгә хуҗа соң мин? Төн уртасында урыныннан куптарып кара син берәр шоферны... Машинасын кабыздырып кара... Иртән нәрәттә әйтсәң бер хәл булыр иде...

— Нәрәтне көтеп үлеп ятсынмыни инде?!

— Уралга барып кара... Бәлки, аектыр... Мин кушты, диярсең...

Хатын кире йөгерде. Тагын бер капканы озаклап кагып, аннан чыкканнарын көткәнче, хәлне аңлатканчы, ир кешенең, машина ватык, кузгатып булмас, дигәненә төшенгәнче, әллә ни гомер узгандай тоелды.

Хатын кире йөгереп кайтканда, аның кызган маңгаена тамган яңгыр тамчылары чыжлап парга әйләнәдер кебек иде. Мөнирә аны ишек төбенә чыгып каршы алды, хәлне сүзсез аңлады.

— Бар, Гыйззетдингә йөгер, — диде. — Баштук шуңа гына эндәшәсе калган.

Гыйззетдин аръякта, председательнең күршесендә. Хатын кире йөгерде. Бу чабуларның очы-кырые булмас иде шикелле... Ләкин, ниндидер кодрәт белән, ниһаять, саташуга охшаган бу болгануның да ахыры җитте. Хатын кече капкадан керүгә, өй эчендә ут кабынып, ишек ачылды. Бу юлы озак аңлатырга кирәк булмады, өй хуҗасы Гыйззетдин ишегалды түрендәге «Нива» машинасын кабызып та җибәрде. Өйдән хатыны йөгереп чыгып, плащын, кепкасын бирде.

Аңарчы туктап калган кебек тоелган тормыш кинәт хәрәкәткә килде. «Нива», мәктәп турында туктап, фаралары белән түрдәге өй ишеген яктыртты.

Хатын машинадан төште дә йөгереп эчкә кереп китте. Озак та үтмәде, алар, шәфкать туташы белән икесе, озын буйлы ир кешене ике яктан култыклап алып чыктылар. Мөнирәнең кызы да килеп җиткән икән, ул да чыкмакчы иде, әнисе:

— Син монда гына йокла, Иркәгә иптәш булырсың, — диде. Аннары, каршыга килгән хатынга таба борылып: — Менә Зиләйләнең килүе яхшы булды бит әле, балаң өчен борчылып йөрмәссең, — дип куйды.

Мөнирә алга, Гыйззетдин белән янәшә, ир белән хатын арткы утыргычларга урнаштылар. Машина нык гүләп борылды.

Гыйззетдин:

— Район больницасынамы? — дип сорады.

— Кармашка барабыз, — дип җавап бирде Мөнирә. — Билал абыйга.

— Билал абый кебеге район больницасында юк инде анысы, — дип, ничектер бик йомшак кына аның белән килеште Гыйззетдин.

Машина, дымлы караңгылыкны фаралары белән ертып, әүмән-тәүмән килеп, авылдан чыгып китте.

Артта иренең биленнән кочып утырган хатынга хәзер инде сулышына кабып каядыр чабарга, кемнәргәдер хәленең авырлыгын кабаланып аңлатырга, ярдәм котәргә кирәкми иде. Хәл-әхвәлләр башкалар кулына тапшырылган. Башын суза төшеп, күн фуражка астыннан елтыр күзләрен алга төбәгән, вак яңгыр һәм туктаусыз чәчрәгән пычрак белән томаланган пыяла аша юл сикәлтәләрен күрергә азапланган Гыйззетдин, биш чакрым араны күпме вакытта узар да Кармашка кайчан илтеп җиткерер?.. Участок хастаханәсенең баш табибы Билал Газимов ни әйтер?.. Аннары хастаны ничек дәвалар?.. Берсенә дә катнашып та, газизенә ярдәм итеп тә булмый... Бу хәл хатынны шомландыра, җегәрен алып, хәлсезләндерә дә иде. Аның зиһене томаланып китте, аннан соңгы вакыйгалар хәтеренә яман төш кебек өзек-төтек кенә булып сеңеп калдылар.

Юлның сикәлтәләре хисапсыз, һәркайсында аның ире укшып куйгандай итә, бу тавыштан хатынның йөрәге тибүдән туктап коргандай була. Ул, плащ кесәсеннән кульяулык алып, иренә сузды. Ире авыз тирәләрен сөрткән иде, яулык каралды. Артына әледән-әле борылып караштырып килгән Мөнирә каяндыр алып мамык кисәге сузды. Ир кулында ул да тиз каралды, авырайды. Кан... Иң тирән чокырлар Кармаш урамында булса кирәк, алар соңгы көчне алды.

Участок хастаханәсенә, олы урамнан борылып, үргә менәсе иде. Ниһаять, килеп җиттеләр. Баш табиб, әлбәттә, монда түгел, өендә икән, аны машина белән барып алырга кирәк. Шуңа күрә эчкә ирнең үзен генә алып кереп киттеләр. Хатынның хәтеренә бик нык уелып калды: болдырда ире басып тора, биленнән хастаханәнең шәфкать туташы Гөлфия кочып алган. Кара плащ өстеннән, Мәгъсүмнең сынын икегә аергандай, ак халат җиңе сузылган. Ул, башын артка каерып, хатынына карый: суырылган, агарган йөзендә хәлсез елмаю. Юаткан да шикелле ул, шул ук вакытта бәхилләшкән дә кебек. Ишек өстенә беркетелгән лампочка яктысында бу караш, бигрәк тә машина эчендәге караңгылыктан караганга, бик ачык күренде. Лампа яктысы көчле иде, ул диварларның, ишекнең искелеген, тузганлыгын, бинаның кечкенә, шыксыз икәнлеген аеруча ачык итеп күрсәтте. Гүяки: «Күрегез, мәңгелек караңгылыкка илтә торган юлның башы менә шушындый була», — дип, аяусыз битарафлык белән кисәтә иде кебек ул. Кинәт: «Ул моннан үз аягы белән чыкмаячак! — дигән уй бәгырьне ярып узды. — Кире кайтмаска китергәнмен...»

Ах, үкенечкә булды аның бу уе! Югыйсә бит ул кулыннан килгәннең һәммәсен эшләде, ләкин шомлануы, алдан хәсрәтләнә башлавы, әлеге өметсез уе... Шушы ишек төбендә ул аның белән хушлаша башлады, араларның мәңгелеккә өзеләсен шул мизгелдә тойды. Һәм моңа иренең хәлсез елмаюы түгел, ә бәлки, хан заманыннан калган бинаның шомлы, битараф, салкын кыяфәте, рәвеше сәбәп булды. Гүяки аның эчендә инде бик күпләрнең соңгы сулышы өзелеп, караңгылыкта, бушлыкта юкка чыккан һәм бу биредә бик тә гадәти хәл иде.

...Ике көннән соң, бу юлы инде хасталарны йөртә торган «УАЗ» машинасында юрганга төрелгән тынсыз гәүдә янына утырып китеп барганда, хатын арткы тәрәзә аша, керфек тә какмый, күздән югалганчы, шул бинага карап барды. Дөрес, көн яктысында ул күңелне артык шомландырмый, чөнки аңа булдыра алган кадәр ямь кертергә тырышканнар: коймасын эчтән сарыга, тыштан зәңгәргә, тәрәзә яңакларын акка буяганнар. Әмма бу буяулар сиксән яшьлек карчык битенә ягылган иннек-кершән кебек

кенә. Күпме яңгырлар юып, күпме карлар сыйпап узган бу йортның туфрак төсенә кергән бүрәнәләрен? Күпме күзләр аларга өмет белән текәлгән дә яннарында күпме яшьләр түгелгән? Шуларга тагын берәүнең ачы яшьләре кушыла икән, аннан ни үзгәрә?

Менә юл борылды, алар авыл урамына килеп керделәр. Хатын як-ягын күздән кичерде. Нык ихаталар эчендә, түбәләре сырлап ясалган биек капкалар артында челтәрле кәрнизләре, иркен янкормалары белән көязләнеп утырган йортларны, авыл очындагы озын ак ферма биналарын, очарга әзерләнгәндәй зур-зур ракеталарга охшаш, борыннарын болытларга төбәп баскан силос манараларын күрде ул. Бу йортларда, бу биналар тирәсендә җиргә нык басып, эшләгәндә йөрәге җилкенә, ашаганда колагы селкенә торган кешеләр яши, алар тагын да шәбрәк өйләр салу, тагын да матуррак киенү, тагын да күбрәк рәхәт күрү турында уйлыйлар. Ә менә аяк астында җирнең ныклыгын тоймый башлаганнар өчен, йөрәге нечкә җепкә эленеп калгандай көч-хәл тибеп, сызланудан сыгылып төшкәннәр өчен, әҗәл белән йөзгә-йөз очрашканнар өчен — әнә шул калкулык өстендәге иске бина...

Бу уйлардан кинәт хатынның зиһене ачылып киткәндәй булды: «Ничек мин моңарчы бу хәлгә түзеп яшәдем икән? — дип уйлады ул. — Нигә мин бөтен халыкка: «Без нишләп болай ваемсыз, нигә без гомеребезнең иң авыр минутлары киләсен уйламыйбыз, нигә бу хакта алдан кайгыртмыйбыз?!» — дип кычкырмадым икән? Ни өчен мин: «Җанда гайрәт, тәндә көч бар чакта вак-төяк җитмәүчелеккә түзеп тә була, кеше кулларына калгач ниләр күрәсебезне алдан уйлыйк!» — димәдем икән?»

Ә бина әле нык тора, аны кузгатып та, үзгәртеп тә булмас шикелле, гүяки аның янында вакыт үзе туктап калган иде шикелле. Баш өстенә ишелердәй булып салынган болытлар да, үзәккә үтеп сибәләгән яңгыр да үтмәскә дип килгәннәр иде сыман.

## 2

Әмма гомер агышы туктамый, үтмәстәй тоелган яңгырлар да узып китә, дөнья үзгәреп тора.

Ул елның маенда да күк йөзен атналар буе каплап торган салынкы болытлар вакыты җиткәч таралды, үз нәүбәтендә җәй, аннары иртә кыраулы көз килде. Аннан соң тагын бер ел узып, көзге болытлар янә яшь коярга кереште.

Иртән күзен ачуга, Давыт: «Тагын яңгыр, — дип уйлады. — Һаман туктамаган. Коюын belә». Парланган тәрәзәләр болай да сүрән көн яктысын саран үткәрә, өй кыегыннан тигезле-тигезсез коелган тамчылар гүяки тыштагы салкын күлдәвеккә түгел, бәгырьгә тама иде.

Аш бүлмәсеннән Фазиләнең савыт-саба шалтыратканы ишетелде. Менә ул, ишектән башын сузып:

— Давыт, ишетәсеңме соң? — дип сорады. — Телефон шылтырый бит, ник алмыйсың?

Әйе шул, шылтырый, тик Давытның тыңлыйсы килми, чөнки күңеле рәтле сүз әйтмәсләрен сизә. Әмма кемдер аны бик кирәксенә, ахрысы, ямьсез зыңгылдау туктамый, колакны ертып, озак-озак кабатлана. Тыңламый котылып булмастыр, мөгаен.

— Алло!

Директорның секретаре икән.

— Давыт абый, хәерле иртә! — Тавышы дәртле, сөенче аламыны. Яшең унҗидедә чакта көзге яңгырлар гына кәефне җимерә алмый шул. — Телефонограмма сезгә!

— Йә, укып күрсәт әле. Туйга чакыралармы әллә?

— Ю-ук, туйга түгел! Нәрсәгә икәнен әйтмәгәннәр. «Урман хуҗалыгының баш инженеры иптәш Гаяровны сәгать тугызга иптәш Нурханова...» — Бу урында кыз тотлыгып калды. Аннары гаҗәпләнгәндәй: — «Үтенеп» дип яздырдылар монда... Нурханова Сезне үтенеп чакыра!

Телефонограммаларда мондый сүзне гомер очратмаган Давыт үзе дә сәерсенеп куйды. Ләкин аны тагын бер нәрсә гаҗәпләндергән иде әле.

— Кем ул Нурханова?

— Соң, шул... теге... Райкомның өченче секретаредыр инде! — диде кыз. — Күптән түгел яңаны сайлап куйдылар, дип сөйләгәннәр иде бит...

— Ә, әйе, җәй башында Гайнуллинны Казанга, министрлыкка эшкә алдылар. Аның урынына хатын-кызны куйганнар иде, моңарчы эш төшмәгәч, онытылып киткән.

Пычрак ярып районга барып йөрисе килми иде. Телефоннан гына сөйләшеп алсаң, ярамас микән? Әмма Давыт бу уеннан шундук кире кайтты. Беренче чакыруында ук бармый калу килешмәс. Аннары килеп, районда Давытның үз йомышы да бар иде.

Иренең сөйләшкәнен ишетеп торган Фазиләнең сукранганы ишетелде:

— Тагын районга чакыралармы? Синсез тора алмыйлармы әллә? Инде бер буш көнең бар, өйне карарсың дигән идем. Шимбә ләбаса бүген! Тәрәзә рамнары какшап беткән әнә, югач рәтләп ябып та булмады. Абзар ишеген дә карыйсы бар.

Давыт дәшмәде, аш бүлмәсенә чыкты да, өстәл янына утырып, чынаягына чәй ясады. Юынгыч янында сыерга он суы болгатып азапланган хатынының аркасына, кыршылган жакетына гаеп эзләп карады. Икесе дә озын буйлы, озынчарак йөзле, кара чәчле булгангамы, әллә холык-фигыльләрен дә охшатыпмы, аларны кайчакта абыйлы-сеңелле дип беләләр, танышлары да, бигрәк пар килгәнсез, ничек шулай табыштыгыз, дип кызыгып карый иде. Ләкин менә мондый көннәрне үзеңә охшаган хатыныңны түгел, үз-үзеңне күрәсең килмәгән чаклар була. Бигрәк тә каршыңда кирле-мырлы сүз сөйләп торсалар...

Фазилә борылып карамады, әмма иренең уйларын аркасы белән үк тоеп торган икән. Чиләген күтәреп, ишектән чыгып киткәндә:

— Бар, бар, юлда батып ятканда, әйткән иде бу, диярсең әле, — диде.

Давыт каты пешкән йомыркага төелә язды: «Ир өйрәтеп маташкан була тагын, йомырка пешерә белмәгән башы белән!»

Башка вакытта, «уазигы»н кабызып юлга чыккач, аның күңеле тынычлана, моторның тигез гөрелтесе гүяки йөрәк тибешен дә бер җайга сала торган иде. Әмма бүген алай булмады. Әллә томан, әллә вак яңгыр пәрдәсе астында каралып яткан шәрә басулар, соры-коңгырт яфракларын инде коеп бетерә язган, шәбәреп, мескен кыяфәткә кергән каенлыклар, алгы пыялага туктаусыз чәчрәп сыланган сыек лай эчтәге ачуны отыры кабарта гына барды. «Кайчаннан бирле коя бит инде, очы-кырые һич күренми!» Соңгы атнаның көннәре дә, соры су тулы юл чокырлары кебек, бертөсле, ямьсез, эчпошыргыч тоела иде.

...Шушы соры, салкын, юеш, күңелне изә торган сәгатьләрдә аның бөтен яшәешен үзгәртәчәк, язмышын хәл итәчәк вакыйгаларның яралганын, соңыннан үзенең дә нәкъ шушы иртәне күп тапкырлар сагынып һәм сызланып искә алачагын белми иде әле ул.

Хәер, безнең кайсыбыз гына киләчәген алдан күрә ала соң? Күпчелек очракта без, бу дөньяда һәммә нәрсә кабатланып тора, кичә баеган кояш бүген иртән тагын чыга, сүрелгән ай, атна үтүгә, яңадан туа, көз артыннан кыш килә, аннары яз җитә, дип уйлыйбыз. Ә бит бүгенге таң кичәгечә түгел, өченче көндәгечә дә түгел, бәлки, өр-яңача ата, җилләр бүтәнчә исә, кошлар башкача сайрый. Шәфәкъ нурлары да, офык сызыгы артыннан моңарчы күрелмәгән төсләр бөркеп, өянке-тирәк ябалдашларын яңача мана. Безнең баш очыннан бер мәртәбә агылып узган болытлар да беркайчан кире әйләнеп кайтмыйлар.

Тик безнең күзләргә — җетелек, күңелләргә сизгерлек җитенкерәми шул, таңнарның балкышларын һәм болытларның агышларын төсмерләре белән аерып күрә белмибез. Язмышыбызның борылышларын башында ук сизми калуыбыз да шуннан киләдер, мөгаен.

Райкомның аксыл-сарыга буялган ике катлы бинасы янына килеп туктагач, Давыт, машинадан төшеп, кызган йөзен, күтәреп, бераз вакыт салкын яңгырга куеп торды, суынырга, тынычланырга тырышты. Җитәкче янына кызуланып, кәефсезләнеп барып керү беркайчан да хәерлегә булмый. Ишектән бераз читтәрәк ләмле су тулы озынча калай савыт тора иде, Давыт андагы озын саплы пумала белән ботинкаларын озаклап юды.

Яңа җитәкче янына, бигрәк тә хатын-кыз каршына барасын уйлап, урманчылар формасын кигән иде ул. Эчкә кереп, гардеробка шинелен, фуражкасын элеп куйгач, зур көзге каршына басып, кителен тарткалады, бөтен кыяфәтен җентекләп күздән кичерде.

Формасы килешле аның, пөхтә-ыспай, үзенә таманлап махсус тегелгән. Буй-сын да, Аллага шөкер, кеше арасында югалып кала торган түгел, кая барса да, бер башка калкып тора — метр да туксан сантиметр! Куе кара чәче артык шома да, килешсез тырпаючан да түгел, җай гына дулкынланып ятып тора. Йөз ак, күзләр тере.

Өченче секретарьның бүлмәсе икенче катта, коридорның аргы башында ук иде. Ике яктан тезелеп киткән бертөсле ишекләр турыннан узганда, Давыт ирексездән чыраен сытты: пычкы чүбеннән укмаштырылган бу ишекләрнең өсте фанер булып, аңа, имән тактага охшатып, майлы буяу сыланган иде. Мондый ясалмалыкны күңеле кабул итмәгән Давытка биредәге бертөсле бүлмәләрдә утырган кешеләрдә дә шундый ук ясалмалык бардыр сыман тоелды.

Аргы баштагы ишек тә башкаларның игезәк сыңары иде. Аңа яңа язу кадаклаганнар: «Нурханова Фидая Госмановна». Сирәк исем, телгә дә бик үк җайлы түгел сыман... Бүлмәнең элекке хуҗасы Гайнуллинны исенә төшереп, Давыт көрсенеп куйды: ул, каршы килеп, ике куллап исәнләшә, өстәл аркылы түгел, янәшә утырып, ачык итеп сөйләшә торган иде. Дөньяның рәтен белә Гайнуллин, ә яши белгән кешегә урман кирәк — тормыш көткәндә дә, ял иткәндә дә... Менә хәзер ишек бикле булып чыкса, Давыт сөенәчәк кенә иде. Әмма аның бу яшерен өмете акланмады: йозакта бер бәйләм ачкыч эленеп тора,

димәк, хуҗа урынында. Давыт бармак буыннары белән фанер ишеккә суккалады. Эчтән яңгыравык нечкә тавыш ишетелде:

— Керегез!

Давыт, көрсенеп, эчкә атлады.

Иң беренче күзгә ташланганы гөлләр булды. Почмак бүлмә булганга, тәрәзәләр ике якка карый; төпләре тулы бүрек-бүрек кызыл чәчкә аткан яраннар, тамчы гөлләр. Биредә элек хөкем сөргән ирләрчә кырыслыкка күнеккән Давытның күзләре камашкандай булды.

Түр өстәл артыннан аягүрә басып кулын сузган хатынга карагач, ул тагын да ныграк сәерсенеп китте. Мондый кабинетларга, дәрәҗәле өстәлләр артына кереп утырган хатыннар гадәттә ир кыяфәтле, тупасрак чырайлы һәм эре бәдәнле була. Алар, бу охшашлыкны тагын да көчәйтергә теләгәндәй, кара яисә зәңгәр костюм киеп йөри. Ә бу исә челтәрле изүе күкрәкләренә сыланып, нечкә билен кысып торган, ачык көрән төстәге бәйләгән күлмәктән иде. Анысы бер хәл, иң гаҗәбе шунда — бу хатын чибәр, чынлап торып бик чибәр иде. Дөрес, Давытның исенә төште, район җыелышларында аның күзгә чалынып киткәләгәне булды, ләкин ул чакта аңа текәлеп каралмаган икән. Хәзер менә, якын ук килгәч, аның чибәрлеге гаҗәпкә калдыра, караган саен карыйсыны китерә. Бөтен җире килешле: сул яктан юл ясап таралган алтын-сары чәче дулкынланып иңнәренә төшкән, зәңгәр күзләренең карашы үткен һәм уйчан, түгәрәк ак йөзен бераз эрерәк, тигез, ак тешләре яктырта, тулышып торган иреннәренә чиста күңелле кешеләрдә генә була торган бераз кыенсыну катыш эчкерсез елмаю эленгән иде.

Фамилияләрен әйтеп танышканда, Давыт каушап китеп, аның кулын учында озаграк тотты, ахры, нечкә, нык бармаклар кош баласы кебек тыпырчынып куйдылар. Давыт кызарынганын тойды.

Нурханова үз өстәленә терәп куелган өстәл кырыендагы тирән кәнәфигә ишарә ясады — утырырга тәкъдим итте, Давытның фикере чуалганын сизмәмешкә салышмады, гади генә итеп:

— Форма кигән кешене күргәч, үзем дә бераз каушап киттем әле, — дип елмайды. Күренеп тора, үзе ул тамчы да каушамаган, моны фәкать сүзне ипле башлап җибәрү өчен генә әйткән иде.

Әмма Давыт биреште, саламга тотынгандай, сүзне ялгап китте:

— Безнең эш хәрби хезмәткә тиң бит ул, — диде, — белмәгән кеше каушап төшсә дә гаҗәп түгел. Урман сакчыларына форма киемен заманында Петр Беренче керткән. Килегез безгә. Бик шәп музеебыз бар, карап китәрсез.

Кәнәфигә утыргач, Давыт кинәт кечерәеп киткәндәй булды, өстәл артындагы биегрәк урындыкта утырган Нурханова белән тигезләнеп калды. Башкаларга өстән карарга күнеккән кеше өчен бу сәер иде, ул үзен җайсыз хис итте. Ләкин аягөсте сөйләшеп булмый бит инде! Ул аякларын сузып җибәргән иде, ботинкаларының өстәлнең икенче ягына ук сузылып чыкканын тойды. Нурхнованың шул тарафка күз салганын күреп, тезләрен өстәл аратасына бәреп, аякларын кире тартты. Каһәр суккыры, Гайнуллин заманында да шушы кәнәфигә утыра торган иде бит ул, аякларын кая куя иде соң әле? Җитмәсә, бүлмә хуҗасына ян белән утырып, муенны борып сөйләшү дә шактый җайсыз икән...

Ә Нурханова аның көйсезлекләрен сизми дә кебек, тыныч кына, нечкә тавыш белән, үзенең инде урман хуҗалыгы музеенда булганлыгын сөйли. Ул Баллыболын мәктәбендә директор булып эшләгән икән, урман хуҗалыгына укучы балаларны алып барган. Фанер цехында да булганнар, бизәкле кашык-савытларны ничек ясаганнарын да күргәннәр.

— Агач савыт-саба цехыгыз бик ошый безгә. Хәл кадәренчә ала идек без аларны. Мәктәп олимпиадаларында җиңеп чыккан балаларга бирү өчен бик яхшы бүләк бит.

Ә Давытның башында бер генә сорау буталды: моңа миннән ни кирәк? Ял көнне, бу пычракта, егерме чакрымнан Давытны болай гына, танышыр өчен чакырып китермәгәндер. Араларны җайлау-майлау, Давытның күңелен йомшарту максаты белән сөйли ул боларны. Акыллы ир җитәкче дә шулай итәр иде, син миңа моны бир дә тегене эшлә, дигәнче, бераз вакыт юк-бар сүз үрчетеп алыр иде.

Ләкин бу чибәр хатынның йомшак, нечкә тавыш белән ирләр сүзен сөйләп утыруын күңел кабул итәргә теләмәде. Урмандагы һәр кош үзенчә сайраган шикелле, адәм балалары да кыяфәтләренә, утырган урыннарына, ниһаять, җенесенә карап, үзләренчә сөйләшергә тиешләр. Давыт, сәерсенүен һәм ризасызлыгын яшерә алмыйча, күке булып кычкырган уткойрыкка тап булгандай, керфек тә какмый, Нурхнованың йөзенә текәлде. Ярый ла ул үзе генә шулай сәер сайраса, ягъни сөйләсә! Аңа соң ничек җавап бирергә? Шулай ук үзеңә хас булмаганча кыланыпмы? Әгәр бу хатын белән башка берәр җирдә, әйтик, клубта, театрда яисә кунакта очрашсалар, Давыт белер иде ничек сайрарга! Югалып кала торганнардан түгел! Ләкин урыны нинди бит! Шушындый җитди, рәсми урынга мондый тәти апаны кертеп утыртырга кайсы түрәнең акылы җитте икән? Хатын-кызга юл бирәләр, имеш... Күтәрәләр... Таптылар гадәт! Хәзер Давыт нишләргә тиеш инде? Иң яхшысы: бу чибәркәйне өстәле артыннан күтәреп алу гына булыр иде дә бит...

Шунда ул, бозлы җил бәргәндәй, артка тайпылып куйды: Нурхерованың ак йөзеннән, боз кыйпылчыкларына әверелгән күзләреннән котып салкыны бөркелгәндәй булды. Ай-һай сизгер икән үзе дә, Давытның уйнак уйларын тоеп та алган! Озаграк шулай карап утырса, үпкәң шешәр, Алла сакласын!

Хәер, Нурханованың араларны бөтенләй суытасы килми иде булса кирәк, тәрәзәгә борылып, гөлләргә карап торды, аннары, зур сүз башлаганын сиздереп, көрсенеп куйды, терсәкләрен өстәлгә терәп, кул бармакларын бер-берсенә аралаштырып кысты. Аның сул кулында, атсыз бармагында, нечкә генә алтын балдак ялтырый иде.

— Сезнең белән киңәшәсе бар иде, — диде ул.

Давыт дәшмәде. «Киңәшәсең булгач, үзең безгә килеп китсәң дә зыян итмәс иде», — дип уйлады эченнән. Шундук моңа үзе җавап та бирде: анда барса, Давытның йөзенә астан, үрелеп карап сөйләшергә туры киләчәк шул аңа.

— Суыклар башланганчы, Кармаш хастаханәсенең котельныен көйләп җибәрергә, инфекция бүлеге бинасының түбәсен ябарга кирәк иде, — дип дәвам итте Нурханова.

Давыт тагын авыз ачмады. Кайсыдыр авылдагы участок хастаханәсенә аның ни катышы бар?

Нурханова аңа туп-туры текәлде дә:

— Утыз кубометр такта кирәк, — диде.

Тынлык урнашты. Алар бер-берсенең күзенә шактый озак карап тордылар. Ниһаять, Давыт авызын ачты:

— Такта кирәкмәгән кеше юктыр инде ул, — диде көлемсерәп. — Тик ник аны миннән сорыйсы иттегез? Лесхоз директоры иптәш Мингалимовка кушыгыз гына. Район үз кулыгызда бит.

— Сөйләштем. Бирә алмыйм, ди. Ел ахырынача тәмамлыйсы төзелешләр күп. Һәр кубометр учетта. Ә хастаханә быел тапшырылачак төзелешләр исемлегенә кертелмәгән.

— Планга кертмәгәнсез, исемлеккә язмагансыз, хәзер инде мин такта урлап китерер дип өметләнмисездер бит?

Нурханова аның күзләренә туп-туры карады да, өзеп-өзеп:

— Әйе, нәкъ менә шулай: урлап китерерсез дип өметләнәм, — диде.

Давыт сызгырып җибәрүдән чак кына тыелып калды. Әйе-е! Ишетмәсәң ишет! Ә ул моңарчы, мондый югары урыннарга шыр тилеләрне утыртмыйлар дип ышанып йөри иде тагын. Чибәрлек булгач, акыл гел кирәкми икән бит, менеп утырган менә. Хәзер инде Давытны әвәрә итмәкче.

Юк инде, апакаем, барып чыкмас! Матур хатыннар күп ул дөньяда, ә Давыт үз-үзенә бер генә!

Ә Нурханова Кармаш хастаханәсе хакында сөйли иде. Районның мәйданы зур, җитмәсә, кыяр кебек озынга сузылган, бер башыннан икенчесенә туксан биш чакрым. Ә район үзәге — Суташ — бер кырыйдарак. Урталыкта, Суташтан утыз чакрымдагы Кармашта, «Ашыгыч ярдәм» үзәге ачу, хирургия бүлеге булдыру бик кирәк. Күпме хасталарга вакытында ярдәм күрсәтелер дә күпме гомерләр сакланып калыр иде...

Урынбасар шул рәвешле сөйли бирде, сүзләре Давытның бер колагыннан кереп икенчесеннән чыга торды. Аның фәкать бер генә сорауга җавап аласы килә иде: моңарчы кара-каршы килеп, ике авыз сүз дә сөйләшмәгән килеш, нишләп әле бу хатын нәкъ менә Давытка шундый четерекле йомыш белән мөрәҗәгать итәргә булган?

Бу сорау кычкырып әйтелмәде, әмма Нурханова үзенең шактый озынга сузылган сүзен аңа җавап рәвешендә төгәлләде:

— Сез яшь кеше, тәвәккәл, уңган, алда торган эшләрнең иң мөһимен аерып ала беләсез. Районда күп урманнар утырткансыз, агач савыт цехын да сез оештыргансыз икән... Эчендә җаны бар кешегә хастаханәнең никадәр кирәклеген аңлатып та торасы юк. Бу бит кашык ясау цехы гына түгел...

Монысы авырткарак җиргә тиде. Ул цех артыннан Давытка күп чабарга, күп тапкырлар «ризыгы булса, тимер калак та ярап тора» дигән сүзләрне тыңларга туры килде. Хәзер әнә район түрәләре, килгән бер кунакка бүләккә бизәкле агач савыт биреп, шуның белән мактаналар.

«Ярый безгә, каткан тезгә, шунысын гына булдырсак та, — дип уйлады Давыт. — Иң кирәген үзегез кайгыртыгыз инде. Урыныгыз югары. Тик менә хастаханә кадәр бинаны аннан-моннан йолкыштырып, урлаштырып, коры тәвәккәллек белән генә торгызып була микән?»

Дөрес, Кармаштагы ул хәрабәне, янындагы сарай-келәтләре белән бергә, бульдозер белән сыдырып алырга күптән вакыт җиткән җитүен. Моннан ике-өч ел элек килгән баш врач Газимов, аның тирәсенә агачлар утыртып, тәрәзә яңакларын буяп, кот кертергә маташа маташуын да, аннан гына хастаханә рәтләнәме?

Тик менә андый зур бинаны төзү — хатын-кыз кулыннан килә торган эш түгел шул. Бу Нурханова, дәрәҗәле урынга менеп утырса да, акылга бик бай түгелдер, күрәсең...

Бу уйлар Давытны кыюландырып җибәрде. Ул, кулларын җәеп, ясалма елмайды:

— Һәммәсен аңлыйбыз, Фидая...

Каһәр суккыры, атасының исеме онытылып китте тагын, ишекнең теге ягына язылган иде бит югыйсә!

— Госмановна, — дип, аның исенә төшерде Нурханова.

— Әйе, Фидая Госмановна. Бөтенесен эшләр идек, мөмкинлеге генә юк. Алай да истә тотарбыз. Киләчәктә бирәр җае чыкмасмы.

Ләкин истә тотмаячагы, бусаганы атлап чыгуга онытачагы көн кебек ачык иде.

— Безнең алда да зур эш тора бит әле, — дип, сүзне икенчегә борды ул. — Баллыболын буасы тирәсенә нарат утыртасы бар. Үсентеләре дә кайтартылган, кеше җитми! Мәктәп балаларны бирми! Директоры киреләнә. Сезнең бер сүзегез җитә, әйтегез әле шуңа!

Нурханова карашын өстәлендәге кәгазьләргә төбәде. Озын алтынсу керфекләреннән ак яңагына күләгә төшкәндәй булды, уң ягы чәч белән капланган киң, шома маңгаенда уйлану чагылды. Бу рәвешле, нәкъ кирәкле минутта бөтен дикъкатьне бер ноктага туплап, бер мәсьәлә турында тирән итеп уйлау — ир-егетләрнең иң төплеләренә хас сыйфат. Хатын-кыз, кагыйдә буларак, теленә беренче килгәнне әйтеп сала да соңыннан кайтып уйлагач үкенә. Әмма ирләргә хас булганча тирән уйлану Нурхановaның мөлаемлыгын киметмәде, тик серлерәк, аңлаешсызрак кына итте шикелле. Менә ул башын күтәрде дә:

— Хәзергә булмый, — диде. — Балалар бәрәңгедә.

— Менә күрдегезме? — Давыт урыныннан торып басты һәм бу юлы инде, гадәтенчә, Нурхановага өстән карады. — Булмастайны булдырып булмый шул!

Нурханова да урыныннан кузгалды. Саубуллашканда икесе дә көчәнеп диярлек елмайдылар. Икесе дә бу очрашудан ризасыз калганнар, аннан да бигрәк киләчәктә дә борчаклары пешмәсен аңлаганнар иде. Алай да, чыгарга дип ишекне ачкач, Давыт борылып карады. Нурханова тәрәзә янына барып баскан иде. Ул, Давытның карашын тоеп, бөдрәләрен сирпеп башын борды һәм боздай салкын карашы белән аңа чыгып китәргә боергандай итте.

«Әйе-е, һәрнәрсәнең үз урыны бар шул, — дип уйлады Давыт, коридор буйлап чыгу ягына барганда. — Ташлы тауда тал үсми, сазламыкта чыршы-нарат мантымый. Биеп торган чаптарларны авыр йөк арбасына җикмиләр, бөдрә йонлы әнчекләрне бүрегә өстермиләр. Бу апакайның да урыны җитәкче өстәле артында түгел. Әнә мәдәният йорты урам аша гына! Шунда баш булып алсын иде дә җырчы-биючеләрне өндәсен иде һәртөрле тәвәккәллекләргә!»

Зиһене таралган Давыт баскыч борылышында берәүнең кочагына барып кергәнен сизми дә калды. Районның төзү-монтаж идарәсе начальнигы Тавис Мирхуҗин икән. Бик яхшы таныш кеше, чөнки яши белә, урманда еш була! Куе кара кашларын җыерып, борынын салындырып йөргән чагын күрмәссең. Бу юлы да менә, кысык кара күзләрен ярык кына калдырып, шукланып елмая.

— Багана, багана, баскычларда аунама, — ди көйләп. — Кайсы юньсез начальник өнеңне алды болай?

— Ә, исәнме, син дә килеп ятасыңмыни? — диде Давыт, ничектер каушап. Кем яныннан чыгып килгәнен нилектәндер әйтәсе килмәде.

— Әллә «үзе» иртәдән явызланамы?

«Үзе» дигәне райкомның беренче секретаре Искәндәровны аңлата иде. Давытка турысын әйтми чара калмады:

— Аннан түгел... Өченче белән сөйләштек.

— Ә-ә, Нурхановада булдыңмыни? Син дә аның тарафына сукмак сала башладыңмы әллә?

— Үзе чакырып алды. Агач материаллары кирәк, ди.

— Булдымы соң? — Бусы инде хәйләкәр үчекләү аралаш әйтелде.

— Нәрсә? — дип аңламаганга салышты Давыт.

— Агач материалын бирдеңме соң?

— Бездә каян булсын ул? Бөтен төзү материаллары сезнең кулда лабаса. — Давыт Мирхуҗинны әйләнеп үтеп китмәкче иде, тегесе аркылы басты да, башын каерып, аның йөзенә текәлде.

— Тәҗрибә җитмидер әле, эшенең рәтен белмидер, шуңа мине чакыргандыр, — дип мыгырданды Давыт.

— Алай димә! Булыр сиңа тәҗрибәсез! Егетләрнең кайсын чакырырга икәнен бик яхшы белә ул! Бөтенесе үз кулында икәнен аңлый. Кинәттән үсеп китте бит, сәнәктән көрәк булды. Уңган хатыннар шулай бит хәзер, ирдән арынулары була, шундук мантып китәләр.

Давыт Мирхуҗинга чын күңелдән көнләшеп карап куйды. Рәхәт тә яши инде, шайтан алгыры! Беркайчан күңелен төшерми, көйсезлекләргә көлеп кенә карый. Атна буе койган яңгыр да аның шат күңелен җебетмәгән, шуклыгын киметмәгән. Аның янында Давытның да кәефе яхшыргандай булды, әле генә бүлмәдә булган сөйләшү көлке булып тоела башлады. Давыт аны мәзәккә сабыштырып сөйләп тә

бирмәкче иде, тик бүлдерделәр: аскы коридорда шау-шу купты, кемнәрдер дөбер-дөбер баскычтан менә башлады. Давыт белән Мирхуҗин диварга елышып юл ачтылар. Талчыккан кыяфәтле биш-алты ир-атның һәм кыска соры пальто өстеннән озын кызыл шарф очларын сузып салган бер хатын-кызның моңарчы районда күзгә-башка чалынганы юк иде. Киемнәре дә авыл җиренә ятышлы түгел: замша һәм күн курткалар, джинсы чалбарлар, ирләрнең икесе сакал җибәргән иде. Берсе Нурханова бүлмәсен сорады.

— Күрдеңме? — дип каш сикертте Мирхуҗин, алар узып киткәч. — Озакламый ул Нурхановага коридор буйлап чират тезеләчәк әле! Миңа аркылы төште бит болар. Соңрак килергә туры килер инде.

Алар сөйләшә-сөйләшә ишектән чыкканда, райком каршына зәңгәр «уазик» килеп туктады.

— Кара, Баллыболын алашасы килеп ята, — диде Мирхуҗин, ачы елмаю аша пошаман белән. — Эләктерә күрмәсен тагын! Берәр нәрсә теләнә башласа, котылам димә!

Һәм, «уазик»ны читтәнрәк уратырга тырышып, шыпан-шыпан гына урамның теге ягына юнәлде. Анда күксел «Жигули»ена утырып китеп тә барды.

Ул арада «уазик»тан кырык яшьләрдәге таза гәүдәле хатын чыкты. Бу шул Мирхуҗин «алаша» дигән кеше — «Үзәк» колхозы рәисе Ниса Таштимерова иде.

Ул Давытның сәламенә баш кагып кына җавап бирде дә, сулы савыт янына барып, итеген юарга иелде. Аркасыннан караганда, Ниса чыннан ир кыяфәтле иде: калын кара плащ астында киң җилкәләре уйнаклап тора, кара берет читеннән кыска чәчләре тырпаеп күренә.

Таштимерова районга гына машина белән килә, авыл арасында ат җигеп йөри, чыбыркысын кулдан төшерми, диләр. Ул, пәһлеван ирләрдәй калын тавыш белән, командирларча кискен итеп сөйләшә, кызып киткән чакларында каршы әйткәннәргә чыбыркысы белән тамызып алырга да күп сорамый, имеш. Бер генә яктан да ирләрдән калышмаска тырыша Ниса. Шулай бервакыт, мәҗлестә бәхәсләшеп, бер стакан аракыны тын да алмый эчеп бетергән, дип сөйлиләр. Ничек итеп, диген әле! Ике кулын аркасына чалыштырып куйган да мөлдерәмә стаканны тешләп күтәргән һәм шул килеш чөмергән! Аракысы да тегенди-мондый гына түгел, «Посольский» булган, диләр.

Моннан алты-җиде ел элек, рәис булып өченчеме-дүртенчеме ел эшләгән чагында, мәҗлесләрнең бик модада вакытында, егетлеген исбат итәр өчен кыланган ул моны. Һәм чыннан да телгә кереп калган бу «егетлек»! Даны еллар аша үтеп, Давыт кебек яшь кадрларга да килеп иреште менә. Ир-ат әһеле Таштимерова турында төрлечә сөйли: бар сукранучысы, бар сокланучысы, әмма, һәммәсе дә аны гайре табигый күренеш дип санасалар да, гаепләмиләр, зур хуҗалык башына куелган хатын-кызның шундый булмый чарасы юк дип исәплиләр.

Әйтик, Нурханова урынында Ниса булса, нишләр иде икән? Һәрхәлдә, Давытны «үтенеп» чакырып тормас, очрашкач, читләтеп әңгәмәләр корып утырмас иде. Аның ишеләр, гомумән, үтенә белми, таләп кенә итә! Брезент тышлы зәңгәр «уазигы»н түбәсеннән сазга батырып, урман хуҗалыгы конторасының каршына килеп туктар иде дә, бүлмәгә бәреп кереп, гайрәтле тавыш белән:

— Такта бир давай! — дияр иде.

Киреләнеп торсаң, чыбыркысын сызгыртырга да күп сорамас иде. Кая керер тишек тапмассың, соңгысын биреп котылырдай булырсың!

Һәм шунысы кызык, ул бит хаклы булыр иде. Бик тырышса, Давыт бераз такта юнәтмәслекмени? «Алай да Нурхановны тыңламыйча дөрес эшләдем, — дип уйлады ул. — Үз урынында утырмаганын белеп торсын!»

Таштимерова һаман әле иелгән килеш резин итеген сулы пумала белән ышкый иде. Плащ итәге тырпаеп күтәрелгән, астан сызылып ап-ак челтәр күренә. Эчке күлмәк итәге.

Давытка ул кинәт бик кызганыч булып тоелды. «Кая гына менгереп утыртсаң да, хатын-кыз үзе булып кала инде, — дип уйлады ул көрсенеп. — Ходай шулай яраткан...»

# 3

Нурханова, тәрәзә янына басып, гөл чәчәкләре аша үрелеп, тышка, яфраклары тутык төсенә кергән, шәбәргән агачларга, ишегалдының юеш асфальтына, яссы кара түбәле гаражларга карады. Әнә, андагы киң ачылган капкаларның берсеннән яшел «уазик» килеп чыкты, ишегалды уртасында туктады, аның ачык тәрәзәсеннән кара мыеклы яшь егетнең башы күренде. Ул сузылып өскә карады. Нурхановaның шоферы Балкыш иде бу. Фидая, тәрәзәне ачып, аңа урамга чыгарга кушып, кулын изәде.

Аннары тәрәзәне япты да авыр сулап куйды. Көне нинди бит, көне! Өстә — соры болыт юрганы, аста — кара боламыкка әверелгән басулар, уртада — теләсә нинди плащ аркылы дым булып саркый торган вак яңгыр. Йөзләрне сүрелдерә, кулдан эшне төшерә, күңелне изә торган мохит. Хәер, борынгы гадәтне искә төшереп, мунча ягып, бәлеш пешереп, самавыр янында гәп корып утырсаң, көн дә болай ямьсез тоелмас

иде. Тик заманы ул түгел, Фидаяның тормышы андый түгел. Аның гаме — халык гаме, ә халык — кырда, бәрәңге алуда. Район җитәкчеләренең һәркайсы аерым колхозларга беркетелгән. Нурханова «Үзәк»тә булырга тиеш. Хәзер ул анда барыр, ләм ерып, басулар буйлап йөрер, кешеләрнең күңелен күтәрерлек сүзләр табарга тырышыр.

Ләкин ул гына да түгел әле: аның беркем дә кушмаган, ләкин үзе өчен бик мөһим дип санаган тагын бик тыгыз бер эше бар. Кармаш хастаханәсенең котельные янына утыз тонналы кран китертеп, егерме дүрт метр озынлыктагы юан торбаны утыртып куярга кирәк. Бернинди оешманың да планына кермәгән бу эшне иртәгә, ягъни якшәмбе көнне башкарып кую уңай. Бүтән көнне кранны бирмәячәкләр. Дөрес, тиешле оешма белән сөйләшенгән, баш табиб Газимовка кат-кат әйтелгән. Тик шулай да кешегә генә ышанып торып булмый. Юк кына нәрсәләр аркасында зур эшләр тукталып кала кайчакта. Торба утыртасы нигез тиешенчә эшләнгәнме? Кран басар урын ныкмы? Тросы, ыргагы чыдарлыкмы?

«Газимов белән минем генә баш җитмәс моңа, — дип уйлады ул. — Мирхуҗин белән киңәшсәң яхшы булыр иде. Үзе барсын, йә булмаса, берәр ышанычлы кешесен җибәрсен. Хәзер үк сөйләшеп куярга кирәк».

Ул, телефонын алып, Мирхуҗинга шылтыратты. Секретарь кыз: «Каядыр шушы тирәдә йөри иде әле, күргәч тә, сез шылтыратканны әйтербез», — дип җавап бирде.

Фидая, аңа юл уңаеннан сугылып чыгарга уйлап, ишек янындагы элгечтән күн пальтосын алган гына иде, коридорда күп һәм тигезсез яңгыраган аяк тавышларын ишетеп туктап калды. «Ходаем, миңа гына кермәсеннәр иде...» Ләкин күңеле белеп шомланган икән, теләге кабул булмады, адымнар якын ук килеп туктады, ишекне каккан тавыш ишетелде.

— Керегез!

Ишек әкрен генә ачылып, анда зур авызлы киң чырай пәйда булды, күшеккән калын иреннәр ачылып, карлыккан тавыш:

— Фидая Госмановна биредәме? — дип сорады.

Аннары бу кешенең киң җилкәсе, нык бәдәне пәйда булды, аның артыннан кыюсыз гына алты-җиде кеше килеп керде.

— Чакырылмаган кунаклар килде, — диде ир кеше елмаеп. — Казаннан без, рәссамнар, күргәзмә белән килдек. Сезнең белән алдан сөйләшенгәнчә.

Фидая, пальтосын кире чөйгә элеп, кунаклар белән кул биреп танышып чыкты.

— Бу төркемнең җитәкчесе мин булам, исемем Тәүзих Әхмәдуллин, — диде кырык яшьләр тирәсендәге киң чырайлы адәм.

Килгәннәрнең күпчелеге яшькә аның тирәсендә иде булса кирәк, чал чәчле, какча яңаклы, чандыр абзый гына өлкәнрәк күренде. Иң күзгә ташланганы исә озын кызыл шарфын кыска пальтосы өстеннән сузып салган, егерме бишләр тирәсендәге хатын-кыз булды.

— Рамилә, — диде ул, салкын, юеш бармакларын Фидаяның учына төртеп.

— Вакытсызрак килеп төштек бугай, гафу итегез инде, — диде Тәүзих. — Коя да коя. Билгеләнгән вакытта килеп булмады, шәһәрдәге бөтен транспортны авылларга бәрәңге алырга җибәрделәр. Менә кинәт кенә бер буш автобус килеп чыкты да, форсатны ычкындырмаска булдык. Ашыгычка туры килде, сезне кисәтеп тә өлгермәдек.

Фидая хәлне төшенә башлады. Күрәсең, районда Казан рәссамнарының күргәзмәсен оештыру турында ел башында Гайнуллин белән сөйләшкән булганнардыр. Аннары эш һәрвакыттагыча сузылгандыр. Изге гамәл, әлбәттә, ләкин иллә дә вакытсыз килеп төштеләр инде!

Алай да сер бирергә ярамый иде. Фидая кунакларны, ачык йөз белән сәламләп, дивар янындагы урындыкларга утырырга чакырды. Һәркайсына кул биреп танышып чыкты.

— Хуш килдегез! — диде. — Матурлык белән очрашу беркайчан да вакытсыз булмый ул. Хәзер кунакханәгә урнашырсыз, чәй хәстәрләрбез!

Ул телефонга ябышты. Ресторанга — табын әзерләсеннәр, кунакханәгә — урын кирәк. Кирәген кирәк, әмма урын юклыгы алдан ук билгеле, чөнки бар булган бүлмәләр урып-җыюга килгән шоферлар белән шыгрым тулы. Нишләргә? Җәелмә ятаклар куярга, диваннарга урын җәяргә. Ә бу кызыл шарфлы Рамиләне, күрәсең, Фидаяның үзенә алып кайтырга туры килер.

— Курыкмагыз, мин сезне кыерсытмам, — дип шаярып күз кысты ул рәссам кызга.

Аннары ул мәдәният сараена шылтыратты: картиналарны алып кереп куйсыннар, эләргә урыннар җайласыннар, бауларын, кадакларын булдырсыннар... Үзе телефоннан сөйләште Фидая, үзе кунакларны күзәтте. Шактый йончыган, талчыкканнар, өлкәнрәк күренгәне йөткергәләп тә куя. Авырып китмәсеннәр тагын, артык мәшәкать ясап... Фидая тагын кунакханә белән сөйләште: кичкә кайнар чәй, мәтрүшкә, сөт кирәк булыр... Алдан кайгырту арзангарак төшә.

Кунакларны беренче тапкырында хөрмәт йөзеннән ресторанга чәйгә үзең алып керү тиеш иде. Фидая күн пальтосын, беретын алып киде дә, бергәләшеп тышка чыктылар.

Балкыш машинасын болдырга ук диярлек китереп terәгән — хуҗасының матур ботинкаларын кайгырта. Шоферлар көтәргә өйрәнгән халык, ул китап укып утыра иде.

Барасы юл ерак түгел, олы урамга чыгасы да чак кына эчкәрәк керәсе. Ләкин шул «чак кына» дигәне шактый сазлы. Фидая Рамилә белән чал чәчле абзыйны машинасына чакырды, башкалары үзләрен алып килгән автобуска утырды.

Ресторанның залы биек, иркен, якты, бер як дивары тоташ тәрәзәдән тора. Хәзерге вакытта биналарны иңгә-буйга, биеклеккә киң итеп салалар, пыяланы да кызганмыйлар. Ә менә андый залларны ничек җылытып бетерәсен уйлаган кеше юк, күрәсең. Бередә дә салкынча иде.

Түрдәге берничә өстәлне берләштереп әзерләгән табында шул хакта сөйләшеп алдылар. Диварларга майлы буяулар белән ясалган сурәтләрне — көлтә күтәргән калфаклы кызларны, комбайн каршына баскан баһадир егетләрне күздән кичерделәр. Рамиләнең йөзендә канәгатьсезлек чагылды, тулы ирен читләренә мыскыллы көлемсерәү бәреп чыкты.

— Ошамыймы әллә? — дип сорады аңа каршы утырган Фидая.

— Ну... Ничек дип әйтим... — Рамилә хуҗа кешенең күңелен китүдән саклана иде. — Дәүләт премиясенә тәкъдим итәрлек димәс идем...

Табындагылар пырхылдашып куйдылар.

— Ә без канәгать, — диде Фидая, тавышын күтәрә төшеп. — Безгә матур тоела, чөнки зәвыгыбыз шундый. Моннан әйбәтрәген күргәнебез юк бит. Зәвыкны тәрбияләргә кирәк шул аны. Әйбәт әсәрләр белән.

— Безнең дә шуңа тырышып йөрү бит инде, — диде өстәлнең аргы башыннан Әхмәдуллин.

— Гомер эченә бер килү — нәрсә ул? Зәвыкны даими тәрбияләү тиеш...

— Безме? — дип, ничектер беркатлы сагаеп сорады Рамилә.

— Курыкмагыз, без сезне монда калырга мәҗбүр итмәбез, — дип шаярып җавап бирде Фидая. — Ә менә картиналарыгыз озаграк торса, начар булмас иде.

— Мин... сезгә берәрсен бүләк итәрмен, — диде Рамилә.

Барысы да аның беркатлылыгыннан көлешеп алдылар.

— Курыкмагыз, без сатып та ала алабыз, — диде Фидая. — Анлык кына байлык бар. Менә сез безгә яңа төзелешләрне бизәргә ярдәм итсәгез иде! Әсәрләрегез һәрвакыт халык күз алдында булыр иде.

— Нинди төзелешләрне?

— Хәзерге вакытта участок хастаханәсе төзелеп ята. Әгәр шуның эче зәвык белән бизәлсә, ә? Анда бармаган кеше тирә-юньдә сирәк бит. Киләләр, озаклап чиратларда утыралар. Карарлар иде, күңелләренә ял булыр, чын сәнгатьне аңларга өйрәнерләр иде.

Рамилә, эчкән чәен, тәмләп ашый башлаган чәкчәген онытып, керфек тә какмый Нурхpraванның чыраена текәлде: чынлап сөйлиме, әллә шаяртамы?

— Сез шаярта да беләсез икән, — диде Әхмәдуллин да, башын селкеп. — Авыл хастаханәсен музей белән берләштерергәме әллә? Андыйның тарихта булганы юктыр ул!

— Ә без менә булдырыйк та, тарихка яңалык язып калдырыйк, — диде Фидая җитди итеп.

— Ә чыннан да, — диде Рамилә уйлангандай. — Хастаханәләрдә дә кешеләр яши инде...

Һәммәсе дәррәү көлешергә тотындылар. Рамилә кызарынып чыкты, сүзен төзәтергә азапланды.

— Күп кеше була, дигәнем... Әнә, сугыш турында кинолар күрсәтәләр, ул чакта госпитальләрдә концерт куя торган булганнар. Барыбер сәнгать... Яралыларга тизрәк терелергә ярдәм иткән.

Нурханова аңа бик җитди итеп текәлеп карады да:

— Димәк, сез хастаханә бинасын бизәргә алынасыз? — дип сорады.

Тынлык урнашты. Рамилә каушап калган иде.

— Карарга кирәк башта, — диде ул. — Бинасы ниндидер бит.

— Алайса, мин сезне анда бүген үк алып барам!

Шулай диде Фидая, әмма шундук үзенең артык ашыкканын тоеп алды: юлдан килгән кешене ял иттерми-нитми тагын юлга алып чыгып китү ярыймы? Аннан файда булырмы?

— Юк, иртәгә барырбыз, — дип төзәтте ул сүзен. Һәм, нокта куйганны аңлатып, башкага күчте: — Үзегез күреп торасыз, без дә монда артта калырга тырышмыйбыз. Ресторанибыз шәһәрдәгедән ким түгел бит!

Барысы да бертавыштан сый-нигъмәтне мактарга керештеләр: ит, каймак бик тәмле, чәкчәкне, балны әйткән дә юк...

— Кичләрен ресторанга чират зур буламы? — дип сорады кайсыдыр.

— Чираттан куркасы юк, — диде Нурханова. — Авыл халкы ресторанда кәеф-сафа корып утыруны гаепкә саный. Ачылган чорында килгән-киткән төзүчеләр, шоферлар килә иде. Суташ кызларын сыйларга да дәртләре бар иде, әмма тиз сүрелделәр. Чөнки бу бусаганы кемнең атлап кергәнен бөтен район халкы белеп тора, айлар буе сүз йөри. Кызларны чакырып булмагач, егетләрнең дә эзе суынды. Шунлыктан кичләрен бу зал буш тора, көндез гади ашханә булып эшли. Ресторан дигәннән ишегендәге язу гына калды.

— Әйе, монда аквариумдагы кебек шул, — диде Тәүзих, тәрәзәдән урамга карап. — Бигрәк тә эчтәге утларны кабызсаң шулайдыр...

— Алайса, ник төзеп куйганнар соң аны? — диде Рамилә гаҗәпләнеп. — Башка кирәк нәрсә беткән иде микәнни?

Ирләр тагын елмаештылар. Алар, күрәсең, бу яшь хатынны сабый чутында йөртәләр иде.

Нурханова исә җитди итеп җавап бирде:

— Мин бу эшкә килгәнче төзегәннәр иде, ни уйлаганнардыр, белмим, — диде.

— Ни уйлаганнары билгеле инде, — диде Тәүзих. — Килгән-киткән начальникларны кунак итүне кайгыртканнардыр. Начальствоны килүгә участок больницасына алып бармыйлар, ашарга алып керәләр бит.

Нурханова сүзне икенчегә борырга ашыкты:

— Хәзер ирләр кунакханәгә урнашыр. Ә сезне, Рамилә, өйгә кайтарырмын. Анда кеше юк, ял итәрсез. Алтыдан соң кайнанам кызымны бакчадан кайтарып куя. Үзем дә озакламам.

## 4

Бәхеткә, якшәмбе көн иртәнгә күк йөзен болыт каплаган булса да, яңгыр туктаган иде. Шәһәр кызы Рамилә авылда сирәк була, шунлыктан һәрнәрсә анда зур кызыксыну уятты. Район үзәге Суташтан Кармаш авылына илтә торган утыз чакрым юл аңа бик озын тоелды. «Уазик» машинасының арткы утыргычыннан алга таба муенын сузып, буразналар белән сырланган кара басуларны, томан өртелгән ямансу агачлыкларны, олы юлдан читтәрәк утырган, күзге моңсулыкка уралган авылларны бөтен төсмерләре белән күңеленә сеңдереп калырга тырышкандай, күзләрен зур ачып күзәтеп барды ул.

Анда-санда тракторлар, Рамилә моңарчы күрмәгән машиналар күзгә чалынып кала, алар тирәсендәге кешеләр кечкенә, көчсез, хәтта кызганыч булып тоела иде.

— Бәрәңгене алып бетереп булмый бит әле, — диде алгы утыргычтагы Фидая. — Гаҗиз булдык инде. Кинәт суытып куйса, эшләр харап дигән сүз. Аннары җылытып җибәрсә дә, өшегән балчыкта актарыну ай-яй авыр ул!

Ниһаять, «уазик», таш җәйгән булса да чокырланып беткән олы юлдан чайкала-чайкала төшеп, зур гына авылга керде һәм тагын да ныграк дыңгырдый, моторын улата башлады. Олы урамнан шактый барып, сөзәк үргә күтәрелгән ян урамга борылгач кына бераз җиңеләеп киткәндәй булды. Ике ягына тезеп тупыл утыртылган юл, чирәмлек өстеннән генә салынган булса да, авыл урамындагыча ук бозылмаган, чокырланмаган, корырак, төзегрәк иде. Ул аулак, ямьле берәр җиргә илтергә тиеш иде кебек.

Әмма машина аулакка түгел, коймa белән әйләндереп алынган ихата янына килеп туктады. Капка өстенә зәңгәргә сары белән эре итеп «Кармаш участок больницасы» дип язылган иде. Эчтәге ике катлы бинаның күңел төшергеч искелеге күзгә ташланды. Дөрес, янтаймаган, түнмәгән үзе, чөнки патша заманнарында йортларны нык итеп торгыза торган булганнар бит. Ярыйсы гына иркен дә күренә — эчендә ким дигәндә унлап бүлмәсе бардыр. Ләкин... хастаханәсе кайда соң?

Машинадан төшкәч, Рамилә Нурхановадан шуны сорамакчы иде, ләкин өлгерә алмый калды. Бина ишегеннән, ак халаты өстеннән плащ кия-кия, кечерәк кенә, әмма нык бәдәнле, сары чәчле бер ир-ат килеп чыкты. Мондый кешеләр тиз картаймый, утызларда гына булып күренсә дә, кырыкка авышкан булуы бик ихтимал иде. Аның артында шулай ак халатлы, утыз бишләр тирәсендәге, сипкелле, мөлаем йөзе борчулы бер хатын күренде. Алар, исәнләшүгә, кызып-кызып үз сүзләрен сөйли башладылар.

— Килделәр килүен, — диде ир кеше Нурхановага. — Тик кузгата алмыйлар әле. Майлыйлар да җайлыйлар. Ә миңа авыру карарга туры килде.

— Беләм мин аларның нинди май өмет иткәнен! — диде хатын, күк күзләреннән ут чәчеп. — Монда килгән шабашникның борын тишекләре үгез танавыдай киңәйгән була, спирт исен аулый!

— Анысы шулай инде, — дип, тыныч кына аның сүзен җөпләгәндәй итте ир кеше. — Син, Гөлфия, артык кызма, тәртибе шул аның. Ял көне эшкә чыкканнар бит, аларны да аңлап була.

— Син, Билал, йомшаклыгыңны сиздердең шул! Алар шуңа азына! Яннарында шешә болгап йөрсәң генә кыймылдаячаклар! Шешә күрсәләр, торбаңны түгел, больницаңны күчереп куярлар. Юк инде, бездән

андыйны өмет итмәсеннәр! Бирмим дигәч бирмим! Ирем кушса да, начальнигым әмер бирсә дә! Син дә кушма, Фидая, ярамаганны. Бар булганы сейфта, ачкычын сорамагыз да!

Гөлфия ике кулын халат кесәләренә батырды, ак тукыма аша тырпайган йодрыклары шәйләнде.

Боларны читтән күзәтеп торган Рамилә эшнең хикмәтен тиз аңлады: Билал дигәне — баш табиб, Гөлфия — Билалның хатыны, өлкән шәфкать туташы булып эшли. Бәхәс ниндидер шабашникларга хастаханә спиртын бирү-бирмәү турында купкан иде.

Төркем, сөйләшә-гәпләшә бинаны әйләнеп, ишегалдының икенче ягына чыкты. Анда, иркен ихата буйлап сузып, зур бинага биек итеп нигез салынган иде. Аның артында, шактый гына ара калдырып, кечерәк кенә таш бинаның диварларын торгызып куйганнар инде, аның янында зур гына кран тора. Якынрак килгәч, җирдә утыз метрлап озынлыктагы, эченә адәм сыярлык юан, тутыккан торба ятканлыгы күренде. Торба янындагы ике ир һәм тагын кран кабинасындагы икәү, дәррәү борылып, якынаеп килгән төркемгә сораулы караш белән төбәлделәр. Баш табибтан спирт таләп итүчеләр шушы иде, мөгаен. Рамиләгә кызык булып китте: Нурханова бу чияләнгән төенне ничек чишәр икән? Үгетләрме, ялынырмы, әллә тиргәп үк ташлармы? Кызып китеп, чәүчәләкләнә башлармы? Каш астыннан сөзеп карауларына караганда, ирләр үз дигәннәреннән чигенә торган түгел. Бигрәк тә хатын-кыз каршында.

— Шушындарак торып торыгыз әле, — диде Нурханова һәм эшчеләр янына үзе генә китте. Ни кызыксынса да, Рамилә аларның сүзләрен ишетә алмады, чөнки сөйләшү тыныч һәм кыска булды. Нурханова кире борылды да баш табибка:

— Ә сез барыгыз, кереп торыгыз, — диде. Үзе капка ягына таба китте, Рамилә аңа иярде. Аларны алып килгән «уазик»ның шоферы кабинасында китап укып утыра иде.

— Тиз генә Суташтан әйләнеп кил әле, — диде аңа Нурханова. Үзе утыргычтан сумкасын алды да егерме бишлек акча чыгарды. — Менә шушының барсына да алып кил. Ни икәнен үзең беләсең.

— Кибеттә андыйны сатмыйлар бит бүген, Фидая Госмановна. Якшәмбе ләбаса.

— Зиннәтовның өенә бар. Складтан алып бирсен. Мин кушты, диген.

«Аракыга җибәрә түгелме бу моны? — дип уйлады Рамилә шаккатып. — Шулай шул!.. Үз акчасына! Менә сиңа җитәкче!»

Әйе, район башында торган кешеләрнең әхлагы бик зур күзәтү астында тотыла шул. Бигрәк тә хатын-кызның тырнак астыннан кер эзләүчеләр күп. Кибетләрдә аракы сату тыелган көнне үз хисабына эшчеләрне эчергәнен сизсәләрме? Сүзе дә күп булачак, җәзасы да каты биреләчәк. Һәм кара даны да сумала булып сыланып калачак, моны гомерең буе юып бетерә алмассың!

Шуны белә торып, ни кылана бу апа? Үз йорты өчен тырышса, ни әйтер идең. Участок хастаханәсе дип, кем шушылай үзенең абруен, киләчәген куркыныч астына куя?

Ләкин Рамиләгә шиген белдерергә форсат чыкмады, — Нурханова ашыгып тагын ишегалдының теге ягына, кранчылар янына юнәлде.

Ә анда һәммәсе хәрәкәткә килгән: кран гөрелдәп озын борынын бик сак кына, әкренлек белән генә бора башлаган, астагылар торба астына корыч бауны кыстырып, очын өскә сузып тора иде инде. Иске бинаның бу яктагы кечкенә ишегеннән берничә ак халатлы хатын-кыз чыгып басты, тәрәзәләр артында пыялаларга борыннарын терәгән йөзләр күренде. Менә кранның борыны тукталып калды, аннан салынган ыргакка торбадан сузылган тросның элмәген элделәр.

— Вира! Пошел!

Торба калкына башлады.

«Эх, альбомымны, карандашларымны аласым калган икән! — дип үкенде Рамилә. — Манзарасы ни тора!»

Чыннан да, ихата калкулык түбәсендә булганлыктан, биредән бик иркен күренеш ачыла иде. Якындагы авыл очыннан-очына картинадагы кебек күз алдында. Әнә басу юлыннан аның урамына тарантас җиккән ат кереп бара. Урман полосалары белән бүлгәләнгән басулар бик еракка, офык читенә кадәр җәйрәп ята. Бер якта рәшә белән төрелгән урман каралып күренә. Һәм шушы фонда болытларны тишәргә җыенгандай сузылган кран угы биегәеп тора. Һавага гүяки кешеләрнең бердәм ашкынуы, дәртсенүе җәелгән...

Рамилә янына килеп баскан шәфкать туташы Гөлфия дә нык дулкынланган, хисләрен кем беләндер бүлешәсе килә иде, ахры:

— Әйткәнен булдырмый калмас безнең Фидая! — диде. — Ул килгәндә тоташ чирәмлек иде монда. Бер җәй эчендә шушы хәтле хикмәтне башкарып чыкты. Нигезен дә салдырды, котельныен да торгызды. Казаннан килгән студентларның төзү отрядын көн-төн эшләтте. Ут өерделәр! Очына чыга алса гына ярар иде.

— Ә нишләп чыга алмас икән? —дип сорады Рамилә.

— Һи, төзү эшенең хикмәтләре! Теләсә кайчан туктый да кала ул. Кирпече булса, измәсе юк, чөнки цементын таба алмыйлар. Анысын тапсалар, кайтарырга машинасы юк! Лесхоз үзебезнең районда була торып, такта юнәтә алмыйлар! Чөнки һәммәсенә Казандагылар хуҗа. Алардан барып сорасаң, Мәскәүдән рөхсәт кирәк, ди башлыйлар. Мондагы кешенең ике кулы богаулы. Шуңа күрә мондый төзелешләр унар-егермешәр елга сузыла да. Аңарчы бу бинада күпме гомерләр өзелеп куяр әле! — дип көрсенеп, башы белән артка, иске бинага ишарәләде Гөлфия.

— Сез шушыны участок хастаханәсе дип йөрисезме? — дип гаҗәпләнеп сорады Рамилә.

— Нишләп без генә? Хуҗалар шулай ди! Монда килгәч тә безнең Билал бу эшне кузгатырга бик тырышып караган иде дә, кая ул! Район башында утыручы берәрсе янып-көеп йөрмәсә, була торган түгел иде. Менә Фидая тотынгач, кузгалды...

— Ул күптән эшлиме соң?

— Әйтәм ич, җәй башында килде...

Сүз шунда өзелеп торды. Кран торбаны җирдән аерып алган, ул юан троска эленеп, салмак кына чайкала, өч ир кеше, аның бер башыннан баулар белән тартып, әзер нигезгә туры китерергә маташа иде. Читкәрәк баскан Нурханованың бөтен гәүдәсе кылдай тартылган, гүяки ул күз карашы, йөрәк тибеше белән тегеләргә куәт бирергә тырыша иде.

«Юкка алмадым альбомымны...» — дип, тагын үкенде Рамилә.

Торбаны, ниһаять, нигезгә утыртып, өч ягыннан тарттырып, җиргә кагылган колгаларга бәйләп азапланганда, хастаханә артыннан гаҗәеп кыяфәтле бер ир кеше килеп чыкты. Соңгы мода белән тегелгән ачык коңгырт төстәге плащ, ялтыравык кара ботинкалар кигән, төз-ыспай гәүдәле бу кешенең аяк басуларында ук үзенә бер затлылык, нәзакәт, үз дәрәҗәсен белү сизелеп тора. Плащы төсендәге эшләпәсе маңгаен каплаган булса да, йөз сызыкларының камиллеге үзенә җәлеп итә иде.

— Кем бу? — дип сорады Рамилә Гөлфиядән пышылдап кына.

— Роберт Альбертович бу безнең. Йосыпов.

«Мәскәүдән килгән вәкил микәнни? — дип уйлады Рамилә. — Йә берәр галимдер, докторлык диссертациясенә материал җыеп йөрүедер...»

— Безнең гинекологыбыз, — дип өстәде ул арада Гөлфия.

Гинеколог? Хатын-кыз врачымы? Мондый егет каршында тора салып ничек чишенергә мөмкин? Андыйлар белән култыклашып театрларга бару, музейларда йөрү, рестораннарда янәшә утыру турында гына хыялланып була!

Менә шушы кәртинкәдәгедәй чибәр егет игенче-терлекче хатыннарның иң яшерен серләрен белә, карый, беркемгә күрсәтеп булмаган сызлавыкларын дәвалый икән.

Ул Нурханова янына узды. Исәнләштеләр.

— Сезнең туегыз булган икән, — диде аңа Фидая. — Котлыйм! Бәхетегезне шушы җирдән табыгыз! Монда тамырланырга язсын! Сезнең кебек яшьләр шулхәтле кирәк безгә! Менә хастаханәне төзеп кенә бетерик, куана-куана эшләрсез әле.

Йосыпов ягымлы елмаеп, калын, йөрәккә ятышлы тавыш белән, һәр сүзенең тәмен татыгандай ашыкмый гына җавап бирде:

— Минем ниятне беләсез бит инде, Фидая Госмановна.

— Ул уегыздан кире кайтмадыгызмыни әле? Инде гаилә коргач, планнарыгыз үзгәргәндер дип өметләнгән идем.

Баксаң, табиб биредән китәргә йөри икән. Дөрес, шәһәргә түгел, туган районына, әти-әнисе янына. «Авылда да нинди зыялы егетләр үсә!» — дип сокланып уйлады Рамилә.

Ул арада алар янына баш табиб та килеп баскан иде.

— Мин сиңа әйтәм бит: әти-әниеңне шушында гына алып кил! — дип сүзгә кушылды ул. — Менә дигән йорт салып бирербез. Шулай бит, Фидая Госмановна?

— Аларны нигезеннән куптарып булмый шул, — диде Йосыпов, йомшак кына итеп.

Баш табиб исә дулкынлана иде. Бу бәхәс алар арасында күптәннән бара булса кирәк, ул хәтта кыза башлады:

— Сез теләсә ни әйтегез, мин моны үз бурычыңа җавапсыз карау дип саныйм. Врачлар булмаса, яңа бина салып куюдан ни мәгънә? Чирлене стеналар дәваламый! Өр-яңа булсалар да! Кадрларны кайгыртырга кирәк, Фидая Госмановна! Аптырадык бит инде! Институт тәмамлап киләләр, эшкә өйрәтеп кенә җиткерәбез, китәләр дә баралар.

Ул ут өстендәге чәйнек кебек кайный, Йосыпов исә эшләпәсе астыннан сабыр гына елмаеп карап тора иде.

Каяндыр, капка ягыннан, каты итеп «Тпру!» дип кычкырган каты тавыш ишетелеп, сүзне бүлде. Алар бинаның алгы ягына чыкканда, бая басу юлында күренгән тарантаслы ат капка янына килеп туктаган, аннан кара беретлы, кара плащ кигән киң җилкәле кеше төшеп килә иде. Плащ итәге ачылып китеп, анда чалбар урынына итәк күргәч, Рамилә аптырап китте: ул бу адәмне ир кеше дип уйлаган иде.

Хатынның җилдән каралган киң чырае ачулы иде. Ул кулындагы кыска чыбыркысы белән итәгенә ябышкан үлән сабакларын каккалагандай итте дә туп-туры баш табиб каршына килеп басты. Коры гына исәнләшеп, басу җилендә карлыккан тавыш белән:

— Син ник безнең колхозга дигән пар казанын алып киттең? — диде.

— Казанны монда куярга мин куштым, Ниса апа, — диде Нурханова тыныч кына.

Алар буйга икесе бер чама, күзләренә туп-туры карашып торалар, әмма резин итекле, аякларын ерып баскан киңчә гәүдәле Ниса каршында нечкә сынлы Фидая көчсез, зәгыйфь күренде.

— Син нишләп алай безгә дигәнне бүтәннәргә бирәсе иттең әле? — диде Ниса, чыбыркы сабы белән итек кунычына суккалап.

— Монда кирәгрәк бит, Ниса апа. Сезгә дә булыр, бераз гына сабыр итегез.

— «Булыр» дигәнен болар көтсен иде! Начальник булдым дигәч тә, ферма малларын катырып үтерергә кем хокук бирде сиңа?

Таштимерова кычкырына башлады, кычкырган саен ярсый барды, әгәр Фидая чигенмәсә, аны йә иңбашы белән бәрер, йә, Алла сакласын, чыбыркы сабы белән төртеп җибәрер кебек иде.

— Мондый эшләрнең ничек эшләнгәнен белмиләр дип уйлыйсыңмы әллә син? Ирдән арынуың булды, күтәрелеп тә киттең! Беләбез ничек икәнен, белмиләр дип уйлама!

Аның тавышы хастаханәнең ачык ишеге янына чыгып баскан хатыннарга гына түгел, авылның үзенә үк ишетеләдер кебек иде.

— Әкренрәк сөйләш! — диде Нурханова.

Нисаның чыбыркысы янтыгы янында уйнаклый иде.

— Кран китми торсын моннан! Хәзер машина белән киләм дә алып китәм казанны.

— Котельныйның эчендә бит инде ул, — диде баш табиб.

— Чыгарырбыз! Алып китәм, менә күрерсез! Ирләр каршында итәк җилпеп үз дигәннәрен итәргә күнекмәсеннәр әле. Барып чыкмас!

Бөтенесе әсәреп киттеләр, башларын читкә борып, ишек тарафына чигенә башладылар. Тик Нурханова гына тыныч иде кебек.

— Монда сөйләшә торган сүз түгел бу, Ниса апа. Минем кабинетыма килерсең, шунда сөйләшербез, — диде ул нык итеп.

— Төкерәм мин синең кабинетыңа! Минем халыктан яшерен эшем юк! Әйтәсе сүземне теләсә кем алдында кычкырып әйтәм! Үземә тиешлене алам да!

Һәм Ниса тарантасына менеп утырды да, чыбыркысын болгап, сөзәк юлдан авылга таба төшеп китте.

«Нинди сирәк очрый торган тип! — дип кызыгып карап калды аның артыннан Рамилә. — Совет хатын-кызының үрнәге итеп плакатларга ясарлык. Ах, карандаш юк кулда!»

...Районга киткән шоферның юлы уңган булып чыкты, ул ярты тартма шешә алып килде. Эшчеләр тартманы күтәреп алдылар да бик канәгать кыяфәт белән кран янына китеп бардылар. Әле генә ыгы-зыгы килеп торган ихата тынып калды, уртак дәртләнеп тырышуның истәлеге булып биек торба гына тырпаеп тора, астан караганда, аңа кайчак салынкы болытларның итәге тиеп китә кебек иде.

Ниса чәпчегән арада, халык, әдәп саклап, таралышып беткән иде. Машина янында Рамилә генә калды. Аңа яны белән читтәрәк басып торган Фидаяның иңнәре салыныбрак төшкәндәй, сыны кечерәйгән кебек тоелды. Бу минутта ул олы җитәкче дә, көчле кеше дә түгел, фәкать рәнҗетелгән, кызгануга, юатуга мохтаҗ хатын-кыз гына иде... Менә ул, кесәсеннән кульяулык алып, йөзен каплады. Рамиләнең якынлашканын сизгәч, яулыгын битеннән алды, сынын турайтыбрак басты. Ә карашы хастаханә тәрәзәләренең берсенә төбәлгән. Тәрәзәнең ак пәрдәсе ике якка дугайландырып ачып куелган, ә уртасы күләгәләнеп тора иде.

— Анда... нәрсә? — дип сорады Рамилә.

— Операция бүлмәсе, — дип пышылдап диярлек җавап бирде Фидая.

Бу хәрабә рәвешендәге бина эчендә, кечкенә тәрәзә артында операция ясаулары Рамилә өчен гаҗәп тоелды.

— Әллә анда... сезгә операция ясаганнар идеме? — дип сорады ул.

— Үземә түгел... Иремә... Шунда йомылды аның күзләре... Мәңгегә...

«Ах, менә ничек икән бит!..» дигән уй әрнетеп сызып узды рәссам кызның күңелен. Тик, тагын да сораулар биреп, Фидаяның йөрәк ярасын бимазаларга базмады. Нурханова авыр итеп көрсенде дә:

— Бу бина яшисен яшәгән инде, — диде. — Бер елдан килсәң, син бу төшләрне танымаячаксың. Бинасы да, палаталары да шәһәрдәгедән ким булмас. Матур итеп җиһазларбыз, өр-яңа приборлар алып кайтырбыз. Мондагы бик күпләрне әҗәл кочагыннан тартып алып кала торган булырлар...

Кинәт ул Рамиләнең кулыннан тотып алды да кире төзелеш ягына әйдәде. Биек нигез аша җиңел генә сикереп, булачак бинаның эченә керде дә, кочагын җәеп, әрле-бирле йөренә-йөренә сөйләнә башлады:

— Менә монда поликлиника була. Ике якта да бүлмәләр. Коридорда чират көтеп утыручылар өчен уңайлы диваннар куярбыз. Авыл җирендә халык хастаханәгә иртәнге якта килеп тула. Чиратны бөтенләй үк бетереп булмас... Диварларына матур сурәтләр ясасак, күңелләре күтәрелеп китәр иде бит, ә? Юк, әллә башта өске катны, хатын-кызлар бүлеген бизик микән? Нечкә күңелле халык бит. Алай дисәң, травматология бүлегендә дә кешеләр озак яталар бит... Балалар бүлеген матур итеп бизәргә кирәк тә кирәк инде. Әкиятләрне сурәтләү яхшы булыр иде, шулай бит?

Рамилә исә нәрсәнең кайда буласын аңлап җиткерми, диварларга ясалачак сурәтләр хакында да уйлый алмый, йөзе алланып чыккан, күзләре очкынланган, таш, балчык өемнәре арасында биегәндәй бөтерелгән хатынга, аның кара күн береты астыннан килеп чыккан алтынсу чәчләренә, күн пальтосы сыланып торган сынына карап хәйран калган иде. Нинди хыялый бу хатын!

Менә ул Рамиләнең каршына килеп басты, арада нигез торып калды.

— Әйдә, кайсын алданрак эшләргә икәнен хәл кылыйк та, бүген үк договорын төзеп тә куйыйк, — диде ул.

— Ничек инде, болай капыл гына... Аны уйларга кирәк, — диде тәмам югалып калган Рамилә.

— Акчасы өчен куркасыңмы әллә? Борчылма. Табарбыз. Колхоз җитәкчеләре белән сөйләшербез. Берсенең дә мондый җиргә йомышы төшми калмый. Иң авыр чакларында киләләр... Ярдәм итми калмаслар!

— Туктагыз әле... Стеналарны күтәрегез башта!

— Аннары соң була ул. Сез тагын кайчан киләсез. Юк, моны хәзер үк хәл итәргә кирәк!

Рамилә салкын нигезгә бармагы белән төртте:

— Мин һавага картина ясау турында сөйләшә алмыйм.

— Планы бар бит аның. Анда бөтен үлчәмнәр күрсәтелгән! Әйдәле, мин сиңа бер нәрсә күрсәтәм!

Фидая нигез арасыннан сикереп чыкты да, Рамиләне кулыннан әләктереп, иске бинаның эченә алып кереп китте.

Эчтән ул тыштан караганда да иске булып күренде. Үзенә бер моңсулык оялаган алгы бүлмәне үтеп эчкә уздылар.

Бина гаҗәп үзенчәлекле төзелгән булып чыкты. Аның уртасында зур гына зал булып, ул ике кат биеклегендә эшләнгән иде. Дивар буенда аклы-каралы телевизор тора, аның каршындагы урындыкларда берничә хатын-кыз һәм ир-ат тезелеп утырган. Арада бер-ике үсмер дә бар. Алар, борылып, моңсу карашларын керүчеләр тарафына төбәделәр. Бер ишектән Гөлфия чыгып басты.

— Менә, кара әле! — дип, кулы белән түшәмгә ишарәләде Нурханова.

Анда, ике кат биеклегендәге диварга, зур итеп рәсем ясалган иде. Иркен сахра уртасында киңәеп үскән ялгыз имән. Зәңгәр күктә тынгысыз болытлар айкала, имән ябалдашы да, даладагы үлән сабаклары да көчле җилдән бер якка авышкан. Сулышларны иркенәйтерлек киңлекне, яшәешнең мәңгелеген һәм җиңелмәс гайрәтен тасвирлый иде бу картина һәм, сурәтләү җәһәтеннән караганда камиллектән ерак торса да, хисле иде. Иске, төссез, гомере беткән бу бинага каяндыр читтән килеп кергәндәй ят иде ул.

— Кем ясаган моны? — дип сорады Рамилә, соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп.

— Бер каторжанның әсәре бу.

— Нинди каторжан?!

— Заманында биредән Себер юлы узган бит. Этап хастаханәсе булган монда. Юл килгәндә сырхаулаган арестантларны дәвалаганнар. Шуларның берсе ясап калдырган, дип сөйлиләр. Күрәсеңме, бер гасыр элек яшәгән кешеләрнең дә эчендә җаны булганнары хастаханәләрне бизәргә тырышканнар! Ә без шул заманның арестантларыннан да катырак бәгырьлемени соң?!

## 5

Машинага утырып кайтыр юлга кузгалгач, Фидая, ян тәрәзәнең өчпочмаклы кечкенә өлгесен ачып, кызган битен салкын, дымлы җилгә куйды. Артта утырган Рамиләгә аның алтынсу бөдрәләре арасыннан алланып чыккан тыгыз яңагы гына күренә иде. Йөзендәниләр чагылганын белеп булмый, Нурханова моны юлдашларына күрсәтергә дә теләми, әмма Рамилә, эчке бер сиземләү белән, аның күңелендә ниләр кайнаганын тоя иде кебек. Хатын-кыз лабаса ул да!

Әйе, Нурханова бая ничәмә кеше алдында йөзенә бәреп әйтелгән хурлау сүзләренә каршы чәчрәп чыкмады. Гомумән, аларны ишетмәмешкә салышты. Ләкин йөрәгенә бик авыр иде аның, ай-һай авыр! Эчке ярсуын, сызлануын басарга тырышканга күрә дә, нигез ташлары арасында очынып, хыялланып йөрде бит инде ул! Киләчәктә булачак матур күренешләрне күз алдына китереп, үзенә юаныч табарга тырышты! Рамилә аннан Ниса турында сорашмасын, ул әйткән сүзләрне исеннән чыгарсын, дип шулай әвәрә килде...

Ә хәзер йөгереп йөреп тә, сөйләнеп тә булмый, машина кабинасы төрле яктан чикләп куйган. Баягы рәнҗүләр Фидаяның күңелен ялкын телләре булып көйдерә иде. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Болай гына үткәреп җибәрерлекмени? Онытырлыкмыни?

Рамиләнең битенә шул рәвешле пычрак аткан булсалармы? Хәзерге минутта түзеп утыра алмас иде ул. «Тукта!» — дияр иде шоферга. Сикереп төшәр иде машинадан, йөгереп китәр иде юл буена тезелеп баскан наратлар арасыннан... Барып чумар иде әнә теге авыл очындагы салкын күл суларына...

Хәер, бу машинага утырганчы ук әллә нишләп беткән булыр иде инде ул. Таштимерованың якасына ябышыр, битен тырнар иде...

Һәм... тәмам адәм көлкесенә калыр, җиңелер, хур булыр иде...

Әйе, ишетмәгәнгә салышып дөрес эшләде Фидая. Сабырлыгы белән җиңде. Нинди матур иде ул шул минутта. Һәм аның каршында пырдымсызланып, нәфрәтеннән тагын да сөйкемсезләнгән, кадер күрмәгәнлектән тупасланып иртә картайган, керле чәч очлары берет астыннан тырпаеп чыккан Ниса нинди ямьсез, котсыз күренде... Бичара... Үз кадерен белеп, үз-үзен бераз караса, битенә кершән ягып, чәчен әйбәтләп тараса, рәтлерәк киенсә, иң мөһиме — хатын-кызларча йөрсә һәм иплерәк сөйләшсә, башкалардан ким күренмәс иде, мөгаен. Әмма ул, үз җенесенә хыянәт итеп, ирләрчә булырга тырыша шул. Рамилә, күзен йомып, аны ир-ат рәвешендә күз алдына китерергә тырышып карады. Юк, барыбер ниндидер кыяфәтсез кушылма гына килеп чыкты. Ходай бирмәгәнне үз теләгең белән ясап булмый шул...

Шунда кинәт Рамиләнең күңел күзе ачылып киткәндәй булды: Нисаның болай ярсуы пар казаны аркасында түгел бит! Аның Фидаяга нәфрәте күптәннән килә булса кирәк. Ул аны, мөгаен, чибәрлеге, чын хатын-кызларга хас кыяфәте, сөйдерә, сөелә алганы өчен күралмыйдыр. Аннан сирпелгән нурны сүндерәсе, аны керләндерәсе, түбәнәйтәсе киләдер!

Ләкин Фидая, никадәр генә тырышса да, бу үчләнү хисен бетерә дә, киметә дә алмаячак. Андыйларның нәфрәтен тоеп гомер итәргә туры киләчәк аңа.

...Рамилә, алгарак авышып, юлдашының бөдрәләрен сулышы белән тибрәтеп:

— Теге хатын сезне казан өчен генә тиргәмәде бит, — диде.

Фидая гасабиланып көлеп куйды.

— Бер авылдан без. Кулга-кул тотынышып дигәндәй эшләдек. Ул — колхоз рәисе, мин мәктәп директоры идем.

— Ничек килешә идегез соң?

— Эт белән мәче кебек. Балкыш, туктат әле!

Фидая, алгы утыргычтан төшеп, Рамилә янына күчеп утырды. Аның эчен бушатасы килә иде.

— Ничек... шундый булды соң ул хатын? — дип сорады Рамилә, машина кузгалгач.

— Ирдәүкәләнгән дисеңме? Үзе шулай тели. Егет булу иң зур дәрәҗә бит ул. Сиңа ир-атларның: «Чын егет син, Рамилә!» — дигәне юкмыни? Иң зур мактау сүзе шул бит инде аларча. «Син чын хатын-кыз икәнсең» дию исә хурлауны аңлата. «Баба» дигән сүз бит инде ул. Шулай түгелмени?

— Бичара! — диде ихтыярсыздан Рамилә.

— Дөресен әйткәндә, мин үзем дә гомер буе егетләрдән ким булмас өчен тырыштым, — диде Фидая.

— Ә ник?

— Егет булу бит ул — чын кеше булу дигән сүз. Шулай түгелмени? Мин моны нәни чактан ук аңлаганмын. Күрше малае Ваккас белән сәкедә уйнап утырганда ук, мин әти булам, дип тарткалаша идем.

— Курчак уйнарга яратмадыгызмыни?

— Ярата идем. Тик моны яшерә идем. Әни гади колхозчы минем. Ә этием бик абруйлы кеше, тракторчы, тракторчыларның укытучысы иде. Исемен зурлап әйтәләр, район газетасында мактап язалар. Хезмәте дә күз алдында, нинди зур машиналарны дуылдатып йөртә! Ничек кызыкмыйсың? Ә менә без алтынчыны тәмамлагач, эти үзенә комбайн ярдәмчесе итеп Ваккасны алды. Мине түгел.

— Эшчән малай булгандыр.

— Ә укуда миннән нык калышты. Гел «бишле»гә генә укыдым бит мин, отряд советы председателе булдым. Классны рәткә тезеп, «айт-два»га бастырып, линейкага алып чыкканымны күрсәң син минем! Ваккас рәтнең уртасында гына иде.

— Ничек түзде икән? — дип көлеп сорады Рамилә. — Гарьләнгәне сизелә идеме?

— Гадәттә шулай бит ул. Мәктәптә иң активы — кызлар. Ә урамга чыксаң? Трактор-комбайн тирәсендә — малайлар, ат сыртында алар... Ваккас сабан туйларында ат чабышып, мәйдан әйләнә иде. Ә кызларга нәрсә? Авызга йомыркалы кашык кабып йөгерүме? Минә кайда ул гарьлек!

— Нәрсәсе гарьлек?

— Нишләп гарьлек булмасын? Бер мәктәптә, бер үк парта араларында утырабыз бит. Хыял күкләрендә бер үк йолдызлар кабына. Кемнәр безгә үрнәк? Корчагин, Газинур Гафиятуллин, Гагарин... Утлар-сулар кичү, зәңгәр күккә менү, ерак юллар гизү... Хыяллар малайлар өчен дә, кызлар өчен дә бер үк, уртак.

— Нишлисең, барыбызны да бер көтүгә кушып, бер үк чыбыркы белән куалыйлар шул, — диде Рамилә. — Сарык көтүен кәҗә тәкәсе артыннан иялтеп йөртәләр, дип укыганым бар. Без сарыкларга үрнәк итеп кәҗә тәкәләрен куялар шул.

Фидая җиңеләеп көлеп җибәрде.

— Дөрес! Ә минем башка андый чагыштыру килмәгән иде.

— Безнең мәктәпләр балаларны тормышка яраклы кеше итеп үстерә алмый. Табигать үзе җиңсә генә. Әйтик, мәхәббәт килгәч, һәммәсе үз урынына урнаша. Малае-кызы үзенең кемлеген аңлый башлый.

— Мәхәббәт?.. Ә беләсеңме, бу сүзне ишетүгә, минем аякларым ачыта башлый?

— Аяк? Мәхәббәт бит ул йөрәккә каба!

— Ә менә минем балтырларга капты.

— Ничек алай?

— Җәйге бер кичтә көтү каршыларга бара идем. Карасам, Ваккас кычыткан сабаклары белән кызларны куркытып йөри. Ул аларның аягына кизәнә, тегеләр чәрелдәшеп чабалар. Мине күрүгә йөгереп килде дә, озын кычыткан сабаклары белән шәрә балтырларыма уңлап-суллап бәргәләргә тотынды. Ә мин, аны күрмәгәндәй, һаман туп-туры үз юлым белән атлавымда. Күпмедер шулай бардык без урам уртасыннан. Мин — башны чөеп, ул минем янда иелеп, титаклап. Аякларның әрнүенә түзәм, бирешмим, Корчагин кебек чыдамлык күрсәтәм!

— Менә юләр, — диде гаҗәпләнеп Рамилә. — Ярткандыр ул сезне. Малайлар беренче мәхәббәтен шул рәвешлерәк аңлата, диләр бит.

— Аякларым төн буе ут янып чыкты... Яратуны шулай аңлаталармыни? Кычыткан белән генә дә бетмәде әле. Кышын тагын шундый бер «аңлашу» булды. Анысы да аяклар аша. Өлкән классларны без өч чакрымдагы күрше авылга йөреп укыдык. Беркөнне дәрестән соң стена газете чыгарырга калдык та, иптәшләремнән аерылып калдым мин. Кышкы юлдан чаңгы белән ялгызым кайтып бара идем, каршыма, чаңгы шуып, Ваккас килә. Мине туктатты да кесәсеннән карточка чыгарды бу: «Таныйсыңмы?» — ди. Карасам, моның учында минем сурәт ята. Дус кызыма бүләк иткән идем, мөгаен, шуннан урлаган. Җәлт итеп карточканы эләктереп алдым да фетр итегемнең кунычына кыстырып куйдым. Башымны чөеп, эреләнеп китмәкче идем, бу юлысы барып чыкмады. Ул мине төртеп екты да, итегемне салдырып, карточканы алды. Сугыша алмыйсың, ул көчлерәк! Оекчан килеш карга басып калдым шулай!

— Яратуы чын булган, димәк!

— Яратуны бик матур хис, дип сөйлиләр тагын! Шул булдымы инде матур мөнәсәбәт? Ваккасның кыланмышлары миндә ярату кешене кимсетә, кечерәйтә дигән ышаныч тудырды. Гомеремдә беркемне яратмам, миңа беркем гашыйк булмасын, ди торган идем. Олы максатларга омтылып, Газинурлардан, Гагариннардан үрнәк алып, зур эшләр башкарып яшәргә, егет булырга кирәк, дип уйладым һәм шуңа инандым.

Рамилә көлеп җибәрде:

— Ярый әле морадыгызга ирешә алмагансыз. Юкса нәкъ Ниса кебек булыр идегез. Ай... карагыз әле, анда үрдәкләр йөзә түгелме?

Машина елга аша салынган күпергә барып кергән иде.

— Әнә тегесе, зуррагы, шәмәхә муенлысы, этиләредер! Әниләре кайсы икән? Анысын бүтәннәрдән аерып алырлык түгел...

Күпер аша чыккач, Балкыш машинаны туктатты. Алар, җиргә төшеп, иркен сулыш алдылар.

# 6

Нурханова район үзәге Суташның үзәк урамында, биек тупыллар белән ышыкланган ихата уртасындагы яңа йортта яши иде. Ихата ачык яшелгә буялган койма белән әйләндереп алынган, ишегалдында такта кисәкләре, пычкы чүбе, шифер калдыклары ауный — төзелештә була торган үзенә бер күңелле тәртипсезлек хөкем сөрә. Түр яктагы койманы әле буяп та өлгермәгәннәр, аның артында җир казылып, түтәлләр ясалган, кырыйдарак куралар, карлыган куаклары тырпаеп утыра. Хуҗа яңа бакча ясый

башлаган, димәк, ныклап төпләнергә ниятләгән. Бакчаның уң кырындагы өр-яңа корылмалар — әле түбәсе дә ябылмаган сарай һәм мунча да шул хакта сөйли иде.

Болдырның яңа такталарында ботинкаларын салганда, Фидая Рамиләгә:

— Хәзер кайнар чәй эчәрбез, — диде. — Син кайната тор, мин тиз генә Иркәне бакчадан алып кайтыйм. Әбисе килеп өлгермәгәндер әле.

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, алар кечкенә аш бүлмәсендә, чәчәкле клеенка җәелгән өстәл янында өчесе бер түгәрәк табын ясап утыралар иде инде. Фидая зәңгәр бизәкле ситсы халат кигән, башына ак яулык чөйгән, тыйнак, сабыр, сөйкемле энигә әверелеп калган иде. Әле бая гына кара көн пальто киеп, игътибар үзәгендә булып, төзелеш мәйданын ду китереп йөргән тәвәккәл җитәкче белән аның бернинди дә уртаклыгы юк иде шикелле. Бу хатынның портретын ясау өчен, кайда булуына карап, төрле буяулар, төрле стиль кирәк булыр иде. Әйтик, гайрәтле ирләрне эшкә җигеп, куәтле машиналарны кузгатканда — ачык төсле майлы буяулар һәм кубизмга тартым стиль, чәй янында кызы белән сөйләшеп утырганда — нурлы да, бераз томанлы да акварель һәм йомшак, сыгылмалы сызыклар.

— Кызым, бакчада нишләдегез бүген? — дип сорый ул, аның тавышыннан-рәвешеннән наз бөркелеп тора иде.

— Менә болай иттек! — дип, ике кулын баш очына күтәреп болгый Иркә. — Флаг белән.

— Сафка басып йөрдегезмени?

— Ие. Сафка.

— Син кайда идең, кызым? Уртадамы?

— Мин иң алда! — ди кызчык мактанып.

Ул, күрәсең, әтисенә охшагандыр: шома көлсу чәчле, очлырак иякле. Соры күзләренең карашы үз яше өчен артык җитди, моңсу күренә.

Урам яктан каты гүләү ишетелде — машина килеп туктады. Өйдәгеләр башларын сузып тәрәзәдән карадылар. Анда олы капканы каерып ачтылар, әрҗәсенә берничә озын торба салган «КамАЗ» әкрен генә шуышып ишегалдына керә башлады. Таза гәүдәле, плащ итәкләрен җилбәгәй җибәргән, эшләпәсен артка шудырган ир уртасы бер кеше, аның каршына басып, уңгарак-сулгарак, дип фәрман биреп тора иде.

Нурхнованың йөзе караңгыланып китте, җитдиләнде, карашына боз суыгы иңгәндәй булды. Минут та үтмәгәндер, ул халатын көрәнсу күлмәгенә алыштырып, иңенә пальтосын элеп чыгып китте. Рамилә белән Иркә дә, өске киемнәрен алып, болдырга чыктылар.

Ишегалдында ике кеше машинадан торбаларны тартып төшереп азаплана, эшләпәлесе исә Фидая белән сөйләшеп тора иде.

— Мин сезне Кармаштан кайтып җитмәгәнсез дип торам, сюрприз ясамакчы идем, — диде ул, хәйләле елмаеп. — Җир катканчы, мунчага торба сузарга кирәктер бит инде. Мондый көнне пландагы объектлардан бушап булмый, шуңа күрә ял көнне китереп ташлыйк дип йөрү иде.

— Рәхмәт инде тырышканыгыз өчен, — диде Фидая, бик чишелеп китми генә. Аннары Рамиләгә борылды: — Таныш булыгыз, бу безнең төзү-монтаж идарәсе җитәкчесе Мирхуҗин иптәш. Ә бу — кунакка килгән рәссам Рамилә.

Мирхуҗин Рамиләнең кулын илтифатсыз гына кысып куйды, ә күзләре исә Фидаяда иде.

— Йортың казна фатиры булып саналса да, көчне аңа гына куеп булмый, төрле якка тарткалыйлар, — дип дәвам итте ул сүзен. — Син инде кешегә сиздерә күрмә, монда торба китергәнне белеп алсалар, асып куячаклар.

Ул, шаярган булып, кабартмадай күпереп торган кулының кырын салынкы ияге астына терәде дә башын өскә чөйгәндәй итенде.

— Үз чираты белән эшләргә иде, кем ашыктыра сезне, — диде Фидая салкын гына.

— Дөрес эшләмисең, — диде Мирхуҗин җанланып. — Ашыктыр син мине, мәҗбүр ит! Җитәкче буларак фәрман бир! Ул чакта без дә иркенләп эшләр идек. Ә болай читен бит. Монда сезнең икегезне, — ул Рамилә янына чыгып баскан Иркәгә ишарә ясады, — ана белән баланы диюем, мунчасыз тота алмыйм бит инде мин! Мәле, кызым!

Ул, плащ кесәсеннән чәчәкле кәгазьле шоколад чыгарып, Иркәгә сузды. Кызчык ике кулын артына яшерде.

— Кирәкми!

— Ал, сеңелем, ал! Биргәннең битенә карама, диләр! Әниеңнең әйткәне юкмы әллә?

— Илдарга бир әнә!

Анысы Мирхуҗинның үз малае иде.

— Ай-яй, анаң кызы булсаң да булырсың икән! — диде Мирхуҗин. Елмаюдан аның күзләре тәмам кысылып беткән иде.

— Мин әтинең кызы!
— Әтиең юк ич синең.
— Бар минем әти! Командировкада! Тиздән кайта!
— Ә-ә, шулаймыни? Бирсен Ходай!
Мирхуҗин шоколадны болдыр идәненә куйды. Алам дигәнне алмыйча, бирәм дигәнне бирмичә кала торганнардан түгел иде, күрәсең.
Фидая, итәгенә капланган кызының шома чәчен, тырпаеп чыккан нечкә толымнарын сыйпаштырып, сүзне Кармаш хастаханәсенә борды.
— Башыгызны катырмагызсана шул бүлнис белән! — дип, кулын селтәде Мирхуҗин. — Үзегезне кайгыртырга кирәк башта!
Фидая пар казаны турында, Таштимерованың дәгъвасы турында әйткәч, аның чыраеннан елмаю качты.
— Бугазы тыгылмас ул Ташнисаның! Сорый белеп сораса бер хәл иде. Акыра да бакыра, алашасына кычкырамыни!
— Казан кемгә тиеш иде соң?
— Аңа тамга сугып куелмаган. Үз өемә дә кайтарып ташламадым. Колхоз шул теләнергә яратылган нәрсә инде ул. Китер дә бир аларга. Кирпечен, тактасын, бульдозерын, запчастен... Йомшаграк торсаң, муеныңа менеп атланып, үзеңне дә басу сөрергә куарлар! Син күп сөйләнергә өйрәтмә аларны, ияләндермә, сүзеңне өзеп әйт тә ку да чыгар!
Монысына Фидая мәгънәле генә елмаеп куйды.
— Әле генә фәрман бир, дигән идең, хәзер инде өйрәтергә керештең. Нисага вәгъдә иткәнсең икән, аңа бирергә кирәк иде. Кармаш өчен тагын бер казан тапмаслыкмы әллә син?
Мирхуҗин аңа бик мәгънәле итеп, серле елмаеп карап торды, нидер әйтәсе килгәне сизелде. Аннары Рамилә белән Иркәгә күз сирпеп алды да:
— Аптыраган инде, Фидая Госмановна, — диде. — Ирләр белән әйбәт кенә аңлашам кебек, ә менә синең кебек хатын-кыз белән сөйләшә башласам, миңгерим дә китәм. Син дигәндә утка керергә әзер югыйсә, билләһи менә! Казанны бит аны басуга чәчеп үстермиләр!
Ул, чыннан да аптыраушта калгандай, ике кулын як-якка җәеп җибәрде, аннары капка ягына таба борылды. Ул арада торбаларны бушатканнар, машина чигенә башлаган иде инде. Нәни Иркә Мирхуҗинны керфек очлары белән тишәрдәй итеп карап калды.
— Бик үткен кешегә охшаган, — диде Рамилә.
— Аларсыз да яшәп булмый шул, — диде Фидая уйчан гына. — Менә бит, миңа йортны да ул җиткерде, хастаханәне дә ул торгызачак. Әгәр теләсә...
Алар кире кереп өстәл янына утырганда, чәй суынган, ризыкның тәме кимегән иде. Гомумән, өйдә ямансулык көчәйгән, почмаклардан посып кына ятимлек карап тора иде кебек.

## 7

Төн карасының бик хикмәтле бер ягы бар: кешеләрне бер-берсенә якынайта, уйларын бер эзгә сала, серләрен ачтыра ул. Бу кич шулай Фидая белән Рамиләне дә сердәш, фикердәш итте.
Урынны Фидая үзенә залга, ә Рамиләгә кече бүлмәгә, Иркә караватының каршысындагы диванга җәйгән иде. Бер көн эчендә күпне күреп, шактый каршылыклы тойгылар кичергән рәссам башы мендәргә тиюгә йокыга талды, әмма күпмедер вакыттан соң кинәт сискәнеп уянып китте. Әллә урамнан узган машина тавышы, әллә пәрдәләр аша саркып шуып узган фара уты бозды йокыны — Рамиләгә эссе булып тоелды. Ул, урыныннан торып, алгы бүлмәгә чыкты һәм, зал ягының якты икәнен күреп, ярым ачык ишеккә карады. Фидая диванда, җәелгән урыны өстендә, халатын бөркәнеп, аякларын бөкләп утыра иде. Кулында кечкенә генә китап. Рамилә ничек кенә сак басарга тырышса да, Фидая аның адым тавышларын сизде, башын күтәреп ишек ягына карады да:
— Кер, кер, — диде. — Утыр менә монда.
Һәм, ак җәймәне сыпыргалап, янәшәсеннән урын күрсәтте.
— Нишләп йокламыйсың? Урын сайланасыңмы әллә?
— Ә сез нишләп йокламыйсыз?
— Гадәт шундый минем, — диде Фидая. — Төнге икеләр тирәсендә йокым кача.
— Күптәннәнме шулай?
— Икенче ел китте.
— Берәр хәл булган идеме әллә?
Рамилә моны бик йомшак итеп сорарга тырышты. Фидая, башын иеп, карашын китапка төбәде.

— Менә тыңла әле, ничек ди шагыйрь Хәсән Туфан:

Таллар кистем, баулар иштем,
Саллар салдым суларга.
Китәр ягым — унда да бит,
Җилләр исә сулларга.
Өстә — дулкын,
Астан упкын
Куллар сала салыма...

— Гаҗәп бит, шундый гади, берничә генә сүз дияргә була. Ә күз алдында — кешенең язмышы. Фаҗигале, ачы язмышы... Әйе, безнең язмышлар дәрья кебек шул, дулкыннар арасында йөртә, упкыннар өстенә илтеп кертә. Аңа чыдарлык салларны кем генә ясый ала икән?

— Тәвәккәл җанлы, оста куллы кешеләр азмыни? — диде Рамилә дә уйланып һәм, иңе белән Фидаяга таба авышып, китапка күз салды: — Өстә — дулкын, астан упкын куллар сала салыма...

— Кем ул «оста куллы, тәвәккәл кеше»? — дип сорады Фидая.

Рамилә бу сорауның эчке бер мәгънәсе барын сизде, әмма аңламады.

— Андый кеше фәкать ир-ат кына була ала, — дип, үзенә үзе җавап кайтарды Фидая. — Әйе, ир-егет кенә. Таллар кисеп, баулар ишеп, давылга каршы салда аккан кешене хатын-кыз итеп күз алдына китереп буламыни?

Ул бераз тынып торды.

— Кыз бала ул дулкын эчендә түгел, ерактан килгән салларны каршы алырга дип, чәчен җилдә тузгытып, ярга чыгып баскан хәлдә генә күз алдына килә. Ә бит язмышларда әллә ни аерма юк безнең: җилләр безгә дә бәрә, без баскан урыннарда да упкыннар хасил була кайчакта. Ә көч, гайрәт тигез түгел! Менә бу шигъри юллар да ир кеше турында. Без, хатын-кызлар, шуны аңламыйбыз. Өермәләрнең уртасына ашкынабыз, көчебез җитмәсен уйламыйбыз.

Рамилә аның йөзенә текәлеп карады да, эчтән әрнеп:

— Нигә сез үзегезне болай кимсетәсез? — диде. — Әгәр беләсегез килсә, сез бик сирәк һәм бик зур хәзинәгә ия. Мин сезнең портретыгызны шундый итеп ясар идем!.. Ә рәссамнар бик талымлы халык, аларны сирәк кеше рухландыра, ышаныгыз миңа. Кайчакта, урамнан барганда, шундый оригиналь кешеләр очрый, ах, дип куясың, артыннан ияреп барасың. Ләкин күзәткән саен, гайрәт чигә бара. Йә күз карашы мәгънәсез, йә хәрәкәтләре килбәтсез тоела башлый. Ә сез... Сезгә караган саен күңел берегә. Сез бик тә, бик тә бәхетле булырга тиеш!

Чыннан да, диван янындагы сары абажурлы торшер яктысы Фидаяның бераз тузгыган чәчләрен алтынга мангандай иткән, бөтен йөзенә, кыяфәтенә затлылык, камиллек өстәгән иде. Ләкин ул үзе моны тоймый кебек, Рамиләнең мактау сүзләренә моңсу көлемсерәү белән җавап бирде. Ирен читләреннән чак кына өстәрәк сөйкемле нәни чокырчыклар уелып чыкты, бу аның йөзенә сабыйларча беркатлылык өстәде. «Менә шушындый яктылыкта, уйчан һәм моңсу итеп тасвирларга кирәк бу хатынны», — дип уйлады Рамилә.

— Бөтен кешенең карашын җәлеп итү бер дә яхшы нәрсә түгел ул, — диде Фидая бераздан.

— Чибәрлек начар димәкчеме әллә сез?

— Бу заманда хатын-кызга урта кул булу бик җиткән. Чибәрлек күпләрне бәхетсез генә итә.

— Болай дип әйтү... — Рамилә сүз таба алмый торды. — Гөнаһ! Җинаять! Кешенең матурлыгы мәңге-мәңге зур байлык саналган.

— Белмим инде, кемгә ничектер. Әгәр дә син минем тышкы кыяфәтемне хәзинәгә санийсың икән, бик нык ялгышасың. Миңа калса, гап-гади ир бала булып тусам, миңа яхшырак булган булыр иде.

— Һәм бик ялгышасыз! Бу һич дөрес түгел!

— Бәлки, кайдадыр, без белмәгән җирләрдә, хатын-кызның чибәрлеге байлыкка саналадыр да, алар рәхәт яшидер. Ләкин бездә түгел. Бу җирлектә үзеңне чын кеше итеп тою өчен ир-егет булу кирәк. Мин үскәндә бар яктан да малайлардан уздырырга тырыштым, океаннар гизү, тауларга менү, күккә, хәтта космоска очу турында хыялландым. Ләкин кыз кеше өчен диңгез причаллары да, күк капкалары да ябык булып чыкты. Үрләрнең иң биеге — үзебезнең университет иде.

— Анысы да начар түгел бит! — диде Рамилә.

— Бик яхшы! Әмма анда бару юллары кызлар өчен кантарлырак булып чыкты. Пароходта бер салмыш адәм өзми-куймый бәйләнеп барды. Нәрсә аркасында? Бер күрүдә гашыйк булган, имеш, мәхәббәтен аңлата! Монысы бер гарьләндерде.

Аңарчы рәсемнәрдә, открыткаларда гына күргән университет ишеген беренче тапкыр атлап кергәндә шулкадәр рухланган идем. Ләкин анда да кемлегемне сиздерделәр. Бер көнгә соңга калгансың, диган

булып, документларымны кабул итмәделәр. Ә егетләрне чакырган белдерүләре тактада эленеп тора иде! Ай-ваема карамыйча, кире борып җибәрделәр мине. Шуннан китте... Әллә син Ниса апагыз гына миңа ажгыра дип уйлыйсыңмы? Мин андыйларны яшьтән ишетәм. Казанга шул беренче баруымда ук башымнан коендырдылар.

Әйе, Нисаның агулы сүзләре нык кадалган иде бу чибәр ханымның бәгыренә!

— Онытыгыз сез аны! — диде Рамилә. — Эт өргән кебек кенә кабул итегез!

— Бер генә булса, чүпкә дә санамас идем дә... Адым саен зәһәрен салгач, кул селкеп кенә узып китеп булмый шул.

— Әллә бик еш килеп бәйләнәме?

— Эш анда гына түгел. Эш, гомумән, кешеләрнең мөнәсәбәтендә. Теге чакта Казанга баргач та шундый хәлгә юлыктым. Документларымны тапшыра алмагач, шактый кыен хәлдә калдым мин. Шәһәрдә танышым юк, тулай торакта кундырырлар дип өметләнгән идем. Хәер, кем кертсен инде анда мине? Ул көнне пароходка да соңга калдым. Нишләргә дә белгән юк.

Бер кечкенә бакчага кереп утырдым шулай. Каршымда бүрәнәләрдән ясалган баһадирлар басып тора, үзем дә агач кебек уйсыз, хиссез, кирәксез. Шунда бер узгынчы каршымда туктап калды. Кырык яшьләр тирәсендә, гади генә киенгән арык кына абзый иде бу. «Баядан бирле караштырып йөрим, сеңелем, бик нәүмиз күренәсең, — ди. — Адаштыңмы әллә? Авылдан килгәнгә охшыйсың».

Күңелем тулып китте. Күз яшьләремә буылып, ике авыз сүз белән хәлемне аңлатып бирдем мин моңа.

— Менә күрдегезме, — диде Рамилә. — Кыяфәтегез гадәти булса, ул кеше, бәлки, күз дә салмый узып киткән булыр иде. Чибәрне күреп тукталып калган ул, мөгаен.

— Шул шул менә, узып китсә, бәлки, яхшырак та булыр иде...

— Начар кеше булып чыктымыни?

— Юк, бик яхшы булып чыкты үзе. Зарымны тыңлады, юатты. Үз башыннан үткәннәрне сөйләп алды. Яшь чакта ул да институтка кермәкче булган да, керә алмаган икән. Хәзер заводта эшли, инженерлардан күбрәк ала. «Баш ярылып, күз чыкмаган, борыныңны салындырма, — диде ул миңа. — Хатын-кызга эш табу җиңелрәк. Парикмахер дисеңме, пешекче, сатучы дисеңме, һәммәсе дәрәҗәле, төшемле хезмәт». Минем кунар җирем югын белгәч, үзләренә чакыра башлады. «Кунакханә кебек үк иркен түгел, гаиләбез дә ишле ишлесен, — диде. — Бер кичкә кер мичкә, диләр. Сыярбыз». Өйдә кеше күп, дигәч, шикләнеп тормадым, иярдем инде. Кабан күле артында үз йортлары белән яшәп яталар икән, чыннан да, өй тулы кеше иде. Абзый минем хакта: «Авылдан укырга килгән, кунып чыгар җире юк», — дип таныштырды. Бик ачылып китми генә табын янына чакырдылар. Абзый бераз салмыш булган икән, үз хәлем хәл булганга, мин анысын сизмичәрәк калганмын.

Урынны миңа идәнгә салдылар. Төнне ничек кирәк алай уздырдым. Иртән абзый сандык актарырга тотынды. Хуҗа хатын миннән ниндидер абза-җиңгәләрен сораштыра башлады. Чит-ят икәнемне белүгә, чырае кара янып чыкты, иренә ябырылды бу: «Нинди кәнтәй алып кайттың син монда?» — ди. Абзый аңлатырга маташып та карамады: «Мунчага бармакчы идем, чиста майка кайда икән?» — ди. «Ә-ә, мунчага барасыңмыни, аруланасың киләмени, — дип кычкырына башлады хатыны. — Алайса, бу кәнтәеңне дә иярт, бар, арканы ышкырга кирәк булыр!»

Баш түбәмнән шакшы су койдылармыни! Минем урында берәр малай-шалай булса, аны да шулай мыскыл итәрләр идеме икән?

Аның белән генә бетмәде әле. Пароходка утыргач, кеше күзенә чалынмаска тырышып, өске киштәгә менеп яттым. Иртән табанымны кытыклаганга уянып китсәм, пумала башлы бер ир аягымны сөямләп үлчәп маташа. «Моны босоножка белән алып кайтып булмас, бездә юллар бик пычрак, — дип сөйләнә үзе, — берәр пристаньга төшеп, галуш алып кигезергә кирәк булыр». Мине авылына алып китмәкче!

Рамилә көлеп җибәрде:

— Монысы инде анекдот!

— Кемгә анекдот, кемгә гарьлек. Күз төшәрлек кызларга күпләр тәти әйбергә караган кебек кенә карый. Кайсы тарта, кайсы төртә, кайсы тибеп очыра. Казанга беренче баруымда менә шундый «университет» үттем мин. Шуннан соң бер чәчкәгә охшаттым үземне.

— Дөрес! Гөл кебек сез!

— Гөлнең ниндие бит! Берәүләрнең бакчасында бик ерактан күзгә ташланып торган сирәк гөл күргән идем. Биек сабаклы, учма-учма куе сары чәчкәле. Сокланып якынрак килгән идем, ни күрим, чебен сарып алган моны. Ямь-яшел эре чебен! Чирканып киттем.

— Сез бит үлән түгел! — диде Рамилә. — Чебеннәрне куарлык кына хәлегез бар. Үзегезгә насыйп, пар булган бердәнбер күбәләкне димме, яки бал кортын гына җибәрегез янызгыза! Сез олы мәхәббәткә лаек. Чибәрләргә ярын табу башкаларга караганда мең тапкыр җиңелрәк. Язмышыгызга рәхмәт укып яшәгез!

Фидая, башын түбән иеп, серле көлемсерәде. Нидер әйтергә теләде, ләкин шул минутта күрше бүлмәдән:

— Әни! — дип еламсыраган тавыш ишетелде.

Сүз өзелде, Фидая чыгып китте. Ә Рамиләнең күбрәкне beләсе килә иде. Җиде төн уртасында очраклы кешеләрнең үзен ничек-ничек җәберләгәннәре исенә төшкәннән йокысы качып торып утырмаган иде ул, билгеле. Бөтенләй башка уйлар, тирәнрәк, көчлерәк хисләр белән яна иде бу чибәр хатын. Тик, күрәсең, ул Рамилә кебек чит кешегә яшерен серләрен белдерергә ашыкмый, сөйләгәннәре — өстә ятканнары гына иде.

Рамилә, урын өстендә яткан китапны алып, ачык битендәге соңгы юлларны укыды:

Тынма, дәрья, айка-чайка,
Күнмәгәнмен тынлыкка.
Упкыннарың берни түгел,
Батырма тик моңлыкка...

# 8

Күргәзмәне бөтен шартын туры китереп ачтылар. Картиналар мәдәният сараеның бию кичәләре үткәрелә торган иркен вестибюленә эленгән, керер юлга аркылы киң кызыл тасма сузылган иде. Билгеләнгән сәгатьтә ишек төбенә халык җыелды.

Райкомның беренче секретаре Искәндәров белән Тәүзих Әхмәдуллин, тасманы уртадан кисеп бәрәр кисәген кесәләренә салдылар, мондый очракларда сөйләнә торган сүзләрен әйттеләр. Халык, кереп, картиналардан карап торган таза егетләр, чибәр кызлар каршында каушап калгандай сагаеп, әкрен генә зал буйлап йөренә башлады.

Ул арада ишек төбенә нык пычранган «ПАЗ» автобусы килеп туктады. Аны тәрәзәдән күреп, Фидая ишеккә юнәлде. Залга чәчәкле кызыл шәле бөдрә чәченнән шуып төшкән, утлы күмердәй кара күзле, янып торган битле хатын килеп керде дә Фидаяны кочагына алды.

— Ник алдан әйтмәдең?

— Ниса барыбер җибәрмәс, транспорт бирмәс дип уйладым. Шуңа күрә алгысытасым килмәгән иде, — диде Фидая акланганнай.

— Ташнисадан куркып тораммы соң! Үземә кирәкне бугазыннан каерып алам мин аннан! Өлкән классларның бөтенесен алып килдек!

— «Бишле» сиңа, Каләмгөл апа! — дип, аның аркасыннан сөеп какты Фидая. — Плюс белән. Шуңа өстәп — медаль! Анысы Таштимеровага бирешмәгән өчен!

— Аның өчен медаль тага торган булсалар, минем түштә урын калмас иде инде. Балалар! — дип, ишектән кергән укучыларга борылды Каләмгөл. — Итекләрегезне әйбәтләп юдыгызмы? Шыпырт, шауламагыз! Хәзер экскурсовод һәммәсен аңлатыр.

— Экскурсовод юк бит монда, — диде Фидая.

— Нишләп юк? Булырга тиеш! Балаларның кайберләре беренче тапкыр күргәзмә күрә. Укучылар! Кулыгызны күтәрегез әле: кайсыгызның күргәзмәдә булганы бар?

Үсмерләрнең күбесе учын баш түбәсенә сузса да, Каләмгөл, үзенең сүзен расланган дип санап:

— Күрдеңме? — диде.

— Рәссамнар гына килгән шул монда, — диде Фидая.

Каләмгөл шундук килгән кунаклар белән таныштыруны таләп итте, һәркайсы белән кул бирешеп күрешеп чыкты. Аның кыяфәтенә һәм ташып торган дәртенә таң калган Тәүзих, танышканда, кулын бик озак кысып торды.

Шул рәвешле залның бер башында болганыш булып алды, дәрәҗәле тынлык бозылды, бөтенесе хәрәкәткә килде. Һәр рәссам, чиратлап, үзенең әсәре турында балаларга аңлатма бирергә тиеш булды. Укучыларның берничәсенә алар сөйләгәнне язып барырга кушылды. Ә Каләмгөлгә охшаган, шундый ук ут күзле, алма битле, иңбашына чәчәкле шәл салган Зарема сумкасыннан фотоаппарат чыгарды.

— Монда да төшер, урамга чыккач та төшерерсең, — диде аңа Каләмгөл. — Берсе чыкмаса, икенчесе чыгар.

Ул булган җирдә эш җиңеләя иде. Фидая, җиңел сулап, төркемнән читләште: картиналарны шау-шусыз, ялгызы гына күздән кичерәсе килә иде аның.

Балаларның йөзләрендә соклану һәм кызыгу... Бәхетлеләр, алар сәнгать әсәрләренең җитешсез якларын күрергә өйрәнмәгән шул әле. Керләнмәгән, сизгер күңелләре белән фәкать рәссамнарның тырышлыгын, ихласлыгын, омтылышларын тоялар, шуннан тәм табалар. Фидая исә күпне күрә: төсләрнең күзне ерткан

урыннарын да, кеше тәненең хәрәкәтен бирә алмыйча, күп очракта адәм балаларын курчак кебек тасвирлаганны да... Күп белгәннең башы авырта, дигәннәре шушыдыр инде.

Ләкин, тукта... Бусы нәрсә? Гап-гади күренеш тасвирланган, фәкать тәрәзә төбенә балчык чүлмәк белән куелган чәчәк бәйләме генә. Менә син аның каршына килеп бастың һәм бүрәнә йортның эченнән ачык тәрәзәгә карагандай булдың. Ә анда, чүлмәктә, алсу, алтынсу, кызыл розалар... Нәрсәсе белән күңелне кузгатты, аякларның хәлен алып, үзләре каршында бастырып калдырды соң әле алар?

Чәчәкләргә әле күтәрелеп кенә килгән иртәнге кояш нурлары төшкән. Бу нурлар яктысында чәчәкләр шундый чын, теп-тере булып тоела ки, орынсаң, таҗ яфракларының дымсу, салкынча тыгызлыгын тоярсың, хуш исе күкрәккә тулыр кебек. Күңелдә шигъри юллар терелде:

Баскан эзләреңә мин битемне куям,
Эзләреңнең назын, җылылыгын тоям...

Тукта, нилектән мондый юллар хәтергә килде соң әле? Таң нурына коенган гөлләр бәхет турында сөйли — шуңа. Алар офык артыннан күтәрелеп килгән кояшка каршы тагын да ныграк күкрәп, матураеп ачыла баралар. Гөл керфекләренең бу рәвешле талгын һәм тыелгысыз ачылганын адәм баласы гомеренең иң бәхетле минутларында гына күрә, тоя ала торгандыр. Фидаяның да андый минутлары бар иде... Әйе, гөлләр белән бергә йөрәге нурга, гүзәллеккә каршы ачылган, күңеле яшәү тантанасы белән тулган сәгатьләре бар иде аның...

— Исәнмесез, Фидая Госмановна!

Ул кинәт айнып киткәндәй булды, борылды һәм карашы белән кемнеңдер китель түшенә төртелде. Аннары, башын күтәргәч кенә, исәнләшүченең көлемсерәгән йөзен, үчекләү тулы соры күзләрен күрде. Урман хуҗалыгының баш инженеры Гаяров икән.

— Фидая Госмановна, сез бит укучыларны бәрәңгедә дигән идегез. Басулары мондамы әллә аларның? Тик бәрәңгеләре генә күренми нишләптер, — диде ул, як-ягына карангандай итенеп.

— Сез дә бу сәгатьтә агач утыртып йөрмисез икән бит әле.

— Ә мин монда эш белән йөрим. — Гаяров, Нурханованың төкселегән сизмәгән дә шикелле, һаман көлемсерәвендә иде. — Рәссам иптәшләрне күреп сөйләшәсе бар иде. Безнең кызлар кашык өчен бизәк таба алмый җәфалана. Открыткалардан, китаплардан эзләп интегәләр. Андагылар бит инде ул мең күргән нәрсә. Яңалары булсын иде. Менә, мәсәлән, бу чәчкәләр ярыйсы гына кебек. Сез ничек уйлыйсыз?

Фидаяның ачуы йөзенә бәреп чыкты. «Надан! Туң йөрәк! — дип уйлады ул. — Сандугачтан сыбызгы ясарга маташу белән бер ләбаса бу!» Тамакка ачы төер утыргандай булды. Фидая, тупас сүз әйтүдән тыелыр өчен, Гаяровка аркасы белән борылды. Ләкин Давыт аны аңламады, әллә юри аңламамышка сабышты, каршысына чыкты да, иелә төшеп, һаман көлемсерәп:

— Минем генә сүзем үтмәс дип куркам, Фидая Госмановна, — диде. Әллә җитди сөйли, әллә шаяра иде, аңламассың. — Олы җитәкче буларак, безнең гозерне аларга сез җиткерсәгез яхшырак булыр иде. Районга нинди зур кунак килсә, бүләк сорап безгә йөгереп киләсез бит!

— Минем сезгә килгән юк бит әле.

— Килегез, карагыз! Без инде зур вазалар да ясый башладык. Маркетри дигәненә дә өйрәнеп киләләр. Бераз гына ярдәм кирәк! Сурәтләрнең беркемдә югын ясарга иде. Әнә теге картинаны маркетри белән рәхәтләнеп ясап булыр иде бит. Төсе дә мач килгән: күксел, коңгырт та карасу. Менә монысын әйтәм, монысын!

Ул Фидаяны, беләгеннән әләктереп, аргы башка әйдәде. Кулы кайнар, нык икән...

Аны җәлеп иткән картинада ат сурәтләнгән иде. Җәйге иртә, томан әле генә таралып килә. Алгы планда ак айгыр арт аякларына баскан да, җир тетрәтеп чабарга әзерләнеп, күкләргә ирешерлек итеп кешнәп җибәргән. Ул башка атларны да үзе белән бергә җилкетеп, офыкларга ыргылырга, кояшка таба чабарга өнди. Аның артында янып торган учакка аргамакның ургуы күчкән диярсең, ялкын телләре биеккә күтәрелгән һәм гүяки атның канатларына әверелеп, аның ялына кушылып җилпенә.

Көч, гайрәт, яшәү дәрте, хисләр кайнавы тасвирланган иде төсләргә саран бу картинада. Киләчәк көннәргә озын юллар, кайнар хисләр вәгъдә итә кебек ул.

— Учагын алып ташларга кирәк, — дип сөйләнде ул арада Гаяров. — Бутый гына. Агачтан ясаганда катлауландыра. Ә айгыры шәп. Анысы өчен тырышсаң да була.

Алар янына Рамилә килеп басты.

— Фикерегезне миңа да әйтерсез, бәлки? — диде ул сагаеп кына.

— Миңа бик ошый. Канатлы ат, канатлы хыяллар, ашкыну һәм гайрәт, — диде Фидая ашыгып. Ул Гаяров берәр төрле саксыз сүз ычкындырып, рәссамның нәзберек күңелен китеп куймагае дип шикләнә иде. Фидаяның сүзләреннән Рамиләнең йөзе ачылып китте.

— Кайчакта мин тәҗрибә ясыйм шулай, — диде ул, аңлатуны кирәк табып. — Үземне төрле стильдә сынап карыйм. Әгәр ошый икән, мин бу картинаны сезгә бүләк итә алам!

— Фидая Госмановнага әнә тегесе дә бик ошады, — дип, Гаяров кулы белән роза чәчәкләренә ишарә ясады.

Рамиләнең тәкъдименнән һәм Гаяровның әдәпсезлегеннән югалып калган Фидая авыз ачканчы, тегеләр үзара килешеп тә өлгерделәр.

— Чынлапмы? — диде рәссам кыз рухланып. — Анысы да минеке. Алайса, мин сезгә шунысын бүләк итәрмен, — диде ул Фидаяга.

— Ә аты миңа бик ошаган иде, — диде көрсенүен эченә яшергәндәй, шул ук вакытта өмет белән Гаяров.

— Сез нәрсә? Алай шаярырга ярыймыни! — диде Фидая, ниһаять, аңына килеп. — Сәнгать әсәре бит алар. Бик кыйммәт тора!

— Арзанмы, кыйбатмы, һәркем үз әйберсенә үзе хуҗа, — диде Гаяров, искитмәгән кыяфәт белән. — Бүләктән баш тарту килешми. Менә хәзер бик әйбәтләп, үз кулы белән, артына «Калтай урман хуҗалыгына. Чын күңелдән» дип язып имза куя да, без аны мең рәхмәтләр әйтеп кабул итәбез. Үзебез дә җавапсыз калмабыз, маркетрида ясалганның иң беренчесен аңа тапшырырбыз.

Һәм ул аяк очларына басып, тагын да биегәеп, шактый югарыдагы кадактан рам асылган бауны ычкындырырга үрелде.

— Туктагыз! — дип, аның терсәгенә ябышты Фидая. Егетнең сүзләрендә дә, кыланмышларында да янында торгын хатыннарны баласыту, үртәү ярылып ята, бигрәк тә шунысы күңелгә тия иде. Фидая Рамиләгә борылды да: — Бирмим, диген, ныгытып әйт! — диде.

Рәссам икеләнеп калды:

— Сезгә ошавына мин бик шат. Күргәзмә ябылганчы гына торсын инде. Аннары...

— Үзем өчен түгел, мин дә коллектив өчен тырышам, — дип, Гаяров, ниһаять, баудан кулын алды.

Ул арада Рамиләне Каләмгөл балалар янына чакырып алып китте.

— Сез теге чәчкәләрдән баш тарта күрмәгез тагын, — дип күз кысты Гаяров Фидаяга. — Кулга керергә торганны ычкындырырга ярамый.

— Кулыгыз үзегезгә таба кәкре икән. Урман хәтле урманнан бер түбә ябарлык такта бирәсегез килми, ә кешедән булса, давай да давай.

— Хуҗалык эше шундый бит инде ул, Фидая Госмановна. Кулдагыны ычкындырмаска, эләккәнне тартып алырга. Шундый булмасак, безне эштә тотмыйсыз да сез!

Сүзне тагын да озайту килешмәс кебек тоелды, Фидая балалар төркеме янына атлады.

Бу Суташ халкы моңарчы рәссамнарсыз ничек яшәгән, диярсең. Каләмгөл күргәзмәне берәр атнага Баллыболынга илтүне таләп итә башлады. Алдынгы колхозчыларның портретларын ясатып булмас микән, дип сорашты. Ул эш кыйбатка төшәрме, Таштимеровадан акчасын алып булырмы, рәссамнарның кайсысы кеше сурәтен ясарга остарак икән... Ник дисәң, күрше «Җиңүче»гә ниндидер рәссам портретлар ясаган икән дә, акчаны күп каерган, сыер савучыларны, комбайнчыларны ямьсез ясаган, дип сөйлиләр.

# 9

Урамга чыгып, җыелышып карточкага төшкәндә, шактый гына ыгы-зыгы булып алды. Каләмгөл рәссамнарны уртага бастырды, тирәли балаларны тезде, егетләргә алга чыгып чүгәләргә кушты. Фидая Рамилә белән Әхмәдуллин арасына туры килде.

— Кызларыгыз бик чибәр икән сезнең, — дип пышылдады аның колагына Тәүзих.

— Безнең район халкын чибәр диләр шул. Берәр кая барып кайтсам, үзем дә сизәм, — диде Фидая.

— Матуррак киендерергә иде, — дип куйды Рамилә.

— Нишлисең, кибеттән алган курткалар инде, — диде Фидая. — Халыкны матур киендерү турында уйлаган кеше юк шул бездә.

— Зиләйлә, Зиләйлә, кил монда! — дип кычкырды шунда бер кыз. — Бас менә монда, сыясың!

Барысы да, борылып, төркемнән читкә китеп барган озын, төз буйлы, кызыл курткалы кызга карадылар. Ул җавап бирмәде, борылып та карамады, урам якка атлавында булды.

— Кем ул? — дип сорады Рамилә Фидаядан.

— Укучы. Сигезенче класстан.

Карточкага төшү мәшәкате төгәлләнеп, балалар автобуска утыра башлагач, тагын кычкырдылар:

— Зиләйлә! Кил тизрәк! Китәбез бит!

Кызыл курткалы кыз клуб почмагы артыннан чыгып килә иде. Шулчак каршыдагы китап кибетеннән кулына юка китапчыклар тотып, — балалар өчен булса кирәк, — кыска плащ, күн фуражка кигән утыз бишләр тирәсендәге бер ир кеше килеп чыкты. Аны күргәч, Зиләйлә сөртенеп куйгандай булды, йөзенең бурлаттай кызарынганы ерактан ук күренде. Рәссамнар белән көлә-көлә сөйләшеп торган Каләмгөл нидер сизенгәндәй борылып карады да, китап тоткан ир кешене күреп, аңа каршы китте.

— Китәбез, Гыйззетдин, эшеңне төгәлләгән булсаң, әйдә, утыр!

Ир кеше, Зиләйләгә карап, адымнарын әкренәйтте. Бу өчәү арасында ниндидер киеренкелек, катлаулы мөнәсәбәтләр барлыгы күзгә ташланып тора иде. Урам кырыендагы машинага таба юнәлгән Фидая белән Рамиләнең юлы алар арасыннан үтә иде, ничектер яхшысынмыйча туктап калдылар.

Зиләйлә, нишләргә белмәгәндәй, башын боргалап торды да урам якка юнәлде. Гыйззетдин аның артыннан карап калды.

— Әтиле-кызлымы әллә алар? — дип сорады Рамилә Фидаядан.

Кыз, автобустагыларның карашыннан ышыкланырга теләп, Нурханованың «уазигы» артына килеп басты.

— Әй, кызый, — дип, тәрәзәдән башын сузды Балкыш. — Баллыболыннанмы әллә сез?

— Баллыболыннан.

— Юл ничегрәк анда? Батып ятмадыгызмы?

Зиләйлә, таралган зиһенен тупларга тырышкандай, көттереп кенә җавап бирде:

— Баттык... бер тапкыр.

— Тартып чыгардылармы?

— Малайлар төшеп этеп чыгарды.

— Ә сез утырып тордыгызмы?

Кыз егеткә, мисыр рәсемнәрендәге кебек чигәгә таба озынчалап уелган шомырт күзләрен тутырып, мөлдерәп карап куйды. Аның тулы иреннәре елагандай җилсенгән, яңакларына эчтән ут бәреп чыккан — бу минутта ул бик моңлы да, ифрат чибәр дә иде.

Машина янына Фидая белән Рамилә килделәр.

— Әниеңнең хәлләре ничек соң, Зиләйлә? — дип сорады Фидая.

— Эшли.

— Районга килгәлиме соң ул?

— Көн аралаш килеп тора.

— Нишләп миңа сугылмый икән? Әйт әле, кереп чыксын бер. Сөйләшәсе бар иде.

Кыз дәшмәде.

— Суташта йомышың бармы әллә?

— Юк...

— Алайса, әйдә безнең белән. Әнә Балкыш абыең янына, алгы утыргычка утыр. Ул безне өйгә илтеп куяр да, аннары сине олы юлга чыгарып, берәрсенә утыртып җибәрер.

— Авылына хәтле илтеп куяргамы әллә? — дип көлемсерәде Балкыш.

— Анысын үзең кара. Шарты шул гына: караңгы төшкәнче кыз өендә булсын.

Автобустагылар Зиләйләнең Нурханова машинасына утырганын күреп тынычландылар булса кирәк, Гыйззетдин шофер утыргычына кереп урнашты, автобус кузгалды.

Мәдәният йортының ишек төбендә Гаяров белән Әхмәдуллин генә сөйләшеп калдылар. Алар Фидаяга караганнар, кулларын болгыйлар, көлешәләр иде. «Мине талкыйлар, ахрысы, — дип уйлады Фидая. — Татар ирләренең шул булыр инде: хатын-кыздан көлү...»

Һәм, күңелендә үпкә-рәнҗү тоеп, машинаның арткы утыргычына, Рамилә янына кереп утырды.

...Ә ирләр чыннан да аның хакында сөйләшәләр иде.

— Шәп хатын күренә бу Нурханова, — диде Тәүзих.

— Нәрсәсе шәп? Зур урынга үрмәләгән чәчбиләр әзмени хәзерге вакытта?

— Бу бит гадәти чәчби генә түгел... Берүзе ике кешедән тора кебек. Бер карыйсың, чибәр, ягымлы, йомшак сүзле хатын. Икенче караганда, нык куллы, уңган җитәкче.

— Төрлечә кыланып карый инде, тырыша, — диде Давыт, исе китмәгәндәй. — Башына төшкәч, нишләсен. Булдыра алмаса да көчәнә.

— Безнең күп җирләрдә булган бар. Мондый эшлекле җитәкчеләр сирәк.

— Минем юк кына йомышны да үти алмады әле... Теге мәсьәләне ничек хәл итәбез соң? Районга килгәнсез икән, безнең цехка да бер яхшылык эшләми китмәссез бит инде? — дип сүзне икенчегә күчерде Давыт.

## 10

Суташ елгасы аркылы салынган биек күпер аркылы чыгып, зират турыннан узып үргә менгәч, Балкыш машинасын туктатты. Зиләйлә сүзсез генә ишекне ачты да җиргә сикерде. Ишетелер-ишетелмәс кенә рәхмәт әйтте, шоферны шундук оныткандай, алгарак узып, юл читенә басты. Балкыш машинасын кирегә борды. Бәби түгел, җиткән кыз, үткән-сүткән машинага кул гына күтәрерлек. Мондый кызларга шоферлар да игътибарлы, саз чәчрәтеп, выжылдатып узып китмиләр, аяклары үзләреннән-үзләре тормозга баса.

Ләкин Балкыш тиз генә кузгалып китә алмады, башын сузып, артка, Зиләйләгә карады. Кыз кара җирдә ачык кызыл тап булып күренә, тик бу тап никтер бик ямансу, әйтерсең лә аңа йөрәк ярасының төсе саркып чыккан иде. Балкыш «уазик»ны кире борды да, кыз турына барып туктап, ишекне ачты:

— Утыр.

— Кирәкми, — диде Зиләйлә киреләнеп. Ул егеткә түгел, каядыр читкә, зиратның җилдә тибрәлеп, яфрак коеп утырган каеннарына караган иде.

— Нәрсә ялындырып торган буласың? — диде Балкыш, каты гына итеп. — Узгынчы шоферлардан кай җирем ким минем?

— Сиңа юл уңае түгел лә.

— Ә син каян беләсең минем юл уңаен? Утыр әйдә.

Ниһаять, кыз тәвәккәлләде, арткы ишекнең тоткасына килеп ябышты. Утыруын утырды, ләкин шофер белән янәшә түгел, артка урнашты.

Кузгалып киткәч, Балкыш аңлатуны тиеш тапты:

— Минем бер дус шоферны сезнең авылга бәрәңгегә җибәргәннәр иде. Хәлен белеп кайтасы бар. Ватылып ятмый микән. Сагындым да. — Һәм шаяртып җырлап та куйды: — «Бик күрәсем килә, күрәсем...»

Кызның, күңелен күтәреп, телен ачасы, сүз куертып, юлны кыскартасы килә иде аның. Әмма теге тешләк булып чыкты, сүзне җөпләмәде. Балкыш каршындагы көзгене аның йөзенә борып куймакчы булды. Ләкин кыз, утыргыч аркасына беләгеп куйган да, янтаеп, маңгаен шуңа терәгән. Йөзе күренми, тик иңбашлары тетрәнгән кебек тоелды. Елый инде әллә? Балкыш, чүпрәк алып, пыяланың парын сөрткәләде. Кыз елаганга шулай парланамы соң бу тәрәзәләр?

Кыскасы, юл шактый ямансу булып чыкты һәм озын тоелды. Алар авылга кергәндә, караңгы төшкән иде инде. Урам юлы сикәлтәле, көйсез, тизлекне алыштыра-алыштыра шактый озак барылды. Ниһаять, кыз:

— Мин кайтып җиттем, — диде.

Машина фаралары капка өстендәге «Медпункт» дигән язуны яктырттылар.

— Мин шушында торам.

— Нишләп?

— Әни фельдшер минем.

— Бөтен утларны яндырып куйган. Сине көтәдер инде.

— Кешесе күптер. Басуда суык тидерәләр.

Зиләйлә, аяк астын чамалап, сакланып кына машинадан төште.

— Кайсыберсе юри дә хастага сабышадыр инде, — диде Балкыш. — Справка аласылары киләдер.

— Безнең әнинең андый түгеллеген беләләр, — диде Зиләйлә тыныч кына.

— Нинди түгеллеген?

— Алдашмаганын.

Ул рәхмәт әйтеп саубуллашты да капкага юнәлде.

— Әй, кызый!

Фара яктысында кызның бөтен торышы, хәрәкәте сәхнәдәге кебек ярылып ята иде. Шундый горур һәм шул ук вакытта нәфис хәрәкәт белән әйләнеп карады ул, махсус өйрәтелгән диярсең!

— Күздән чүп ала беләсеңме син?

Зиләйлә фара яктысыннан бер адым читкә атлады, аның күзләре йолдыз чагылган күл кебек җемелдәп куйды.

— Беләм,— диде ул тыныч кына.

— Ничек аласың?

— Гадәттәгечә. Мамык белән.

— Минем әби күздәге чүпне теле белән ала. Син дә шулай өйрәнеп куй, яме!

— Мин болай да әйбәт алам. Әни өйрәтте.

— Ә син телең белән алырга өйрән. Алай әйбәтрәк. Күзгә чүп кергәндә, сиңа гына килә торган итәрмен.

Шулай диде дә машинасын бора башлады. Арттан кызның тавышы ишетелеп калды:

— Әбиеңә сәлам әйт!

Кара син аны, тешле дә икән әле! Сөйләштереп булмады чукынганны, тешен күрми калынды. Алары ничек икән? Хәер, берәүнең дә бөтен җире килеп бетми, моның, мөгаен, тешләре ямьсездер. Гел турсаеп кына торуы да авызын ачмас өчен махсус кылану гына түгел микән!

Урамнан узып барганда, машина каршына бала күтәргән бер ир килеп чыкты. Сабый, фара яктысыннан күзләрен яшереп, этисенең муенына сарылды. Балкыш аны таныды: Суташ кибетеннән китаплар алып чыккан, Зиләйләгә каршы юлыгып, кызны барыр юлыннан туктаткан адәм иде бу.

## 11

Бу кичне Рамилә Иркәнең йокыга киткәнен генә көтеп ятты да урыныннан кузгалды. Фидая белән икәүдән-икәү генә калып, иркенләп сөйләшәсе, күп сорауларга җавап аласы килә иде аның.

Фидая да ятмаган икән, нәкъ кичәге кебек, диванда аягын бөкләп утыра, сары абажурлы лампа аны узган кичтәгечә үк серле дә, нәфис тә итеп күрсәтә иде. Кулында шул ук зәңгәр тышлы кечкенә китап.

Рамилә аның янына килеп утырды да, шигырь юлларын исенә төшереп:

— «Өстә — дулкын, астан упкын кулын сала салыма...» дигән, — дип башлады. — Хисләр бәрелешен шундый оста итеп әйтеп биргән. Туган иленнән генә түгел, сөйгән ярыннан аерылган кеше генә үзен шулай хис итә ала торгандыр.

Фидая ачылып китмәде, серләр уртаклашыр өчен күңел кыллары көйләнеп җитмәгән иде әле. Алай да сүзне җавапсыз калдыруны яхшысынмады:

— Әллә сиңа да шундый хәлләр кичерергә туры килгән идеме? — дип сорап куйды. — Кияүгә чыкмагансыңдыр бит әле?

— Нишләп алай дип уйлыйсыз?

— Кыяфәтең шундыйрак. Беркатлы, тәҗрибәсез кебек.

Рамиләнең үзе турында озаклап сөйләргә нияте юк иде, әмма үз күңелен ачмаса, хуҗаның да теле чишелмәячәген аңлады.

— Мин иртә кияүгә чыктым, — диде. — Сәнгать училищесында укыганда ук.

— Гыйшкың шулкадәр кайнар булдымыни?

— Кан кызганнан түгел, аптыраганнан булды ул. Үги эти белән үстем, бәләкәйдән кыйналдым. Тизрәк котыласы килде. Паркта бию кичәсендә бер егет белән танышып, күпмедер очрашып йөрдек тә, ул, әйдә, өйләнешәбез, дигәч, риза булдым да куйдым. Торыр җир бар, Казанның бер читендә үз йортлары белән яшиләр иде, безгә аерым бүлмә бирделәр...

— Озак яшәдегезме соң?

— Ә сез... каян белдегез безнең аерылышкан икәнне?

Фидая авыр сулап куйды.

— Ул инде кыяфәттән сизелеп тора. Күңелең эремәгән булган синең. Ә каты күңел гыйшык тәмен беләмени?

Рамилә карашын аска төшерде.

— Сигез ай бергә яшәдек. Аннары аны армиягә алдылар. Күнеккән идем инде мин аңа, сагынып көтеп алырмын дип уйлаган идем.

— Әмма тиз оныткансыңдыр.

— Оныттым дип үк әйтеп булмый. Көттем. Ике ел аларда тордым. Кайтты бу. Бөтенләй бүтән кеше булып. Тазарган, кояшта янып каралган. Футбол тубы кебек. Ә мин аны ак, ыспай, йомшак куллы итеп хәтерли идем. Ятсындым, кабул итә алмадым.

— Мөгаен, бүтәнгә күңелең төшкән булгандыр.

Рамилә сискәнеп китте.

— Сезнең белән сөйләшү кыен, Фидая Госмановна. Мин бу хакта үзем дә уйларга куркам. Ул рәссам. Талантлы. Тагын ничек дип әйтергә? Портретын сызгалап бирсәм генә. Сүз белән тасвирлый белмим.

— Ә ул сине яратамы соң?

— Юк-юк... Минем кичерешләремне дә белми... Бирегә килүемнең төп сәбәбе шул: аннан качасым килде. Мин әле иремнән законлы рәвештә аерылышмаган да бит. Дөрес, алардан киттем, фатирга күчтем. Белмим, алданиләр булып бетәр...

Фидая бераз уйланып утырды да:

— Беләсеңме, миңа синең ирең кызганыч, — диде. — Ул сине чын күңелдән яраткандыр бит?

Рамилә иңнәрен генә сикертеп куйды.

— Шул шул менә, — дип дәвам итте Фидая. — Хисләр уртак булмаса, мәхәббәтнең бер кадере дә юк. Әрәм яну-көю, юкка өзгәләнү, йөрәкнең мәгънәсезгә талкынуы гына ул. Андый чакта салкын йөрәкле кеше хиследән көчлерәк булып чыга. Һәм, үзе дә сизмәстән, хәйран калырлык шәфкатьсезлек күрсәтә, аяусыз кылана. Минем дә булды андый каты бәгырьле чакларым. Ир-егетләрне елаткан вакытларым булды...

Һәм ул, ачылып китеп, кичә өзелеп калган кыйссасын дәвам иткәндәй сөйли башлады:

— Теге чакта, университетка керә алмыйча кире кайткач, ронодан мине Баллыболын мәктәбенә пионервожатый итеп җибәрделәр. Юллама алып чыктым мин моннан. Эссе көн иде, сумка-фәләнем дә юк, акча белән кульяулыкны кыска җиң бөрмәсенә генә кыстырып куйган. Ронодан алган кәгазьне, бөгәрләнмәсен дип, түгәрәкләп бөтереп тоттым да кибеткә кердем. Эш өчен кирәклениләр бар икән дип, киштәгә карап тора идем, учымдагы кәгазь төргәге шуып чыгып китте. Күтәрелеп карасам, янымда озын гына буйлы бер егет басып тора, кәгазьне шул тартып алган икән. Ачып укыды да: «Карале, син анда минем урында эшләячәксең икән бит, — ди. — Былтыр мин эшләгән урын ул!» Баштан кичкән хәлләрдән соң егетләргә минем нинди караштa булганымны аңлыйсыңдыр инде. Бер сүз әйтми генә кәгаземне аның кулыннан тартып алдым да кибеттән чыгып киттем.

Барып урнаштым авылга. Әйбәт кенә эшләп киттем. Беренче атнадан соң үзебезнең авылдан, мотоциклга утырып, Ваккас килеп йөри башлады. Мин инде аңа караңгы чырай күрсәтми идем, чөнки, ни дисәң дә, белгән кеше, ят авылның бәйләнчек егетләрен якын китермәү өчен бик ярап куйды. Егете булган кызның дәрәҗәсе дә югары бит аның. Дөрес, балалар арасында абруй казану авыррак булды. Алар сүз арасында элекке пионервожатыйны исләренә төшерәләр: «Мәгъсүм абый алай түгел, болай итә торган иде, Мәгъсүм абый бар чакта...» — дип, гел канга тоз салып тордылар. Мәгъсүм дигәннәре шул теге миңа кибеттә юлыккан егет булып, аны Суташның мәдәният сараена эшкә алганнар иде.

Бер шимбәдә бу үзе дә, велосипедка атланып, мәктәп капкасы төбенә килеп туктады. Дәрес беткән чак иде, укучылар, алар артыннан укытучылар сөенешеп, шаулашып моның каршына киттеләр. Мин болдырда басып калдым. Балаларның баш очыннан бер күз сирпүеннән сизеп алдым: мәктәпне сагынып кына килүе түгел моның. Минем янга килгән бу... Әмма мин моңа һич тә сөенмәдем. Беркем күрмәде, сизмәде, ә менә ерактан ук шул рәвешле аңлаштык: «Мин сине күрергә килдем. Нихәлләрең бар?» — диде ул. «Юкка мәшәкатьләнеп йөрисең. Мин сине көтми идем», — дидем мин карашым белән.

Ә балалар, укытучылар үзләренекен сөйли: «Мәгъсүм абый, нишләп баяныңны алып килмәдең? Син киткәч, мәктәпнең яме калмады, рәхәтләнеп җырлап-биеп тә булмый. Магнитофон тасмасының ни рәхәте бар аның», — диешәләр.

Һәммәсе аның үзенә, велосипедына, өендә калган баянына мөкиббән иде. Һәммәсе, тик мин түгел. Аларны әйләнеп үттем дә фатирыма кайтып киттем. Авыл очындарак, Наилә исемле бер апада яши идем мин. Кайтып чәй эчәргә утырган идем, кемдер тәрәзәгә чирткән шикелле тоелды, үрелеп карадым — урамнан теге Мәгъсүм үтеп бара икән. Турыбызга җиткәч кенә, велосипеды янтаеп китте дә, чак егылмый калды, төшеп, тәгәрмәчен караштырырга кереште. Мин, пәрдә артына посып, аны җентекләп күзәттем. Көлсу туры чәчләре маңгаена төшә, әледән-әле аларны уң кул аркасы белән артка тарап куя. Кул хәрәкәтләре ничектер бик ипле, гәүдәсе нык, җилкәләре киң. Ә менә йөзе... Йомры иякле түгәрәк йөзе ничектер сабыйлыгын саклаган иде аның. «Бөтенләй бала-чага төсле бит бу!» дигән уй килде минем башыма.

Шуннан соң кичләрен Баллыболын юлында ике яктан ике егет тузан куптара торган булып киттеләр. Үзәнтаудан, мотоциклга атланып — Ваккас, Суташтан, велосипед белән — Мәгъсүм. Ике яктан килгән юл клуб янында кисешә. Кайчакта шунда велосипед тәгәрмәчләре тишелеп тә куя.

Ә мин егетләрнең берсеннән дә озаттырмыйм, икәүдән-икәү калып сөйләшеп тормыйм. Тик шулай да аларны болай йөртүнең яхшы түгеллеген күңел сизенә. Бер кичне шулай, җир каткан, кар төшмәгән иде әле, күңелем аерата алгысап китте. Аяклар үзеннән-үзе тыпырдый. Инеш ярындагы чишмәдән су ташырга тотындым, бар булган савыт-сабаны мөлдерәмә тутырдым. Наилә апа әйтә: «Җитте инде сиңа, — ди. — Бүген мунча ягасы юк, төнлә нык суытып җибәрмәгәе, сулар катып, чиләк төпләре төшмәсен тагын», — ди. Ә мин һич тик тора алмыйм!

Ул кичне клубта да гел уртада бөтерелдем. Ике егет ике яктан мине машина фараларына алгандай иткәннәр. Мәгъсүм сәхнә кырыена утырып баян уйный, Ваккас ишек төбендә басып тора. Чырае караңгы, үртәлгәне әллә каян сизелеп тора. Баштарак миңа бу икәүне үртәү кызык сыман иде, ләкин бераздан әдәпсез кыланам кебек тоела башлады. Килешми иде болай.

Шуны сиздем дә, кичә тәмамланганны да көтмичә чыгып киттем. Артымнан Ваккас чыкты, беләгемнән тотып алды. Артыгын пырдымсызланып, каты бәрелүдән тыелдым, чөнки Ваккас армиягә китә, хушлашырга килгән иде.

Әллә ничек җанны өшетә торган булып истә калды ул кич. Тулган айның яктысы җирнең җылысын суыра, аяк астында боз кыйпылчыклары шытырдый. Наилә апалардан ерак түгел бура тора иде. Шуның турына җиткәч, Ваккас мине туктатты да:

— Хуш инде, Фидая, — диде.

— Исән йөреп, сау кайтырга язсын, — дидем мин.

Кул биреп саубуллаштым да кереп киттем. Ул мине туктатырга батырчылык итмәде, чөнки артык хисләнү аның ихтыярын сындырган, көчен алган иде.

Ул төнне мин фермада кизү торырга тиеш, чөнки сарыкларның бәрәнләр чагы җиткән иде. Өйгә кереп, утны яндырмый гына өс-башны алыштырдым, кире чыктым. Ваккас китмәгән, бурага йөзе белән капланып басып тора иде. Мин узганда борылып карамады. Елый иде бугай.

— Сез нишләдегез инде? — дип сорады Рамилә.

— Нишлим? Ни әйтим? Күлдәвек бозларын шытырдатып, тыгыз-тыгыз атлап узып киттем. Ул калды шунда...

— Андый чакта бернишли алмыйсың шул инде, — диде Рамилә. — Аларга бит безнең кызгануыбыз түгел, яратуыбыз кирәк. Әмма кирәк дип кенә яратып та булмый.

— Рәнҗетәсе килми дә бит, юатып та булмый. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга: мине яраткан кешеләргә газап кына китерәм шикелле. Бәхетле итә белмим. Әллә инде очраклы бәндәләр еш бәйләнгәнгә күрә күңелем катыланып, тәнем чирканып калганнан шулай булды... Ваккаска карата гына түгел, иң газиз кешемә салкын булганыма үкенеп бетә алмыйм...

...Кинәт сискәндереп телефон зыңгылдады. Фидая, алгы бүлмәгә чыгып, телефонны алды, Рамиләгә аның хәвефле тавышы ишетелде:

— Кайда яна? Кайчаннан?

# 12

Суаштан чыгып, зират үрен менүгә, алда офыкта шомлы кызыллык уйнаганы күренде. Барган саен, ул биеккәрәк үрли, бер күккә ургыла, бер сүрелеп китә иде. Ярты юлны узгач, көчле шартлау яңгырады, болытларга таба утлы давыл бөркелгәндәй булды.

— Газ баллоны шартлады, — диде Балкыш теш арасыннан. — Йортларының көле күккә очты.

Баллыболынның таныш урамы шом белән тулган иде. Аргы очка барганда, машина берничә кешене куып узды. Кайсының кулында чиләк, кайсы багор тоткан, юл күрсәткәндәй, кулларын алга болгап калдылар. Алар әйтмәсә дә, әллә каян күренеп тора: янгын аръякта, югары очта котыра иде. «Гыйззетдиннәр түгелме?» — дип уйлады Фидая чамалап.

Арттан сирена улаганы ишетелде: район үзәгеннән янгын сүндерүчеләр килә иде. Фидая Балкышка аларны уздырып җибәрергә кушты. Түбәсенә озын баскыч сузып салган зур кызыл машина, нык улап, җир селкетеп узып китте.

Фидаялар килеп җиткәндә, ирләр машинадан сыгылмалы юан көпшә сузып азапланалар иде.

— Китегез! Еragрак торыгыз! — дип кычкыргаладылар алар ыгы-зыгы килгән халыкка.

Алар әйтмәсә дә, якын килерлек түгел иде! Кая! Нисаның йорты урынында зур өем күмер көйри, кисәү пыскый, аннан аргы йорт һәм тагын каршыдагысы дөрләп яналар иде. Берсе Гыйззетдиннәрнеке, икенчесе Фаязларныкы. Ялкын болытларны ялмый, тирә-якка утлы кисәүләр оча. Ихаталардагы каралты-курага да ялкын үрли башлаган. Бу дәһшәт тирәсендә, алмашынучан яктылыкта ут сүндерергә килүчеләр бик көчсез булып күренә иде. Кемнәрдер кычкырына, бәргәләнә, сыер-сарыкны абзарлардан чыгара, кемнәрдер каңгылдашкан казларны инешкә таба куа. Күрше йортлардан ду килешеп әйбер-кара чыгаралар — янгын үрләүдән куркалар. Елга буендагы агачлар арасында, тәртипсез өелгән мендәр-юрган өстендә, бала-чага утыра. Аларның йөзендә, куркынган күзләрендә ялкын шәүләсе чагыла.

Бу мәхшәрдә Фидаяга игътибар итүче булмады, үзе дә нишләргә белми чарасыз калган иде. Ләкин шунда кемнеңдер, башына пинжәк каплап, түбәсеннән ут ургыган Фаяз йортына таба йөгергәнен күреп алды.

— Тукта! Кая керәсең?

Яначак! Һәлак булачак! Фидая аны кычкырып туктатмакчы булды, ләкин утның гөрелдәве, машиналарның гүләве, кешеләрнең кычкырышуы кушылган тоташ шау-шуда аның нечкә тавышы ишетелерлек түгел иде. Ул күн пальтосын өстеннән салды да, эссегә каршы калкан итеп сузып, тегенең артыннан китте. Туктатырга, алып чыгарга... Күн пальто кулларны пешерде, эссе һава тынга капты, чәчтән көек исе килә башлады... Ул соңгы көчен җыеп талпынды һәм әле ут капмаган тәрәзә төбенә барып ябышкан кешене, күлмәк итәгеннән тотып, көч белән артка тартты:

— Кая керәсең! Янасың бит!

Соңыннан, бу минутны исенә төшергәндә, Фидая үз кылганына үзе ышанмады. Юктыр, булмас, алыптай гәүдәле бу кеше ул итәгеннән тартканга түгел, үзе аңына килеп кире чигенгәндер. Аларның киемен ялкын өтеп алырга өлгергән иде. Фидая, пальтосын җиргә ыргытып, чәчен-башын сыйпады, ир кеше җиргә ятып тәгәрәп алды. Фидая аны шунда гына таныды: бу Фаяз үзе иде. Ул арада фельдшер Мөнирә килеп җитте дә кулындагы чемоданыннан ниләрдер чыгара башлады. Фидаяның башына, битенә нindидер май сөртте. Аның бармаклары салкынча һәм назлы иде, аларның орынуы тынычландырып җибәргәндәй итте. Аннары ул Фаязның кулын бинт белән урарга кереште, үзе:

— Бәргәләнмә бу хәтле, сабыр бул, — дип сөйләнде. — Дөнья малы табылыр, башың сау булсын да кулларың исән булсын...

Фаяз утка карап тора, йөзе бурлаттай, маңгай чәче көеп каралган. Ул, башын артка ташлап, таза тешләрен елтыратып, шаркылдап көлә башлады:

— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!

Фидая аның иңенә кулын салды.

— Бик кызыкмыни, Фаяз абый?

— Әнә, күр! — дип, кулын Мөнирәдән тартып алып, утка төбәде Фаяз. Беләгеннән уралып бетмәгән бинтның очы сузылып төште. Йортның бер кырыена машинадан су агызып, ялкынны басканнар, ә уңда ул үз көченә ургый, юан нарат бүрәнәләр кызарып, яктырып, балкып тора, текәлебрәк карасаң, алар аркылы өй эчен күреп булыр кебек иде.

— Карап калыгыз! Мондыйны күрмәссез бүтән! Өйнең биеклеге ике дә туксан! Ишекләре генә дә егерме! Бөтенесен менә шушы кулларымнан әллә ничәшәр тапкыр үткәрдем!

Караңгыдан, агачлар арасыннан, Наилә апа килеп чыкты:

— Сабыр булырга кирәк, Фаяз! Дөнья малы — дуңгыз каны, дигәннәр борынгылар. Күрә торып утка керәләр димени. Әнә, Нисаны кара, җәһәннәм эчендә калды бит! И, ялгызлык хәлләре, шушындый мәхшәр купканда уятучың да булмасын инде!

— Җә-әл! — диде шаркылдап Фаяз. — Җәл, янган!

Болганган халык арасында Таштимерованың күренмәве шунда гына Фидаяның аңына барып җитте.

— Ул өендә калганмыни?

— Өендә булмый кая булсын. Юк бит менә. Мондый чакта бөтенесен дуылдатып йөрер иде, күздән югала торган түгел.

Бу сүзләр Фидаяның йөрәген ялкын теле белән ялмап алгандай итте, тынсыз калдырды, ә Наилә апаның тавышы салмак, ул инде Нисаның һәлакәтенә тәмам ышанган иде. Фаяз исә моңа кинәнгән кебек кыланды:

— Бәхете, үлеп котылган! Монда булса, мин аны, үз кулларым белән тотып, шушы җәһәннәмгә тыгачак идем!

Ниһаять, тырыша торгач, янгын сүрелә төште, ике йорттан да төтенгә уралып, болыт йомарламнары булып, пар күтәрелде.

Агачлар арасында бу ыгы-зыгыда пөхтә-чисталыгы, үзен тыныч тотуы белән башкалардан аерылып торган берәү күренде. Түгәрәк ак сакаллы, кечкенә гәүдәле, тәкъва кыяфәтле Фәтхрахман бабай иде бу. Кулындагы өр-яңа калай чиләк эченнән намазлык алып, тупыл төбенә, коелган яфраклар өстенә җәйде дә йөзен Ниса ихатасына төбәп тезләнде һәм укырга кереште. Шунда гына, ниһаять, фаҗиганең чынлыгы Фидаяның аңына бөтен аяусызлыгы белән барып җитте кебек: Ниса янып үлгән, Фәтхрахман бабай аңа ясин чыга. Утта янмас, суда батмас кебек иде, шундый нык, батыр кеше дә бу хәтле кинәт һәм мәгънәсез рәвештә юк була ала микәнни? Ничек алай? Бер рәхәт тә күрергә өлгермәде бит әле ул! Гел халык өчен тырышты, колхозны күтәрәм дип тырмашты, тарта алмаслык йөккә җигелде. Менә-менә авыр йөкне кузгатыр, кешеләрне бәхетле итәр, аннары үзе дә тын алыр сыман иде...

Теге көнне, хастаханә янында булган хәлләр исенә төшеп, Фидая үкенеп куйды. Болай буласын кем белгән. Елмаеп каршы алырга иде дә каһәр суккыры пар казанын биреп җибәрергә иде. Үпкәләп киткәндер мескенкәй. Бәхиллеген алып булмады...

Күпер ягыннан ат чабып килгән тавыш ишетелде. Тарантастан ике ир-ат сикереп төште, аларга башкалар ябырылды:

— Эт җаннар, кайда себерелеп йөрисез сез? Сезнең аркада ничә йорт янды, кеше үлде!

— Сез нәрсә? Без ут төрткәнме әллә? Ниса үзе тыкырдатып алып китте безне! Сугышыйкмыни аның белән!

— Нишләп соң сез бер Нисаны икәүләп ташыйсыз!

— Аның белән төнге юлга үзем генә чыгыйммы, малайны гына җибәримме?

— Малаең әйбәтрәк булыр иде!

— Үзең дә ярап торыр идең караңгыда! Караңгының күзе юк, кармаласа сүзе юк!

Фидая пальтосын алды да машинасына таба китте. Ирләрнең тавышы бөтен урамга яңгырый иде.

— Ай-һай озак йөргәнсез, айгырыгыз буксовать иттеме әллә?

— Андагы хастаханәдән баш врачны алырга җибәрделәр башта, аннары теге хатыннарны карый торган кенәз Юсуповны алып килергә куштылар. Әрле-бирле чаптык урам буйлап, — дип аңлатты өлкәне Гариф.

— Кенәзе ник кирәк булды тагын?

— Ник булсын, Ниса да хатын лабаса!

— Кит аннан? Әллә берәрсе шуның белән чирттергәнме?

— Алай димә! Нисаның да бар җаны!

— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!

Ирләр, шаярган булып, җаннарына тынычлык эзли, тирә-юньне камап алган шаукымның күңелне баскан авырлыгын аз гына булса җиңеләйтү юлын эзли иде. Ә Фидая чирканып киткәндәй булды. Ул арада районнан башка кайбер җитәкчеләрнең машиналары, шул исәптән Мирхуҗинның «Жигули»е да килеп туктады. Фидая Балкышка кузгалырга кушты. Ул сәламәтлек саклау, мәдәният буенча җаваплы кеше, мондыйга кысылып йөрмәсә дә була иде.

## 13

Балам ялгыз дип борчыласы юк, өйдә Рамилә калган иде, Фидая шундук Кармаш хастаханәсенә барып килергә булды.

Анда утлар сүндерелгән, тик бер генә тәрәзәдән яктылык сибелә иде. Ишекне Гөлфия чыгып ачты.

— Төнгә үзем калырга булдым әле, — диде ул. — Ул-бу булмагае, дидем.

Фидая Нисаны күрергә килгәнен әйткәч, Гөлфия гаҗәпләнмәде.

— Ул-бу куркыныч юк, — диде. — Хатыннарда була торган хәл.

— Әллә... чыннан да йөкле булганмы?

— Әйе шул. Баласы төшкән. Кинәт кенә эченнән кан коела башлаган. Түзеп-түзеп яткан да килми булдыра алмаган инде.

Янгын хәлләрен ишеткәч, Гөлфия уфылдап куйды.

— Электр плитәсен калдырган микәнни бичара... Алай булгач, әйтми китә алмассың инде, — диде.

Палатага кереп, өске утны кабыздылар. Ниса, алты кеше белән бергә, ишек янындагы караватта ята икән. Янында тумбочка гына, урындык та юк. Китергән хәбәре аягөсте генә әйтә торган түгел, Фидая караваt читенә утырды.

— Хәлләрең ничек, Ниса апа?

Таштимерова тузгыган чәчләре астыннан ачулы карады да нык кына итеп аягы белән тибенеп куйды. Аннары башын калкытып, кызарынып:

— Сестра! Сестра! — дип кычкырды. Ишектән кергән Гөлфиягә каты итеп: — Сезнең монда бөтенләй тәртип юкмыни соң? Төн уртасында палатада чит кешеләр йөри. Йокларга ирек юк!

Гарьләнүдән Фидаяның күз аллары караңгыланып китте. Әллә хәзер ниләр булганын туп-туры әйтергәме? Өенең янганын, Фәтхрахманның аңа ясин чыкканын, ирләрнең аның турында ниләр әйткәнен — бөтенесен бергә кушып, ярып салыргамы? Караватлардан башын калкыткан хатыннарның күз алдында хак дөресен, бар булганын чыгарып селкергәме? Ниса үзе мондыйрак очракта Нурхановань аяп торыр иде микән? Ләкин юк... Фидая бирегә аның мескенлеген күреп, бәгыренә ук кадап ләззәтләнергә, үч алырга дип килмәде. Киресенчә, ул аңа яман хәбәрне мөмкин кадәр йомшак итеп җиткерергә, хәлен белергә, элек хәтерен калдырган булса, гафу үтенергә теләгән иде.

Ләкин ул бу рәвешле каршы алган икән, җавапны да шул рәвешле бирү гадел булмас идемени? Әмма юк, егылганны кыйнамыйлар. Фидая тыелды.

— Хәлең яхшы икән, Аллага шөкер, тавышың бик көр чыга, — дип, аягына басты да, утны сүндереп, хушлашып чыгып китте.

Гөлфия Ниса өчен гафу үтенгәндәй елмайды:

— Син инде аның кыланмышларын авырга алма, — диде. — Тавышы көр чыкканга сөенергә кирәк. Монда килгәндә, тырнаклары күгәреп чыккан иде. Үлә дип котыбыз чыкты. Ярый әле Йосыпов өйдә булды. Берәр җиргә киткән булса, бик үкенечле булачак иде. Куллары алтын шуның, билләһи.

— Ничек үзен шул хәлгә җиткергән соң ул? — дип сорады Фидая.

— Өйдә бала төшерү бик куркыныч нәрсә бит ул. Аннан күпләр үлә.

— Ә бәлки, егылгандыр йә авыр күтәргәндер? Дуамал бит ул!

— Нишләгәнен әйтмәде. Ләкин Йосыпов әйтә, төшерергә азапланган, ди. Кешегә сиздерәсе килмәгән инде. Белсәләр, шундук эшеннән куачаклар бит. Уҗымга чыгу ирләрне генә бизи ул.

— Мир теленә керсәң, гомер буе чистарына алмыйсың инде, анысы бар, — диде Фидая. — Мондагыларга әйтеп куярга кирәк, күп сөйләшеп йөрмәсеннәр.

— И-и, моның ише җирдә сер саклап буламыни?

— Табиблар сер сакларга тиеш бит. Гиппократ антында да шулай диелгән.

— Гиппократ заманында хастаның чын хәлен табиб кына белгәндер дә бит. Монда Нисаны озата килгән кешеләр дә сизгәндер инде. Мир авызына бияләй тыгып буламыни. Менә, яңа бина булгач, бездә дә тәртип урнашыр, бәлки. Авырганны үз машинабыз белән барып алып килербез, Ниса кебекләрне аерым палатага яткырырбыз. Ул чакта табибтан сер саклауны да таләп итеп булыр, бүтәнен дә. Хәер, больничныйга барыбер дөрес диагнозны язарга кирәк бит...

— Өе янып киткәнне ипләп кенә үзең әйтерсең инде, — диде Фидая саубуллашканда.

Ә шулай да Ташнисаның берәрсен иркәләгәнен-назлаганын күз алдына китереп булмый иде. Иш-ишен тапкан, ишәк к... тапкан, дияргә кала. Аңа кызыккан кем булды икән? Әллә каян, ерактан килмәгәннәрдер бит инде, күз күргән берәрседер. Кем ул?..

Иртәгесен иртән төнге хәлләр турында райкомның беренче секретарена, яше илледән узган, саллы гәүдәле күзлекле абзыйга сөйләгәндә, Фидая Таштимерова хакында дөресен әйтергә кыймады. Хатын-кызның дәрәҗәсен төшерәсе, гайбәтче булып күренәсе килмәде.

— Аппендицитка операция ясаганнар бугай, — диде.

Искәндәров калын күзлек пыялалары аша аңа текәлеп карады.

— Мин монда хуҗалык җитәкчеләре белән киңәшәм хәзер, — диде. — Янган өч йортны торгызуны өч колхозга йөкләргә туры килер. Ә син, Баллыболынга барып, халык белән сөйләш. Тынычландыр. Таштимерова — районда бердәнбер хатын-кыз җитәкче, безнең горурлыгыбыз дияргә була. Аның абруен сакларга кирәк.

Фидая:

— Зуррак кеше барса, яхшырак булмасмы? — дип, Искәндәровның үзенә киная ясап караган иде дә, тегесе кырт кисте:

— Кешегә салынырга өйрәнмә, — диде. — Андагы халыкны синнән әйбәт белүче юк.

Фидая «Үзәк» колхозының рәис урынбасары Әхсән Вәлишинга үзенең киләсен телефоннан хәбәр иттерде дә юлга чыкты. Авылда сөйләшүнең җиңел булмаячагын күңеле сизә иде аның.

Аны көтәләр иде: рәис бүлмәсе шыгрым тулган. Кечерәк буйлы, йомшак табигатьле Вәлишиннан әллә ни ярдәм көтеп булмый, җыелган халыкның исә кәефе шәптән түгел иде.

Башта өе янган кешеләрнең хәлен сөйләшеп алдылар. Янгын Таштимерова йортыннан чыккан, шуннан күршеләргә капкан, электрдандыр дигән нәтиҗә чыгарып куйганнар иде. Хәзергә Гыйззетдиннәр клубның арткы бүлмәсенә урнашкан, Фаязлар туганнарында, ә Ниса...

— Аның урыны корыда, җылыда бит әлегә, — диде берсе, астыртын киная белән.

— Бүген малайлар, кисәү актарганда, Нисаның ике күлмәген табып алганнар. Адәм ышанмас, төс тә салмаганнар, бөтен чәчкәләре чекерәеп тора! Бөрешкәннәр генә бераз.

— Заман товары шундый бит инде ул, утта янмый, суда батмый, биш буынга чыдарлык.

— Заман товары тузмый, адәм баласының гына заманы уза.

— Узды инде Ташнисаның заманы да!

Шулай итеп, тәртип белән рәсми рәвештә фикер башлап җибәргәнче үк, хуҗалык җитәкчесенең язмышын хәл кылып куйгандай итте болар.

Ләкин алай гына бирешергә ярамый иде. Түр өстәл артына Вәлишин белән янәшә кереп утырган Фидая торып басты да, тавышын күтәрә төшеп:

— Бәла-каза тал башыннан түгел, адәм башыннан йөри, — диде. — Электр белән саксыз булганы өчен генә кешене аяк астына салып таптау килешми.

— Электр белән генә микән?..

Монысына астыртын мәгънә салып, хихылдашып алдылар. Бигрәк тә ирләр. Алгы урындыктагы ике-өч хатын-кыз гына, әдәп саклап, дәшмәделәр.

Фидая, кашларын җыерып, сүзне җитди юнәлешкә борырга тырышты. Кеше турында үзе югында теләсә нәрсә сөйләп утыру килешми. Ниса озакламый кайтачак, үз эшен эшләсен. Отчет-сайлау җыелышына күп калмаган, шунда һәммәсен уртага салып, бөтен халык белән бергәләшеп сөйләшергә кирәк булыр. Башка вакытта Фидаяны дикъкать белән тыңлый торган кешеләр, бу юлы пышан-пышан килә башладылар. Ул да булмады, ревизия комиссиясе рәисе Гаделша карт, чәчрәп чыгып, өстәл янына килеп басты.

— Ни йөзе белән кайтыр ул монда? — диде ул, нечкә тавыш белән кычкырып. Ни чикса, авылның шундый актив картларыннан чыга бит инде. — Әле дә ярый районнан килеп җиттеләр, әле дә ярый коры

чак түгел иде! Җәйге чиллә чак туры килсә, бөтен авыл белән янып көл була идек бит. Шул булдымы җитәкче! Ул бүлнис юлында йөрүе тагын! Кем ни әйтер, мин андый җитәкче кул астында эшләргә риза түгел! Минем яклылар монда күп!

Фидая белән Вәлишин аңышып та өлгермәделәр, Гаделша мәсьәләне тавышка куйгандай итте.

— Булмый инде аннан хәзер!

— Үзе китәргә тиеш!

— Андыйның бары ни дә, югы ни! — диештеләр.

Фидая аларга сүзен үткәрә алмаячагын аңлады. Янгын халыкны нык кыздырган иде шул.

Хуҗалыкка яңа рәис сайларга кирәк булачак иде.

## 14

Кич ашап-эчеп, Иркәне бүлмәгә йокларга яткыргач, алар тагын икәүдән-икәү калдылар. Янгында зыян күргән көн пальтоны әйләндерә-әйләндерә карадылар.

— Их сез, — диде Рамилә. — Шушындый затлы әйберне киеп, пожарга баралармыни?

— Алты йөз сумга алган идем, — диде уфтанып Фидая. — Утка якын килермен дип башка да килмәгән. Ашыгып чыгып кителде бит.

— Таза урыннары бар әле барын. Ательеда пинжәк чыгарырлар иде, бәлки.

— Анда кайберәүләрнең бөтен милке көл булды, — диде Фидая, үзен юаткандай. — Кайсыларның абруе янды хәтта.

Бераздан алар янә диванда янәшә утыралар иде инде. Ниса турында, адәм баласының эш аты булып кына яши алмавы, никадәр генә кырыс булып кыланса да, җаны мәхәббәткә сусавы турында сөйләшеп алдылар. Җырларда җырланган, кыйссаларда илаһи дип макталган сөю хисенең бик күп очракларда йөрәкләрне иң үткен хәнҗәрдән дә ныграк яралавына гаҗәпләнештеләр.

— Ул бит яраткан кешенең генә түгел, яратмаган кешенең дә күңеле тырнала, — диде Фидая. — Теге чакта Ваккасның әрнүләрен белү миңа бер дә рәхәт булмады. Хәсрәтләрен кулым белән сыдырып кына алыр идем. Алай итеп булмый икән шул. Онытыр дигән идем, башка берәү белән танышыр дигән идем. Армиядән язган хатларына да җавап бирмәдем. Ә ул язды да язды. Ахырда мин, беләсеңме нәрсә уйлап чыгардым?

— Ә нәрсә уйлап чыгарып була андый очракта?

— Солдатлар бит алар сөйгән кызларын гына түгел, туган якларын да сагыналар. Кемнән генә хат килсә дә кадерле. Шуны уйладым да классташым Лилиягә бардым. Аның Ваккаска күңеле төшкәне сизелә иде. Ваккас сиңа бик күп сәламнәр әйткән, хат язмас микән, дигән, дидем. Ул инде минем хәйләмне аңлагандыр да, бәлки. Ләкин мин укырга китәргә йөри идем, шулай булгач, аңлатып йөрүнең кирәге дә булмады. Ул миңа бик моңсу итеп карады да беләсеңме нәрсә диде: «Егетләр синең аяк астыңда туфрак булырга әзер, кадерен генә белмисең, — диде. — Ә үз аяк асларында туфрак булырга әзер торган кызларның кадерен алар белми».

— Хат алыштылармы соң?

— Алышканнар. Солдатлар хат алышырга ярата бит ул. Алай да мине күңеленнән сызып ташлый алмаган булып чыкты. Армиядән кайткач, чемоданының капкачы эченә ябыштырган карточкамны күреп алганнар. Теге миннән талап алган сурәт булгандыр инде. Ул армиядән, мин каникулга кайткач, урамда очрашып күрешкән идек, җаен туры китереп, бармагымнан көмеш йөзегемне суырып алды. Анысы тагын халыкка фаш булды: шул йөзек бармагына сыйсын өчен махсус ябыккан икән, дип көлеп сөйләделәр.

Сөеп тә сөелмәгән кеше читтән караганда көлке тоела бит ул. Мәгъсүмнең дә кыланмышлары шактый мәзәк кебек иде. Мин педагогия институтына барып кергәч, ул анда читтән торып укуыннан көндезге укуга күчте. Мине күздән югалтмас өчен дип сөйләделәр.

Тик андый чакта, ник шулхәтле бәйләнә икән бу, дип, ачу гына килә бит ул, ачык чырай күрсәтми идем, баскычта йә коридорда кара-каршы очрашсак, итәгем аңа орынмасын өчен, җыебрак тоткан булып кылана торган идем...

Бу урында Фидая, бик нык үкенгән кебек, уфтанып куйды.

— Әйтәләр икән аңа дуслары: «Әрәм итмә хисләреңне шул тәкәбберbegә. Кызлар беткәнмени? Син бит теләсә кайсын каратырлык». Ә ул аларга: «Тимәгез күңелемә, — дип җавап бирә торган булган. — Кеше үзгәрми тормый, ул да үзгәрер».

Ул хаклы булып чыкты: үзгәрдем мин. Күңелемдә хис кузгалды. Әмма ярату түгел иде бу. Фәкать көнләшү генә иде.

— Яратмаган кешене көнләп буламыни?

— Була икән шул. Көнләшү бит ул бүтән берәүне кайгырту, аны зурлау, аңа соклану дигән сүз түгел. Һәм ул яратканнан түгел, кемдер синең мин-минлегеңә тигәнгә, кемдер кайсы ягы беләндер синнән өстен күтәрелгәндә кабына. Мәгъсүмнең дус егетләре минем шушы кылда уйнадылар да инде. Аңа ярдәм итәргә тырышып, миңа каршы заговор кордылар, дияргә була.

— Заговор укмыни? Ничек итеп? — дип гаҗәпләнеп сорады Рамилә.

— Әйе, сүз берләштереп әвәрә иттеләр мине. Андый чакта җае да чыгып тора бит аның. Институтка, ниндидер бер журналга татар яшьләре турында мәкалә язарга дип, Венгриядән корреспондентлар килеп төшкән. Бер егет белән бер кызны табып бирегез, диләр икән. Комсомол комитетындагы егетләр Мәгъсүмне тәкъдим иткәннәр.

— Ә аның янына сезнеме? — Рамиләгә бу бик кызык тоелды.

— Юк шул менә. Мине түгел. Минем кыяфәт татарга охшамаган, имеш. Башка чибәрне тапканнар. Кемне диген әле. Тулай торактагы бүлмәдәшемне, төндәй кара чәчле, йолдыздай күзле Флераны. Атна буе парлаштырып әле китапханәгә, әле театрга, әле чаңгы шуарга йөрттеләр боларны. Төн җиткәч кенә, очынып кайтып керә Флера, түбәсе күккә тигән. Ул мактануы, ул талпынуы... Сизәм, көнләшү ачысы җебетә башлады бит минем күңелне. Ваккасны Лилиягә үзем биргән идем, бик эре, тәкәббер булып калган идем, ә бу юлы Мәгъсүм үзе миннән Флерага авышкан кебек тоела башлады. Ничек инде мин-минлегеңә тимәсен!

Бер айдан журналлар килеп төште боларга. Тышында да, эчендә дә Мәгъсүм белән Флера тора парлашып. Берсендә егетем, иелеп, бүлмәдәшемнең чаңгы бавын рәтләп азаплана. Ә мин, аның горур башы минем каршымда гына иелә, дип уйлап йөрим тагын!

— Әллә чыннан да йөрешеп киттеләрме?

— Кем ничек уйлый инде. Ул бит егетләрнең хәйлә коруы гына булган булуын да, ләкин Флера һәммәсен чынга алган булган. Шул арада Яңа ел килеп җитте, без, гадәттәгечә, маскарадка әзерләндек. Мин, кара күлмәгемә елтыравыклар тегеп, төн булып, ә Флера чегән кызы булып киенде.

Менә шул маскарад барысын да үзгәртте дә куйды. Башта бөтенесе гадәттәге тәртип белән барды: чыршы тирәсендә концерт булды. Бию кичәсе башланыр алдыннан, Флера Мәгъсүмгә баян китереп тоттырды. Зал буйлап шундый итеп йөри, егетне тәмам үзенеке итеп бетергәне әллә каян күренеп тора. Баян уйнап җибәрде, егетләр кызларны чакыра башлады. Гадәттә, иң беренчеләрдән булып, минем янга килә торганнар иде. Бу юлы ник берсе борылып карасын. Без, кызлар, стена буенда тезелешеп басып торабыз, аргы баштан елмаеп бер егет килә, инде хәзер миңа таба кулын сузар дисәм, янәшә басып торган иптәшемне биленнән эләктереп алды да бөтереп алып китте. Стенага сөялеп берьялгызым басып калмаммы шулай! Бик читен хәл бит ул!

Соңыннан гына белдем: ул кичне Мәгъсүмнең дусты Мидхәт егетләрне юри котыртып куйган икән: «Фидаяга якын бармагыз, кикриге бераз шиңсен әле», — дигән. Ә егетләр үзара сүз беркетсә, хәтәр бит ул, бигрәк тә кызларны үртәргә дигәндә.

Барсы да парлы-парлы, мин генә моңлы-зарлы кебек, сураеп торып калдым шулай. Менә, егет карамаган кызлар шушындый була, дип, күргәзмә әсбап итеп бастырып куйганмыни! Ә Мәгъсүм баян уйный, аның урындыгына бер кулы белән таянып, янында, җилпәзәсен селкеп, чуар итәкле Флера басып тора.

Нишләргә миңа? Андый чакта чыгып китү — үзе җиңелү, кимлегеңне раслау дигән сүз. Музыка тынып торса, башкалар таралышса, шым гына ишектән чыгып сызарга булыр иде дә бит, ә Мәгъсүм уйный да уйный, көйләрне бер-берсенә ялгый да ялгый. Дәртлеләрен, салмакларын, шаяннарын, моңсуларын. Моң ташкыннары күңелемә, битарафлык буаларын җимереп, ташып килеп кергәндәй булды. Алар үчекли дә, юата да, назлап тибрәтә дә иде кебек. Мин җырларга яратам, музыканы аңлый кебек идем. Әмма барыбер аңарчы чукрак булып яшәгәнмен икән. Моңның серен аңлатыр өчен, мине шул таш диварга ялгызымны терәтеп куеп алгысытырга, көйләрнең төрлесен тыңлатырга кирәк булган икән.

Мин, Мәгъсүм күрмәслек итеп, чыршы артынарак авыштым. Ә көй-моңнарга киртә юк, алар бизәлгән чыршыга, аның тирәсендә бөтерелгән бәхетле парларга орынып кына уза да минем йөрәккә килеп тула иде. Ниһаять, музыка өзелде, баян нык кына сыздырып куйды, бию туктады. Чыршы артыннан Мәгъсүм килеп чыкты.

— Һәм сез аны елмаеп каршы алдыгыз, — диде Рамилә, мөһер суккандай итеп. — Үзегез дә аны ярата башладыгыз, шулаймы?

— Туң йөрәгем эрегән иде, анысы хак. Ә менә очынып-талпынып, янып-көеп, бөтен дөньямны онытып сөюгә килсәк, анысын татый алмый калдым шул... Болай буласыларын белсәм, бөтенләй бүтәнчә, кинәнеп, куанып назлар, назланыр идем, мәхәббәтнең татлы касәсен төбенәчә эчәр идем, туя алмас идем... Ә мин үз бәхетемнең кадерен белмәдем. Хәзер менә үкенеп бетә алмыйм.

Май аенда өйләнештек без. «Май аенда туй ясарга кушмый борынгылар, кайгы күп килер», — диделәр миңа. Ә без андый сүзләргә игътибар итмәдек, чөнки хорафатларга ышанмый идек. Аннары укулар бетеп килә, эшкә бергә китәм дисәң, өйләнешкән булырга кирәк иде бит. «Ник аңа чыгасың? Син аны яратмыйсың бит!» — диде Флера турыдан-туры. «Артык өзелеп сөймәсәң, яшәү җиңелрәк, диләр, артык ялкынланудан йөрәгем дә янмас, саурак булырмын», — дидем мин.

Алай да Флераның бу сүзләре күңелне тырнап, хәтергә сеңеп калды. Туй мәшәкатьләре арасында да вак-төяк күңелсезлекләр булгалады. Кибеттән эчемлекләр алганда, Мәгъсүмнең кулыннан бер шешә төшеп ватылган. Ничектер сөмсере коелып кайтып керде бу. Алай да елмаерга тырыша: «Сатучы әйтә, ди, кәләшең чибәр, ахры, синең, ди. Каян белде икән?» Мескенкәем, ул мине бөтен кешегә ошый дип белә иде.

Фидая, урыныннан кузгалып, каршы стенаны биләп торган шкафның аскы тартмасыннан кызыл бәрхет тышлы альбом алды.

— Менә безнең туй фотолары. Монда мин бөрчекле күлмәктән. Мәгъсүм, агын табында киярсең, загска гадирәген киеп бар, дигән иде. Ул миңа күз тияр дип курка иде... Анда да бер кытыршылык килеп чыкты безнең. Менә кара әле, өстәл артындагы бу апага. Бөтен кеше елмайганда, ул берүзе турсаеп утыра. Миңа ачуы чыккан аның. Безнең гаризада язылганнарны рәтләп укымаган, никахлашу турындагы таныклыкка мине ирем фамилиясенә күчереп куйган булып чыкты бу. Каләм тотып кул куярга үрелгәч, мин моны күреп алдым да: «Ник минем фамилияне үзгәрттегез?» — дип сорадым. Апаның күзе шар булды, йөзе алланып чыкты. Хатасы өчен оялгандыр дип уйлаган идем, соңыннан аңлашылды: минем өчен оялган, минем кыланмышларымны затсызлык, әдәпсезлек дип санаган икән. Андый урыннарда эшләүчеләр төрле ырымнарга ышанучан бит алар. Тантана өстәле янында, кияү-кәләш мәңгелеккә бергә булырга ант итешкән урында, чебен дә очмасын, аларча. Ләкин ул чакта мин моны аңламадым. Апа бу кытыршылыкны сиздерми үткәреп җибәрү җаен тапты, колагыма иелеп:«Бүгенгә шулай торсын, соңыннан төзәтербез», — диде.

Ул, бәлки, минем хакта, зөфаф киченнән соң акылга утырыр бу, дип уйлагандыр. Ләкин бер кермәгән акыл тиз генә керми икән шул ул.

Икеме-өчме көннән әйләнеп килдем мин. Таныклыкны төзәттереп, кыз фамилиямне яздырып алдым. Апа пыр-пыр килде, алай да карыша алмады. Үземнекен иттем, әмма күңелем күтәрелмәде. Көне дә җилле иде, кайтканда язуымны җил очырып, күлдәвеккә илтеп ташлады.

— Ирегез үпкәләмәдемени?

— Мин алдан ук шундый шарт куйган идем бит: кыз фамилиямдә калырга. Ә син менә кияүгә чыкканда фамилияңне алыштырган идеңме? — дип сорады Фидая.

— Алыштырган идем дә, аерылгач, кире кайтырга туры килер инде, — диде Рамилә.

— Мин аерылу турында уйламадым, билгеле. Тик баш бирәсем килмәде, мөстәкыйльлегемне саклыйм, янәсе. Ир фамилиясенә күчсәң, гаиләдә аны баш итеп саныйсыңдыр кебек тоелды. Ләкин моның төп хикмәте бөтенләй башкада икән. Балалар өчен кирәк икән ул фамилиянең бертөсле булуы. Мин моны кызым тугач кына аңлый башладым.

Берничә ел узгач, безгә кунакка килгән бер чорсыз хатын бөтен табын алдында: «Сез нишләп икегез ике фамилиядә?» — дип сораган иде. «Мин юләр булганга», — дип җавап бирдем көлеп. Шунда Мәгъсүмнең йөзе ничек балкып киткәнен күрсәң иде син! Соңрак фамилиямне үзгәртмәкче дә идем. Ләкин, җитешермен әле, ашыгыч түгел, дип, һаман суза килдем. Шулай суза-суза бөтенләй соңарганыңны сизми дә каласың икән. Кызым белән икебез ике фамилиядә калдык менә...

Бер караганда, шушы рәвешле заманча кыландым мин, икенче яктан караганда, чордашларымның кайберләреннән шактый артта калган идем бугай. Флера миңа: «Юләр син, — диде. — Акыллы кызлар башта егет белән болай гына торып карыйлар. Бер-берсенә ярашканнарына ышангач кына, загска баралар. Ә син кадимчә кыланасың».

Аны инде сиңа гына әйтәм, бүтәннәр аңламас, мөгаен, кияү кочагына керү минем өчен бик катлаулы вакыйга булып чыкты. Без бит ул хакта беркемнән рәтләп ишетмәгән, бернәрсә укымаган. Ә оялу көчле. Дөрес, мәхәббәт булган җирдә оят юк, дигән булалар да бит, кыз бала өчен алай түгел икән шул ул. Мәхәббәтең акылыңны җуйдырып, бөтен дөньяңны оныттырырлык кайнар булмаса, бигрәк тә. Кыскасы, мин туйдан соң кияү келәтенә кергәч нишләсемне күз алдына китерергә дә курка идем.

Ә «келәт»не безнең студент кызлар бик матур итеп әзерләгәннәр иде: тулай торакның бер бүлмәсендәге дүрт караватның өчесен кырыйга этеп, дүртенчесен ширма белән аерыбрак куйганнар, чигүле мендәрләргә, бизәкле җәймәләргә хушбуй сипкәннәр. Ә мин, анда килеп кергәч, коелып төштем. Мәгъсүм иңемә кул салгач, дерт итеп читкә тайпылдым. Ул моны сабыр кабул итте. Тәрәзә турындагы өстәлгә табын әзерләнгән, уртасына кызыл тюльпаннар куелган иде. Ул җитәкләп мине шул өстәл янына илтеп утыртты.

Төннең калган өлешен без кара-каршы утырып үткәрдек, дисәм, ышанырсың микән? Чәй эчеп кенә түгел, шигырь укып узды безнең сәгатьләр.

Фидая шкафтан бер кечкенә китапчык алып килде. Ул бик затлы итеп шома ак кәгазьгә басылган, тышына чалма кигән егет белән кулына кош тоткан кыз сурәте ясалган иде.

— Мәҗнүн шигырьләре бу, — диде Фидая. — Тыңла әле.

Әйтте дуслар миңа: йоклый аның җаны,
Канат яралмаган кош баласы кебек,
Ә мин җавап бирдем: сөям фәкать аны,
Уятырмын җанын, күңел нурым сибеп...

— Бу шигырьне кат-кат укыйм да, гел безнең хакта язылгандыр, дип уйлыйм, — дип дәвам итте кыйссасын Фидая. — Гаҗәп. Гүяки Ләйлә белән безнең арада гасырлар, чүлләр, таулар, елгалар да булмаган, гүя без алар белән янәшә яшәгәнбез, бер үк язмыш кичергәнбез. Тыңлап кына кара, чын гашыйклар бүген дә нәкъ шушы сүзләрне кабатламасмыни?

Баскан эзләреңә мин битемне куям,
Эзләреңнең назын, йомшаклыгын тоям...

Фидая тураеп Рамиләгә күз тутырып карады да:

— Без шулай алты кичебезне шигырь укып, сөйләшеп үткәрдек, — диде. — Кызлар безгә «баллы атна» ясадылар, башка җирдә кунып йөрделәр. Сине бу гаҗәпләндермиме?

— Гаҗәпләндерә, — диде Рамилә.

— Ышанмыйсың дамы?

— Ник ышанмаска? Гаҗәп нәрсәләр күп бит бу дөньяда. Һәркемнең күңеле үзенчә, мөнәсәбәтләр дә төрле-төрле. Нигә безне пычраклык гаҗәпләндерми дә, сафлык, бер-береңә саклык ышандырмаска тиеш?

— Ә башкалар ышанмый. Флера белән берничә елдан соң очрашкач, мин моны әйтергә тырышып караган идем, шаркылдап көлде генә: «Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, — ди. — Әгәр чыннан да, атна буе бикләнеп, шигырь такмаклап утыргансыз икән, димәк, сез нормаль түгел!» Ә бәлки, мин чыннан да нормаль хәлгә килеп, җитлегеп җитмәгән булганмындыр... Ул моны аңлады. Алты кич буе мине үзенә ияләндерергә тырышты. Үзе белгәнчә, булдыра алганча. Кичләрен баян уйнап, төннәрен шигырь сөйләп. Мин тарсынуымнан, оялуымнан әкренләп арына бардым. Кайсыдыр минутта үзем якынаеп аның иңенә сарылдым, кочагына кердем...

Ә бит монда гайре табигый берни дә юк. Салкын күңелне җылыту өчен алты кич күпмени ул? Таш күңелгә җан өрү өчен озак вакытмыни ул — җәйге кояшның алты тапкыр берничәшәр сәгатькә офык сызыгы артына посып торуы? Шул сәгатьләр эчендә миндәге үзгәрешне ясау өчен шигырьнең, моңның тылсымы кирәк булган да.

Күңелебездә якты моң, өстәлебездә гөлләр иде. Синең теге роза чәчәкләре бәйләмен күргәч, шул кичләрем исемә төште. Хәтеремдә Мәҗнүн шигырьләре терелде.

— Рәхмә-әт, — дип сузды хисләнгән Рамилә.

— Моңнар да күңелләрдән күңелләргә күчеп яши, шигырьләрне дә алып укып була, гөлләр, үз вакыты җиткәч, яңадан терелеп чәчкә ата, тик бәхетнең түм-түгәрәк чаклары гына әйләнеп кайтмый икән. Аңламаганмын, уйламаганмын, кадерен белеп җиткермәгәнмен. Әйе, мин аны кабул иттем. Ләкин бу — рәхмәт йөзеннән аңа буйсыну кебегрәк булды. Минем тәнем салкынча калды. Мин аңа ул көткән, ул лаек булган бәхетне бирә алмадым һәм үзем дә чын ләззәтне татый белмәдем... Үз-үземне шулхәтле тиргим хәзер... Әгәр гомеремнең иң бәхетле чаклары шул икәнен белгән булсам...

Фидаяның сүзе өзелде, күз керфекләренә яшь эленде.

— Алай димәгез, — диде Рамилә. — Гел үткәннәрне генә уйлап, уфтанып яшәргә ярамый. Безнең гомер әле башлана гына, дөньяда яхшы кешеләр дә күп. Үз бәхетебезне тапмабызмыни?

Әмма Фидаяның күңеле мөлдерәмә тулган, ялгызы каласы килгәне сизелеп тора иде. Рамилә сак кына кузгалды да, тыныч йокы теләп, кече бүлмәгә чыгып китте.

## 15

Бу урманчы Гаяровның аягы бер дә җиңел түгел икән — иртән райкомга килгәч, беренче булып коридорда шул очраган иде, хәерлегә булмады. Аны күрүгә, Фидаяның хәтеренә келт итеп Баллыболын буасы янына урман утыртырга кирәклеге килеп төште.

— Укучылар бу атнада бушар, сезгә ярдәм итәрләр, — диде ул Гаяровка юл уңаеннан гына.

Гаяров, аңа өстән карап, гадәтенчә көлемсерәп җавап бирде:

— Онытмавыгыз өчен рәхмәт инде, Фидая Госмановна. Тик соңардыгыз. Без анда предның замы Вәлишин белән сөйләштек, мәсьәләне хәл иттек инде.

«Кирәгең шулхәтле генә», — дигән сыманрак килеп чыкты бу, күңелгә тиде. Шуның аркасында Фидая Искәндәров бүлмәсенә кәефсезләнеп барып керде. Алай да күңелне төшерерлек нәрсәләр алда булып чыкты. Искәндәров кичә «Үзәк»тә ниләр булганын сорап та тормады, чөнки сәгать алтыда эшкә килүгә, телефоннан Вәлишин белән сөйләшкән, колхозның җитәкчесез калганын белгән икән инде. Барыннан да бигрәк Фидаяның Таштимерова турында дөресен, ягъни нинди чир белән хастаханәгә эләгүен әйтмәве абзыйның ачуын чыгарган иде. Фидаяны күрүгә ул, зур башын алга суза төшеп, күзлеге аша текәлеп карады, сәламне дә алмыйча:

— Бер-беребезгә ялган сөйли башласак, беләсеңме, кая барып чыгачакбыз? — диде. — Әгәр Таштимерованың бу хәлләрен белгән булсак, без башка юл сайлар идек. Бүтәнчә уйлар идек. Син монда безне буташтырып кына калмадың, аның үзен дә бик авыр хәлгә куйдың бит, аңлыйсыңмы? Председательнең әхлагын җыелышка куеп тикшерергә кем кушты сезгә? Үзегез, кая карама, хатын-кызга юл бирмиләр, дип дәгъвалыйсыз, үзегез бер-берегезнең башын ашарга гына торасыз! Төштән соң активны җыеп сөйләшәбез, әзер торыгыз! — дип, Искәндәров Фидаяны тыңлап та тормыйча чыгарып җибәрде. Хәер, аңа каршы ни әйтеп була иде соң?

Актив дигәне, районның төп җитәкчеләре, ап-ак күлмәкләр өстеннән галстуклар таккан, пөхтә костюмнар кигән, ботинкаларын ялтыратып чистарткан, чиста итеп кырынган, шома битле, түшләре, корсаклары шактый бүлтәйгән ирләр иде. Алар янында талдай зифа буйлы, йомшак тавышлы Фидая үзен гадәттәгечә ят итеп, карга өеренә килеп эләккән чыпчык кебегрәк хис итте.

Искәндәров мәсьәләне кыска гына аңлатып, фикер алышырга тәкъдим иткәч, беразга тынлык урнашты. Аннары төзү-монтаж идарәсе начальнигы Мирхуҗин, үзалдына уйлангандай, сабыр гына әйтеп куйды:

— Дүрт аяклы ат та абына, җитәкче дә ялгыша шул инде. Халык белән эшләү ифрат авыр бит ул. Җыелыш алдына барып басканчы, алдан уйлап, барысын да әзерләп-көйләп куйсаң гына. Аннары тагын шунысы да бар: халык Таштимерованы сөйми икән, Фидая Госмановна гына аны көчләп яраттыра алмый. Тәҗрибәсезлектән килеп чыккан хәл инде бу. Хатын-кыз кешегә халык белән эшләү җиңел дә түгел.

Шуннан телләр ачылды. Кемнәрнең ни әйткәне хәтергә сеңеп калмады, сүз сөреше бер юнәлештә барды: яшь җитәкчегә тәҗрибә җитмәгән. Дөрес, каты бәрелмәделәр үзе, әдәп сакладылар. Әмма шулай да, уңга-сулга карап, болай дисәм ничек булыр, алай әйтсәм, үпкәләтмәмме дип, сүзне үлчәп торасы да юк, хатын-кыз хакында турысын әйтергә була иде. Чөнки ир җитәкчеләрнең һәркайсының яклаучылары, бергәләп табын корып серләшердәй, бер-берсенә терәк булырдай фикердәшләре бар. Аларга ялгыш кына орынып кара син, дуслары, чәчрәп чыгып, өстеңә ябырылачак. Ә хатын-кызның мондый югары даирәдә кеме бар? Аның өчен кемнең эче пошсын да ул үзе кемгә терәк була алсын?

Бу җыелышта Нурханова ялгызлыкның ачы касәсен тутырып эчте. Әмма сер бирмәскә, түзәргә кирәк иде. Чөнки алдында торган зур эшне башкарып чыгу өчен, морадына ирешү өчен аңа хәзергә үз урынында калу кирәк иде.

Гомуми сүз дә җайлап кына нәкъ менә шуңа — Кармаш хастаханәсен төзүгә килеп терәлде. Нурханованың күп вакытын, көчен шуңа сарыф итеп, колхозга дигән пар казанын әле яңа башланган төзелешкә илтеп аткару кебек кыланмышларын ничек аңлатырга? Юк-бардан ыгы-зыгы куптару гына түгелмени бу? Быел тапшыру планына кертелмәгән, акча белән дә, кирәкле материаллар белән дә тәэмин ителмәгән төзелешкә тегене-моны таләп итүне ничек аңлатырга?

— Кармашның иске казаны бөтенләй эштән чыккан иде бит инде. Аның әле иске бинасын да җылытырга кирәк ләбаса. Кышка авыруларны катырып үтерергәмени? — диде Фидая.

— Минемчә, хатын-кызларча фикер йөртү бу, — диде, катгый итеп, чандыр гәүдәле, муртайган кыяфәтле финанс бүлеге мөдире Хатипов. — Гафу итегез, әйтмичә дә булдыра алмадым. Тегеннән-моннан эләктергәләп, кешенекен чәлдереп кенә андый зур эшләр эшләнми. Ярый, монысы зур мәсьәлә түгел, шулай үтеп тә китәр. Ә менә бинасын торгызганда, ирләрчә уйларга кирәк. Проектны тиешле оешмалардан раслатырга, бюджеттан кирәк кадәрле акчаны бүлеп бирүләрен сорап, югары оешмаларга мөрәҗәгать итәргә! Һәм шуңа ирешергә!

Фидая бармакларын авырттырып кысты. «Кызма, — диде эчтән генә үз-үзенә. — Сабыр бул. Иелгән башны кылыч кисми... Дөрес сүз сөйләп кинәнсеннәр, үзләрен хатын-кыздан өстен куеп ирәйсеннәр. Күңелләре хуш булса, миңа да карашлары йомшар, бәлки...»

— Документлар барсы да әзер бит, янгын сүндерүчеләрнең, санэпидстанциянең искәрмәләрен күздә тотып, тагын төзәтмәләр кертелде. Мин дә, баш табиб Газимов та сезнең ярдәм итүегезгә ышанабыз.

Шунда Тавис Мирхуҗин торып басып, сөйләшүне һич кирәкмәгән юнәлешкә борып җибәрде.

— Фидая Госмановна безнеңчә генә түгел, яңача эшләргә омтыла, — диде, авызын ерып, көр тавыш белән. — Билләһи дип әйтәм, менә күрерсез, ел да үтмәс, больнисны ачып та җибәрер, Билал шунда берәребезнең корсагын да ярып куяр әле. Әйткән иде диярсез.

— Инде ул больниска керергә язмасын, — диде кемдер.

— Газимовка кадәр анда гомумән операция ясау дигәнне онытканнар иде инде. Таблеткалар гына өләшәләр иде.

— Больница кирәк, анысы турында сүз дә юк, — диде Искәндәров, карашын Фидаяга төбәп. — Ләкин һәр төзелеш эшенең үз тәртибе бар. Кабаланып кына рәтле эш майтарып булмый. Итәккә ут капмаган лабаса, район больницасы бар бит. Врачлары да бик әйбәт. Катлаулы очракларда Казаннан санавиация чакыра алабыз... Безнең сүз читкәрәк китте әле монда. Нишлибез бу Таштимерова белән? Районда бердәнбер хатын-кыз председатель иде. Безнең горурлыгыбыз. Болай гына эштән чыгарып, селтәп атып булмый. Моның өчен өстәгеләр безгә рәхмәт әйтмәсләр.

Һәммәсе ничектер сагаеп калгандай булдылар, берсенең дә башлап сүз әйтәсе килми иде. Ниһаять, күрше «Җиңүче» колхозының рәисе, алтмышны тутырып килә торган тәҗрибәле абзый Хасият Ясәвиев әкрен-салмак кына урыныннан кузгалды.

— Дөресен генә әйткәндә, Ниса халык белән уртак тел таба алмый башлады кебек. Үзегез беләсез, узган елны гына да Баллыболыннан унбиш семья чыгып китте. Безгә күчәргә дәртсенүчеләр дә бар. Күрше хакы — Тәңре хакы, дип, яхшысынмаганга гына китермибез. Нисада тәҗрибә җитәрлек. Бик тырыш та. Тик менә хәзерге заманда халыкка ярау бик авыр шул. Кеше бит ул җитәкченең тырнак астыннан кер эзләргә ярата, бер гаебеңне мең итеп күрә. Шул якларын уйласаң, ай-һай ла, мондый хәлләрдән соң халыкны тыңлата алыр микән...

— Бер караганда, аның шушылай килеп чыгуы хәерлегәдер дә әле, — диде Мирхуҗин, гадәттәгечә җиңел генә итеп. — Әгәр шунда ут чыгарып өч йортны яндырмаса, Ташнисаны берничек урыныннан куптарып булмас иде. Бердәнбер хатын-кыз җитәкче, горурлыгыбыз, дип, орынырга куркып утырыр идегез. Чыбыркысын шартлатып, бөтен авылны куып тараткнчы, баш булып йөрер иде шунда. Монда инде форсаттан файдаланмый чара юк, минемчә. Сәламәтлеге какшавын сылтау итеп, гариза бирсен. Фидая Госмановна әйбәтләп сөйләшер үзе белән.

Бу урында Мирхуҗин Нурхановага серле генә карап куйды.

— Шулай итми дә булмас шул, — диде Искәндәров. — Бик җайсыз вакытта председательне алыштырырга туры килә. Аның бит әле ул урынга әзерлекле кандидатурасы да юк. Бергәләп уйлашыйк әле: кемнәрне тәкъдим итәрсез?

Ул арада телефон шылтырады. Секретарь кыз Казаннан шылтыратканнарын әйткәч, Искәндәров трубканы алды. Бик кирәкле кеше иде, ахры, ә бәлки, зур җитәкчедер, ул бүлмәдәгеләргә кулын изәде.

— Тәнәфес! Ял итеп керегез бераз. Уйлаша торыгыз...

Алгы бүлмәдә секретарь кыз Фәүзия чәй хәстәрләп куйган икән, чынаякларны учларына алып, почмаккарак елыштылар. Уртада, әлбәттә, Мирхуҗин иде. Шыпырт сөйләшсәләр дә, аларга аркасы белән торган Фидаяга ишетелде: сүзләре әлеге дә баягы шул Таштимерова турында иде.

— Бер карасаң, кызганыч та инде мескен. Эштән башы чыкмады, чыбыркы болгаудан бүтәнне белмәде.

— Әйтәсе дә юк! Югары эшкә күтәреп кенә хатыннарны бәхетле итәм димә икән шул. Бер рәхәт тә күрмәде мескен.

— Алай димә! Рәхәтен күрмәсә, кенәз Йосыпов кулына барып кермәгән булыр иде әле!

Хихылдашалар. Тычканга үлем, мәчегә көлке.

Фидаяның кулындагы чынаяк чайпалып, кайнар чәй тәлинкәгә түгелде...

Ярый, мескен Нисаны тиз оныттылар тагын. Мәзәк сөйләүгә күчтеләр.

— Шул «Үзәк»кә радио хәбәрчесен алып барырга туры килгән иде берзаман, — дип сөйли башлады пропаганда бүлеге мөдире Фәнис. — Ул чакта анда савым күрсәткечләре яхшы иде. Ферма мөдире Газизуллинны чакырып китердек. Шулай-шулай дим, менә Казаннан сезнең янга килгәннәр. Хәбәрче тегенең авызына микрофонын китереп терәде. Сөйлә, дибез, савымны арттыруга ничек ирешәсез. «Силос ашатабыз, салам бирәбез», — диде дә шуның белән төгәлләп куйды бу. Хәбәрче әйтә: «Син, абзый, сузыбрак сөйлә», — ди. «Сило-о-ос а-ашата-а-а-абыз, сала-а-а-ам бирә-ә-ә-әбез», — дип сузып-сузып сөйли башлады теге.

Хихылдашалар. Ниса да, «Үзәк» тә, Искәндәровның уйлагыз әле, дигәне дә онытылды.

Җыелышта сөйләгәннәрне ишектән чыгуга онытырга олы җитәкчеләрдән өйрәнгәннәр булса кирәк. Алар да бит шулай: әле генә мәртәбәле кабинетларда яки зур залларда җаннарны актарырлык сүзләр сөйлиләр яки кемнәрнедер эштән алып, бөтен язмышын җимереп ташлыйлар, халык өчен, гомуми эшкә бирелгән бу нинди фидаилә, дип уйларсың. Ә алар кул күтәреп карар чыгаралар да, таралыша башлауга,

берни булмагандай, шаярыша-көлешә, мәзәк-анекдотлар сөйләшә башлыйлар. Ничек шулай тиз үзгәрә алалар икән? Эчләрен ярып карыйсы иде.

Боларны да мизгел эчендә кемдер алмаштырып куя диярсең: кабинетка кире кергәндә, чырайлар җитдиләнде, сыннар турайды.

— Йә, кемдә нинди тәкъдимнәр бар? — диде Искәндәров.

— Элекке председательне Фидая Госмановна эштән алган бит, алмашка кемне куясын уйлагандыр инде, — диде Мирхуҗин, бик җитди кыланып. — Аны тыңлап карыйк.

Башка кайнар су койгандай итте дә куйды бу. Әгәр шунда шәбәреп, җебеп төшсәң, ык-мык итсәң, беттем диган сүз инде, сине бүтән санга сукмаячаклар. Фидая тешләрен кысып торып басты.

— Әйе, бар минем кандидатурам, — диде ул.

— Кем ул?— дип, аңа текәлде Искәндәров.

Башта уйлар яшен тизлеге белән йөгереп узды.

— Район халкы ихтирам итә торган кеше. Яшь, энергияле, тәҗрибәле.

— Кем?

— Гаяров.

Һәммәсе дә гаҗәпләнеп Фидаяга төбәлделәр.

— Урман хуҗалыгыннан, директор урынбасары, — дип ачыклады Фидая. Ул үзен буаның билгесез урынында суга сикергәндәй хис итә иде. Әлбәттә инде, аның бу сүзен җитдигә алмаячаклар, көлешәчәкләр, аннары аңа тәкъдименең төптән уйланмаган булуын аңлатырга керешәчәкләр. Ләкин, ни хикмәттер, бүлмәдәгеләр, көләсе-шаулашасы урында, тынып калдылар, башларын аска иеп, уйга талдылар. Аннары берәм-берәм күтәрелеп сөйли башладылар. Һәм барысы да бу тәкъдимгә кушылдылар, Гаяровны мактадылар. Дөрес, белеме — урман белгечлеге буенча, яше дә әле утызга җитмәгән. Ләкин яшьлек — үтә торган кимчелек, дигәннәр бит. Ә егет тырыш, уңган, үсәргә бөтен мөмкинлекләре бар.

— Ярый, уйлашырбыз, — диде Искәндәров, йомгак ясап. — Ничек кенә булмасын, сез бу колхозга үзегез шефлык итәчәксез, Фидая Госмановна. Яңа җитәкчегә ярдәм итәрсез, аның белән бергә җавабын да тотарсыз.

Алгы бүлмә аша чыгып барганда, Мирхуҗин Нурхановага яны белән ышкылып узды.

— Егетләрнең асылларын сайлый беләсез икән, — дип пышылдады. — Ялгышсагыз да, үкенече булмас, егылсаң, атның яхшысыннан егыл, диләр бит!

## 16

Шуннан соң эшне коры тоттылар: Гаяровны районга чакырып сөйләштеләр дә раслатыр өчен Казанга җибәрделәр. Авылның булачак хуҗасы белән иң элек республиканың җитәкчеләре очрашып сөйләшә, аның бу эшкә ярау-ярамавын тикшерә. Шуннан соң гына авыл халкына сайларга тәкъдим итәләр.

Ул арада Таштимерованы тыныч кына санаторийга озаттылар.

Баллыболынга яңа председатель сайлатырга, Искәндәров һәм авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире Мөҗәһит Сәлахов белән бергә, колхозның шефы буларак Нурханова да барырга тиеш булды.

Авылның клубы соңгы елларда салынган булып, райондагы башка шундый биналар белән бериш иде. Биек тә, иркен дә, якты да, тик салкын вакытларда ничек җылытырга икәнен генә уйлап җиткермәгәннәр. Халык куртка-пальтосын салмаган, хатыннар шәлгә төренеп, ирләр бүреген киеп утыра. Сәхнәдәгеләр, алар белән бергә Давыт Гаяров та иңнәренә пальтоларын салганнар иде.

Җыелышны рәис урынбасары Вәлишин ачты.

— Здравствуйте, товарищи! — дип башлап җибәрде ул. — Разрешите начать собрание.

Шактый гына акцент белән русча әйтелгән бу сүзләрдән Гаяровның хәйран калганлыгы йөзенә бәреп чыкты, моны күзәтеп утырган Фидая шаркылдап көлүдән чак кына тыелып калды.

— Если вы не возражаете, мы будем разрешать выступающим говорить на родном языке. На русский потом переведем, — дип дәвам итте Вәлишин.

Бу сүзләрне ул иң арткы рәттә утыручы, картузларын батырып кигән берничә ир-атка карап әйтте. Алар шушы «Үзәк» колхозына кергән Сидоровка авылы кешеләре иде. Бу урыс авылында утызлап кына йорт бар, аларның да яртысы инде бушап калган, эш көче дә биш-алты механизатордан гыйбарәт. Фидая Баллыболын мәктәбендә директор булып эшләгәндә, Сидоровканың үзендә башлангыч мәктәп кенә булып, зуррак балаларны унбиш чакрым ераклыктага Николаевканың интернатына илтеп урнаштыралар иде. Шунлыктан Фидаяга андагы кешеләр белән якыннан аралашырга туры килмәде. Берничә ир-ат кына менә шушылай еллык отчет-сайлау җыелышында күренгәли. Сәхнәгә күтәрелгән берәү дә, алар өчен генә дип, телен сындырып, русча сөйләп азапланмый, билгеле. Арткы рәттәге Сидоровка егетләре кыймылдамый да

утыра, ни уйлый, ни кичерәләрдер, Алла белсен. Гомумән, ул авылдагы урысларның кайчан, каян килеп утырган булулары белән дә әллә ни кызыксынган кеше юк, алар үзләре дә Баллыболын халкы белән аралашмый, татарча өйрәнергә теләми. Сагышлы күз карашлары унбиш чакрымдагы Николаевкага, аннан да ары китеп, йөз егерме чакрымдагы тимер юл станцасы тарафына төбәлгән.

Фидая, иелә төшеп, Гаяровка:

— Колхозга бер урыс авылы да кергәнен беләсеңдер бит, — диде.

Вәлишин татарчага күчте, Давыт бөтен дикъкатен аңа юнәлтте. Аңа иң беренче чиратта шушы адәм белән, ягъни үзенең урынбасары белән эшләргә туры киләчәк иде бит. Бу кешенең эчендәге тышында булса кирәк, бөтен кыяфәтендә сабыйларча беркатлы ихласлылык ярылып ята иде. Фидая, Давытка күз сирпеп, җитәкче кешегә беркатлы булырга ярамый, бу урынбасар белән, ай-һай, уңарсың микән, дип уйлап куйды. Яхшы күңелле, йомшак табигатьле кешеләрнең күбесенә хас булганча, Вәлишин башкаларның игътибарын җәлеп итәрлек, авызларны ачып тыңлатырлык итеп сөйли белми иде. Халык бит ул төртмә сүзне күбрәк ярата, Әхсән Вәлишин исә кешегә каты бәрелә белми. Аның тоньк тавышы, шома сүзләре дикъкатьне таркатып җибәрде.

Фидая үз уйларына бирелде, чөнки чыгыш ясарга да җыенмый, төп сүзне райкомның беренче секретаре Искәндәров, халыкча әйтсәк, «беренче» әйтәчәк иде.

Бу авылда эшләгән елларда, мәктәп директоры һәм колхозның идарә әгъзасы буларак, күп тапкырлар президиумда, шушы өстәл артында утырганы булды аның. Залдагы кешеләр һәммәсе яхшы таныш, күбесе күптән гадәтләнгән урынына утырган. Ә менә ак шәл бәйләгән фельдшер Мөнирә дүртенче рәтнең уртасына күчкән. Ник анда утырды икән Мөнирә? Мәгъсүм урындыгы бит ул! Хәер, киткәннәрнең урыны буш тормый шул... Тик сәхнәдә утырган Фидаяның анда һаман газиз кешесенең йөзен генә күрәсе килә иде. Хатынына көч биргәндәй, балкып утырыр, ара-тирә, икесе генә сизәрдәй итеп, күз кысып куяр иде... Ә Мөнирәнең йөзе моңсу, уйлары уелыплар китәрлек, мөгаен. Аңа карагач: «Һәркемнең дә хәсерәте була торгандыр инде», — дигән җыр хәтергә килә. Әйе, моң дәрьялары тирән шул Мөнирәнең... Аны ул дәрьяларга салган кеше үзе дә якында гына, икенче рәттә, сул кырыйдарак утыра. Янәшәсендәге бер урындык буш... Ул аны башка берәү өчен саклаган. Әнә ишектән, чәчәкле шәлен төзәтә-төзәтә, клуб мөдире Каләмгөл килеп керде һәм, иелә төшеп, рәт арасыннан узып, Гыйззетдин янына, буш урынга барып утырды. Шул тирәдәгеләр борылып карады, ә Мөнирәнең исә башы туры калды, йөзе генә үзгәреп китте.

Җыелыш үз тәртибе белән барды. Нисаның авыру сәбәпле эшеннән азат итүләрен сорап язган гаризасын укыгач, бераз тынып тордылар да, бер-бер артлы сәхнәгә күтәрелеп, куллар болгап, кызып-кызып сөйләргә керештеләр. Телләр ачылды, чөнки соңыннан, ник алай әйттең дә ник болай дидең, дип, күзгә төртергә баш өстеңдә җитәкченең юк чагы, икенчедән, әйтәсе килгәнең турыдан-туры район җитәкчесенең үз колагына ирешә. Яңа хуҗага үзеңне күрсәтеп кую да зыян итми. Актив икән, уртак эш өчен янып йөри икән бу кеше, дип уйласын. Сөйлим дигән кешегә исә сүз җитәрлек, кабыргасы белән куярлык мәсьәләләр буа буарлык. Ферма буйларын тирес баскан, ташырга трактор юк, чөнки запчастьлар җитми... Җылытырга дисәң, котельныйның казаны эштән чыккан, ягулык та кайтартылмаган... Авылдан яшьләр китә тора, чөнки эш авыр, рәтләп түләү юк, яңа өйләнешкәннәргә торыр урын юк. Әле менә янгыннан зыян күрүчеләргә чит авыллардан ярдәм итәргә тиешләр иде, анысының да очы күренми, барыбер үз колхозыңның ярдәменнән башка башкарып чыга алмаячаклар...

Ниса турында әйтүче юк, әмма эшнең авырлыгы һәм тормышның читенлекләре хуҗалык җитәкчесенең булдыксызлыгыннан килгәнлеге сөйләүчеләрнең тел төбеннән аңлашыла иде. Чыгыш ясаучыларның һәммәсе Искәндәров белән янәшә утырган Гаяровка төбәлеп-төбәлеп карап куялар, боларны, син, колагыңа киртләп куй, дип кисәткән кебек итәләр иде. Чөнки Беренченең үзе белән янәшә утырган егетнең председатель итеп куелачагы һәммәсе өчен дә көн кебек ачык иде инде.

Сәхнәгә Гаделша карт күтәрелгәч, зал сагаеп калды. Абзый, исеменә лаек рәвештә, һәрвакыт чәчрәп чыгып гаделлекне яклый һәм бу изге юлда берәүне дә аяп тормый иде. Чын коммунистларча, хак дөресен битенә чәпи дә куя, кимчелекләрне бөтен мир алдында ача да бирә. Ә кемдә юк ул кимчелек? Сөйли башласа, керер тишек тапмассың. Колхозның ревкомиссия председателе дигәнен урыныннан алып ташлап булмый. Алсалар да исе китмәс иде, гаделлек өчен җәфа чигәм, дип кукраеп кына йөрер иде. Кыскасы, Гаделша картның күгәренгән иренле, черек тешле авызын томалар әмәл юк иде. Ул бит әле авылда гына сөйләп калмый, район гәзитенә дә яза! Бик актив хәбәрче ул анда! Кимчелекләрне тәнкыйть утында көйдерергә дисәң, аңа куш! «Саф намуслы хезмәт ветераны буларак, сезгә шуны хәбәр итәргә тиеш дип табам ки...» — дип башланган хатлары редакциядә әллә ничә папка тулы, диләр.

Бу юлы кем килеп кабар икән моның кармагына? Бу сәгатьләрдә санаторийда иркәләнеп яткан Ташниса белән генә авыз чайкаса, ни әйтер идең дә бит. Башка-бүтәннәрне дә каптырып алуы ихтимал. Исеме чыккан кешегә бик җайсыз булачак иде бу. Ул бит яңа хуҗаның хәтеренә уелып калачак, Гаделша

тәнкыйтенең керен-карасын кер порошогы белән генә юып алып булмый! Шуларны уйлап, һәммәсе шым калдылар. Куркулары юкка булмаган икән. Гаделша абзый Ташнисаны телгә алып тормады. Егылганны таптый торган гадәте юк чөнки. Ул күпләрнең иң авырткан җиренә тотынды:

— Бу эчүчелек дигән афәткә кайчан чик куябыз, иптәшләр? Кая барсаң, шунда шешә белән әшнәлек! Ремонтка туктаганнарның айныганы юк, исерек килеш рульгә утырып чабалар...

Арттарак утырган ирләр, муеннарын бөгеп, алдагыларның артына елыштылар. Картның күзе миңа гына төшмәсә ярар иде, дип, Ходайга ялваралар.

— Инде хәзер хатыннарның да кайсыберләре фермага сыер саварга барган җирдән әсәренеп кайта башлады. Кайберләрегез белән кара-каршы очрашканда, сезнең өчен мин оялам! Җир тишегенә керерлек буласың, билләһи!

Бусында инде хатыннарның башы иелде. Йөрәкләр дерт-мерт килә! Әйтәләр шул аны авылда, талпан кадалса, суырып алып була, Гаделша каныкса, котылам, димә, дип, халык әйтсә, хак әйтә шул. Ах, аның намуслы булулары! Карт кешегә намусын тыярга өйрәнергә кирәк иде дә бит, юк шул, һаман иске гадәтен куа. Намусын тыя белмәсә, телен тыярга өйрәнсен иде, ичмасам... Бу минутта клубтагы шактый кешенең кайнарланган башында шундый уйлар чагылып узды.

— Бүгенгә фамилияләрне әйтми торам әле. Намус саклыйм. Әмма дә ләкин яңа хуҗаны алдан ук кисәтеп куярга кирәк: бу мәсьәләдә безнең барыбызга да би-ик уяу булырга туры киләчәк! Югыйсә, билләһи дип әйтәм, авылыбыз белән шул хәмернең сасы баткаклыгында тончыгачакбыз. Әйткән ие бу диярсез, соң булыр!

Һәммәсе җиңел сулап куйдылар. Карт сәхнәдән төшеп үз урынына барганда, берничәсе, маладис, дөрес әйтәсең, дип аның кулын кысып, сөякчел иңеннән каккаладылар хәтта. Сыннар турайды, йөзләр ачылды. Искәндәровның чыгышын тын да алмый тыңладылар, яңа рәисне шау-шусыз гына, бертавыштан сайлап та куйдылар. Арада икеләнүчеләр дә, ә бәлки, Давытка бөтенләй каршылар да булгандыр булуын, ләкин яңа хуҗа белән араны алдан ук бозып куярга ярамаганын ахмак та аңлый иде. Шунлыктан каршы кул күтәрүче булмады.

Җыелыш тәмамланып, һәммәсе иркен сулап куйгач, сәхнә артында чәй эчеп алдылар. Шундагы бер бүлмәдә Гыйззетдин белән Каләмгөл яшәп ята, Наилә апа сумсалар пешереп китергән, табын ярыйсы гына иде.

Яңа хуҗа өчен йорт салырга кирәк булыр, ә хәзергә Наилә апада торып торырга туры киләчәк, дип килештеләр. Ирләр алданрак китеп барды, Фидая, хуҗалар янында хәл-әхвәл сорашып, бераз гына тоткарланды.

Каләмгөл белән Гыйззетдин аны озата чыктылар. Капка төбендә Балкышның машинасы юк иде.

— Шоферың бик үткен күренә, Фидая, кызлар озатып йөридер, мөгаен, — диде Гыйззетдин. — Дөньясын онытмаган булса ярый инде.

— Эчендә җаны булган егет кеше мондый кичне начальнигын уйлап утырамыни? — дип, Каләмгөл тыенкы гына, әмма йөрәк түреннән, хисле итеп көлеп куйды. — Йолдызларны гына карагыз. Салют ясап сипкәннәрмени! Кемнәр хөрмәтенә икән, белмисеңме, Гыйззәтлем?

Шулай диде дә Каләмгөл, шәленә уралып, аркасы белән иренең күкрәгенә терәлде. Гыйззетдин аны кочып алды. Туңмасын дип инде, әлбәттә, чөнки көн суыткан, ә Каләмгөл кофта өстеннән шәл генә урап чыккан иде. Үзләренең тотышлары Фидаяның күңелендә хисләр өермәсе кузгатканын сизмәделәр, чөнки бер-берсенә тартылу, елышу алар өчен сулыш алу кебек табигый халәт, яшәешнең рәвеше иде.

Ә Фидаяның беркайчан да кеше күз алдында иренә бу рәвешле елышканы, аның кочагына кереп басып торганы булмады. Әдәп саклаганнан, мәктәп директоры буларак абруен югары тотканнан гына иде микән? Ә бәлки, ул үз парына-ярына бу рәвешле анасына тартылган сабый бала ихласлыгы белән тартыла, омтыла белмәгәндер?

Ах, төне нинди бит, төне! Аяз күктә йолдызлар шулхәтле мул сибелгән, шулхәтле якынайган, шулкадәр чекерәеп, зәңгәрсу, саргылт, кызгылт нурлар чәчеп яна. Тик алар да ялгыз-ялгыз, бер-берсенә елыша алмыйлар. Фидая кебек... Яктысы бар, җылысы юк аларның.

— Кырау төшәр, ахрысы, — диде Гыйззетдин.

Югары очтан гүләгән тавыш ишетелде, фаралар төн караңгылыгын кисте.

— Әнә, табылды егет, — диде Каләмгөл.

# 17

Һәр кешенең үз эше, ә Балкышның бу авылда үз йомышы бар иде. Җыелыш барган арада, ул эчен пошырып машинада утырмаска, югары очка барып килергә булды. Таныш капка төбендә машинасын

туктатып, фаралары белән «Медпункт» дигән язуны яктыртты. Ике тәрәзә яктырып тора, димәк, өйдә кеше бар дигән сүз. Фельдшер үзе җыелышта булырга тиеш, мөгаен, Зиләйлә үзе генәдер. Менә хәзер, машина тавышын ишетеп, тәрәзәгә килер, фараларын балкытып торган машинаны күреп, йөгереп чыгар. Кем килгәнен күңеле сизәргә тиеш бит аның!

Ләкин Балкыш, моторны шактый үкертеп, фараларын уйнаткалап торса да, чыккан кеше күренмәде. Әллә Зиләйлә дә җыелышта микән? Юк ла, мәктәп баласын кем кертсен анда!

Машинаны сүндерергә туры килде. Балкыш төшеп кече капкадан керде, болдырга менеп, ишекне шакыды. Анда да йөгереп чыкмадылар, шактый көткәч кенә, эчке ишек шыгырдады. Көйле, нечкә, таныш тавыш сузып кына:

— Кем ул анда? — дип сорады.

— Авыруны кабул итегез! — диде Балкыш, сыкранган сыман кыланып.

— Әни клубка китте. Җыелышка.

— Ай, үләм-үләм! Хәзер егылам шушында!

Өйалдының ишеге шуннан соң гына ачылды. Эчке яктан сөйләшкән тавышлар ишетелде. Кеше бар иде микәнни? Балкыш, сул күзен учы белән каплап, эчкә атлады. Бүлмәнең түрендә аклы-каралы телевизор эшләп утыра икән. Мәскәүдән концерт күрсәтәләр. Сөйләшкән дигәне шундагы ирнең тавышы булып, аны бер җырчы кыз алыштырды.

Балкыш каршында басып торган кызны күзеннән кичерде. Зиләйләне кызыл куртка, итекләр кигән килеш кенә күргән иде бит әле ул. Кыз шактый искергән, кечерәйгән бумази халат кигән, итәк астыннан йомры тез башлары күренеп тора, кыскарган җиңеннән озын нечкә, шома, карап торышка ук җылы тоелган куллары сузылып чыккан. Куе, кара чәчен баш артына кереш белән тарттырып куйган, калку маңгае яктырып тора, чигәгә таба озынчалап уелган коңгырт күзләре мөлдерәп карый, тулы иреннәре гаҗәпләнүдән бераз ачылган. Тешләре тип-тигез, ап-ак икән. Әле генә җитлегеп килгән кызкайның кыяфәте күңелнең нечкә кылын сызып җибәргәндәй итте.

— Исәнме, — диде Балкыш. — Әйткән идем бит мин сиңа киләм дип. Килдем менә.

Кызның күз карашы ачылыбрак киткәндәй булды — ул Балкышны исенә төшерде.

— Исәнме!

Ул ак шакмаклы ашъяулык җәйгән өстәл янындагы урындыкны ишеккә табарак шудырды.

— Утырып тор. Әни, кайткач, медпункт ягын ачар да алып кереп карар.

— Уф, авырттыра, түзәр хәлем юк, — диде Балкыш. — Син карап карыйсыңмы әллә?

— Ни булды?

— Әйткән идем бит мин сиңа, күземә чүп керсә, киләм, дип, керде менә!

Зиләйлә стенадагы шкаф киштәсеннән мамык кисәге алды.

— Каяле!

Оста икән үзе, Балкыш сизми дә калды, нечкә бармаклары белән өске күз кабагын әйләндереп куйды.

— Өскә таба кара, — диде. — Ә хәзер аска таба.

Ул иелеп якын ук килде, хуш исле сулышы белән битне өтте, тәненнән исерткеч дулкын бөркелгәндәй булды. Башка берәү шулай якын килсә, Балкыш аны кочагына алмый калмас иде. Әмма бу юлы тыелды, саксыз кыланып, кызның күңеленә тиюдән курыкты.

Зиләйлә, иркә хәрәкәт белән аның керфекләрен сыйпаштырды да, күз кабагын кире кайтарып:

— Әйбер-кара күренми, күз яшең белән юылып чыккандыр, — диде.

— Юк, кыра! Рульдә бит мин, төнге юлда сыңар күз белән йөреп булмый! Син күрмисең генәдер. Минем әби әйтә, күздәге чүпне күреп булмый, тел генә сизә, ди. Телең белән ялап кара, телең белән!

— Өеңә кайткач, әбиеңнән ялатырсың, — дип кырт кисте Зиләйлә. Һәм, шкафтан нәни генә шешә, пипетка алып, салкынча бармаклары белән егетнең күз кабакларын киереп, дару тамызды.

— Әллә-әй! — диде Балкыш. — Күзне чыгара күрмә тагын! Белеп саласыңмы соң?

— Даруларны бутарга монда беренче көнем түгел. Мин аны килгән-киткәнгә гел салып торам.

— Күп эшләгән бутала да инде. Әнә безнең авылның фельдшеры төнлә торып дару тамызган икән дә күз алмасы кайнап, шешеп чыккан. Шешәләрне бутаган, ди.

Зиләйлә, шикләнгәндәй, шешәнең тышындагы язуга карап алды.

— Бер дә курыкма. Бу нәкъ тиешлесе.

— Кансыз да инде шушы врачлар!

— Җебеп аксаң, врач була алмыйсың шул, — дип, көтмәгәндә бу сүз белән килеште Зиләйлә. — Хирургларга, әнә, кешеләрнең эчен ярып, әллә нинди операцияләр ясарга туры килә. Мәлҗерәп төшеп, бәлтерәп торсалар, ни булыр иде?

— Ә син шулай бәгырьсез булырга әниеңнән өйрәнәсеңме әллә?

— Кирәк нәрсәгә өйрәнәм. Кем әйтте сиңа минем әнине бәгырьсез дип? Ныклык белән күңелнең катылыгы икесе ике нәрсә ул.

Кара син аны, тыштан бик нәфис һәм нәзберек күренгән бу баланың үзәге шактый нык икән бит!

— Районга кайтып җиткәнче генә чыдарсың әле, — диде ул, ияге белән ишеккә таба ымлап. — Авыртса, иртәгә район больницасына барып күренерсең.

Ул Балкышның чыгып киткәнен көтә иде. Хәзер инде аның чибәрлегеннән, тәненнән бәргән җылы дулкыннан тыш, күңеленең чыннан да катылыгы сизелде. Җитлегеп килгән кызлар, Балкыштай егет белән мондый аулакта очрашканда, бу рәвешле җитди, хәтта кырыс булып кала алмыйлар. Табигатьнең тылсымлы кодрәте аларны алгысыта, йөрәктә сихри күмерен көйрәтеп, күзләрдән очкын чәчрәтә, бит очларында ялкын шәүләсе уйната. Ә бу кыз нишләп шушы хәтле тыныч, салкын була ала соң әле? Балкыш аның йөзенә текәлеп карады да эчендә нindидер шомлы сер, үсмерләргә хас булмаган ваем, гамь барлыгын күргәндәй булды. Моңлы бала иде бу, зарлы бала иде. Кешеләргә сагаеп карый, җәберләмәсләрме дип шикләнә. Нилектән бу шулай? Анысын сорап булмый, бу кыз очраклы кешегә тиз генә, ансат кына күңелен ачмаячак иде.

— Юк, мин фельдшерның үзенә күренәм әле, юлда ни булмас, — диде Балкыш һәм, урындыгын җайлап куеп, телевизорга таба борылып утырды. Зиләйлә аңа аркасы белән, өстәл янына урнашты.

Ул җырчы кызларга мөкиббән иде, ахрысы, шушы минутта суырылып экранга кереп китәрдәй булган иде. Әллә анда күрсәтелгән муллык, якты сәхнә, дан кызыктыра, киенгән-ясанган, сикеренгән-боргаланган хатын-кызлар чибәр булып күренә идеме? Балкыш исә Зиләйләне күзәтте. Аңа калса, Мәскәү җырчылары бу кызның кара чәче астыннан күренеп торган колак яфрагына да тормый иде шикелле.

Ничектер ямансу иде. Шаяру килешмәс кебек, ә җитди сүз башларга кыз үзе мөмкинлек бирмәде. Вакыт та сиздерми генә, бик тиз узып китте. Мөнирә кайтып керде дә Балкышның күз кабагын янә кайтарып карады. Чүп кергән иде, дигәненә ышандымы-юкмы, тагын бер тапкыр дару тамызды һәм нәкъ кызыныкы төсле күкрәктән чыккан тавыш белән, иртәгәсен күз врачына күренергә киңәш итте. Аның да йөзе-кыяфәте басынкы, моңсу иде. Балкыш пөхтә итеп җыештырылган бүлмәне, ишек янында чөйдә эленеп торган пальто-курткаларны, клеенка кисәгенә тезеп куйган чип-чиста итеп юылган резин итек, галошларны күздән кичерде. Һәммәсе хатын-кыз әйберләре. Өй эченә дә хуш ис таралган. Ирсез-әтисез йорт иде бу. Әтиләре кая икән соң? Әмма моны сорау килешми иде.

Балкыш рәхмәт әйтте дә саубуллашып чыгып китте.

## 18

— Туганнарыгыз бармы әллә монда? — дип сорады Фидая Балкыштан. Егет, башын сузып, фара белән яктыртылган сикәлтәле юлга төбәлгән килеш, ничектер үзгәреп киткән тавыш белән җавап бирде:

— Медпунктка кереп чыгарга туры килде.

— Нишләдең анда? Мөнирә җыелышта иде бит.

— Кинәт кенә күз чәнчешә башлады. Чүп кергән иде бугай.

— Алдырдыңмы соң?

— Фельдшерның кызы алды, — диде Балкыш.

— Зиләйлә, яшь булса да, андыйга оста ул, — диде Фидая. Аның тавышы йомшап китте, ул фельдшерның кызын бик тә якын күрә иде булса кирәк. — Гел әнисе янында бит, ярдәм итешә, ул эшкә кулы да ятып тора. Әйбәт укый. Институтка керер, врач булыр, дип торабыз.

— Атасы врачмы әллә? — дип, җаен туры китереп сорап куйды Балкыш.

— Атасы... механизатор, — диде ничектер сүрелеп Фидая. Аннары авыр сулап өстәп куйды: — Син аннан атасын сораштырма инде. Ул ягы көйсез аның.

— Эчәме әллә?

— Юк, эчми. Колхозны җигелеп тартып алып баручыларның берсе. Тик болар белән яшәми... Башкага өйләнде.

— Ташлап чыгып киттемени?

— Шулайрак булды шул. Клуб мөдиренә өйләнде.

— Шул авылныкынамы?

— Баллыболынныкына. Аларның тормышын да көйле дип әйтеп булмый. Теге көнне янган йортларның берсе аларныкы иде бит. Хәзер клубта яшәп яталар менә.

— Ә-ә, шулармыни...— диде Балкыш сузып.

Ул район үзәгендә күргәзмә ачылган көнне Зиләйләнең кая барырга белмәгәндәй әйләнгәләп йөргәнен, юлда башын утыргыч артына салып хәсрәткә чумып кайтканын исенә төшерде. Менә нинди яра бар икән аның эчендә, менә нилектән моңлы икән нурлы күзләренең карашы...

— Бер авылда алай яшәү читендер шул, — диде уйланып Балкыш.

— Каләмгөл китик дип үгетли дә, Гыйззетдиннең китәсе килми. Чит җирләрдә, җиде ят арасында яңа тормыш башлап җибәрүләре җиңел түгел бит ул. Ә бәлки, Зиләйләдән ерагаясы да килмидер. Ни дисәң дә, монда күз алдында бит. Каләмгөл безнең авылныкы түгел, тамыры ныкберекмәгән, ул җиңел кузгалыр иде дә бит, Гыйззетдинне куптара алмый. Ул инде такмаклар да чыгарган, бер серләшеп утырганда, миңа да сөйләгәне булды. Такмаклары шундый җиңел, бер ишетүдә истә кала.

Фидая, җиңелчә елмаеп, үзе өчен искә төшергәндәй, яттан сөйләп алды:

Өзелеп әйткән сүзләремне тыңласана, Гыйззәтлем,
Шушы авылга ябышып кына ятмасана, Гыйззәтлем.
Туган җирдәй булмаса да торган җирләр, Гыйззәтлем,
Чын сөюем ул җирләрне оҗмах итәр, Гыйззәтлем.
Уйнап түгел уйлап әйтәм, ишетсәнә, Гыйззәтлем,
Тәвәккәлләп бу авылдан китиксәнә, Гыйззәтлем.

— Гыйззетдин дип түгел, Гыйззәтлем дип кенә эндәшә ул аңа. Гыйшыклары бик кайнар булды, бөтен авылны хәйран калдырды.

— Балалары буй җиткәч тә акылга туймый халык. Шаккатарсың.

— Гыйшык тоту — ут йоту, дигәннәр. Бернишләп булмый.

— Ярый ла үзләре генә ут йотса, башкаларның бәгырен яндыралар бит, — диде Балкыш.

Фидая сүзне үрчетмәде, тынып калды. Ничек кенә аңлатырга тырышсаң да, яшь кеше өлкәнрәкләрнең дә күңелендә кайчакта тыелгысыз сөю хисе кабынуына ышана алмаячак. Хәер, яшьләр генә түгел, күпчелек халык моны аңламый. Аңламый һәм акламый. Гашыйк булдым дип, хатынын, баласын калдырып, икенче хатын янына чыгып киткән ирнең кыланмышларын күпләр азгынлыкка саный, гаепли. Каләмгөлне җыелышларга куеп тикшерергә, халык каршында рисвай итәргә, эшеннән куарга, Гыйззетдиннән беренче хатынына, кызы янына кайтуын таләп итәргә дә күп сорамаслар иде. Мөнирә генә рөхсәт бирми, тегеләргә тел тигерергә кушмый...

Бу өчәүнең — хәер, нигә өчәү генә булсын, балаларны да кушып санаганда, бишәү бит инде... әйе, бишәүнең — язмышы Фидаяның күз алдында, гыйбрәт булып, чияләнеп төйнәлде. Теш белән дә чишәрлек түгел. Тешең сынар, төен тагын да ныграк чияләнер.

Фидая Баллыболын мәктәбенә пионервожатый булып эшкә килгәндә, Мөнирә белән Гыйззетдин бик матур яшәп яталар иде. Икесе дә чибәр, бер-берсенең күзенә генә карап торалар, гөл кебек кыз бала үстерәләр. Авыл хатыннары аларның мәхәббәте турында кызыгып та, көнләшеп тә сөйли иде. Бер класста укыганнар, мәктәптә чакта ук бер-берсен яратышканнар. Егет армиядә чакта кыз медицина училищесында укыган. Аннары өйләнешкәннәр. Тормышлары тәртип-әдәп белән, матур итеп көйгә салынган. Гел шулай яшәрләр кебек иде. Ләкин... Ah, бу гыйшык хәлләре! Һич кирәк түгел чагында никләр генә йөрәккә килеп каба икән ул?

Фидая институтта укып йөргән арада, асыл парның бәхете җимерелгән булып чыкты. Гөлдәй үсеп килгән Зиләйләне дә янгын уты өтеп шиңдергәндәй иткән иде. Фидая башта аны танымады. Класска дәрес бирергә кергәч, башка кайбер балалардан сораган кебек, аның да фамилиясен сорады. Ул торып басты да, турсаеп, карашын партага төбәде. Дәшмәде. Ник? Фамилияңне әйтүнең ни авырлыгы бар? Фидая аптырап калды. Шунда бер шук малай көлеп: «Кыйбатлы кыз ул безнең!» — дип ярып салды. Кызчык кызарынды, тәмам коелып төште.

Моның хикмәтенә Фидая дәрестән соң фатирына кайтып, Наилә апа белән сөйләшкәч кенә төшенде. Гыйззетдин яшьли сөйгән Мөнирәсен ташлап, клуб мөдире булып эшкә килгән балалы хатын Каләмгөлгә өйләнгән икән. Менә сиңа, ишетмәсәң ишет! Зиләйләне дә бөтенләй ташламаган, кирәк-ярагын алып, акча биреп тора. Мөмкинлеге бар, авылда эш хакын аннан күп алган кеше юк. Шуңа күрә Зиләйләне «кыйбатлы кыз» дип үртиләр икән.

— Авылга кертәсе түгел иде ул мөртәт чегән токымын, — дип сукранды Наилә. — Мин менә өемә кертмәдем, чөнки кем икәнен бик яхшы беләм. Фатирда синдә торсын, дип, хуҗалар бик ялынган иде дә, ризалыгымны бирмәдем. Нәсел-ыруы күз буучы бит аның. Сихерләп әллә нишләтеп бетерер, Алла сакласын! Каберең якын булмасын!

Баксаң, бу Каләмгөл «күз буучы» Баһавиның кызы икән. Ул Баһави турында районда төрле мәзәкләр йөри иде. Имеш, беркөнне кемгәдер барып кергән бу, ә анда кызлар утырмага килгән, сәке йөзлегенә

тезелеп, бәйләп-чигеп утыралар икән. «Кызлар, күл ясап, үрдәк йөздереп күрсәтимме?» — дигән бу. Кызларга кызык бит инде, күрсәт тә күрсәт, диләр икән. Шуннан ни күрсеннәр, берзаман идәнгә су керә башлаган. Артканнан-арта, күтәрелә икән бу, аны-моны абайлаганчы, сәке йөзлеген дә күмгән. Кызлар, чыр-чу килешеп, сәкегә менеп басып, итәкләрен күтәргәннәр... Карасалар, ишектән тезелешеп бер оя үрдәк йөзеп кереп килә икән... «Кызлар, мин боларның берсен тотып суйыйм әле, аш пешереп ашарсыз, — ди икән Баһави. — Туктале, булгач-булгач булсын, икесен Аллага тапшырыйк әле, мине дә сыйларсыз». Пычак алып, ике үрдәкне суйган да, мәгез, тазартыгыз, дип, кызларга биреп чыгып киткән бу. Шуннан, ул чыгып киткәч, күзләрен ачып карасалар... Су да юк, үрдәк тә юк, кызлар сәкедә итәкләрен күтәреп басып торалар, икесенең кулында галош, ә галошларның башы киселгән...

Дөнья күргән кешеләр, Баһавида гипноз сәләте бар, дип сөйли, каядыр читтә ул, концертларда катнашып, фокуслар күрсәтеп тә йөргән, имеш. Менә шундый токымнан яратылган, шундый гаиләдә тәрбияләнгән кыз иде ул Каләмгөл. Үзе дә бәләкәйдән чытлык булган, гармун уйнарга, мандолина чиертергә өйрәнгән, авылга килгән чегәннәрдән җыр-биюләр отып алырга маһир икән, имеш. Бервакыт чегәннәр аны үзләре белән алып китәргә дә үгетләгәннәр.

Аңлашыла ки, мәктәпне тәмамлагач, культура-агарту училищесына укырга кергән ул. Укуын тәмамлар алдыннан, гастрольгә килгән ансамбльдәге бер артист егеткә гашыйк булып, соңгы имтиханын ничек кирәк алай тапшырганнан соң, шуңа ияреп китеп тә барган. Алар белән бергә җырлап-биеп, концертлар куеп шактый йөргән, кызы туган. Ләкин бөтенләйгә берегеп китә алмаган, күрәсең, сигез яшьлек кызын ияртеп, Суташка кайтып төшкән. Район культура бүлегеннән аны Баллыболынга клуб мөдире итеп җибәргәннәр. Нәкъ шул җәйне Ниса клуб мөдире Җәмитне эшеннән кудырткан икән. «Гармун шыңгырдатудан бүтәнне белмисең, бөтен кеше чөгендердә чакта клубыңда бикләнеп ятасың», — дип бәйләнгән. Алай дигәненә үпкәләп тә булмый, чөнки чөгендер тәпкеләргә бөтен халык йөри: бухгалтеры да, укытучысы да, фельдшеры да. Басуны җан башына кишәрлекләп бүлеп эшкәрттермәсәң, планны үтим, уңыш алам димә!

Каләмгөлнең авылга ничек-ничек итеп килеп кергәнен Фидаяга бер мәзәк итеп сөйләгәннәр иде. Урак өсте булган бу, кичкырын эштән кайтып килгән халык клуб турысында туктап калган. Ә анда тамаша, ди. Болдырда кара чәчен иңенә туздырып салган бер яшь хатын мандолина чиертеп утыра, шундый ук бөдрә чәченә кызыл бант бәйләгән кыз бала тузан туздырып биеп ята икән. Баксаң, клубка яңа мөдир килгән икән.

— Бөтенебезне шаккатырды, — дип сөйләде Наилә апа. — Авызларыбызны ачып карадык та каттык. Кешене әвәрә итәргә бабасыннан өйрәнгәндер шул. Анысы гына җитмәсә, чегәннәргә ияреп йөргәндә остаргандыр.

Наилә апа ул йөргән концерт бригадасын чегән таборы дип кенә белә.

— Кыланмышлары кырга сыймады. Мин клубны җыештыра идем әле ул чакта. Тәрәзә төбендәге чиләккә бәйләнде, идән юган чиләгеңне ник монда куясың, ди. Мин әйтәм, идән чиләге түгел ул, эчә торган су тотабыз без анда. Бу сиңа, ди, сыер абзарымы әллә? Хәзерге заманда, ди, сыерларга да махсус эчергеч куялар. Монда, ди, самавыр булырга тиеш! Һич булмаса, кранлы матур бак торырга тиеш. Тәрәзәләргә пәрдә эләргә кирәк, кино күрсәтергә яңа экран кирәк, ди... Аның гына күзе бар да, ул гына күрә диярсең. Матурны да яхшыны аны барыбыз да ярата. Акча бирүчесе генә юк.

— Алай да пәрдәләрне элгән бит, — диде ул чакта Фидая. Ул клубны күреп чыккан иде инде. — Экран да яңа, кранлы су багы да ялтырап тора.

— Яңа кеше булгач, бирделәр инде. Районнан да, колхоздан да. Тасыраеп бер караса, җаныңны актара бит ул. Нәчәлникләрнең күзен бугандыр...

Наилә апа Каләмгөлне Мөнирәнең гаиләсен таркаткан өчен яратмый иде.

Ни генә булмасын, авыл халкы өчен яңа мөдирнең кыланмышлары сәер дә, кызык та тоелган. Клуб янына элеп куйган беренче игъланы да такмаклап язылган булган аның:

> Шимбә көнне концерт була, гафил булып калмагыз,
> Җыелып килсен өлкәнегез, һәммә бала-чагагыз.

Концерт дигәнен, урып-җыюга килгән студентлар, өлкән класс укучылары белән бергә, ике-өч көн эчендә оештырып та өлгергән бу. Егетләр-кызлар магнитофон уйнаганга җырлагандай итеп авызын ачып боргалана, бала-чага чүпрәктән-кәгазьдән аллы-гөлле киенеп бөтерелә, ди. Ләкин иң шаккатырганы Каләмгөлнең чегәнчә биюе булган. «Ир-атның күзе лампочка булган иде инде. Аракы эчеп исерүләре бер якта торсын», — диде Наилә апа.

Башкалар ничектер, ә менә Гыйззетдин шул исерүдән айный алмаган, күрәсең. Клуб — зур хуҗалык, анда кирәк-яракның исәбе-хисабы юк, Гыйззетдиннең исә кулы оста, килергә, ярдәм итешергә форсаты

чыгып кына тора. Авыл кешесе аның ишене тиз күрә. «Клубның яңа мөдире Гыйззетдинне сихерләгән, сөйдергеч эчергән» кебек сүзләр йөри башлый.

Дөрес, бераздан Каләмгөл, гайбәттән куркып, Гыйззетдинне читтәрәк тотарга тырыша, тегене-моны төзәтергә кирәк булганда, башка берәүне чакырып тора. Авыл хатыннарына бусы да ярамый: «Гыйззетдиннең канын кыздыру өчен юри шулай кылана, — диләр. — Сихерләп сөйдерә дә читкә тибәреп көйдерә».

Чыннан да, янган-көйгән Гыйззетдин, ике-өч ай эчендә ябыгып киткән, төс ташлаган, имеш. Тәмам акылын җуйган бу, нишләгәнен үзе белми башлаган. Беркөнне кичкә таба хатыннар кое янында сөйләшеп тора икән. Ул чакта авылда колонкалар юк, суны коедан алалар иде әле. Араларында Каләмгөл дә булган боларның. Урамнан Гыйззетдин узып бара икән, туктап, эчәргә су сораган. Шунда бер төртмә теллесе шаяртасы иткән: «Хәзерге ирләр коедан суны үзләре тартып алмый, хатыннар чыгарганны гына чөмерә, — ди икән. — Яратам да яратам, синең өчен җаным фида, дигән булалар тагын. Менә, мәсәлән, Каләмгөл берәрсенә, шушы коеның суын төбенә үзең төшеп алып мен, дисә, берсе дә төшми. Билләһи дип әйтәм, төшми!» Хатыннар шаркылдап көләргә тотынган. Ни уйлагандыр Гыйззетдин, әллә уйлап та өлгермәгәнме, кызулыгы белән ни кылганын үзе дә аңлап җиткермәгәндер, мөгаен, сиртмә бавына тотынган да коега сикергән бу. Сизми дә калганнар.

Ах иткәннәр, ух иткәннәр, көчкә тартып чыгарганнар моны. Аның әллә ни куркынычы да булмагандыр да, әмма даны ни тора! Кайсыдыр, суны пычраттың, юньсез, дип, сыртына көянтә белән тамызган. Таштимерова, бу хакта ишетүгә, районнан милиция чакырган. Гыйззетдинне хулиганлыгы өчен унбиш тәүлеккә утыртып куйганнар. Янгын сүндерүчеләр, килеп, коеның суын тазартканнар.

Башка берәү булса, мондый гына шуклыгы өчен унбиш көн ябып тотмаслар иде, билгеле. Ә Гыйззетдингә, оста куллы булуы аркасында, җәзаның катысы бирелгән. Ул болай килеп чыккан: милиция аны, исерекме-аекмы икәнен ачыклау өчен, район хастаханәсенә алып барган. Ә анда Гыйззетдинне беләләр. Хастаханәдә эшлисе эшләр һәрвакыттагыча күп, акча исә юк икән, ә унбиш көнгә ябылганнарны бушлай эшләтәләр бит инде. Баш табиб милиция начальнигына, сез бу кешене озаграк ябып тотыгыз әле, көндез эшкә безгә алып килерсез, дигән. Табиб сүзен кем тыңламый инде! Ул көннәрне хастаханә пешекчеләре Гыйззетдингә дигән ашны аерым пешерде, дип сөйләделәр соңыннан. Ә Гыйззетдиннең хатыны фельдшер Мөнирә анда гел барып тора бит.

Кыскасы, гайбәт авылда гына түгел, бөтен районга таралган һәм гөл кебек гаилә өстенә кырау булып төшкән. Йорт эчендәниләр булгандыр, алар чүпне читкә чыгара торганнардан түгел, әмма шуннан соң, озак та үтми, Мөнирә, кызын алып, башка авылга эшләргә китеп барган. Гыйззетдин өендә ялгызы торып калган.

Алай да Каләмгөл аны шактый озак ялындырган, дип сөйлиләр. Алар берничә ай узгач кына кавышканнар. Гайбәте тынар, күрше-күлән белән мөнәсәбәтләр дә көйләнер иде, мөгаен, әгәр дә Мөнирә бер елдан кире әйләнеп кайтмаган булса. Дөрес, җае да туры килгән үзе, Мөнирә урынында эшләгән фельдшер кыз, кияүгә чыгып, авылдан китеп барган. Фатиры-ние белән яңа медпункт та салып куйганнар икән, эш урыны да, торак та бушаган. Кер дә утыр, күнеккән урыныңда рәхәтләнеп эшлә генә. Алай да Мөнирәгә бер киткәч кире кайтмау яхшырак булмас иде микән?

...Фидая җыелышта Мөнирәнең ничек сагышланып утырганын күз алдына китерде. Ир бирмәк — җан бирмәк, диләр, башка берәү булса, йөрәгендә нәфрәт уты гына янар иде дә, үч алу теләге генә кайнар иде. Ә Мөнирәнең йөзендә үчлек тә, хөсетлек тә юк, фәкать сызлану һәм сагыш кына көйри төсле. Яратуы сүнмәгән-сүрелмәгән, ә бәлки көчәйгәндер генә, күрәсең...

Күп кешегә бу гаҗәп тоелса да, Фидая Мөнирәнең хисләрен аңлый иде шикелле.

# 19

Әйе, һәрбер йөрәк үзенчә ярата, сөйгәне белән үзенчә кавыша. Сөю белән кавышу гел бергә генә килеп тә тормый. Мисалга, Давытны Фазиләгә кайнар мәхәббәт бәйләде, дип әйтеп булыр иде микән? Ни генә дисәң дә, Давыт, аны үзенә каратыр өчен, авыл хатыннары күз алдында коега сикермәс иде. Һич юк. Алай да бу ир турында, хатыны белән санашмый, гаиләсен кайгыртмый, дип әйтү дөрес булмас иде.

Баллыболында булып узган җыелыштан соң, «уазигы» белән караңгы юлдан лесхозга кайтканда, ул җайга салынган яшәеш тәртибенең үзгәрәчәге турында, хатыны хакында уйлады. Председатель булып сайлангач, кайда, нинди йортта яшәячәкләре турында алдан ныклап уйланмаган икән. Бөтенесе бигрәк кинәт килеп чыкты да капыл гына хәл ителеп куйды шул. Фазилә кеше өстендә яшәргә риза булырмы? Ай-һай! Яңа йорт кайчан төзелер бит әле. Инде йөреп эшлим дисәң, көннең көнендә иртәнге сәгать бишкә илле чакрымнан килеп йөрүләре җиңел булмас... Димәк, алда аерым-суырым яшәү тора дигән сүз. Аның

күпмегә сузылачагын да ачык кына әйтеп булмый. Хатынны юмаларга, ничек тә көйләргә кирәк булачак. Яңа урында шундый зур эшкә тотынганда, өйдә җан җылысын киметү һич тә ярамас. Аннары тагын шунысы: Фазиләнең эш урыны да абруйлы: лесхозның экономисты ул. Баллыболында да аңа шундый җайлы эш табып булыр микән?

Моңарчы Давыт хатынын үз җаена бора белә иде белүен. Ир баш булса да, хатын муен, дигәнне алга куеп, ул кушкан тарафка гына карап яшәү егет эше түгел дип саный иде ул. Чын егетнең горур башы хатын-кыз алдында Сигезенче март көнне кулын үпкәндә генә иелә, ә тормыш иткәндә, ул калкып торырга тиеш. Бу шулай булсын өчен, гомер юлдашың булачак кызны танышкан көннән үз ягыңа борырга кирәк иде.

Давыт нәкъ менә шулай итте дә. Фазиләне ул студент яшьләрнең бию кичәсендә бер күрүдә ошатты. Дөрес, ул ялгыз түгел, таза гәүдәле, түгәрәк йөзле, үз-үзеннән бик канәгать кыяфәтле бер егет белән иде. Давыт аларның парлашып биегәнен шактый вакыт читтән генә күзәтеп торды. Адымнарыннан, кыланмышларыннан, кызның парына бик үк елышмыйча, башын артка ташлап, читкә карап биюеннән, күзгә бик ташланмый, әмма күңел сизенә торган ваклыклардан ул бу парның бер-берсенә бик үк берегеп җитмәгәнен аңлап алды. Араларына җил үткәреп булыр кебек иде. Һәм Давыт, тәкәббер егетнең залдан чыгып киткән вакытын туры китереп, кызга таба юнәлде. Озын буйлы, нечкә сынлы, кара чәчен баш артына бик килешле итеп төйнәп куйган кыз бу минутта язмышын хәл итәчәк егетнең якынлашканын белми, шуңа күрә эче пошкан кыяфәт белән читкә карап тора иде. Әгәр теге таза егет күңеленә якын булса, ул башка берәү белән биергә чыкмаячак иде, билгеле. Әмма Давытның сизенүе дөрес икән, кыз аны кире какмады, тыенкы гына көлемсерәп, җиңел кулын иңбашына салды. Алар, беренче хәрәкәтләреннән үк, адымнарының бик тәңгәл килгәнен тоеп алдылар, вальс көенә җиңел генә зал тирәли бөтерелеп киттеләр. Музыка тәмамланганда, теге егет кире кереп урынына баскан иде, әмма Давыт кызны аның янына озатып куймады, озын, салкынча бармакларын кайнар учына кысып, янында тотып калды. Алар тагын берничә тапкыр биеделәр. Ахырга таба кыз:

— Миңа китәргә вакыт, — диде.

— Бергә китәбез.

— Минем озатучым бар.

— Бар, әлбәттә, — диде Давыт. — Мин ул. Мин озатып куям сине.

Менә шулай. Беренче күрүдә үк үз сүзен үткәрде Давыт. Һәм дөрес эшләде.

Тормышның төп мәсьәләләрен үзе хәл кыла, хаталанса, үкенүнең ачы шулпасын үзе генә чөмерә, хатын сүзен тыңлап кына хур булдым дигәнне кешегә сөйләү түгел, үз башына да китерми ул.

Искәндәров аны чакырып алып «Үзәк» колхозына җитәкче булырга тәкъдим иткәч тә, иң элек үз акылын җигеп, ныклап уйларга кирәклеген яхшы аңлады Давыт. Абзый: «Ике көннән Казанга барырга кирәк», — дигәч кенә, күзләрен хәйләкәр кысып:

— Хатын ничек карар бит әле, аның белән киңәшмәгән, — дип куйды.

— Әллә кая китә алмас, энә кайда, җеп шунда, — диде Искәндәров. — Бер хатыныңа гына баш була аласыңдыр. Колхозда йөзләгәненә үз сүзеңне үткәрергә кирәк булачак әле.

— Үз хатының читләрнең йөзеннән уздыра ул!

Ләкин Искәндәровны алдый алмассың, ул Давытны үтәли күрә иде.

Хәлбуки Давытның шаяруга сабышып әйткән сүзләрендә бөтенләй үк дөреслек юк түгел иде. Фазилә бер дә җебеп төшкәннәрдән түгел, «айт» дигәнгә «тайт» дип кенә тормый. Давыт кайтып, уратып-нитеп тормыйча, гадәтенчә турыдан-туры Баллыболынга эшкә бару турында сүз кузгаткач, Фазиләнең кашы-күзе җимерелде. Ул, тавышын нык кына күтәреп, ризасызлыгын белдерде. Бу ниткән санашмау? Төбең-тамырың белән куптарылып күчеп китүне шулай капыл кына хәл итәләр димени? Мондый очракта район җитәкчеләре, Фазиләне дә чакырып алып, әйбәтләп сөйләшсәләр артык булмас иде!

Давыт аны бүлдермәде, пар казанының бушаганын көтте. Хатыны әйтәсен әйтеп бетереп, тын алырга туктагач, тыныч кына:

— Алдан кайгырмыйк әле, — диде. — Казанга барып, андагыларга күренәсе бар. Бәлки, яратмаслар, кире борып җибәрерләр. Аларны белеп булмый.

Монысы тагын Фазиләгә ошамады.

— Аларга кем кирәк тагын? — диде кызып. — Колхоз җитәкчеләре булып та мөгезле кешеләр эшләми. Ул Таштимерованы ташка үлчим! Район җитәкчеләре арасында да синә җиткәне сирәк.

Фазиләнең ышануынча, Давыт бервакыт, һичшиксез, Искәндәров урынына менеп утырачак иде. Тик анда күтәрелер өчен нишләп әле Баллыболыннан урап йөрергә? Туп-туры Суташның үзенә барып, берәр югары урынга урнашып булмыймыни?

Хатын сукранудан туктамады, ә үзе ирен дәрәҗәле урынга әзерләп озатуның хәстәрен күрә башлады. Олы начальниклар янында авыл гыйбаты булып күренмәсен, үзләреннән кәттә булсын! Фазилә бу якны бик кайгырта, лесхозга олы кунаклар килгәндәме, үзе берәр кая баргандамы, киеп чыгып китәргә ире өчен һәммәсе әзер: ак күлмәк, кара костюм, ялтырап торган ботинкалар, чиста оекбашлар, затлы одеколон, ап-ак кулъяулык — барысы да һәрвакыт тәртиптә.

Мондый хатын — олы бер хәзинә, андый байлык миллионерларның да күбесендә юк. Чөнки миллионер булуның рәхәте, кесәнең калын булуыннан бигрәк, тормышның ваклыкларыннан азат булу дигән сүз ул. Ә Давыт ваклыклардан өстен, тәрбияле-караулы. Урманда яшәсә дә, йөреп тора, дөнья хәлләрен белеп тора. Мәскәүдә дә булгалый, ялтыравык журналларны да актаргалый. Затлы әйберләрнең кыйммәтен, кадерен аңлый, бүгенге көндә нинди сәгатьләрнең, радиоалгычларның модада икәнлеген яхшы белә. Дөрес, галстук каптырмасы, запонкалар мәсьәләсендә чит ил байларыннан уздырып булмас, әмма пөхтәлек дигәндә калышмаска тырыша, һәм бу мәсьәләдә Фазилә аңа теләктәш иде.

Казанга баргандагысын әйткән дә юк, Баллыболынга җыелышка озатканда да, Фазилә аның бөтен кыяфәтен энә күзеннән үткәрде.

— Авыл халкының күзе үткен, тырнак астыннан кер эзләргә генә куш син аларга, — диде.

Җыелыш алдыннан сәхнә артында чәчләрне төзәткәләп, пинжәк итәкләрен тарткалап торганда, Искәндәров та Давытка баштанаяк сынап карады. Аннары, канәгать елмаеп, янәшәдә басып торган берничә авыл кешесенә борылды:

— Егетнең шәбен алып килдем мин сезгә, шулай бит, ә? — диде. — Татарлар менә шушындый алар, дип, дөньяның теләсә кайсы җирендә бастырып күрсәтеп була. Кадерен белегез! Алга таба колхозыгыз да башкаларга үрнәк булсын!

Аның бу сүзләрен исенә төшереп, Давыт үзалдына елмаеп куйды. «Тәмам күргәзмә әсбап ясады миннән! — дип уйлады. — Фазиләгә әйтергә кирәк әле, күңеле булсын».

Кайтып кергәч, ул сүзне шул шаярудан башлады.

...Иртән сәгать алтыда Баллыболынга килеп җиткән Давыт ап-ак күлмәк, бер җыерчыксыз кара костюм кигән, йөзе-кыяфәте әле генә санаторийдан кайткандай ялтырап тора иде.

Әле беренче тапкыр булганга, нәрәтне Әхсән Вәлишин бирде, Давыт, аның белән янәшә өстәл артына утырып, үзенә кирәкне калын куен дәфтәренә язгалап барды. Колхоз, башка хуҗалыклар кебек үк, муеннан бурычта икән. Дөрес, анысы барлык хуҗалыклар өчен хас нәрсә, чөнки хөкүмәткә тапшырган икмәк һәм тапшырылачак чөгендерләр өчен исәп-хисап ел ахырында ясалачак. Ә хәзергә сөт, ит өчен түләнергә тиешле акчаларга гына исәп тотарга кала. Бүген дә ит комбинатына ике машина белән дуңгызлар озатырга булдылар.

Иң ахырдан, ишекне каерып ачып, таза бәдәнле, кызыл чырайлы бер кеше килеп керде.

Сәлам бирде дә, чакырганны да көтмичә, иркенләп урындыкка утырды.

— Яңа хуҗаның колагына баштан ук киртләп куясы бик кирәкле бер мәсьәлә бар бит әле бездә, — диде ул, карлыккан тавыш белән. — Аны җыелышта да сөйләмәделәр, Әхсән, син дә онытып утырасыңдыр, мөгаен. Бездән эш кенә таләп итәләр. Атыңны ничек җигәсең, дип сораган кеше дә юк.

— Скотник бу безнең, Ишмуллин Фаяз, — диде Вәлишин Давытка.

— Скотникларга ат җигәр өчен дә ярдәм кирәкмени? — дип сорады Давыт.

— Ә сбруясын каян алырга? Складта ни камыт, ни ыңгырчак, ни дуга юк!

— Аның ише нәрсә дефицит бит ул! — дип, чыраен сытты Вәлишин. — Табып кара син аларны. Заводлар ясап чыгара торган әйбер түгел. Моңарчы һәр тапканны иң элек сиңа биреп бардык лабаса...

Башка авыллардан аермалы буларак, биредәге халык ат җанлы булып чыкты.

Аннары Наиләгә чәй эчәргә киттеләр. Табын тирәсендә бөтерелеп йөргән хуҗабикәнең теле дә тик тормады. Сүз арасында ул да яңа хуҗаның кыяфәтен мактап алды:

— Хатының бик әйбәттер, мөгаен, сиңа кер кундырмый икән. Авыл халкы андыйны бик тикшерә бит ул. Ул яктан Нисаны яратып бетермәделәр. Гомуми эш өчен янды-көйде, үземне карыйм-тәрбиялим димәде. Казанга-фәлән барасы булса, авыл сәвите персидәтеле Нәзифә үз күлмәген биреп тора иде. Матур киенүне азгынлыкка санады Нисабыз, авыр туфрагы җиңел булсын.

— Үлгәнме әллә? — дип куркып китте Давыт.

— Тәне исән дә бит, абруе үлде шул инде, — диде Наилә авыр сулап. — Безгә шул гыйбрәт итеп сөйләргә генә калды.

Шулай итеп, яңа хуҗаның салпы ягына салам кыстырылды, искесенең җитешмәгән яклары искә алынды. Әмма, табыннан кузгалгач, Наилә, Давытны тагын бер тапкыр күздән кичерде дә, өйалдыннан иске кожанка алып керде.

— Сыярсың микән инде син моңа, — диде, бер кожанкага, бер Давытка карап. — Минневафа мәрхүм дә гәүдәле кеше иде гәүдәлесен. Җилкәсе синеке чама. Кыскарак булса инде. Мә, киеп кара әле!

Давытның аптыраганын күреп:

— Басулар, фермалар буйлап бу матур киемең белән йөри алмассың бит инде, — диде. — Кичкә элә-танагы калмас. Эшләпәңне дә монда калдырып тор. Берәр картуз табарбыз. Минневафадан калган бардыр әле.

Давыт Минневафаның искеләрен киюдән көчкә котылды, алай да олы резин итекләрне машинага куярга рөхсәт итте, чөнки күп җирдә ялтыравык ботинка белән аяк басып булмаячагын Вәлишин да кисәтеп тора, үзе дә белә иде.

Чыннан да, ферма янына барып туктагач, машинадан төшкәнче, ботинкаларны салып, итекләрне кияргә туры килде. Саз тездән иде. Тигезле-тигезсез акшарланган озын корылма янына якынлашуга, аларны сыер савучылар, терлек караучылар уратып алды. Автоэчергечләр ватылган, төзәтергә запчастьлар юк, тиресне кул белән чыгаралар икән.

Склад ишеге төбенә онлы капчыклар өелгән иде.

— Болар ник монда ята?

— Һәр савучыга тиешлесен үлчәп чыгарып куйдык, — диде ферма мөдире Хәбир.— Моннан үзләре алып китәләр.

— Күтәреп ташыйлармы әллә?

— Күтәрми ташып булмый бит инде!

— Нишләп скотниклар ат белән генә таратмый? Сыртлары кәҗүнниме әллә?

— Он бит ул кул тигән саен кими, үзләренә дигәнне үзләре аласы килә, — дип аңлатты Вәлишин.

Абзарларның эчен карап чыккач, күңел тагын да төште. Ишеге өстенә «Савымны арттыруга ирешик!» дигән лозунг эленгән терлекчеләр йортына җыелып сөйләшеп алдылар. Сыер савучыларның барысы да илледән узган, таушалган кыяфәтле, калын бәдәнле, моңсу карашлы апалар икән. Хәлләрегез ничек, дип сораганга, зарланып түгел, ничектер җанланышып җавап бирделәр:

— И, хәзер эш җиңеләйде инде! — диештеләр. — Элек кул белән сава идек, суны көянтә-чиләк белән ташый идек.

Гүяки яңа җитәкче каршында үзләрен ни өчендер гаепле саныйлар, ферманың җитешмәгән җирләре өчен аннан гафу сорыйлар иде. Аларның күндәмлеге, сабырлыгы күңелдә ризасызлык тудырды. Давыт үз-үзен шушы апалар күзе белән күргәндәй булды, чисталыгы-пөхтәлеге бу мохиткә ятышмаганын тойды.

Сораша торгач, фермада ничә баш сыер, ничә тана барлыгын төгәл генә белмәгәнлекләре ачыкланды.

— Ничек инде сез үзегез караган малларның баш санын белмисез? — дип гаҗәпләнеп сорады Давыт.

— Көн саен үзгәреп тора бит ул. Кайсын, бозаулагач, группадан группага күчерәләр, кайсын иткә озаталар...

Бу җавапта салкын битарафлык ярылып ята иде.

— Бүген ничек булса, шул кадәресен санап куярга кирәк булыр. Ревкомиссиягә кушыйкмы соң әллә? — диде аптырап Давыт.

Һәм, куен дәфтәрен чыгарып: «Бүген үк терлекләрнең төгәл исәбен алырга!» — дип язып та куйды.

Аннары Вәлишин белән бергә басуларны карарга киттеләр. Хуҗалыкның җирләре иркен, тигез, офыкка кадәр җәйрәп ята. Нинди байлык, хәзинә! Биләп ал шушы сахраларны, хуҗа бул, бае, рәхәт яшә!

Ләкин Давыт яхшы белә: бу җирләр кәгазьдә генә «Үзәк» колхозының биләмәләре» дип язылган. Асылда, авыл кешеләре дә, үзара сөйләшкәндә «хуҗа» дип аталып йөртелә торган җитәкче дә бу җирләрнең чын хуҗасы түгел. Алар һәммәсе фәкать тир түгүчеләр, бил бөгеп эшләүчеләр генә. Нишләргә кирәген аларга өстән күрсәтеп торалар, теләсәләр кукуруз чәчтерәләр, теләсәләр рапс игәргә боерык бирәләр... Җыелган уңышны элеваторга, шикәр заводына илтеп тапшырырга боералар да хакын үзләре куйганча түлиләр... яки, бурычыгыз күп иде, дип, акчасын бөтенләй бирмиләр.

Басу киңлекләре уртасында басып торган Давыт, иркен сулыш аласы урында, җилкәсенә ифрат зур авырлык төшкәнен тойды. Анда-санда күз күремен чикләп торган озын, тар агачлыкларга карап: «Урманнарны күбрәк утыртасы иде», — дип уйлап куйды. Әмма бу эш белән ныгытып шөгыльләнергә аның вакыты да, көче дә җитмәячәк иде.

Көн сүрән булса да, өстән явып тормый, халык чөгендер кырында мәш килә иде. Комбайн актарып ташлаган җирдән чөгендерне җыеп, яфрагын кисеп, өемнәргә өяләр. Пычрак, авыр хезмәт, очы-кырые күренми. Чөгендерне аны җир каткач, кар төшкәч актарып алган чаклар да була. Биредә дә күпчелек өлкән яшьтәге хатыннар иде.

Аннары мехдворга керделәр, механизаторларның тракторларның искелеге, запчастьлар кытлыгы турындагы зарын тыңладылар.

Иң ахырда авыл читенә, иңкүлеккә салынган биш таш йорт янына сугылып чыктылар. Соңгы яңгырлардан соң куерып күтәрелгән яшел чирәмлектәге бу ак йортлар читтән караганда яктырып, күңелгә ямь биреп тора иде. Аларга илтә торган юл да, җир өстеннән генә салынган булса да, изелмәгән, бозылмаган икән. Тик яннарына ук барып җитеп булмады — тирән, озын канау юлны кисте. Машинадан төшеп су тулы чокыр аркылы сикереп чыккач, кәеф кырыла башлады. Якындагы йортның ихатасын койма белән әйләндереп ала башлаган булганнар да, ярты юлда калдырып китеп барганнар. Кыйшайган баганалар гына тырпаеп тора да, анда-санда күгәргән такталар аунап ята.

Йортның эче тагын да котсызрак булып чыкты. Җимерелгән мич, актарылган идән такталары, тутыккан торбалар. Аш бүлмәсенең ишеген, такта түгелме дип белер өчендер инде, пычак белән каезлаганнар. Ишек фанердан гына корыштырылган икән, эченнән идәнгә пычкы чүбе коелган. И, ясап та карыйлар инде бездәге әйберләрне! Тырнак белән чиртсәң, таралырга тора...

— Яшь гаиләләр өчен дип салган идек тә, тормадылар, чыгып качтылар, — диде Вәлишин. — Балалары чирдән арынмады. Мөнирә әйтә, өй дымлы булганга, ди.

Чыннан да, идәннең куптарылган төшеннән су күренеп тора иде.

— Су чыгасын төзер алдыннан белмәгәннәрмени? Ни уйлаганнар? — дип сорады Давыт.

— Кем белә аларның ни уйлаганын. Казаннан да килеп тикшереп йөрделәр үзләре. Проектны да анда расладылар.

— Ә сез ни карадыгыз? — дип сорады Давыт, үзеннән шактый түбән Вәлишинга өстән карап.

— Мин ул чакта мәктәптә эшли идем бит әле. Аннары аны авыл кешесенә кем күрсәтеп торсын...

Ул, Давытның йөзендә ризасызлык галәмәтләре күреп, аңлатырга тиеш тапты:

— Сугарулы җирләр якын бит монда, — диде. — Шуны исәпкә алып бетермәгәннәрдер. Авылның бу ягында яшәүчеләр дә зарлана, базга су төшә, диләр. Ындырларына камыш үсә башлаган. Югыйсә, генеральный план буенча, бөтен авылны шушы якка күчереп утыртасылар иде.

— Кемнәр?

Вәлишин югалып калды, Давытка мөлдерәп карады. Чыннан да, кемнәр? Анысы билгесез. Тик кем генә булмасын, монда яшисе кешеләр түгел. Авыл халкының исә үз акылы, үз планы булган. Моннан ничәдер гасыр килеп утырган бабайлар йортларын калкурак урынга салганнар. Ул чакта, күрәсең, читтән килеп, генеральный планнар сызып бирүче булмагандыр.

Давыт басу ягына борылып карады.

— Ә бу якта кайдан уза безнең ызан?

— Әнә теге полосадан, — дип, еракта күгелҗемләнеп торган агачлыкка ымлады Вәлишин.

— Каенлыкмы соң ул?

— Шайтан белсен! Андагы агачлар корып беткән инде. Басуларга агуны самолеттан чамасыз коялар бит. Шуның зыяны тигән, диләр.

...Төш турында Наилә апаларга әйләнеп кайтканда, Давытның кыяфәте шактый үзгәргән — костюмы таушалган, чырае караңгыланган иде.

Кичен идарәгә килгәч, бүлмәсенә кергәндә ярым-караңгы коридорда тәмәке пыскытып торган алты-җиде ир-ат арасыннан узарга туры килде. Борынга хәмер исе бәрелде, колакка «Хуҗалар килә дә китә, без генә һаман монда» дигән сүзләр чалынды.

Эчкә кергәч, иң беренче шул мәгълүм булды: иртәнге нәрәт буенча ит комбинатына дуңгызлар озатканнар иде. Кабул итмәгәннәр, ит комбинатының планы тулган икән. Чучкаларны, машинада йөз илле чакрым сәяхәт кылдырып, кире алып кайтырга туры килгән. Һәркайсы ким дигәндә кило ярым авырлыгын югалткан, ярый әле үлмәгәннәр.

Инде моның ачысын йотып та бетереп булмады, Гаделша карт, килеп кереп, бик белдекле кыяфәт белән акыл сатып, эчне пошырырга кереште:

— Быел җир иртә катырыр сыман тоела әле. Моннан тугызмы-унмы ел элек тә шулай булган иде. Синтәбердә тотынды коярга, тотынды коярга. Шул койган көйгә үктәбер уртасында катырып та җибәрде. Балта белән ватып алдык чөгендерне. Балта белән!

Аның сүзен телефон бүлдерде.

— Карале, — диде авыл хуҗалыгы мөдире Сәлахов, көр тавышы белән, — сез анда нишләп савымны киметтегез? Кичәгедән ярты килога ким дип сводка биргәнсез. Комиссия җибәрикме әллә?

— Туктагыз әле, баш-күз алырга ирек бирегез, — диде Давыт ачынып.

Гаделша карт ферма малын санарга бухгалтериядән өч кызны җибәргән булган икән. Алар килеп керде. Тоташ кына санап чыкканнар, сыерын-танасын аерып исәпли алмаганнар, чөнки танымаганнар.

— Сез нәрсә, сыерны танадан аермыйсызмы әллә?

Кызлар, сулыш алудан да куркып, аңа текәлделәр.

— Сыер ул бала тапкан хатын төсле була, ә тана кызлар кебек!

Давытның бу сүзләреннән кызларның күзе шар булды, йөзләре кызарынып чыкты. Берсе, яшьрәге, еламсырый ук башлады бугай.

«Боларга каты бәрелергә ярамый, сылтау итеп, авылдан чыгып сызу ягын карарлар», — дип уйлап куйды Давыт. Һәм, тавышын йомшарта төшеп:

— Алайса, үзегез генә булдыра алмасагыз, Гаделша абый ярдәм итәр, — диде. — Иртәгә аның белән бергә барырсыз.

Ни гаҗәптер, башка бөтен җирдә гел дөреслекне юллый торган карт бу юлы кәҗәләп алды:

— Ник кирәк аларның санын белү? — диде гаҗәпләнеп. — Ниса махсус бөтенесен бергә болгатып тотарга куша иде. Алай-болай районнан берәрсе килеп санарга тотынса, очына чыгарлык булмасын, дия иде. Бухгалтерия кәгазендәгедән унбиш-егермегә артык сыерың булмаса, савым планын ничек тутырмак кирәк?

Ул иртәдә бу сүзнең очына чыгып булмады, бүлдерделәр. Көн эчендә ниләр эшләнгәнен барлап, йомыш белән килгәннәрне тыңлап бетергәч, алар Вәлишин белән тагын икәүдән-икәү калдылар.

— Таштимерова халыкны камчы белән ярып эшләтә дигән сүз йөри иде, хакмы? — дип сорады Давыт.

— Мир теленә керсә, берне биш итәләр инде, — диде Вәлишин өнәмичә. — Һәммәсе дә Гыйззетдин кебек булса, Ниса да сандугачтай сайрап торыр, теленнән бал коелыр иде! Эшлисе килми бит халыкның, күңел биреп тырышканы бармак белән генә санарлык! Хуҗа кеше дә бөтенесенең башыннан сыйпап кына тора алмый, катырак бәрелгән чаклары да булгандыр. Үзе өчен тырышмады, бар булган көчен гомуми эшкә бирде. Кырыкка ярылырдай чаклары булды, рәхмәт әйтүче генә юк иде.

«Мин ничек чыдармын икән бу хикмәткә? — дип уйлады Давыт. — Юкка риза булдым бугай, юкка. Монда председатель булырмын дигән уйның ике ятып бер төшемә дә кергәне юк иде, кем башына килгән дә, кем монда мине тәкъдим иткән диген...»

Моңа төп сәбәпче Нурхановадыр дигән уй аның үзенең башына да килмәде.

# 20

Яшь председательнең беренче эш көнендә Фидая Баллыболынга бармады. Гәрчә, «Үзәк» колхозына шефлык итәргә беркетелгән җитәкче буларак, баруы бик табигый булыр иде. Авылны, халыкны яхшы белә, файдалы киңәш биреп куяр иде, бәлки.

Ләкин ул бармады, чөнки... чакыручы булмады. Гаяров аны кирәксенмәде...

Бу уй ничектер күңелне тырнап узды. Ярый, текә ярдан буага белер-белмәс башы белән сикерә икән, үз эше. «Аннан башка да мәшәкатем баштан ашкан ла», — дип уйлады Фидая һәм Кармашка китеп барды. Аннан соң гына кайтты.

Кайнана Иркәне бакчадан кайтарып куйган да, Рамиләгә калдырып, үзе китеп барган иде. Рәссам кыз мәктәпнең сәнгать түгәрәгенә йөрүче балалар яныннан кайткан, кәефе бик күтәренке, сөйлисе сүзләре күп иде. Ләкин Фидаяның сүрән йөзенә карагач, тыелды, сабыр итәргә булды.

Табын янында Рамилә, сәнгать түгәрәгендәге кайсыбер балаларның шактый ук сәләтле булуы, һәр сүзне авыз ачып, беркатлы ихласлык белән рухланып тыңлаулары, чын рәссам сызган һәр сызыктан даһилык эзләүләре турында сөйләде. Ләкин Фидая үз гаменнән арына алмады.

— Минем эш бик авыр бара бит әле, — диде. — Котельныйны көч-хәл эшләтеп җибәрдек, җылыны бирә башладылар. Анысы әйбәт булды булуын. Бинасын кузгата алмыйм, төзү материаллары да, эшче көчләр дә юк. Аның баш врачы үз эшенә генә оста. Төзелеш ягына килгәндә, уңган кеше булып чыкмады. Мин тапсам — була, мин тапмасам — юк. Гел минем авызга гына карап тора.

— Миңа да шулай тоелган иде шул, — дип, аның сүзен җөпләп алды Рамилә. — Сезнең авызга гына карап тора... Читтән караганда, бу бик сизелә. Хатыны да сезне күздән ычкындырмаска тырыша кебек.

Фидаяның йөзе алланып чыкты.

— Җитәкче килгәч, аның янында булмыйча, бүлмәләрендә качып утырмаслар инде. Берсе баш врач, икенчесе өлкән медсестра бит аларның!

Рамилә, гаепле кешедәй, башын иде.

— Бәлки, миңа гына шулай тоеладыр... Мин дә бит ялгыз хатын, ир күргән, ирсез калган... Хатыннарның күбесе безгә шикләнеп карый... Бәлки, сезгә алай түгелдер. Ә мин бик сизәм. Берәрсенең ире янында биш кенә минут басып торсаң да, көнләшә башлыйлар. Ирсез хатыннарның маңгаена «бозык хатын» дигән мөһер сугып куйганнармыни!

— Эш урынында да гел шуны гына уйлап торып булмый инде! — диде Фидая әрнеп. Күренеп тора, Рамиләнең әйткәннәре аның өчен һич тә яңалык түгел, үзенең дә андый карашларны сизгәне бар иде инде.

— Без уйламыйбыз да бит, бүтәннәрнең уен үзебез теләгән якка борып куя алмыйбыз. Үз башлары, үз йөрәкләре үзләрендә аларның... Сез үзегез моңа бөтенләй игътибар итмисез кебек күренде миңа. Ләкин белеп тору зыян итмәс... Әйтмәм дигән идем дә, ничектер телдән ычкынды... Бәлки, мин бөтенләй хаксызмындыр. Авырткан җирегезгә тигән булсам, кичерегез...

— Иркә, кызым, сиңа йокларга вакыт, — диде Фидая, урыныннан кузгалып.

Ул кызын кече бүлмәгә кертеп яткырган арада, Рамилә өстәлне җыештырып куйды да залга керде. Фидая, диванны җәеп, урынын әзерләгән, мендәрен кабарткалап азаплана иде. Аннары утырды да торшерны кабызды.

— Өске утны сүндер әле, — диде. — Утыр монда. — Өзелгән сүзне дәвам итеп: — Бернишләр хәл юк, түзәрләр, — диде. — Аларга мәшәкать дип тә, читен дип тә торып булмый, барырга туры килә. Миңа җиңел дип уйлыйлар микән әллә? Анда барган саен, йөрәгем генә таланып кайта. Бөтен язмышым шунда җимерелде, өметләрем шунда өзелде бит минем...

Шактый вакытка тынлык урнашты. Шкаф киштәсендәге түгәрәк сәгатьнең текелдәве генә ишетелеп торды. Рамилә сорау бирмәде, ашыктырмады, көтте. Ниһаять, Фидая, тынычланыбрак киткәндәй булып, сөйләвен дәвам итте.

— Аңарчы олы кайгы күргәнем юк иде шул минем, — диде. — Чыныкмаган йөрәккә хәсрәтнең иң авыры, үкенечлесе кинәт килде. Аңа хәтле мин түтәлдәге гөл кебек яшәгәнмен. Антуан де Сент-Экзюпериның роза чәчәге төсле. Минем дә шулай кайгыртучым, көйләп торучым, үстерүчем, үсендерүчем бар иде. Хәзер генә аңлый башладым: асылда, мин ул теләгәнчә яшәгәнмен, ул теләгәнчә үзгәргәнмен икән. Оста бакчачы да агачларны, гөлләрне шулай үзе теләгәнчә үзгәртә бит. Әмма моннан аларга зыян килми, һич юк, киресенчә, алар тагын да гөрләп үсеп китәләр, тагын да балкып чәчәк аталар һәм мулрак җимеш бирәләр. Ул булмаса, мин бүтәнчәрәк, булдыксызрак, игелексезрәк булып калыр идем. Күпмедер вакыт бергә яшәгәннән соң, моның шулай икәнлеген аңлый башлаган идем инде. Бервакыт хәтта: «Син миңа ничек курыкмыйча өйләндең?» — дип, үзеннән дә сорадым. Нәрсәдән куркасы икәнен әйтмәдем, ул болай да аңлады. «Ә мин синең яхшы буласыңа ышандым», — дип, башымнан сыйпады. Теге чакта минем хакта, тәкәббер ул, дигән егетләргә: «Кеше үзгәрми тормый, ул да үзгәрер», — диюе шул хакта булган икән.

Җиде ел бергә яшәгәнебез хәзер бер тын, бур сулыш кына булып тоела. Укуны тәмамлаганнан соң, Баллыболын мәктәбенә кайтып ике ел эшләгәч, директорыбызны райкомга эшкә алдылар да, ул үз урынына мине тәкъдим итте. Бик актив идем, шуңадыр инде. Мин икеләнеп калдым. Мәгъсүм әйтте: «Ике дә уйлап торма, алын син бу эшкә», — диде. «Үз иремә начальник булыйммыни инде? — дидем мин. — Сиңа читен булмасмы соң?» — «Баш булырга яратасың бит син! — диде көлеп. — Дөрес, ир — баш, хатын — муен, дигәннәр дә бит, без киресен кыланып карыйк әйдә! Син баш бул, мин булырмын муен! Кызык булсын!» Хәзер менә искә төшерәм дә шуны аңлыйм: башы да, муены да ул булган, мин аяк-кул, авыз гына булганмын. Мин башкаларның эшен оештырам, кирәк-ярак артыннан чабам, җыелышларда, сикереп торып, акыллы сүзләр сөйлим. Нык куллы, акыллы җитәкче итеп тоям үземне. Баксаң, ул ныклык, зирәклек, минем үземнән дә бигрәк, арка терәгем булган иремнән килгән икән. Аның белән киңәшмичә кыл да кыймылдатмый идем шул...

Фидая тагын тынып, моңсу уйларына чумып утырды.

— Хәзер менә, ул булмагач, абынам да сөртенәм, гел кирәкмәгән кешеләргә барып сүз кушам. Яннарымда ул булса, бу рәвешле бәргәләнер идеммени?.. Ә бит кайчакларда аның миңа сөеп, сокланып каравы, гел киңәш биреп торуы туйдыра да иде шикелле. Кадерен белеп җиткермәгәнмен шул, дөньяда бөтен ир-хатыннар шулай яши, дип уйлаганмын. Бер җәйне аңа Казан санаториена путевка биргәннәр иде. Минем эшнең кызу чагы, мәктәп ремонты артыннан чабасы, ялгызы барырга үзем үгетләдем. Ике-өч көн үтүгә, телеграммасы килеп төште аннан: «Иртәгә үк килеп җит, югыйсә ташлап кайтам», — дигән. Ачу килде килүен, алай да беләм: үзем барып көйләмәсәм, кайтып төшәчәк. Ашказаны борчый иде аның, дәваланырга кирәк иде. Барып керсәм, авызын ерып тора. «Ни булды?» — дим. «Син булмагач, дәваларының шифасы тими, чөнки монда миңа сагыну чире ябышты», — диде дә, күтәреп алып, әйләндерергә тотынды. Аңа ничек ачуланасың инде? Путевка сатып алдым да калдым аның янында. Ялга килгән хатыннар: «Ирен каравылларга килгән, уҗымга чыгар дип курка», — дип, артыбыздан гайбәт сөйләп йөрделәр. Сөеп-сөелеп, матур итеп яшәп калырга, бәхетле булырга ашыккан икән ул. Гомере кыска булырын алдан сизде микән әллә? Мин исә мәңге-мәңге янымда ул булыр дип ышанган идем. Юләр! Ул бит мине алдан ук кисәтеп куйган булган, аңламаганмын гына.

Фидая, урыныннан торып, шкафтагы альбомыннан бер фоторәсемне куптарып алды да, артын әйләндереп, Рамиләгә сузды.

Анда өлкән класс отличнигының язуы кебегрәк авыш, пөхтә хәрефләр белән шигырь язылган иде:

Урал суы бигрәк матур, борма,
Урал тауларыннан чыга ул;
Авырлыклар килсә, түзәрлек бул,
Мәңгелеккә бирәм сиңа кул.

— «Авырлыклар килсә, түзәрлек бул» дигән бит, — диде Фидая. — Кайчак миңа хатыннар ирләреннән зарланып килә, мин аларга акыл өйрәтәм: бергә чакларның кадерен белегез, парыгызга рәхәт күрсәтеп, үзегез дә тормышның тәмен белеп яшәгез, дим. Күзләреннән күреп торам: күбесе аңламый, вак-төяк белән башын бутый, үз сүзен өскә чыгаруны гына кайгырта. Аларга карыйм да, үткәннәрем искә төшә: үзем дә шундый түгел идеммени? Мин күп төннәремне аның янында түгел, башка бүлмәдә үткәрдем. Кызымны үзем белән йокларга өйрәттем, ә иремә-бәгыремә: «Врачлар бергә йокларга киңәш итми», — дия идем. Кайсы ахмагы журналда язып чыккан да мин ничек шул сафсатаны эләктереп алган диген. Бер төнне ничектер сискәнеп уянып китеп: «Аерым үткәргән төннәрем өчен үкенмәм микән!» — дип уйлап куйдым. Тик урынымнан кузгалырга ирендем. Хәзер менә үкенепләр туймыйм, кайтарып алып кына булмый. Их, хәзерге акылларым булса, беләгеннән башымны кузгатмас идем, аның кайнар иңенә сыенып, хуш исле сулышына коенып идем. Бер гамем калмас иде... Соңгы төнемдә дә мин аннан аерым яткан идем. Кинәт нәрсәдәндер сискәнеп уянып киттем, шактый вакыт сагаеп, тыңлап яттым. Кап-караңгы, тып-тын иде. Кабыргаларыма бәргәләнеп, йөрәгем типкәне генә ишетелә. Күпме вакыт узгандыр, тагын йокымсырый башлаган идем, күрше бүлмәдән сәер, нечкә аваз колагыма килеп ирешге. Бәрелгән туп кебек бусага аша атылдым, өстәл лампасының төймәсен капмаланып таптым. Ут кабынгач, сәгатькә күз төшереп алдым. Төнге ике иде. Шуннан бирле мин нәкъ төнге икедә сискәнеп уянам да йоклый алмый уйланып ятам...

Ул бөгәрләнеп ята, йомарлап тоткан җәймәнең башы канга чыланган иде. Маңгаен тотып карасам — манма тир. Безне уятмаска тырышып, шактый озак газапланып яткан иде, күрәсең.

Шәһәрдә булса, телефоннан «скорый» гына чакыртыр идең дә бит, ә монда төн уртасында машинасын табу да мең бәла. Майның унөченче числосы, яңгырлы чак иде. Авылыбызның урамын, саз ерып, әллә ничә урадым мин ул төнне. Ярый фельдшерыбыз бик әйбәт, ярый әле аның элекке ире, йөгереп барып әйтүгә, машинасын кузгатты. Анда-монда чапканга, бөтен тәнем кызышкан иде, әллә шуңа микән, иремә оекбашлар кигезгәндә, аяклары боздай салкын булып тоелды, йөрәгем жу итте. Ничә ел бергә яшәп, мин аның аякларын сыйпамаганмын-иркәләмәгәнмен икән. Беренче тапкыр назлавым соңгысы булды. Исән чагында...

Сикәлтәле юллар буйлап машинада барганда, аны исән килеш кочагыма алуым да соңгы тапкыр булган. Анысын аңлый башлаган кебек идем инде, йөрәккә кара сагыш килеп ябышкан иде. Шом басты минем күңелне, шом, шом... Әгәр шунда алдан ук өметсезлеккә бирелмәсәм, тереләчәгенә иманым камил булса, ул, бәлки, исән дә калган булыр иде. Чын сөю, өмет, ышаныч могҗизалар ясый, диләр бит, ә мин кара кайгыларга сабыштым, өметем сүнгәннән-сүнә барды. Алдан ук Газраилгә бирдем мин аны, шунысы өчен үземне гафу итә алмыйм!

Рамилә бүлдерми түзә алмады:

— Хасталарны йөрәк хисләре белән генә дәвалап булмый шул! — дип көрсенеп куйды.

— Минем тойгыларыма Билалның осталыгы да кушылырга тиеш иде бит югыйсә! Иртәнге якта аның операция бүлмәсеннән нинди йөз белән чыкканын күреп, мин барысын да аңладым. Шунда мине әйтеп бетермәслек гаҗизлек биләп алды. Бүлмәгә йөгереп кердем дә кочаклап алдым бәгырькәемне. Күзен ачмады. Бөтен гәүдәсен сыйпадым, аякларын тотып карадым. Алар җылы иде. Миңа ул исәндер кебек тоелды. Йөгереп чыктым да Билал каршына барып бастым: «Нишләттең син аны? — дидем. — Наркоздан айнып җитмәдеме әллә? Монда ничек килеп кергән булса, шул хәленә кайтар! Алып китим! Районга илтим!..» Тагын ниләр кычкырганмындыр, хәтерләмим, артык ярсыган идем. Еладым, каргадым. «Үз башыңа килсен!» — дидем. Ник Кармашка алып килгәнемә үкенгәнемне белсәң син! Район үзәгенә илтеп салган булсам, коткарган булырлар иде дигән уй килде башка. Әгәр шунда арага Гөлфия килеп кермәгән булса, белмим, нишләгән булыр идем. Ә Гөлфияне төртеп җибәреп булмый, кызыбызның кендек әбисе бит ул...

Аннары мәрхүмне, тикшерергә дип, районга алып киттеләр. Минем Билалны гаепләп кычкырынуым да сәбәп булгандыр инде...

— Үзегезне юкка гаепләмәгез, больницада үлгән кешене тикшермичә күммиләр, законы шундый, — диде Рамилә.

— Миннән сорап-нитеп тормадылар шул...

Ә авылда укытучылар, балалар чәчкәләр, бүләкләр әзерләгәннәр — Мәгъсүмнең туган көне иде ул. Ямьле май айлары миңа менә шундый хәсрәт алып килде, шатлык белән кайгыларны буташтырды да куйды.

Үлемнең сәбәбен ачыкладылар: диагноз дөрес куелмаган булган икән. Билал Мәгъсүмнең ашказанын ачкан, ә кан үңәчтән киткән. Үңәчкә операция ясау өчен исә катлаулы аппаратлар таләп ителә, аның ишеләр безнең Кармашта гына түгел, район хастаханәсендә дә юк. Диагнозын ачыклау да безнең шартларда мөмкин эш булмаган. Аның өчен кирәкле аппаратны японнар моннан ун ел элек уйлап чыгарганнар икән дә бит, ләкин алар кайчан безгә килеп җитә! Аңарчы күп меңнәр бездән китеп барыр әле...

— Үлгән артыннан үлеп булмый, ди торган иде минем әби, — диде Рамилә. — Сез инде булдыра алганны эшләгәнсез бит.

— Ләкин мин моның белән риза түгел! Минем башка сыймый: ничек инде ул, кешене үлемнән алып калуның чарасы булып та, шуны без кулланмыйбыз? Без соң японнардан кайсы ягыбыз белән ким?

Бу урында Рамилә ихтыярсыздан көлемсерәп куйды.

— Менә шул-шул, — диде Фидая. — Кемгә сөйләсәм, шул көлә. Җитәкчеләр дә кул гына селти. Юкны сөйләп йөрмә, аннан башка да җитмәгән әйберне санап бетерерлек түгел, диләр. Ә нишләп алай? Ник без үз аягыбызда чакта, кулыбыздан эш килгәндә, иң элек шул якны кайгыртмыйбыз? Мин, мәсәлән, хәзерге акылым булса, ипи-сөт ашап яшәргә, куртка киеп йөрергә риза булыр идем. Ярты эш хакымны бирер идем, тик шул аппаратны гына сатып алып китерсеннәр иде. Минем кебек газиз кешеләрен югалтканнар азмыни? Алар да шулай уфтанмыймыни?

Фидая хуплаганны көтә иде кебек, Рамилә исә, шикләнүен белдереп, башын чайкап куйды.

— Исәннәр үлем турында түгел, яшәү турында уйлый шул, — диде.

— Әйе, җиң сызганып дөнья куабыз, — дип ризалашты Фидая, төшенке тавыш белән. — Ә кешенең үзе турында уйлау юк. Совет иле — иң кешелекле ил, дип мактанабыз үзебез. Әгәр дә шулай икән, иң элек авырган кешеләрне дәвалау турында кайгыртырга кирәк бит. Мин, җитәкче эшкә күтәрелермен дип, башыма да китермәгән идем. Искәндәров өченче секретарь булырга чакыргач, иң элек шул Кармаш хастаханәсен рәткә китереп булмасмы дигән уй башка килде. Шуны уйлап, ризалык бирдем. Баш врач Газимов мең бәла белән проектын эшләткән иде инде. Тик алар кәгазь генә икән шул. Андый төзелешләрнең күпмесе шул кәгазьдә килеш кала! Монда килгәч кенә белдем: бездәге сәламәтлек саклау системасы җәмгыятьнең саилчесе генә икән ул, аңа шул, урам хәерчесенә биргәндәй, тиеннәрне генә сузалар. Без бу илгә җигелеп эшләгәндә генә кирәк. Хәлдән таеп егылсаң, рәтләп кайгырту юк икән. Кешенең бер кадере дә юк икәнен хәзер генә аңладым. Мин моны аз гына булса да үзгәртергә тиеш. Иремнең истәлеге хакына, кызымның киләчәге хакына эшләргә тиеш мин моны. Әлбәттә, Мәгъсүм исән чакта алдыбызга шундый максат куйсак, җиңелрәк булыр иде дә бит. Нишлисең, ялгызлык гаҗиз итә. Мин күңелемнән гел аның белән сөйләшәм, киңәш сорыйм. Тик җавап кына ала алмыйм.

— Мин сезгә бик булышыр идем дә, кулымнан килми шул, — диде Рамилә. — Тик шул хастаханәнең стеналарын бизәргә ярдәм итешсәм генә инде.

— Анысы да зур эш, — диде Фидая. — Рәхмәт сиңа тыңлаганың өчен, аңлаганың өчен рәхмәт. Эчемне бушаттым, җиңел булып китте. Бәлки, бүген уянмый йоклап булыр. Башның саф булуы кирәк миңа. Төзелеш өчен кирәкне аю кебек ирләрдән тартып алу бик зур көч-гайрәт сорый.

— Алла ярдәм бирсен сезгә, — диде Рамилә.

# 21

Күргәзмәне ябу тантанасына рәссамнар тагын автобус белән килеп төштеләр. Мәдәният йортында шушы очракка муафыйк сүзләр сөйләп, кулларны кысышып, киләчәктә дус булырга вәгъдәләр бирешкәннән соң, Искәндәров кунакларны зурлап ресторанга, саубуллашу мәҗлесенә чакырды. Тәүзихның сүзләре хак иде шул: мондый урын зур кешеләрне олылап хөрмәт итү өчен кирәк! Табын мул, йөзләр ачык, сүзләр җылы, хисле булды. Рәссамнарның һәркайсына лесхозда эшләнгән агач кашыклар белән бергә ачык буяулы, ялтырап торган агач вазалар да бүләк иттеләр. Аларын күргәч, Рамиләнең күзләре ялтырап китте:

— Бик кыйбатлы бит болар! Мондый сувенирларны чит ил кунакларына гына бирәләр!

— Безнең өчен сез чит ил кунакларыннан мең тапкыр кадерлерәк, — диде Искәндәров. — Бусы аның күңел өчен генә әле. Иң кирәк күчтәнәчләрне монда кертеп тормадык. Анысын өегезгә кайткач актарып карарсыз.

Чыннан да, кунаклар кызарынып, шаулашып рестораннан чыкканда, аларның автобусына катыргы тартмалар тутырып азапланалар иде. Ни икәнен әйтмәсәләр дә, билгеле — анда ит. Фидая Беренче аша әйттереп, колхозлардан соратып алды һәм тартмаларга унар кило итеп салырга кушты. Күчтәнәч итеп бирелгән кебек булса да, асылда, бу — рәссамнарга эш хакы, чөнки районның акчалата бәхилләтү мөмкинлеге юк иде.

Рамилә автобус эченнән катыргы кәгазьгә төрелгән ике картина алып чыгып, Фидаяга сузды:
— Розалары сезгә, — диде. — Ә атны теге лесхоз инженерына тапшырырсыз инде. Хәтерлисезме, маркетрига өлге кирәк, дигән иде.
Фидая аптырап китте:
— Миңа биргәне өчен мең рәхмәт. Ләкин аңа ник бирәсең? Ул хәзер лесхозда түгел бит, колхозда! Аннары шундый зур хезмәт җимешен очраклы кешегә бирәләр димени?
— Алар да безгә бүләкнең зурысын бирде бит. Агач вазалар кыйбат тора алар. Аннары мин вәгъдә иткән идем бит инде. Вәгъдә — иман, ди торган иде минем әби.
— Аның ише килде-китте шаярып сөйләшкән сүз нинди вәгъдә булсын ул? Үзе дә әллә кайчан оныткандыр инде. Кирәксенсә, күргәзмәнең ябылышына сугылып чыгар иде.
— Анысы аның эше, үз сүземә үзем хуҗа булу минем эш, — дип, сумкасыннан калын кызыл фломастер чыгарды Рамилә. Аннары төргәкнең кәгазен бер кырыйдан каерып ачты да: — Исеме ничек соң әле, — дип сорады.
— Давыт Зиннәтович.
— Мин кешегә отчество белән эндәшергә яратмыйм. Үзем дә башта туташ идем, хәзер ханым. «Әфәнде» дип кенә языйм әле.
Кочаклашып саубуллашканда, күңелләр йомшарып, күзләргә яшь килде. Бергә үткәргән кичләр сагынып искә алырга гына калды.
Розаларны Фидая олы бүлмәнең түренә, диван каршына элеп куйды. Төн уртасында сискәнеп уянып киткән сәгатьләрдә, гомернең иң матур чакларын искә төшереп, юаныч биреп торыр.
Кәгазьгә төрелгән икенче рам алгы бүлмәнең стенасына сөялеп тора, яныннан узган саен, Гаяровны искә төшерә иде.
Әманәтне тапшырмый озак тоту яхшы түгел, яңа председательнең эшләре ничек барганын белергә дә кирәк иде, беркөнне төшкә таба Фидая Баллыболынга китте. Картина колхозга түгел, шәхсән Гаяровның үзенә бүләк ителгән, шулай дип артына язып та куелган, шунлыктан аны эш бүлмәсенә түгел, фатирына илтеп бирү дөресрәк иде. Фидая Балкышка Наилә апалар турында туктарга кушты.
— Сезне чәй эчерми җибәрмәсләрдер бит? — диде егет.
— Нишләп мине генә? Син дә эчәрсең. Әйдә керәбез.
— Юк, карын ачмады әле. Медпунктка сугылып чыгасы иде.
— Әллә тагын күзеңә чүп кердеме? — дип сорады Фидая, хәйләкәр елмаеп.
— Муен начар борыла. Шофер халкының умырткасына бәрә бит аның. Әле биленә, әле муен турына...
— Бар инде алайса, сылатып кайт, — диде Фидая. — Балалар мәктәптән кайткандыр инде... Кара аны, дөньяңны онытма. Берәр сәгатьтән килеп җит. Кая, теге төргәкне алып бир әле!
...Бусаганы атлауга, Фидаяның йөрәге сулкылдап куйды: монда бернәрсә дә үзгәрмәгән! Гади генә булса да, тигез-имин көн итәр өчен яратылган ямьле куыш иде бу. Түр тәрәзә өсләрендә чигүле кашагалар, стеналардагы рамнарда карточкалар, караватта челтәр итәкле япмалар, тәрәзә төпләрендә гөлләр. Идәндә кулдан тукылган паласлар. Аларга йон оекбашлары белән тавышсыз гына басып, әле Мәгъсүм узгандыр, аның бармагына тотынып, тәтелди-тәтелди нәни Иркә тәпиләгәндер кебек. Әйтерсең алар, шулай җитәкләшеп, ишегалдына тавык-казларны күреп керергә генә чыкканнардыр да менә-менә әйләнеп керерләр шикелле... Гүяки аларның мәктәп фатирына күчеп яшәгән еллары да булмаган, баштан авыр кайгылар да узмаган... Әйберләрнең гомере кеше гомереннән озынрак. Бу өй, мөгаен, Наилә апаның яшьлегендә дә шушындый булгандыр, кайчандыр бу идәннең паласларын хәзер инде йөз чалымнары тоныйк фоторәсемнәрдә генә сакланып калган кешеләр таптап йөргәндер. Ә менә хәзер анда яңа кеше — авылның хуҗасы Давыт Гаяров басып тора.
Кече яктан, куанычыннан балкып, Наилә апа килеп чыкты.
Гаяров урындык аркасына элеп куйган кара пинжәген алып киде, галстук төенен төзәткәләп, кунакның сузылган кулын саксыз гына каты итеп кысты. Фидая ихтыярсыздан йөзен сытып куйды: бармагын балдагы авырттырды. Гаяров аның каршысында биегәеп, түр тәрәзәнең яктысын каплап басып тора, бу өй аңа тар, кысан кебек, аның янында Фидая да кечерәеп калган сыман иде.
— Бик зур бер вазифа йөкләделәр әле миңа, — диде ул, шаярткан кебек итеп.
Гаяров аңа гаҗәпләнеп карады, күргәзмә ачылган көнне сөйләшкәннәр, әлбәттә инде, аның хәтереннән чыккан иде. Төргәкне чишкәч, картинадагы канатлы тулпарга илтифатсыз гына күз ташлады да рамны кире ягы белән әйләндереп куйды.
— Язуын укы, ичмасам, — диде Фидая.
«Әфәнде» сүзе Давытны сәерсендерде булса кирәк, ул, җилкәләрен сикертеп, елмаеп куйды. Елмаю килешә аңа, кысылган күзләреннән үзенә бер назлы яктылык саркып, бөтен йөзен балкыта, сабыйларныкы

кебек алсу иреннәре арасыннан тешләре җемелдәп күренә. Моңарчы Фидаяның аңа болай текәлеп караганы булмаган икән. Ихлас та кебек үзе, әмма кеше алдында чишелеп бетә торган да түгел.

— Моңа җавап итеп нишләрбез икән соң? — диде Давыт. — Лесхозда мин хуҗа түгел хәзер. Шәһәр кешесенә күчтәнәчкә бераз ит бирсәң, зыян итмәс иде.

— Киттеләр инде алар. Бүләге дә, күчтәнәче дә бирелде. Яңа председатель булганга, сезне борчып тормадык.

Наилә апа, өстәлгә электр самавырын, балын-каймагын куеп, чәй табыны әзерләргә кереште.

— И-и, Фидая, мактап кына йөрисең икән, бигрәк вакытында килеп кердең, — диде. — Әллә фәрештәләр колагыңа пышылдадымы? Бүген генә ипи салдым. Әле менә син җибәргән индийский чәем дә бетмәгән иде. — Аннары, Давытка карап: — Мине тәмле чәйдән өзми ул, рәхмәт төшкере, — дип өстәде. — Хәмидә сөт тә керткән иде.

Җиңел гәүдәле, пөхтә киемле, билен чуар алъяпкыч белән буган, ак яулыгын чөеп бәйләгән апа, күңелле такылдап, Фидая белән Давыт арасындагы уңайсызлануны таратып ташлады, сүз ялгауны җиңеләйтте.

— Фидая миңа үз туганым кебек бит ул. Безнең өйдә начар кеше торганы юк-югын, бик сайлап кына кертәм. Алай да Фидаяларга җитмәс. Син гаиләңне алып килгәч ничек булыр, анысын әйтә алмыйм, әмма болар белән бер гаилә кебек идек. Аларга бөтен халык соклана иде. Капка төбенә «КамАЗ» белән кайтып туктасалар, Мәгъсүм мәрхүмкәем руль ягыннан сикереп төшәр иде дә, йөгереп килеп, Фидаяның кулыннан тотып төшерер иде. Хатынын шулай зурлаган кешене беренче күрдем. Фидая аңа лаек та шул. Үзе дә мактап туймаслык, ир кадерен дә белә. Андыйлар сирәк бит ул.

Наиләнең күзгә карап мактавы, җитмәсә, аларның мәхәббәте турында сөйләве Фидаяны кыенсындырып җибәрде, әйтерсең лә аны ят кеше алдында чишендерә башладылар. Ул кызарынып чыкты, сүзне икенчегә борырга ашыкты, Давытка карап:

— Сезнең белән киңәшәсе бар иде, — диде.

— Киңәшкә үзем дә бик мохтаҗ шул әле. Яшь җитәкче буларак, мине шефлыкка алган кешеләр дә монда сирәк күренә, ярдәм итәселәре килми, — дип, баягыча елмаеп, шаян гына төрттереп куйды Давыт.

— Мин үзем ярдәм өмет итеп килдем әле, — диде Фидая. — Бата башладым, кул сузучы юк.

Давыт җитдиләнеп китте, ничектер йомшарып:

— Кулым җитәрлек булса, йөгереп кенә барыр идем дә... — диде.

— Йөгерергә кирәк булмас анысы. Машина белән барырбыз. Мин сине Кармашка чакырмакчы идем. Төзелешне карап кайтырга.

— Мин барып караудан гына ни файда булыр икән соң? Хәзер инде теләсәм дә такта урлап бирә алмыйм. Минем кулдан китте.

— Каян табарга икәнен әйтерсең. Хәзер инде лесхозның серләрен сакламасаң да була... Анысы гына да түгел. Моңарчы минем андый эшләр белән шөгыльләнгән юк иде бит. Ә син инде төзелешләрне шактый күргән. Юлларын күрсәтер идең.

Сүзгә Наилә апа кушылды:

— И-и, шулай шул инде ул ялгызлык хәлләре, — диде. — Әгәр ирең исән булса, бүтәннәр каршына барып, ярдәм сорап йөрер идеңмени син, Фидая! Әйткән сүзе саф алтын, биргән киңәше үткен корал иде мәрхүм Мәгъсүмнең. Кире кайтарып булмый шул!..

Фидая янә йөзен чытты. Кирәкмәгәнгә кысыла иде карчык, болай да әрнегән йөрәк ярасына тоз сибә иде!

Әмма Гаяровка карчыкның сүзләре бөтенләй башкача тәэсир итте, ирлегенә, мин-минлегенә тиде. Үлгән кешенең генә холкы җәүһәр, акылы алтынмы әллә? Аннан бүтәннәрнең дә башы эшли ләбаса!

— Барырбыз, ник бармаска, — диде ул, кыска гына итеп.

Табыннан тиз кузгалдылар. Капка төбендә Балкышның машинасы юк иде әле. Фидая, юл уңаеннан Мөнирәнең хәлен белеп чыгармын дип, югары очка, медпунктка китте.

Нинди гади һәм аңлаешлы тоела иде бу дөнья Наиләдә фатирда яшәгән чакларда! Агы ак, карасы кара, кешеләрнең кылган гамәлләре дә йә яхшы, йә яман. Гыйззетдин Мөнирәне ташлаганмы? Ташлаган, димәк, бик начар эшләгән. Каләмгөл кеше ирен тартып алганмы? Алган! Димәк, әшәке гамәл кылган.

Күпләр шулай сөйли, Фидая да нәкъ шулай уйлый иде.

Ә Мәгъсүм андый түгел, кеше күңелен аңлый белә, кызгана, уйлана иде.

— Яшәү ул сиңа кушу-алу, тапкырлау-бүлү генә түгел, — ди торган иде ул. Хатынының математика укытучысы булуына һәм һәр мәсьәләдә кискен фикер йөртеп, сүзен өздереп әйтүенә шулай киная ясый иде. — Ул синең математика кагыйдәләреңә буйсынмый.

— Кагыйдәсез генә яшәсәң яхшыракмы әллә? Кешенең күңеле бүген берне тели, иртәгә икенчене. Нәфесеңне тыя белмәсәң, барып чыгарсың.
— Нәфескә намус хуҗа булырга тиеш, анысы дөрес.
— Соң, шул кагыйдә бит инде!
— Кагыйдәсен кагыйдә, ләкин бөтен кеше өчен нәкъ бертөсле түгел. Эткә яраган ишәккә ярамый дигәнне ишеткәнең бармы синең? Берәүнең эте белән ишәге булган, ди. Хуҗа кайтуга, эт каршы чабып бара да, тәпиләрен абзыйның түшенә куеп, битен ялый икән, ә тегесе маэмаеның башыннан сыйпый икән. Ишәк моны карап торган-торган да, нишләп әле миңа да шулай итмәскә, минем дә хуҗа бит ул, дип уйлаган. Теге кеше кайтуга чабып барган, тоякларын аның иңбашына салып, телен битенә сузган. Ә хуҗасы, башыннан сыйпыйсы урынга, моны камчы белән яргган, ди.
— Шуннан нинди нәтиҗә чыга инде?
— Кеше турында фикер йөртә башлаганчы, аның кемлеген белергә кирәк. Шулай бит?
Бу сөйләшү хәтергә нык уелып калган икән, менә хәзер, мәктәп турыннан узганда, ап-ачык булып күз алдына килде. Әнә шунда, мәктәп йортында яшәгән чаклары иде. Мәгъсүм дәфтәр битенә квадрат сызып та күрсәтте әле.
— Әйтик, мин менә үзем өчен шушындый кыса сызып куйдым. Шуннан чыкмаска тырышам. Ләкин намус кысасы ул бөтен кеше өчен дә нәкъ бертөрле түгел. Ноктасы — ноктасына, җебе җебенә туры килеп бетми. Йә бер ягы киңәеп киткән, йә икенче почмагы тырпаеп чыккан. Моның өчен, аларны гаепләргә керешкәнче, ник алай икәнен аңларга тырышырга кирәк.
— Синең ул квадратыңа хатын алыштыру да сыямы әллә? — дип бәреп сорады Фидая.
— Нәкъ менә мин сызганына андый нәрсә керми шул.
— Әгәр гашыйк булсаң? Гыйззетдин кебек коега сикерер дәрәҗәгә җитсәң, нишләр идең?
— Телемне аркылы тешләр идем...
— Әйтүе җиңел.
— Миңа җиңел. Чөнки минем күңелемә синнән башка беркем дә сыймады, сыймый һәм сыймаячак, — дип, гадәттәгечә йомшак сүзе белән хатынының күңелен йомшартып, бәхәскә тыныч кына нокта куйды Мәгъсүм.
...Күпләр гаепләде Каләмгөлне, әмма Мәгъсүм аңа беркайчан да кашын җыерып карамады. Кичләрен клубта аның баяны еш яңгырый иде. Баян уйнап торганда, клуб буш булмый!
Әкренләп Фидаяның да күңеле йомшарды. Каләмгөл белән бергәләшеп кичәләр үткәрергә туры килгәндә, Яңа елга чыршыларны бизәгәндә, күргәзмәләр оештырганда, баштарак Мөнирәгә карата нииндидер бер хилафлык кылгандай тоелса да, тора-бара ул хис әкренләп сүрелде, бу кешеләрнең өстән караганда көйсез тоелган яшәешенә күз күнекте.
Тик үсеп килгән Зиләйлә генә күнегә алмады. Киресенчә, вакыт узган саен, йөрәкләре хисләрнең зурларын сыйдырырлык булып җитлегә барган саен, андагы ризасызлык көчәя генә бара, кайчакта нәфрәт булып ургылып чыга иде.
Бу үсеш-үзгәреш Фидаяның күз алдында барды. Мөнирәнең Гыйззетдин белән булган олы мәхәббәтеннән яралган Зиләйлә белән Каләмгөлнең чегәннән туган кызы Зарема икесе бер класста укыйлар, икесе дә Аллаяровалар. Заремага җиңелрәк иде. Ул уңга-сулга дикъкать белән карый белми, күңеле әллә кайларда гизә. Нәкъ Мәгъсүм әйткәнчә: математика кагыйдәләрен яратмады, кешеләрнең кылганнарын кысаларга чамалап үлчәргә өйрәнмәде, гаеп-кыекны күрмәде, гайбәтне ишетмәде. Дәрестә дә күңеле әллә кайларда йөзгәне шомырт кара күзләреннән үк күренеп тора. «Зарема, ни уйлап утырасың син анда? Яле, кабатла әле мин әйткәнне!» Торып баса, дәшми. Ә дәрестән соң калдырсаң, авызын йомдыра алмый аптырыйсың. «Менә, апа, кичә телевизордан шундый бию күрсәттеләр, сез күрдегез микән. Ансат кына төсле иде, кабатлап булмый шуны! Йокларга ятсам да, дәрестә утырганда да, ап-ачык күз алдына килә, аякны шулай-шулай итсәм, килеп чыгар шикелле. Аякка баскач, булдырып булмый!» Сикереп торып биеп тә күрсәтә шунда. Бернишләр хәл юк, тагын Мәгъсүм әйткән сүз дөрескә чыга. Шундый талантлы кызны икенче елга утыртып калдырып булмый, намусыңның кысаларын киңәйтеп дигәндәй, еллыкка «өчле» чыгарырга туры килә.
Ул кыз Зиләйләнең көйдергеч карашына да күнеккән, аңа да исе китми кебек. Наилә апа моны үзенчә аңлата: «Әртисләр әртилендә кем очраса, шул башыннан сыйпаган бит аның, кайсысының үз атасы икәнен дә аермагандыр. «Әти» дип Гыйззетдингә әйтте ни, башкага әйтте ни, аның ишегә барыбер. Аңа шул биергә сәхнә булсын да дыңгырдатырга думбра булсын. Ә Зиләйлә — ата баласы бит ул. Атаңны башкага бирү ирелне бирүдән җиңел түгелдер ул. Бигрәк тә бу яшьтә, атаның иң кирәк чагында».
Бишенче класска җиткәч, Зиләйлә, анасының кыз фамилиясен алып, класс журналына үзен Касыймова дип яздырырга маташып караган иде — Мөнирә рөхсәт итмәде. Атасы биргән бүләкләрне дә алып-алып

ыргыта икән, аннан акча алма, дип, анасына бәйләнә икән. Ләкин Мөнирә аның бу сүзен дә тыңламады, акча кирәктән бигрәк, Гыйззетдин белән арасын бөтенләйгә өзәсе килмәде. Араларны шул алимент җебе генә булса да тоташтырып торуын теләде.

...Медпунктның өйалдында аяк киемнәрен алыштырырга кирәк, кырыйда клеенкада башмаклар тезелеп куелган. Фидая ботинкаларын салып эчкә узды. Ак халатлы Мөнирә өстәл артында язып утыра иде.

Сагынышканнар икән, елмаешып исәнләштеләр.

— Синең шоферыңны дәваларга салдым бит әле мин, — диде Мөнирә, бүлмәнең почмагын каплап торган ак җәймә артына ымлап.

— Операция дә ясадыңмы әллә? — дип көлеп җибәрде Фидая. Аңа чыннан да көлке иде: кыз янына дип килгән егет анасы кулына килеп капкан икән. — Бик озак яткырасың бугай.

— Кеше бар иде, чират көтте, — диде Мөнирә. — Муенына компресс куйдым, бора алмыйм, ди бит. Безнекеләр чөгендердән суык тидереп кайта, җылы кабинада утырып моңа ни булгандыр тагын. Бераз ятсын инде. Миңа да күңелле булыр. Сагындым.

— Зиләйлә өйдәме соң?

— Мәктәптән кайтып җитмәде әле. «Тынгысыз санитар», тактага яңа язулар эләм, дигән иде.

Фидая, пальтосының изүен генә ачып, артсыз урындыкка утырды.

— Яңа хуҗа ничегрәк соң? — дип сорады, карашын каядыр читкә төбәп.

— Мәнле адәм сыман күренә болай. Районга барганда, үз машинасын биреп торды әле. Аның безне иң тилмерткәне — чирләүчеләр үзләре бит. Соңгы чиккә җиткәнче йөриләр, больница юлын таптамас өчен әллә нинди хәйләләр коралар. Әле беркөнне көчләп диярлек Наилә апаны алып барган идем. Врачка зарлана: «Йөрәгем кага, бавырым чәнчи, башым сызлый», — ди. Врач әйтә: «Нишләп элегрәк килмәдең», — ди. Наилә апа ни дип җавап бирде дисең? — «Бер генә чир өчен бу хәтле ерак юлга чыгасым килмәде, бөтенесен бергә җыеп алып килергә булдым», — ди.

Көлешеп куйдылар.

— Наилә апа әйтсә әйтә инде ул, — диде Фидая.

— Үз кадерен үзе белми халык, шулай диярга генә кала. Башкасына түзәр идең, корсаклы хатыннар сүз тыңламый. Сау-сәламәт килеш нишләп Кармашка хәтле өстерәлеп барып йөрик, бушка вакыт уздырып кына, диләр. Алар бармаганга мин гаепле булып калам, минем башка тукмак төшә. Аның бит Йосыповы да, Гөлфиясе дә миннән таләп итәләр. Ул Йосыпов китеп барса, хатыннарны Суташка ук әйдәклисе булачак бит әле. Ә анда чиратның кимегәне юк. Бәби табар чаклары җитсә, инде, Ходаем, ни булыр икән, дип ут йотып йөрисең. Үзең беләсең, баласын өендә табучылар булды бит бездә. Шушы заманда!

Бусы Каләмгөл турында иде. Көндәше янына килеп, чишенеп ятасы килми, күрәсең. Әле дә ярый, корсагын да җиңел күтәрә — авыл хатыннары аның озын, киң чуар итәге астында гәүдәсе түгәрәкләнгәнне сизми дә калалар, ул арада бәби туып та куя. Шулай сиздерми генә ике малай алып кайтты инде. Кечесен коймак пешереп йөргән җирендә тудырган, бала башы белән шапылдап идәнгә килеп төшкән. Зыян килмәдеме икән, дип коты очкан Мөнирәнең.

Хатыннарның сүзен бүлеп, чаршау артыннан, гаепле кешедәй кызарынып, сөмсере коелган Балкыш килеп чыкты. Керфекләрен күтәрми генә, ишек янындагы чөйдән курткасын алды.

— Җиңеләйдеме бераз? — дип сорады Мөнирә. — Сызлавы кимедеме?

Ул, бичара, егетнең бирегә нинди дәва эзләп килгәнен башына да китерми иде.

— Кимеде, бик әйбәт, — дип, башын боргалады Балкыш. — Рәхмәт. Сау булыгыз.

Ул чыгып киткәч, Фидая да саубуллашырга дип аягына баскан иде, — кинәт телсез калды. Мөнирә, урам як тәрәзә яңагына ышыкланып, кызыл җеп белән чигелгән, читләренә челтәр тегелгән ак пәрдә белән битен каплый төшеп, тышкы якка караган иде. Бит очлары алланып чыккан, ирен читләренә елмаю кунган. Әгәр күбәләк кебек канатлы булса һәм тәрәзә ачылса, очып кына чыгып китәр иде шикелле. Фидая да үрелеп тәрәзәгә күз салды: олы урамнан күпергә таба Гыйззетдин узып бара иде. Зәңгәр курткасының изүен ачып җибәргән, чалбар балакларын резин итек кунычларына батырып куйган. Үз уйларына чумган, медпункт тәрәзәсенә күз дә салмый кебек. Ләкин нәрсәдер — адымнарының сафтагы солдатныкы кебек артык тигез булуыннанмы, башын артык туры тотуыннанмы — каушаганлыгы, тәрәзәдән карап калганнарын белгәнлеге сизелә иде сыман.

Менә ул биектәрәк торган күпергә керде дә күздән югалды. Мөнирә бүлмәгә таба борылды, Фидая аның турайган сынына, яшәреп киткән йөзенә, бәхет нуры сипкән күзләренә карады һәм көнләшеп куйды. Бу хатын сөйгәнен ерактан күреп кенә дә зур куаныч таба, шуның хакына бөтенесенә: кеше сүзенә дә, кызының көйсезләнүләренә дә, көндәшенең көн саен очрап торуына да түзә иде. Чөнки ул сөя иде.

Бу минутта Фидая чын сөюнең, олы мәхәббәтнең шаһиты булганын аңлады. «Ул миннән мең тапкыр бәхетлерәк», — дип уйлады.

## 22

Фидая белән Давыт Кармашка һәркайсы үз машиналары белән бардылар. Шунлыктан юлда аны-моны сөйләшеп булмады. Хастаханәгә барып керү белән, сүз Газимов белән Гаяров арасында куерып китте, Нурханова артык кебек тоелды. Фидая моңа игътибар итмәскә тырышты, чөнки бу икәүнең серләре килешү яхшы фал иде. Хастаханә азык-төлеккә дисеңме, башка кирәк-яраккамы күп мохтаҗлык кичерә, хуҗалык җитәкчеләренең ярдәме бик кирәк иде.

— Әйдәгез, палаталарны карап чыгыгыз, — диде Билал. — Бәлки, үзегезгә дә кереп ятарга туры килер. Кая киләсегезне алдан белеп торырсыз.

Давыт, гадәттәгечә күзләрен кысып, серле генә көлемсерәп куйды.

— Хуҗалык җитәкчеләре районга да барып җитәр анысы, — диде Фидая, аның сүзсез кинаясен аңлаткандай итеп. — Машина үз кулларында. Тик менә сезнең кебек хирургны гына кайдан табарлар икән.

— Ишеткән бар, — диде Давыт җитдиләнеп, — багана башыннан егылып имгәнгән монтерның өзелгән аягын урынына тегеп куйгансыз, дип сөйләгәннәр иде. Халыкның монда ашкынуы юкка гына түгел.

Иңнәренә халатлар салдылар да эчкә керделәр. Түрдәге зур залның диварына ясалган сурәтне күргәч, Давыт бераз туктап карап торды. Ошатты.

— Агачның җанын тоеп ясаган, — дип куйды. — Шундыйның кечерәген үз өемә дә элеп куяр идем.

— Куптарып кына алып булмый, — диде Фидая.

Палаталардагы искелек, тузганлык нык күзгә бәрелде. Ишекләр какшаган, почмакларда штукатурка купкан, тимер караватлар тутыккан. Тынчу ис килә. Әмма керүчеләрне күрүгә, урыннарыннан кузгалышкан ак күлмәкле, ак ыштанлы ирләр бик канәгать күренделәр.

— Хәзер рәхәт, җылы бирделәр бит, — диештеләр. — Моннан берәр атна элегрәк килгән булсагыз, катлы-катлы юрган астыннан безнең кызарган борыннарны гына күрергә идегез. Җылысы булгач, калганын Билал булдыра инде!

Баш табиб түр почмакта тезен чәнчеп утырган чандыр карт янында тукталып алды.

— Хәлләр ничек соң, Халик абый?

— Рәтләнә кебек инде, — дип, аяк йөзендәге бәйләвечне чишеп, җәрәхәтен ачып күрсәтте абзый. — Монда кергәндә, йодрык сыярлык иде бит, хәзер күгәрчен күкәе хәтле генә калды.

Читләре кызарып шешкән зур җәрәхәтне күргәч, Фидая ихтыярсыздан күзләрен йомды.

— Трофическая язва, — дип аңлатты баш врач, Давытка карап. — Сугышта яралануның нәтиҗәсе.

— Әйе, Курск дугасының истәлеге, — дип җөпләде карт. — Әледән-әле ачылып тора. Бер чүлмәк балчык сыяр моңа диярсең.

— Төзәтүен төзәтәбез, чарасын табабыз, — диде Билал, караңгы коридорга чыккач. — Ләкин ярты елдан яңадан ачыла. Тагын яткырып дәваларга туры килә.

Янәшә ишек артында кинәт кенә гармун сыздырып җибәрделәр. Барысы да сискәнеп куйды. Көй бик дәртле иде һәм шунысы белән мондый ямансу җирдә сәер тоелды.

— Җиһансылу апа шулай моңая безнең, — дип көлеп куйды Билал. — Сәлам биреп чыгабызмы?

Һәм, җавап та көтеп тормыйча, хатын-кызлар бүлмәсенең ишеген ачты. Түр тәрәзә буендагы караватта өлкән яшьтәге бер хатын башын хромкасының күрегенә терәп диярлек утырган иде, кергәннәрне күрмәде, «Әнисә»не сыздыруында булды: «Тыпыр-тыпыр биергә тимер идәннәр кирәк...» Әйтерсең лә ул караватларда кайсы ятып, кайсы утырып торган хасталар арасында түгел, аулак өйдә утыра, кызларны-егетләрне биетә...

Бүлмә бусагасын беренче булып атлап кергән Фидая, Давытка борылып:

— Җиһансылу апа Баллыболынныкы бит... — дип башлаган иде — киселеп калды. Егетнең карашы гармунчыга, дөресрәге, гармуннан аскарак карават кырыена, аяклар буласы урынга төбәлгән. Ә анда бушлык... Авылның шушындый кешесе — ике аяксыз ялгыз карчыгы да барлыгын яңа рәискә әйтеп өлгермәгәннәр иде әле, күрәсең. Әйе, беренче күргәндә шаккатыра, хәтта имәндерә шул бу, Фидая үзе дә нәкъ шушылай өнсез калган иде.

— Җиһансылу апа, син монда безнең авыруларны, вакытыннан алда сикертеп торгызып, биетмәкчеме әллә? — диде Билал. Аның тавышында үзенә бер якын итү, хәтта соклану чалымнары сизелде. Гармунның кызыл күреге авыр ыңгырашып җыелды.

— Күрми дә торам, кунаклар бар икән, — диде апа. — Исән-саулармысез!

— Кунакның иң олысын алып килдем мин бүген, — диде Фидая. — «Үзәк»нең яңа председателе бу, Җиһансылу апа. Исеме белән генә дәшәсеңме, Давыт Зиннәтович, дисеңме, хәтереңә сеңдереп кал. Моннан ары, ни кирәк булса, аннан гына сорарсың.

Аннары әле дә аңын җыя алмый басып торган Гаяровка борылды:

— Җиһансылу апа — фашистларны җиңгән батыр ул безнең. Икенче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены бар аның, медальләре күп. Зенитчы булган ул. Польша өчен сугышканда яраланган...

Һәм берничә авыз сүз белән апаның язмышын аңлатып бирде. Ул сугышта чакта әтисе фронтта һәлак булган, әнисе монда үлеп киткән, йортта бер сеңлесе генә торып калган. Җиһансылу аяксыз гарип булып әйләнеп кайткач, шактый еллар икесе бергә яшәгәннәр. Тик менә узган елны сеңлесе дә вафат булган...

— Безнекеләр нишләп яталар анда? — дип сабырсызланып, аның сүзен бүлдерде Җиһансылу. Тавышы яшьләрчә чиста, йомшак аһәңле, ягымлы яңгырады. Анда зарлануның, мескенләнүнең, үзен кызгандырырга тырышуның әсәре дә юк, ул үзенең кыяфәтеннән һич тә читенсенми иде шикелле. Хәер, күз карашыңны йөзенә генә төбәсәң, кемнән ким соң әле ул? Чөеп куйган ак яулыгы астыннан шома итеп, икегә аерып таралган көмеш чәче күренеп тора. Зәңгәр күзләренең карашы җете, үткен, якты, ак йөзе, сулган булса да, тирән сырлар белән бозылмаган, бит очлары шома, күз тирәләре, ирен читләре генә җыерчыкланып тора. Гомумән, аның яшьлектә бик чибәр булганлыгы сизелә, үз чордашлары арасында ул әле дә матурлардан иде. Фидаяның Гаделша абзый, Наилә апа, Мөнирә һәм башка авылдашлар турында әйткән сүзләрен йотылып тыңлаганда, апаның йөзе тагын да ныграк яктырды.

Палатадан чыккач, Давыт нәрсәгәдер абынып егыла язды: дүрт тәгәрмәчкә беркетелгән такта кисәге булып чыкты бу. Аяксыз кешеләрнең җирдән кул белән этәреп тәгәрәтеп йөри торган арбасы.

Күрше ишектән Гөлфия килеп чыкты.

— Нишләп мондый әйберне аяк астында тотасыз? — диде аңа Билал, арбага ишарәләп. Аның тавышы ризасыз, хәтта кырыс яңгырады.

— Җиһансылу апа шунда куярга куша, бүлмәне ямьсезли, бүтәннәрнең күңеленә тимәсен, ди, — диде Гөлфия тыныч кына һәм, чит кеше алдында ире белән сүзгә килүдән сагаеп, шундук кире кереп китте.

— Әллә шуңа утырып йөриме? — диде Давыт. Сугыш кырында яраланган, батырлыгы өчен орден белән бүләкләнгән хатынның җирдә шул рәвешле үрмәләп йөрүе аның башына сыймый иде. — Рәтле коляска бирмиләрмени?

— Бирәләр, ник бирмәсеннәр, — диде Фидая, үзен гаепле сизгәндәй. — Аңа да биргән булганнар. Тик коляскасы нинди бит аның. Үзе ипсез, үзе чәрексез, ике-өч елдан тарала да төшә.

— Нишләп алай? Бездә кешеләрне космоска очырырга өйрәнделәр бит инде, гарипләр өчен җайлы арба ясый белмиләр микәнни?

— Германиядә бик әйбәтләрен ясыйлар икән, дип ишеткән бар да бит, — дип сүзгә кушылды Билал. — Баскычтан менеп-төшеп йөреп була, диләр. Тик андыйны безнең монда күргән юк шул.

— Сугышта җиңелгән нимескә арбаның баскычтан менеп-төшеп йөри торганы, аны җиңгән Җиһансылуга кисеп ташлаган такта башы дигән сүз түгелме соң бу?

— Нишлисең, безнекеләрнең күңеле күктә шул, Америкадан югарырак сикерәселәре килә, бөтен көч шуңа китә. Ә Германиянең дәүләт башындагылар иң беренче чиратта үзенең халкын күз уңында тота, — дип ачынып җавап бирде Билал.

— Шәһәрдә дә менә шушындый тәгәрмәчле такта кисәкләренә утырып, кулы белән этеп йөргән гарипләрне күргәнегез бардыр бит, — диде Фидая. — Ул бит әле шәһәрдә шулай! Андагыларга чиратка басу да, артыннан йөрү дә җиңелрәк.

— Чираты шулай зурмыни?

— Икешәр-өчәр ел көтәләр.

— Ватан сугышы ветераннарына чиратсыз гына бирмиләрмени соң?

— Аның чиратында күпчелек шундыйлар бит. Мин эшкә килгәч, Җиһансылу апа өчен бөтен кирәкле документларны тутырып, Казанга илткән идек, тиз генә булмас, аңа биргән идек бит инде, монда бер тапкыр да алмаганнар буа буарлык әле, диделәр.

— Нәрсәгә барып төртелсәң дә шул бит инде, — диде өметсез тавыш белән Билал. — Протез заводыннан хат килеп төште әле менә. Берәрсенең аягына ампутация ясарга туры килсә, тездән түбән унбиш сантиметр калдырып кисеп алуыгызны үтенеп сорыйбыз, дигәннәр.

— Ни дигән сүз инде бу? Теге абзыйныкы кебек, аяк йөзе генә эштән чыкса да, тездән кисеп ыргытырга кушмыйлардыр бит?

— Нәкъ шулай. Чөнки протезларны конвейерда эшләү җайлы. Бөтенесен бериш итеп ясыйлар да килгән кешенең кулына әзерне тоттырып кына җибәрәләр. Алай итсәң, аяксызларның чираты кимиячәк, диләр. Халыкны кайгырталар!

Соңгысы Давытны тәмам аягыннан егар дәрәҗәгә җиткерде, ул ике кулы белән башын тотып чайкап торды:

— Ай-яй! Менә нинди адәмнәр утыра бит безнең баш өстендә!..

Урамга чыккач, ул күкрәген тутырып дымлы, салкын һаваны сулады да ертык болытлар арасыннан аеруча чиста, якты булып күренгән зәңгәр күккә карады. Йә Алла, дөньяның барча мәшәкатьләренә, авырлыкларына, һәр көн иртән сәгать биштән торып эшкә килүгә, басуларда саз ерып йөрүләргә, механизаторлар белән телләшүләргә, төн йокламый бу яңгыр кайчан туктар икән дип тыңлап ятуларга, атнага бер район җитәкчеләре каршына барып, мине бастырып тиргәмәсә ярар иде, дип эчтән калтырап утыруларга — һәммәсенә-һәммәсенә түзәргә риза, тик менә шушындый диварлар арасына, кысан, котсыз бүлмәләргә генә кереп ятарга язмасын!

— Һава авыр сезнең анда, — диде ул.

— Хаста булган җир хуш исле булмый инде ул, ресторан түгел, — диде Билал. — Тик сез курыкмагыз, зур кешеләрне гомуми палатага салмыйбыз, аерым бүлмәгә урнаштырабыз без. Телевизоры да бар, суыткычы да, башкасы да. Хәзергә буш түгел, андагы авыруны борчып йөрисе килмәде, шуңа күрсәтмәдем. Әгәр минем кул астына кереп тикшерелеп аласыгыз килсә, бер дә икеләнеп тормагыз.

Моңа Давыт йөзен генә җыерып куйды.

Бина эчендә гармун авыл көен сыздырып җибәрде.

— Бу апа кем белән яши соң хәзер? — дип сорады Давыт.

— Караучысы юк шул әле, — дип җавап бирде Фидая.

— Картлар йортына урнаштырырсыз инде алайса.

— Анда барасы килми. Ризалыгын бирми, — диде Фидая.

— Без дә кат-кат үгетләп карадык инде, — диде Билал уфтанып. — Дәвалыйсын дәваладык, безнең эш төгәлләнде. Ләкин чыгарып җибәреп булмый. Дүрт ай ята инде. Андыйларны асрарга шартлар да юк бит бездә. Мунчабыз да юк хәтта.

Давыт баш табибка гаҗәпләнеп карады:

— Больницага мунча нәрсәгә?

— Айлар буе ятучылар бар бит, кайсыларын кузгатырга да ярамый, өйләренә кайтып юынып килә алмыйлар. Булсын гына иде әле! Мунчаның шифасы да зур бит аның. Менә дигән дәвалау чарасы ул.

Билалның тавышында өметсез хыялга бирелгән кешенең чарасызлыгы ярылып ята иде.

— Мунчаны да проблемага әйләндермик инде, иптәшләр! — диде ияген чөеп Давыт. — Аны инде һәр хуҗалык үзенә салып куя лабаса.

— Дөрес әйтәсез, Давыт Зиннәтович, — дип күтәреп алды Фидая. — Ирләр аерым, хатыннар аерым керерлек итеп салсаң, әллә ни зур булмаса да ярый бит ул. Монда ятучылар ул хәтле күп түгел. Әйдәгез, эшләгез әле бер яхшылык!

— Мин үземчә аның планын да сызгалап куйган идем инде, — диде Билал, бик үк кабынып китмичә.

Шунда Давыт үзенең җилкәсендәге саллы йөк өстенә тагын бер зур бүрәнә китереп салачакларын аңлап алды. Тайпылырга, бу хакта бүтән сүз кузгатмаслык итеп кырт кисәргә кирәк иде. Әмма хәтер калдырмыйча гына каршы әйтерлек сүзләр тиз генә табылмады. Ә бәлки, күгәреп төс җуйган диварлар артыннан килеп ирешкән моңлы көй телгә уралгандыр. Нечкә моң иркен дөньяга чыга алмый яткан мөлаем апаның җан авазын күңелләргә күзгә күренмәс нурлы күпер аша китереп ирештерә, үзәкне өзә иде. Бу дөньяда безне көннең көнендә әвәрә иткән бихисап мәшәкатьләрдән өстенрәк нәрсәләр бар. Колхоз бухгалтериясендәге кәгазьләргә тезелгән саннардан, һәр иртәне телгә килә торган рация тартмасыннан мөһимрәк нәрсәләр бар бу тормышта. Ул менә шушы — безне яклап сугышканда аягына һич төзәлмәс яра алган моңсу һәм риясыз карашлы абзый, хисләрен моңга урап, тар диварлардан ургытып чыгарган Җиһансылу. Әгәр без алар турында, ярдәмгә мохтаҗ башкалар хакында онытабыз икән, ни мәгънә итнең-сөтнең күбәюендә, отчет кәгазьләрендәге саннарның зураюында?

Нурханова, шушындый тойгыларга бирелеп, кызып-кызып сөйли башлады:

— Хәзер үк урынын билгеләргә, җир катканчы нигезен салып куярга кирәк. Чүгендер беткәч, кешеләрен табу да җиңел булыр.

— Аны котельный тирәсенә куйсакмы әллә дигән идем, — диде Билал. — Торбаларны ерак сузасы булмас.

— Котельный яны булдымы мунча өчен урын! — диде Давыт. — Андый эш кузгатканда, илле метр торба кызганып торалармыни. Булгач-булгач булсын инде ул, матуррак урын сайларга кирәк. Әнә теге агачлар артында бик ямьле бит! — дип, урам якка, юлның икенче ягындагы тупыллар ышыгындагы чирәмлеккә таба кулы белән изәде ул. — Әйдәгез карап килик әле!

Аның, алдан уйламыйча, аркылысын-буен үлчәмичә генә, төкерек салдым, сикереп чык, дип каударланып эшкә ябыша торган гадәте юк-югын. Ләкин бу юлы ни сәбәптәндер үзе дә сизмәстән мавыгып китте.

Урам аша чыкканда, Билал, Давыт кире уйлый күрмәсен дигәндәй, туктаусыз сөйләнеп барды:

— Шартлар булмау ул безнең эшкә төрле яктан китереп суга бит. Врачлар, сестралар моннан таярга гына җай эзләп йөри. Эшкә өйрәтеп кенә өлгерәбез, китәләр дә баралар. Әле менә бездә эшләп киткән берсен Казанга баргач очраттым. Менә дигән анестезия сестрасы булып өйрәнеп җиткән иде. Китте, тотып кала алмадык. Шәһәргә барып, телефон станциясенә урнашкан. Эше дә җиңел, акчасы да күбрәк, ди... Болай барса, без мәңге кадрларга тиенә алмаячакбыз. Җитәкчеләр ни уйлыйдыр. Алар да кеше бит югыйсә, ә кеше дигәнең, бу дөньяга килүгә, иң элек безнең кулларга килеп керә...

Давыт, сәерсенеп, чыннан да, аның кулларына күз салды. Күп юганга һәм дарулар белән эш иткәнгә күрә, Билалның куллары ап-ак, хәтта бераз зәңгәрсуланып тора иде.

«Күпме кешеләрнең бу дөньяда яшәве-яшәмәве шушыларга бәйле булган һәм булачак бит», — дип уйлап куйды Давыт.

# 23

Иркәне балалар бакчасына алып барганда, Фидаяга һәр иртәне диярлек Мирхуҗинның күксел «Жигулие» каршы була. Ул машинасын бер тынга туктата да, эшләпәсен артка шудырып, башын тәрәзәдән суза, кулын үзенчә нәфис хәрәкәт белән болгап, елмаеп сәлам бирә:

— Исәннәр генәмесез! — ди. — Ничек йокладыгыз? Нинди төшләр күрдегез?

— Саумысез, — ди Фидая салкын гына.

— Кичә сезнең сарайның түбәсен ябарга җибәргән идем мин анда. Әйбәт эшләгәннәрме?

— Рәхмәт. Больницаның түбәсе кайчан ябылыр икән? Ул тирәдә күптән күренгәнегез юк, диләр. Җитәкләп алып барыйммы әллә?

— И-и, Фидая Госмановна, таптың! Миндәй егетләр белән парлашып хастаханәгә баралар димени? Башка берәр җиргә чакырсаң иде син!

Иркә мондый ямьсез кинаяләрне аңларлык түгел әле, әмма нәни күңеле нидер сизә, әнисенең бу абый белән сөйләшеп торганын яратмый, кулыннан тарта:

— Әйдә инде, әни! Әйдә инде!

— Бүген Кармашка бригада җибәрәсезме? — дип, мәсьәләне кабыргасы белән куя Фидая.

— Карарбыз, Фидая Госмановна, тәртибегезгә карарбыз...

— Мин дә карармын сезнең тәртипне. Кичке якта анда булам!

Соңгысы ялгышрак ычкынды, Тависның моны нәрсәдер вәгъдә иткән кебегрәк аңлавы ихтимал иде. Кичләрен тиз караңгы төшә, ә төннәрен бергәләп юл йөргәндә ни булмас...

Каршысында башка берәү басып торса, Фидая бу сүзен шундук төзәткән булыр иде, ләкин бу юлы, Мирхуҗинның көенә торырга кирәген исендә тотканга, эченнән: «Әй, теләсә ничек аңласын сана, тик эшне генә туктатмасын», — дип уйлады да Иркәне җитәкләп китеп барды.

Хәлбуки аның Кармашка кичке уңайда баруының бик җитди сәбәпләре бар иде: иртә-көндез ул өченче секретарьга йөкләнгән төп вазифаларын башкарырга тиеш. Алда бик зур эш тора: ел әйләнәсендәге иң зур бәйрәм — Октябрь революциясенең чираттагы еллыгы якынлаша. Аның ничек оештырылуына карап, мәдәният хезмәткәрләренең хезмәтенә бәя бирелә. Һәр авылда һәм район үзәгендә тантаналы җыелышлар, алдынгыларны бүләкләүләр, кичә-концертлар үткәреләчәк, аларга алдан ук әзерләнергә кирәк. Культура бүлегенә генә салынып торып булмый. Райондагы егерме ике авылның һәрберсенә кат-кат барып, һәр клубтагы эшнең тамырына төшәргә. Аның мөдирләре һәммәсе дә Каләмгөл кебек булса икән лә! Тегене эшлә дә моны болай ит, дип, күрсәтмә биреп, өйрәтеп йөрергә кирәк тә булмас иде. Тик андый тагын берәү районда гына түгел, республикада да бөтән юктыр шул.

Аның төзәтеп-үзгәртеп булмый торганнары: клубларны җылытырга йә котельныеның көче җитмәү, йә ягулыгы булмау, музыка коралларының җитешмәве, кайсыберләрендә баянчының да булмавы... Акча кытлыгы...

Кыскасы, кичкә таба баш тубал булгач кына, Фидаяга үз күңеленә төп эш дип беркетеп куйган төзелешне барып карарга мөмкинлек туа.

Тависның аягы авыр булып чыкты, ул көнне авыллардагы хәлләр бик тә ачуны китерде. Бер клубында сәхнә такталары череп убылып төшкән, икенче авылның баянчысы эчеп ята, репетиция ясый алмыйлар...

Кармашка барып кергәндә, Фидаяның бер дә кәефе юк иде. Тәрәзәләрендә тонык кына ут янган бинаны әйләнеп, аның артындагы төзелеш мәйданына чыккач, утырып елыйсылары килде: монда кыл да кыймылдатмаганнар иде.

Йа Раббым, бу төзелеш гел Фидаяга гына кирәкмени соң? Ник баш табиб Газимов әзрәк булса да кайгыртмый, ник шул Мирхуҗин белән уртак тел тапмый? Ул аның үзе өчен, эше өчен кирәк!

Фидая, ярсуын тыярга тырышып, иске бинаның арткы ишегеннән кереп зал аша узды. Ни хикмәттер, анда һичкем юк, телевизорны да кабызмаганнар. Гадәттә, машина килеп туктаган тавышка йә Газимов үзе, йә Гөлфия чыгып карый торганнар иде, бүген алар да күренмәде. Өлкән медсестра бүлмәсендә дә кеше юк иде. Ниһаять, операция бүлмәсеннән ак чүпрәк башлыгын маңгаена ук төшергән, кашы-күзе җимерелгән Гөлфия килеп чыкты.

— Исәнме, Гөлфия.

— Хәзергә исән әле...

Фидая аның дорфалыгын сизде, ләкин илтифат бирмәде, чөнки үзе артык гасабиланган иде.

— Баш врач кая? — дип сорады ул, каты гына итеп.

— Юк баш врач! Хасталар гына калды хәзер монда.

— Ничек юк? Берәрсенең өенә киттеме әллә?

— Урам буйлап чабып йөрерлек хәле бар дип беләсеңме әллә син аның? — диде Гөлфия, ачулы пышылдап.

— Рәтләп кенә аңлат әле, бу ни дигән сүз?

— Синең теләгең кабул булды дигән сүз бу. Ни теләгән идең соң син аңа, ә? Әллә оныттың дамы?!

Ул, каты-каты басып, бүлмәсенә кереп китте дә аннан халат белән тапталган башмаклар алып чыкты.

— Бик беләсең килә икән, мә, ки!

Андый чакта тыелырга кирәк иде. Кара-каршы әйткәләшү дәрәҗәне генә төшерә. Фидая пальтосын, беретын салып, залдагы урындыкларның берсенә куйды, халат киде.

Гөлфия операция бүлмәсенең эчтән ак пәрдә корылган тәрәзәле ишеген ачуга, Фидаяның тезләре йомшап китте, ул, хәле бетеп, ишек борысына ябышты. Анда, таныш тар ятакта, салкын, ялтыраган тимер аппаратлар астында берәү ята кебек күренде.

— Син нәрсә, Гөлфия, кешенең котын алып йөрисең? Беркемне дә кертмә, дидем бит мин сиңа...

Билалның йомшак тавышы иде бу. Ятак буш, анда фәкать ак җәймә генә күпереп ята. Билал исә дивар буендагы өстәл янында утыра. Кулын өстәлгә куйган, аңа кан салу аппаратының нечкә көпшәсен тоташтырган. Тамырына дару сала икән. Менә ул беләген мамык кисәге белән кысты да энәне тартып алды, аннары торып халатын тарткалады. Фидая аңына килә башлаган иде инде.

— Чирләп киттеңмени? — дип сорады ул.

— Профилактик чара гына бу, Фидая Госмановна. Авырып китмәс өчен генә.

— Нигә яшерәсең? Әйт дөресен! Көн аралаш система астына кереп утырганыңны белеп торсын! Күңеле булсын! Сөенсен! Теге чакта, хәтерлисеңме, ниләр әйткән иде ул сиңа? Ничек каргаган иде?

— Гөлфия, — дип, хатынының беләгеннән тотмакчы булды Билал. — Томана карчык түгел ләбаса син! Адәм көлдермә!

— Көлүдән узды монда эшләр! Чирен яшергән үлгән, ди, беләсеңме син шуны? Начальникларга син эш аты гына! Атны да бит бер генә арбага җигеп була, сине берьюлы икегә дә җигәләр, өчкә дә! Каян килгән ул төзелеш мәшәкатен хирург сыртына салу? Ник алайса Мирхуҗиныгыз операция ясамый? Әнә Суташтан бер кызны китереп салдылар бүген, бит уртасына чуан чыккан, тула да тишелә, тула да тишелеп ага икән. Район врачларына ике ел йөргән, рәтләнмәгән. Егет карарлык җире калмаган мескеннең. Хәзер елап монда килде менә. Билал шундыйларны карасынмы, ташчыларны көтүләсенме?.. Аңа нинди нервы чыдасын да, ул кеше ничек чирләмәсен? Үз ирең бик кадерле иде бит, кешенеке булгач, хәленә керү дигәннең әсәре дә юк!

Фидая Гөлфияне бу хәтле чыгырыннан чыга торган хатын дип башына да китермәгән иде. Ул күптәннән тыелып килгән, ире өчен борчылуы күңелендә чуан булып тулышкан һәм шушы минутта кинәт тишелгән иде. Гөлфия күз яшенә сулыгып кычкырынды да кычкырынды, Фидая исә җавап бирмәде, башын иеп басып торды. Бу минутта Гөлфиянең кичерешләрен аннан да ныграк аңлаган кеше булыр иде микән. Нәкъ шушы урында бервакыт ул да бит, үзен-үзе белештермичә, ниндидер рәнҗүле, каргышлы сүзләр кычкырган иде. Билалга чыннан да начарлык теләгәнгәмени? Ирен югалту хәсрәтеннән зиһене чуалганга...

Каршы сүз әйтүче булмагач, ямьсез кыланганы Гөлфиянең үзенә дә, ниһаять, барып җитте, ул, битен куллары белән каплап, йөгереп коридорга чыгып китте. Бүлмәдә кара-каршы басып калган Фидая белән Газимов бер тын һуш җыеп тордылар. Бераздан Билал:

— Сез аңа ачуланмагыз инде, — диде. — Явызлыгыннан түгел, аңлыйсыздыр.
— Бик аңлыйм, — дип җавап бирде тыныч кына Фидая. — Сиңа җитди дәваланырга кирәк, димәк.
Билал көлемсерәде:
— Сез врач түгел бит, Фидая Госмановна. Дәвалану мәсьәләләрен без үзебез карарбыз инде.
— Авырган табибны башка табиб карарга тиеш бит. Казанга барып, тикшерелеп кайтырга кирәктер. Аның ишене сузарга ярамый, иртәгә үк китсәң дә була.
Билал елмаеп башын чайкады.
— Иртәгә үк булмас, Фидая Госмановна, — диде.
— Нишләп булмасын? Балкыш белән барырсыз әнә. Иртүк килеп алып китәр.
— Иртәгә минем операция ясыйсым бар. Бая Гөлфия бите шешкән кыз турында әйтте бит әле?
— Үлем чире түгелдер ләбаса. Кайткач карарсың.
— Юк инде, алай булмый. Мин аны бүген рентгеннан карадым, диагнозын ачыкладык. Аңа теш тамырыннан инфекция кергән. Иртәгә иртән теш врачы тешен ала, аннары миңа, операция ясап, зарарланган каналларны чистартырга туры киләчәк. Бик җаваплы операция. Яшь кызның бите ул! Мин аңа бүген вәгъдә бирдем инде. Ул болай да күпме вакыт газапланган, Казанга китеп барсам, дөньясы җимерелгәндәй булачак.
Үзеңә зыян киләсен белә торып, башка берәүгә яхшылык кылуны китапларда бик мактыйлар мактавын да, ләкин бу дөрес гамәл микән? Билалның соңгы сүзләрен тыңлаганда, Фидая шул хакта уйлап куйды. Ләкин табиб барыбер үзенекен итәчәк иде, шуңа күрә бәхәсләшеп тормады, тагын бер тапкыр сәламәтлеген кайгыртырга киңәш бирү белән чикләнде.
Көзге кара төнне ерып Суташка кайтканда, ул үзенең тәмам берьялгызы калганлыгы турында уйлады. Гөлфия хаклы, хәзер инде төзелеш эшендә Билалдан ярдәм көтеп булмаячак. Битарафлык дәрьясында берьялгызы йөзәргә чыккан иде Фидая, һәм бу дәрьяның ярлары күренми иде. Аңа ямансу, бик ямансу булып китте.
...Иртәгәсен кызын бакчага илткәндә, ул урамның уртасыннан түгел, койма кырыеннан барды, каршыга килгән таныш «Жигули»ны да, аннан сузылып сәламләгән кулны да күрмәмешкә салышты, хәтта өзек-өзек сигнал тавышын ишетмәгән булып кыланды.
...Райкомның беренче секретаре Искәндәров эшенә гадәттә иртәнге җидегә килә. Коридорда аны ике-өч кеше көтеп тора торган була. Нәкъ шушы вакытта хуҗаны тотып, гозереңне әйтеп калсаң гына. Җәгъфәр Латыйпович аларны аяк өсте генә, шул ук вакытта игътибар белән тыңлый. Ләкин вәгъдәләр бирергә ашыкмый, чөнки халыкны бу рәвешле үзеңә ияләндерергә ярамаганын ул яхшы белә. Аң булырга кирәк, юкса һәр иртәне райком ишеге төбенә су буе чират тезелеп басачагын көт тә тор.
Бүлмәсендә ул районның «Сельхозтехника», «Агрохимсервис», «Гидромелиорация» кебек зур предприятиеләре җитәкчеләрен генә кабул итеп сөйләшә. Андыйларның зур хуҗа белән генә хәл итеп булырлык мәсьәләләре чыгып кына тора. Ул арада авыл хуҗалыгы идарәсендә кызу эш бара: бөтен колхозлардан кичә күпме сөт савылган, күпме ит тапшырылган, һәр бозауның һәм дуңгыз баласының авырлыгы ничә граммга арткан, шикәр заводына күпме чөгендер озатылган — һәммәсе турында мәгълүмат алып, таблицаларга язып куялар һәм бу күрсәткечләрне алдагы көн белән чагыштыралар: үсеш бармы, әллә артка китеш күзәтеләме. Сәгать сигез тулганчыга кадәр бу саннар Беренченең өстәлендә ятарга тиеш.
Сигездә аның кабинетында киңәшмә башлана. Анда совет власте кешеләре — район башкарма комитеты, авыл хуҗалыгы идарәсе мөдире, башкалар белән беррәттән идеология секретаре да була. Узган көнгә нәтиҗә ясала, алдагы эшләрнең иң мөһим дигәннәре ачыклана. Юл уңаеннан кайберәүләргә сүзләрнең ачыларын тыңларга туры килә, шунлыктан, киңәшмә бетеп таралышканда, кемнәрнеңдер сөмсере коелган, башы иелгән була.
Хуҗа янында банк директоры гына кала. Алар шактый озак бикләнеп утыралар. Ни сөйләшәләр — анысын үзләре генә белә. Һәрхәлдә, банкка кергән һәр тиен хуҗада исәптә тора, аның рөхсәтеннән башка бер сум да акча чыкмый. Аларның әңгәмәсен кайчак телефон гына бүлә: өлкә комитеты эшен башлый. Хәер, бу сәгатьтә әле Казандагыларга кайсы районда күпме уңыш җыелып, күпме сөт савылганы, күпме ит тапшырылып, дуңгыз-бозауларның ничәшәр граммга артканы турындагы мәгълүматлар барып ирешә генә башлаган була. Алар, шул саннардан чыгып, нәтиҗәләрне соңрак ясыйлар һәм күрсәткечләре кимегән районнарның җитәкчеләрен тыкырдатырга керешәләр.
Өлкә комитетыннан шылтыратулары ихтимал булуын истә тотып, райком секретарьлары гадәттә сәгать уннарга кадәр үз урыннарында утыра. Шуннан соң инде Искәндәровны тотармын димә: район буйлап чыгып киткән булыр. Ул юкта райком бинасы да тынып тора.
Ыгы-зыгы кичке бишләргә таба куба. Көтелмәгәндә килеп чыккан хәлләр, кыенлыклар турында шул сәгатьтә сөйләшеп, киңәшеп алырга була. Райкомның беренче секретаре Искәндәров, ягъни Беренче,

өченче секретарьдан, ягъни Нурхановадан, идеология-пропаганда өлкәсендә эшнең торышы турында шушы вакытта сораша, зарларын тыңлый.

Ә Фидаяның исә аның белән иртәнге якта, иң мөһим, иң кирәкле мәсьәләләрне хәл иткәндә сөйләшәсе килә иде. Мирхуҗин дигән чыгымчы атны, авызлыклап, хастаханә төзелешенең арбасына җигәргә кирәк, ә моны Беренче аша гына хәл кылып була иде.

Тик көннең башында Искәндәров эре хуҗалар — хөкүмәтнең байлыгын кулында тоткан кешеләр белән генә эш итә иде шул. Ә идеология секретареның кулы буш бит аның. Бар байлыгы — тел. Үзенең шул тел тегермәнен әйләндереп, халыкның күңелен партия идеологиясе дигән тузан белән томалап, бастырып торырга тиешле кеше ул. Идеологияне исә һәммәсе кайгырта, җитәкчеләрнең барысы да коммунистлар, шунлыктан өченче секретарьның эше җиңел дип санала һәм нәкъ шуңа күрә дә ул урынга еш кына хатын-кызларны сайлап куялар, дөресрәге, менгереп утырталар. Моның исә үзенә бер яхшы ягы бар: җае туры килгәндә, менә бит, без хатын-кызларны җитәкче урыннарга күтәрәбез, дип мактанып алырга була.

Боларны яхшы белгәнгә күрә, Фидая саллы хуҗалар арасында үзенең урыны бик тыйнак икәнен, аны җитдигә санамаганнарын аңлый иде. Әмма ул үз алдына гайрәтле ирләр кулыннан гына килерлек олы максат куйган һәм, морадына ирешер өчен, аңа Беренче каршында үзен ирләрчә тотарга, хатын-кыз икәнлеген онытып һәм оныттырып торырга кирәк иде.

Иркәне бакчада калдырып эшкә килгәндә, ул хәзер үк Искәндәровка бәреп керергә ниятләгән иде. Хатын-кызның үз өстенлеге бар: ямьсез сүз белән йөзенә бәреп яисә типкәләп чыгарып җибәрә алмыйлар. Ир кеше, үзләренчә әйткәндә, «гүзәл зат» каршында әдәп сакларга мәҗбүр. Шуннан файдаланып, әйтәсе сүзеңне әйтергә, һәм, ничек кенә булса да, Беренченең башын үз ягыңа борырга кирәк. Шундук Мирхуҗинны чакырып алсын да хастаханә төзелешен өзеклексез алып бару турында күрсәтмәсен бирсен!

Фидая кичтән дә, иртән дә алда торган сөйләшү хакында уйлады, иң үтемле сүзләр эзләде. Эш бүлмәсенә кереп, пальто-беретны салгач, ботинканы туфлигә алыштырырга, чәчне рәтләргә дә, туп-туры коридорның түрдәге затлы башына барып, алгы бүлмә аша, Беренченең ишеген ачарга. Секретарь кыз Фәүзия авызын ачып сүз әйтә башласа, колак салмаска.

Ләкин андый тәвәккәллек кылырга туры килмәде. Фидая үз бүлмәсенең йозагын ачып азапланганда, эчтән телефон зыңгылдаганы ишетелде. Трубкадан секретарь Фәүзиянең нечкә тавышы ишетелде. Җәгъфәр Латыйпович Фидаяны үзе чакыра иде.

Фидаяның ямансу җилле-болытлы, шомлы күңел күге ачылып, кояш төшкәндәй булып китте. Иртә таңнан кирәксенә икән, төзелеш өчен борчылуы түгел микән? Хуҗаның бусагасын атлап кергәндә, Фидая чыраена тәвәккәллек тә, ризасызлык та, эшлекле кыяфәт тә бирергә тырышты һәм көр күңел белән сәлам бирде:

— Саумы, саумы, — диде Искәндәров. — Утыр әле, Фидая Госмановна.

Һәм нәкъ менә Фидаяның бәгыренә шырпы булып кадалган Мирхуҗин турында сүз башлады. Хәзер инде сөйләшү үзеннән-үзе төзелешкә барып ялганырга тиеш иде...

Әмма... Беренченең исенә төшкән нәрсә бөтенләй башка булып чыкты. Баксаң, Мирхуҗинга кырык яшь тулып килә икән. Төзү-монтаж идарәсе начальнигының юбилее якынлаша! Олы бәйрәме!

— Кайчан туган соң ул? — дип сорады Фидая.

— Моны мин сиңа түгел, син минем искә төшерергә тиеш идең, — диде Җәгъфәр Латыйпович, кашын җыерып. — Сигезенче мартта туган ул. Бәйрәмнәр, кичәләр оештыру турыдан-туры синең вазифаңа керә ләбаса. Иң элек шуны кайгыртырга тиеш син. Ә төзелеш өчен Тавис иптәш җавап бирер.

Хуҗаның бу кинаясе бик яхшы аңлашылды: Кармаш хастаханәсенең яңа бинасын, аның мунчасын салу артыннан гына йөрисең, үз эшеңне җиренә җиткереп башкармыйсың дигәнне аңлата иде бу. Хәзергә йомшак кына. Ләкин әгәр дә Нурханова бу сүзләрдән сабак алмаса, райком бюросына куеп тикшерү дә ерак йөрмәс. Ә анысы инде хәтәр — бюрода тикшерү гадәттә эштән азат итү белән тәмамлана, ә эшеннән куылган кеше бүтән мантымый. Шуңа күрә җитәкчеләр өчен иң куркынычы — бюрога куелу иде... Бик җитди кисәтү бу. Ләкин Фидая коелып төшмәде.

— Аңарчы дүрт ай яшисе бар бит әле! — диде гаҗәпләнеп. — Юбилей кичәсе оештырырга гына җитешербез!

Җәгъфәр Латыйповичның чырае тагын да кырысланып китте.

— Юбилей ул, башта җыелыш җыеп, аннары табын корып, матур сүзләр сөйләү өчен генә түгел. Дәүләтнең зур бүләген тапшыру өчен дә бу форсатны файдаланып калырга кирәк. Ә орден, медаль яки берәр мактаулы исем бирү өчен документларны ким дигәндә ярты ел алдан әзерләп тапшыру зарур.

— Әгәр дә минем фикеремне беләсегез килсә, мин ул Мирхуҗинның туган көненә район башкарма комитетының грамотасын тапшырыр идем дә, шуңа өстәп, бер тартма конфет белән бер бәйләм чәчәк

бирер идем. Анысы да артык әле аңа! — дип тыела алмыйча, хисләнеп, тавышын күтәрә төшеп әйтеп куйды Фидая.

— Эшләгән кешенең кадерен белергә кирәк! Ничә авылда мәктәп, ничәсендә культура йортлары салдырды, Суташның үзәген бөтенләй үзгәртеп төзеде!.. Нишләргә икән? Орден сорыргамы? Аның инде «Почет билгесе» ордены бар. Зуррагына тәкъдим итәргәдер, бәлки. Әллә «РСФСРның атказанган төзүчесе» дигән исем сорыргамы? Аның андый исеме дә бар барын, тик Татарстанныкы гына. Обкомга илтәсе документларны төзегәндә, ике якны да бик нык уйларга кирәк. Бирмәстәйне сорарга да ярамый, алырдайны алмый калу да начар. Мирхуҗинның рәнҗеп калуы бар...

Җитәкчесенең сүзләрен баш иеп тыңлаганда, Нурханова күңелендәге ризасызлык хисен тыярга тырышты. Тынычлан, Фидая, тынычлан, дип, ике кулының бармакларын аралаштырып, авырттырып кысты. Ул Мирхуҗин аласын алды, талыйсын талады, гадел күзлектән караганда, суд каршында басып торырга тиешле адәм дә бит... Ләкин аның белән булышырга ярамый... Борыныңны гына җимерәчәксең... Андыйларның юлына аркылы төшүдән Алла сакласын... Берәр кыек сүз ычкындырганыңны гына ишетсә дә, Кармаштагы хастаханәнең нигезе мәңгегә шулай тырпаеп торып калачак.

Ул арада Җәгъфәр Латыйпович сүзен дәвам итте. Бүләкләү өчен документларны Нурханова тутырып бирергә тиеш икән. Сүзләрнең шундыйларын табарга кирәк ки, рәсми кысага да сыйган булсын, шул ук вакытта чын йөрәктән кайнап чыкканы да сизелеп торсын.

— Шундый итеп язарга кирәк: өстәгеләр укыгач, тәкатьсез булсыннар, сораганны бирми калмасыннар, — дип нәтиҗә ясады Беренче.

Ул арада Фидая ныклы бер карарга килгән иде инде. Искәндәровтан чыгуга, ул Мирхуҗинга шылтыратты:

— Миңа кирәгез әле. Хәзер үк!

Озак көттермәде Тавис, чаж итеп килеп тә керде. Кыска итәкле пальтосының төймәләрен ычкындырып, ап-ак күлмәге, карасу кызыл галстугы, күксел буйлы венгр костюмының якасы күренерлек итеп изүен ачып җибәрде, күк эшләпәсен арткарак шудырды. Аннары Фидаяның каршысына җәелеп утырды да, майлы күзләрен ярык кына калдырып кысып, авызын киң ерып, мәгънәле итеп елмайды.

— Сезгә болай кылану килешми, — диде Фидая салкын гына. — Чын җитәкче кешенең күзе ачык, авызы йомык булырга тиеш.

— Анысы бит аның үз кул астында эшләүчеләр янында шундый булырга кирәк! Аны гына беләбез, — диде Тавис, өстәл аркылы Фидаяга таба авыша төшеп. — Монда бит бөтенләй башка! Кояшка бит күзне киереп ачып карап булмый! Сине күргәч, минем күзләр үзләреннән-үзләре камаша, авыз үзеннән-үзе ерыла. Миннән сорап тормыйлар!

Ләкин алда торган юбилей, шул уңайдан бүләк сорау турында сүз башлауга, егет алыштырып куйгандай булды: сыны турайды, пальто изүләре җыелды, күзләре түгәрәкләнеп ачылды, калын иреннәре кысылды. Ах, нинди кодрәткә ия бу орден дигән тимер кыйпылчыгы һәм синең исем-фамилияң куелып, мактаулы исем бирелде, дип язылган, кызыл папкага салынган кәгазь бите! Шуны алыр өчен ничек тырыша гайрәтле егетләр һәм бирми калсалар, ничек коелып төшә алар! Шуларга өстәп, бераз акча бирсәләр ни әйтер идең. Анысы да юк бит, ичмасам!

Мирхуҗинга тагын бер орден кирәк икән. Түшенә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены тагып йөрү турында хыяллана икән ул.

Кыскасы, тәти бирәм дигәч, ипләнде дә куйды егет. Иртәгәдән Кармашка ташчылар бригадасы җибәрергә, кирпечен, измәсен, бөтен кирәк-ярагын үз вакытында илтеп торырга вәгъдә бирде.

Ләкин әгәр дә эшлекле сөйләшү тәмамланганнан соң тыныч кына кузгалып чыгып китсә, Тавис Тавис булмас иде шул. Ул Фидаяның йөзенә мәгънәле итеп, өздереп карады да:

— Их, Фидая Госмановна, син мине исем йә бүләк өчен тырыша дип беләсеңме әллә? — диде. Аның калын тавышы ничектер калтыранып куйды хәтта. — Әгәр дә алай уйлыйсың икән, бик нык ялгышасың. Дан-дәрәҗә артыннан куа торганнардан түгел мин. Кешеләрнең чын күңелдән әйткән рәхмәте, ихтирамы — минем өчен бүләкнең иң зурысы шул. Әгәр дә без бер-беребезне аңлашып яшәсәк, шуннан артык ник кирәк тагын?

Һәм ул, калкына төшеп, Фидаяның өстәлгә куйган куллары өстенә үзенең зур, симез кулын салды. Аркасына сирәк, эре кара төк үскән, дымлы, салкын уч бармакларны чиркандырды, күңелдә җирәнү хисе кузгатты. Әмма Фидая тыелды. Түзәргә кирәк иде, беразга түзәргә...

Мирхуҗин чыгып киткәннән соң, Фидая авыр уйга чумды. Документларны, Беренче кушканча, өстәгеләрне тәкатьсез калдырырлык итеп язарга туры килер анысы, сүз дә юк. Ләкин аның белән генә Тависны үз ягыңа авыштырып булыр микән? Ул теләгәнне булдырып булмый, күңелен йомшартуның башка бер чарасын табарга иде. Әйтик, туган көненә истә калырлык бүләк биреп була. Үз исемеңнән. Тик

нинди бүләк? Гел күз алдында тора торган әйбер булсын иде ул... Әһә, сәгать бирергә кирәк аңа. Кыйбатлыны, затлыны, районда юкны эзләп табарга да үз акчаңа сатып алырга. Аннан гына бөлмәссең. Вакыт та җитәрлек... Фидая күңеленнән Казандагы танышларын барлый башлады. Кем шундыйны табып бирер икән?

Ә күңеле ничектер арусызланган кебек иде. Бу кер тышкы якта түгел, эчтә, аны кул юган кебек кенә юып алып булмый. Ләкин чистарынасы килә иде. Фидая телефонны алды да «Үзәк»кә шылтыратты. Ул таныш тавыш ишетелгәнен көтте. Тик трубка, колакны ертып, озын-озын чинады да чинады. Фидая гүяки ике араны тотыштырган озын чыбыклар аша кызыл телефон аппаратын күргәндәй булды. Аны гына түгел, бер-берсенә «т» хәрефе ясап терәтеп куелган ике озын өстәлне, алар янына һәм дивар буйларына урындыклар тезелгән иркен генә бүлмәне, аның почмагында үскән каен гөлен күз алдына китерде ул. Бүлмә буш, аның хуҗасы урам як капкадан кереп кенә килә. Ул бүлмәсендәге кызыл аппаратның сузып-сузып зыңгылдаганын ишетми, әмма күңеле сизә, шуңа күрә ашыга, эре-эре атлый. Менә ул өйнең почмагыннан борыла. Бу турыда өй түбәсеннән тутыккан торба сузылып төшкән, аның очы җирдән ике метр чамасы биеклектә. Әле өченче көн генә, шушы урыннан узганда, Давыт, Фидаяга борылып: «Сак булыгыз! Башыгызны бәрә күрмәгез!» — дип көлгән иде. Һаман шул баласытуы инде! «Үсәм әле мин, үсәм!» — дип җавап биргән иде аңа Фидая. Бинаның ишеге янына зур гына плакат эленгән, анда мич авызыннан бөркелгән ялкын телләре сурәтләнгән, эре хәрефләр белән: «Мичең төзек булмаса, янгын чыгуын көт тә тор», — дип язылган.

Әгәр бу минутларда Фидаяның йөрәгендә үрләгән ялкын теле күзгә күренсә, бер дә шул плакаттагыдан ким булмас иде.

— Алло! Гаяров тыңлый!

Давыт әллә чыннан да урамнан ашыгып килеп кергән иде инде, сулышы капканы сизелде. Фидая тиз генә җавап бирә алмады, тавышы өзелеп китүдән шикләнде, йөрәге шулкадәр тигезсез тибә иде.

— Алло! «Үзәк» тыңлый!

— Нурханова бу. Нихәлләр бар анда?

— Тәртип, Фидая Госмановна.

Давытның тавышы тынычланды, шул ук вакытта гадәттәге җылы көлемсерәү белән өртелде.

— Ә мунчаның бурасын кайчан китереп куясыз?

— Борчылмагыз, Фидая Госмановна, озак көттермәбез. Тәнгә мунча булыр ул, җанга гына юк менә!

Монысына җавап табып булмады, әмма ризалашасы да килмәде, чөнки бар иде ул җанга мунча! Давытның шифалы тавышы күңелдәге керне юып алды, җанны сафландыргандай итте.

## 24

Язгы җил, Наиләнең ятимлеген, яклаучысы юклыгын белгәндәй, ихата аша аерата өздереп, кистереп исә иде кебек. Дөрес, өй артыннан алай ук дуылдап, иркенләп үтә алмый үзе, чөнки анда мәрхүм хуҗа утыртып үстергән биш-алты төп алмагачның нык кәүсәләре, тармаклы ябалдашлары каршы тора. Алар, өйне ышыкларга тырышкандай, шәрә ботакларын шифер түбә өстенә үк сузып салганнар. Ә менә ишегалды ягы бөтенләй ачык, андагы тавык кетәге, кар базы өстендәге куыш, хәтта мунча да елдан-ел искерә, иңә бара, җил алар өстеннән уйнаклап кына уза. Ул абзар-кура, койма тирәләренә ышыкланган бозлы карны да берничә көн эчендә ялмап алды, аның астыннан корыган тигәнәк, кычыткан сабаклары тырпаеп килеп чыкты. Алар ятимлек сагышын тагын да көчәйтеп җибәрде.

Иртән эшкә киткәндә дә, көндезге чәйгә кайтканда да, Давыт аларга карап-карап уза, йолкып ташларга һаман кулы җитми иде. Көннәрнең берендә ул, өенә кайткан арада, урман хуҗалыгыннан нарат һәм каен үсентеләре алып килде. Наратлар кыска булса да, ныкча, яшел, куе бөдрә, ә каеннар озынга тартылган, нәзек кәүсәле, күгелҗем бөреле иде.

Аяз, салкын, җилле бер иртәдә, нәрәт биреп кайткач, Давыт койма буендагы кураларны, ниһаять, йолкып алды. Көрәк алып чыгып, ике-өч селтәнүдә чокырлар казыды һәм урам капкасыннан сул якка өч нарат, уңга өч каен утыртып та куйды. Каен сабаклары янына нечкә казыклар кадап бәйләде, нарат төпләрен таптады.

— Катырак басасың түгелме? Тамырларын өзеп бетермә тагын! — диде чиләк белән су алып килгән Наилә.

Ир кешенең ихатаны тутырып, иркенәеп йөрүе хуҗалыкка ямь керткән, йортның абруен күтәргән иде, һәм хуҗабикәнең бу бәхетне түкми-чәчми татыйсы, гайрәтле ирнең эшенә кысылып, өйрәтеп, үзенең хуҗа икәнлеген искәртеп, хокукларыннан файдаланып каласы килә иде. Ир-атның аяк астында буталып, комачаулап һәм үзендә юк акылны аңа биреп йөрмәгән хатын-кыз үзен чын кеше дип санамый да шул ул.

Ә Давыт дәшми, үз эшен белә: Наилә сузган чиләкне алып, үсенте төпләрендәге юеш кара туфракка су коя. Ул да, көздән бирле гаиләсеннән аерым яшәгәнгә һәм өй эчендә Наилә апа мыштым гына йөргәнгә күрә, хатын-кызның аяк астында чуалуына зарыккан, шунлыктан апакайның ат дагалаганда бака ботын кыстыргандай өйрәтеп маташуы бераз гына эчне тырнап куйса да, дөньяны түгәрәкләндереп җибәргәндәй итә иде. «Каеннар яфрак яруга, Фазилә белән Алмаз да монда булыр инде», — дип уйлады ул. Әллә кайчан алып килгән булыр иде дә, авылда председатель өчен салына торган яңа йортны әлегәчә өлгертеп җиткермәделәр. Өлгерткән дә булырлар иде, балта осталары көзен янган Фаязларга һәм Гыйззетдиннәргә өй җиткерергә ярдәм иттеләр, аннары Кармаш хастаханәсенә мунча салдылар. Кыш уртасына эшчеләр бушаган иде дә, мең мәшәкать арасында Давыт йортка нигез салдырырга оныткан булып чыкты, туңган җирне актарттырырга исә намуссынды.

Инде менә идарә белән янәшә ихатада нигез салынды, әзер бураны шуның өстенә китереп утыртасы гына калды. Агачлар шаулап яфрак яргач, иншалла, түбә астына да керелер. Давыт та ике авыл арасында буталудан котылыр, фатирда түгел, үз өендә яши башлар. Фазиләдәй киңәшчең, ярдәмчең гел янәшә булса, яшәү дә, эшләү дә күпкә җиңелрәк бит ул.

Давыт суның туфракка сеңеп беткәнен көтеп торды да агач төпләренә берәр көрәк черемә салды, аннары, Наиләгә яны белән торган килеш, күтәрелеп карамый гына:

— Чыршының табигате кырыс аның, — дип куйды. — Урынның ныгын, туфракның тыгызын ярата. Тамырлары җиргә никадәр ныграк берексә, шулкадәр тизрәк тернәкләнә.

Уйлары исә бөтенләй башкада иде Давытның. Иртән ферма мөдире Хәбир скотник Фаяздан зарланды. Ике көн инде эшкә чыкмый икән теге, сыер савучылар онны гына түгел, силосны, саламны да сыртларына салып ташыйлар.

Давыт көрәген болдыр кырына сөяп куйды да, иелеп, кушучын Наилә кулындагы комганның борынына сузды. Өтеп алырлык салкын су белән битен, муенын ышкыды, рәхәт сискәнеп, ах итеп куйды.

Өйгә кереп чәй эчкәннән соң, бераз ятып ял итеп алды да Фаяз янына барып килергә булды.

Ишмуллиннарның такта белән тышланган, кыйгач буйлар ясап аклы-зәңгәрлегә манылган йорты, биек зәңгәр койма өстеннән сигез тәрәзәсе белән берьюлы балкып, урам ягына начальник кебек кукраеп карап тора иде.

Иске йортларының янып китүе хәерлегә генә булган икән диярсең, һәммәсен зурдан, яхшыдан торгызып куйганнар. Ишекләре утыздан ким түгелдер!

Соңгы елларда урыс капкалар модадан чыгып бара, күпләр аны койма биеклегендә генә ясыйлар, тик аерылып торсын өчен, булдыра алганча бизиләр. Фаяз үзенең зәңгәр капкасының уртасына зур-зур ак ромашкалар ясаган. Давыт кече капканың келәсен күтәреп эчкә узды. Иң беренче күзгә ташланганы — уң кулда ишегалдын нык кысрыклап, сузылып яткан нарат бүрәнәләр булды. Биек итеп өйгәннәр дә, таралмасын өчен, өч җиреннән юан тимерчыбык белән тарттырып бәйләп куйганнар. Түрдә, ихатаның бөтен киңлеген иңләп сузылган яңа сарайлар янында, араларына кирпечләр кыстырып өйгән такталар биегәеп тора. Почмакта тугарылган туры алаша арбадан печән чемченә, сарай эченнән дуңгызлар чинаганы, мыркылдаганы ишетелә. Бер сарайның ачык ишегеннән ике яшь үгез башын сузган. Ай-һай нык мантыган бу хуҗа! Тагын бер йорт җиткерерлек мая да җыеп куйган! Әйтәләр иде аны, бер яктан үзе колхозныкын аты белән ташый, икенче яктан Суташта шофер булып эшләүче малае кайтарып аудара, дип. Хак икән. Әле бер төнне электр баганалары өчен әзерләнгән агачларны чәлдереп алып кайтканнар дип тә ишетелгән иде. Әмма Давыт бу хәтле үк дип белми иде.

Сулдан, биек йортның ачык тәрәзәләреннән шаулашкан тавышлар ишетелде. Давыт сузылып пыялага чирткәләде. Өйалдының калын такталардан ясалган таза ишеге ачылды, болдырга футболка белән спорт чалбары кигән Фаяз чыгып басты.

— Кара, нинди олы кунак килгән безгә! Өй котларга килдеңме әллә, Давыт Зиннәтович? Рәхмәт инде. Үзебез дә чакырырга торадырыек. Озакламый өй туе ясыйбыз, Алла боерса.

— Син нишләп бу вакытта өеңдә утырасың? — дип сорады Давыт кырыс кына.

Фаязның кызарынган киң чыраенда, сары кашлары астындагы күзләрендә сагаю чагылды, ләкин сорауны шаяруга бормакчы булды:

— Үз өемдә утырмыйча, күршегә кереп утырмам бит инде, — диде.

— Сәгать ничәдә фермада булырга тиеш әле син?

Фаяз болай да бүлтәеп торган корсагын тагын да киеребрәк басты.

— Хәлең ничек, дип сора син башта, иптәш прсидәтел, — дип акыл өйрәтергә кереште. Давыттан шактый өлкән, яше кырыктан узган булганга, ул моңа тулы хокукы бар дип саный иде, ахрысы. — Давай да давай дип, эш кешесенең бугазына басып куалый торган заманалар узып бара бугай бит инде. Скотник

кына дигәч тә, без ата баласы. Кешечә булырга кирәк. Аш өстенә килеп кергәнсең икән, табынга уз. Аштан олы түгелсеңдер.

Давыт аның ачулы, тәкәббер чыраена карады да үзенең зур хата ясаганын аңлады: монда килеп йөрисе түгел, Фаязның үзен тагын бер тапкыр идарәгә чакыртасы калган. Килми кала алмас иде, чөнки авылда яшәгән кешегә җитәкче белән санашмый мөмкин түгел. Әмма хәзер чигенергә соң иде шул инде.

— Син телеңә салынма, сораганга җавап бир, — диде Давыт, мөмкин кадәр таләпчән тавыш белән. — Кайда булырга тиеш син бу сәгатьтә?

— Ә мин нәкъ тиешле урында бүген, бик беләсең килсә! Шулхәтле авырлыклардан соң тернәкләнеп кенә килгән чак. Пермьнән туганнар кайтып төште. Аларга кадер-хөрмәт күрсәтергә тиешме мин? Отпускыда дип санагыз мине. Гомергә бер тапкыр скотникка да ял бирелергә тиештер.

— Йортыңны торгызганда атналар буе эшкә чыкмадың, аны санамыйсыңмыни?

— Анысы аның янган өчен бирелде. Стихийный бедствиегә дучар булган өчен. Һәм, гомумән, фирмедән китәргә ниятләп йөрим әле мин. Йөгенгәнче бушка эшләү туйдырды инде. Гарык!

Фаяз кул кырые белән таза ияге астыннан кыска муенын сызып күрсәтте.

— Йортыңны сыртыңа салып китәрсеңме әллә? — дип сорады Давыт. Ул үзенең ваклана башлаганын тойды. Тагын шунысы да бар иде: болдырдагы Фаяз нык калкып тора, бу хәл үзе үк кешеләргә өстән карарга күнеккән Давытны кимсетә иде кебек.

— Нәрсә, әллә йортым-нием белән авылдан сөрер иденме? Элекке прсидәтел кебек ут төртмәкче түгелсеңдер бит?

Кыскасы, сүз базар хатыннары кебек әрепләшүгә әверелде. Өйалдының ачык ишегендә ике-өч ят ир-ат күренде. Әле дә ярый хатыны Фәния чәчрәп килеп чыкмады, фермада булгандыр, бәлки. Йорттан берәү генә булса да колхозда ныклап эшләргә тиеш бит инде. Сыер савучы Фәния шул вазифаны үти иде.

Һәрхәлдә, Давытка борылып чыгып китүдән башка чара калмады. Һәм бу — абруйга бик каты сугачак, гомумән, эштә чигенүнең башы булачак иде. Үз сүзен сүз итә алмаган җитәкче белән кем санашыр икән? Ул, ярдәм эзләгәндәй, як-ягына каранды.

— Законнарны яхшы беләсең, димәк? — диде, тешен кысып.

— Син уйлаганча ук шыр надан түгелбез!

— Алайса болай: законга киткән икән, законча булсын. Син безгә шушы агач материалларына булган документларыңны күрсәт әле.

Фаязның болай да кызыл чыраена бурлат төсе иңде. Ул, юан бармаклары белән болдырның нәзек, шома терәгенә тотынып, алга авышты, гүяки председательнең өстенә сикерүдән чак кына тыелып тора иде.

— Ә синең ни эшең бар анда? — диде ул, хырылдаган тавыш белән. — Болар миңа янгыннан соң йорт салырга бирелгән. Хөкүмәтнең ярдәме!

— Өч йортлык материал бирелдеме сиңа?

— Кеше ихатасындагы милекне санап йөрергә прокурор түгелдерсең. Тентергә праваң юк!

— Ә менә бар минем правам. Халык контролеры мин, беләсең килсә.

Давыт чалбарының арткы кесәсеннән кызыл катыргы тартып чыгарды:

— Менә!

Авыл кешесе аның ишедән уттан курыккандай курка — ничек кенә әтәчләнсә дә, Фаязның кикриге шиңә башлаганы сизелде. Алай да тиз генә җебеп төшәргә исәбе юк иде әле.

— Кара аны! Мыскал белән үлчи торган мал түгел! Нахак яла яккан өчен дә суд бар! — дип мыгырданды ул.

— Аны гына үлчи беләбез!

Давыт борылып урамга чыкты да капка төбендәге «уазик» янында басып торган шоферы Мөҗипкә:

— Бар әле, Әхсән белән Гаделша абыйны алып кил тиз генә, — диде.

Ишегалдыннан Фаяз сөйләнеп чыгып килә иде:

— Урман арасы түгел бу сиңа! Син анда, лесхозда, кем эләксә шуны тотып яптырырга өйрәнеп беткәнсеңдер дә бит, монда алай итә алмассың...

Бусы чын нахак иде — Давытның берәүне дә суд каршына бастырганы булмады. Ләкин сүз көрәштерү артык озынга киткән иде, шуны аңлап дәшмәде, авыл очына таба китте. Мөҗипне көткән арада, зират турыннан әйләнеп килергә булды.

Ярый әле, партоешма секретаре да, ревкомиссия председателе дә өйләрендә булган икән, озак көтәргә туры килмәде. Фаяз, йомшак табигатьле, нечкәрәк тавышлы Әхсән Вәлишиннан куркып тормаса да, җыерчыклы йөзен картузы белән күләгәләгән Гаделшаны күргәч, шым булды.

Мәсьәләнең асылын карт ике сүздән аңлады. Бүрәнәләргә карап:

— Ничек үлчибез? — дип сорады.

Лесхоздан калган гадәте буенча, Давыт машинасында җыелма метр йөртә, картка шуны кертеп бирде. Гаделша, метрны сүтә-сүтә, бүрәнәләргә таба атлады, аның кулында боргаланып озынайган елтыравык нечкә тасма Фаязга зәһәр елан кебек тәэсир итте. Аның тиз арада әкияттәге дию кебек баеп китүенә Гаделшаның болай да эче пошып йөргән, күрәсең, ул бу эшкә бик теләп алынды.

— Артыгын нәфесләнәсез шул, — дип сөйләнде үзе. — Харам малның очы барыбер төртеп чыгасын уйламыйсыз... Тот әле, — дип, метрның очын Әхсәнгә таба сузды. — Үлчәргә икән, үлчик.

— Син дә йөрисең шунда, кирәкмәгәнгә кысылып, — дип ысылдады Фаяз теш арасыннан. — Районнан килеп, колхозның күпме итен алып китәләр, ник анысын бер дә күрмисең? Ә миңа килеп тырнак астыннан кер эзлисең!

Тик картның күптән бирчәйгән тиресен аның чише кылчыклар гына тишә торган түгел, ул метрын бүрәнә өеменә аркылы сузып салды. Низаг ни белән тәмамланыр иде, билгесез, капкадан, кызу-кызу атлап, Гыйззетдин килеп керде.

— Исәннәрмесез! — диде ул, көр тавыш белән. — Нихәл, күрше! Безгә әйтмичә генә өй туе үткәреп ятасыңмы әллә? Гаделша абый, син нишлисең анда?

Ишегалдындагы киеренкелек кимеде, әлегәчә, бу хәлләр ни белән төгәлләнер икән инде, дип сагаеп басып торган кешеләр җиңел сулап куйдылар.

— Җыелыш җыйдыгызмы сез әллә монда? — диде Гыйззетдин, Давытка таба борылып.

— Җыйдык шул. Фаяз үзе идарәгә килми, без килдек менә. Сөйләшергә кирәк бит.

— Фермада эшләр сөйләшүдән узган анда! Бүген Каләмгөл терлекчеләр белән политчас үткәрергә тиеш иде, гәзитләрдәге соңгы яңалыкларны аңлатырга. Хатыннарның бөтен ачуы аның башына төшкән. Имгәнеп бетәбез инде авыр эштән, диләр. Фаяз туган, син монда ике кулыңны кесәңә тыгып торма, тиз генә алашаңны җик тә хәзер үк фермага барып җит, югыйсә хатыннарның бөтенесен төяп үзеңә алып киләм!

Гыйззетдиннең шушы сүзләре белән һәммәсе хәл ителде дә куйды. Давытка скотникның эшкә баруы гына кирәк, Фаязның бөтен теләге исә — бүрәнә-такталарның исәбен алырга ажгырган председательдән котылу иде. Ул, гадәтенчә һаман әле мыгырданып, атына таба юнәлде, Давыт исә машинасына чыгып утырды.

Шулай итеп, председательнең сүзе сүз булды шикелле. Тик күңелдә ачыту калды. Бу авылга килгәч, эчкә сызлавык чыгып, әкренләп үсә барды. Чарасызлыктан, алдагы көнгә өметсезлектән килеп чыккан чир иде бу, күрәсең. Эш җайга салынган бер тәртип белән, көйле итеп түгел, ә сикәлтәле, хәтта тирән-тирән чокырлар белән бүлгәләнгән юл аша бара шикелле. Фермаларда азык җитмәү, трактор-комбайннарның искелеге, запчасть юклык... Инде кеше җитмәү, ир-атның эчүен әйткән дә юк. Авыл хуҗалыгында эшне болай да алдан билгеләп куйган план буенча гына алып барып булмый, табигать китергән көйсезлекләр генә күпме: шагыйрь әйтмешли, җиле дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында яуса, ни әйтер идең дә, алай булмый бит ул! Өстәгеләрнең, бүген фәлән литр сөт савыгыз, төгән центнер ит тапшырыгыз, фәлән гектар чөгендер чәчегез, дип күрсәтмә биреп торулары, планнарның ничек үтәлүе хакында көн саен хисап таләп итүләре тагын... Шуның өстенә адәм баласы бер-берсенә генә түгел, үзенә-үзе аяк чалудан туктамый. Көннең көнендә, башка таш төшкәндәй диярлек, берәр тәртипсезлек, күңелсезлек булып тора. Беренче айларны Давыт, тора-бара үзем дә буразнага төшәрмен, авыл халкы белән дә уртак тел табылыр, эшләр җайга салыныр, дип уйлаган иде. Ләкин бу колхоз дигәнең җайга салына торган нәрсә түгел, ахрысы. Көн саен иртән торуга, бүген кайсы яктан китереп орырлар да, тәгәрмәчем кайсы төштә чокырга барып төшәр дип яшәп булмый бит инде. Игенчелекне алга этәр, терлекчелекне текә күтәр, печән әзерләгәндә дә, кукуруз эшкәрткәндә дә, зур уңышларга ирешү өчен көрәш. Ә инде уракка төшсәң, син урып-җыю фронтында. Аңа кеше ничек чыдасын!

Һәм чыдамыйлар да. Ничек тә булса чыгып качу ягын карыйлар.

Үзе авыл баласы булса да, бирегә килеп, бу эшкә тарыганчы, Давыт хәлләрнең мондый да мөшкел икәнен белмәгән икән. Өстән өсте-өстенә мәгънәсез күрсәтмәләр килеп торганын, председательгә үз акылы белән эшләргә бернинди мөмкинлек бирелмәгәнен, барысыннан да бигрәк, хөкүмәт тарафыннан авылның бу кадәр таланганын белмәгән, шуның белән бәхетле булган икән ул. Ә менә Фаяз кебекләр аңлыйлар, мөмкин булганда, һәрнәрсәне үзләренә ташу ягын карыйлар. Хәер, барысы да шул инде. Савучылар иртәнге савымнан соң сөт тутырган резин грелкаларны билләренә бәйләп, бөрмәле чалбар балакларына он яки комбикорм тутырып кайталар. Скотникларның арба төбенә аннан күбрәк сыя, билгеле. Көз көне капка төбенә кайтып туктаган комбайнда бер-ике центнер бодай булмаса, ул механизаторны шыр тилегә санарлар иде. Зур җитәкчеләр, боларның һәммәсен белгәнгә күрә, авыл халкына хезмәте өчен акча түләргә кирәк бит, дип борчылмый, хуҗалыгында бәрәңге үстереп, мал асрап көн күрер, җитмәгәнен колхоздан чәлдерер, дип исәпли булса кирәк.

Авылда бөтен тормыш шуңа — бармагың орынганны үзеңә тартуга корылган. Яңа председатель, иң беренче эш итеп, үзенә йорт салдыра, райком секретаре да иң элек үзенә яхшы торак булдыру ягын кайгырта. Балаларын урнаштыра, туган-тумачага да ярдәм итү ягын карый...

Болай яшәп, бу ил кая барып чыгар икән? Менә шундый уйлар тынгы бирми иде Давытка соңгы вакытта. Бу хакта берәр бик тә мәнле һәм гамьле кеше белән ачылып сөйләшәсе килә иде аның. Ләкин мондый борчуларыңны теләсә кемгә ачып салып булмый. Фазилә белән дә уртага салып сөйләшә торган сүзләр түгел бу. Барма анда, дип әйткәнием бит мин сиңа, колхозчы көтүләп йөрергә үзең ашкындың, дип кенә җибәрәчәк.

Коммунист кеше өчен зур гөнаһ булган бу уйланулары турында ул бер кешегә иркенләп сөйли алыр иде алуын. Ни гаҗәп, ул кеше — партия идеологиясе сагына куелган өченче секретарь Нурханова иде. Ул да илдәге шушы мәгънәсез кысаларда бәргәләнә, район халкына яхшылык эшлим, хастаханә салдырыйм, дип тырмашып йөри әнә. Аның бу максатына да гадел юл белән генә ирешеп була торган түгел, әгәр кагыйдә-тәртип белән генә барсаң, хастаханә тагын йөз ел шул арестантлар туктап ял иткән корылмада калачак. Шуңа күрә бичара хатын аны тегеннән-моннан йолкыштырып, булдыра алганны элэктереп төземәкче... Аның белән аңлашып булыр иде, күңел бушап калыр иде. Сер сыяр иде аңа... Ләкин кайда, ничек сөйләшергә? Икәүдән-икәү озаклап аулакта калу мөмкин түгел... Гайбәт чыкса, кереннән арына алмассың... Кер дигәнең бигрәк тә хатын-кыз намусына нык сеңә бит ул...

Төньякның язгы гөле кебек якты, җылы ул хатынга тузан да кунарга тиеш түгел иде... Шуңа күрә Давыт, очрашкан чакларда, аның бит очлары алланып китүен, күзләреннән моң сирпелүен, тавышының яңгырашы үзгәрүен күрсә дә, аннан да бигрәк, бөтен вөҗүденнән бөркелгән назлы дулкынның тирбәнешләрен һәм бөтен барлыгы бу дулкынга тетрәнеп җавап биргәнен тойса да, хисләрен тыярга, яшерергә тырыша, очрашканда, тизрәк читләшү ягын карый иде.

Ә кичләрен, бигрәк тә өйгә кайтырга соңарып Наилә апада кунып калган төннәрдә, уйларның очы һаман аңа барып тоташа... Ул хәзер дә «Үзәк»нең шефы булып санала бит югыйсә, нигә сирәк килә икән?..

Гадәттәгечә, көндез нык арылган иде, ләкин караватка ятып утны сүндергәч тә, күзгә озак йокы кермәде. Кинәт капка шыгырдаганы, ишегалдыннан лап-лоп адым тавышлары ишетелде. Давыт, сикереп торып, янындагы урындыктан спорт чалбарын алып кияргә чак өлгерде, кемдер өйгә килеп керде дә аның өстенә ыргылды.

Кече якта яткан Наилә, шакылдаган, ахылдаган, кычкырынган тавышларга уянып, утны кабызды да чаршау артыннан олы якка карады. Анда Давыт берәүнең аркасына менеп атланган да кулларын каерып тоткан иде.

— Аллаһемә, ни булды? Кем ул?

— Наилә апа, бау бир тизрәк!

Давытның бот арасында яткан адәм, каты мышкылдап, тузгыган башын боргалады.

— Фаяз түгелме соң бу?

— Тизрәк бул! — диде Давыт, сулышына буылып.

Наилә, мичкә аркасын сыдырып, идәндә мәш килгән ирләр яныннан ничек кирәк алай өйалдына чыкканда, юл уңаеннан ишек янындагы электр төймәсенә басып, утны яндырды. Каһәр суккыры, кирәк чакта бавы да тиз генә табылмый бит аның! Әһә, он капчыгы артына төшкән икән.

Давыт Фаязның кулларын артка каерып бәйләде дә тартып торгызды һәм баудан тоткан килеш җилтерәтеп алып чыгып китте. Наилә сәгать икеләргә кадәр аны көтеп утырды. Карчыкның сораулы карашына:

— Милициягә алып киттеләр, — диде.

— Кемнәр?

— Вәлишинны йокысыннан уятырга туры килде. Мөҗипкә утыртып җибәрдем.

— И-и, Давыт энем, алай итәргә кирәгие микән? Зәйни нәселеннән бит ул!

— Төнлә кереп суйганын көтиммени?

— Нишләп суйсын? Аларның кеше үтергәннәре юк. Тукмыйлар гына.

— Тукматыйммы?

— Тукматмадың бит инде. Артына каты гына тибеп чыгарып җибәрсәң, шул бик җиткән булырые. Анисы аның шул бәргәләшү исәбеннән үтә дә китә. Эшне милициягә җиткезү хәтәр бит ул. Үчен кайтармый кала торган нәсел түгел!

— Фаяздан да куркып торсам, кем санга суксын мине? — диде Давыт, үзалдына уйлангандай.

Наилә юкка хафаланган булып чыкты, иртәнге нәрәткә килүгә, Вәлишин кереп шуны әйтте: төнлә Суташка барып җитә алмаганнар, авылдан чыгуга, машина сүнгән, бензины беткән. Фаязның кулын

чишәргә туры килгән, машинаны өчәүләшеп этеп алып кайтканнар... Бу хакта сөйләгәндә, Вәлишинның йөзе сабыр, күзләре ихлас мөлдерәп карый иде.

Давыт, аның сабыйларча гөнаһсыз йөзенә текәлеп, бер тын дәшми утырды. Аннары:

— Таштимерова заманында ничегрәк иде соң ул? — дип сорады.

— Фаязны әйтәсеңме?

Әхсәннең какча ак йөзендә серле, шаян көлемсерәү кабынды.

— Һы... Тукмашмыйлар ые... Ызгышканнарын да ишеткән булмады.

— Нисаның сүзен тыңлый иде, димәк?

— Кем кемне тыңлагандыр инде, анысы безгә караңгы. Әмма серләре бик килешкән бит...

— Нәрсә-ә?

— Фаяз егет ул! Ә Ниса, ни дисәң дә, кыз-хатын... Шул теге янгын чыгар алдыннан бүлнискә эләгеп кенә хур булды. Әле дә серләре килешер ие...

Давыт керфек тә какмый Әхсәнгә озак карап калды. Ләкин аның үзен күрмәде, чөнки парторг әйткәннәр аның зиһенен таратып җибәргән, ул шушы яңалыкны акылына сыйдыра алмый азаплана иде. Әйе, иш ишен тапкан, ишәк к...н капкан, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул...

## 25

Ямьле җәйләр, кемнәр өчендер табигать кочагында ял итеп, ләззәт алу вакыты булса, авыл халкына чөгендер тәпкеләү газаплары алып килә. Йөзәрләгән гектарлы басуларны ким дигәндә ике тапкыр борынгыдан калган ысул белән, тәпке болгап эшкәртеп чыгарга кирәк. Бу эшнең торышы колхоз өчен дә, бөтен район өчен дә иң мөһим күрсәткечкә әверелә, аның ничә гектар эшкәртелгәне турында көн саен обкомга мәгълүмат биреп барыла. Мондый вакытта райком бинасы бөтенләй бушап кала: һәр җитәкче, үзенә беркетелгән хуҗалыкка барып, эшне кызулап йөрергә тиеш була.

Нурханова да иртәнге сигез тулганчы ук Баллыболынга килеп җиткән иде инде. Ул идарәгә кереп кенә чыкты, шундук председатель белән, аллы-артлы ике «уазик»ка утырып, басуга киттеләр. Әмма урам очыннан чыгуга, Балкышның машинасы чых-пых итте дә туктап калды. Алгарак киткән Гаяров та Мөҗипкә артка чигенергә кушты.

— Ни булды?

— Бензонасос тончыга, — дип, капотын ачты Балкыш.

Гаяров Нурхановага үз машинасына чакырды.

— Безнең арбага утырыгыз, безнең җырны җырлап барырсыз, — диде.

— Нихәл итәсең... Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың инде, — дип җавап бирде Фидая, аның бу сүзләрендә ихтыярсыздан эчке бер киная ишетелгәндәй булды.

— Министр урынына утырасызмы? Мин сезнең телохранителегез булырмын. Тән саклаучыгыз, ягъни.

— Минем кунагым булырсыз, дияргә кирәктер, — дип, Фидая Давыт ягындагы арткы утыргычка менеп утырды.

— Әгәр рөхсәт итсәгез, мин юлымны гадәттәгечә башлар идем.

— Ихтыярыгыз. Кунак хуҗаның ишәге, диләр, сезнең теләккә каршы килеп булмас.

— Алайса киттек Сидоровкага, — диде Давыт шоферы Мөҗипкә.

«Үзәк» колхозына кергән ике авылның берсе Сидоровка ике чакрымда гына. Биек тупыллар, киң ябалдашлы юан өянкеләр ышыгындагы сирәк йортлар тыгыз чирәм үскән киң урамның ике ягына иркенәеп утырганнар. Анда-санда оя-оя казлар чүпләнеп йөри, юл кырыендагы су колонкасы кырыена казык кагып, ала бозау бәйләп куйганнар. Калҗайган капка төпләрендәге эскәмияләрдә әби-сәбиләр, балалар утыра. Җәйге кояш бу тыныч, имин дөньяны игелекле нурлары белән коендыра иде. Саладан калага китеп гомер итүче бик күпләрне сагындыра, моңландыра, төшләренә кереп йөдәтә, «их туган ягым, балачагым!» дип уфтандыра торган күренеш иде бу. Арада бушап калган, тигәнәк, әрем баскан ихаталары, тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадаклаган кыйшайган өйләре дә булмаса, чын оҗмах диярсең!

— Мине монда куйганда, бу авылның ниндилеген рәтләп аңлатучы булмады, — диде Давыт, машинадан төшкәч. — Икенче көнне килеп карагач, кәеф бик кырылды... Һәр көнне мин монда иртәнге якта килеп китәм, кичкә хәтле башка мәшәкатьләр арасында бераз онытылсын өчен, юри шулай итәм.

Әйе, табигате бик ямьле булса да, авыл үзе чыраена үлем төсе кергән хастаны хәтерләтә иде: шөгыльсезлектән аптыраган балалар, кулларын тезенә салып оешып утырган карчыклар — саф һава сулап, шау-шудан колакларын тындырып торырга дип кайткан шәһәр кешеләре. Озак тормаслар, китеп барырлар. Алар артыннан әлегә чирәм чүпләп йөргән казларның түшкәләре дә, колгага бәйләнгән бозауның ботлары да кала тарафына озатылыр. Авыл урамы үле чыккан йорттай бушап калыр.

Аргы баштарак ике комбайн тора, яннарында ике абзый кайнаша иде. Алар, башларын күтәреп, запас частьлар юклыктан зарландылар.

Кире машина янына барганда, Давыт аларны мактап алды:

— Алтын куллы алты кеше алар монда, — диде. — Ут уйнаталар, кыр эшләренең яртысын башкарып чыккан чаклары була. Ә менә хатыннары турында алай дип әйтеп булмый. Мин инде, дуңгыз фермасын шушы яккарак авыштырсак яхшы булмас микән, дип тә уйлаган идем. Мондагыларга эше дә, ашы да булыр иде. Ләкин маржа түтәйләрнең берсе дә дуңгыз карарга дәртсенмәде. Кул гына селтәделәр! Исем китте...

Урамда аклы күлмәк кигән яланаяклы кыз күренде. Ул колонка янына барып, тимер таякка басты да, иелә төшеп, кояшта ялтыраган су агымына ак, йомры балтырын куйды. Салам төсле тыгыз, юан толымы аркасыннан шуып салынып төште. Бу күренеш Фидаяга Некрасовның шигырен хәтерләтте:

Шундый хатыннар бар авылларда...
Ярсып чапкан атны туктатырлар,
Дөрләп янган өйгә керерләр...

Менә сиңа ут уйната торган чибәркәй, менә аның гүзәл туган җире. Гөрләп яшәсен генә дә иде бит...

Яны белән баскан кыз үзенә якынаеп килгән кешеләргә күтәрелеп карамады.

— Здравствуй, Оля, — диде Давыт туктап.

— Здравствуйте...

Давыт йомшак кына итеп аның хәл-әхвәлен сораша башлады. Кыз Николаевкада урта мәктәпне тәмамлап кайткан гына икән. Әлегә нишләрен, кая барырын белми.

— Идарәгә килеп чык әле син, — диде аңа Гаяров. — Иркенләп сөйләшербез, киләчәгең турында бергәләп уйлашырбыз. Без, мәсәлән, сине бүген үк хисапчы итеп куя алабыз. Киләсе елга, направление биреп, укырга җибәрербез. Колхоз стипендиаты булырсың.

Кыз башын күтәрми, алтынсу чәч бөтеркәләре генә кояшта ялтырый.

— Ә сез бит клуб турында берни дә әйтмисез, — диде ул, ниһаять, әкрен тавыш белән.

Клуб хакында ни әйтмәк кирәк? Әнә ул, ерак та түгел, таш диварлары биегәеп тора. Ләкин тирәсенә котырып тигәнәк, кычыткан, шайтан таягы үскән, ишегендәге йозагы тутыгып беткән. Кичләрен анда килеп, җырлап-биеп күңел ачарга яшьләр юк. Армиягә киткән егетләрнең кайсылары туган ягын сагынып әйләнеп кайткалый, әмма алар да озак тормый, чөнки сүз кушарга кызлар юк.

Оля, председательнең чакыруына бер җавап та бирмичә, чак ишетелерлек тавыш белән саубуллашып китеп барды. Давыт аның артыннан моңаеп карап калды.

— Клуб кирәк аңа, — дип, авыр итеп көрсенде. — Ә менә быел мондагы мәктәп ябыла. Өч укучы өчен тулы бер мәктәп тотып булмый шул. Кемнәрдер хәлне шушы чиккә җиткергән, ә ябучысы мин булам. Гаяров председатель булып эшләгәндә, Сидоровканың мәктәбе ябылды, дип сөйләячәкләр. Менә нишләттегез бит сез дөньяны, — дип, һич көтмәгәндә каш астыннан Фидаяга төбәлеп карап тәмамлады ул сүзен.

— Кемнәр ул «без» дигәнең?

— Кызлар. Алар китмәсә, егетләр дә авылны ташлап качмас иде.

— Иркен, рәхәт яшәп булса, бәхетне читтән эзләмәсләр иде. Тормышның көйсезлегеннән кача бит алар. Бүгенге авыл шартларында бик табигый күренеш бу.

— Табигый дисезме? Авылларның таланып бетеп, мондагыдай уңдырышлы җирләрнең бушап калуы табигый күренешме, сезнеңчә?

— Җиргә алар үзләре хуҗа түгел бит.

— Кем хуҗа соң бу колхозның меңләгән гектар басуларына? Мин түгел бит инде! Мин монда көтүче итеп кенә куелган...

— Синме көтүче? Ә мин үземне көтүче дип торам тагын. Сине каравылларга җибәрделәр ләбаса мине.

— Илдә тәртип шундый бит... Безне куалаганнарның баш очында чыбыркы шартлатучылар тагын бар...

Шул рәвешле, капка төбендә утыручыларның һәм машина тәрәзәсеннән башын сузган шофер Мөҗипнең карашлары астында аз гына сөйләшеп торганда да, бу икәүнең сүзе бик тирәнгә, төннәрен Давытның йокысын качырган борчуларга барып тоташты. Ләкин күңелләрне тирәнрәк ачып, уйларны бүлешеп булмады, урыны, вакыты ул түгел иде. Фидая борылды да машинага кереп утырды.

Ун-унбиш минуттан алар басу читенә чыгып басканнар иде инде. Монда дөньяның иркенлеге аерата нык сизелде, битне талгын җил сыйпады, күктән тургай сайраганы ишетелде. Киң кыр, менә күрегез мине дигәндәй, җәйрәп ята, аның өстендә юлдан офыккача тар яшел тасмалар сузылган. Чөгендер тишелеп чыккан, матур гына булып үсеп килә. Тик аның рәтләре өстенә яшел челтәр җәйгәннәр диярсең, урыны-

урыны белән ул тоташ тукымага әйләнгән — бусы чүп-үлән, башлыча сарут, көне-сәгате белән күтәрелеп килә. Берничә көн эчендә утап чыкмасаң, чөгендерне басып китәчәк.

Шуңа күрә кызу эшкә керешкәннәр — басуда, бер-берсеннән шактый ара калдырып, хатын-кызлар сибелгән, тәпкеләре белән җил-җил селтәнеп, әкрен генә ары таба кыймылдыйлар. Фидая кулын маңгаена куеп текәлеп карады да иң кырыйда башкалардан шактый алга киткән берәүне танып алды. Урман полосасы янындарак ак яулыклы Мөнирә җилпенә иде. Ул һәр елны кишәрлекне басуның сулыннан ала. Уң якта, ачыклыкта, чуар итәкле Каләмгөл алга киткән. Бер-берсеннән шактый ерак булсалар да, җан-фәрман узышканнары әллә каян күренеп тора... Элекке елларны Фидая үзе дә мондый рәтләр арасында шактый казганды, тик беркайчан да теге икәүне узып китә алмады. Һәм ашкынмады да. Аларның үз узышы, үз ярышы. Уртадагы хатыннар бер тирәдәрәк баралар. Хәер, берсе нык алга киткән, теге көндәшләр белән тигезләнә язган бит. Озын буйлы, зәңгәр халатлы, шундый ук зәңгәр яулыклы ул хатынны Фидая танымады.

— Колхозчыларга — дүртәр гектар, хезмәткәрләргә берәрне бүлеп бирдек, — диде Гаяров. — Өлкән класс укучыларына яртышар гектар тиде. Җир күп бит, кеше аз. Һаман шул бер сүз инде.

Анысын аңлатып тормаса да була, бөтен авылларда да чөгендерне шулай бүлеп бирәләр. Халык авырсына, билгеле, үзара зарланыша, әмма аяк терәп баш тартучы сирәк. Чөнки чөгендер эшкәрткән өчен аерым, күбрәк хак түләнә. Акча белән булмаса, кышын шикәр белән бәхилләтәләр. Дөрес, бәясен базардагыдан шактый кыйбаткарак чутлап бирәләр бирүен, сатканда арзанракка китә, ләкин барыбер дә сыер савучыларның хезмәт хакыннан күбрәккә чыга. Шуңа күрә, эссе кояш астында бөтен гаиләләре, бала-чагалары белән бергәләп, социалистик ярышка чыгып, узыша-узыша эшлиләр дә инде.

— Теге зәңгәр халатлы кем соң әле ул? — дип сорады Фидая. — Танып бетермим.

— Танымавыгыз гаҗәп түгел. Минем хатын ул.

— Кай арада аны эшкә җигеп өлгердегез әле?

— Ул өйдә ятканда, бүтәннәрне ничек эшкә чыгарасың... Хәзер минем сүзем нык, үз хатыныма да бер гектар бүлеп бирелгән, дип кенә авызларын каплыйм.

— Өегез әзер түгел бит әле. Лесхоздан килеп йөриме әллә?

— Наилә апаларда торып торырга булдык әлегә...

Давыт әйтеп бетермәде, әмма Фидая калганын сүзсез аңлады. Зәңгәр халатлы хатын, һичшиксез, ире янында булыр өчен, үзе шулай теләп күчеп килгән иде. Әнә бит ул, еректан ук нидер сизенгәндәй тураеп басты да, тәпкесенә таянып, бу тарафка карап тора. Ара ерак булганга, йөзе ачык кына күренми, әмма бөтен торышыннан, башын чөеп тотуыннан үзенә бер горурлык, ныклык сизелә. Басу иркенлегендә, зәңгәр күк фонында калкып торган таш сын кебек иде ул. Аның кыяфәтендә үзенә бер кисәтү дә бар иде кебек...

Давыт та бая авыл урамындагыча түгел, үзгәреп киткән кебек булды. Фидаядан ике-өч адым ераграк басып торды һәм машинага да беренче булып кереп утырды.

— Безнең Җәгъфәр Латыйпович, чөгендерне бер кат тулысынча эшкәртеп чыктык, дип, обкомга рапорт бирде инде бүген, — диде Фидая, машина кузгалгач.

— Анысы аның эше. Мин аңа андый рапорт бирмәдем, — диде Давыт.

— Соңаруыгыз бар.

— Соңарсак, ятып еламабыз, поезд түгел. Әнә азык чөгендере бөтенләй тишелмәде әле. Анысын эшкәртергә карчык-корчыкны үгетләдем, олы башымны кече итеп, өйләренә барып, һәрберсе белән аерым сөйләшеп чыктым. Хәлне аңладылар, ризалыкларын бирделәр. Ә чөгендер тишелмәде. Яңадан чәчтек инде, нишлисең. Тишелерме-юкмы дип җан атып йөрим хәзер...

Бераздан сөрелгән басу янына барып туктадылар.

— Менә шушында.

Машинадан төшүгә, Давыт эре-эре атлап, буразналар арасына кереп китте. Менә ул иелде дә, озын бармаклары белән сак кына туфракны сыдырып, буразнаны ачты. Кара ярма кебек туфрак бөртекләре арасында саргылт кисәкчек күренде. Кытыршы таш кыйпылчыгына охшаган бу кисәкчек — орлык иде.

Давыт тураеп басты, маңгаена бүселеп төшкән коңгырт чәчен сыңар кул аркасы белән артка сыпырып, орлыкны күзләренә якын китерде. Каты, кытыршы сырлы бөртектән кызгылт, сусыл тамырчыкларның башы төртеп чыккан иде. Берьюлы өчәү! Узган атнада сеңдереп явып киткән яңгырның шифасы тигән. Димәк, өй борынча йөреп, карчыкларны үгетләү дә бушка китмәячәк... Давыт, тамырчыкларны имгәтүдән курыккандай, сулышын тыйды — аның учында яшәешнең бөек могҗизасы, ачылмаган сере ята иде. Таш кыйпылчыгына охшаш бөртек эчендә күзгә күренмәс, әмма тыелгысыз, туктаусыз хәрәкәт бара. Җепсел сузыла, калыная, туфракка омтыла. Тиз арада ул тармакланып, ныгып җиргә берегер, эре, яшел яфракларын өскә чыгарып, кояшка таба сузар. Һәм җәй ахырына кушучка сыймаслык чөгендер булып үсеп җитәр. Моннан да зур могҗизаның булуы мөмкинме?

Нурханова да җирдән бөртек табып алган, аның тамырчыгын күреп сөенгән иде. Менә ул, егетнең карашын сизеп, керфекләрен күтәрде. Аның күзләреннән бөркелгән җылы нур Давытны тынсыз итте. Моңарчы ул бу хатынны каты күңелле, кырыс дип уйлый иде. Ә ул менә нинди икән бит!.. Салкын якларда, тундрада язларын бик иртә шытып чыга торган умырзая кебек гөл бар. Бик каты кырауларга да бирешми ул, чөнки чәчкәләренең таҗ яфраклары эчендә, үзәгендә кояштан алып калган җылыны саклый белә. Бу минутта Фидая менә шул гөлне искә төшерде. Карашын бик тиз читкә алды ул, әмма җылысы күңелгә сеңеп калды.

Бу минутта ул бөтенләй башкача, өр-яңача булып күренде. Ачык коңгырт күлмәге ыспай сынын назлагандай сыланып тора, йөзен яртылаш каплаган алтынсу бөдрәләре кояшта ялтырый. Үзе дә табигатьнең камил һәм гүзәл баласы, алай гына түгел, күпне кичергән хис кешесе, күп уйланган акыл иясе булып тоелды ул.

Давыт, иелеп, учындагы орлыкны кире буразнага салды да өстенә туфрак юрганын ябып куйды. Назлап сыйпады. Бала башыннан сыйпаган кебек. Әмма... үз баласын түгел, очраклы бер ятимне иркәләп узгандай хис итте ул үзен. Чөнки... чыннан да ятим иде бу җир. Иясе, хуҗасы юк иде аның. Авыл халкы бу кырлар, басуларны үзенеке итеп тоймый. «Бу минем җирем, моннан кубарылсам, тамырларым өзелер дә корырмын», — дип борчылмый. Бу җирдә ул үзе бер ятим. Давыт та биредә вакытлыча гына туктап калган узгынчы кебек. Узган елны бу кырлар өчен Ташниса җаваплы булган булса, быел — Давыт. Картайганчы «Үзәк»нең рәисе булып калмас бит инде... Рәис булса да, барыбер хуҗа түгел ул монда. Искәндәровның ачуын китерсәң, эһ дигәнче алып ташлар... Күңелең тамырларын бу туфракка беркетергә ярамый, соңыннан авырга туры киләчәк.

Авылга кире кайтканда, алар шушы хакта сөйләшеп алдылар. Сүзләр өзек-өзек кенә иде, әйтелмичә калганы күңел җепләре аша, дәшми генә аңлашылды.

# 26

Хуҗалык җитәкчеләрен туктаусыз өйрәтеп, нәрсәне ничек эшләргә кирәген күрсәтеп торырга кирәк дип исәпләнә. Шушы максаттан авыл җирендә әледән-әле семинарлар уздырыла.

Терлекләрне җәйләүгә чыгару уңае белән «Җиңүче» колхозында шундый бер семинар үткәрү планлаштырылгач, районның бөтен көче диярлек андагы җәйләүнең корылмаларын үрнәк булырлык итеп төзүгә юнәлтелде. Мирхуҗин атналар буе шуннан кайтмый ятты: маллар өчен киң аранны киртәләп куйдылар, автоэчергечләрне көйләп җибәрделәр, терлекчеләр өчен ике вагончик илтеп куйдылар, аларның ишеге алдындагы мәйданчыкка бетон җәйделәр, бидоннарны юып, зарарсызландырып киптерү өчен махсус озын өстәлләр ясадылар.

Ниһаять, бер иртәне барлык хуҗалыкларның җитәкчеләрен, ферма мөдирләрен, зоотехникларын шунда җыйдылар. Җәйләүнең урыны әкияттәгедәй матур иде: «уазик»лар, «Жигули»лар тезелеп баскан такыр басу юлының бер ягында — яшь нарат урманы; икенче ягында — ала-кола сыерлар белән тулы аран һәм аның тирәсендәге корылмалар артында — яр астыннан инеш агып ята. Шәраб урынына эчәрлек саф, җиләс һаваны күкрәк тутырып сулап, бер гамьсез йөрүләр килгән халык өчен үзенә бер ял иде. Бар эш шул: башкалар белән бер төркем ясап басып торасың һәм Беренченең акыллы сүзләрен тыңлыйсың. Анысы инде биредә мал асрауның рәтен-тәртибен белмәгән кеше юктыр, тик чыраеңда дикъкать галәмәте сакларга кирәк. Искәндәров, сыерларны җәйләүдә ничек карарга, кайчан ничек саварга кирәклеген сөйләгәннән соң, өсте кыек белән капланган озын өстәл янына якынрак килеп, бидоннарның чисталыгын тикшереп карарга чакырды. Аннары кәҗә тәкәсенә ияреп йөргән сарыкларга хас күндәмлек белән, Беренчегә ияреп, корылмалар тирәсен әйләнеп чыктылар.

Хәер, һәммәсе дә җитәкченең авызына гына карап тора дип әйтеп булмый иде. Урман ышыгынарак автолавкалар китереп куйганнар, халыкның бер өлеше, бигрәк чуар-чабыр киенгән хатын-кыз, шул тарафка тартыла башлады. Семинар бит ул тәҗрибә уртаклашып, акыл туплау урыны гына түгел, үзенә күрә бер бәйрәм дә. Бу кытлык заманда яхшы товар сатылмаса, нинди бәйрәм инде ул? Автолавкаларның каерып ачып куелган ишекләрендә кием-салым җилпенә, кыяр, помидор, кәнфит өемнәре, шешәләр күренә. Авыл кибетләрендә гомер булмаган бу муллык ымсындыра, үзенә чакыра, тәкатьсез итә иде. Ул тирәдә чиратлар ук хасил була башлады. Сыер карау кайгысы ди монда!

— Син ник кыяр алмыйсың? — дип сорады Мирхуҗин Давыттан.

— Чират торыйммыни?

— Чиратсыз гына алып биримме? Кайткач, хатының белән кара-каршы утырып, миңа рәхмәт укый-укый ашарсыз рәхәтләнеп.

Давыт көлеп җибәрде:

— Үзем куәтле чакта хатынга сине мактап утырмам инде.

— Сыерларының имчәкләрен кара син боларның, — диде Тавис. — Грузиннарның шәраб тутырган турсыгы диярсең, ә! Башка колхозлардагы кебек, уңмаган хатыннарның итәге төсле сәлперәеп салынып төшмәгән...

— Семинар уңае белән дә имчәкләре бүртмәсә, оят булыр тагы бу сыерларга. Районга тиешле бөтен комбикорманы Ясәвиевкә биреп җибәргәннәр бит.

— Озакка сузылыр микән инде бу?

Шул сүзләр белән Мирхуҗин, ялтыравык каптырмалы ак җиң очын кайтарып, беләген күтәрде. Зур, калын сәгатенең алтын уклары кояшта ялтырап, Давытның күзен чагылдыргандай итте. Шәп сәгать иде бу, затлы, кыйбатлы, үз кадерен белүче, әйбер таный торган кешеләр генә тага торган. Бу кешене мондый ук товар таный торган дип белми иде әле Давыт... Мирхуҗин аның карашын сизеп алды, канәгать елмайды:

— Син дә мал таный беләсең, ә? — диде.

— Тану нәрсә ул, кайберәүләр, әнә, таба белә!

— Эзләп йөрисе дә юк, китереп кулга тоттыралар, малай. — Ул, аяк очларына басып, Давытның колагына кайнар сулышын өрде: — Кызлар бүләге!

— Кит аннан! Бездә дә шундый бүләк бирә торган кызлар бармыни?

— Табыла алар күзен ачып йөргәннәргә, ярның асылын үзенә карата белгәннәргә.

Һәм ул, гадәттәгечә күзен кысып, калын кашын сикертеп, төркемнең аргы ягына ишарә ясады. Давыт эчтән дерт итеп куйды: Нурхановага ымлады Тавис…

Фидая чак кына читтәрәк «Җиңүче»нең парторгы, бөтерчектәй түгәрәк Рәсимә Фәләхова белән янәшә басып тора иде. Бүген ул кыска җиңле зәңгәр күлмәк кигән, билен ак каеш белән буган, чәчләрен, җилдә тузып ямьсезләнмәсен өчен генә, ак бөрчекле кечкенә зәңгәр кыекча белән бәйләп куйган. Сул беләген, нәни сары сәгатеннән өстә, терсәге турындарак ак бинт белән урап куйган. Ник бәйләде икән?.. Һәм кем өчен болай матур итеп киенгән? Әллә чыннан да Мирхуҗин өченме? Бу уй бәгырьгә шырпы булып кадалды, сыкрандыра да сыкрандыра. Үзенең дә җаны тыныч түгел кебек, сынын киеренке тотуыннан, ара-тирә кыекчасы астыннан таралып төшкән бөдрәләрен сыйпап куюыннан дулкынлануы сизелеп тора.

Шул минуттан башлап, Давыт аны күзеннән ычкындыра алмады. Ул арада җәйләү корылмалары, мәктәпчә әйтсәк, күргәзмә әсбаплар каршына бастырып дәрес бирү тәмамланды. Хәзер инде укытучыга җавап бирер вакыт җитте. Моны аягөсте генә эшләп булмый, җайлырак урынга күчәргә кирәк иде. Халык таралып, машиналарына утыра башлады. Әнә Нурханова да «уазигы» янына барды, яшь кызларча нәфислек белән, җиңел генә бөгелеп, машинасына керде, ак туфлиләре ялтырап алды. «Ник аягына акны киде икән? Пычраныр бит», — дип уйлады Давыт. Машиналар, бер-бер артлы әкрен генә кузгалып, чирәм үскән юлдан урманга таба киттеләр. Давыт мәктәптә укыган чакта ук утыртылган наратлар кул җитмәстәй биек булып, куерып үсеп җиткәннәр. Барысы да кояш нурларына коенган иркен аланлыкка кереп туктадылар. Тубыктан узып үскән чирәмлеккә сап-сары идән такталарыннан ясалган озын-озын эскәмияләр тезеп куйганнар, алар каршында шундый ук таза өстәл дә бар. Аның артына Беренче үзе, авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе Сәлахов һәм кырыйгарак Нурханова утырды. Председательләр, ашыкмыйча гына, эскәмияләргә урнаштылар. Сүзләр сүлпәнләнде, йөзләр сүрелде. Семинарның иң күңелсез өлеше килеп җитте.

Сәлахов, кулына кәгазь битләре тоткан, җилбәгәй җибәргән күк пинҗәге эченнән ак күлмәк белән капланган мул корсагын бүлтәйтеп, тураеп басты. Эскәмиядәгеләрнең башлары аска иелде, берәүләрнең тузган чәче күзгә төшсә, икенчеләрнең пеләше ялтырады. Мөҗәһит, кабалана-йотлыга, кайсы колхозда күпме сөт савылганы турында сөйләргә керешге. Иң авыры менә шушы инде... Һәр сыердан алты литрдан ким сөт савылган хуҗалыкларның җитәкчеләрен торгызып бастырып җавап алу башланды... Икелегә укучы балаларны орышалармыни! Давытның эчендә бер нәзберек тамыры авырттырып тартышырга тотынды. Аның торып басасы килми иде. Бигрәк тә өстәл артыннан Нурханова карап утырганда... Ә җиде литрга күчсәләр, торгызачаклар. Чөнки савымны шуннан арттырып булмады. Сыерларның утызлабын исәпкә кертмичә, алардан сауганны башкаларныкына кушып күрсәтәләр күрсәтүен, тик алай да начальниклар алдында мактанырлык санга ирешеп булмый! Давыт беренче көннәрдә, малларның төгәл исәбен алыгыз, дип, бухгалтерия кызларын тинтерәтеп йөрткәнен үзе үк көлеп искә ала хәзер. Әгәр алай итсәң, башың тиргәлүдән чыкмас...

Аллага мең шөкер, бу юлга аңа кеше арасында сораеп, башын иеп басып торырга туры килмәде. Искәндәров, сүзне озынга сузмыйча, йомгаклап куюны мәгъкуль күрде. Аягөсте күтәрелеп:

— Сөт буенча яртыеллык планны үтәү авырга киләчәк быел, — диде ул, таза күкрәгеннән чыккан тавышын нык гөрелдәтеп. — Үлән җитәрлек, ашатыгыз малларны! Җәй башы коры килсә, сөт мул була, моны һәркем белә ләбаса. Чиста парларга үлән чәчәргә кирәк, силос салынсын, яфрак азык җыелсын...

Ә Давытның күзе һаман Нурхановада иде. Мирхуҗинга теге затлы сәгатьне чыннан да ул бүләк итте микәнни? Әллә Тавис юри шапырынамы?

— Гаяров!

Давыт сискәнеп торып басты.

— Нишләттегез сез анда «Җинүче»нең борчагын?

Давыт, йомранга әверелеп, җир тишегенә кереп китәргә әзер иде. Нурхbuilt mondый кызганулы карашын күрмәс өчен әллә ниләр бирерсең? Ләкин ни гаебе бар әле Давытның? «Үзәк»нең бодай кырына самолеттан гербицид сиптергәндә, бер очтан ызанның икенче ягындагы борчак басуына да коеп киткәннәр. Әллә бригадир басу кырыена флаглар тоткан сигналчыларны вакытында чыгарып бастырмаган, әллә очучылары игътибарсыз булган, Алла белсен. Очучы — бригадирга, бригадир очучыга өстерә хәзер. Ә син монда хур булып басып тор менә... Ясәвиевен әйтер идең... Башка берәү булса, күрше хакы — Алла хакы, диешеп, үзара килешеп йомып куярлар иде. Ә бу әнә райкомга барып әләкләгән...

— Зыян салгансыз икән, түләргә туры килер, — диде Искәндәров.

— Борчакны безнең басуның шул кадәр гектарыннан урып алырлар, — диде Давыт.

— Орлыклык басу иде бит ул безнең! — дип чәчрәп торып басты Ясәвиев. — Сездә нинди борчак үскәнен беләбез, сыдырып силоска салырга гына ярый ул!

Давыт дәшмәде: сүз үрчегән саен, башка тукмак катырак төшәчәк иде. Һәм, чыннан да, Искәндәров әрепләшүгә юл куймады, кулын гына селтәде.

— Утыр. Килешеп хәл итегез анда.

Шуның белән җыелышны йомгаклап, барысын да төшке ашка чакырды.

Табынны эчтәрәк, агачлар ышыгына корганнар. Әле генә яргычтан чыгарылып шомартылган алтышар метрлы нарат такталарны сузып салган өстәлләрдә сый-нигъмәт авылча мул иде. Калачның телемнәре калын, пешкән ит калҗалары эре, каймак, бал савытлары зур.

Табын тирәсен таза гәүдәле ирләр сырып алды. Давыт карашы белән Нурхановны эзләде. Тик ул күренмәде. Кая юкка чыкты соң әле ул? Үзе генә китеп барганмы, әллә Мирхуҗин белән икәүләшепме? Ә юк, әнә ул Тавис, машинасыннан затлы шешә алып килеп ята. Потребсоюзның складларыннан тартмалары белән китерелгән Чистай аракысы гына ярамый аңарга, үзенә аерым төрлесе кирәк. Үзеннән бигрәк, югарыдагыларга эчемлекнең шәбен табып китереп бирүең яхшы, дип уйлый ул. Түгәрәк өстәлнең түренә — Беренче янына узды да аның стаканына шешәсеннән кызгылт эчемлек койды. Үз ягын карый белә, хуҗага ярый белә, чукынган!

# 27

Нурханова аланда әзерләнгән табынга бармады. Ир-ат стакан белән аракы эчкән җирдә нинди ямь дә ни рәхәт? Анда булмаган өчен Беренче дә шелтә белдермәс, шәт. Алай-болай сүз әйтсә, фәлән авылның үзешчәннәрен күреп кайтасы бар иде дияргә булыр. Урып-җыю вакытында кырга, комбайнчылар янына агитбригадалар барып концертлар куячаклар, әзерлекләрен хәзердән үк тикшерә башларга кирәк. Җитди сәбәп түгелмени?

Фидая машинасына барып утырды да Балкышка кузгалырга кушты. Юл әкияти урыннан уза иде: уңда — яшь наратлык, сулда — күкрәп үсеп килгән бодай кыры. Чирәмле басу юлы дыңгырдатмый, талгын гына тибрәндерә иде. Күңелне нindидер татлы да, моңлы да бер хис биләп алды.

Әмма бу матур сәяхәт кинәт өзелде — машина пых-пых итте дә туктады. Балкыш машинадан төшеп капотны ачты.

Аның янында каравылчы булып басып торасы килми иде.

— Эшең беткәч эндәшерсең, мин монда гына булам, — диде Фидая һәм наратлар арасына кереп китте. Юл читендә куерып үскән агачларның аскы корыган ботаклары күлмәкне, чәчне эләктереп тарткалады, сагыз исенә туенган бөркүлек тынга бәрде. Фидая, кулларын алга сузып башын иеп бераз баргач, киң генә аланлыкка килеп чыкты. Аның артында янә наратлык, тик анысы, сөзәк кенә үр күкрәгендәгесе, соңрак утыртылган, куерып өлгермәгән иде әле. Мондагы яшь наратлар, ботакларын җирдән үк киң җәеп, күкрәп утыралар, очлары Фидаяның баш өстеннән чак кына күтәрелеп, тырпаеп тора. Рәт эчендә алар бер-берсенә астан тоташкан диярлек, ә менә рәт аралары иркен, анда кояшта үлән куерып үскән, җил йөри. Фидая янәшәсендәге агачның сусыл, тыгыз, салкынча тармакларын назлап сыйпады. Ылыслар арасыннан, тереклекнең серле төене булып, авыр, каты, күгелҗем күркәләр тырпаеп чыккан иде.

Үр күкрәгенең көлсу туфрагыннан нинди көч, кодрәт күтәрә икән яшәешнең мондый гүзәл дә, гайрәтле дә мисалын, үрнәген? Бу тереклек ияләре аерым тәрбия дә, ашлау да таләп итми, фәкать комачаулама — йолкып атма, өске бөресен өзмә генә. Алар үзләре айдан-айга, елдан-елга ныгыр, югарыга, зәңгәр күккә

таба үрләр, куерыр, күп кошларның, җәнлекләрнең йорты булган чын урманга, җирнең гүзәл бизәгенә, кешеләр өчен зур байлыкка әверелер... Шундый илаһи бер гайрәт бар аларда. Фидая, җирдән-туфрактан күтәрелеп, кәүсәләр, ылыслар буйлап туктаусыз агып торган шушы могҗизалы көчнең авазын ишетергә теләгәндәй, сулышын әкренәйтеп тынып калды, һәм бераздан ул аны ишетә дә башлады шикелле. Әйтерсең чыннан да җир куенында ниндидер өн ярала һәм ул наратлар аша саркып чыга иде. «Ш-ш-ш, ш-ш-ш...» Әйе-әйе, чыннан да, карап торышка хәрәкәтсез утырган наратлар чак ишетелерлек кенә шаулый түгелме?

Фидая читкә, рәт арасындагы чирәмлеккә чыгып басты, тавыш ишетелмәс булды. Куркытудан сагайгандай, әкрен атлап, тагын рәт арасына керде — тавыш янә, серле аваз булып, колакка килеп ирешге... Яшь наратларның теле ачылган чак — алар үз җырын өйрәнәләр иде.

Каян, ничек отып алалар икән алар бу җырның көен, тирбәлешен, аһәңен, кабатланмас моңын? Алар, бәлки, талгын искән җылы җил аша ерактагы калын урманнарның тавышын ишетеп, шуны кабатлыйлардыр? Ә бәлки, ул моң, яшәешнең мәңге тынмас авазы булып, орлыкларда сакланадыр да җирдән калыккан кәүсәләр аша ботак-ылысларга килеп ирешәдер?

Табигатьнең өзлексез яңарып, яшәреп торуын бәян итә, тормышның мәңгелеген искәртә иде бу җыр. Син дә шушы тереклек дөньясының бер кыйпылчыгы, җирнең бизәге, дип җырлый иде ул Фидаяга, тыңлый һәм ишетә белгән һәр адәм баласына... Гомереңнең кадерен, яшәү бәхетенең тәмен бел, ди иде кебек ул.

Фидая, үзалдына елмаеп, яшь наратларның моңлы да, дәртле дә җырын тыңлап, шактый басып торды. Аннары, бөтен тәнендә рәхәт бер талчыгу тоеп, кире уйсу аланлыкка чыкты. Аяк астына келәм җәеп куйганнармыни, ял ит диеп, ымсындырып, чакырып тора. Ә нигә ял итмәскә? Монда беркем күрми ләбаса! Әнә тыгызланып бәбкә үлән үскән такыррак җире дә бар. Фидая башта утырды, аннары, аскы яктан күлмәк итәген кайтарып, сузылып ук ятты. Ул авыл кызы, җирне, үләннәрне тоеп, алар белән бербөтенлеген аңлап үскән кеше... Меңьяфрак, гөлбадран, ак әрем сабаклары, аны яшереп, биегәеп киткәндәй булдылар. Сирәк ак болыт мендәрләре белән бизәлгән зәңгәр күктән тургай җыры белән назлы кояш нуры гына килеп ирешә иде.

Гүзәл иде дөнья, камил иде, тик Фидаяның бәхете түгәрәк булсын өчен нидер җитми иде. Бу китеклек наратлардан саркыган тантаналы җырга нечкә сагышлы бер аһәң өсти иде. Бу сагыш сызланулы да, шул ук вакытта татлы да, чөнки аның белән берләшеп, күңел кылларын якты өмет чиртә иде. Син яшь әле, күкрәп күтәрелгән шушы наратлар кебек чагың, күңелең гөлләре чәчәк атып кына килә... Бәхетең алда көтә, дип чыңлый кебек иде ул.

Кинәт бу оркестрга ят бер тавыш килеп кушылгандай булды. Дөп-дөп, дөп-дөп... Адымнар. Кемдер килә. Ә бәлки, күрмәс, читләтеп узып китәр? Ләкин юк, дөпелдәү көчәя, адымнар якыная... Күренми калып булмас, ахрысы...

Фидая торып утырды, итәген рәтләп, аягына басарга дип кулына таянды...

Алар икесе дә бу очрашуга әзер түгел иде, шунлыктан күңел төбендәге тойгыларның күз карашларында чагылуын сизми калдылар. Ә бу тойгы — башта гаҗәпләнү, аннары әйтеп бетермәслек шатлык, куаныч булды.

Давыт, сөенеченнән балкып караган хәлдә, аңа кулын сузды. Фидая аңа сул кулын бирмәкче иде, әмма Давыт, аның беләгендәге бәйләвечкә карап, авырттырудан куркып, җиргә таянган уң беләгеннән тотып алды. Һәм, кискен итеп күтәреп, үзенә тартты. Чын ирләрчә буйсындыручан бу хәрәкәттә каршы торалмаслык гайрәт бар иде, Фидая аның кочагына барып кергәнен сизми дә калды. Сизсә дә, карышырга өлгермәде. Чөнки каршы тору өчен ихтыярны туплау кирәк иде... Аның ихтыяр көче югалган иде... Аяклары җирдән аерылды, җан җанга беректе. Ул иреннәренең егетнең көчле, каты, таләпчән, эссе иреннәре арасында калганын тойды. Үзенең иреннәре дә берни белән исәпләшмичә, кайнарланып, тәкатьсезләнеп җавап бирде... Һәм гүяки дөньяның иң татлы шәрабын эчте дә эчте, эчте дә эчте, һич кенә дә туя алмады...

Күпмедер вакыттан соң гына аяк очларының, ниһаять, җиргә терәлгәнен тоеп, аңына килде, айнып киткәндәй булды. Ике учын егетнең нык күкрәгенә куеп, бар көченә аны читкә этәрде. Аннары аркасы белән борылды да агачлар ешлыгына, машинасы калган тарафка китте. Давыт аның артыннан атлады.

— Балкыш бензонасосны карап маташа иде анда, минем Мөҗип аңа ярдәм итә калды, — диде.

Сүзенә җавап булмагач, берничә адымнан соң:

— Беләгеңне ник бәйләдең? — дип сорап куйды.

— Укол ясаткан идем. Медсестра тузан-фәлән кермәсен дип урап куйды.

— Ә нәрсәдән ул укол?

— Болай гына. Витамин.

— Витамин хәзер болай да җитәрлек. Әнис ашарга була әнә, кузгалак, какы. Нәрсәгә тәнгә җәрәхәт ясарга.

Давытның Мирхуҗин кулындагы сәгать хакында сорыйсы килә иде. Әмма бу минутта Тависның исемен телгә аласы килмәде. Алар ешлыкка барып керделәр. Фидая, корыган ботаклардан сакланып, кулларын алга сузды. Ах, шушылай учлар белән ышыкланып кына йөрәккә капкан ялкыннан сакланып булса икән!.. Алда ачыклык күренде.

— Син бар, алдан чык, — диде Фидая, борылып карамый гына. Аларның урманнан парлап чыкканын шоферлар күрсә, яхшы булмас иде. Давыт аңа сузылган иде, Фидая дерт итеп артка тайпылды... Тыелырга, үзеңне кулда тотарга кирәк иде...

Машина кабынмагач, Мөҗип аны тартып алып кайтырга тәкъдим итте. Ләкин Фидая риза булмады. Давыт аны аңлады: район үзәгенә ике машинаның бер-берсенә тагылып кайтуын күрсәләр, сүзгә сәбәп булуы ихтимал иде.

— Суташ сезгә юл уңае түгел бит, — диде Фидая. — Безне Рәсимә тарттырып илтеп куяр әле. Ә сез, барыгыз, үз юлыгызда булыгыз.

Тик Рәсимәне эзләп йөрисе булмады, юл чатыннан Мирхуҗинның күксел «Жигули»е килеп чыкты. Ул инде тукталмыйча, мәсьәләне хәл кылмыйча китеп барачак түгел иде!

# 28

Җәй башы коры килде, яңгырны бик теләгәннәр иде, ләкин ул, һәрвакыттагыча, җайсыз чакта килеп коярга тотынды. Сабан туе буласы иртәне, чәй янында Давытның тәрәзәгә текәлеп утырганын күреп, Фазилә:

— Бөтен дөньяны каплап алган әле бу, утырып, пыскаклап яварга көйләнгән, тиз генә туктамас, — дип куйды. Давытның эч пошуы көчәйде, чөнки Фазилә әйткән сүз гадәттә рас килә иде. Елына бер була торган, көтеп алган бәйрәмнең быел бөтенләй булмый калуы ихтимал. Давытның бу авылда беренче сабан туе. Матур узсын дип нык тырыштылар: авыл янындагы болында яңа эскәмияләр ясатып, бер өлешен кояштан ышыкладылар, колгалар, баганалар утырттылар. Бүләкләр җыйдылар, әтәчен, тәкәсен әзерләп куйдылар. Һәммәсе юкка гына иде микәнни?

Иртәнге нәрәттән соң мехдворны, фермаларны әйләнеп чыккач, Давыт машинасын Гыйззетдиннәр турында туктатты.

Фаязларныкыннан тәбәнәгрәк һәм кечерәк булса да, бик матур итеп җиткерде йортны Гыйззетдин. Капкасы зәңгәргә буялган, уртасына сарыдан кояш ясалган, тәрәзә яңаклары, кыек аслары челтәрләп уелган.

Давыт кече капканы ачты да, тавышын күтәрә төшеп:

— Керергә ярыймы? — диде.

Бөдрә чәчен киң кызыл тасма белән бәйләгән Зарема болдыр такталарын юып маташа иде, тураеп, зур, серле күзләрен тутырып карады.

— Ярый, — диде. — Исәнмесез!

— Саулармысез. Әниең өйдә түгелме әллә?

Зарема, артына әйләнеп, моңлы күкрәк тавышы белән:

— Әни! — диде. — Сине прсидәтел чакыра!

Өйалды ишегеннән башта майка гына кигән Гыйззетдин, аннары чәчен баш артына учлап тоткан Каләмгөл килеп чыктылар.

— Ни эшләр майтарып ятасыз? — дип сорады Давыт, сәлам алышкач.

— Кер тизрәк, чыланып торма, — диде Гыйззетдин. Аның кәефе, болытлы көннән аермалы буларак, күтәренке, көр иде. — Без монда машинаны юып куйдык. Мәйданга барырга дип, киенеп-ясанып маташа идек менә. Кызым, эшеңне бетергәнсең икән, бар, син дә әзерлән!

— Мәйданда ни кылырсыз икән? Ява бит!

— Хәзер туктый ул, — диде Каләмгөл.

— Каян беләсең?

— Кәрт ачтым!

Давытның аптыраганы йөзенә чыкты булса кирәк, хуҗалар икәүләшеп көлеп җибәрделәр.

— Хәзер сәгать унбер, халыкны икеләргә җыйсак, кичкә хәтле туйганчы бәйрәм итеп була әле, — диде Гыйззетдин.

Давыт, борылып, кояш баешына, соры болыт белән капланган офыкка карап куйды, анда бер генә дә ачыклык күренми иде. Ләкин Гыйззетдиннәрнең дә буш сүз сөйләгәннәре юк бит...

Бу юлы да белми әйтмәгәннәр икән, өйлә үтүгә, болытлар таралып ук бетмәсә дә, яңгыр чыннан да туктады. Ул арада кинәт урамны баян тавышы, аңа кушылып, җыр яңгыратты: «Сабан туе, хезмәт туе, шатлык һәм бәхет туе...» Зареманың күкрәк түреннән чыккан йомшак, ягымлы тавышы иде бу. Әнисе уйный, кызы җырлый. Гыйззетдиннең ялтыратып юган зәңгәр «Нива»сы бик әкрен генә урам буйлап килә, аның ачык тәрәзәсеннән яңгырый иде бу җыр, шуннаң агыла иде. Менә ул өзелде, Каләмгөлнең шат тавышы ишетелде:

— Туганнар, дуслар, авылдашлар! Сабан туе мәйданына рәхим итегез. Нәкъ бер сәгатьтән бәйрәмне башлап җибәрәбез. Бүләкләребез күп, тәкә симез, чабыш атлары әзер. Күктән тамчы тама дип куркып тормагыз, шикәр түгелсез, эремәссез! Көтәбез! Сезне күңелле ярышлар, затлы бүләкләр көтә!

Аннары тагын җыр: «Сабан туе, хезмәт туе...»

Халыкны кузгата да, төшенке күңелләрне күтәрә дә белә иде шул бу гаилә. Табигать тә алар белән бер сүздә иде шикелле: бераздан, чыннан да, көнбатыш якта офыкта күкнең зәңгәрлеге ачыла башлады, ул зурайганнан-зурайды, болыт пәрдәсенең читендә нур уйнады.

Халык дәррәү авыл янындагы иңкү болынга агылды. Телефоннан хәбәр итеп өлгергәннәр булса кирәк, «ГАЗ» машинасының ачык кузовына тезелеп басып та, ике-өч «Жигули» белән дә, һәр елдагыча Сидоровкадан килеп төштеләр.

Мәйданда инде һәммәсе әзер: уртадагы багана тирәсендә меринос тәкә әйләнә, авыш колга очындагы җәтмәдә этәч бәргәләнә, бер яктагы эскәмияләр өстенә тартып куелган брезент ышыгында беләкләренә кызыл тасма бәйләгән комиссия әгъзалары әвәрә килә, анда бүләккә дип әзерләгән тартмаларны, төргәкләрне, сөлге-яулыкларны барлыйлар иде. Шунда ук микрофон да чыгарып куелган.

Аның янына басып бәйрәмне ачып җибәргәндә, Давыт нык дулкынланды. Биредә эшләгән ярты елдан артык вакыт эчендә, ул мондагы кешеләрне чын күңелдән якын итеп, күпләрен хәтта яратып та өлгергән иде. Ни генә дисәң дә, нинди генә кимчелекләрен күрсәң дә, бу дөньяда иң кирәкле, иң мөһим эшне башкаручылар алар. Икмәк булмаса, яшәеш юк, ә икмәкне менә шушындыйлар булдыра... Яхшы сүзгә лаек булган берәүне дә мактаусыз һәм бүләксез калдырмаска тырышты ул. Бу хакта Әхсән, Гаделша кебек авылның абруйлы кешеләре белән дә, Нурханова белән дә алдан киңәшелгән иде. Бәйрәмне ачып җибәргәч кенә, Фидая да килеп төште әнә. Бүген берничә авылда сабан туе үтә, өченче секретарь һәммәсе өчен җавап бирә, монда килер алдыннан кайлардадыр булган, шуңа монда соңаргандыр, күрәсең. Әнә, машинасын читтәрәк калдырып, янәшә килеп басты. Семинарда кигән зәңгәр күлмәктән, билен шул ук тар ак каеш белән буган, башына яулыгын гына бәйләмәгән. Давытның тавышы калтыранып китте бугай, йөрәге сулкылдап куйды. Каушап калганын сизмәсеннәр тагын!

Ул тавышын көрәйтебрәк җибәрде. Аннан соң Нурханова, микрофон алдына басып, район җитәкчеләре исеменнән котлады. Менә бүләкләүләр башланды. Монда инде хуҗалыгың фәкыйрь дип тормыйсың, бүләкләрнең саллысын әзерлисең. Гыйззетдингә телевизор тапшырылды, Гаделшага — велосипед, Мөнирәгә — бик матур тартмада чех чынаяклары...

Һәркайсына канат үстемени, яшәреп, чибәрләнеп киттеләр. Председатель булып эшләүнең иң рәхәт минутлары менә шушы икән. Давыт матур сүзләр әйтеп, куллар кысып тора, Гаделша абзый бүләкне китереп тоттыра, баян тотып баскан Каләмгөл туш уйнап җибәрә.

Аннары китте тамаша... Баядан бирле көтүләре белән җәтмәдәге этәч тирәсендә бөтерелгән малайлар, тезелешеп, кулларын ике якка җәеп, авыш колгага менеп киттеләр, аннан төшүгә, уртадагы баганага үрмәләргә чаптылар. Бер якта капчык сугышы, икенче якта чүлмәк ватыш, аркан тартыш... Чыклы чирәмдә чыланып та, кайсыберсе пычранып та беткән, тик аңа игътибар итәләр димени? Уртадагы паласта бәләкәй малайлар, бер-берсенең биленнән сөлге белән эләктереп алып, әүмәкләшергә керештеләр — көрәшне башлап җибәрделәр. Эскәмияләрдә утырган халык ярышучыларны дәртләндереп тә, үчекләп тә кычкыра, көлешә. Бер якта палас өстенә Фаяз кырын яткан, алдында ризык, тирәсендә туганнары. Икенче якта, брезент җәеп, Сидоровка халкы шулай ук кәеф-сафа кора. Бала-чагалары кайсы — көрәшеп, кайсы узышып алган бүләкләре белән мактанышып сикергәли. Комиссия рәисе Гаделша карт аларга оекбаш, кулъяулык, тастымалларның, майкаларның шәбрәген бирергә тырыша. Моны берәү дә гаделсезлек дими, кунакчыллык дип кабул итәләр.

Сидоровканың берничә үсмер малае зират буенда айкалган җайдаклар төркемендә дә бар. Анда чабыш алдыннан атларның аягын яздырып йөриләр. Давыт бигрәк тә шуларга кызыгып карый. Малай чакта сабан туйларында күп чапты, атының муенына сөлгеләрне шактый күп бәйләде. Хәзер дә йөрәк җилкенә, ярыйсы гына атлар да бар. Сикереп менәр идең дә яшел болынлык буйлап чабып китәр идең. Әмма җитәкче кешегә килешмәс шул. Аның урыны биегрәк, киңрәк эскәмиядә, брезент астында. Башкаларны дәртләндереп, үсендереп, маһирлыкларына сокланып утырырга тиеш ул. Уң ягында — хатыны Фазилә, аның кулына матрос костюмы кигән нәни Фәрит ябышкан, сулында — Нурханова. Сирень төсендәге костюм киеп, шома

кара чәчләрен баш артына өеп куйган Фазилә, кылдай тартылып, туры утыра, чырае җитди. Алар турыннан узып китүчеләрнең дә, сәлам бирешкәндә, йөзләрендәге елмаю сүрелеп киткәндәй була. Ә Нурхановага борылгач, кояш чыккандай балкыйлар.

— Кәефләрең ничек, Фидая?

— Әйбәт кенә, Мөнирә. Бәйрәмдә кәеф начар буламыни?

— Гаделша абыйның кулындагы шәлгә кызыктым. Алып булмас микән дип барам.

Чыннан да, Гаделша ялтыравык җеп белән чигелгән аллы-гөлле шәл болгап тора, хатын-кызларны көянтә-чиләк күтәреп узышырга чакыра. Мөнирә үтеп киткәч, Каләмгөл дә иңеннән баянын салып янындагы Заремага сузды:

— Мәле, кызым. Безгә дә авыз ачып карап торырга гына димәгән...

Һәм ул да, киң итәкле чуар күлмәген тарткалап, чәчкәле чиләкләр, бизәкле көянтәләргә таба китте.

Нурханованың шоферы чыркылдашкан-көлешкән кызлар арасындагы Зиләйләгә якынрак барып, сүз кушарга җай эзләп йөри иде. Эскәмияләр артыннан барганда, бер урында зур гына паласны әйләнеп узарга туры килде аңа. Анда, ризык-нигъмәт каршында, ике ир утырган, бүлтәйгән корсаклы, юан муенлы абзый аеруча күзгә ташлана иде. Шул тирәдә үк Балкыш таныш кешене күреп алды — Зиләйләнең әтисе иде бу. Чегән егетләре кебек, кыек якалы ачык кызыл күлмәк кигән. Кулындагы өч-дүрт яшьлек малайга болындагы җайдакларны күрсәтә:

— Әнә, карале, улым, тегендә малайлар ничек чаба, ә? Мин дә чабар идем шулай. Чапкын атларның биле чыдамый шул инде хәзер безгә. Бөтен өмет синдә, улым. Әз генә үс тә, син дә шулай узышырсың!

— Син анда карама, хатыннарыңа кара! — диде паластагы юан абзый. Бу Фаяз иде. — Иң кызыгын күрми каласың! Син күрсен дип тырышалар анда!

Гыйззетдин дә, Балкыш та, борылып, мәйдан уртасына, иңнәренә көянтә-чиләк асып, дымлы чирәмлек буйлап җан-фәрман йөгереп килгән яланаяклы хатыннар төркеменә карадылар. Чатыр чабалар, чәчкәле чиләкләре болгана, сулары болыт арасыннан балкып чыккан кояш нурларында җемелдәп еракка сибелә. Балкыш иңбашларын сикертеп куйды: аның ни кызыгы бар? Сабан туеның һәркайсында була торган бер ярыш лабаса бу.

Ләкин Гыйззетдиннең йөзенә курку бәреп чыкты. Алдагылар арасында ак кофта, кара юбка кигәне, аркасында толымнары җилпенгәне — Мөнирә, кара бөдрәләрен бер яктан гына ялтыравык каптырма белән эләктереп куйганы, чуар күлмәклесе Каләмгөл иде. Икесе ике яккарак авышканнар, әмма тизлеккә бер чама киләләр. Гаделша болгап торган шәл кем кулына эләгер? Һәм... шәлдә генәме хикмәт? Менә Мөнирә алгарак чыкты кебек, Каләмгөл калыша башлады шикелле. Әллә артыграк ярсыган, чиләкләре нык чайкала, сулары күп түгелә. Комиссия анысын да күзәтеп тора, чиләктә суың яртылаш кына калган булса, алдан килсәң дә, җиңүче булып саналмыйсың! Кинәт халык ах итте: Каләмгөл көянтәсен, ике кулы белән чөеп, баш очына күтәрде. Һәм адымнарын бик ипле, әмма җитез бер көйгә салып алга ыргылды. Тезләрен чүгә төшеп пыр тузып килгән юан хатыннар фонында ул каргалар арасындагы күгәрчен кебек иде. Үзенең аерылып торганын сизә, бу аңа гайрәт, көч өсти иде.

— Көчле!.. — диде Фаяз, соклануыннан майлы иреннәрен ялап. — Көндәшен уздырамы соң! Янып үлсә үлә, үзенекен итә. Шулай бит, ә, Гыйзди?

Ләкин Гыйззетдиннең йөзенә соклану түгел, борчылу, хәтта курку бәреп чыккан иде.

Гаделша шәлне Каләмгөлнең баш очындагы көянтәсенә аркылы салды. Мөнирәгә зур гына яулык тоттырды.

— Мондый шәл тагын бар әле. Анысын йөгерештә җиңгәнгә бирәбез, — диде.

Озак тормады, анысына да чират җитте.

— Утыздан узган хатыннар! Йөгерешкә чыгыгыз! — дип, Гаделша тагын да зуррак, матуррак шәлне алып болгады. Күпчелекнең карашы ак кофталы Мөнирә белән чуар күлмәкле Каләмгөлгә төбәлде. Гаделша хатыннарны бер рәткә тезеп куйды да иелә төшеп кулын селтәде. Башланды! Мәйдан эченнән ярты түгәрәкне узганда, Каләмгөл алга чыккан иде инде. Ул башын артка ташлап, терсәкләрен нык хәрәкәтләндереп, чын оста узышчылар кебек, бер көйгә үрчемле итеп йөгерә, ялан үкчәләре киң итәген җилпеп-җилпеп җибәрә. Бу юлы да Мөнирә аннан калышты. Түгәрәкне икенче тапкыр әйләнергә киткәндә, төркем шактый таралган, сузылган, икенче булып йөгерүче Мөнирә дә ким дигәндә ун адымлап артта калган иде инде. Менә Каләмгөл килеп тә җитте, йөгергән көйгә бүләкне эләктереп китәргә дип, кырыйга сикереп тә куйгандай итте, әмма Гаделша шәлне аның бите турыннан җәһәт кенә җилпеп алды да артына таба болгады — бирмәде:

— Өч тапкыр әйләнергә кирәк! — дип кычкырды. — Тагын берне! Йөгер!

— Чап әйдә, нәрсә туктап калдың! — дип кычкырыштылар бүтәннәр дә. Әмма Каләмгөл сөртенгәндәй булды, сулышына капкандай адымнары тигезсезләнде, ул арада үз көенә тигез генә йөгереп килгән

Мөнирә, аннары тагын икәү-өчәү аны узып та киттеләр. Каләмгөл алар артыннан иярде. Ләкин аның адымнарында, итәгенең җилпенүендә элекке ашкыну сизелми, терсәкләре дә салыныбрак төшкән, башы да артка артык нык каерылган төсле иде. Гыйззетдин аны тартып алырга теләгәндәй омтылыш ясап алды.

— Шәл өчен генә дип болай чаба алмас иде, шулай бит, Гыйзди? — диде Фаяз. Аннары, Гыйззетдиннең чыраеннан төс качканны күреп:

— Ничава, берешә торганнардан түгел, — дип, юатырга тиеш тапты. — Биергә бик оста әле!

Әмма Каләмгөл береште, хатыннар арасына кереп буталды. Мөнирә генә түгел, башкалар да аны узып китә башладылар. Туктарга, түгәрәктән чыгарга кирәк иде аңа! Ләкин түгәрәктән чыгучылар Каләмгөл түгел шул алар! Ул алтынчымы, җиденчеме булып килде, Гаделшаның кулыннан кечкенә ак яулыкны исе китмәгәндәй генә алды да читкә атлады. Ләкин эскәмияләр янына барып җитә алмады, кинәт урталай сыгылып төште. Бер тын бөгелеп торды да, чак атлап, барып утырды. Аны шундук хатын-кызлар уратып алдылар.

— Ай Алла, ни булды?!

Гыйззетдин эскәмия аша атлап эчкә узган иде, нәни Өлфәт аның чалбар балагына ябышып елап җибәрде.

— Хәзер киләм, улым!

Бу хәйран тамашаны дулкынланып күзәтеп торган Балкыш сабыйны күтәреп алды.

— Барыгыз, бар, борчылмагыз, — диде Гыйззетдингә.

Гыйззетдин мәйдан аша турыдан гына, кызыл күлмәге белән бөтен халыкның дикъкатен үзенә тартып, каршы якка чапты. Ул килеп җиткәндә, Мөнирә үзенең кечкенә чемоданын актарып азаплана иде. Үз эшенең остасы шул ул, халык күп җыелган җирдә төрле хәл булуы ихтимал икәнлекне белә, иң кирәкле даруларны үзе белән алып килгән. Күнегелгән хәрәкәт белән укол энәсен чыгарды, ампуладан дару суыртып, Каләмгөлнең беләгенә тотынды. Ләкин Каләмгөл башын күтәрде дә кулын тартып алды.

— Кирәкми. Үтте инде...

...Баланың игътибарын зират ягыннан чабып килгән атларга юнәлтергә тырышып, Балкыш сизмичәрәк калган икән, кинәт якында гына таныш тавышны ишеткәч, сискәнеп китте. Иптәш кызлары белән Зиләйлә үтеп бара икән, шул шаркылдап көлә.

— Ни кызык бар? Миңа да әйт әле, бергә көләрбез, — диде Балкыш.

— Бу тамашадан көлми ничек чыдамак кирәк!

— Авызың ертылмасын, — диде егет, үзе дә сизмәстән шактый тупас итеп.

— Авызым үземнеке, күпме теләсәм, шулай ерам. Сиңа да бүләк бирделәрмени? — диде ул, Балкыш кулындагы Өлфәткә ымлап. — Чабышкан өченме, әллә капчык белән сугышкангамы? Кызлар, карагыз моңа нинди бүләк биргәннәр! Ха-ха-ха!

Балкыш аңа сәерсенеп карап торды: Зиләйләнең моңарчы бик матур да, җанга бик якын да тоелган йөзенә явыз үчләнү, усал тантана бәреп чыккан да бөтенләй чит-ят иткән, ямьсезләгән иде. Кызларга ияреп китеп барганда, артыннан:

— Гел кәмит булды быел безнең сабан туйлары, — дигәне ишетелеп калды.

Аларны Фаяз да ишеткән, кызның кыланмышларын ул да яратмаган икән. Паласыннан торып басты да:

— Эттән туган нәрсә, — дип мыгырданып калды. — Атаң урынында булсам, күрсәтер идем мин сиңа! Кыйбатлы кыз итеп, Гыйзди азындырып бетерде шуны.

Бер малай йөгереп килеп, Балкышның күлмәк итәгеннән тартты:

— Сине Фидая апа чакыра.

Балкыш, малайны күтәргән килеш, мәйдан аша китте.

— Каләмгөлне Кармаш больницасына илт әле син, — диде аңа Нурханова. — Анда бераз көтеп торырсың, алып калмасалар, бергә кире кайтырсыз.

Каләмгөл бу юлы да карышмакчы иде, әмма аны әйләндереп алган хатын-кызлар, ай-ваена карамыйча, «уазик»ның арткы утыргычына кертеп утырттылар.

Улын күтәреп торган Гыйззетдин Заремага:

— Син дә әниең белән бар, кызым, — диде.

...Алар хастаханәгә барып җитмәделәр. Кармаш урамына таба борылганда, Каләмгөл кайнар учын Балкышның иңбашына салды:

— Тукта әле, — диде.

Егет, газ педаленнән аягын күтәрә төшеп, артка борылып карады:

— Ник?

— Борыл. Кире кайтыйк.

— Фидая Госмановна хастаханәгә диде бит...

— Аның сүзе анда калды. Ә монда минем сүз сүз. Алып кайтасың килмәсә, без монда төшеп калабыз. Җәяү кайтырбыз.

Балкыш рулен сулга каерды.

## 29

Быелгы сабан туе ярышларда алган бүләкләр, төрле мәзәк хәлләр белән беррәттән, кемнәрнеңдер күңелендә ике көндәшнең узышуы, берсенең, чабышта янган ат кебек, хәлсезләнеп егылуы белән дә истә калачак иде. Фидая өчен исә ул сабантуйларның иң ямансуы булды. Ак кофталы Мөнирә белән чуар күлмәкле Каләмгөлнең йөрәген талаган көнләшү уты аның да бәгыренә килеп капкан иде. Алар Фазилә белән кара-каршы басып танышкан минутта, бер-берсенең күзләренә текәлеп караган бер мизгелдә чакма ташыннан ут чәчрәдемени, бәгырь түрендәге кайнар күмер астыннан кинәт ялкын теле сузылып чыккандай булды.

Фидая килгәндә, Давыт микрофон каршына басып, сүзен башлаган иде. Аннан соң Фидая да сөйләгәч, алар икесе бергә борылып эскәмиягә таба киттеләр. Анда бер кешелек кенә урын калган иде, янәшәдән Фидая өчен тагын бераз ара бушаттылар.

Менә шунда Фазилә аңа каршы торып басты, һәм Давыт аларны таныштырды. Аларның моңарчы да бер-берсен күргәннәре бар, ләкин кара-каршы килеп сүз кушарга туры килгәне юк иде. Менә җай чыкты. Һәм, нык холыклы, акыллы хатын буларак, Фазилә куе керфекләре арасыннан коңгырт күзләренең бер карашы белән кисәтеп куйгандай итте: минем өлешемә кермә, уңмассың... Буйга озын булганга, аның сирень чәчәге төсендәге костюм кигән нык, ипле сыны Фидая янында шактый калкып тора, йөзенә башны чөебрәк карарга туры килә иде.

Эчтәге нәни ялкын теле корыган каен тузына капкандай зурая, ишәя баргандай булды. Фидая аның эссесен йөзенә чыгармаска, башкалар белән йомшак елмаеп, гадәттәгечә ачык, тыныч сөйләшергә тырышты. Үзенең дикъкатен көрәшчеләргә, узышчыларга, ат чабышларына юнәлтте. Давыт янәшәсендә булу читен иде аңа, ләкин китеп тә булмый, биредәге иң зур ике җитәкче иде бит алар.

Ярышлар бер-бер артлы төгәлләнә барды, берара бөтен халык урыныннан кузгалып, шаулашып, атлар чабышын карады. Менә инде тәкәне дә баганадан чишеп алдылар һәм «Җиңүче»дән кунакка килгән Исламның таза җилкәсенә салдылар. Шунда берничә кеше Гаделша янына килеп дәгъвалаша башлады:

— Ул нинди бетмәгән Ислам? Сабан туйлары җитте исә, авылдан авылга барып, тәкә чүпләп йөри.

— Үзебезнекеләргә бирергә кирәк!

— Әнә Сидоровканың Николаена бирергә иде, ичмасам! Ул да үзебезнеке бит. Ник аны икенче генә иттең?

— Мин итмәдем, үзләре итте, — диде Гаделша кайнарланып. — Ничек көрәшсәләр, шулай. Мин — гадел кеше!

— Синең ул гаделлегеңнән гарык инде...

Ләкин бәхәс зурга китмәде, мыр-мыр килделәр дә таралыштылар, чөнки Давыт, микрофон алдына басып, барысына да рәхмәтләр әйтеп, йомгаклау сүзен сөйли башлаган иде инде. Аның сүзе бетүгә, комиссия әгъзалары, бушап калган тартмаларны, әйбер-караны җыеп, «ГАЗ» машинасының әрҗәсенә ыргытырга тотынды. Халык, болынга сибелеп, авылга таба китте.

— Фидая, әйдә безгә чәй эчәргә!

— Юк, безгә!

— Иң олысы мин әле монда, безгә керә ул!

— Рәхмәт, — ди Фидая. — Ашыгам. Кызым әбисе белән калды, мине көтеп утыралар. Кайтып, аларны сыйлыйсы бар.

Ул арада бер төркем хатыннар аны бөтереп алдылар да, үгетләп тә тормыйча, үзләре белән алып киттеләр. Боларының күңеле алгысак, чөнки тормышлары түм-түгәрәк үк түгел. Кайсының ире үлгән, кайсыныкы ташлап киткән, ә кайсылары сазаган карт кыз исәбендә. Көлешәләр, чытлыкланалар, каядыр ашкыналар. Ирле хатыннар андый түгел. Алар бәйрәмдә дә ипле, сабыр, горур.

Әнә алданрак Гаяровлар гаиләсе бара. Давытның сул беләгенә хатыны ябышкан, уң кул очына — матрос киемле малае. Аларга һичкем кирәкми, дөньялары түгәрәк. Бар иде Фидаяның да нәкъ шушылай итеп, кояш нурына коенган яшел болын буйлап, сабан туеннан кайтып килгән чаклары. Мәгъсүмнең бер ягында ул, икенче ягында Иркә...

Хатыннар җырлап җибәрделәр: «Сагынганда ак болытка кара...» Мондый бәйрәмнәрдә дә нигә җырларның моңлысын, сагыну турындагысын җырлыйбыз икән без?

Каршыга түгәрәк ак сакаллы, кыска буйлы, йомры гәүдәле авыл мулласы — Фәтхрахман карт килә. Мәйданда берәр әйберсен төшереп калдырган инде әллә? Авызы ерык, күңеле хуш. Мулла бабай каршына хатыннарның тезелешеп, урам әйләнгән егетләр кебек кычкырып җырлап баруы шәригатькә дә, әдәп кысаларына, гадәт-йолаларга да сыя торган күренеш түгел түгелен. Кыз балаларга кечкенәдән, өлкәннәр каршында авыз күтәреп җырлау түгел, кычкырып сөйләшү, дөньяны яңгыратып көлү дә килешми, дип сеңдерәләр. Шуны уйлап, Фидая эчтән генә кыенсынып куйды. Ләкин болай ярамый дип әйтсәң, аларның кәефе нык кырылачак, бәйрәме бозылачак. Замана мулласының да күңеле киң, җаннарны аңлый торган...

Җырның берсен тәмамлап, икенчесен башларга тын җыеп торганда, читтәнрәк яшь бер тавыш кычкырып җырлап җибәрде:

Җилләр исә, җилләр исә,
Җилгә бөгелә гөлләр;
Безгә түгел, дошманга да
Килә ул кара көннәр!..

Тагын берәүнең күңел сызлавыгы тишелгән. Зиләйлә иде бу...

Балкыш хуҗасын күздән ычкындырмый, «уазигы» белән, күзгә ташланмый гына, әкрен генә арттан килә иде. Фидая хатыннар белән хушлашты да машинага кереп утырды.

— Каләмгөлне алып ук калдылармы әллә? — дип сорады ул. —Бик тиз әйләнеп килдең.

— Кермәде дә ул анда. Кире алып кайтып, өйләренә кертеп калдырдым.

— Бер баргач, врачка күренергә иде инде, — диде Фидая үзалдына.

— Авыл очыннан борылырга кушты. Хатын-кызның акылы керделе дә чыктылы, — диде Балкыш һәм шундук, ялгыш сүз ычкындырганын аңлап, кызарынып, җәлт кенә хуҗасына карап алды. Фидая аның соңгы сүзләрен ишетмәгәндәй үткәреп җибәрде дә, олы юлдан төшеп, инеш буендагы әрәмәлеккә борылырга кушты. Анда, үсеп килгән яшь каенлык артында, юлдан күренми торган җирдә, җиләкле үлән белән капланган иркен генә аланлык бар. Ул арыга таба түбәнәеп, таллы-шомыртлы әрәмәлеккә барып тоташа. Андагы серле ешлыкта, куаклар ышыгында, кизләү мөлдерәп тора.

Элекке елларны сабан туе мәйданыннан укытучылар, җыелышып, туры шушында килә торганнар иде. Мәгъсүм, берәр атна алдан ук һәммәсенә әйтеп, әзерлекне күрә башлый. Уртакка сарык алып, бер көн алдан суйдыралар, монда учак ягып шашлык кыздыралар. Чирәмлеккә җәелгән ашъяулыкка һәркем үз сыен китереп куя. Ашыйлар, эчәләр генә түгел, үзләренә аерым сабан туе да оештыралар. Көрәшәләр, аркан тартышалар, катык эченнән тәңкә эзлиләр. Җырлыйлар, бииләр.

Мәгъсүм булмагач, быел оеша алмаганнардыр, күрәсең, аны-моны әйтүче булмады. Алай да истәлекле урынны күреп, таныш кизләүнең салкын суын эчеп, йөрәкнең януын басасы килә иде...

Ләкин ул ялгышкан булып чыкты: болын буш түгел, элеккечә үк гөрләп тора иде. Чирәмгә ашъяулыклар җәелгән, читтәрәк, сөзәгрәк урынга, учак ягылган. Табын тирәсендә мәш килгән хатыннар машина килеп туктаган тавышка дәррәү борылып карадылар. Елмаешып каршыга атладылар:

— Менә Фидая да килеп җитте.

— Фидая Госмановна, нәкъ вакытында килдең!

Тик берәү — Фазилә генә — урынында баскан килеш, җитди булып калды.

Давыт, бөгелеп, ирләр белән бергә учак янында кайнаша иде, калҗалар тезелгән шампурны күтәреп:

— Хәзер әзер була! — дип куйды да кире иелде.

Каенлык ягыннан: «Әти-и!» — дип кычкырган бала тавышы яңгырады. Учакка таба матрос костюмлы малай йөгерә иде. Ул кулларын алга сузган, башлыгының зәңгәр тасмалары җилдә җилпенә, ак тузганак башлары күкрәгенә бәрелә. «Кинодагы кебек...» — дип уйлады Фидая.

— Юк, сезнең белән утыра алмыйм, ашыгам, — диде Фидая үзен кыстаган хатыннарга. — Өйдә кызым көтә. Тамагым кипте, чишмәгә дип кенә килгән идем...

Ул, таллар арасына кереп, кизләүгә иелде, боздай салкын суны кушучлап кызган битенә сипте.

## 30

Ах, әгәр дә ул ир-ат затыннан булса! Яшәве дә, эшләве бу хәтле четерекле булмас иде, мөгаен.

Кармашта хастаханә төзүне берәр ир җитәкче максат итеп куйса, эше күп мәртәбәләр тизрәк, уңышлырак барыр иде. Чөнки ул шул ук Мирхуҗин белән бөтенләй башкача сөйләшер, кушканын үтәтер иде. Ләкин... Фидаяны күрүгә, Тависның авызы ерыла, күзләре ярык кына булып кала һәм кыска керфекләре арасыннан майлы, ябышкак караш саркып, күңелне тончыктыргандай итә. Һәм ике арада

ниндидер җитди булмаган уйнак мөнәсәбәт урнаша. Фидая үзен кырыс тотарга һәм каты сөйләшергә тырыша. Ләкин күз кунарлык хатын-кыз күрүгә нәфесе котырмаса, Тавис булмас иде шул ул.

Алай да, тамчы таш яра дигәндәй, нәрсәгәдер ирешелде ирешелүен: хастаханә бу елда тапшырылырга тиешле объектлар исемлегенә кертелде. Төзү материалларын шул исемлеккә карап бирәләр, ләкин ул барысына да җитәрлек булмый, булганының да шактые читкә шудырыла. Шуны белгәнгә күрә, ул кирпеч, цемент, бетон плитәләр, торба, җылыткыч батареяләрне, такта-кадак һәм тагын һәр мең төрле кирәк-яракны, кирәгеннән дә арттырыбрак язып, «фонд»лар таләп итте. Ансыз булмый, чөнки бөтен нәрсәне — кирпечен дә, кадагын да — Мәскәү үз исәбендә тота, Казан аннан сорап ала, ә районнар — Казаннан. Тәртип шундый булганга күрә, Мәскәүдән рөхсәт алмыйча, «фонд» бирелмичә торып, бер рәтле бина да торгыза алмыйсың.

Шуннан соң мәсьәлә эшче көчләргә барып терәлде. Райондагыларга гына ышанып ятып булмый, аларны төрле якка тарткалыйлар. Фидая, Казанга барып, андагы танышлары аша, төзүче-инженерлар институтының каникул вакытында оеша торган төзү отрядын Суташка чакырды. Аларга: «Тиз һәм сыйфатлы эшләсәгез, бушлай ашатуны оештырачакбыз», — дип вәгъдә бирде.

Ә азык-төлекне колхозлардан каерып алырга кирәк иде. Председательләргә хатлар язарга туры килде. «Җиңүче»нең хуҗасы Ясәвиев, райком коридорында бер очрагач:

— Сез анда ит, сөт, он сорагансыз, барысын да каян алып биреп бетерербез икән? — диде. — Колхоз сыртын кимерергә атлыгып торучының исәбе-хисабы юк. Әртис килсә дә давай, художник килсә дә... Законный эшме соң бу?

Фидая аның май баскан, әмма шулай да иңгән иңбашын сыйпады.

— Продукциясен кая куясыз дип, якага ябышсалар, кем җавап бирер? — диде, аның елмаюын күрмәгәндәй, җитди калган абзый.

— Бер тиргәгәннән үлмәбез, Хасият абый. Алай-болай кинәт чирләп китеп Кармашка илтеп салсалар, ни булыр, син шуны уйла, — диде Фидая, авыр көрсенеп.

Хасият ачылып китмәде, чөнки хасталап китсә, Суташка яисә Казанның үзенә үк китә. Кысмыр да адәм үзе, саран дияргә була. Әмма Фидая бай хуҗалык саналган «Җиңүче»дән үзенә кирәкне каерып алуның җаен белә иде. Партком секретаре Рәсимә Фәләхова белән генә сөйләшергә кирәк. Ул председательнең урынбасары, хуҗа берәр кая китсә, аның урынында кала. Ясәвиев сәламәтлеккә туймый, кайчак айлар буе эшкә чыга алмый. Әмма бу сизелми дә шикелле, чөнки Рәсимә, «К-700» тракторы кебек, бөтен эшне сыдырып алып бара. Дөньяның җаен белә һәм Фидаяның да хәленә керә.

Җәй башында һәркайда эш кызу булды: Нурхановага сабантуйларын оештыру мәшәкате өелде, студентлар имтиханнар тапшырдылар. Ниһаять, авылда — бәйрәмнәр, институтта сессия тәмамланды, студентларның килер чагы җитте.

Мирхуҗин белән сөйләшенгән, төзү отрядын ул каршы алып, Кармашка үзе илтеп урнаштырырга тиеш иде. Фидая үзе исә иртәнге якта, «Җиңүче»гә барып, Рәсимә белән сөйләшеп кайтырга булды. Аннан тиз генә китеп булмады: чәй эчтеләр, бер-берсенә эчләрен бушаттылар.

Кайтуына Фидаяны яман хәбәр көтеп тора иде: ул чакырып китергән төзүчеләрне «Спартак» колхозына илтеп урнаштырганнар. Анда заманча итеп азык кухнясы төзи башлаганнар иде, шуны ашыктырырга карар кылганнар. Райком ишеге төбендә очрашкан Мөҗәһит Сәлахов шулай диде.

Фидая күкрәгеннән ургылган «аһ!» дигән авазны көчкә йотты. Ир-ат арасында эшләү дәверендә ул хисләрен эчендә бикләп тотарга да, телен тыярга да бераз өйрәнгән иде инде. Кырт борылды да йөгереп бүлмәсенә менеп китте. «Нинди кабахәт кеше бу Мирхуҗин! — дип пышылдады үзалдына. — Әйтү юк, нитү юк, һаман үзенекен итә!»

Телефонны алганда, аның куллары калтырана иде.

— Син урыныңда бул әле. Мин хәзер киләм! — дип кычкырды ул трубкага.

Ул кире әйләнеп чыкканчы, Балкыш машинасын ишегалдына алып кереп юарга керешкән иде.

— Ташла! Киттек! — диде аңа Фидая.

Төзү-монтаж идарәсенең ике катлы иске бинасына барып кергәндә, Фидая Тависның битен-күзен тырнарга әзер, шулхәтле кызган иде.

Мирхуҗин өстәле артында телефоннан сөйләшеп утыра иде. Фидая атылып керде дә аның кулыннан трубканы тартып алды.

— Кайда студентлар?

— Нинди студентлар?

Мирхуҗинның карашында гаҗәпләнү чагылды. Соры күзләре ярыйсы түгәрәк икән!

— Мин чакырып китергән төзү отрядын кая җибәрдең син?

— Ә-ә, аларны әйтәсеңмени... «Спартак»ка илттем мин аларны.

— Кем кушты?

Мирхуҗин тураебрак утырды да пинжәгенең ачык изүен тарткалап куйды.

— Нәрсә, «Спартак» гаеп җирме әллә? Үземә мунча салырга куймадым, — диде ул тыныч кына. Күзләре янә кысыла төште, алардан янә таныш ябышкак сумала саркый башлагандай булды.

Аның ваемсызлыгы, астыртын көлемсерәве Фидаяның канын отыры кыздырды, ул тыела алмый кычкыра башлады:

— Алай карап утырма миңа! Мин синең сөяркәң түгел!

Мирхуҗин елмаеп башын чайкап куйды.

— Кызганычка каршы... — диде. Аннары ияге белән ишеккә ымлады: — Әкренрәк, Фидая Госмановна. Ишекне ябарга оныттың бит.

— Ишетсеннәр! Белсеннәр синең кемлегеңне! Җитте сиңа ни теләсәң шуны эшләргә! Хәзер үк, ишетәсеңме, хәзер үк студентларны кире алып кайт та Кармашка илтеп урнаштыр! Әгәр дә шуны эшләмәсәң...

Мирхуҗин күзләрен зур ачып, бик җитди итеп аның йөзенә туры карады.

— Нишләтерсең икән, Фидая Госмановна?

Фидая, хәлсезләнеп, өстәл янындагы урындыкка, аның каршысына утырды. Чыннан да, нишләтеп була соң әле бу адәмне?! Райкомның өченче секретаре бернишләтә алмый аны!

Күңелне чарасызлык томаны басып, тынны бугандай итте.

— Әгәр шулай кирәк икән, кайтарырбыз, — диде Тавис тыныч кына. — Ничек кушсагыз, шулай эшләрбез. Карышып тормабыз. Тик менә Кармашта барсына да эш фронты җитәр микән соң?

— Материалларны да «Спартак»ка ташыта башладыңмы инде әллә?

— Юк ла, Кармаштагыга тимибез. Ике отряд бер-берсенең аяк астында буталышып кына ятмасלармы анда?

— Нинди ике отряд?

— Кармашка кичә үк төзүчеләр җибәрдек инде без. Тоташ институт укытучыларыннан, һәммәсе менә дигән инженерлар...

Әйе шул, җәйге каникулларда студентлар гына түгел, аларның укытучылары да, төзелешләргә ялланып, акча эшләп ала. Ләкин андыйларның киләсен Тавис Фидаяга әйтмәгән иде.

— Әле Билал белән сөйләшә идек, — дип дәвам итте Тавис. — Сүзне син өздең...

Фидая аның күзләренә карап тынсыз калды. Бу минутта ул үзен-үзе тота белмәгән, бер дә юкка чәбәләнгән бала хәлендә иде.

Тавис, урыныннан торып, ишекне ябып килде. Урынына утырмады, Фидаяга да якын килмәде, ихтирам саклап, ара калдырган хәлдә эчке дулкынлану белән:

— Ә син ачуланганда бигрәк чибәр икәнсең, — диде. — Башка хатыннар дуласа, бик ямьсезләнәләр, син алай түгел.

Беразга тынлык урнашты. Фидая сүз табудан гаҗиз иде.

Тавис көрсенеп алды да:

— Син юкка болай ярсыйсың, Фидая Госмановна, — диде, әкрен тавыш белән, тирән уйланып. — Кешене матур хисләре өчен тиргиләр димени... Ул бит минем теләктән тормый. Йөрәк начальникларга буйсынмый. Аңа берни дә боерып булмый...

Фидая аны башын иеп тыңлады. Тависның хисләре ихлас иде, пычрак уйлар Фидаяның үз башына гына килгән иде, ахрысы. Моның өчен аңа бик-бик оят булды.

— Мин сине аңлыйм, — дип дәвам итте Тавис. — Табигать ул акылга буйсынмый, үзенекен таләп итә. Ә син табигать кушканны тыңламыйсың, аңа каршы килеп яшисең, каныңны шул боза.

Тагын пычрак киная!

Фидая башын калкытты. Әмма Тавис аңа кызарга юл куймады.

— Төзелеш өчен нервыңны ул хәтле талкырга кирәкми, — диде. — Без булганчы да төзегәннәр, бездән соң да төзерләр. Ә больница ел азагына стройга керер. Мин аны очлап чыгачакмын. Синең хакка...

# 31

Баллыболынга бер килүендә Фидая Каләмгөлнең хәлен белеп чыгарга булды. Сабан туе мәйданында булган хәлләрдән соң күңелнең бер почмагында борчу калган иде. Кәефе ничек икән, шуны беләсе килде.

Нарат сагызы аңкып торган яңа өйгә керүгә, Фидая борчылуының юкка түгеллеген аңлап алды. Каләмгөл диванда ятып торган, күрәсең, ишек ачылган тавышка торып утырды, итәгендәге берничә журнал идәнгә шуып төште. Ул Фидаяны күреп аягына басты, журналларын җыеп өстәлгә алып куйды.

Эре чәчәкле киң халат кесәсеннән тарак алып, ике-өч селтәнүдә тузгыган бөдрәләрен рәткә китерде, шул ук тарагы белән сул колак турына каптырып куйды һәм сәхнәгә чыгып басарлык булып ыспайланып китте. Ләкин элеккечә дәртле түгел иде ул бүген, хәрәкәтләре дә аңа хас булмаганча сак, салмак иде. Йөзе дә суырылып киткән кебек, күз төпләре каралган. Исәнләшеп хәл-әхвәл сорашканда да, элеккечә шаркылдап көлеп, шаярып җавап бирмәде, тыенкы гына елмаеп:

— Зарланырлык түгел, — диде. — Йокым туймаган иде бүген, өйдәгеләрнең кайсын эшкә, кайсын уенга дигәндәй озаттым да бераз ятып тормакчы идем.

Гыйззетдин эштә, Зарема чөгендер басуында, ике малай да балалар бакчасында, ял итәр өчен бик уңайлы вакыт икән үзе. Әмма Каләмгөл көндез йокы симертә торган хатыннар затыннан түгел бит. Бүтән чагы булса, эре чәчәкле бу ястык өстендә бәйләп тә яткырып булмас иде аны!

— Врачка бардыңмы соң син? — дип, турыдан сорады Фидая.

— Нишләп йөрим мин анда вакыт уздырып?

— Әйдә, хәзер үзем алып барам да чиратсыз кертәм. Машина капка төбендә генә тора.

— И-и, ташла әле. Бүлнис юлын синсез дә таптарга була. Якын итеп килгәнсең икән, хөрмәтләп кабул итим башта. Кара-каршы утырып чәй эчсәк, дәваның зурысы шул булыр.

Ул, шулай сөйләнә-сөйләнә, өстәлдәге самавырны электрга тоташтырды, табын хәстәрләргә кереште.

— Бу бит хәйран калырлык вакыйга... — дип, чыннан да гаҗәпләнгәндәй башын чайкады үзе.

— Нинди вакыйга?

— Синең, безгә килеп, минем белән кара-каршы утырып чәй эчүең шаккатарлык хәл бит бу! Шулай түгелмени?

Ул ястыкны күрше бүлмәгә кертеп куйды да:

— Утыр иркенләп, — диде. — Авыз ит бар булганын. Их, алым җәл түгел сиңа, гөлем җәл түгел сиңа, алым түгел, гөлем түгел, җаным җәл түгел сиңа. Ир-егетләр булсак, рюмкаларны мөлдерәмә тутырыр идек тә җырлап күтәртер идек. Чәкешеп торып эчеп җибәрер идек. Әллә бераз кабабызмы? Гыйззетдиннең запасы бар анда.

— Анысын, бик теләсәң, мин киткәч алып кабарсың инде, — диде Фидая. — Безнең нәсел чәй ярата, әби дә авылда дан тоткан чәйхур иде. Куерак яса. Сөтне ике кашык сал.

Әллә кайнар чәйдән, әллә дулкынланудан Каләмгөлнең йөзе алланып чыкты, күзләре элеккечә очкынлангандай булды.

— Элеккерәк елларны, син Каләмгөлнең өенә кереп, чәй эчеп, серләшеп утырачаксың әле, дисәләр, үзең дә ышанмас идең, шулай бит? — диде ул. — Начар уйлый идең шул син минем хакта. Гыйззетдингә сөйдергеч эчергән дигән сүзләргә дә ышанган булгансыңдыр әле...

Фидаяның бит очлары кызышты. Каләмгөл хаклы иде. Әйе, гаепли иде ул аны! Бозык хатын ул, гөл кебек гаиләне җимерде, Зиләйләне әтисеннән мәхрүм итте дип, Мәгъсүм белән дә күпме тапкырлар кызып-кызып бәхәсләште. Әлбәттә инде андый әхлаксыз кеше белән һичкайчан бер табыннан ризык җыймас кебек иде. Ә хәзер менә күңелдә тамчы да кинә калмаган.

— Син генә түгел, авыл хатыннарының күбесе шулай уйлый иде, — диде Каләмгөл. Һәм кунагының кыенсынып калганын сизмәмешкә салышып, карашын читкә алды. — Читтән караганда, мин явыз булып күренгәнмендер шул. Минем янга клубка йөргән өчен, кызларын тотып тукмаучылар булды. Кайберләреннән, спектакль куярга сандыгыгыздагы борынгыдан калган калфак йә сөлгеләрне биреп торыгыз әле, дип сорасаң, шуны да җәллиләр. Шулхәтле үчле, эчле кешеләр бар, исең китәр!

— Андыйларга карап тормыйлар бит, клубың гөрләп тора, — дип, аның сүзенә каршы төште Фидая. — Яшьләрне тарта торган магнитың бар шул синең.

— Аларны мин түгел, җыр-бию, яшьлек дәрте тартып китерә. Эч чәеңне, курыкма, сөйдергеч салмадым, — дип көлеп җибәрде Каләмгөл. — Кирәге дә калмаган, сиңа аны бүтән җирдә эчергәннәр инде. Гыйшык хәлләре үз башыңа төшкән, шуңа күңелең йомшаган...

Фидая тетрәнеп китте. Нинди гыйшык? Бу ни дигән сүз? Ниткән урынсыз шаяру?

Бу юлы Каләмгөл карашын читкә алмады, аның йөзендәге үзгәрешләрне текәлеп, көлемсерәп күзәтте.

Фидая да елмаерга, сүзне шаяруга борырга тырышты:

— Кем әйтте сиңа мине гашыйк дип?

Каләмгөл урыныннан торды да киштәдәге китаплар арасыннан кәрт алды.

— Менә шушылар әйтте. Ә алар белә!

— Нишләп әле синең кәртләрең минем гайбәтне сата? Ник син миңа кәрт ачасың?

— Үземә кәрт ачканда, мин сиңа да ача идем. Без бит бу авылда җирнең капма-каршы ике полюсы кебек идек. Мин мондагы хатыннарның иң бозыгы булып саналдым, ә син иң инсафлысы идең. Кемнең

бәхете нинди буласын беләсе килә иде. Алар дөрес әйтә. Әгәр теге елларны килгән булсаң, мин синең күрәчәгеңне алдан ук әйтеп куйган булыр идем.

Фидая Каләмгөлнең озын, сыгылмалы бармаклары арасында җан ияләредәй биешкән кәртләргә шомланып карады.

— Телисеңме, хәзер дә ачып карыйбыз? — диде Каләмгөл.

— Алай бик дәртсенгәч, кыланып кара инде, — диде Фидая.

Каләмгөл чынаякларны читкәрәк шудырды. Аның кулыннан ак ашъяулыкка бер-бер артлы шома, зәңгәрсу катыргы кисәкләре сибелеп, үзенә бер тәртип белән ята башладылар.

— Син черви дамасы. Хәзер карыйбыз: ниләр булган, нәрсәләр булачак, ни белән төгәлләнәчәк, — дип, иң өстәгесен ничектер үзенә бер серле хәрәкәт белән, бераз бөгебрәк тотты да бизәкле ягы белән әйләндерде Каләмгөл. Аннары, калган кәртләрне берәм-берәм әйләндереп салып, үзенә бер көй белән сөйләнергә кереште.

— Йөрәк астында нәрсә, йөрәк өстеңдә ни... Синең яныңа ике король төшә. Карга короле һәм буби короле. Буби короле өйләнгән кеше дигән сүз. Ул синең йөрәк өстеңдә. Күптән түгел аның белән күрешү булган. Аның сиңа мәхәббәте, синең аңа интересың... Ә менә арагызга карга короле килеп төште. Нәрсә булачак? Буби короленең сиңа юлы уравыч булачак. Алда зур сөйләшү, күз яшьләре. Ах, бусы кирәкми иде!

— Нәрсә кирәкми!

— Бик зур удар булачак сиңа. Сәбәпчесе — карга короле. Нәрсә белән тәмамлана? Иң ахырда сиңа озын юл төште менә...

Фидая чынбарлык табигыйлегеннән каядыр башка бер мохиткә, зиһен җитми, әмма күңелне чамасыз кузгата торган хисләргә бай бер әкият дөньясына күчеп киткәндәй булды. Күз алдыннан әле Давыт, әле Тавис чагылып уздылар, күрәзәченең әйткәннәре алар турында һәм, чыннан да, дөрес булып тоелды. Әйе, теге көнне наратлыктагы аланда очраштылар бит. Сүзсез булса да аңлашу түгел идемени ул? Ә Тависның арага керүе хак түгелме әллә? Барысы да хак дөрес иде, шул ук вакытта шомлы да иде...

Каләмгөл кәртләрне җыеп бер читкә куйды да, урыныннан торып, кече бүлмә ишеге янына барып басты.

— Минем баштан узган хәлләр сиңа да килгән икән, — диде. — Хәзер инде син дә, бәлки, аңлый башлагансыңдыр. Элек аңламый идең. Үзе янмаган кеше янганның хәлен каян белсен? Ә син кабынмаган идең шул.

Фидая, аның сүзләренә каршы әйтергә омтылып, калкынып куйды.

— Әйтеп бетерим инде, — дип туктатты аны Каләмгөл. — Ирең сиңа үлеп гашыйк иде, ә син юк. Ләкин моның гаебе дә юк. Синең җаның уянмаган иде әле, фәкать шул гына...

Фидая янә хәйран калды: бу хатын нәкъ Мәгъсүм сүзләрен сөйли түгелме соң? Каян белгән?

— Хәзер үкенәсеңдер, кадерен белмәдем, ди торгансыңдыр... Үкенмә, газаплама үзеңне. Ул барыбер бәхетле иде. Арагызга кер кундырмадыгыз, аның җылысында син күкрәп үскән гөлдәй яшәдең. Ә хәзер менә гыйшык утларында дөрләп янар чагың килеп җиткән. Әллә каян күренеп тора. Мин кичкән тәмуг утларына син керәсең хәзер... Көндезләрен аны уйлап зиһенең чуалып йөрерсең, төннәрең аның белән саташып, бөтен тәнең уттай янып узар. Бу ялкын намусны да, оятны да оныттыра, колакны саңгыраулата. Кеше сүзен ишетми торган буласың. Әгәр ул да сине сөйсә, хисләреннән тәкатьсез булып каршыңа килеп тезләнсә, нишләрсең икән? Аның хатынын, баласын уйлап торырсыңмы? Башың, бәлки, уйлар да. Ләкин андый минутларда кеше акылны тыңламый шул ул! Тән аңа омтыла, куллар үзләреннән-үзләре аңа сузыла. Йөрәк аның йөрәгенә кушылып тибәргә ашкына. Сөяргә-сөелергә, шушы минутта аныкы булырга ашкынасың... Аннары үлсәң дә үкенмәссең кебек тоела.

Фидая боларны керфек кагарга да онытып тыңлады. Каләмгөлнең, ут өертеп, сәхнәләрдә бөтерелгәнен күп тапкырлар күргәне бар, әмма аның йогынтысына шушы кадәр бирелгәне, бу хәтле хисләнгәне юк иде. Әллә соң берәр пьесадан роль отып алган да шуны уйныймы? Репетиция ясавымы әллә? Фидаяны әвәрә итеп, үзенең партнерына әйләндереп, кызык күрсәтүеме? Элек тәкәббер кыланганы өчен шушы рәвешле үч алуымы әллә?

— Гашыйк булган бар кеше үлеп тормый ла инде, — дип, бу тамашаны шаяруга бормакчы булды ул.

— Алай димә... йөрәгеңне суырып алып бирердәй минутлар була... Андый чакларда уйларың да башка якка борыла. Гел генә үз-үзеңне битәрләп, үзең белән үзең сугышып яшәп булмый. Аның бит тагын шунысы да бар: әгәр ир кеше бүтәнгә гашыйк булган икән, аның, үзен мәҗбүр итеп кенә, җаны сөймәгән хатын белән яшәп ятуы яхшымы? Әхлакка сыямы шул? Андый гаиләдә үскән бала нинди була? Бер-берсен сөймәгән ата-ана янында үсү файдагамы аңа? Киләчәктә аның үз тормышы, үз пары, үз мәхәббәте булачак. Аның хакына дип, ике кешене генә түгел, өчәүне бәхетсез итү дөресме? Гаделлекме шул?

— Каләмгөл! Бу рәвешле фикер йөртсәң, мәхәббәт хакына дип кеше үтергән бәндәне дә аклап була! Үз-үзеңне тыя белергә кирәк!

— Әллә син мине тыелмаган дип уйлыйсыңмы? Минем бер дә кеше өлешенә керәсем килмәде. Гыйззетдин каршыма килгән чакларда, күзләремне чытырдатып йомып, кулларымны күкрәгемә кыса идем, аңа тартылган тәнемне артка авыштыра идем. Ахыр чиктә бу авылдан китәргә ниятләгән идем инде. Аралар ерагайса, хисләр суыныр дигән өмет бар иде. Тик бит миннән алда башка берәү авылдан китеп барды шул...

«Башка берәү» дигәне Мөнирә иде.

— Гыйззетдинне миңа калдырып чыгып китте. Шулай түгелмени?! Шуннан соң без нишләргә тиеш идек соң?

— Андый чакта ирләр хатыннарын барып алып кайталар.

— Яратсалар, шулайдыр.

— Мин әйтмәсәм дә беләсеңдер, Мөнирә Гыйззетдинне хәзер дә ярата.

— Сөюләре хак булса, бер киткәч кире әйләнеп кайтмаган булыр. Белә иде бит ул монда аның үзенә дә читен, Гыйззетдингә дә авыр буласын. Ул минем бөтен тормышымны агулады. Әле дә агу салып тора. Әгәр ул булмаса, яшәүләре бөтенләй бүтәнчә булыр иде! — диде Каләмгөл өзгәләнеп. — Берәрсенә кияүгә дә чыкмый, ичмасам. Үзен-үзе аз гына ихтирам итсә, аерылган иренә үч итеп булса да, яңа тормыш корып җибәрер иде. Ә бу юк, күз күеге булып калды. Җитмәсә, кызы каныга, үскән саен ныграк ажгыра. Мине генә түгел, атасын бәреп үтерер иде!

— Син менә миңа алданиләр көткәнен әйттең. Үзеңә ниләр киләсен белгәнсеңдер бит? Кәртләрең әйткәндер? — дип сорады Фидая.

Каләмгөл башын иде.

— Кәртләр күрсәткәнне дөрес итеп уку өчен күз карашың җете булу гына җитми, күңелеңнең тыныч булуы да кирәк. Тик менә сөйгәнең турында уйлаганда, күңел кузгалмый калалмый шул. Шуңа күрә алдагысын белеп булмады... шуңа күрә ниләр күрәсемне чамалый алмадым...

— Туктале, Каләмгөл, ярсыма әле син болай, — дип, аның янына барып, иңеннән сыйпады Фидая. — Буласы булган, буявы сеңгән бит инде. Балаларыгызны үстерәсе бар. Гел үткәннәрне генә уйлап торсаң, акылдан язарсың.

Каләмгөл, чыннан да, авыр хисләреннән арынгандай, чәчен сирпеп, башын селкеп куйды.

— Әйдә, тагын берәр чынаяк чәй эчик әле, — диде. — Хәзер кайнарлыйм.

Бу минутта ул ачык чырайлы хуҗабикәгә әйләнгән иде инде. Менә хәзер Фидаяга Гыйззетдиннең аны ни өчен башын югалтып яратканы аңлашылды. Минут саен үзгәреп торучан, серле, шул ук вакытта бик сизгер, нечкә күңелле, тирән хисле кеше икән ул. Әнә нинди давыллар шаулый икән аның эчендә! Акыл белән аңлап, сүз белән әйтеп бетереп булмый торган тарту көче бар иде анда һәм моңа каршы торып булмый иде.

Фидая нык дулкынланган иде, шунлыктан хастаханәгә бару турында бүтән сүз кузгатмады. Каләмгөлнең хәлсезлеге тән сызлануыннан түгел, җан газабыннандыр, күрәсең, дип уйлады.

# 32

Каләмгөлнең хәле төн уртасында начараеп китте. Гыйззетдин, иңбашына йомшак кына какканга уянгач, бераз вакыт зиһенен туплый алмый ятты.

— Тор әле, Гыйззәтлем, — диде Каләмгөл, авыр пышылдап. Аның кайнар сулышы колакка бәрелде. — Бар, машинаңны кабыз әле. Иртәнгә хәтле түзәрмен дигән идем, булмас, ахрысы... Кан күп китә.

Гыйззетдин сикереп торып утны кабызды, караваттан торып утырган хатынына куркынып текәлде. Җаймәдәге кан тапларын күреп, коты очты. Каләмгөлнең үзен кузгатмаска, табибны монда алып килергә кирәктер, бәлки? Күңелгә Мөнирә килде. Ләкин Каләмгөл аны үзенә якын китермәячәк иде.

Гыйззетдин кабаланып чалбарын, күлмәген киде дә машинасын кузгатырга чыгып китте. Күп тә үтмәде, аның «Нива»сы, фаралары белән җәйге төннең сыек караңгылыгын ертып, Кармаш юлыннан бара иде инде.

Язмыштан узмыш юк, күрәсең. Гыйззетдин, Кармаштагы табибларның яхшы данын белгәнгә күрә, хатынын Суташның үзенә түгел, Кармашка илткән иде. Әмма бик җайсыз чакка туры килде. Хастаханәнең тәрәзәләре караңгы, тышкы ишеге өстендә генә лампочка яна иде. Шактый озак шакылдатканнан соң гына, эчке яктан берәү, бала-чагадай нечкә тавыш белән сузып:

— Кем анда? — дип сорады.

Төнге кизүгә куелган яшь кенә шәфкать туташы булып чыкты бу. Быел гына училище тәмамлап монда эшкә килгәнгә охшаган иде. Ул ишекне ачкач, хәлнең мөшкел икәнлеге беленде.

— Хатын-кызлар табибы — районда атаклы кенәз Йосыпов эшеннән китеп барган, баш табиб Казанда, «Медтехника» кибетеннән яңа аппаратлар юллап йөри. Ә бәлки, үзе дә хастаханәгә кереп яткандыр, кәефсезләнеп тора иде, — диде ак халатлы туташ.

Кызыкай, яшь булса да, үзенең эшен белә иде булса кирәк, эченнән кан коела дигән сүздән хәлне аңлап алды. Машина янына барды да, башын салындырып, йокымсырап утырган Каләмгөлне күреп, чәрелдәп кычкырып җибәрде:

— Уяныгыз! Йокларга ярамый сезгә!

Һәм, иелеп, Каләмгөлнең яңагын чәбәкләргә кереште.

— Бер генә минут мыс итеп алыйм инде, — диде Каләмгөл, күзен ачмый гына.

— Йоклама! Күтәр башыңны! Чык машинадан!.. Тартып чыгар! — дип, кинәт таләпчән тавыш белән Гыйззетдингә борылды кыз.

— Ә бәлки, безгә туры Суташка барыргадыр? — диде Гыйззетдин.

— Барып җитә алырсызмы соң? Мин аны дыңгырдык юлга чыгарып җибәрмим. Гөлфия апа килгәч үз сүзен әйтер. Барып алып килерсең, хәзер шылтыратам, киенә торсын. Суташ белән дә сөйләшәм, кул астында машиналары булмаса, анда да үзеңә барырга туры килер. Гинекологны монда алып килергә кирәк.

Бу төн уртасында берничә кеше, йокысыннан сикереп торып, Каләмгөлне коткарырга дип, өеннән чыгып китте.

Иң беренчесе, билгеле, Гөлфия иде. Ул машинада хастаханәгә килгән арада сораштырды да:

— Авылда телефоны да юк бит аның, ичмасам, — диде. — Шылтыраткан булсагыз, туры Суташка гына барыгыз, дияр идек.

— Әле кичә генә әйбәт иде, бер дә зарланмады, — диде Гыйззетдин.

— Зарлана башлагач кына соң була шул инде ул. Йөкле хатыннарыгыздан авыр эш эшләтмәгез, фельдшерларга гына булса да күренеп, тикшеренеп торсыннар, дип, әз тукыйбызмыни без сезгә.

— Ул... авырлы булгандыр, дисеңмени? — Гыйззетдин аптырашта калган иде, чөнки Каләмгөл андый-мондый хәле турында аңа әйтмәгән иде.

— Тик торганнан болай булмагандыр инде. Авыл хатыннары үз кадерләрен белми бит алар. Йөгенермен дип тормый, сабан туенда узыша. Чөгендергә дә чыккандыр әле.

Гыйззетдин сүзсез калды. Әйе шул, йөгерде. Чөгендер басуында да елдагыча, Мөнирә белән узыша-узыша, киң тәпке белән дыңк-дыңк сугып, каткан җирне тукмады. Ләкин бит Каләмгөл беренчесе түгел! Авыл хатыннары элек-электән мин йөкле дип тормаган, көянтә белән суын ташыган, урагын урган, ашлыгын суккан. Берәрсе, мин корсаклы, дип, бот күтәреп, түрдә ятса, тавыклар көләр иде!

— Авыл хатыннарының барсы да шундый бит инде. Элегрәк әле буразнада бала табучылар да булган. Безнең Гаделша абзый, мин басуда туганмын, кендегемне урак белән кискәннәр, дип сөйли әнә, — диде Гыйззетдин. — Үлмәгәннәр бит, яшиләр.

— Үлгәне үлгән, үлмәгәне калган. Элекке заманнарда аның санын кем алган?

Гөлфия, хастаханәгә килүгә, Каләмгөлне бер ягына ялтыравык тимердән ясалган биек, сәер кәнәфи, икенче ягына ак җәймәле ятак куелган бүлмәгә күчереп яткырды да янына кан салу җайланмасын китереп куйды. Гыйззетдингә Суташка барырга кушты.

Юлда барганда, Гыйззетдиннең хәтерендә Мәгъсүмне хастаханәгә илткән төнне булган хәлләр яңарды. Күңелдәге шом тагын да көчәйде. Ләкин нишләп әле Мәгъсүмнең язмышы Каләмгөлдә кабатланырга тиеш? Һаман-һаман бертөсле булмас бит инде! Коткарырлар Каләмгөлне! Әнә бит күпме кеше, җанын ярып бирердәй булып, төн уртасында чабып йөри!

Суташта өлкән яшьтәге хатын-кыз, минут та көттермичә, машина тавышы ишетүгә, капкасыннан килеп тә чыкты. Кире Кармашка килгәч, Гөлфия Гыйззетдингә:

— Бар, өеңә кайт, — диде. — Монда син бүтән ярдәм итә алмыйсың инде.

— Үзен күреп чыгарга ярыйдыр бит?

— Иртән килеп күрерсең, — диде Гөлфия кырыс кына.

Чыннан да, кайтырга кирәк иде, балалар өйдә үзләре генә калды, уяныр, куркышып, елап ятулары ихтимал. Гыйззетдин кире машинасына утырды.

Иртән күрше Фаязның әнисе Вәсимә карчыкка хәлне аңлатып, балаларны аның карамагына тапшыргач, Гыйззетдин тагын Кармашка китте. Машинасын кабызгач кына, авыру кешегә күчтәнәч белән барырга кирәклеге исенә төшеп кире керде, баздан — каймак, шкафтан бал алды. Бераз вакыт, аларны салырга банка таба алмыйча миңгерәп, бүлмәдән бүлмәгә йөрде. Ниһаять, Вәсимә карчык бар булганны әзерләп, төйнәп бирде.

Ярый әле бераз гына черем итеп алыйм дип ятып торасы итмәгән, аз гына соңрак килсә, хатынын күрми дә калган булыр иде. Казаннан санавиация чакырганнар, ике сәгатьтән килеп җитәчәк икән, Каләмгөлне Суташ аэродромына илтергә дип торалар иде.

— Без кулдан килгәнне эшләдек, тик монда гына дәвалап бетерерлек түгел, каны агуланган, — диде Гөлфия. Моны ул тыныч тавыш белән әйтергә тырышса да, хәлнең авыр икәнлеге бөтен кыяфәтенә бәреп чыккан иде. — Бар, күреп чык.

Гыйззетдин шомланып бусага аша атлады. Аскы өлеше акка буялган тәрәзә пыяласы аша иртәнге кояшның нуры, сузылып, биек, сәер кәнәфинең тимерләрендә чагылып, күзгә бәрелде. Каләмгөл сулдагы ятакка сузылып яткан, өстенә ак тышлы юрган ябынган, башына, маңгаена ук төшереп, ак яулык бәйләгән иде. Теләсә нинди яулык астыннан тырпаеп чыга торган тыңлаусыз, шаян чәч бөтеркәләре дә бүген ак чүпрәк астына поскан иде. Каләмгөлнең һәрвакыт хисле — йә көләч, шаян, йә ярсудан алланган йөзе бүген ак, моңсу, гадәттә очкынлы күзләре бу минутта болытлы төн кебек караңгы иде. Гыйззетдиннең аны мондый хәлдә күргәне юк иде кебек. Бәгырьне кызгану хисе телеп узды.

— Кил әле, Гыйззәтлем, утыр әле яннарыма, — дип, хәлсез хәрәкәт белән янына күрсәтте Каләмгөл. — Ярый килеп өлгердең. Әйтәсе сүземне әйтә алмыйча китәм инде әллә дип курыккан идем.

— Бик ашыгычмыни? Кайткач сөйләшербез.

— Ә бәлки, кайта алмам... Күңелем шулай сизә...

— Юкны сөйләмә! Анда сине шундук аякка бастырачаклар, менә күрерсең. Булмастайны аны... — Гыйззетдин сүз таба алмый торды. — Өметсезне самолет белән әрле-бирле ташып та йөрмиләр.

Ишектән, тавышын күтәрә төшеп, Гөлфия дәште:

— Самолет Казаннан чыккан, диделәр. Кузгалырга кирәк.

— Әгәр мин кайтмасам... — дип башлады Каләмгөл.

— Нишләп кайтмыйсың ди син?

— Әйтеп бетерергә ирек бир, — диде Каләмгөл сабырсызланып. — Өйләнерсең, ризалыгымны бирәм... Тыңлап бетерәсеңме син мине, юкмы?

Аның сүзен өзәргә дип авызын ачкан Гыйззетдин, теләсә нишлә инде дигәндәй, тешен кысып башын иде.

— Тик, бүтәнне ал. Аны түгел. Ишеттеңме? Аны якын китермә! Сүз бир миңа!

Ул ятагыннан калкына төште, агарынган йөзенә ярсу һәм гаҗизлек бәреп чыкты. Гыйззетдин аны кочаклап күкрәгенә кысты.

— Ярый, ярый, борчылма. Ничек дисәң, шулай эшләрбез. Икебез бергә. Менә күрерсең, без, синең бу сүзләреңне искә төшереп, шаркылдап көләчәкбез әле...

Ә Каләмгөл аны тыңламый, үзенекен сөйли иде.

— Үзәгемә үтте, бәгыремне талады... Син дә аны бөтенләй чит итмәдең. Әгәр мөмкин булса, икебез белән берьюлы яшәгән булыр идең. Йөрәгең зур шул синең, аны да, мине дә сыйдыра... Ләкин минем урынны ул алмасын... Теләсә кемгә бул, аңа түгел... Якын китермә! Үзеңә орындырасы булма! Бәхиллегем юк!

Аның сүзләре, саташуга әйләнгән кебек, Гыйззетдинне тәмам чарасыз иткән иде. Ярый әле Гөлфия керде дә ашыктыра башлады. Каләмгөлне, күтәреп алып чыгып, машинаның арткы утыргычына җайлап яткырдылар.

# 33

Күңеле дөрес сизгән икән: бер атнадан Казаннан Каләмгөлнең үле гәүдәсен алып кайтып җирләделәр.

Аның үлеме турындагы хәбәр Фидаяны тетрәндерде, күңелен авыр кайгы басу өстенә, үкенү ачысы әрнетте. Чөнки бу фаҗигадә ул үзен дә гаепле санады. Язмыш аңа бер генә түгел, берничә тапкыр Каләмгөлне коткарырга форсат биргән булган икән бит. Сабан туеннан соң озакка сузмыйча, мәҗбүриләп табибка алып барган булса... Теге көнне аның кәрт ачканына мөкиббән китеп, ник кергәнен онытып җибәрмәсә... Кармашка яңа хатын-кыз табибы китертүне вакытында кайгыртса... Аннан да бигрәк, хастаханәсе яхшы булса, һәм андагы табиблар авыл халкының сәламәтлеген тиешенчә кайгыртып торса... Участок хастаханәләре һәр кешене күздә тоту максатыннан булдырылган да бит инде!

Шул бинаның рәтле булмавы аркасында тагын күпме кешенең гомере вакытсыз өзелер? Ни көтәбез без?

Иртәнге сәгать сигезенче яртыда Фидая Беренченең бүлмәсенә кызуланып барып керде. Кабаланып сәлам бирде дә:

— Бик зур бәхетсезлек булды бит әле бездә, Җәгъфәр Латыйпович, — диде. — Каләмгөл үлгән.

Искәндәров, зур башын өстәлендәге кәгазьләрдән күтәреп, гаҗәпләнеп карады.
— Кем дисең?
— Баллыболынның клуб мөдире. Аллаярова.
— Нәрсәдән үлгән? Машина бәргәнме әллә?
— Юк... Хатын-кыз чире...
— Андый хәлләр дә булгалый шул, нихәл итәсең. Авыр туфрагы җиңел булсын, — диде Искәндәров, битараф тавыш белән, һәм өстәлендәге кәгазьләрне актаргалады.
Фидая карамаса да белә: аларда кайсы колхозда күпме сөт савылган, чөгендер җире эшкәртелгән, печән әзерләнгән һәм силос салынган — шул хакта саннар, хәбәрләр язылган иде. Алар исә һич тә куандырырлык түгел, чөнки район сөт буенча да, силос салу буенча да артта калып бара, ә моның өчен Беренченең башын сыйпамаячаклар.
— Больницалар рәтле булса, мондый хәлләр булмас иде бездә, — диде Фидая. — Кайчанга кадәр?..
Ул сүз таба алмый тотлыгып калды. Искәндәров аның нык борчылганын күреп алды.
— Район хәтле районда туучы да, үлүче дә булмый тормас шул инде, — диде ул, юатырга теләгәндәй. — Андый-мондый көтелмәгән фаҗига гына була күрмәсен.
— Өч бала анасының үлеп китүе фаҗига түгелмени, сезнеңчә?
Сорау шактый тупас яңгырады, Искәндәровның чырае кырысланып китте:
— Партия органнары һәр хатын-кызның итәк астында ни булганын тикшереп йөри алмый, — диде ул, тавышын күтәреп. — Үзен-үзе карасын иде. Ире бармы әле аның?
— Бар...
— Ул Баллыболында безнең эчне пошырган башка нәрсәләр дә җитәрлек әле. Савымны ун литрдан арттыра алганнары юк. Быел менә саламны силослау бурычы куелган иде. Ул эшне дә кузгатканнары сизелми. Син ни карыйсың анда? Яшь җитәкчегә ярдәм итәргә кирәк! Ә син анда шеф итеп беркетелгән! Партия дисциплинасы дигән нәрсәне онытмагансыңдыр бит?
— Мин анда гел булып торам. Гаяров бик тырыша, — дип, акланырга маташкан гаепле бала кебек сөйләнде Фидая.
Бүлмәсенә чыккач, ул башын салып уйга чумды. Баллыболынга барырга күңел атлыгып кына тора да бит, ләкин Давыт тирәсендә артыгын чуалырга ярамый...
Кармашка барырга кирәк иде. Әмма өч көн инде машинаның моторын ремонтлыйлар, иртәгә дә бетмәс әле, диде Балкыш.
Фидая чуалган уйларының очына чыга алмый утырганда, телефон шылтырады.
— Исән-саулармысез, Фидая Госмановна! — диде Мирхуҗинның шат тавышы.
— Ярыйсы. Сезнең хәер-дога белән.
— Безне бөтенләй оныттың әле син, ә? Күргән дә юк.
Чыннан да, Фидая Кармашка ул юк чактарак барырга тырыша иде.
— Машина ватылды әле, — диде ул.
— Без анда шактый эшләр майтардык. Бер җылы сүз әйтер идең, ичмасам.
— Күргәч, әйтермен.
— Әйдә, бергә барып карап кайтабыз!
Фидая тынып калды. Сәгать уннан район клубында «Белем» җәмгыяте лекторлары белән семинар билгеләнгән, анда чыгыш ясыйсы бар. Аннары башкаларның сүзләрен тыңлыйсы. Кыскасы, кичкә кадәр утырырга туры киләчәк иде.
— Молчание — знак согласия! — диде Тавис. — Хәзер килеп җитәм!
— Хәзер генә булмый әле, эшем бар.
— Төштән соңга калдырыйкмыни?
— Кичкә табарак булса инде...
Кичке алтылар тирәсендә җайлы булыр дип килештеләр.
Фидая аны шоферы белән булыр дип уйлаган иде. Күксел «Жигули»ның руле артында зәңгәрсу күлмәкле, тузгыган кыска чәчле Мирхуҗинның үзен күргәч, сөрлегеп киткәндәй булды.
Тавис алгы уң як ишекне ачты.
— Рәхим итегез, ханым, утырыгыз.
— Шоферың кая?
— Казанга туйга китте бит әле минем Равил. Үземнең дә ачу килде килүен дә, җибәрми дә булмады.
— Кеше туй ясаганга ник ачуың килә алай?
— Соң, ни бер бәйрәм түгел, ни ял итә торган чак түгел. Уттай эш өстендә ул нинди туйлап йөрү? Тәмам азды халык.

— Шәһәрдә туйларның көнен загс билгели бит...

— Шул шул менә. Күп тәртипсезлекне җитәкче органнар үзләре оештыра... Утыр инде, нишләп торасың?

Фидая икеләнебрәк калган иде. Әллә берәр сылтау табып баш тартыргамы? Ләкин әле бер, әле икенче төрле сөйләнә башласаң, Тавис моны хатын-кызның җиңел акыллылыгы дип кабул итәчәк иде. Теге көнне әйткәләшкәндәге кебек, ул гына пычрак уйлы булып күренәчәк.

Фидая тәвәккәлләде. Тик Тавис күрсәткән урынга утырмады, арткы ишекне ачты.

Машинаның тимер тартмасына кереп утыргач, кешеләр гадәттә бер-берсенә күңелләре белән дә якынаеп киткәндәй булалар. Юлда сүз үзеннән-үзе ялгана. Ләкин Фидаяның бу кеше белән әллә ни сөйләшер сүзе юк иде.

Тавис атна буе яуган яңгырдан зарланып алды. Колхозларда печән әзерли алмый интегәләр. Ярый, менә бүген аязып китте. Инде яңадан каплый гына күрмәсен...

Фидая исә тәрәзәгә карап бара. Әнә таныш күпердән уздылар. Буага яздан үрдәкләр килгән иде, балалары үсеп беткәндер инде. Фидая машинаның ачык тәрәзәсеннән башын сузып карады, тик үрдәкләр күренмәде... Җәйнең иң матур чагы, соңгы яңгырлардан соң үләннәр, игеннәр үсеп киткән. Чөгендер басуында бер баштан икенче башка сузылган яшел тасмалар нык киңәйгән, күпергән. Урман аланнарында җиләк пешкәндер. Яңгырдан соң ул аерата эре, татлы, хуш исле була. Әнә теге наратлык аланында җиләк мул булыр кебек иде. Урманнарга барырга да вакыт тими, ялгызың йөрергә күңел дә үсми. Янында берәрсе булса икән. Аланда Давыт белән очрашкан минутлар күз алдыннан чагылып узды да тәнгә учак эссесе бәрелгәндәй итте...

— Ясәвиев зарланып ята әле анда, — диде Тавис. — Шәһәрдән килгән осталарыгызга ит-майны миннән генә каерасыз, ди. Башкалар да бирсен, ди. Анысы шулай инде, гел бер кешегә генә салыну килешми. Ник Гаяров бирми әнә? Кереп сорап чыгыйкмы әллә?

Чыннан да, Баллыболын турыннан узып баралар иде.

— Борылыйммы? — дип сорады Тавис.

— Борыл инде алайса...

«Әле иртән генә Искәндәров, «Үзәк»кә игътибарыңны киметтең, дигән иде, аның да сүзен сүз итү булыр, — дип уйлап куйды Фидая. — Ялгыз баруга караганда, икәү булуың яхшырак та».

Идарәдә эш беткән, бер Вәлишин генә үз бүлмәсендә нидер язып утыра иде.

— Гаяровның машинасында рация бар хәзер, — диде Әхсән. — Шылтыратып карыйк әле.

Ләкин Давыт машинасыннан чыккан иде булса кирәк, җавап булмады.

Ул мехдворда, печәнне ваклап киптерә торган АВМ машинасы янында булып чыкты. Шакмаклы күлмәк кигән, яланбаш, ике тракторчы белән кызып-кызып сөйләшеп тора иде. Күксел «Жигули»ны күреп, чалбар кесәсеннән кульяулык алды да, майга баткан кулларын сөрткәли-сөрткәли, машинадан чыгып баскан Мирхуҗинга таба юнәлде.

Тавис исәнләшергә дип кулын сузган иде.

— Саумы, — дип, бармакларын кульяулык белән ышкуын дәвам итте Давыт. — Гафу, кул чиста түгел әле минем...

Һәм, машинадан башын сузган Фидая белән салкын гына исәнләшеп, Тависка таба борылды.

— Иртәдән бирле кабыза алмыйлар шуны, — дип, котсыз машинаның кабинасында казынган тракторчыларга ымлады ул. — Гексохлоранда әвәләнгән тараканнар кебек миңгерәп йөриләр шунда. Исләре дә китми. Бер миңа гына кирәк диярсең. Гыйззетдин дә хатынын күмгәннән бирле эшкә чыкмый... Һаман аңына килә алганы юк...

Ул нык кызган иде, күрәсең, тиз генә тынычлана алмады. Машинадан чыгып, ирләр сүзенә кушылыргамы, әллә утырып кына торыргамы, дип икеләнеп калган Фидаяга исә, аны күргәннән соң, Давыт тагын да ныграк кара коелган сыман тоелды. Кичкырын Тавис белән парлашып кына машинада йөрүен ошатмады, мөгаен. Ул ягы алдан башка килмәгән икән. Хәзер генә Фидая үз-үзенә Давытның күзләре аша карагандай булды да оятыннан кызарынып чыкты...

Ул арада ирләр тагын ниләрдер сөйләштеләр. Читкә караганнар иде, сүзләре ачык кына ишетелмәде. Менә алар машина янына килделәр.

— Минем машина сварка аппараты алып килергә киткән иде, — диде Давыт һәм алгы утыргычка кереп утырды.

— Давыт дус безнең төзүчеләргә бераз ит бирә әле монда, — дип, Фидаяга хәлне аңлатты Тавис. — Идарәдән язу алыйк та аннары складка сугылырбыз.

Авыл урамыннан узганда, кибет турында тукталырга туры килде. Ак халат кигән сатучы Әлфия, су түгәргә дипме, чиләк күтәреп ишектән чыккан иде, узып киткән машина артыннан кул болгап кычкырырга кереште:

— Туктагыз әле! Тукта!

Давытны күреп калган Мирхуҗин, тормозга басып, кире чигенде.

— Исәнмесез, — диде Әлфия, машина тәрәзәсенә иелеп. — Ярый әле күреп калдым. Син сораганны алып кайттым мин, Давыт Зиннәтович. Кереп карыйсыңмы әллә? Иртәгә иртүк сельпога барабыз, ярамаса, алыштырып алып кайтырмын.

Мирхуҗин шундук, кызыксынуын яшерә алмыйча:

— Ни бар анда сельпода? Мин күрмәгән берәр нәрсә түгелдер бит? Кая, карыйк әле, — дип, машинадан чыкты.

Бу юлы инде Фидаяга, нәрсәдәндер читенсенгән ят кеше шикелле, машинада посып утыру килешмәс кебек тоелды. Ул да ирләргә иярде.

Ярыйсы гына иркен таш бинага урнашкан кибеттә, башка авыллардагы кебек үк, товарның төрлесе сатыла иде. Бер якта азык-төлек: тоз, шикәр, конфет-прәннек, консервылар, шешәләр; икенче якта кием-салым: ситсы-клеенка, чиләк-чәйнек, себерке-тырма, сабын, кер юу порошоклары — авыл кешесенә тормыш итү өчен кирәкле дип саналган һәммә нәрсә шушында кайтарыла. Ләкин, килеп керүгә әйбер-кара күп күренсә дә, үзеңә кирәкне табу кыен, күп очракта мөмкин дә түгел. Шуңа күрә үз кадерен белгән һәм мөмкинлеге булган кешеләр сельпо складына керү җаен карый, анда да булмаса, Казаннан йә Мәскәүдән үк кайтарту хәстәренә керешә.

Давыт исә гозерен сатучыга әйткән булган икән. Әлфия, берәрсе килеп кермәсен тагын дигәндәй, ишек ягына караштыргалап, прилавка астыннан зәңгәр бәрхет тышлы кечкенә бер тартма алды. Аның эчендә, кызыл атлас өстендә, бриллиантлы алкалар ята иде. Шактый зурлар, салынып тора торганнар. Моның ишенең, гомумән, алтын әйберләрнең авыл кибетенә кайтканы юк, билгеле. Сельпода ничек тапканнар әле!

Кырыклар тирәсендәге җирән чәчле Әлфиянең кояшта янмый торган ак йөзендә горурлану хисе чагылды, Мирхуҗин аңа ихтирам белән карады.

— Мондый сатучың барда, авылда да кешечә яшәп була шул, малай, — диде. — Хатыныңның туган көнеме әллә? — дип сорады аннары Давыттан.

— Шулай иде шул, — диде Давыт, бик ачылып китмичә.

— Мондыйны бүләк иткәч, хатын майлагандай җайлана инде. Шулай бит, Фидая Госмановна?

Фидаяның тамагына әйтерсең лә кайнар төен утырды, телен әйләндереп сүз әйтә алмады. Туган көнендә аңа мондый бүләкләр бирүче юк һәм булмаячак та инде...

Давыт, икеләнебрәк калган кебек, алкаларга текәлгән иде.

— Иң матуры шушы иде инде, — диде Әлфия.

— Миңа да шундыйны табып бир әле, — диде Тавис, шаяргандай итеп. — Минем хатынга да килешер иде бу.

— И-и, Тавис Бәдыйгович, минем кулга карап тора торганмыни сез... — дип, аска карап, прилавканы сыпыргалады Әлфия. — Безнең сельпоны гына түгел, теләсәгез, Казанга барып, бөтен потребсоюз складларын актарып чыга аласыз...

Әйе, Мирхуҗинның уңганлыгын район халкы яхшы белә иде шул. Давытны да кысарга өлгергән менә, утыз кило ит бирергә ризалаткан. Кибеттән чыгып, идарәгә барган уңайдан, бухгалтер Халисәнең өенә сугылып, аны да машинага утыртып алып киттеләр, чөнки иткә кәгазьне ул тутырып, пичәт басарга тиеш иде. Склад мөдире Гарифҗанны да өеннән барып алырга туры килде. Кыскасы, Мирхуҗин белән парлашып дигәндәй, машина белән авыл урамын тагын бер кат урап килергә туры килде.

Бу көнне булган хәлләрне соңыннан хәтеренә китереп уйлап караганда, Фидая болай йөргәненә үкенеп туймады. Иң элек Мирхуҗинның машинасына утырырга һич ярамый иде. Инде утыргансың икән, Баллыболынга керергә ник риза булды ул? Авыл урамы буйлап ник әрле-бирле йөрде? Күңеле кушмаганда машинага утырмаган булса, ак сакаллы карт булыр иде. Инде авылга килгәнсең икән, Наилә апагамы, Мөнирәгәме кереп калырга иде. Кармашка Мирхуҗин складтан итне алып үзе генә барсын иде...

Фидаяның иң зур хатасы — ирләргә ышанып, алар сүзен алга куеп йөрүендә булды.

Бүген генә суйган сыерның арт ботын, капчыкка төреп, багажникка чыгарып салдылар. Ә Фидаяның күңеленә ниндидер пошаман төшкән, аның Кармашка барып йөрисе килми иде. Соңга калынды... Ләкин итне вакытында иясенә илтеп тапшырмыйча да ярамый, иртәгә таңнан аның артыннан йөрергә әллә вакыты була Мирхуҗинның, әллә юк...

Урам уртасында басып калган Давытның карашы астында Мирхуҗин белән парлап китеп бару күңелне бик тырнады тырнавын, ләкин бу минутларда Фидаяның хатын-кыз табигате өстенлек алып, йомшаклыгы җиңде, машинадан төшеп калырга ихтыяр көче җитмәде.

Кармашта тоташ ике сменага сузылган эш күне тәмамланган, төзелеш мәйданы буш иде. Тавис кичке шәфәкъның тынгысыз нурларында биегәеп утырган яңа диварларны әйләнеп чыгарга әйдәде:

— Шәп бара бит эшләр, Фидая Госмановна! Мактале син мине! Башымнан сыйпа, ичмасам! Ир кеше бит ул синең кебек хатын-кыз каршында гомере буе малай-шалай булып кала! Җылы сүз көтә ул, кәнфит өмет итә!

Чыннан да, төзелеш бик үрчемле бара, Фидая килми торган өч көн эчендә дә шактый нык эшләп ташлаганнар иде: түбәне ябып бетереп киләләр, ишек-тәрәзәләрне куя башлаганнар, озакламый штукатурлый башлаячаклар икән. Куанырга гына кирәк иде. Әмма ни сәбәптәндер Фидаяның күңеле артык очынмады.

Төзелешне әйләнеп чыккач, хастаханәгә керделәр. Бәхеткә күрә, Гөлфия анда булып чыкты.

— Әйбәт булды әле бу, — диде ул. — Суташ аптекасыннан дарулар аласы бар. Кичтән барсам, әниләрдә кунып чыгар идем дә иртүк кире кайтыр идем. Сезнең машинада урын булыр микән?

— Бар-бар, — диде Фидая ашыгып, сөенгәнлеген яшерә алмыйча. Машинада өченче кеше бик тә кирәк иде!

Ул арада Мирхуҗин ит салган капчыкны җирдән өстерәп алып кереп килә иде.

— Әйдәгез, арткы ишектән кертик, суыткыч анда безнең, — дип, аңа юл күрсәтте Гөлфия. Итне урнаштыргач: — Әз генә көтегез инде, — диде ул. — Халатны салып, плащымны гына киям.

Ул бүлмәсенә кереп китте, Мирхуҗин белән Фидая машинага чыгып утырдылар. Гөлфия озак көттермәде, сумкасын болгый-болгый йөгереп тә килде. Ләкин, иелеп машина эченә күз салгач, кинәт хәрәкәтсез калды. Бер руль артындагы Мирхуҗинга карады, бер — арткы утыргычтагы Фидаяга. Аннары чигенде дә сумкасын актарырга кереште.

— Бәй, рецептларны онытканмын икән бит, — диде.

— Алып чык, көтеп торабыз, — диде Фидая.

— Бик озакка китте әле бу, — дип мыгырданды Тавис.

— Сезне көттермим инде, — диде кинәт сүлпән, ниндидер эчке бер мәгънәле тавыш белән Гөлфия. — Аннары, монда берәү авыр операциядән соң хәлләнеп китә алмый ята. Билал да Казанда бит әле, бүген кайтасы иде, нишләптер кайтып җитмәде. «Медтехника»дан аласын алып бетермәгәндер, күрәсең. Монда төнлә үземә кизү торырга туры килмәгәе...

Сүзе дә, сәбәбе дә табылды, ләкин чын дөресе әйтелмәде. Дөресе исә Гөлфиянең бу машинага өченче кеше булып утырасы килмәвендә, рульдәге кешенең моңа ачуы килгәнен сизүендә иде.

Фидая Гөлфияне тартып кертеп утыртырга әзер иде. Ләкин ул борылып китеп тә барды.

— Бала-чага түгел, нишләсен үзе белә, — дип, Мирхуҗин машинасын кабызды.

Алар, калкулыктан төшеп, авылдан чыктылар да кояш баешына таба юл алдылар. Талгын гына агылган болытлар арасыннан балкып, зураеп кояш килеп чыкты да, алсуланып торган бит урталарын офык сызыгына терәп, бар дөньяны тынгысыз да, ямансу да нурга күмде. Бу яктылыктан күз адаша, күңелгә сагыш иңә, юл читеннән шуып узган басулар, агачлыклар күнегелгән төсен үзгәрткән, эченә серләр яшергән кебек тоела иде.

Бу авышу, серлелек Мирхуҗинның да күңеленә иңде бугай, ул рульне сулга каерды да, бодай басуын ярып, каенлыкка таба сузылган басу юлына төште.

— Кая барасың син?..

— Хәзер, хәзер, — диде Мирхуҗин, кысынкы иреннәре арасыннан ярым пышылдап.

Машина, Баллыболын каенлыгы аша узып, таныш аланга килеп керде.

— Мотор кыза, радиаторның суы беткән, — диде Мирхуҗин, машинаны туктаткач. — Монда кизләү бар иде бугай.

Ул, Фидаяга карамый гына, багажниктан ак пластмасс чиләк алды да таллыкка таба китте. Көн җиләс булуга карамастан, ак күлмәге киң аркасы турында юешләнеп чыккан.

— Суга пычрак чиләгеңне тыкма! Чүмечең юкмыни? — дип сорады Фидая һәм, тавышының ихтыярсыздан калтыравын тоеп, машина ишеген кире япты да утырган урынына посты. Тавис аны ишетмәде дә кебек, куаклар арасына кереп югалды.

Ә Фидаяның моңлы күзләрен яшь пәрдәсе каплагандай булды. Ул пәрдә аланлыкны тылсымлы томанга төргәндәй итте, анда җанга якын кешеләрнең шәүләләре калыккандай булды. Менә Мәгъсүм баянының кызыл күреген киергән, такмак уйнап, балаларны биетә... Менә өлкәннәрне җырлата... Менә ул кинәт юк булды, аның урынына учак янына бөгелгән башка берәү җанланды... Аннары, хәзер мин монда хуҗа

дигәндәй, горур баскан, сирень төсендәге костюм кигән хатын пәйда булды. Аның колак очларында асыл ташлы алтын алкалар җемелдәште... Фидаяга ямансу, бик тә ямансу иде...

Таллыктан Тавис килеп чыккач, ул кинәт айнып киткәндәй булды, күзне буган серле томан юкка чыкты, ә күңелне мөлдерәмә тутырган сагыш алды.

Мирхуҗин машинаның капотын ачты да, бүрәнкә урынына яртылаш киселгән пластик шешәне куеп, радиаторга су агызырга кереште. Аннары шап итеп шешә борынын буш чиләккә ыргытты, дыңк итеп капотны япты, машина, тезен чүккәндәй, тирбәлеп алды. Тавис, чиләкне җиргә ташлап, машинаның арткы ишеген ачты. Фидая, утыргычның артыннан берәр нәрсә аладыр бу дип, юл биреп, эчкәрәк авышты. Шул минутта Тавис җәнлек җитезлеге белән аның өстенә ыргылды. Фидая үзен тимер капкынга эләгеп кысылгандай тотты. Ул хыялларына чумып утырган арада, Тавис үз ягыннан бөтенесен әзерләп куйган иде инде, ишектән шуып кергән арада, аның чалбары сыдырылып кына төште, йонлач шәрә тәне Фидаяның тезләреннән өскә таба шуышты, эссе, тыгыз иреннәре авызны каплады, бите, борынны томалап, сулышны буды. Фидая, аңына килеп, карышырга дип кулын күтәргәнче, таш арасына кысылгандай, чарасыз калган иде инде. Ул каршылык күрсәтмәкче булып тыпырчынды, ләкин көчләрнең тигез түгеллеген аңлап тынды. Кайсыдыр бер мизгелдә башыннан: «Ни булса, шул булсын, аннары яши алмасам, яшәмәм дә...» — дигән язмышка үчле уй чагылып узды һәм шул аны җиңелүгә дучар итте дә. Нишләтергә соң бу тәнне, сөелер өчен яратылып та, язмыш тарафыннан сөелүдән мәхрүм ителгән тәнне? Нишләп аны кайсыдыр минутларда акылга буйсындырып булмый икән?!

...Күпмедер вакыттан соң тураеп утырып, итәген тартып, чәчләрен рәтләштергәндәй иткәч, нәрсә булганын аңларлык хәлдә түгел иде әле ул. Машинаның ачык ишеге аша канлы пәрдә аркылы саркыгандай кызгылт яктылыкка төренгән каен ябалдашларына, баш очында куерып каралып килгән болытларга карагач, үзен яман төш күргәндәй хис итте. Менә-менә уяныр да йә өендә, йә эш бүлмәсендә булып чыгар кебек иде.

Ләкин бу саташу түгел, бу чынбарлык иде. Аның аяусыз дәлиле булып, янәшәдә Тавис утыра, саксыз терсәге белән беләккә төрткәләп, чалбарын-күлмәген рәтли, каты мышный. Менә ул, Фидаяның муенын каерып, таза тешләре белән иреннәрне изеп, янә сулышны буды. Авырту Фидаяны аңына китерде, ул, артка тайпылып, учлары белән Тависны читкә этте. Тик тегесенең моңа исе китмәде, он капчыгы кебек, каршылык күрсәтмичә генә кырыйга авышты да, Фидаяның итәген кайтарып, тезен сыйпаштырды:

— Беренче тапкырында шулай булгалый шул ул, — диде. — Әдәп саклаган булып кылана торгач, ир тәмен дә оныта язгансың икән инде. Зарар юк, син бер дә оялып торма. Оныткан гына булсаң, исеңә төшерербез, белмәгәнеңне өйрәтербез. Бездәй егетләр барда, хатыннар ир тәмен онытырга тиеш түгел!

Фидая аның кулын бәреп җибәргән иде, Тавис моны чытлыклану дип кабул итте. Үз-үзеннән бик канәгать кыяфәт белән руль артына күчеп утырды да, педальгә басарга ашыкмыйча, артына борылып:

— Хәзер йөзәр грамм җибәрсәк, шәп булыр иде дә бит, алдан хәстәрен күрмәдек, — диде. — Башка вакытта буш йөрмәскә кирәк булыр. Мин онытсам, син искә төшерерсең, шулай бит?

Фидаяны гүя әллә утлы, әллә бозлы чоңгылга батырып алганнар да кызышкан тәненә сасы лайла ябышкан иде. Бу лайла, аның эченә, үзәгенә саркып, күңелне болгата башлады.

Ул арада шәфәкъ ягыннан бөркелгән сәер яктылык сүнде, офыкны күксел болыт юрганы каплап алды, өстән вак яңгыр сибәләргә кереште. Әйтерсең лә, Фидаяга кушылып, күкләр елый иде...

Машина, каенлыктан чыгып, чыланган бодай басуы аша узды да, алгы ягы белән күтәрелеп, олы юлга менде. Тавис фараларны кабызды. Ул тизлекне арттырган иде, Фидаяның буталган зиһенен бер сорау телеп узды: «Кая барам мин?!»

— Тукта!

Тавис ишетмәде бугай, тамчы эзләре белән чуарланган тәрәзәгә текәлгән килеш калды.

— Тукта, дим!

Бу юлы, борылмый гына:

— Ни бар? — дип сорады ул.

— Мин шушында төшеп калам!

— Нәрсәгә монда? Авыл очында төшәрсең.

«Авыл очында»... Суташ урамына икәүдән-икәү кайтып керергә ярамаганын үзе дә аңлый. Кеше күзе үткен, караңгыда да күреп калулары бар. Ә Фидаяның хәлен аңламый, тәнен кайнар лайла чорнап, күңеле болганганын белми ул.

— Туктат, дим! Югыйсә сикерәм!

Фидая машина ишеген ача башлады. Тавис тормозга басты, көпчәкләр ямьсез чинады, машина, кисәк борылып, юл читендә туктады.

Фидая ишектән атылып чыкты да фараларын яктыртып каршыга килгән машинаның юлына аркылы чыгып басты. Чак тәгәрмәч астына эләкми калды, ян-ягына кызыл тәре сугылган ак «уазик», «Жигули»ны бәрә язып туктады, ямьсез сүгенгән тавыш ишетелде. Аннан кемдер сикереп төште дә Фидаяга таба атлады.

— Син нишлисең? Үләсең киләме әллә?

Ул арада «Жигули», кузгалып, каты үкереп китеп барды, аның артындагы кызыл утлар яңгыр томаны артында кечерәйгәннән-кечерәйде. Фидая каршында Билал басып тора иде.

— Ни булды сезгә, Фидая Госмановна? Кем иде ул?

Күрәсең, ул караңгыда Мирхуҗинның машинасын танымый калган иде.

— Машинагызга утыртасызмы? — дип сорады Фидая.

— Әйдәгез, әйдә!

Билал ярдәм итмәкче булып кулын сузган иде, Фидая корт чаккандай артка тайпылды.

Кызыл хачлы машина хастаханәнең капка төбенә килеп туктауга, ишектән ак халат кигән Гөлфия килеп чыкты. Төнге кизүгә калам дигән сүзе дөрес иде, күрәсең. Ул йөгереп килеп капканы ачты. Ир белән хатын ишек өстендәге лампадан сибелгән яктылыкта болдырга басып сөенешеп чөкердәшкән арада, Фидая авырлык белән машинадан төште дә ачык калган капкадан урам якка чыкты. Тупылның кытыршы кәүсәсенә тотынып, укшып җибәрде.

Билал белән шофер егет машинадан хастаханәгә катыргы тартмалар кертәләр, Гөлфия исә лампа яктылыгында Фидаяга карап басып тора иде. Ул һәммәсен беләдер һәм... гаеплидер, хәтта җирәнәдер кебек тоелды.

Фидая башын иеп аңа таба атлады.

— Мунчагыз җылы микән? — дип сорады.

— Җылы... — Гөлфиянең күз карашы да, тавышы да пыскаклаган яңгыр кебек чиркәндергеч салкын иде. — Җиһансылу апа юынып ята анда. Теләсәң, кер.

Чыннан да, мунчаның хатын-кызлар ягында, җылы, якты алгы бүлмәдә, Җиһансылу ялгызы гына иде. Әле генә кергән булса кирәк, чишенеп тә өлгермәгән, киң, озын, сап-сары эскәмиядә нидер уйлангандай тын гына утыра иде ул. Аналарча игътибарлы, үткен күзләрен күтәреп карауга, ул Фидаяның бик авыр хәлгә дучар булганлыгын тоеп алды. Әмма берни дә сорамады. Берәрсенең явызлыгы аркасында фаҗигагә юлыкканмы ул, әллә үзенең хаталануы нәтиҗәсендәме — Җиһансылу өчен анысы мөһим түгел иде. Фронтларны кичкән кеше буларак, дошман снаряды тигән сугышчыны да, минага үз аягы белән китереп баскан саперны да бер үк дәрәҗәдә кайгырту, дәвалау тиеш, дип саный иде ул. Күп еллар инде тормышның кайнар нокталарыннан читләштерелгән булуына карамастан, аларда кайнаган кешеләрнең хәлен аңлый иде. Бу минутта ул Фидаядан күпкә көчлерәк, зирәгрәк күренде, тез турыларыннан киң итәге салынып торганга, аның гариплеге дә күренми иде, ә йөзеннән, зур, якты күзләреннән мәрхәмәт, рәхим-шәфкать бөркелде. Фидая идәнгә тезләнде дә, маңгаен аның күкрәгенә терәп, үксеп җибәрде.

— Нихәл итәсең, дөнья шундый, егылмый гына яшәп бетереп булмый, — диде Җиһансылу, аның башын сыйпап. — Егылгач торып китсәң, яшәп була әле ул... Аякларыңа ныгытып баса алсаң, куанычлар килә... — Аннары бераз тынып торды да: — Бигрәк олы эшкә тотындың шул үзең дә, — дип өстәде. — Борынгылар әйткәннәр бит: өйне өя-өя көеп беттем, дигәннәр. Ә бу сиңа өй хәтле генәме? Син генә күтәрерлекмени?

Ә Фидая тавышсыз гына елый, күз яшьләре үзләре белән күңелнең уйнаклавын, йөрәкнең сызлавын да тамчылап-тамчылап алып китә иде шикелле.

# 34

Фидая үзен каһәрләнгән, ялгыз итеп тойганда һәм Җиһансылуның йомшак та, көчле дә кочагында үксеп яшь койганда, аның өчен тагын берәүнең йөрәге сыкрый иде. Мәгъсүмнең әнкәсе Шәрифә карчык иде ул.

Аларның, ягъни кайнана белән киленнең, үзара мөнәсәбәтләре баштан ук шома булмады. Мәгъсүмнең кичләрен велосипедка атланып Баллыболынга нинди кыз янына чапканын белгәч, ул Фидаяны үз күзләре белән күрү җаен эзләде. Октябрь бәйрәменә багышланган бер кичәдә сары чәчле, ак чырайлы, чөенке борынлы бер кызны күрсәттеләр аңа. Баллыболыннан концертта катнашырга бер төркем өлкән класс укучыларын алып килгән, шулар белән әвәрә килә иде ул. Шәрифә аның балалар белән ничек таләпчән, нык сөйләшкәнен, үзен ничек эре тотканын җентекләп күзәтте. Һәм шомга төште: башын чөебрәк куйган, җитез хәрәкәтле бу кыз аңа артык чая, артык горурдыр, башкалардан өстен булырга күнеккәндер кебек күренде. «Ай-һай ла, мондый кыз йомшак табигатьле Мәгъсүмгә баш биреп торыр микән!» — дигән шик сызды күңелне. Үзенең озын гомерендә Шәрифә андыйларны шактый күргән иде инде: халыкны

оештырырга, җыелышларда сөйләргә, демонстрацияләрдә байрак күтәреп йөрергә маһир алар, иргә ярарга, өй карарга дисәң, теләкләре дә юк, көчләре дә калмый. Шәрифә исә үзенең улына, мондый ук күзгә ташлана торган чибәр булмаса да, тыйнак, сабыр, ипле кәләш тели иде. Матурлык туйда кирәк, акыл көн дә кирәк, диләр бит. Ә хатын-кыз өчен акыл ул иң беренче чиратта ирне олылауны, аңа буйсынуны аңлата.

Шәрифә үзенең шик-шөбһәләрен читләтеп кенә улына сиздерергә тырышып карады, ләкин гыйшыктан башы әйләнгән кайсы гына егет ата-ананың сүзенә колак сала соң? Хисләренә дә, сүзенә дә тугрылыклы бала иде шул Мәгъсүм. Ул Фидаяны алып кайтып: «Әни, бәхетле кеше күрәсең килсә, миңа кара, бүгенге көндә миннән бәхетлесе юк», — дигәч, Шәрифә эчтән куырылып килде. Иреннән иртә тол калып, ике улын ялгызы үстергән Шәрифә өлкән улы Маннур, армиядән кире кайтмыйча, ерак җирләрдә калганга, картайган көнемдә кече улым белән аның гаиләсенә сыенып яшәрмен, дип өметләнә иде. Ләкин килен аның тормышына кояшлы көн булып түгел, салкын яңгыр булып килеп кергәндәй булды. Бөтен хикмәт шунда: яшьләрнең мәхәббәте тигез булмауда, яшь киленнең иренә салкын калуында иде. Ана күңеле моны сизә, рәнҗи, ә бу рәнҗеш киленнең кечкенә генә кимчелеген дә зурайтып күрсәтә, кулыннан ялгыш кашыгы гына төшеп китсә дә, кайнананың җен ачуларын чыгара иде. Ул халыкның сөймәс килен сөяк тотар дигән мәкален исендә тотканга күрә генә ачуын тышка чыгармаска тырышты.

Үзе өчен иң газиз булган ике кешенең бер-берсе белән дуслаша алмавы Мәгъсүмне бик борчыды, билгеле. Ул моның сәбәбенә төшенә алмады, ахыр чиктә: «Бик күп китаплар укыдым, күбесендә килен белән кайнананың дошманлыгы турында язылган, тормышның табигый бер көйсезлегедер инде бу», — дип, үз-үзен юатты һәм аларны еш очраштыру өчен артык тырышмый торган булды.

Аның вафаты бөтен тормышның астын өскә китергән кебек, килен белән кайнана арасындагы мөнәсәбәтләрне дә нык үзгәртте. Уртак кайгы әйтерсең лә Шәрифәнең күзен томалаган кара пәрдәне алып ташлады, ул Фидаяны өр-яңадан күргәндәй булды. Сөймәс килен урынында аның каршында бөтенләй башка берәү — газиз ирен, баласының атасын югалтудан сыгылып төшкән хатын басып калган иде.

Аның янында Иркә дә бар бит әле. Баланың баласы балдан татлы, диләр, Шәрифәнең җәрәхәтле җанына ул гына шифа бирә. Аларның Суташка күчеп килүе аның бәхетенә булды. Дөрес, бер йортта яшәү турында сүз кузгалмады, әмма кайнана киленгә бик кирәк кеше булып китте: ул һәр кич килеп баланы бакчадан алып кайтып ашата, гөлләргә су сибә, еш кына ашын да пешерә. Фидаяның эш сәгатьләре чикләнмәгән, ул күп вакыт бик соңарып кайта. Аңа кирәкле булу, Иркәне карау карчыкка олы юаныч иде.

Тик менә болай яшәү озакка барырмы? Белгән-күргәннәр дә: «Киленең бик чибәр, эше дә кеше арасында, озак ялгыз йөртмәсләр», — дип, йөрәкнең ярасына әледән-әле тоз сибеп торалар. Ярый ла, киң күңелле адәм туры килсә... Ләкин хатынының элекке ирен искә төшереп тора торган карчыкны кем генә үз өенә якын китерер икән? Андый кешене табулары, ай-һай... Димәк, әгәр дә Фидая кияүгә чыкса, Шәрифә Иркәне күрүдән мәхрүм калачак бит...

Бу уйдан карчыкның йөрәге телгәләнә иде. Ул һәр көн күрешкән саен килененең йөзенә сорау белән текәлә, күңеле шулкадәр сизгерләнде ки, хәтта Фидаяның әле үзе дә аңлап җиткермәгән кичерешләрен яралгы вакытында ук күреп ала иде шикелле. Киленен ул булачак иреннән, әле күрмәгән, белмәгән кешедән көнли иде.

Әле аязып, әле яңадан явып торган бу кичне Шәрифәнең йөрәге аерата нык сыкранды. Каядыр барасы булса, Фидая алдан ук әйтә: «Әни, иртәгә кич мин авылга концертка барам, соң кайтылыр, мине көтеп тормагыз, Иркәне ашатып, йокларга яткыр», — дип, бер көн алдан ук кисәтеп куя торган иде. Бу юлы исә аны-моны әйтмәде, ә үзе кайтмый да кайтмый. Баланы ач тотып булмый, шактый гына көттергәннән соң, ашны яңадан җылытып ашадылар, Иркәне иркәләп-назлап, белгән әкиятләрне әллә ничәнче кат сөйләп йоклатканнан соң да шактый вакыт узды.

Ниһаять, капка төбенә машина килеп туктаганы ишетелде. Тик бу Фидаяның үз машинасы түгел, Шәрифә аның тавышын ук таныргa өйрәнгән иде инде. Ят гүелдәү иде бу. Тәрәзәдән карап, өй турында кызыл тәреле ак машина торганын күргәч, карчыкның йөрәге жу итте: ни булды икән, Ходаем?

Шәрифә, бәргәләнеп, тышка атылды. Аллага шөкер, капкадан Фидая үз аягы белән кереп килә иде.

— Ул-бу булдымы әллә?

— Үземнең машинам ватылды, юл уңаеннан утырып кайттым, — диде Фидая, ничектер тоньк, карлыккан тавыш белән.

Өйгә кергәч, ут яктысында килененең юешләнеп шомарган, тоныкланган чәчен күреп, Шәрифә:

— Яңгыр астына эләктеңмени? — дип сорады.

— Юк, мин мунча кердем...

Килененең өтек кыяфәтеннән, яңгырда күшеккәндәй тавышыннан, барыннан да бигрәк, «мунча кердем» дигән сүзләреннән Шәрифә һәммәсен аңлады. Менә ул курыккан көн дә җитеп килә. Кешесе табылган, буласы хәлләр булган...

Ләкин ник шушы хәтле сөмсере коелган соң бу киленнең? Еллар буе иркәләү-наз күрмәгән яшь хатын, ниһаять, берәү белән кавышкач, бөтенләй башка кыяфәттә булырга, ләззәт диңгезендә йөзгәннән соң килә торган рәхәт хәлсезлек кичерергә тиеш иде бит... Йөзе якты, тавышы чиста, хисле булырга тиеш аның... Ә бу — язгы ташу суына төшеп өшәнгән маэмай кебек...

Көчләгәннәр... Ире-яклаучысы булмаудан файдаланганнар... Шәрифәнең йөрәк түреннән кайнап, ачу, җирәнү хисләре күтәрелде һәм бу ташлы, ләмле дулкын кызгану хисен күмеп киткәндәй булды. Мондый очракта улы кичерергә тиешле хисләр кайнады аның күңелендә...

Ләкин акыл сакта тора, акыл аны сорашудан, ялгыш сүз ычкындырудан тыя иде.

— Ярый, мин киттем! Аш әзер анда, җылытып ашарсың!— диде ул, ясалма, күтәренке тавыш белән. Һәм ашыгып плащын киде дә йөгерә-атлый урамга чыкты.

Каршыдагы ресторанның тәрәзәләрендә ут балкый, аннан көе колакка ятышсыз, сүзләре аңлаешсыз җыр ишетелә иде. Дөнья без дигәнчә генә бармый.

«Ул куанып, очынып кайтып керсә, минем өчен яхшырак булыр идеме әллә? — дип уйлады Шәрифә. — Болай әле тиз генә оя корыр төсле түгел. Бәлки, тегесе хатынлы кешедер. Теләсә нишләсеннәр, тик Иркә белән минем араны гына өзмәсеннәр...»

Шуны уйлап, ул үзенә юаныч табарга тырышты.

## 35

Каләмгөлнең җеназасында да, аннан соң да Наилә Гыйззетдингә кат-кат әйтте:

— Олы мәет үз артыннан бүтәннәрне тарта торган була, балаларны да сакла, үзең дә саклан, — диде.

Бәла дигәне, чыннан да, озак көттермәде. Гыйззетдин сагыш дәрьясына бата-чума, йокылы-уяулы яткан бер төндә, кече бүлмәдән Зарема чыгып, куркынган тавыш белән пышылдады:

— Өлфәт буыла анда!

Чыннан, ачык ишектән баланың сызгыру аша бик каты ютәлләгәне ишетелде. Гыйззетдин, йөгереп кереп, аны күтәреп алды. Зарема ут кабызды. Сабыйның чырае чөгендердәй кызарган, күзләреннән яшь ага, тамагыннан һава, сыбызгы аша узгандай, сызгырып кына уза иде. Ул әтисен күреп сулкылдарга тотынды, елаган саен сулышы ныграк кысылды. Гыйззетдин үзе сулу ала алмагандай булды. Әллә Наиләнең әйткәне хак киләме?

— Мә, тотып тор әле! — дип, баланы Заремага сузды да кабаланып чалбарын кияргә кereште ул. — Тизрәк, тизрәк! Мөнирәгә йөгерергә кирәк! Коткарса, фәкать ул гына коткара ала!

Ул ни арада күпер аша чабып барып җиткәнен сизмәде, өстенә «Медпункт» дип язылган капканы йодрыгын авырттырып какты.

— Мөнирә, мин бу, мин, Гыйззетдин! — дип, урамны яңгыратып кычкырды.

Тәрәзәдән өмет йолдызының нуры булып яктылык сирпелде. Ишек шыгырдаган тавыш Газраилне куган фәрештә канатының җилпенүе кебек тоелды.

Мөнирә баланы медпункт ягына алып керде дә, берни сорап тормыйча, ак пыяла шкафтан нәни шешә алып, стакандагы суга берничә тамчы тамызды һәм сабыйның инде күгәрә башлаган иреннәренә китерде.

— Эч. Хәзер бетә.

Аңа килеп ирешкәч, яшисең дә яшисең инде! Гыйззетдин, баласын кочагына кысып тоткан килеш, рәхәт хәлсезлек тоеп, Мөнирәне күзәтеп утырды. Менә ул ак чаршау белән бүлеп алынган кече яктан халатын алып чыгып китте, толымнарын җыеп, ак яулыгын чөеп бәйләде. Аннары чыгып китте дә, озак та тормыйча, кайнар сулы чәйнек тотып керде.

— Хәзер тәпиләрне җылытабыз, — диде. Ак ләгәнгә башта кайнар, аннары салкын су салды, шкафтан банка алып, аннан мул итеп сары порошок сипте. Борынга Зиләйләнең бала чагыннан бик таныш горчица исе килеп бәрелде. Салкын тигән чакларда Мөнирә кызының аякларын менә шушылай җылыта торган иде. Ул Гыйззетдиннең каршысына тәбәнәк ак эскәмия куйды, аның өстенә ләгәнне урнаштырды һәм, тезләнеп, нәкъ нәни Зиләйләгә дәшкән кебек назлы тавыш белән:

— Яле, балакай, бир әле тәпиләреңне, — диде. Һәм бик сак, иркә хәрәкәт белән, малайның аякларын пар бөркеп торган суга батырды. — Пешермиме? Хәзер без сиңа кызыл оекбаш кигезәбез. Кызыл оекбаш бик матур бит ул, шулай бит?

Әллә аның тавышыннан, әллә горчицалы судан саркыган җылы баланың тамырларына таралды, сулышын ачты, йөрәк тибешен җайга салды. Сабыйның тәне аша бу җиңеллек Гыйззетдингә дә килеп ирешә, аның күптәннән тынгы белмәгән җанына ял бирә иде.

Бераздан Өлфәтнең керфекләренә йокы эленде, Мөнирә аны ак чаршау артындагы ятакка кертеп салды.

— Ларингит анда, — диде, борылып чыгып, ләгәнне ишек төбенә алып куйгач. — Суык тигән.

— Чирләгәне бер дә сизелми иде бит. Кинәт башланды, — диде Гыйззетдин.

— Кинәт башлана, гадәттә төнлә китереп кыса башлый шул ул. Тамак эчтән шешә дә сулыш юлын каплый.

— Котым очты, үлә дип торам.

— Гадәттә бер өч көннән үтә ул үтүен. Тик барыбер берничә төнне бик сакларга кирәк инде.

— Син безне ташлама инде, Мөнирә, — диде Гыйззетдин һәм аның кулын тотып яңагына кысты. — Бәлки, син аны кич кунарга үз яныңа алырсың?

Мөнирәнең үз хәле хәл, аны эчке бер калтырану биләп алган иде, телен әйләндереп каршы әйтә алмады. Хәер, әйтә алса да ни дияр иде? Хасталаган кешеләрне карау фельдшер вазифасы түгелмени? Күңеле яралы бу газиз эти кеше үзе дә авыру түгелмени?

Әллә ни булды Мөнирәгә, Гыйззетдиннең яңагы кулны пешерде! Юк, кулны гына түгел, йөрәкне пешерде ул, һәм бу кайнарлык уйларны чуалтты. Аның сул кулы, үзеннән-үзе күтәрелеп, сагынылган хәрәкәт белән дөньядагы иң газиз кешенең чәчләреннән сыйпарга кереште.

Кинәт шартлап ишек ачылды. Бусагада, мәһабәт бер кыяфәт белән яктырып, ак җәймәгә уралган Зиләйлә басып тора иде. Аның бөтен рәвешеннән ачу ташый, күзләреннән боз суыклыгы бөркелә, бер чите муенына уралган, икенче чите идәнгә салынып төшкән җәймә аны сәхнәдә фаҗигане тасвирлаган артистка охшаткан иде.

Бер мәлгә өчесе дә тынсыз калдылар. Гыйззетдиннең колагына Мөнирәнең йөрәк тибеше генә бәреп торды. Бу күпмегә сузылгандыр, беркем дәшмәде, ниһаять, Зиләйлә борылды да бусага аша кире атлады, ачу белән ишекне шапылдатып япты. Күренеш шуның белән тәмамланырга тиеш иде. Ләкин кыз уйлаганча килеп чыкмады — җәйменең почмагы ишеккә кысылып калды, аны ачарга туры килде. Балаларының чәпчегәнен күзәтеп торган ата белән анага кызык булып китте. Алар елмаештылар да бер-берсенә тагын да ныграк сарылдылар.

## 36

Иртән эш башлануга, гомуми бүлектән Фидаяга зур бер конверт кертеп бирделәр. Почта аша килгән бу конверт Рамиләдән булып, аннан ватман кәгазь битләренә ясалган шаян төлке, моңлы куян, хәстәрле керпе сурәтләре килеп чыкты. Рәссам хатын Рамилә узган елгы сөйләшүне онытмаган, Кармаш хастаханәсенең балалар бүлегенә, диварларга ясар өчен рәсем үрнәкләре җибәргән. Кечкенә генә сәлам хаты да бар: «Сезнең белән кич утырган чакларны сагынып искә алам, хастаханәгезне бизәшергә мине чакырырсыз дип көтәм», — дип язган. Фидаяның күңеле нечкәреп, күзләренә яшь килде. Бергә серләшеп үткәргән озын кичләр нинди күңелле булган икән бит! Ул чакта Фидая үзе дә, уйлары да, хәтта кайгы-хәсрәтләре дә саф-чиста, керсез иде, ә бу — үзе бер бәхет икән ләбаса! Хәсрәтләрнең пычрагы, йөз каралыгы китергәннәре, кешегә сөйләргә ярамаганнары да була икән бит! Менә шундый кайгы талый Фидаяның бәгырен һәм хәзер инде Рамилә белән кич утырырга туры килсә дә, аны сөйләп булмаячак, чөнки баштан кичкәннәре оят кына түгел, әхлакый җинаять дәрәҗәсендә иде.

Коридорда аяк тавышлары ишетеп, Фидая ян өстәлдә таралып яткан рәсемнәрне тискәре ягы белән әйләндереп куйды. Алар бер сер кебек, теләсә кемгә, бигрәк тә арадан берәүгә күрсәтәсе килми иде. Ә коридордан аның ишегенә таба нәкъ шул «арадан берәү» дигәне килеп ята — Фидая аның аяк тавышын таныды. Ул ашыгып үз өстәле артына кереп утырды. Ишектән, пинжәк итәкләрен җилпендереп, Мирхуҗин килеп керде.

— Саумы! — дип, тукталып та тормыйча түргә узды, Фидаяга терәлеп диярлек килеп басты ул.

— Исәнме!

Тавис баш түбәсенә кайнар сулышын өреп биегәеп торганга, Фидаяга кысан булып китте, ул да урыныннан күтәрелде. Ләкин тураеп өлгермәде, Тавис аны кочаклап алды да, көчле куллары белән киң күкрәгенә шытырдатып кысып, авызы белән сулышын каплады. Фидая ычкынырга маташты, ләкин Тавис баш артыннан чәчен умырып тоткан, кыймшанып та булырлык түгел иде. Бу хәлсезлек, чарасызлык күпмегә сузылгандыр, ниһаять, ул авыздан аерылды, әмма шундук иреннәре белән дә, тешләре белән дә муеннан каптырып алды. Фидая, бүлтәеп чыккан иреннәре белән, куркынып пышылдый иде:

— Син нәрсә... Тукта, харап итәсең... Хәзер берәрсе килеп керсә... Монда ярамый...

— Ә кайда ярый? — диде Тавис, аның муеныннан аерылгач, шашынган күзләре белән аңа карап. — Мин сине тагын кайда күрә алам? Чакырган җиргә килмисең, телефоннан рәтләп сөйләшмисең. Андый чакта ир кеше нишләргә тиеш, синеңчә?

— Үзеңне кешечә тотарга тиеш! — диде Фидая, бар ныклыгын җыярга тырышып. — Мин синең сатып алган малың түгел болай кыланырга! Моннан соң минем кабинетыма якын киләсе булма!

— Фидая аны әйләнеп узды да ишекне барып ачты:

— Чыгып кит хәзер үк! Кирәгең чыкса, үзем чакырырмын!

Тависның болай да кара чыраена кисәү төсе иңде, күзләрендә, бу охшашлыкны көчәйтеп, шәмәхә ялкын телләре уйнагандай булды.

— Әһә, шулаймыни? Сиңа бөтенләй кирәгем чыкмавы да мөмкинмени әле? — диде ул ысылдап. Ни кызган булса да, коридордан үтеп-сүтеп йөргән берәрсенең мондагы талашны ишетүеннән сагая иде үзе. — Мин сиңа ярап бетә алмадыммыни? Башка бүтәннәр ныграк ошыймыни? Кара аны, минем белән алай уйнарга ярамый. Уеннан уймак чыкмасын! Мин сиңа уенчык түгел!

Аның бөтен торышыннан, тәненнән хәтәр, шомлы янау бөркелде. Ул чыгып киткәннән соң, Фидая сумкасыннан кечкенә көзге алып карады. Иреннәр шешенеп, турсаеп чыккан, муенда зур гына кызыл тап пәйда булган. Бераздан ул зәңгәрләнеп чыгачак һәм очраган берәүгә Фидаяның уйнашчы хатын икәнлеген әллә каян белгертеп торачак. Әгәр Давыт очраса?!

Өйгә кайтып, бу ачык якалы зәңгәр костюмны салып, ябык якалы кофта кияргә кирәк иде. Ә бәлки, муенга ак шарф бәйләргә... Ләкин тап бик югары, колак яфрагы астында ук диярлек, капларлык кына да түгел. Мондый гамәлләрнең рәтен яхшы белә, күрәсең, Мирхуҗин... Инде ничек чыгып китәргә? Иртәнге сәгатьтә коридорда да, ишек төбендә дә кеше өзелми...

Фидая, тарагын алып, чәчен сул якка тарарга кереште.

...Ә ишек төбенә, чыннан да, яшел «уазик» килеп туктады, аннан Давыт төште. Каршыга бик кызган кыяфәттә Мирхуҗин килеп чыкты. Давытны күрүгә, аңа каршы атлады.

— Тәмәке белән сыйла әле, малай, — диде, кул биреп исәнләшкәч.

— Мин сине тартмый дип беләм бит, — диде Давыт һәм кесәсеннән «Родопи»ның алтын язулы ак тартмасын чыгарды.

— Артык нервыга тияләр шул кайчакта, тартмас җиреңнән тартырсың.

— Беренченең кәефе начар чакка туры килдеңме әллә?

Тавис тәмәке төтенен йотлыгып суырды да:

— Беренченең генә көен көйли беләбез анысы... — диде.

— Сине чыгырдан чыгарырдай тагын кем бар бездә?

Тавис мәгънәле итеп башын боргалады, бер аска, бер өскә карады. Икенче катта, баскыч мәйданчыгы тәрәзәсендә Нурханованың йөзе чагылып узды. Нәкъ шул минутта башын күтәргән Давыт аның йөзендә курку чалымнарын күреп калды.

Тавис, әңгәмәдәшенең йөзе үзгәреп киткәнен сизеп алды да, авызын чалшайтып, иреннәре арасыннан төтен өрде:

— Әллә, мин әйтәм, без синең белән уҗымда уртак малга тап булдык инде? — Аннары кызарынып чыккан, сүз таба алмый торган Давытка текәлеп карады да: — Дуслар өлешенә керү яхшы түгел, — дип өстәде.

— Кем өлешенә кергән әле мин?

— Әгәр беләсең килсә, муенына кара, — диде Тавис, мәгънәле итеп. — Минем малның тамгасы шунда булыр.

Давытның ихтыярсыздан йодрыклары йомарланды. Ишектән сөйләшеп-көлешеп бер төркем ирләр килеп чыкмаса, ул Тависка китереп бәрә иде.

— Башка җирдә очрашырбыз әле, — дип, теш арасыннан пышылдады ул һәм ашыгып ишектән кереп китте. Икенче катка күтәрелеп, коридордан барганда, аның каршына бүлмәсеннән Нурханова килеп чыкты.

— Исәнмесез, Фидая Госмановна!

— Саумысез...

Күтәрелеп карау юк, хәл-әхвәл сорау юк — выжт итеп баскыч мәйданчыгына таба китте бу. Эре бөдрәләрен сул якка тараган иде, әмма алар җилпенеп куйды да астан кызыл тап күренеп калды.

Давытның куллары хәлсезләнеп салынып төште: Мирхуҗинга ачу саклауда мәгънә юк, чөнки эш анда түгел, эш Нурханованың үзендә, дип уйлады ул.

# 37

Гыйззетдиннең берничә тапкыр, кич, караңгы төшүгә, баласын күтәреп медпунктка баруы, аннан соңгы көннәрдә Мөнирәнең бала янына бик еш килеп йөрүе һәм ул өйдә озак-озак торуы турында авылда сүз бик тиз таралды. Хатыннар бу хакта бер-берсенә гайбәт итеп түгел, мактап сөйләделәр. Яшь балалар белән тол калган ир кеше үзенең элекке хатынына бармыйча, кемгә барып егылсын тагын? Дөрес, Каләмгөлнең үләр алдыннан нинди васыять әйтеп калдырганын да беләләр, мәрхүмәнең соңгы сүзен аяк астына салып

таптауның яхшы түгеллеген дә онытмыйлар. Ләкин үлем чиреннән зиһене чуалган хатынның теленә ни килмәс? Көнчелек галәмәте җан бирүдән дә ачыдыр, күрәсең, кабер якасына баскач та, көндәшенә үчләнүдән бизми икән бу адәм баласы... Үзара шулай сөйләштеләр хатыннар. Каләмгөл үзе дә фәрештә булып кына яши алмады, кеше ирен кан-яшь түктереп тартып алды бит, дип өстәп куючылар да булды.

Менә хәзер һәммәсе үз урынына кайта, гаделлек өскә чыга иде шикелле. Каләмгөлне дога белән искә алырга да Мөнирә өчен сөенергә генә кала. Тик бер кешенең уй-кичерешләре искә алынмый — ул да булса Зиләйлә иде. Аның атасына каты бәгырьле булуын белсәләр дә, моны холыксызлык, әдәпсезлек, хәзерге яшьләрнең олыларны санга сукмавының бер мисалы дип кенә кабул иттеләр. «Гыйзззетдингә дә каршы әйткән бала булыр икән! Авылда беркемдә юкны китереп биреп тора, гөл итеп киендерә. Артык иркәләделәр шул, артына атасының каешы эләкмәде», — диештеләр.

Бу гаиләнең язмышы нинди дулкынга эләккәнен чамалаган Балкышның гына кыз өчен йөрәге сыкрана иде.

Бер кичне Нурханованы өенә иртәрәк илтеп куярга туры килде дә, Баллыболынга үзе генә барып килергә ниятләде ул. Караңгы төшкән, егет-җилән клуб тирәсенә җыела башлаган иде инде. Тәмәке тарталар, үзара гәпләшәләр, елтыр күзләрен урамның әле бер, әле икенче очына төбәп, нидер көтәләр кебек. Бу сагаюда, көлешеп, төрткәләшеп алуда күңел алгысавы, каядыр ашкыну һәм ниндидер бер ятимлек сизелә иде. Мондый сабырсыз алгысауны басып, күңелне үсендереп җибәрер өчен, бу тыныч, серле кичтә җанны-тәнне шушы авылның тупыллар ышыгында тынып калган урамына, күләгәле тыкрыкларына, елга-өянкеләргә, бер сүз белән әйткәндә, туган җиргә бәйләр өчен кызлар кирәк. Ә алар авылда сирәк. Күпчелеге мәктәпне тәмамлауга китеп бара, егетләр армиядән йөреп кайтуга, алар инде, кайдадыр, кемнәрнеңдер куенына сеңеп, күздән югалган була.

Клуб янына ят машина килеп туктагач, егетләр, әлбәттә, сагаеп калдылар. Ят кешенең монда кирәге юк, шуның өстенә арада Зиләйләгә күз салып йөрүчеләр дә, мөгаен, бардыр. Шунлыктан, болай да кычытып торган йодрыкларны килмешәкнең сыртында кашып алыр өчен, аларга сылтау гына кирәк иде.

Балкыш моны тоеп алды, бәйләнергә урын калдырмас өчен, узып барышлый гына: «Культура бүлегеннән ашыгыч йомыш белән җибәрделәр», — дип мыгырдап, эшлекле адымнар белән эчкә узды. Алгы зал буш иде, сәхнә артына үтте. Андагы бер бүлмәнең ишеге ачык булып, анда Зарема моңаеп утыра иде. Балкыш, дәшми генә кире борылып чыгып, машинасына утырды. Зиләйләне күрәм дисәң, медпунктка барырга кирәк иде.

Ул машинасын олы урамда калдырды, медпунктка шау-шусыз гына, тирә-күршегә сиздермичә генә кереп чыгу хәерле иде. Капка төбенә килеп җиткәч, эчтән кычкырган тавыш ишетеп, туктап калды:

— Чыгып китсен хәзер үк! Эзе булмасын монда бүтән! Күрәсем дә килми!

Чарасызлыктан буылып кычкырынган бу тавыш иясе, һичшиксез, Зиләйлә иде. Балкыш, капканы шыгырдатмаска тырышып, ишегалдына узды, ләкин өйгә керергә яхшысынмады.

— Нишлисең син, кызым? Нишләп болай холыксызланасың? Үз әтиең ич ул синең! — диде өлкәнрәк хатын-кыз тавышы.

— Миңа әти түгел ул. Зареманың атасы ул. Аның белән яшәсен әнә, бездә дәхеле булмасын!

Өйалды ишегеннән яланбашлы ир кеше чыкты, ул, Балкышны күрмәгәндәй, тигезсез атлап һәм авыр сулап, капкага таба узып китте. Бу — Гыйззетдин иде. Ә эчтә Зиләйлә һаман кычкырына иде әле:

— Син үзең аны куып чыгарырга тиеш! Ул безне ташлап китте! Кеше алдында хур итте! Шундый ата буламыни? Ул нинди ир? Кая синең горурлыгың?

— Мин үз горурлыгымны үзем беләм! — Бу юлы ананың тавышы нык, хәтта шактый каты яңгырады. — Атаң белән анаң арасын тикшерергә башың яшь әле!

— Минемме башым яшь? Минемме? Алайса, ник мине катыштырдыгыз?

— Кем катыштыра сине? Телеңне тый да тик кенә утыр! Синең башың җитә торган эшмени бу?

— Сез теләсә ни кыланасыз, бер аерылышасыз, бер кушыласыз, ә ояты миңа төшмиме? «Кыйбатлы кыз» дип кемне мыскыл итәләр? Безнең күз алдында әллә ниткән бер килмешәкне култыклап йөргән ул түгел идеме әллә?

— Мәрхүмәне хурламыйлар. Телең корыр!

— Минем телем корысынмы? Минемме? Син мине каргый башладыңмы инде? Алайса, минсез генә яшә! Тегенең... балаларын үзеңнеке итәрсең!

Ишек шакылдап ачылды, аннан ак күлмәкле кыз атылып чыкты һәм, Балкышны бәреп ега язып, капкага таба томырылды. Болдырга әнисе чыгып басты:

— Кызым! Зиләйлә! Тукта! Өйдәгене урамга чыгарып түкмиләр! Килешми! Ярамый!

Шунда Балкышны күреп алды да, кинәт кырысланып:

— Нишләп торасың монда? — диде. — Йомышың булса, туры керергә кирәк!

Балкыш борылды да Зиләйлә артыннан йөгерде. Аны ул күперне чыккач, яр буендагы карт өянке янында куып җитте. Кыз маңгаен агач кәүсәсенә терәгән, Балкыш елыймы әллә дип уйлаган иде, ләкин юк, борылып карагач, күзләре утлы күмердәй көйдергеч, коры булып җемелдәде.

— Исәнме, Зиләйлә!

— Күзеңә тагын чүп кердеме әллә? Мин монда чирлеләрне кабул итмим. Юньле кеше, күзенә чүп керүне сылтау итеп, районнан монда килеп йөрми дә.

— Ничава! Кайбер очракларда мин үзем дә ашыгыч ярдәм күрсәтә беләм.

— Ярдәмгә мохтаҗ кеше күренми әле монда.

— Ә минемчә, бар ул. Берәүнең йөрәгенә шырпы кергән, шуны тартып алырга кирәк. Бик ашыгыч рәвештә.

Ул моны җитди итеп, шул ук вакытта менә-менә көлеп җибәрергә әзер тавыш белән әйтте. Зиләйлә шунда бер елмаеп куйса, ирексездән көлемсерәсә, күңеле дә, теле дә йомшап китәчәк иде дә бит, тик ул тагын да дорфалана төште.

— Безнең йөрәкләр нык, шырпы керерлек түгел! Үзегезне саклау ягын карагыз! — диде.

Балкыш, аның усаллыгын шаяру тамчылары белән генә басып булмаячагын аңлап, сүз сөрешен үзгәртергә кирәк тапты, кызга якын ук килеп, иңбашы өстеннән кулын сузып, өянке кәүсәсенә таянды һәм йөзен йөзгә якын ук китереп:

— Син нәрсә, өйрәтелмәгән тай шикелле тояkларыңны болгап чабасың? Берәүне бер якка тибеп очырдың, икенчесен икенче якка, хәзер инде мине бәреп егасың киләме?

Кыз, иелеп, аның култык астыннан читкә чыкты, ләкин китеп бармады, баскан килеш калды.

— Читтән карап торган кешегә сөйләве ансат ул, — диде. — Үз башыңа төшсә, минем кебек кенә дә булмас идең әле.

Балкыш, аркасы белән өянке кәүсәсенә сөялде. Төн үзенекен иткән, һава шактый җиләсләнгән булса да, агач ышыгында җылы иде һәм аның, тәнгә рәхәтлеге өстенә, күңелне тынычландыра торган шифасы да бар иде. Балкыш, башын чөеп, яфраклар арасыннан сирәк кенә җемелдәшкән йолдызларга карады, гүяки эчендәге сорауларына алардан җавап эзләде.

— Синең урында булсаммы? — диде уйлангандай. — Минем дә йөрәк әрнеми калмас иде.

— Шул шул менә, читтән карап сөйләү ансат ул. Чынын башына төшкәннәр үзләре генә аңлый.

Бу юлы Зиләйләнең тавышы йомшап китте, анда сулкылдау ишетелеп куйгандай булды.

— Ә шулай да кеше әйткәнгә колак салмый булмый. Үзең дә бит кеше сүзеннән гарьләнеп ярсыйсың. Нигә син начарны гына йөрәгеңә якын аласың, ә яхшыны тыңларга теләмисең?

— Күп тыңлаган инде...

— Нишләп син әтиең белән әниеңә шулхәтле каты бәреләсең? Әгәр алар бергә булырга телиләр икән, моның ни гаебе бар?

Караңгыда кызның йөзе күренми, әмма соңгы сүзләр аңа китереп органдай тәэсир итте булса кирәк. Ул, куллары белән битен каплап, башын читкә борды да сулкылдау аша:

— Әгәр сине атаң ташлап китсә... Әллә кемнәрнең атасы булып йөрсә... Аннары яңа хатыны үлгәч, башка барыр җире калмагач кына кире кайтса... Аңа бит без яшь хатыныннан туган балаларын карап үстерү өчен генә кирәк! Ирләр алар үзләренә кирәкне генә карый! Син үзең дә шундыйдыр әле!..

Балкыш аның өзек-төтек сүзләрен сабыр гына тыңлап торды да, якынрак килеп, иңнәреннән тотып алды.

— Син мәктәпне кайчан тәмамлыйсың әле?

— Бер ел калды.

— Аннары нишләреңне уйладыңмы соң?

— Медучилищега...

— Әниең кебек фельдшер буласың килә, димәк.

— Аннары институтка керергә тырышачакмын.

— Менә күрдеңме? Анаң янында, күп булса бер ел яшисең калган. Аннары чыгып китәчәксең дә кире кайтмаячаксың. Ә анаң ялгыз кала. Ишеткән бар андыйларны! Тол калган йә аерылган аналарының яңадан тормыш коруына теш-тырнак белән каршы торалар, ә үсеп китеп канат яргач, фью-үт! Ай күрде, кояш алды була. Китеп баралар да юкка чыгалар. Аналары картаймыш көнендә ялгыз кала. Балаларының нурлы йөзен бер күрергә зар-интизар булып яшиләр, мескеннәр. Син әниеңә шундый язмыш телисеңме?

Зиләйләнең сулышы ишетелми башлады. Егетнең сүзләре аның башын эшләтә башлаган иде, күрәсең.

— Ә әниең акыллы синең, дөнья бәясе кеше, — дип дәвам итте Балкыш.

— Үз кадерен үзе белми... Горурлыгын җуйган ул...

— Ул синең әтиеңне ярата, күрәсең. Кызганадыр да. Кешенең хәлен аңлау горурлыкны төшерә димени? Бигрәк тә яраткан кешеңне кызгану. — Балкыш кызны үзенә якынрак тартып күкрәгенә кысты. — Әгәр син әниең кебек булсаң, әгәр без дус булсак... Мин... — Балкыш дулкынлануыннан сүз таба алмый торды. — Мин сиңа үземә ышангандай ышаныр идем... — диде. — Арабызга кер кунмас иде...

Зиләйлә аның кочагыннан аска таба балыктай шуып чыкты да, сынын турайтып:

— Нинди «безнең ара»? Ни булсын безнең арада? Мин беркайчан да егетләргә ышанмаячакмын! Мин, беләсеңме, кем булам? Фидая Госмановнадан ким булмаячакмын, менә күрерсең! Үземнең кабинетым булачак, машинам... Аның шоферы булачак! — диде.

Зиләйлә үчекләп, үртәп, шул ук вакытта әрнеп-ярсып көлеп җибәрде.

— Яратам дигән булып, башка берәүгә баш бирергә юләрме әллә мин? Ул ташлап киткәч, рисвай булып йөрергәме әллә тагын?

Балкыш аның каршында әйтер сүз таба алмый хәйран калып басып торды.

# 38

Фазилә ире янына Баллыболынга күчеп килергә соңара язды бугай. Ул председатель өчен яңа йортның өлгергәнен көтәргә ниятләгән иде. Ләкин кыш үтте, яз җитте, төзелешнең очы-кырые күренмәде. Янган кешеләргә йортлар торгыздылар, Кармаш хастаханәсенә мунча салдылар. Ә авылда шул ук бер осталар эшли бит инде. Аннары язгы чәчү, чөгендер эшкәртү, печән әзерләү кебек кызу эшләр бер-берсенә тоташып кына бара башлады. Ахыр чиктә, кеше өстендә яшәүне һич күңеле тартмаса да, язын, улын алып, Наиләгә күчеп килергә ниятләде Фазилә. Карчык та моны хуплады кебек, аның чәй янында: «Күгәрчен кебек гөрләшеп яшәр чакларда, ирең белән аерым-суырым, икең ике җирдә торалармыни», — дигән кебегрәк сөйләнүендә астыртын бер мәгънә ятадыр сыман тоелды.

Шулай итеп, ул яз ахырында күчеп тә куйды. Вакытсызрак та иде кебек үзе, чөгендер басуын эшкәртергә бүлеп бирер чак җиткән генә иде. Ләкин ир дигәндә анысына гына түзәсең инде. Сәбәбе дә килеп чыкты: колхозның экономисты, пенсия яшендәге Шакир абзый, йөрәге начарланып, эшеннән китәргә мәҗбүр булды. Финанс-экономика белгечлеге булган Фазиләгә ярыйсы гына эш иде бу. Ул, мөгаен, әле килеп урнашкан белгеч буларак, басуга чыкмый да кала ала иде. Ләкин ул алай итмәде, укытучылар, бухгалтерлар, фельдшер, клуб мөдире белән беррәттән, кулына тәпке алды. Һәм бу гамәле белән авыл халкы алдында иренең абруен тагын да ныгытты.

Ләкин, зирәк хатын буларак, ул Наилә ишарә ясаган афәтне болай гына юкка чыгарып булмаганын яхшы аңлый иде. Һәм ул хәвефле җилнең кайсы яктан искәнен тиз чамалап алды, райкомның өченче секретаре Нурханова тарафыннан исә иде ул.

Фазилә аны бер күрүдә яратмады һәм юка гәүдәле, сары хатынны ни өчен шундый зур урынга утыртканнарын аңламады. Өрлектәй ирләргә начальник итеп кем куйган аны? Ни төрле сәләте, нинди яхшылыклары өчен күтәргән?

Кемнеңдер игътибарын җәлеп иткән, кемнәрнедер үзенә караткан. Кайсыларынадыр яраган... Нәфес торган саен котыра, хәзер инде ирләрнең асылларын үзе сайларга да күп сорамас... Сабан туенда Давытка карагач йөзе үзгәреп китүен генә күр син аның...

Фазиләгә, башка күнче хатыннар кебек, иренең кесәләрен актаруның да, артыннан шымчылык итүнең дә, кеше гайбәтен җыеп йөрүнең дә кирәге юк: гаиләсенең иминлеген кайгырта белгән хатынның иң зур коралы — сизгер күңел. Ул иренең һәм аның тирәсендә еш әйләнгән хатыннарның адымыннан, сулышыннан, бер керфек сирпүеннән хәлне сизеп алырга тиеш. Тегеләрнең күңелендә борынлап килгән хисләрнең яралгысын ук күрә белергә тиеш ул. Һәм, шуннан җитди нәтиҗә чыгарып, чарасына керешергә.

Бу очракта Фазилә чыгарган нәтиҗәләр бик тә җитди иде. Дөрес, Нурханованың Гаяровка күзе төшкән дигән сүз халык теленә кермәгән, аларның начар даны чыкмаган әле. Әмма дан чыккач соң була шул инде ул. Монда хәлләр шул ук чөгендер басуындагы кебек: чүп үләнен никадәр иртәрәк утасаң, шулкадәр яхшырак. Тамырын киң җәеп, ныгыган сарутны йолкып алуы авыр, җитмәсә, ул үзе белән чөгендернең үзен дә өстерәп чыгара! Гаиләңнең тамырсыз каласын көт тә тор!

Ләкин хәзер инде басудагы кебек, бөтен халык күз алдында сураеп, китмән болгап йөреп булмый. Сарутның тамырын астан кисү җаен табарга кирәк иде. Наилә белән, авылның башка хатыннары белән аны-моны сөйләшкәндә, сүзне җай гына Нурхановага тоташтырып, ул бу хатын турында шактый күп нәрсәләр белде. Мәрхүм иренең аңа булган кайнар мәхәббәтен, ул вафат булганнан соң, хатынның кинәт күтәрелеп киткәнен, хәзер хастаханә салу артыннан җан атып йөрүен һәм бу бетмәс-төкәнмәс мәшәкатькә

тирә-юнь колхозлардан да ярдәм соравын белде ул. Ә инде баш табиб Газимовның өстеннән төшми, аны шушы төзелешкә бик каты җиккән икән...

Димәк, аның белән еш очрашалар дигән сүз бит бу. Ә баш табибның хатыны моңа ничек карый икән?!

Атнага бер тапкыр Баллыболыннан Кармашка автобус бара, Давыт шундый тәртип керткән иде. Көннәрнең берендә Фазилә дә, тәвәккәлләп, шул автобуска барып утырды.

Юлы ифрат уңды: Нурханова да анда иде, баш врач белән икәүләшеп яңа бинага керә-чыга йөриләр, төзүчеләр белән кызып-кызып нидер сөйләшәләр.

Хатын-кыз табибы һаман юк икән, Баллыболыннан четереклерәк зар белән килгән хатыннар Гөлфия янына керергә чират алдылар. Фазилә ишек төбендәге соңгы урындыкка барып утырды. Аңа өлкән шәфкать туташы белән ашыкмыйча сөйләшергә кирәк иде...

Гөлфиянең ак халаты, ак яулыгы фонында чекерәеп торган сипкелле йөзенә бер күз салу белән, Фазилә борчуларының уртак икәнлеген сизеп алды. Үзе эче авыртудан, күременең озакка сузылуыннан зарланган булды.

— Чөгендергә чыгып кына шулай булдым, — диде. — Эш кушканда бит хатыннарның хәлен сорап тормыйлар, корсаклымы син, вакытсыз чагыңмы, берни белән исәпләшү юк. Баллыболында бер хатын шул чөгендер басуында өзлегүдән үлеп тә киткән, дип сөйлиләр...

Шулай сөйләнде Фазилә, үзе исә үткен күзләре белән шәфкать туташын күзәтте. Ә Гөлфия шактый таркау, аның башында бөтенләй башка уй, күзләре исә төзелеш ягына караган тәрәзәдә иде.

— Хатын-кызның хәленә керә белүче юк инде бездә, — дип дәвам итте Фазилә. — Җитәкчеләр барысы да ир-ат бит. Хатын-кызлардан берәрсе югары күтәрелсә дә, шул ир-ат кубызына биергә мәҗбүрдер инде. Кая китсеннәр... Янында ире булмаса, бигрәк тә... Начальникның да бар җаны...

Тәрәзәгә ян белән утырган Гөлфиянең башы исә һаман тәрәзәгә борылган, күз карашы яңа бинаның ишеге төбендә кызып-кызып сөйләшеп торган өч кешегә: бер төзүче һәм Фидая белән Билалга төбәлгән иде.

Фазилә бу хатынның күңелендә нинди хисләр айкалганын аңлады, сүзен шул көйгә салды:

— Мондый төзелеш кебек зур эшләр кузгалгач, төрле хәлләр була шул инде ул, — диде. — Бер бәхәсләшәләр, бер килешәләр... Җае чыкканда сөешәләр... Дөнья шулай корылган!

Гөлфия таркау, аны дикъкать белән тыңламый да иде кебек, әмма соңгы сүзләрдән бите алланып чыкты, сипкелләре тоныкланды. Яшьлеге узгач та мондый сөйкемле сипкелләрен саклаган хатыннар бигрәк беркатлы була шул алар! Менә ул күк күзләрен Фазиләгә төбәде дә:

— Сине карыйммы соң? — диде. — Күренәсең киләме? Бар әнә, чишен дә ят, — дип, ялтыравык тимер ятак тарафына ишарәләде.

— Син миңа эч авырткannan берәр дару гына бир. Үтмәсә, тагын килермен.

— Монда килүдән мәгънә юк. Суташка гинекологка барырга кирәк.

Фазилә рәхмәт әйтеп, урыныннан кузгалды. Ул максатына ирешкән, шик-көнләшү сарутының орлыгын бу сипкелле-сөйкемле хатынның күңеленә салган иде инде. Сугаруын исә Нурханова үзе эшләр: килеп торыр, Газимов белән очрашып торыр, бу хатынның шиген үстерә торыр. Аның башка чарасы юк, чөнки башлаган төзелешне тәмамлап, макталасы, дан аласы киләдер бит инде!

Данын да алыр, макталыр да, бәлки. Ләкин ул урынында озак утырырга, машинасында теләсә кая чабарга, теләгән минутында Давытны очратырга тиеш түгел. Аның мондый мөмкинлеге булмаска тиеш. Димәк, аны бу урыныннан очыртып төшерергә кирәк. Фазилә моны эшләячәк иде. Тик үз куллары белән түгел, башка куллар белән...

# 39

Аһ бу күңел дигәнең, ник тынгы белми икән дә, ник һаман үзгәреп, әледән-әле җилләп-давыллап тора икән? Кайчакларда күңелләрдә шундый гарасатлар куба ки, алар безне бөтереп алып китәләр дә чоңгылларга илтеп ташлыйлар.

Гыйззетдин белән нәкъ менә шундый хәл булды да.

Таяныр, юатыр кешесе булгач, аның олы хәсрәте җиңелрәк үтәргә тиеш иде кебек. Шуның өстенә ике яктан ике малай гел тынгысызлап тора, башны аска салындырып, моңаеп утырырга ирек бирмиләр. Йортта мәшәкатьнең чиге юк, ә Зарема яшь әле, ярым ятим калган өйне ул гына ямьле итеп тота алмый. Хуҗалыкка — чын хуҗабикә, балаларга әни кирәк һәм авыл халкы Гыйззетдин озакламас, Мөнирәне үз янына бөтенләйгә алып кайтыр дип көтә иде. Әмма алар уйлаганча булмады.

Хәер, арадан берәү зур бәхетсезлек киләсен сизенгән иде. Бу берәү — Фидая иде. Ләкин ул да хәлнең никадәр хәтәр икәнен аңлап җиткермәгән икән.

Беркөнне кичкә таба Кармаштан кайтып килгәндә, ул басу артындагы каенлык янында зәңгәр «Нива» торганын күреп алды. Машина таныш иде. Күңел сыкрап куйды: истәлекле урында, истәлекле машина... Фидаяның башыннан узганнар менә хәзер Гыйззетдингә килде. Хатыннар, Мөнирәсе янына барып юаныч таба ул, дип сөйлиләр сөйләвен дә, эчендә нинди утлар янганын кем белгән? Хәлен белү начар булмастыр...

— Каенлыкка сугылып чыгыйк әле, — диде Фидая Балкышка.

Агачлык артындагы алан буш иде, әрәмәлектә, таллар арасында кызыл тап күреп, Фидая шунда таба китте. Кизләү янында, ауган өянке кәүсәсендә кызыл күлмәк кигән Гыйззетдин утыра иде. Каршысында сусыл үләнгә гәзит җәелгән, аның өстенә ипи телемнәре, ит калҗалары һәм шешә белән бер стакан. Гыйззетдин ялгызы, табын корып, эчеп утыра иде...

— Исәнме, иптәш секретарь, — дип, урыныннан торып басты ул. — Мактап йөрисең икән, ризык өстенә туры килдең.

Һәм гаепле кешедәй, чалыш елмаеп, кулы белән гәзиткә ишарәләде.

— Уз әйдә, утыр менә монда, җылы урынга, — диде.

Фидая каршы килмәде, барып, агачка утырды.

— Бәйрәм түгел, туй түгел, бу нинди табын соң әле монда? — дип сорады йомшак кына.

— Каләмгөлнең кырыгы бит бүген, — диде Гыйззетдин, каядыр югарыга карап. Ул әйткәннең мәгънәсен көчәйткәндәй, агач башларын шаулатып кисәк кенә җил исеп куйды.

— Мәрхүмнәрнең кырыгын болай үткәрмиләр, — диде Фидая. — Гөнаһ бу.

— Үткәрдек... Карчыклар җыелып барысын да тиешенчә эшләделәр. Кешечә булсын дип тырыштылар... Наилә дә... Башкалар да...

Фидая калкынып куйды: «башкалар» дигәне Мөнирәне аңлата иде.

— Кешечә булды, ләкин Каләмгөлчә булмады, — диде Гыйззетдин һәм, иелеп, яртылаш бушаган шешәдән стаканга аракы койды. — Инде монда килгәнсең икән, мә, тотып куй әле берне аның истәлегенә...

Фидая стаканны кире этәрде.

— Мин эчмим. Ярамый.

— Нәрсә генә ярый соң сезгә? Наилә апа сине карчыклар мәҗлесенә чакырмакчы иде, райком секретарена дога укыган җирдә утыру ярамас, диделәр. Шуңа күрә сиңа әйтеп тә тормадылар. Монда, кеше күрмәгәндә, аның хөрмәтенә бер матур сүз әйтеп тост күтәрергә тагын ярамый.

— Мәрхүмне яхшы яклары белән искә алырга ярый, мәсәлән. Аның якты хатирәсен күңелләрдә сакларга...

— Аның яхшы якларын белә идегезмени соң сез?

Гыйззетдин, башын артка каерып, стакандагы аракыны эчеп җибәрде, йөзен җыерып, җиң очы белән авызын сөртте, иелеп ит калҗасы алды. Ләкин ашамады, бер кулына стакан, икенчесенә калҗа тоткан килеш тынып торды, аннары кулындагы әйберләрне кире газетага куйды да, өянке ябалдашларына карап, үзалдына сөйләнгәндәй:

— Бер мин белә идем аның нинди икәнен, юк андый башка бүтән, — диде. — Алашалар арасына килеп эләккән тай кебек иде ул. Йөгәнне дә, тәртәне дә белмәгән. Ирекле! Далаларны иңләп-буйлап чабар өчен туган тай иде ул. Үзе генә түгел, башкаларны да шулай талпындыра белә иде. Аңа ияреп, җилне ярып, офыкларга ыргыласың, йөрәгең күкрәк читлеген тишеп чыгардай булып тибенә, ә син һаман чабасың! Андый чакта янып үлсәң дә жәл түгел...

Гыйззетдин, кулларын күтәреп, җилпенеп куйгандай итте. Әллә чыннан да чабып китәргәме? Юк, чәчен сыпыргалады. Кызыл җиңнәре сәер кошның канатлары кебек иде. Каләмгөл иренә ачык төсле күлмәкләр кигезергә ярата иде шул. Озакка чыдар әле алар, мәрхүмәне гел-гел искә төшереп торыр. Әгәр барысын да алыштырырга Мөнирәнең акылы җитмәсә...

— Әйе, ул теләгәнен эшләде, сүзнең турысын сөйләде, икейөзлеләнүне белмәде, — дип сүзен дәвам итте Гыйззетдин. — Ә бу тормышка андыйлар кирәкми шул. Эш атлары гына кирәк. Чәчсеннәр, урсыннар, чөгендер басуында йөгенсеннәр. Көндезен ярышта җиңәм дип көчәнсеннәр. Артыгын сорап, сезне борчымасыннар. Бездәге җитәкчеләр халыкның шундый булуын тели. Шулай бит?

— Алай ук гадиләштереп булмый инде.

— Ә нигә катлауландырырга? Асылда шуңа кайтып кала. Мин дә бит аны һаман тәртә арасына тарттым. Шуңа чыдамый вафат булды да. Исән чагында үзе теләгәнчә яшәргә ирек булмады, үлгәч, васыяте үтәлми... Ул әйтеп калдырганча бармый берсе дә! Җидесенә-кырыгына табынны ул теләмәгән кеше әзерли, гомере буе аның артыннан гайбәт сөйләп йөргән карчыклар килеп сыйлана...

— Туктале, Гыйззетдин, кемне чакыру синнән тора бит...

— Миннән генә тормый шул. Дөнья үз җаена бора да куя. Мин менә үзем дә... Исән чагында хыянәт итмәгән идем, үлгәч хыянәт иттем мин аңа!

— Нинди хыянәт?

— Уйлап түгел. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Кече малай бик каты чирләп китте. Үлә дип торабыз. Төн уртасында минутында кемне табасың? Мөниргә барып егылдык. Ул алып калды баланы... Ләкин Каләмгөлнең ризалыгы юк иде моңа... Орындырма, дип, васыять әйтеп калдырган иде...

Ничек юатырга иде соң бу кешене, хәсрәтен, үкенечләрен җиңеләйтерлек нинди сүзләр табарга? Юк иде андый сүзләр, юк иде мондый кайгыдан котылу чарасы! Булыр иде ул, әгәр дә гашыйкның хисләре икесенең генә язмышын хәл итә торган булса. Ләкин ул тойгылар башка кайберәүләргә дә нык кагыла. Бу очракта ике баланы кая куясың? Алар өчен яңа ояны кем корыр да кем аларны иркәләп-назлап үстерер? Мөнирәдән гайре моны эшләрлек башка берәү дә юк бит! Һәм Гыйззетдиннең үзен юатырлык та юк бүтән. Каләмгөл хаклы булмаган, андый васыять әйтеп, нык ялгышкан ул. Аның сүзен кире алдырып, хатасын төзәттереп булмый, ләкин исәннәр алда ничек яшәү турында уйларга тиеш! Иң беренче чиратта, балалар хакында төптән уйларга тиеш алар.

Әйе, киләчәкне үткәннәрнең бизмәне белән генә үлчәп булмыйдыр шул.

— Чирле кеше гел акыллы сүз генә сөйләп тора ала микән? — диде Фидая. — Менә хәзер күрсә-белсә, иң элек балаларын уйлар иде, дөрес эшлисең, дияр иде, мөгаен. Шулай түгелмени?

— Ә Мөнирә... сез дигәнчә яши торган бер адәм баласы инде ул... Көтүдәге бер мал... Кичен кереп ышыкланырга абзар, улагында солы булса, шул җиткән аңа... Ә көндезен нинди арбага җиксәң дә карусыз гына тарта да тарта... Очынып яшәү юк... Җылысы бар, уты юк... Абзары бар, даласы юк... Ә миңа кысан... Тыным кысыла...

Һәм ул үрелеп стаканга тагын аракы салды. Фидая аның җиңеннән тартты:

— Җыеп ал әле син, Гыйззетдин абый, бу ризыкларны, гәзитне. Әйдә, кайтыйк. Улларың көтәдер анда.

«Улларың» дигәнне ишеткәч, Гыйззетдин туктап калды.

— Мин сине машина янында көтәрмен, — диде Фидая һәм узып барышлый, таеп киткәндәй итеп, шешәне тибеп аударды да, тал тармакларын аралап, алан ачыклыгына чыкты.

«Нива»ның ишеген ачып карады, руль астында эленеп торган ачкычларны күреп алды да әрәмәдән чыгып килгән Гыйззетдингә:

— Сиңа бу хәлдә рульгә утырырга ярамый, — диде. — Әйдә, кайтарып куябыз. Машинаңны берәрсе килеп алыр. Йә булмаса, хәзер Балкыш әйләнеп килер дә кайтарып куяр.

Ләкин Гыйззетдин риза булмады. Ачкыч өчен бәхәсләшеп алдылар. Салган кеше белән әрепләшүнең мәгънәсезлеген тойган Фидая машинага кереп утырды.

— Кузгал, — диде Балкышка. — Тәпи-тәпи кайтыр әле, авыл монда гына.

Ләкин алар ерак китә алмадылар, арттан кычкырган тавыш ишетелде. Гыйззетдин машинасы янында шешә болгап тора иде.

— Запас белән йөри икән, — диде Балкыш.

Олы юлга күтәрелеп, авылга таба борылгач, уң яктагы борчак басуында туктап калган комбайн янында таныш сын күзгә чалынды. Менә бит, күреп китәргә сылтау да бар, Гыйззетдиннең ачкычларын колхоз җитәкчесенә бирергә кирәк. Фидая машинадан төште дә комбайнга таба китте. Давыт та, Әхсән дә шунда, тузанга баткан комбайнчылар белән сөйләшеп торалар иде. Фидаяның Гыйззетдин турында әйткәннәрен ис китми генә тыңладылар.

— Уттай эш өсте дип тормый кеше, — диде Давыт, карашын читкә борып. — Хатынының кырыгын сылтау итеп, бүген тагын эшкә чыкмады. — Ачкычларны чалбар кесәсенә салып куйды да: — Үзе килеп алыр әле, әллә кая китмәс, — диде.

Алар борчак уруның барышы, силос салу, карчыкларны кычыткан себеркеләре бәйләүгә күндерү турында сөйләшеп алдылар. Фидая кире юлга чыгып машинасына утырган гына иде, яннарыннан выжт итеп зәңгәр «Нива» узып китте.

— Ничек кабызган ул аны? — дип сорады Фидая Балкыштан.

— Аның ише тимер кортына чутмыни ул! Ярты сәгать азапланса, ул синең тырмаңны да үзйөрешле итә.

Фидаяның күңелен шом басты: «Хәерлегә булмас бу! Юньлегә булмас!»

Бу шомлану һаман күңелне борчып торды, кичен кайтып, өй мәшәкатьләреннән бушагач, көчәеп киткәндәй булды. Һәм Фидая Баллыболынга шылтыратты. Болай гына алды ул трубканы, вакыт соң, җавап булырга тиеш тә түгел иде. Әмма ни хикмәттер Давыт үз бүлмәсендә булып чыкты. Аның тавышын ишеткәч, Фидая каушап китте, телефон чыбыгының теге башында да дулкынлану сизелде шикелле. Гыйззетдин өендә булырга тиеш, диде Давыт, машинасы капка төбендә тора иде. Гомумән, көйсезләнде

әле ул кеше. Кайгылы вакыты дип, сүз әйтергә намуссынып йөрибез йөргүен дә, эшләми яшәп булмый бит! Тәртипкә чакырырга туры килер ул абзыйны.

Фидая йомшак кына Давытка каршы төште. Кешенең хәленә керә белергә кирәк. Мәрхүмнең кырыгы Гыйззетдиннең күңеленә ятышлырак үткән булса, бәлки, шуннан үзенә юаныч табар иде. Әллә соң Каләмгөлне үзебезчә искә алыйк микән? Әйтик, аның истәлегенә багышлап матур гына бер кичә үткәреп алырга булыр иде. Ул яраткан җырларны җырларга, ул куйган биюләрне биергә...

Ләкин бу тәкъдим Давытны рухландырмады. Уттай эш өстендә аның ише белән кем шөгыльләнсен? Күңелле кичәләр оештыру өчен Каләмгөл үзе кирәк бит.

Сүз шуның белән өзелде. Фидаяның йөрәк тибеше генә колакка бәреп торды. Телефон чыбыгының теге очына да барып иреште инде әллә? Аның тагынниләрдер әйтәсе, араны тимерчыбык тоташтырган минутларны озынайтасы килә иде. Давыт та нәрсәдер көтә иде кебек... Соңгы вакытта күңелдә тулып торган хисләр кинәт ташып чыкты. Ах, Гыйззетдин әйткәнчә, Каләмгөл кебек ирекле булсаң иде дә бернигә карамый томырылып чабып китсәң иде!

Ләкин... Кая чабасың?.. Йөгерепләр генә барыр идең дә кочагына кереп сеңәр идең... Ләкин безнең хисләр кузгаткан давыл башка берәүләр өстенә дә килә шул. Йә шифалы яңгыр булып, йә аяусыз боз булып.

Фидаяның өстенә дә шундый боз яумадымыни? Юк, боз гына түгел, сасы лайла булып ишелде аның өстенә башка берәүнең хисләре. Һәм аны тазара алмаслык итеп пычратты. Бу минутларда тимерчыбыкның аргы башында тигезсез сулаган, бик якын, бик газиз кешегә орынырга хокукы юк иде инде хәзер Фидаяның. Гәрчә аның пары, якты дөньядан киткәндә, бернинди васыять әйтеп калдырмаган булса да, Фидая, чын күңелдән бирелеп, башка берәүнеке була алмаячак иде.

## 40

Наилә юкка әйтмәгән, Фидаяның шомлануы юкка булмаган икән. Бер атнадан Гыйззетдин, кичке якта Суташтан чыгып барганда, машинасы белән күпердән төшеп һәлак булды.

Мәрхүмне җирләгәндә дә, өчесен-җидесен уздырганда, хатыннар пышын-пышын бер үк сүзне сөйләделәр: «Чын сихерче булган икән бу Каләмгөл, — диделәр. — Ирен барыбер көндәшенә бирмәде, барыбер үз янына алды. Әгәр шунда Гыйззетдин, аның васыятен тотып, башкага өйләнсә, мөгаен, яшәр иде әле».

Ә балалар белән ни булыр инде хәзер? Фидаяның белүенчә, Мөнирә әлегә Гыйззетдин янына күчеп өлгермәгән, чөнки Зиләйлә каршы булган, димәк, бер оя булып оешып та бетмәгәннәр иде. Ничек яшәп яталар икән?

Фидая медпунктка иртәнге якта барып керде. Болдырда сөйләшеп торган өч-дүрт хатын белән исәнләшеп кенә узды да эчкә керде. Мөнирә каршында Наилә утыра иде, мөгаен, чирен сөйләргә түгел, үзе киңәш бирергә килгән. Фидая керүгә:

— Мин бүтән чакта керермен, сез монда сөйләшегез, — дип, җәһәт кенә чыгып китте.

— Кай җирең авырта? — диде, моңсу гына елмаеп, Мөнирә. Ә Фидая аның күз яшьләре кипмидер, дип уйлаган иде.

— Синең хәлеңне белергә килдем әле.

Мөнирә карашын аска төшерде дә башын чайкап куйды.

— Бөтенесе шулай дип килә. Урын өстендә ятмыйм ла мин! Ә хәлне үзең беләсең. Синең дә башыңнан узган.

Фидая ни әйтергә белми аптырабрак калды. Башына олы хәсрәт төшкән кешенең күңелендә гадәттә бүтәннәрнең гаменә урын калмый. Ә бу хатын күңеленә күпне сыйдыра шул...

— Бәхетеңне бер югалткач, яңадан табармын димә икән, — диде бераз тынып торгач Мөнирә, ак бармаклары арасында очы ватылган ампуланы бөтереп. — Ә мин таптым дип уйлаган идем. Ышанасыңмы, ул кире кайткач, мин үземне яшь чагымдагыдан мең мәртәбә бәхетлерәк тойдым! — Ул, башын күтәреп, сәер ялтыраган күк күзләренең карашын Фидаяга төбәде. — Көндезләрен күреп туймадым, төннәрен башымны аның беләгеннән алмадым. Һаман шулай булыр, дип уйлаган идем. Аның күңеле сынык иде, билгеле, тик сөюем белән дәваламын, терелтермен дигән идем. Әмма хисләремнең шифасы тимәде. Ник алай икән ул, Фидая? Йөрәктә шундый хисләр кайный, таулар күчерерсең кебек. Әмма бернәрсәне дә үзгәртә алмыйсың...

Фидаяның күз алдына аермачык булып Гыйззетдин белән әрәмәлектә булган соңгы очрашу җанланды. Әллә сөйләргә микән? Юк, ярамас...

— Аңлап булмый шул аны, — диде Фидая. — Мин дә бик күп уйладым. Бер карасаң, хисләр бөтен тормышны әйләндереп сала, икенче карасаң, йөрәкне генә яндырып көл итә.

Мөнирә торып басты да, чигүле пәрдәне төзәткәләгәндәй итеп, гөлләр аша үрелеп, урам якка карады. Аның ак йөзендә нәрсәдер көтү, яшерен өмет чагылгандай булды. Әмма урам буш иде.

— Балалар кайда соң әле? — дип сорады Фидая.

— Бакчада... Килгән кешеләрне кабул итәм, аннары икесенең өенә барып укол ясыйсым бар. Шул уңайдан Өлфәтне алып та кайтырмын дип торам. Бәләкәй бит әле, бакча тәрбиясе генә җитмәс дип куркам.

— Ә Зиләйлә?

— Зиләйлә Кармашта әбисендә әле.

— Зарема?

— Зарема клубта. Төшкә кайта.

— Син соң һаман монда яшисеңме әле?

— Күчеп беттем дияргә була инде, — диде Мөнирә. — Семья зур бит. Дүрт бала белән монда ничек тыгылып ятасың.

Фидая балаларны кая куярбыз икән дигән сорауны бирергә соңарганын аңлады. Мөнирә һәммәсен үзе хәл иткән иде инде, күрәсең. Ул көндәшенең балаларын үз өстенә ала. Кызына каршы килеп!

Фидая:

— Зиләйлә ничек соң? — дип сорамый булдыра алмады.

— Яшь бит әле, аңлап җиткерми. Яши-яши аңлар әле. Аның туганнары бит алар. Ә туганнар кирәк, аларсыз яшәү читен.

— Әллә соң Зареманы берәр кая урнаштырырга микән?

— Кая чыгарып җибәрәсең инде аны? Аллаярова бит ул. Гыйззетдин аны үзенеке кебек күрде... Бер генә ел укыйсы калган. Аннары культпросветучилищега керер. Түзәрбез бер елга. Ике фатирыбыз бар менә...

Мөнирә бераз тынып торды да:

— Әле дә ярый алар бар, ничек түзәр идең, — дип куйды.

Фидая аның халат астында иңебрәк калган җилкәләренә, колак турында яулыгы астыннан тырпаеп чыккан чәчләренә, очлаебрак киткән борынына карады да: «Әле дә ярый бу дөньяда синең кебекләр бар, — дип уйлады. — Югыйсә ничек яшәр идек тә, нинди булыр идек без?»

Мөнирәне кочаклап аласы, рәхмәт әйтәсе килә иде. Ләкин ул тыелды. Чөнки мондый хәлдә өч ятимне үз канаты астына алу бу хатын өчен бик табигый гамәл, һәм ул мактау да, рәхмәт тә көтми иде.

Аның яныннан чыкканда, Фидая, бу гаиләне гел кайгыртып торырга кирәк булыр, моны Давытның колагына киртләп куярмын әле, дип уйлады.

# 41

Киңәшмәдән соң Беренче биш колхозның җитәкчесен үз бүлмәсендә алып калды. Күпчелек хуҗалыкларда урып-җыю эшләре тәмамланган, бушаган комбайннарны артта калганнарга җибәрергә ниятләгән икән.

— «Җиңүче»гә ничә комбайн кирәк булыр? — дип, Ясәвиевкә текәлде Искәндәров.

Хасият урыныннан торып басты, суга чумарга әзерләнгәндәй тирән итеп сулыш алды да:

— Берәү дә кирәкми, — диде.

— Ничек алай? Ничә гектар арпаң урылмаган әле синең анда?

— Үстергәнне югалтасы килми.

Искәндәров сүзнең нинди югалту турында икәнен сорап тормады, болай да аңлашыла иде. Арпа бөтен көченә җитлегеп бетмәгән, атна-ун көннән ул тәмам өлгерәчәк, һәм уңышы да күбрәк булачак иде. Беренче сүз куертып тормады, башкаларга күчте:

— «Үзәк»кә ике комбайн: берне «Спартак»тан, берне «Егерме бишенче партсъезд»дан...

Арпаның тәмам өлгергәнен көтеп, уңышны арттыру «Үзәк» өчен дә начар булмас иде, билгеле. Ләкин бәрәңге алу башланды гына, алда чөгендер тора, тыгызга туры киләчәк. Һава хәле нинди була бит әле...

Шуларны уйлап, Давыт үз комбайннарын да, читтән килгәннәрне дә бөтен көченә эшләтергә тырышты. Үзе дә кырдан кайтмады, кичләрен бик соң ятса да, караңгыдан торып чыгып китте.

Егерме җиденче сентябрь көнне кич, кояш баер алдыннан, бер-бер артлы тезелеп килгән өч комбайн зур басуны урып бетерделәр, юл аркылы егерме генә гектар арпа калды. Комбайннарны юл читендә туктатып, Давыт янына килеп басканда, егетләрнең талчыккан чыраенда канәгать елмаю балкыды: бүгенгә эш тәмам. Авылга кайтып, тәмләп ашарга да рәхәтләнеп ял итәргә була.

Давыт исә борчылган кыяфәт белән әледән-әле кояш баешына карады, чит-читләре алланган, уртасы кара-кучкыл болытлар калкып килә, мөгаен, һава бозылачак иде.

— Мең рәхмәт сезгә, — дип, ул егетләрнең кулын кысып чыкты.
Комбайнчылар Давытның «уазигы»ннан зур гына төен күтәреп чыккан ак яулыклы апага сәерсенеп карадылар.
— Бик тәмле итеп итле бәрәңге пешерде сезгә Наилә апагыз, — диде Давыт. — Хәзер ашап бераз хәл алыгыз да теге басуны да бетереп куйыйк инде.
Моны ишеткәч, егетләрнең чырае сытылып китте. Хәтта Сидоровка Николаеның да сары кашлары җыерылды.
Ул арада Наилә апа, чирәмгә шакмаклы ашъяулыгын җәеп, уртасына термос китереп утыртты. Егетләр төкерекләрен йотып куйдылар: тамак кипкән иде.
— Килегез, утырыгыз, суынганчы ашап алыгыз. Тамагыгыз ачкандыр, бик күп эшләгәнсез бит, — дип сөйләнде Наилә.
Каршы әйтергә, ә бәлки, аты-юлы белән сүгенергә дип ачылган авызлар йомылды. Авыл кешесе басуга китергән ризыкның кадерен белә шул...
Табын тирәсенә урнашкач, авызлар тагын тиз генә бушамады. Председатель дә янәшәдә утыра, бик тәмләп ашый. Уртак табыннан ризык җыю күңелдәге ризасызлык хисен дә әкренләп киметте.
Бераз тамак ялгангач, күңел хушланып китте. Көнбатыш якта кабарынган болытларның куерып, көннең тиз караңгылануына егетләр үзләре дә игътибар иттеләр. Давыт үзенең борчуын иплэп кенә аңлатты:
— Монысы өчен икеләтә түләнер, — дип тә өстәде.
Кешене үзе теләмәгән, күңеле тартмаган эшкә тарту бик авыр. Тик бу очракта Давыт арыган-талган егетләрнең күңеленә ачкыч таба алды.
Тирән итеп сулыш алдылар да тәвәккәлләп кузгалдылар. Дөм караңгылыкны ерып, комбайннарның фаралары кабынды. Давыт беренче булып баскан Николайның комбайны каршына яктылыкка чыгып басты да, юл күрсәтеп, алдан үзе атлап китте.
Ниндидер бер ашкыну, дәрт биләп алган иде бу басудагы кешеләрне. Көн буе эшләгәннән соң кайтып китсәләр дә була иде, ләкин алар менә тагын кузгалдылар. Аларны һичкем мәҗбүр итмәгән, басым ясамаган иде, алар үз ихтыярлары белән, иректә кешеләр булып, бу сәгатьләрдә шушы җирнең, байлык-муллыкның хуҗалары икәнлекләрен тоеп кузгалдылар. Шушы иркенлекне, ирекне тою, хезмәтенең зурлыгын аңлау аларны нык рухландырган иде. Игенченең хезмәте авыр, ләкин аның менә шушындый, зур җиңүгә тиң вакытлары, кешене бәхетле иткән чаклары була. Бу төнне, бу көнне Давыт та, комбайнчылар да шушы халәтне кичерде.
Төн уртасы узгач, басуны урып бетерделәр. Комбайннарны туктатып, утларны сүндергәч, төннең караңгылыгы күзне буды, кызган битләргә кисәк-кисәк дымлы җил бәрде. Әмма барысының да күңеле якты иде, алар үзләрен зур итеп, кодрәтле итеп тойдылар.
«Урып-җыю фронты» дигән сүзләр шапырыну, арттырып җибәрү кебек тоелса да, аның менә шушындый җиңү куанычы китергән чаклары була.
Иртә сүлпән килде, чөнки пыскып яңгыр сибәли иде инде. Озакка килгән, утырып ява торган яңгыр иде бу. Давыт нәрәт биреп кайтты да йокларга ятты. Аннары көн гадәти мәшәкатьләр белән уралып үтте. Ә күңел куаныч, үзенә бер очыну белән мөлдерәмә тулы иде. Ул, чыннан да, җиңде, акылы, тырышлыгы белән җиңде. Сизгерлеге белән дә. Көннәр бозыласын да чамалады, комбайнчыларга да сүзен үткәрде, төнге кырда гаҗәеп рәхәтлек тә кичерде.
Бу якты хисләрне кем беләндер бүлешәсе килә иде аның: эштән арыган ирләрне тагын эшкә керешергә ничек үгетләгәнен, төн карасын ярган фараларны, тынлыкны бозган гөрелтене, орлыкның шаулап бункерларга коелганын...
Кичкә таба түзмәде, машина руленә үзе утырды да Суташка китте. Давытның аны күрәсе килә, шул ук вакытта курка да иде. Соңгы вакытта Фидая үзгәрде, бик нык үзгәрде, кырау тиеп киткән гөлне хәтерләтә кебек. Аңа нидер булды. Менә хәзер, Давытның күңеле нечкәргән чакта, ул да, бәлки, ачылып китәр? Серен ачар? Давыт аны юатыр, моңнарын таратыр иде...
Әмма күңел сизә, Фидая үзенең шатлык-кайгыларын аның белән уртаклашырга теләми. Нәрсәдер тыя...
Хәер, очрашырлармы әле алар бүген? Нишләп әле райкомның өченче секретаре кичке алтыдан соң бүлмәсендә утырсын? Давытның киләсен белми лә ул! Кармашта ук түгел микән?

# 42

Ул көнне кичкә таба Кармаш юлында Фидаяның «уазигы» белән Рәсимә Фәләхованың яшел «Жигули»е кара-каршы очраштылар. Бер-береңне күрмәгәндәй выжт итеп узып китеп булмый, туктадылар, машиналардан төштеләр. Рәсимәнең капюшонлы курткасы нык чыланган, резин итекләре пычранган иде.

— Рульдә болар белән җайсыз түгелме? — дип сорады Фидая, аның аягына ымлап.
— Күптән күнеккән инде. Алдагы көндә моннан озынрак кунычлысын кияргә дә туры килмәгәе әле.
Һәм Рәсимә, башын күтәреп, күксел болыт пәрдәсенә карады.
— Басудан кайтып киләм. Комбайннар сазга батып ята анда, — диде. — Шушылайрак явып торса, кар төшкәнче кузгатып булмас.
— Озакка бармас әле, бәлки, туктар, — диде Фидая, аны юатасы килеп.
— Туктарга охшамаган әле бу. Өченче елны да шушылай булган иде. Безнең Хасият арпаны өлгерсен дип соңга калдырды, ул көтеп торган арада, яңгыр коярга тотынды. Ай буе туктамады. Ниләр генә кыланмадык! Басуны йорт саен кишәрлекләп бүлеп бирдек, җыйганның ун процентын үзләренә бирергә вәгъдә иттек. Бөтен халык белән бергәләп чалгы белән чаптык. Тездән сазга бата-бата!
— Син дә чаптыңмыни?
— Чапмый кая барасың. Иң алдан Хасият үзе чалгы болгап йөрде.
— Бигрәк уңган җитәкче икән!
— Уңган җитәкче үзе эшләми ул, башкаларны эшләтә! Инде дә үзәгенә үтмәгән икән, комбайннар бирәбез дип торганда алмаган бит, ахмак. Ирләрдә тавык мие дә юк ул, Фидая. Аларның бер сүзенә дә ышанырга ярамый.
— Ышанмый кая барасың, — диде Фидая, эчке уфтану белән. — Аларсыз булмый. Кармаш больницасын мин берүзем төзи алмыйм бит инде.
Рәсимә, иренен тешләп, читкә карады.
— Мин әле сиңа әйтергә кыенсынып йөри идем, — диде, ничектер мәгънәле итеп. — Үзең башлагач кына әйтүем... Төкер син ул больницага! Сиңа гына кирәкме әллә? Шул эшкә куелган кешеләре бар. Төзесеннәр! Ә син кабинетыңда эш кушып кына утыр! Мин синең урыныңда булсаммы!
— Үзең басуда йөрисең бит әле...
— И-и, Фидая, колхоз белән райкомны чагыштырып буламыни! Әгәр дә мин Хасияткә баш булсаммы? Тырпылдатмас та идем мин аны. Авызын да ачтырмас идем! Райкомнан күпме кирәк комбайнны каерып алган булыр идем дә бүгенге көндә, әнә Гаяров кебек, рәхәтләнеп йоклап ятар идем. Яки мунча кереп, майлы коймак ашап утырыр идем. Мин баш түгел, шунысы харап итә. Ә синең урының зур бит! Чакырып китер дә приказ бир, үтәмәсәләр, выговор чәпеп куй! Алар каршында җебеп торалар димени! Шуларның арбасына утыралар димени!
Фидаяның бит очлары салкын яңгыр астында пешеп чыкты. Бу ни дигән сүз инде тагын? Әллә Рәсимәгә берәр гайбәт килеп ирешкәнме? Аның бу шиген раслагандай:
— Ул Мирхуҗин ишеләр белән каберең якын булмасын! — дип өстәде Рәсимә. — Кеше сүзен тыңлый торганмыни ул! Әгәр ирләр безнең сүзгә колак сала торган булса, тормыш бөтенләй бүтәнчә булыр иде. Бу дөнья хатын-кызлар сыртында бара, ә эшләгән данын ирләр ала. Менә күрерсең, больницаны мин төзедем дип, Мирхуҗин түшен киереп йөриячәк, сине искә алучы да булмас. Белеп тор.
Туктамый яуган яңгырга, сазга баткан комбайннарга бик кәефе кырылган иде Рәсимәнең, үз күңелендә дә бозлы яңгыр ява башлаган кебек иде. Һәм аның сүзләре, карлы-бозлы җил булып, Фидаяның бәгыренә өргәндәй итте.
Шуннан соң аңа кире борылып кайтып китәргә кирәк булгандыр. Шулай итсә, ак сакаллы карт булган булыр иде дә бит, ләкин безнең кайсыбыз дусларның акыллы киңәше белән генә йөри соң?
Фидая да, чая хатын белән тизрәк саубуллашып, машинасына кереп утырды һәм юлын дәвам итте.
Элегрәк килгән чакларда, яңа хастаханәнең ак кирпеч диварларын күрүгә, аның кәефе күтәрелә торган иде. Ләкин соңгы айда килгән саен күңел төшә башлады, чөнки, август ахырында төзү отряды китеп барганнан соң, биредә хәрәкәт туктады. Эшнең зурысы эшләнгән, бина түбә астына кергән, штукатурланган иде инде югыйсә. Ишекләрен куясы, буйыйсы, идәннәренә линолеум җәясе... Үз җае белән барыр иде, әгәр дә Мирхуҗин бригаданы даими җибәреп торса. Ләкин юк, юк... аннан мөһимрәк эш күп, дип, сылтавын табып тора. Искәндәровны да үзенә ышандыра.
Тик Фидаяга гына ашыгырга кирәк. Бу урында утырганда, яңа бинаның ишеген беренче булып үзе ачып керергә тели ул! Ә күңеле сизә: урынында аны озак утыртмаячаклар. Рәсимә да шуңа ишарә ясады. Нишләргә? Кем ярдәм итәр аңа?
Ул хастаханәгә кергәндә, халат кигән Билал үз бүлмәсендә утыра иде. Кулында китап. Машина тавышын да ишеткәндер, Фидаяның килгәнен дә белгәндер, мөгаен, ләкин каршы да алмый, чыгып та карамый. «Бөтенләй санга сукмый башлады», — дигән уй узды кызган баштан.
— Исәнмесез, Фидая Госмановна.
— Саумы. Ни эшләр майтарып ятасыз?

— Операциягә әзерләнәбез менә. Шактый катлаулы очрак. Китап актарып, белгәннәрне искә төшерми булмас.

— Ә төзелешне тәмамларга кирәге исеңә төшмиме синең? Аны бөтенләй оныттыңмы инде?

— Һәркем үз эшен эшләргә тиеш, Фидая Госмановна! Врач дәваласын, ә биналарны төзүчеләр салсын. Ник Мирхуҗиннан ныгытып таләп итмисез?!

Соңгысында пычрак бер киная ишетелгән кебек булды, Фидаяның җәберләнгән күңеленнән ярсу ташып чыкты. Ул алга таба атлады да, кизәнеп, Билалның яңагына сугып җибәрде. Тагын, тагын... Әгәр шунда кулында камчы булса... Камчы булса...

Билал гаҗәпләнүеннән хәрәкәтсез калган иде, читләшмәде дә хәтта. Шул мизгелдә арттан:

— Ни булды? Нишлисез сез монда? — дигән тавыш ишетелде.

Ишек төбендә Гөлфия басып тора иде.

Фидая, аны этеп, тышка атылды, машинасына чыгып утырды да Балкышка:

— Кайтабыз, — диде.

«Нишләдем мин? Нишләдем?»

Аның үз гомерендә бер мәртәбә дә кул күтәреп кешегә сукканы юк иде. Киноларда хатын-кызның ир-атны яңаклаганын күрсә дә, гаҗәпләнү катыш чиркану хисе генә кичерә, ир кеше моңа ничек түзеп тора, нишләп ул хатынны селтәп атмый икән, дип уйлый иде.

Тависка тиешле тукмау бөтенләй башка берәүнең яңагына төште...

Кичен, райкомга сугылып, ул-бу юкмы дип белешеп чыксаң да ярый бит ул, ләкин Фидая бу рәвешле гасабиланган хәлендә кеше күзенә күренеп йөрергә теләмәде, туры өенә кайтты. Шәрифә карчык Иркәгә китап укып утыра иде, килене кайтуга кузгалып чыгып китә алмады. Фидая, өстен алыштырып, бер чынаяк чәй генә эчте дә нишләргә белми әрле-бирле тулганды. Чыдарга кирәк иде, әмма ул түзмәде, телефонга тотынды. Тависның өенә шылтыратты.

— Әгәр син иртәгә Кармашка бригада җибәрмәсәң... — диде дә тукталып калды. Нишләтә ала ул бу бәндәне? Рәсимә әйткәнчә, каты шелтә бирдерергә дисәң, анысын да өченче секретарь үзе генә булдыра алмый, Беренченең шундый теләге кирәк.

Тавис бераз көтеп торды да тыныч кына:

— Син миңа янамакчы буласыңмы әллә, Фидая Госмановна? — диде. — Куркыр дип уйлыйсыңмы әллә? Курка торган туннар күптән тузган инде безнең. Алдырсаң, мине яхшылык белән генә алдырып була, шуны белеп тор.

Шулай диде дә трубканы куйды. Шунда гына Фидая аңына килде: ә бәлки, Тавис янәшәсендә хатыны тыңлап торгандыр?

Урамда машина килеп туктаганы ишетелде. Фидая кече бүлмәгә керде дә, утны яндырмый гына, пәрдәне күтәреп карады. Каршы якта «уазик» тора, аның каршына чыгып, берәү капотны ачкан иде — таныш сын!

Ник син монда туктадың? Ярамый! Ярамый!

Фидаяның күңелендә Каләмгөлнең күрәзәлек иткәндә әйткән сүзләре яңарды: «Ул синең каршыңа килер. Синең күзләрең аны күреп туймас, һәр күзәнәгең аңа омтылыр, кулларың аңа сузылыр, алар синең акылыңа буйсынмас...»

Фидая ихтыярсыздан борылды, аяклары ишеккә таба ашкынды. Шунда зал ягыннан:

— Әни! — дигән иркә тавыш ишетелде. — Әни, кил әле монда! Әби яңа әкият укый!..

Фидая, сөртенгәндәй, бусага янында тукталып калды.

Күпмедер вакыттан соң, колакны шаулатып, машинаның кузгалып киткәне ишетелде.

...Давыт туры гына кайтып китмәде. Күңел нидер көтә, нәрсәдер өмет итә иде. Каршы якта зур тәрәзәләре белән балкып торган ресторанга кереп утырды ул. Таныш-белеш очрады, әңгәмә куерды, күңелнең алгысавы басылып ук бетмәсә дә, зиһен ачылды.

Иртәгесен иртүк авыл хуҗалыгы идарәсеннән Мөҗәһит Сәлахов, шылтыратып, гаҗәпләнү катыш шелтә белдерде:

— Бер көн эчендә савымны дүрт йөз литрга киметкәнсез, ничек алай килеп чыкты ул? — диде.

Кичке якта председатель фермага бармаган, малларны тиешенчә ашатуны кайгыртып йөрмәгән, менә шуннан килеп чыккан иде бу. Яңгырлар башлангач, бу мәсьәләдә аеруча уяу булырга кирәк шул.

Тормыш үз агымы белән бара һәм адәм балаларын да үз җаена сала иде.

## 43

Рәсимәнең кисәтүе бер дә юкка булмаган икән. Башка тукмак килеп тә төште.

Иртәнге киңәшмә тәмамланып, халык таралыша башлагач, Җәгъфәр Латыйпович:

— Фидая Госмановна, сез калыгыз әле, — диде.

Беренчегә әйтер сүзе булган кайберәүләр тоткарланмакчы иделәр дә, моны ишеткәч, чыгып китү ягын карадылар.

Искәндәровның авыр башын иеп утыруыннан, бераз күтәрелгәч күзлеге сәер елтыраудан Фидаяның йөрәге жу итте. Белеп сизенгән икән, Җәгъфәр Латыйпович тирән итеп сулыш алды да:

— Хәлләр шәптән түгел әле безнең, Фидая Госмановна, — диде. — Жалу килде синең өстән.

Фидая дәшмәде.

— Ник сорамыйсың, ни турында дип?

— Үзегез әйтерсез әле, — диде Фидая.

— Берәү генә булса, ничектер йомып калырга да булыр иде, — диде Җәгъфәр Латыйпович, — моннан бер ай чамасы элек килгән анонимканы ерагракка салып куйган да идем. Анысы финанс кагыйдәләрен бозу турында. Аларны ничек бозганыңны үзең дә беләсеңдер инде.

— Беләм, — диде Фидая. — Төзелештә андый хәлләр була инде.

— Андагы эшчеләрне эчереп яткыру ник кирәк иде сиңа? Хатын-кыз эшеме ул? Син бит прораб түгел! Хөкүмәтнең акчасына дип язганнар монда.

— Ревизор чакырыгыз. Тикшерсеннәр. Эчерсәм дә, мин аларны үз акчама эчердем, — диде Фидая.

— Димәк, эчердең? Яшерер идең, ичмасам. Нахак бәла ягалар, дияр идең. Үзең әйтеп торгач, бу хатны мин ничек йомып калыйм инде?

Искәндәров өстәл тартмасының эченнәнрәк канцелярия каптыргычлары белән конвертларына беркетелгән ике хат тартып чыгарды.

— Икенчесе менә имзалы да, хәтәррәк тә. Кеше гаиләсен бозуда гаеплиләр сине, иптәш Нурханова. Кем язганын беләсеңдер инде?

— Беләм, — диде Фидая. Ул Мирхуҗинның хатынын күздә тота иде.

— Әйтәм аны Кармаш юлыннан эзеңне суытмыйсың, — диде Җәгъфәр Латыйпович. — Йөрәгең шул тарафка җилкенә икән. Ә мин сине чынлап торып төзелеш өчен янып йөрисең, дип уйлаган идем тагын. Ул Билалны шундый дип кем уйлаган! Гөлфиясе бер тотам да үзеннән читкә җибәрми, диләр бит югыйсә.

— Билал белән Гөлфиянең ни катышы бар монда? — дип сорады Фидая аптырап.

— Хатны кем язганын беләм, дисең бит. Күңелең кемгә тартканын да беләсеңдер. Гөлфия язган синең өстән. Мә, укы!

Мәктәп баласыныкы кебек тигез, пөхтә хәрефләр белән язылган хатның эчтәлеге бик усал иде. Фидаяның хәтеренә сүзгә-сүз сеңеп калмады, әмма: «Нурханованың, югары эш урыныннан намуссыз рәвештә файдаланып, баш табибны, төп эшеннән аерып, бик еш кына үзе белән алып чыгып китүе, аның белән төнлә машиналарда утырып йөрүе, ахыр чиктә, баш табиб аның белән араны өзәргә теләк белдергәч, авырулар күз алдында сугышуы...» — тәфсилләп язылган иде.

— Аның ишене кылсаң да, кешегә белдермиләр аны, — диде Искәндәров башын иеп. — Без халык алдында көзге кебек ялтырап торырга тиеш.

— Мин эштән китәргә гариза язармын, — диде Фидая.

Җәгъфәр Латыйповичның: «Ярый, бу юлга зурга җибәрмик, киләчәктә аң бул», — кебегрәк сүз әйтмәсме дип өметләнгән иде, әмма Беренче шундук аның бу сүзен тотып алды.

— Шуннан башка чара калмый инде болай булгач, — диде. — Адәм ышанырлык сылтау тап та, шома гына ычкын. Ронодан берәр мәктәпкә направление бирерләр. Кайсы авылга барасың килә, әйтерсең.

— Ераграгына инде, — диде Фидая.

— Уку елының башы гына, мәктәпләрдә сәгатьләр бүленеп беткән. Эшен табу да җиңел булмас, мөгаен.

— Кайбер мәктәпләргә пионервожатыйлар кирәк әле, — диде Фидая. Шундый тыныч тавыш белән әйтте ки, аның үзе хакында түгел, бөтенләй башка берәү турында сүз бара диярсең.

Искәндәров урыныннан кузгалды да бүлмәне әйләнеп килде.

— Хатын-кыз күп вакытта менә шуның аркасында харап була шул инде ул, — диде. — Үзенә-үзе хуҗа була белми, бөтен хикмәт шунда. Дөнья бәһасе кеше бит син югыйсә. Чибәрлек дисеңме, акыл дисеңме, уңганлыкмы — бөтенесе бирелгән... Тыныч кына эшләсәң, югарырак күтәрербез, Казанга ук җибәрербез, дип уйлап йөри идем әле мин. Мондый койрык тагылгач, мантый алмыйсың шул инде. Кызганыч...

Ул шулай уфтанып калды, Фидая, үз бүлмәсенә чыгып, тизрәк гариза язу ягын карады.

Атна ахырында мәсьәләне бюрога куеп, «райкомның өченче секретаре Нурханованы шәхси үтенече буенча эшеннән азат итәргә» дигән карар чыгарып та куйдылар. Бу очракта тимерне кызуында сугарга кирәк иде, чөнки озакка сузган саен, районда сүз күбрәк үрчи, тәмсез исе ныграк тарала.

Нурханова бюро утырышына иңерактагы Саеккүлдән килде. Чөнки ул алдан ук шул авылның башлангыч мәктәбенә укытучы булып урнашкан иде инде.

Китәр алдыннан, кичен, ул, кызы белән бергәләп, бакчаны карап чыкты. Яфраклар коелган, ул утырткан карлыган, кураларның зәгыйфь сабаклары гына тырпаеп тора. Гөлләрне кырау көйдергән, тик тәбәнәк бәрхет гөлнең кызгылт сары чәчкәләре генә чекерәеп утыра. Алар кырауларга тиз генә бирешми шул. Фидая, иелеп, берничә сабагын өзеп алган иде, Иркә:

— Әни, гөлләргә тияргә ярамый бит, — диде.

— Хәзер ярый инде, кызым. Алар өстенә барыбер кар явачак.

Балкышның машинасы капка төбенә килеп туктаган иде инде. Фидая берничә төенне аның багажнигына китереп салды. Зур әйберләрне бер җае чыккач йөк машинасы белән килеп алырга дип, алдан ук ниятләп куйган иде ул. Кызын алып, арткы утыргычка кереп утырды.

Зират турыннан узганда, машинаны туктатты. Чардуганнар арасыннан йомшак яшел чирәмгә басып барды да зәңгәр тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган, бер башына мәрмәр таш куелып, уртасында яшь нарат үсеп килгән калкулык янында туктады, кызгылт сары чәчкәләрне таш янына куйды. Аннары, салкын рәшәткәгә тотынып, хәлсезләнеп башын иде.

— Минем тормышым тагын асты-өскә әйләнде, Мәгъсүм, — диде. — Мин моннан китәм. Шунысы кызганыч, морадыма ирешеп булмады, хастаханәне эшләтеп җибәрергә өлгермәдем. Ләкин диварлары тора, түбәсе ябылган. Инде миннән башка да очлап чыгарлар. Башка һичкем синең язмышка дучар булмасын иде инде. Эшне төгәлләп бетерә алмавымда минем гаебем юк, моны бер син генә беләсең. Рәнҗемә миңа. Кичер мине...

Бу сүзләр аңа бик гади кебек тоелды. Күзаллап булмый торган аңлашылмас караңгы мәңгелектәге иң газиз кешеңә әйтү өчен, кылганнарыңны, ирешкәннәреңне сөйләп, гөнаһларыңны ярлыкавын үтенер өчен җыр кебек моңлы, көйле башка сүзләр кирәк иде шикелле. Тик Фидая андыйларны таба алмады, зәңгәр рәшәткәгә ачы күз яшьләре генә тамды.

## 44

Давыт, йокламаган да шикелле, кинәт күзен ачты. Гүяки аның кабыргасына сискәндергеч итеп кемдер төрткән иде. Шундук аның миен бер уй ярып узды: «Без көрешә алмаячакбыз...» Йокыдан бераз айныгач, ул тынычлана төште, ләкин сагышлы уй тынгы бирмәде: «Көрешә алмабыз, ахрысы...»

Тып-тын, сәгать биш тә тулмаган икән әле. Тышта чалт аяз, салкын, нык кырау төшкән. Бөтен дөнья тынып, басынкыланып калган, фәкать Давытның гына күңелен тынгысызлык биләп алган кебек иде.

Ул нәрәт бирергә гадәттәгедән алда барып утырды, сүзне кыска тотты. Аннары кайтып чәй эчеп алды да, машинасына утырып, район үзәгенә китте.

Ул райкомга килеп кергәндә, сәгать тугызынчы киткән, һәммә кеше үз урынында, тик Нурханованың гына ишеге бикле иде. Кая да булса чыккан дияр идең, йозакта ачкычлары да эленеп тормый.

«Кармашка киткәндер...»

Давыт күңеленнән хастаханәгә бару өчен берәр сылтау эзләде. Билал белән сөйләшер сүз табылыр әле. Юлда барганда һаман бер сорау тынгы бирмәде: үзе генә микән, әллә Тавис беләнме?

Кармаш урамын узып, хастаханә үренә борылгач ук, капка төбендә ике машина торганын күреп алды. «Жигули»лар. Нурханованың «уазигы» юк. Башка берәүгә утырып килде микәнни?

Хастаханәнең бинасы кояшта яктырып, ерактан ук күренеп тора иде. Капка төбендә машинадан төшеп, иске бинаны әйләнеп узгач, Давыт, яңасы янына килеп, агач исе, буяу исе сеңгән һаваны күкрәк тутырып сулады. Яңа торгызылган бина янында кеше үзен үсеп киткәндәй, тәненә гайрәт, җанына яктылык иңгәндәй тоя шул.

Давыт ишекне ачты. Эчтән, буш коридорда яңгырап, сөйләшкән тавышлар ишетелде. Диварлары штукатурланган, әмма әле буялмаган, түшәмнән шәрә лампочкалар асылынып торган коридорның аргы башында кара костюмлы дүрт ир кеше, һәм алар янында ак халатлы берәү күренде. Халатлысы баш табиб Газимов, уртадагысы Мирхуҗин, калганнарын Давытның моңарчы күргәне юк иде. Ул, ботинкаларын шакылдатмаска тырышып, төркемгә таба китте.

— Район җирендә мондый зур бинаны бер ел эчендә торгызып кую җиңел түгел, — дип сөйли иде Мирхуҗин, көр тавыш белән. — Бөтен көчне шуңа салдык. Бөтен резервларны шушыңа юнәлттек. Республика җитәкчеләренә дә, министрлыкка да мең рәхмәт, бик нык ярдәм иттеләр.

Давыт, Билал янына барып, кул биреп исәнләште дә, пышылдап:

— Кемнәр бу? — дип сорады.

Баш врач, аяк очларына басып, аның колагына үрелде:

— Казаннан килгәннәр. Министрлыктан.
— Бинаны кабул итү комиссиясеме әллә?
— Жалу тикшерәләр.
— Нинди жалу?
— Нурханова өстеннән.
— Нәрсә турында?
— Җыен юк-бар шунда. Имеш, төзелеш тирәсендә урлашканнар, эчеп ятканнар, бозыклык кылганнар. Андый кәсепкә керешкән кеше сүзен таба инде ул.
Давыт Билалның халат җиңеннән эләктереп читкәрәк тартты.
— Кем язган?!
— Анонимка, диләр.
— Анонимка артыннан Казаннан ук килгәннәрме?
— Партиянең сәясәте шундый бит. Бер генә сигналны да игътибарсыз калдырмаска. Тикшерегез, чара күрегез дип, тыкырдатып торучылар бардыр, күрәсең.
— Нурханованың дошманнары шулхәтле күп микәнни? — дип шаккатып сорады Давыт. — Кемгә зыяны тиде икән?
— Дошмансыз кеше буламыни? Бигрәк тә мондый эшләр майтарып йөргәндә.
Билал күзе белән коридорны айкагандай итте.
— Үзе кая соң әле ул? — дип, тавышын калтыратмаска тырышып сорады Давыт.
— Фидая Госмановнаны әйтәсеңме? Киткәндер инде ул.
— Кая?
— Син белмисеңмени? Кичә бюро утырышы булды бит. Аны эшеннән азат иткәннәр. Ул инде алдан ук Саеккүлгә эшкә урнашып куйган, ди Гөлфия. Болар да монда кычытмаганны кашып йөриләр. Казанда да берсе нишләгәнне икенчесе белми. Партия өлкә комитетына шылтыратып сөйләшсәләр, килеп йөриселәре дә булмас иде. Ә килгәч, тикшерәләр инде, нишләсеннәр.
— Бусы нәрсә? — дип сорады берсе. Төркем коридорның аргы очында туктаган, барысы да, башларын иеп, идәнгә карап торалар иде. Анда төсле рәсемнәр тезелеп ята икән. Шаян, мәзәк итеп ясалган куян, төлке, аю сурәтләре.
— Бу шул Нурханованың эшчәнлеге инде, — диде Тавис, бала-чаганың шуклыгы турында сөйләгәндәй көлемсерәп. — Хастаханәнең стеналарын бизәргә сурәтләр ясаткан, имеш. Хатын-кыз бала-чага белән бериш бит ул. Ирләр җиң сызганып бетон актарганда, ул менә шушындыйлар белән уйнап утыра. Аннары, мин төзедем, мин булдырдым, дип мактанып йөри. Басудан кайткан үгез мөгезендәге чебен дә, көн буе җир сөрдек без, дип әйткән, ди бит. Шул инде.
Давыт, үзен-үзе белештермичә, алга ыргылды. Ләкин Тависка кулы җитмәде, күкрәге белән Билалга килеп бәрелде.
— Син нәрсә? — диде табиб, каты ысылдап. — Скандал чыгармакчымы әллә монда? Фидая Госмановна турында тагын гайбәт үрчесен дисеңме әллә?
Фидая исемен ишеткәч, Давыт тынды. Билал аны кире якка әйдәде. Тышкы ишектән, аларга каршы, муенына озын кызыл шарф таккан хатын-кыз килеп керде. Култык астына каты коңгырт кәгазьгә төрелгән такта кебек әйбер кыстырган.
— Исәнмесез.
— Исәнмесез. Сез... лесхоздан бит?
— Минме...
Давыт зиһенен тупларга тырышты.
— Ә-ә, сез — рәссам кыз. Узган елны күргәзмә белән килгән идегез. Миңа картина да бүләк иттегез. Аның үрнәгендә маркетрилар ясыйлар анда. Лесхозга керсәгез, берсен үзегезгә дә бүләк итәрләр.
— Анда ук барып йөреп булмас шул, — диде Рамилә моңаеп. — Мин монда танышыма ияреп кенә килдем бит. Алар машинасы белән. — Ул коридорның аргы башындагы төркемгә күрсәтте. — Бер көн эчендә барып кайтабыз, диделәр. Фидая Госмановна күптән чакыра иде инде. Озакламый стеналарны буйый башлыйбыз, дигән иде. Ә ул киткән икән. Килүем яхшы булды әле, белеп китәм, югыйсә мин анда һаман эскизлар ясап ята идем.
— Эшләгез, эшлә, — диде Билал. — Элегрәк җибәргәннәрегезне Фидая Госмановна безгә калдырып китте. Мин әнә аларны үзебезнең осталарга күрсәтергә әзерләп тә куйган идем. Бөтенесен ясатабыз! Яңаларын да алып килдегезме әллә? — дип, Рамиләнең култык астындагы төргәккә ымлады ул.
— Юк, бусы башка. Фидая Госмановнаның портретын ясаган идем.
— Яле, карыйк әле! — диде Давыт.

Рамилә төргәкне чиште.

Гади генә ак кысадан Давытның күзләренә Фидая тутырып карап тора иде. Рәссам аны иртәнге кояш яктысына охшаш алтынсу нурлар белән яктыртып, эре алтын бөдрәләрен түгәрәк йөзе тирәсендә серле бөҗра итеп тасвирлаган. Нindидер яхшылык көтеп, өмет белән караган зәңгәр күзләренең төбендә яшерен моң, ялвару да бар кебек.

Давыт рамга тотынды.

— Сатыгыз миңа. Күпме тора?

Рамилә картинаны үзенә тартты.

— Фидая Госмановнаның үзенә бу. Бүләк. — Аннары Билалга борылды да: — Өлкән медсестрага биреп калдырмакчы идем. Бер җае чыкканда тапшырыгыз әле, дип. Алмый, — диде ул гаҗәпләнеп. — Үз кулың белән бир, ди. Ничек бирим? Без хәзер китәбез бит.

— Калдырыгыз миңа, — диде Билал. — Тапшырырмын.

— Минем тормышымда бик зур роль уйнаган кеше ул, — дип, картинаны кире кәгазьгә төрә-төрә сөйләнде Рамилә. — Аның белән очрашканнан соң, мин үз тормышыма өр-яңача карадым. Күзләрем ачылгандай булды, кешеләрне бөтенләй башкача күрә башладым. Ул чакта без ирем белән аерылышкан идек. Бүтән кавышмабыз, дигән идем. Моннан кайткач, фикерем үзгәрде. Яңадан кушылдык... Кунакка чакыра, диегез. Мин аңа үзем язып та җибәрермен, билгеле...

— Сез аңа портретның да яңасын ясый аласыз бит, — диде Билал, яңа фикергә килгәндәй тәвәккәл тавыш белән. — Ә монысының артына «Кармаш участок хастаханәсенең яңа бинасы ачылу уңае белән бүләк итәм» дип язып бирегез әле. Мин аны шушында элеп куям. Фидая Госмановнага багышлап, аерым бер почмак ясаячакбыз без монда. Күрсеннәр, укысыннар, бу бинаны кем торгызганын һәммәсе белеп торсын. Онытылырлык булмасын!

...Кире кайтканда, Давытның күңеле алгысыган, каядыр барасы, нидер эшлисе, нindидер гадәти булмаган бер мохиттә каласы килә иде. Юл кырыеннан буш басулар, яфракларын койган агачлыклар шуып бара. Әнә шәрәләнеп калган каенлык, аның артында сабан туен үткәргәч табын корган аланлык. Ул чакта каеннар тармакларын аска ук игән, аланлыкны юлдан күренмәслек итеп ышыклаган иде. Һәм шул яшел пәрдә артыннан һич уйламаганда, гүзәллек алиһәсе булып, җанга газиз бер сын пәйда булган иде.

Хәзер инде аны читтән генә күрүләр дә насыйп булмастыр...

Давыт машинасын басу юлына борды, каенлык янында туктатты да, чирәмлек аша таллыкка узды. Талларның яфраклары куырылган, әмма коелып бетмәгән, алар һаман кизләүне ышыклап торалар иде. Давыт үлән-керфекләр арасыннан яшьле күз кебек мөлдерәгән чокырга иелде. Кушучлап су алды да йөзен шуңа батырды. Бозлы су битне өтеп алгандай итте. Әллә җирнең күз яше белән юынды ул, әллә үзенең күз яшьләре белән...

Озакламый кыш килер, җир туңар, бу кизләүне дә кар каплар. Алда салкын бураннар, алда ямансу көннәр көтә иде.

Аяк табаны белән ул җирнең суына башлаганын, анда тамырлар хәрәкәтенең тына барганын тоя иде кебек. Шул ук вакытта тәнгә сарылган бу суык күздәге яшьләрне киптерә дә иде сыман. Әйе, җиһанга кыш килә, үзе белән салынкы болытлар, җил-давыллар, кар-бозлар алып килә. Җир кышка әзерләнә, ләкин шул ук вакытта язның киләсен дә онытмый иде. Ул үз куенында бихисап тамырларны, орлыкларны тере килеш саклый. Вакыт җитәр, алар һәммәсе җанланыр. Гөлләр сабагын югарыга сузар, керфекләрен киң ачып кояшка карар. Әмма, бәбәгенә кояш нурын җыеп, үзәгендә тылсымлы җылы саклый белгән гүзәл бер чәчәк Давыт өчен башка ачылмас. Безнең өчен генә үскән гөлнең чәчәкләре, бер коелгач, яңадан ачылмый шул.

Һәм... безнең баш очыннан бер агылып узган болытлар да кире әйләнеп кайтмыйлар.

*1984–1987, 2005 еллар*

**Автор турында белешмә**

Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстанның Сарман районы Мортыштамак авылында колхозчы гаиләсендә туган. Үз авылларында җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1949–1954 елларда — Минзәлә педагогия училищесында, аннары Казан педагогия институтында укый. Институтның тарих-филология факультетын кызыл диплом белән тәмамлап, 1959–1964 елларда «Чаян» журналында корректор, 1964 елдан «Азат хатын» журналында әдәби хезмәткәр, ә 1978 елдан 1987 елгача журналның җаваплы секретаре булып эшли. 1989 елны ул Татарстан Язучылар берлегенең рәис урынбасары итеп сайлана. 1993 елдан — Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыятенең президенты.

Узган гасырның 70—80 нче елларында 400 меңнән артык тираж белән басылган «Азат хатын» журналында Мәдинә Маликованың очерклары, сәнгатькә, әхлак темаларына багышланган язмалары киң яңгыраш таба, журналда басылган беренче хикәяләре, повестьлары укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. 1967 елда чыккан «Юлдашлар» исемле беренче хикәяләр җыентыгында ук ул укучы алдына тирән әхлакый мәсьәләләрне җитди итеп куярга омтылуы белән игътибарны җәлеп итә. Һәм бу омтылыш аның озын гомерле иҗади эшчәнлегендә төп сыйфат булып кала. Авторның «Кар сулары», «Сары тюльпаннар», «Көндәшләр», «Ай сүрелгән чак иде», «Узма, гомер!» һәм башка хикәяләре моның ачык мисалы булып тора.

Язучының «Казан каласы — таш кала» (1967), «Кояш күпере» (1973), «Янар таулар яктысында» (1977) повестьлары, «Шәфкать» (1985), «Басып сайрар талы бар» (1987), «Фидая» (1990) романнары шәһәр һәм авыл интеллигенциясе — инженерлар, архитекторлар, рәссамнар, врачлар, артистлар тормышына багышлап язылганнар.

Халык язучысы Аяз Гыйләҗев үзенең бер чыгышында Мәдинә Маликованы «зыялы язучы» дип атаган иде. Чыннан да, зыялылык язучы иҗатының бөтен рухында чагыла. Ул, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, геройларының рухи дөньясын бөтен тирәнлеге белән яктыртырга, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрнең нечкәлекләрен ачарга омтыла, яшәешнең мәгънәсен яхшылыкка, матурлыкка хезмәт итүдә күрә. Мәдинә Маликова сюжетны оста, мавыктыргыч итеп кора белә, вакыйгаларны йөрәк аша үткәреп, укучының күңел кылларын тибрәндерерлек итеп тасвирлый.

М.Маликова детектив жанрында да уңышлы эшли. Аның «Хөкем» (1969), «Августның бер кичендә» (1970), «Адашканга юл кайда» (1971), «Югалган якутлар» (2003) исемле маҗаралы повестьлары, жанр хасияте таләп иткәнчә, киеренке вакыйга-сюжетка корылган һәм укучылар тарафыннан яратып укыла.

М.Маликова үзенең әсәрләрендә башлыча хәзерге заман тормышын тасвирлый һәм бүген дә шушы юнәлештә иҗат итә. «Алтын ятьмә» (2001), «Мендем биек тауларга» (2003) повестьлары, «Кыргый дивизия» һәм башка хикәяләре (2001), «Өермә» исемле детектив романы (2002), «Чәчкә балы» повесте (2004) гасырлар алышынган чорда булган кискен үзгәрешләрнең кеше язмышына, аның рухына һәм үз-үзен тотышына йогынтысын тасвирлый.

Мәдинә Маликованың драматургия өлкәсендә дә уңышлары күп. Аның «Оҗмах балалары» (1989) исемле драмасы Г.Камал исемендәге Академия театры сәхнәсендә куелды. «Йөрәк ничек түзсен» (1989), «Моңнар төште башыма» (1992), «Синең өчен үзем үләрмен» (1994) исемле драма әсәрләре Минзәлә һәм Әлмәт театры сәхнәләрендә зур уңыш белән барды. «Сөембикә» трагедиясе (2003) 2004 елда уздырылган «Яңа татар пьесасы конкурсы»нда бүләккә лаек булды.

Мәдинә Маликова — Татарстанның (1976) һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты (1980).

Мәдинә Маликова — 1972 елдан Язучылар берлеге әгъзасы, 1974 елдан 1999 елгача Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, озак еллар «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы булып торды. 1989–1990 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәис урынбасары булып эшләде.

*Татарстан Язучылар берлегенең белешмәләр китабыннан*

**Эчтәлек**

Кызыл гөл. *Роман*

Фидая. *Роман*

Автор турында белешмә

Литературно-художественное издание

Мадина Маликова
(Маликова Мадина Габдулхаковна)

# Красный цветок

Романы
(на татарском языке)

Мөхәррире *В.Р.Шәрипова*
Рәссамы *А.Р.Таһирова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Т.В.Гредюшко*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.Х.Сундукова, Л.З.Шиһапова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.09.2005. Форматы 84г108 1/32.
Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 21,84 + фор. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 22,79.
Нәшер-хисап табагы 24,61 + фор. 0,36. Тиражы 7000 д. Заказ А-665.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
ГУП Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

ААЖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.